**ФӘНИС ЯРУЛЛИН**

# ӘСӘРЛӘР

Өч томда

**III** том

*Әкиятләр, әкият-пьесалар, повестьлар, хикәяләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2008

УДК 821.512.145-2:3
ББК 84 (2 Рос=Тат)-4:6
Я74

РЕДКОЛЛЕГИЯ:

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин, И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Р.Х.Корбанов, Х.Г.Әюпов*

**Яруллин Ф.Г.**

Әсәрләр: 3 томда / Фәнис Яруллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — ISBN 978–5–298–01617–9

3 т.: Әкиятләр, әкият-пьесалар, повестьлар, хикәяләр. — 2008. — 431 б. — 2000 д. — ISBN 978–5–298–01671–1

Татарстанның халык шагыйре, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәнис Яруллин әсәрләренең бу томына аның балалар өчен әкиятләре, пьесалары, повесть һәм хикәяләре тупланды.

ISBN 978–5–298–01671–1 (3 т.)
ISBN 978–5–298–01617–9

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© ЯРУЛЛИН Ф.Г., 2008

# Әкиятләр

## ЙОЛДЫЗ ТАПКАН КЫЗ

Зур да түгел, кечкенә дә түгел, ярлы да түгел, бай да түгел гап-гади авылда яшәп яткан, ди, үзенең карт әбисе белән бер кыз. Кызның исеме Таңсылу икән. Таңсылу әле бик кечкенә булган, үзенең ничә яшьтә икәнен дә белмәгән. Хәер, ничә яшьтә икәнен генә түгел, бик күп нәрсәләрне белмәгән әле Таңсылу. Ә беләсе килә икән. Шуңа күрә ул әбисенә көн саен сорауларның мең төрлесен яудырып торган. «Әбием, мине каян алып кайттың? Әбием, минем исемем ни өчен Таңсылу? Әбием, тауларны кем өеп куйган? Әбием, нигә төнлә караңгы, көндез якты була?»

Менә шундый сорауларны тезеп кенә торган Таңсылу. Ә әбисе аның сорауларына җавап биреп өлгерә алмаган. Андый чакларда кочагына кысып: «Менә, кызым, тиздән үсеп җитәрсең, гыйлем дәрьяларын кичәрсең, кайгы-шатлык чишмәләренең суын эчәрсең — шул чагында бөтенесен үзең төшенерсең», — дип юата торган булган. Кызның тизрәк үсәсе, бар нәрсәне аңлыйсы килгән. Тизрәк үссен өчен әбисе Таңсылуга тәмле-тәмле ризыклар пешергән, һәр көнне зәңгәр күлдә коендырган. Коенып чыккач, Таңсылу күл-көзгегә карап чәчләрен тараган.

— Әбием, мин нинди матур! — дигән кыз, үзенең күлдәге чагылышына сокланып.

— Үз-үзеңә сокланырга ярамый, кызым, — дигән әбисе.

— Нигә? — дип сораган Таңсылу.

— Үзенә сокланып яшәгән кешеләр бик тәкәббер була. Башкаларның матурлыгын, яхшылыгын күрми башлый, кызым.

— Ә мин, әбием, тәкәббер булмам. Мин бит үземә генә түгел, сиңа да сокланам. Кил әле, минем яныма бас әле! Менә бит син нинди матур, әбием. Күзләрең зәңгәр чәчәккә тамган тамчы кебек җем-җем итә. Синең йөзеңдәге җыерчыклар кебек матур җыерчыклар беркемдә дә юк. Мин сине бик яратам, әбием!

Әби белән кыз бик бәхетле яшәгәннәр. Кыз ай үсәсен көн үскән, ел үсәсен ай үскән.

Менә шулай бәхетле генә яшәп ятканда, Таңсылуның әбисе авырып киткән: тамагына ашамаган, төннәрен йокламаган. Докторлар чакырып караганнар — аларның да ярдәме тимәгән.

— Әбием, — дип өзгәләнгән Таңсылу, — әгәр белсәң әйтче: син терелсен өчен миңа нишләргә?

— И балам! Син нәрсә генә эшли алырсың икән соң? Әнә духтырлар да минем чиремә дәва таба алмады бит.

— Ә мин табармын, — дигән Таңсылу, үзсүзлеләнеп. — Мин сине барыбер терелтәчәкмен, әбием.

Таңсылу әбисенең битләреннән, чәчләреннән сыйпаган. Тәмле-тәмле ашлар пешергән, төрле-төрле җимешләр салып чәй кайнаткан. Әмма әбисе һичбер нәрсәгә кагылмаган.

— Аша инде, әбием, ашасаң терелерсең, — дип кыстаган Таңсылу.

— Кыстама, балам, — дигән әбисе, — бер ризыкны да күңелем тартмый. Тик менә...

— Нәрсә, әбием?

— Юк, балам, юк...

Әбисенең нидер әйтергә теләп тә әйтеп бетермәвен сизгер күңелле кыз бик тиз аңлап алган.

— Син нидер әйтергә теләдең, әбием, әйт, — дигән кыз.

— Тел нәрсә әйтергә теләмәс, балам.

— Әйт инде, әбием. Әллә берәр нәрсә ашыйсың киләме?

— Әй, балам, бу тамакны әйтер идем, юк нәрсәгә нәфесен суза шунда.

— Ни соң ул, әбием, әйт инде.

Әйтергәме, әйтмәскәме дип озак кына уйланып ятканнан соң әбисе мендәрдән башын калкытып:

— Урман җиләге белән чәй эчәсе килә минем, кызым, — дигән.

— Һ-и, әбием, хәзер урманга барам. Былтыр синең белән җиләк җыйган урыннарны яхшы беләм әле мин, — дигән Таңсылу һәм кәрзинен beләгенә асып чыгып та йөгергән.

— Юкка әйттем, — дип хафаланган әбисе, — хәзер җиләкләр беткәндер инде. Көн дә кичкә авышып бара. Хәерлегә булсын, берүк хәерлегә булсын.

Кыз йөгерә-йөгерә урманга барып җиткән. Узган ел әбисе белән җиләк җыйган аланга килгән. Әмма анда учак эзләре, сындырылган агач ботаклары һәм тагын әллә нинди чүп-чарлар гына аунап ята икән. «Ярар, — дигән кыз, — җиләк башка җирдә дә бардыр. Бөтен урманны айкасам айкармын, әмма җиләксез кайтмам. Әбиемне терелтермен».

Әле уңга сугылган ул, әле сулга, әле алга йөгергән ул, әле артка. Йөгерә торгач, эзли торгач ярты кәрзин җиләк җыйган Таңсылу. Тик җиләккә мавыгып караңгы төшкәнен сизми калган. Ә исенә килеп кайтырга чыкканда, төн үзенең кара җәймәсен күктән җиргә кадәр җәеп куйган булган. Кыз ятьмәгә эләккән балыктай бәргәләнгән. Кая барырга белмәгән. Бөтен җирдә биек-биек агачлар, агачларда шомлы итеп ябалаклар кычкыра. Йөзгә бәрелә язып ярканатлар очып үтә, ди. Әллә шүрәлеләр, әллә агач ботаклары киеменнән эләктерә икән. Кыз тәмам адашкан. Тегендә чабып, монда чабып хәле беткән. «Әбием мине көтә-көтә арып беткәндер инде. Тизрәк кайтып аңа җиләкле чәй эчерергә иде», — дип уйлаган кыз. Шулай дип уйлавы булган, күктән бер йолдыз атылып кызның алдына төшкән. Бөтен тирә-як көндезге кебек яп-якты булган. Кыз аланга тәгәрәп төшкән йолдызны кулына алып юлга чыккан.

Йолдыз белән яктыртып баргач, юлны тиз тапкан ул. Юлны табу сөенече аның барлык аруларын оныттырган.

Таңсылу кайтып кергәндә, әбисенең хәле тагы да начарайган булган. Ул көчкә-көчкә сулыш алып ята икән.

— Әбием, — дигән Таңсылу, — мин сиңа җиләк апкайттым. Хәзер чәй кайнатып җибәрәм. Менә кара әле, әбием, җиләкләр нинди кызыллар, матурлар. Син терeләчәксең, әбием.

Тиз арада чәй кайнап чыккан. Таңсылу әбисенең чәчәкле чынаягына җиләкләрнең иң пешкәннәрен генә салып чәй ясаган.

— Менә, әбием, чәй әзер, — дигән кыз, җиләкле чәйне әбисенең алдына куеп.

— Рәхмәт, балам, азапланма инде, эчәр хәлем юк, — дигән әбисе.

— Эчәсең, әбием, эчәсең. Менә бу матур кашык белән үзем эчерәм.

Таңсылу кашык белән әбисенә чәй каптырган. Әбисе озак кына чәйне йота алмый торган, ә йотып җибәргәч, үзенең тамырлары буйлап ниндидер көч килүен сизгән.

— И балам, — дигән әбисе, — синең җиләкле чәең бик сихәтле булырга охшый бит әле. Кая әле, кая, тагын бераз эчим.

Әкрен-әкрен бер чынаяк чәй эчелеп беткән, аннары икенчесе эчелгән. Ә инде самавырда — чәй, кәрзиндә җиләк беткәндә, Таңсылуның әбисе тәмам терелеп җиткән.

— И кызым, яңадан тугандай булдым, рәхмәт инде сиңа, — дигән әбисе һәм Таңсылуны кочагына алган. Бу минутта алар икесе дә әйтеп бетергесез бәхет кичергәннәр.

Тагын шулай тыныч кына көннәр узган. Тынычлыклары, бәлки, бик озак дәвам иткән булыр иде, әмма Таңсылуның урманга баруы, анда йолдыз табуы турындагы хәбәр авылның бер почмагыннан икенче почмагына таралып өлгергән. Хәзер инде боларга күктән атылып төшкән йолдызны күрергә кешеләр килә башлаган. Ә йолдыз гаҗәеп матур, гаҗәеп нурлы — аңардан тирә-юньгә мең төрле төс таралып тора икән. Кешеләр йолдызның матурлыгына сокланганнар: йолдызга караган һәр кешенең йөзендәге җыерчыклары беткән. Таңсылуның әбисе дә унҗиде яшьлек кызга әверелгән. Хәтта күрше-тирәләре әбине танымаган. «Каян килгән соң бу сылу кыз?» — дип аптырашып караганнар аңа.

Йолдыз чынлап та хикмәтле булган. Ул үзенә кагылган кешеләрне яшәртеп кенә калмаган: ә барлык чирләреннән дә арындырган. Моны белеп алгач, Таңсылуларга иртәдән алып кичкә кадәр кешеләр агылган. Аларның кайберләре таякка таянган, кайберләрен балалары җитәкләгән, кайберләрен бөтенләй күтәреп алып киләләр икән. Таңсылу һәр авыруга үзенең тылсымлы йолдыз кисәге белән кагылган. Ул кагылуга, күзсезләр — күзле, аяксызлар — аяклы, телсезләр — телле, бөкреләр тураеп киткән. Мәңгелек чиреннән котылган кешеләр сөенечтән нишләргә белмәгәннәр. Һәммәсе Таңсылуга рәхмәт укыган.

Кызның даны ерак-еракларга таралган. Аның янына әллә кайлардан, хәтта күрше патшалыклардан авырулар килгән. Кызның инде йокларга да, утырып ашарга да вакыты калмаган. Шулай да ул үзен бик бәхетле сизгән, чөнки чирләреннән терелгән кешеләрнең балкып елмаюларын күрү, чын күңелдән әйтелгән рәхмәт сүзләрен ишетү аның өчен иң зур шатлык булган.

Шулай көн артыннан көннәр уза торган. Кыз үскән, җитлеккән. Егетләр аның матурлыгын мактап җырлар чыгарганнар, карт-корылар Таңсылуга исәнлек теләп намаз саен дога кылганнар. Кызга инде төрле яклардан яучылар да килә башлаган.

Көннәрдән бер көнне Таңсылуларга бер әби килеп кергән. Таңсылу үзенең әбисе белән бәрәңге ашап утыра икән. Әлеге карчык керә-керешкә өйнең төрле почмакларын күзе белән айкап чыккан һәм ямьсез итеп көлә башлаган.

— Нигә көләсең? — дип сораганнар аңардан.

— Көлмичә! — дигән мосафир карчык, — бөтен дөньяга даны таралган кыз бәрәңге ашап утырсын әле. Ничек инде көлмисең.

— Бәрәңге бик тәмле ул, — дигән Таңсылу.

— Бүтән аш күрмәгән кешегә тәмледер, әмма дөньяда никадәр тәмле ризыклар барын белсәң, син болай әйтмәс идең. Карагыз инде бу өегезне: өстегезгә ишелергә тора бит. Караватыгызның аягы кыегайган. Сабы кәкрәеп беткән тимер кашыклардан ашыйсыз.

— Башка кашыкларыбыз юк безнең, — дигән кызның әбисе.

— Булдырырга кирәк, — дигән карчык. — Таңсылу никадәр кешеләрне дәвалады һәм әле дә дәвалап тора. Нигә мондый эшне бушка эшләргә? Сезнең өстегезгә байлык үзе аварга тора бит. Сезгә ни сорасагыз — шуны бирәчәкләр.

Карчык шулай дигән дә Таңсылулардан чыгып киткән. Кыз белән әбисе ашауларын онытып уйга калганнар. Алларындагы бәрәңгеләре суынган, самавырларының кайный-кайный суы бетеп, эреп чыккан.

— Әллә чынлап та дәвалаган өчен бераз түләү сорыйсыңмы соң, кызым? — дип сүз башлаган әбисе. — Инде кияүгә китәр вакытың җитеп килә. Өс-башыңны карарга, туйлар ясарга, бүләкләр алырга да акчабыз юк бит безнең.

Кыз белән әбисе ул көнне озак сөйләшкәннәр. Һәм, дәвалаган өчен күпмедер түләү алырга кирәк, дигән нияткә килгәннәр.

Бу хәбәр дә дөньяга тиз таралган. Хәзер инде кыз янына беркем дә буш кул белән килмәгән. Өйгә асыл маллар, алтын-көмешләр агыла башлаган. Әби белән кыз башта кыйммәтле бүләкләрне бик кыенсынып кына алганнар. «Үзебезгә кирәк-яракны булдырсак, өйне яңартып җибәрсәк, тагын бушлай дәвалый башларбыз», — дип уйлаганнар. Әмма затлы әйберләргә күз ияләшкәч, тәмле ризыкларга тамак күнеккәч, нәфсе дигән явыз шайтан күңелне гел котыртып тора башлаган: «Мөмкинлекне кулдан ычкындырмагыз. Байлык өстенә байлык сыя ул», — дип пышылдап торган. Ныгып өлгермәгән яшь күңел вәсвәсәгә аеруча тиз бирешкән. Кайчагында әбисе Таңсылуны тыярга тырышып караса да файдасы булмаган. «Син кысылма, — дип кычкырган Таңсылу, — йолдызны мин таптым, шулай булгач, аңа мин хуҗа.

Шулай итеп, Таңсылу комсызланганнан-комсызланган. Әйберләрнең беркемдә булмаганын, ризыкның беркем ашамаганын теләгән ул.

Ә беркөнне боларга бер хәерче карчык кергән. Аның өс-башы шундый сәләмә, кагылсаң бөтенләй ертылып төшәр кебек. Хәерче калтыраган тавышы белән болай дигән:

— Балам, мин бик ерактан килдем. Бөтен кешегә баш ия-ия минем билем бөкрәйде. Ансына түзәр идем, менә кулларым эшләми башлады. Кешеләрдән хәер сорап кулларымны суза алмыйм. Хәерчегә кул бик кирәк. Теге хикмәтле йолдызыңны тоттырып каратчы, балам. Кулларым рәтләнеп китсә, ничек тә ачка үлмәс идем.

— Кит! — дигән Таңсылу. — Бушка тоттыра торган йолдыз юк миндә. Башта түлә, аннары карармын.

— И балам, — дигән хәерче. — Иңемдәге буш капчыктан кала бернием дә юк бит минем.

— Булмаса, булгач килерсең, — дигән Таңсылу һәм икенче якка борылган. Хәерче елый-елый чыгып киткән.

Хәерче чыгып киткәч Таңсылу хикмәтле йолдызны кулына алса, ни күрсен — йолдыз нур сибеп янудан туктаган. Ул кап-кара салкын бер ташка әйләнгән. Әлбәттә инде, аның тылсымлы дәвалау көче дә беткән. Таңсылу хәерче артыннан чыгып йөгергән, тик күпме генә эзләмәсен — хәерчене тапмаган.

— Ярар, — дип юаткан Таңсылу үзен, — байлыгым гомер буена җитәрлек. Егетләрнең асыллары минем бер карашым өчен җаннарын бирергә торалар. Берәр бай егеткә чыгып тыныч кына яшәргә кирәк. Юкса көн саен авырулар белән мәшәкатьләнеп үзем турында кайгыртырга онытып бетердем бугай.

Таңсылу көзгегә карап, үзенә сокланып утыра башлаган. Батырдан батыр, байдан бай кияү егетләре килеп кереп алдына тезләнер дип көткән ул. Әмма аларның ишекләрен кагучы булмаган. Әкрен-әкрен өйдәге зиннәтле келәмнәрне тузан каплаган, татлыдан татлы ризыклар беткән. Таңсылуның әбисе дә үлеп киткән. Таңсылу вакытыннан элек картайган. Нәкъ үзе куып чыгарган хәерче төсенә кергән: биле бөкрәйгән, хәер сорашырга кулларын да суза алмаган. Ә үзе һаман дөнья буйлап йөри һәм болай дип пышылдый, ди:

— Кешеләр, бер-берегезгә мәрхәмәтлерәк булыгыз. Дөнья малы дөньяда кала. Гомер — аккан су, байлык — бер айлык. Мәр-р-хә-мәтле булы-ы-гыз!

## ЯРАЛЫ ТОРНА

Гап-гади көзге көннәрнең берендә, биектә-биектә, күкләрнең әллә икенче, әллә өченче катында, тартылган җәядәй тезелешеп, бер төркем торна очып бара икән. Үзләре моңсу тавыш белән мондый җыр сузалар, ди:

Торыйк-торыйк,

Торыйк-торыйк.
Туган җирсез
Ничек торыйк?
Монда тудык,
Монда үстек.
Тәмле сулар
Монда эчтек.
Инде хәзер
Китә башлар,
Язмыш безне
Кая ташлар?
Торыйк-торыйк,
Торыйк-торыйк.
Туган җирне
Соң кат урыйк.
Саубуллашыйк,
Каңгылдашыйк.
Торыйк-торыйк,
Торыйк-торыйк!

Алар шулай дип җырлый-җырлый туган яклары, коенып үскән елгалары, канат ярган оялары өстеннән әйләнеп очып йөри башлаганнар. Аларның тавышларын ишетеп, өйләрдән бала-чагалар йөгереп чыккан. Торналар хыялый җанлы малайларга, кызларга истәлек билгесе итеп үзләренең иң матур каурыйларын ташлап киткәннәр. Учларына торна каурые төшкән малайлар-кызлар бу көнне бик бәхетле булганнар.

Ә бу гүзәл торналар балаларның гына түгел, өлкәннәрнең дә җанын кузгаткан. Баш калкытырга вакыт тапмый җирдә нидер казынучы кешеләр, торналарның сагышлы-моңлы җырын ишетеп, башларын калкытып күккә караган. Авырулар тәрәзәләрен ачып җибәргән. Торналарның шундый матур итеп очулары, ак каурыйларын җиргә сибә-сибә туган яклары белән саубуллашып йөрүләре һәркемнең күңелендә матур истәлекләр уяткан. Картлар бер-берләренә сиздерми генә күлмәк җиңнәре белән күзләрен сөрткән. Яшьләр, ярсу хисләренә чыдый алмыйча, изүләрен чишеп җибәргән. Һәркемнең күңелендә бер теләк, телендә бер сүз булган: «Исән-сау әйләнеп кайтыгыз! Безнең якларга яңа язлар китерегез!»

— Ярар, — дигән торналар. — Торыйк-торыйк, юлда булыйк. — Шулай дип әйткәннәр дә күккә күтәрелә башлаганнар. Ләкин шул вакыт ниндидер куак артыннан көчле шартлау тавышы яңгыраган. Ул да булмаган, иң уртада очып баручы бер торна хәлсезләнеп дусларына эндәшкән: «Дусларым, әкренрәк очыгыз әле, тыным кысыла. Артыгыздан иярерлек көчем калмады».

— Нәрсә булды сиңа, Сылукай? Син бит безнең иң көчле, иң ярсу дустыбыз идең! — дигәннәр аңа.

— Яраландым, — дигән Сылукай, — канат астыма кайнар кургаш керде.

— Канатыңны ныграк җилпе, бәлки, ул кайнар кургашың җиргә төшеп китәр, — дип киңәш биргәннәр дуслары.

— Булмый шул, — дигән Сылукай, өзгәләнеп, — канатымны ныграк селтәгән саен, ул эчкәрәк керә бара. Быел сезгә җылы якларга миннән башка гына барырга туры килер инде. Хушыгыз...

— Юк, юк, сине бу салкын якларда калдырмыйбыз без. Ни ашарсың, кайда оя корырсың?

— Әйдә, үземә тотын, — дигән алдан баручы Төркем Башлыгы. — Авыру канатыңны минем сыртыма салып тегесе белән селтән.

Болай иткәч Сылукайга җиңел булып киткән. Төркем башлыгының мәрхәмәтлелеге хәтта беразга авыруын да оныттырган. Төркем башы бик көчле кош икән, әмма күпмедер ара үтүгә аның да канатлары авырайган. Тыны күкрәгеннән гыжлап чыга башлаган. Сылукай аның хәлен сизеп: «Ташла син мине, Төркем башы, барасы җиргә барыбер алып барып җиткерә алмассың, җәлләмә, ташла», — дигән.

— Андый сүзне ялгыш та әйтмә, — дигән аңа Төркем башы, — без монда күбәү. Хәзер миңа алмашка бүтәннәр килер. — Төркем башы шулай дип әйтеп бетерүгә янәшәдәге торна Сылукайның яралы канатын үз сыртына салган. Берсе арыса — икенчесе, икенчесе арыса — өченчесе Сылукайга ярдәмгә ташланган. Алар шулай шактый ара үткәннәр. Карурманнар кичкәннәр, яшен болытларын тураклап узганнар. Һәммәсе дә арыганнар, алҗыганнар, тик аруларын бер-берләренә белгертмәгәннәр. Сизгер күңелле Сылукай дусларына үзенең авыр йөк булып төшүен яхшы аңлаган. Һәм алда очсыз-кырыйсыз бер зур диңгез күргәч, дусларына болай дигән:

— Дусларым, сезнең күңелегез тулы мәрхәмәт, җаныгыз тулы яхшылык икәнен мин күптән беләм. Рәхмәт сезгә, мең-мең рәхмәт. Әмма мин бүтән бара алмыйм. Күрәсезме, әнә анда олы авызлы дулкыннары белән ярсыз-чиксез диңгез җәелеп ята. Әгәр сез мине күтәргән килеш диңгез өстеннән оча башласагыз — һәммәгез һәлак булачак.

— Үләбез икән — бергә үләбез, — дигән Төркем башы. — Сине монда калдырмыйбыз.

— Юк! — дигән Сылукай да кискен итеп. — Минем сезнең кебек дусларымны югалтасым килми. Сез яшәргә, туган якларга яңа язлар алып килергә, малайларга-кызларга өмет каурыйлары өләшергә тиешсез, ә хәзер мине әнә теге күл янына төшерегез.

Дуслары Сылукайны үгетләп тә, аңа ялынып-ялварып та караган, әмма Сылукай үз сүзендә нык торган.

— Юк, бүтән бара алмыйм. Әгәр минем аркада безнең бөтен нәсел юкка чыкса, мин үз-үземне мәңге кичерә алмаячакмын.

Шулай дигәч, дуслары-туганнары Сылукай белән килешкәннәр. Аны үзе теләгән күл буена ипләп кенә, ярасын авырттырмыйча гына төшереп куйганнар. Бу күл шундый шыксыз, шундый ямьсез икән — хәтта аның яр буйларында үләннәр дә үсмәгән, суларында төнбоеклар чәчәк атып утырмаган, ярларында камышлар шауламаган. Камышлары булмагач, кошлар да кунып сайрамаган. Күлнең кайсы ягына гына карама — шәп-шәрә, әйтерсең аның ярларын суга сусаган аждаһа ялаган. Монда яшәү түгел, үлү өчен дә артык күңелсез икән.

— Ничек яшәрсең икән монда? — дигән дуслары Сылукайга. — Тирә-юньдә бернинди матурлык юк.

— Бәлки, мин терелермен дә артыгыздан куып җитәрмен әле, — дигән Сылукай.

Әлбәттә, ул бу сүзләрне дусларын юатыр өчен генә әйткән. Чөнки инде канаты беркайчан да төзәлмәячәген яхшы аңлаган ул.

— Ә сез, дусларым, юлыгызда булыгыз, юкса һавалар бозылып китүе бар, — дип, Сылукай дусларын ашыктыра башлаган. Дуслары аның белән саубуллашып, һаваны бер кат урагаииар да җылы якларга китеп барганнар. Сылукай дуслары янында сер бирмәсә дә, ялгызы гына калгач үксеп-үксеп елап җибәргән. Күз яшьләре аша карагач, аңа бу күл аеруча ямьсез күренгән. «Нишләргә инде? — дигән Сылукай, башын аска иеп. — Ичмасам, ятып үләргә йомшак үләне генә дә юк. Нинди ямьсез җир бу? Моны ничек матурларга? Әллә тәнемдәге каурыйларымны йолкып күл буена утыртып чыгыйм микән?»

Сылукай шулай уйлап томшыгы белән тәненнән берәм-берәм каурыйларын йолкып чыгара башлаган. Ә үзе йолкынган каурыйларын җиргә кадый барган. Әмма берничә каурыйны җиргә кадаганга гына күл буе матурланмаган.

Шуннан ул моңаеп, күңелсезләнеп, җансыз күлгә карап болай дип җырлаган:

Канатлы идем — канатсыз калдым,
Күктә очарга яраксыз калдым.
Болай яшәүдә бар соң ни мәгънә?
Яралы канат йолкынсын әйдә...

Шулай дип Сылукай үзенең яралы канатын йолкып атмакчы булган. Ул чытырдатып күзләрен йомган да, бар көчен куеп, канатын тарткан. Әмма канат йолкынмаган. Бары тик канат астыннан сиптереп кан гына чыккан. Ни гаҗәп: Сылукайның яралы тәненнән тамган һәр кан тамчысы күз ачып йомганчы кып-кызыл чәчәк булып күл буеның ярлы туфрагында үсеп чыга икән. Сылукай күзләрен ачып караса ни күрә — тирә-ягында әллә ничә кызыл чәчәк үсеп утыра.

— И матур чәчәкләр, — дигән Сылукай, — сез монда юк идегез бит әле, каян килдегез?

— Без синең кызыл каныңнан ярałдык, — дигәннәр чәчәкләр.

— Димәк, сез минем туганнарым? — дигән Сылукай.

— Әйе, әйе, — диешкәннәр чәчәкләр.

— Ә сез туганнарыгызның күбрәк булуын телисезме? — дигән Сылукай.

— Телибез-телибез, — дигән чәчәкләр.

— Алайса, хәзер күбәйтәбез аларны, — дигән Сылукай һәм яралы канатын янә канаткан. Тагын тирә-юньгә кан тамчылары сибелгән. Ул кан тамчыларыннан яңа чәчәкләр калкып чыккан. Күл буеның бер өлеше терелеп, матураеп киткән. Әмма Сылукайга бу гына җитмәгән. Күлнең бөтен ягын аллы-гөлле чәчәкләргә күмәсе килгән аның. Ул бер урыннан икенче урынга көч-хәл белән күчә-күчә кайнар кан тамчылары агызган. Кайвакытларда хәле бетеп озак-озак йокымсырап утырган. Йокымсырап киткән чакларында үз канатыннан үсеп чыккан кызыл чәчәкләр, әллә нинди матур кошларга әверелеп, һавага очканнар. Ул кошларга бөтен кеше сокланып, яратып карый икән. Әгәр ул кошлар кешеләрнең иңнәренә килеп кунса, иң ямьсез кешеләр дә матураеп китә икән. Бөкреләр турая, күзсезләрнең күзе ачыла, телсезләр телгә килә, боеклар елмая, авырулар терелә, картлар яшәреп китә икән.

Сылукай үзенең шундый тылсымлы көчкә ия икәнен белгәч, үзен һич кызганмыйча яралы канатын каерган. Тора-бара канатының каны беткән. Ә күл әйләнәсен матур чәчәкләргә күмү өчен әле бик күп кан тамчылары кирәк икән. Шуны аңлаган Сылукай бар көчен җыеп күкрәге белән очлы таш өстенә ташланган. Күкрәктән кан ургылып чыккан. Бу тамчыларны күбрәк урынга җиткерү өчен, Сылукай

мөмкин кадәр тизрәк атларга тырышкан. Ә ул узган җирдә тагы да матуррак кызыл гөлләр тибрәлешеп кала икән.

Шул вакыт һавада әллә нинди өермә барлыкка килгән. Һәм бу өермә эченнән җиде башлы Дию пәрие килеп чыккан: «Әй, кем син? Минем биләмәмә басып керергә сиңа кем рөхсәт итте?» — дип үкереп җибәргән ул. Сылукайның куркудан җаны чыгып оча язган. Шулай да ул, куркуын сиздермәскә тырышып, болай дигән: «Мин — яралы торна. Мине синең биләмәңдәге ниндидер явыз затлар яралады. Мин җылы якларга очарга тиеш идем. Инде хәзер шушында үләргә калдым».

— Алайса үл, — дигән аңа Дию пәрие. — Нигә минем җиремдә чәчәкләр үстереп йөрисең?

— Миңа үләр өчен дә матур җир кирәк, — дигән Сылукай. — Шунсыз үлә алмыйм мин.

— Ха-ха-ха, — дип көлгән Сылукайдан Дию пәрие, — матур җир кирәк аңа. Ә менә миңа матур җир кирәкми. Мин чәчәксез-гөлсез, урмансыз-күлсез, шыксыз җирләрне яратам. Нигә дисәң, матур урыннарга кешеләр бик тиз ияләшә. Ә минем бер дә аларга якынаясым килми.

Шулай дигән дә Дию пәрие Сылукайның кан тамчыларыннан үсеп чыккан чәчәкләрне таптый, изә башлаган. Тик ни гаҗәп: күпме генә таптамасын, күпме генә измәсен — чәчәкләргә берни булмый икән.

— Син берәр сихерчеме әллә? — дип акырган Дию пәрие.

— Юк, мин сихерче түгел, гап-гади торна, — дигән аңа Сылукай.

— Алайса, нигә чәчәкләрең мин таптаганга үлми? Моңа кадәр мин баскан җирдә бер генә үсемлек тә исән калмый иде, — дигән Дию пәрие.

— Болар гади җир чәчәкләре генә түгел, — дигән Сылукай, — болар — минем йөрәк канымнан үсеп чыккан чәчәкләр. Әнә ныклабрак тыңлап кара әле: алар һәрберсе торна тавышы белән кычкыра.

— Торна түгел, сихерче син, — дигән Дию пәрие һәм, үзенең өермәсенә утырып, Каф тавы артына китеп барган.

Ә яралы торна соңгы тамчы каны калганчы үзенең күкрәгеннән тырный-тырный күл буенда гөлләр үстергән. Ә соңыннан ул күл буендагы кызыл гөлләр уртасында бик зур ак чәчәк булып үзе үсеп чыккан.

Яз көне торналар бу якларга әйләнеп кайтканда, әлеге күл янына төшкәннәр. Алар ак чәчәккә әверелгән Сылукайны шунда ук танып алганнар. Төркем башы ак чәчәк янына килеп: «Күңелең синең нинди матур булган икән. Мәңге шиңмәс гөлләр үстергәнсең. Бу гөлләр синең җырың булып язларын безне каршы алыр, ә салкын көннәрдә кул болгап ерак якларга озатыр. Рәхмәт сиңа, матур җанлы дустыбыз. Арыганда-талганда, күңелләребез матурлыкка сусаганда җаннарыбызны сафландырыр өчен без синең яныңа килербез. Ә хәзергә хуш, Сылукай».

Алар Сылукай белән шулай хушлашып очып киткәннәр. Күл буенда үскән чәчәкләр аларның канат җилпүеннән әкрен генә тирбәлешеп үзара ниндидер моңлы җыр сузганнар. Бу җырда җиде диңгезне, җитмеш тауны кичеп яздан көзгә, көздән язга күченеп йөрүче барлык кошларның моңнары-сагышлары, югалтулары-табышлары, үкенечләре-сөенечләре — һәммәсе дә бар икән. Әгәр юлыгыз шул якка туры килеп, әлеге күл янына барып чыксагыз, чәчәкләрнең пышылдашуларына колак салыгыз. Бәлки, сез шунда бер яралы җанның кайгы-сагышын аңларсыз. Күңелегезне биреп тыңласагыз, бер яралы җан да сезгә дөньяның бөек серләрен ачар: кайгылар аша — шатлыкка, югалтулар аша табышларга бару юлын өйрәтер.

## УРМАН ӘКИЯТЕ

Көннәрнең берендә, карурманның түрендә, кәкре усак төбендә ялкау Куян кишер сабагы белән борынына кунган черкиләрне куып ята икән, шунда аның күзе усак ботагында эленеп торган бер әйбергә төшкән. «Нәрсә булыр бу? — дигән ул. — Яфрак дисәң, артык зур. Гөмбә дисәң, түгәрәк түгел. Гөмбә белән яфрактан башка дөньяда тагын нәрсә бар соң әле? Әйе, исемә төште: кишер, шалкан, кәбестә. Тик бу әкәмәт әйбер аларның берсенә дә охшамаган. Мөгаен, бу ашый торган нәрсә түгелдер. Юкса мин белми калмас идем. Үз гомеремдә урманның аркылысын-буен әз айкамадым», — дип уйлаган Куян һәм ботактагы ят әйберне үрелеп алган. Аны астын өскә әйләндереп тә, кырын-кырын яткырып та, кырыена ук килеп тә, ераккарак китеп тә караган, әмма барыбер ни икәнлегенә төшенмәгән.

«Хәйләкәр төлкедән сорап карыйк, аның дөньяда белмәгән нәрсәсе булмас», — дип уйлаган ул һәм алгы тәпиен авызына кабып бик каты сызгырган. Аның сызгыруын гына көткәндәй, куаклар арасыннан атылып-бәрелеп Төлке килеп чыккан.

— Нинди хәвеф бар, нигә сызгырдың? — дигән ул.

— Менә бер әкәмәт нәрсә таптым. Шуның ни икәнен һич белә алмыйм. Төлке дус, син кара әле, эчендә берәр тәм-том юкмы? — дигән Куян.

Төлке Куян кулындагы нәрсәне шунда ук таныган.

— Һи, юләр Куян, — дигән ул мыскыллап, — бигрәк надан инде син. Үзең егерменче гасырда яшисең. Бу бит телевизор. Мин ферма тавыклары янына кунакка барган саен аны каравылчы өендә күреп кайтам. Хәтта зуррагын. Аю корсагы кадәресен. Бервакыт тәрәзәдән шуны карап, чак килеп капмадым.

— Усак ботагына каян килеп эләккән соң ул? — дип сораган беркатлы Куян.

— Мин беләм, мин беләм, — дигән Тиен, агач башында сикеренгәләп.

— Белсәң әйт.

— Монда кичә бер көтү яшьләр килгән иде. Шулар онытып калдырган.

— Алайса, кире урынына элеп куйыйк, килеп алырлар.

— И, юләр Куян. Бигрәк башың юк синең. Шундый нәрсә кулга төшкәндә ычкындыралармы соң? Китер әле үземә! Озакламый Аю абзыйның туган көне җитә. Шуңа бүләк итәбез аны.

Төлке телевизорны култык астына кыстырган да өенә тайган. «Шәп булды әле бу! — дигән ул, сөенеченнән нишләргә белмичә. — Аю абзый белән аралар суынып киткән иде. Хәзер менә рәтләнер. Телевизор ул сиңа бер тустаган бал гына түгел инде. Каравылчы әнә, бар ферма тавыгын онытып, төн буе шуңа кадалып утыра. Бүреләрнең борынына чиертәм мин моның белән. Юкса Аю абзыйның корт чаккан борынына салкын компресс куйган булып, әллә кем сыман йөриләр».

Төлке алдан ук тантана итеп, Аю абзыйның туган көнен көткән. Ә үзе астыртын гына бу мәҗлескә кемнең нәрсә алып киләчәген белешкәләп йөргән.

Ниһаять, көтелгән көн килеп җиткән. Ала карга урмандагы иң биек агач башына менеп, өч тапкыр каркылдаган. Бу барлык җәнлекләрне мәҗлескә чакыру булган. Шушы чакырудан соң бөтен урман хәрәкәткә килгән. Кайсы сыртына сыер боты салып, кайсы рамы белән кәрәзле бал күтәреп, кайсыберсе кесәсенә чикләвеген тутырып урман аланына мәҗлескә йөгергән. Һәркем үз бүләген беренче булып Аю абзыйга тапшырырга теләгән. Бары тик Төлке генә ашыкмаган. «Зур эшләр ашыгып эшләнми, — дигән ул үз-үзенә. — Әйдә, картлач мин юклыкны күреп, бераз борчылып алсын. Бүләкнең олылыгын аңларга шәбрәк булыр».

Аланда мәҗлес башланган. Аю абзый дәү агач төбен өстәл итеп, үзенә китергән күчтәнәчләрне шунда өя барган. Кунакларга да өлеш чыгарган. Ашаганнар, эчкәннәр, җырлаганнар, биегәннәр.

Мәҗлеснең иң кызган чагында, култык астына ят бер тартма кыстырып, Төлке килгән. «Уф, — дигән ул, маңгаендагы тирләрен тәпие белән сыпырып, — бөтен дөньяны әйләнсәм әйләндем, әмма эзләгәнемне таптым».

— Нәрсә таптың? — дигән Аю.

— Менә нәрсә! — дип, Төлке үз бүләген Аю абзый алдына китереп куйган.

Аю бу бүләкне иснәп караган да:

— Бал исе килми, нәрсә бу? — дип үкереп җибәргән. — Әллә син, хәйләкәр таз, миннән көләргә уйладыңмы?

— Мин сиңа, — дигән Төлке, койрыгы белән җир себереп, — дөньяда бер генә Аюда да булмаган нәрсә алып килдем. Моны күрсәләр, бүтән аюлар көнләшүләреннән тәгәрәп үләчәкләр.

— Йә, йә, — дигән Аю, — ашап карыйк. Тәмле нәрсә микән.

Аю казыктай тешләрен телевизорга батырам дигәндә генә, Төлке:

— Туктале, галиҗәнап Аю абзый, — дигән, — бу ашый торган әйбер түгел. Бу — җан азыгы, — дигән.

Аю корсагын уа-уа көләргә тотынган:

— Ха-ха-ха! Җан азыгы! Ха-ха! Моңарчы җанымның ашарга сораганы юк иде. Син, астыртын, берәр хәйлә корып маташмыйсыңмы?

Төлке, Аю абзыйның сүзләреннән үпкәләп, читкәрәк китеп баскан.

— Йә, йә, — дигән Аю, — бүләгеңнең нәрсәгә яраклы икәнен күрсәт. Җанымның да тамагын туйдырып карыйк.

Төлке, ялындырып тормаган. Телевизорның бер кнопкасына басып җибәргән. Экранда башта ниндидер утлар җемелдәгән, аннары мылтык тоткан аучы килеп чыккан. Җитмәсә, аучының бозау хәтле эте дә бар икән. Моны күрүгә, мәҗлескә җыелган барлык җәнлекләрнең котлары очкан. Хәтта качарга кирәклеген дә онытканнар болар.

— Курыкмагыз, — дигән Төлке телевизордагы аучы белән этнең башыннан сыйпап. — Болар безгә тия алмый. Аларның үзләрен тотып пыяла тартмага япканнар. Менә карагыз: аучы да, эте дә тими. — Төлке үзенең батырлыгы һәм тапкырлыгы белән мактанырга теләгәндәй, экран тирәсендә бөтерелгән.

Озакламый телевизорда күренешләр алышынган. Мультфильм башланган. Бүре Куянны куа киткән. «Бусы мин!» — дигән Бүре экранда үзен танып. «Син мине мәңге тота алмыйсың», — дигән Куян. Алар бераз бәхәсләшеп алганнар. Мультфильм барысына да ошаган.

— Бүләгең ярыйсы икән, — дигән Аю абзый Төлкегә. Аюның мактавыннан күңеле күтәрелгән Төлке телевизорны икенче программага күчергән. Анда футбол уены бара икән.

— Сарык башы типкәләп йөртәләрме анда? — дигән Бүре, тәгәрәп йөргән тупны күреп.

— Син үзең сарык башы, — дигән Аю, бик белдекле булып, — сарык башы өчен шултиклем кеше йөгереп йөри димени? Бер йомарлык кәрәзле балдыр ул.

— Юк, олы шалкан, — дип кырт кискән Куян.

— И, юләр башлар! — дигән Төлке. — Туп бит ул.

— Ә нәрсә соң ул туп? — дип сораганнар аңардан.

— Түгәрәк әйбер, — дигән Төлке, исе китмичә.

— Түгәрәк икәнен үзебез дә күрәбез, — дигән Аю, — ни өчен аны типкәләп йөртәләр? Акыллы булсаң, син безгә шуны аңлат.

— Әнә теге ятьмәле капкага кертергә маташалар, — дип аңлаткан Төлке.

— Тапканнар кызык нәрсә, — дип, Аю борылып китәргә җыенган икән, шул вакыт капкага туп килеп кергән. Бу тамашаны карарга җыенган халык сызгырырга, кычкырырга тотынган. Бөтен урман гөжләп торган. Аю исә, тагын нишләрләр икән дип, яңадан экранга таба борылган. Тупны янә капкадан тибеп чыгарып җибәргәннәр. Тагын куыш киткән. Тора-бара урмандагы җәнлекләр бу уенны ярата башлаганнар. Алар хәтта төрле-төрле төркемнәргә бүленеп беткәннәр. Һәр төркемнең яраткан командалары барлыкка килгән. Уен беткәч, урманны яңгыратып бәхәсләшә торган булганнар. Чөнки һәр төркемнең үз командасын көчле итеп күрәсе килгән. Капкага туп керткән саен, Аю бөтен көченә «Го-ол!» дип кычкыра икән. Бу тавышка хәтта Аю тирәсендә утырган куяннарның колаклары чукракланып беткән. Ярый әле туп күп кермәгән, юкса мондагы тавышка зилзиләләр кубып, урмандагы агачларның асты өскә килеп бетәр иде. Болай да инде телевизор табылганнан бирле урмандагы тәртипләр үзгәргән. Бер җәнлек тә үзенең баласын вакытында йокларга яткыра алмаган. Бер яктан ата-аналары аларны җылы түшәккә куып торганнар, икенче яктан балалары сикерешеп торып телевизор карарга утырган. «Сүземне тыңламасагыз олы капчыклы аучыга бирәм», — дип тә караганнар. Тик балалары: «Аучының да телевизоры бардыр әле», — дип кенә җавап кайтарганнар.

Аю, Бүре, Төлке, Куяннарның ауга йөрүләре дә тукталган. Ач корсакларын уа-уа һәркем көне-төне телевизор караган. Бервакыт ачыгудан күзләре әлҗе-мөлҗе килә башлаган Төлке урман җәнлекләренә мондый тәкъдим керткән.

— Дуслар, сүземне тыңлагыз әле. Мин менә нәрсә әйтергә телим...

— Теләсәң әйт, озакка сузма. Телевизор карыйсы бар.

— Сүзем шул: телевизорда футбол барганда, бөтен халыкның күзе шунда була. Абзарларыннан тавыкларын гына түгел, сарыкларын күтәреп китсәң дә беркем күрмәячәк. Әйдәгез, бер уен вакытында күмәкләшеп авылга барып кайтыйк.

— Юк инде, бик теләсәң, үзең бар. Без — честный җәнлекләр, — дигәннәр Төлкегә. — Болай итү хәрәмләшүгә керә.

— Үлән ашап торсам торырмын, урынымнан кузгалмам, — дигән Бүре.

Бүрене кузгата алмагач, Төлке Аюга дәшкән:

— Берәүнең бик шәп умарталыгын күреп кайттым, бәлки, галиҗәнап Аю, син минем белән барырсың, ә?

— Юк белән башымны катырма әле, — дигән Аю. — Мин карап тормасам, йә безнең команда оттырып куяр. Болай да уйнауларының рәте-чираты юк.

— Син, Төлке, кеше котыртып йөрмә, үзең бар, — дигән Мәче башлы ябалак. Шуның белән сүз беткән. Ябалак тикле ябалакны телевизор яныннан кузгатып булмагач, башкаларга тел әрәм итеп тормаган Төлке. Һәм, ашау-эчү ише нәрсәләргә кул селтәп, үзе дә телевизор карарга яшел чирәмгә сузылып яткан. Телевизор һаман күрсәткән дә күрсәткән.

Әмма, һәрнәрсәнең чиге була, абзарның бите була дигәндәй, көннәрдән бер көнне экранда ут сүнгән. Тегеләй борып, болай баскалап караганнар, тик хикмәтле тартмага җан кермәгән.

— Инде нишлибез? — дигәннәр Төлкегә. Төлке җавап бирә алмаган.

Шулчак аяк астында йомгактай йомарланып ятучы Керпе, үзен күрсәтергә теләп, болай дигән:

— Үзебезгә уйнарга кирәк бу туплы уенын. Җитәр инде, кешеләргә күп кызыктык.

Керпенең бу фикерен барысы да берьюлы күтәреп алган: «Әйе, үзебезгә уйнарга!»

— Аюны капкага куярга.

— Бүреләрне төп һөҗүмче итәргә.

— Куяннар сакчы булыр.

— Ә без нишләрбез? — дигән Төлке.

— Сезме? — дигән Керпе. — Сез читкә тәгәрәгән тупны китереп торырсыз.

— Уйнавын уйнарсыз, — дигән шул вакыт Елгыр Болан, — ә тупны каян алырсыз?

Бу сорау һәммәсен аптыраашта калдырган. Бер-берләре белән озак киңәшкәннән соң, Тилгәнгә болай дигәннәр:

— Синең күзең очлы. Һавага күтәрел дә дөньяны күзәт. Тупка охшаш нәрсә күрсәң әйтерсең.

Тилгән ике әйткәнне көтмичә һавага күтәрелгән. Канатын җәеп урман-таулар өстеннән озак очкан ул. Оча торгач, күзәтә торгач, биек тау башында туп сыман түгәрәк әйбер күреп алган. Бу хәбәрне кайтып әйтү белән, үр куяннары тауга менеп киткәннәр. Тилгән күреп кайткан түгәрәк нәрсә чуерташ булып чыккан. Куяннар аны көч-хәл белән генә таудан тәгәрәтеп төшергәннәр.

Аю бу ташны күтәреп караган да:

— Ярыйсы гына саллы икән бу. Кешеләр ничек шулай җиңел очырып йөртәләр икән соң моны? Күрәсең, алардагы көч йөз Аюны җиңәрлектер инде, — дигән.

Аю таш тупны мәйданга чөйгән.

— Бераз аякларыгызны яза торыгыз, мин өйгә кереп капкалап чыгам, — дигән ул. Таш тупка әле Куян, әле Бүре китереп типкән. Типкәне берсе аякларының авыртуына чыдый алмыйча бөгелеп төшкән. Аю өеннән тамак туйдырып чыкканчы урманның ярты халкы аксап беткән.

— Ни булды сезгә? — дигән Аю. — Аякларыгызга шырпы кадалдымы әллә?

— Галиҗәнап Аю, — дигән Бүре, өч аякта биеп. — Бу бик хәтәр уен икән. Әллә моны уйнамыйбызмы?

— Уйныйбыз! — дигән Аю, кире какмаслык итеп. — Мин хәзер бу уеннан башка тора алмыйм. Менә бу ике агач арасы капка булыр. Мин капкага басам, ә сез үз урыннарыгызга таралыгыз.

Җәнлекләр: «Без хәзер өс-башыбызны гына алыштырып киләбез», — дигәннәр дә урманга таралганнар. Һәм, Аюга танытмас өчен, җәен-кышын кием алыштырып йөри башлаганнар. Ә Аю исә ике агач арасына басып һаман аларны көтә, ди. Үз капкасына бер туп та керттермәгән бердәнбер капкачы булуы белән ул бик бәхетле икән.

## ЯЗ КАЙДА КЫШЛЫЙ?

Кара диңгез артындадырмы, Казыл диңгез артындадырмы — кайдадыр еракта, моннан күренми торган якта бар икән, ди, бер утрау. Ул утрауга әле бер генә сәяхәтченең дә аяк басканы юк икән. Кеше аяк басмаган әлеге утрауда һәртөрле җимешләр агачларын сыгып утыралар, кавын-карбызлар таудагы ташлар кебек кояшта кызынып яталар, кош-кортлар бернәрсәдән курыкмыйча, ояларын кая теләсәләр шунда корып, бала чыгаралар икән, ди. Андагы матурлыкны, андагы байлыкны күрсәң, хәйран калып шунда ук телдән язасың, ди.

Менә шушы гаҗәеп утрауга Язбикә кыш кышларга килә икән. Ни өчен ул күз күрмәгән, колак ишетмәгән утрауга барып кышлый соң? Чөнки якын-тирәдә булсам артымнан килеп җитәрләр дә кире кайтуымны үтенерләр дип курка икән. Әйе, безнең кайсыбызның гына йомшак җанлы, көләч йөзле, иркә куллы Язбикәне мәңге-мәңге үз яныбызда тотасыбыз килми дә, кайсыбызның гына чәчәкләр, гөлләр түшәлгән болыннар буйлап йөгерәсе килми соң? Ә бит Язбикәгә дә ял кирәк. Безгә кар-бураннар ыжгырган, колак-борыннарыбызны Кыш бабайның шаян малайлары чеметеп-чеметеп уйнаган чакта, Язбикә үзенең утравында хәл җыеп ята. Диңгез суларында коенып, комнарда кызынып көчен-гайрәтен арттыра. Менә бервакыт аның йөзенә алсулык йөгерә, тамырларында чишмә булып каны уйный, күкрәгендә ашкыну туа. Тәненә көч-дәрт керүгә үк, ул туган җире турында уйларга тотына. Һәм тиз генә өлкән улы Җилбатырны чакырып китерә дә болай ди:

— Улым, без монда бик озак яттык, тәнебездә көч, җаныбызда ашкыну туды, әйдә, тиз генә юлга җыен. Туган якларга кайтып кил, анда безне көтәләр микән? Сагынганнар микән? Тик шуны онытма: без монда сине дүрт күз белән көтеп торачакбыз.

Җилбатыр, әнкәсенең сүзен ишетүгә, сөенә-сөенә юлга җыена башлый: аягына диңгезләрне сикертеп кенә чыгара торган тылсымлы итеген кия, кесәсенә төрле-төрле сыбызгыларын сала, аннары бүреген маңгаена ук төшереп киеп куя да күздән югала.

Ел барасын ай барып, ай барасын көн барып Җилбатыр туган иленә килеп җитә. Килеп җитә дә хәйран кала: мондагы хозурлык, мондагы киңлек! Болыннар, кырлар буйлап күпме генә йөгермә — чигенә барып чыга алмыйсың, ә юллар соң, юллар! Башы да юк аларның, ахыры да. Тылсымлы итегеңнең табаннары төшкәнче чап та чап. Юлыңа киртә булып таулар ятмый, йотам-йотам дип диңгезләр олы авызларын ачып сагалап тормый. Рәхәт, иркен!

Һәм Җилбатыр әнкәсенең: «Без монда синең кайтканыңны көтеп калабыз», — дигән сүзләрен бөтенләй исеннән чыгарып, кырлардан басуларга, шәһәрләрдән авылларга, урманнардан болыннарга чаба башлый. Кайвакыт артык шукланып китеп, урамда кар йомарлап атышучы малайларның бүрекләрен салдырып ала, кызларның куеннарына җепшек кар тутыра, картларның сакал-мыекларын чуалта, судан кайтучы киленнәрнең чиләкләренә бәрелеп, суларын түктерә.

Бик-бик рәхәт була Җилбатырга туган илендә. Кечкенә утрауда бикләнеп яткан көннәре өчен дә йөгерә-уйный ул. Ә Язбикә исә һәр көн юлга карап улын көтә. Көтеп-көтеп улы кайтмагач, үзенең иркә кызы Тамчыкайны чакырып ала.

— Кызым, — ди ул, Тамчыкайның иңенә йомшак кулын салып. — Юлга син җыен, булмаса. Бәлки, барышлый абыеңны очратырсың. Тик кара аны, озаклама. Безне анда көтәләрме-юкмы, шуны гына белеш тә монда йөгер.

— Ярар, әнкәем, — ди Тамчыкай, шатлыгыннан күңеле нечкәреп. — Мин бик тиз әйләнеп кайтырмын.

Чибәр Тамчыкай көзгегә карап бизәнә-ясана да яфрактан яфракка, агачтан агачка сикерә. Иң биек агачның иң өстәге яфрагы болытларга тиеп тора икән. Тамчыкай яфрактан тиз йөрешле болытка күчеп утыра. Шулай итеп юлга чыга.

Көн бара, төн бара, туктамыйча гел бара торгач, килеп җитә Тамчыкай туган иленә. Озак итеп карурманнарга карап тора, елга өсләрен күзәтә ул. Тамчыкайга да бик ошый туган илендә. Иртәләрен ул берәр биек йортның түбә кыегына менеп утыра да чыгып килүче кояшның нурларына күз кыса. Ә кояшка бер күтәрелеп карадыңмы — бетте диген инде. Син аңа мәңгегә гашыйк буласың. Йөрәгеңә дәрт тула, йөзеңдә сөенеч балкый башлый. Бөтен дөньяңны онытып, син аның иркенә биреләсең.

Тамчыкай да әнкәсе турында оныта. Ул сөенеченнән нишләргә белмичә каен ботакларында тирбәлә, тәрәзә юучы апаларның керфекләренә куна, болытларга утырып, басуларга барып кайта. Ә Язбикә күз өстенә кулын куеп юлга карый: «Кызым күренмиме?»

Юк шул, кызы күренми.

Әмма Язбикә өметен җуймый. «Бәхетлеләрдер, — ди ул Җилбатыр белән Тамчыкай турында. — Бәхетле чагында хәтер кыска була». Һәм туган иленә ашкынган Язбикә, белеп кайтырга дип, кошларын-оныкларын җибәрә. Берәм-берәм дә, күпләп-күпләп тә китәләр кошлар. Аларга Җилбатырныкы кебек тылсымлы итек тә, Тамчыкайны алып киткән елгыр болыт та кирәкми. Аларның канаты үзләрендә. Язбикә әбиләренең рөхсәтен алуга, үзләренең утрауларын бер әйләнеп чыгалар да туган илләренә юл тоталар. Онықларын озатып бетергәч, Язбикә бик ямансулап кала. Яулык почмагы белән еш-еш күзләрен сөртә, аяк очларына баса-баса юлларга карый. Җилбатыр белән Тамчыкай кебек үк, кошлар-оныклар да әйләнеп кайтмыйлар.

— Мөгаен, балаларымны анда бик әйбәт каршылаганнардыр, — дип уйлый Язбикә, — җибәрмиләрдер. Үземә дә юлга чыгарга кирәктер. Юкса соңга калуың бар.

Һәм Язбикә тал чыбыгы белән билен буып, чәчкәле яулыгын башына чөеп юлга чыга. Адымнары шундый җиңел, шундый җитез аның. Диңгезләрне атлап, күлләрне урап, елгаларны сикереп кенә үтә Язбикә. Аның килүен иң беренче кошлар күреп алалар. Кошлар — урманнарга, урманнар — болыннарга, болыннар елгаларга Язбикәнең килүе турында хәбәр тараталар. Бу хәбәрдән бөтен дөньяның йөзенә шатлык йөгерә. Елгалар, йөрәкләренең ярсуына чыдый алмыйча, ярларыннан ташып Язбикәгә таба чабалар, урман күзе — умырзаялар — үзләренең зәңгәр күзләрен кар суларында юып, көн тудымы, юлга карыйлар. Җилбатыр гафу сорап әнкәсенең кочагына ташлана, Тамчыкай гаебенең зурлыгын аңлап мөлдерәп тула да әнкәсенең аяк астына тәгәри. Ә Язбикә һәммәсен гафу итә. Хәтерсез оныкларын да, җилбәзәк улы Җилбатырны да, үзе турында гына уйлаучы гүзәл кызы Тамчыкайны да тиргәми, Язбикәнең бүген күңеле киң, бәхете чиксез. Чөнки ул үзенең туган иленә кайта. Ә биредә аны әнә ничек зарыгып көткәннәр. Язбикә килеп җитүгә, игенчеләр басу-кырларына ашыгыр, авыруларның күңелләрендә яңа өметләр уяныр, карт-корылар тагын бер язны көтеп ала алулары белән бәхетле булырлар, сабыйлар яшел чирәмгә тәпи басуларына сөенерләр.

Үзеңнең һәр урында көтелгән кунак икәнлегеңне белеп яшәүдән дә олы бәхет бармыни соң?!

## ТЫЛСЫМЛЫ АЧКЫЧ

Борын-борын заманда, кеше аяк басмаган кара урманда бер карт белән карчык яшәгән. Аларның булган, ди, Ибрай исемле бик акыллы, бик зирәк бер уллары. Кечкенә чакта Ибрайның бишеген җилләр тирбәткән, көйсезләнсә — кошлар сайрап юаткан, авырып китсә — урман чәчәкләре үзләренең шифалы

суларын эчереп терелткәннәр. Малайның теле бик иртә ачылган. Бишектә чакта ук сандугачларга кушылып җырлаган, урман шавын тыңлап моңайган, сихри күккә карап уйланган.

Ел үсәсен көн үсеп, малай буын ныгыта да əти-əнисе каршына килә:

— Әткәй, әнкәй, миңа фатихагызны бирегез. Юлга чыгам, — ди ул. — Дөнья гизәрмен, зиһенемне чарлармын, акыл җыярмын. Күңелемнең каен тузыдай ап-ак чагы, анда берни язылмаган. Күргәннәремне шул хәтер дәфтәремә теркәрмен. Дөнья хикмәтләрен аңлатып бирерлек кешеләр очратырмын. Карурманнарның нигә шаулавын да, офыкларның нилектән аллануын да, чәчәкләрнең нәрсәдән хуш ис таратуын да — бөтенесен-бөтенесен беләсем килә минем.

— Ярар, улым, — дигән изге күңелле ата-ана. — Бездән хәер-фатиха. Юлда ашарыңа менә бөтен ипи, бәхетең шуның кебек гел түгәрәк булсын.

Чыгып киткән Ибрай юл капчыгын җилкәсенә асып. Ай барганмы, ел барганмы, анысы безгә мәгълүм түгел, бары шунысы гына ачык: юлында очраткан ул бер карт бабай. Карт бик ач та, ялангач та икән. Аның кулында бары тик табак хәтле бер баш көнбагыш кына бар икән. Карт шул көнбагышның берсен ашый, берсен җиргә ташлый, ди. Ибрай аңа гаҗәпләнеп карап торган-торган да, сәлам биреп янына килгән һәм болай дигән:

— Бабакай, нигә көнбагышның берсен ашыйсың, берсен җиргә ташлыйсың? Үзең инде ачлыктан хәлсезләнгән күренәсең.

— Әйе, улым, — дигән карт, — шушы көнбагышымнан башка минем бернием дә юк. Әҗәлем дә ачтан егылуымны көтеп шушы тирәдә сагалап йөри. Нәфесемә буйсынып бөтен көнбагышымны ашап бетерсәм, бәлки, бер-ике көн озаграк яшәрмен. Алай итсәм, үзем үлгәч дөньяда бернием дә калмас иде. Ә кешеләр, улым, дөньяда нәрсә дә булса эшләп калдырырга тиешләр. Минем хәзер бүтән чарам юк, бары шушы көнбагышым гына. Ичмаса, үзем үлгәч, шулар үссен.

Малай әдәп белән генә аның сүзләрен тыңлап торган да биштәреннән ипиен алып картка сындырып биргән. Аннан тагын юлын дәвам иткән. Бер йөгереп, бер атлап, кай урында титаклап бара торгач, Ибрай зур шәһәргә килеп җиткән. Бу шәһәрдә һәммә нәрсә бакырдан икән. Ташпулатларның түбәләре дә, җимеш бакчаларын уратып алган коймалар да, хәтта урамдагы юллар да бакырдан коелган. Моңарчы төшендә дә күрмәгән сарайларны, тап-такыр урамнарны тамаша кылып йөргәннән соң малай-шалай бик күп җыелган бер бакыр сарай янына килеп туктаган Ибрай.

— Малайлар, — дигән ул, тавышына көрлек бирергә тырышып, — бу сарайда ни бар? Нигә монда җыелдыгыз?

Шәһәр малайлары Ибрайның кояшта уңган юл капчыгына, тигәнәк-сырлан сарган чалбар балакларына мыскыллабрак карап торганнар да:

— Әй, урман пәрие, сиңа биредә ни калган? — дип көлеп җибәргәннәр. — Монда дөнья гыйлемнәренә өйрәтәләр. Ә сарайга керер өчен өч өр-яңа табышмак әйтергә кирәк. Без ничә көннәр буе сарайның капка төбендә ятып та эчкә үтә алмыйбыз әле. Син борыныңны сузасың, җитмәсә.

— Әллә, улым, син дә бәхетеңне сынап карарга телисеңме? — дип сорый Ибрайдан бакыр чәчле, бакыр башлы бер карт.

— Әйе, бабай, — ди Ибрай. — Карурманнар кичеп, тигәнәкле сукмаклардан үтеп, мин сезнең шәһәрегезгә килдем. Йортымда мине атам-анам озатып калды. Алар да, урмандагы бөтен дусларым да минем акыл җыеп, дөнья серләренә төшенеп кайтуымны телəделəр.

— Әйдә алайса, зиһенеңне сынап карыйк, — ди бакыр сакаллы карт һәм Ибрайның кулына бер ачкыч тоттыра. — Шул йозак ачкычын өч тапкыр боргач кына ачыла. Үзең уйлап тапкан бер табышмак әйтсәң дә борасың. Табышмагың яңа булса гына борыла ачкыч. Аннан соң икенче, өченче табышмакларыңны уйлыйсың.

Ибрай бераз каушап карт кулыннан ачкычны ала һәм:

Һаман матур, һаман яшь,
Ел да чыга яңа чәч, —

дип, ачкычны йозакка тыга. Йозакта нидер шалтырый, нидер зыңлый, аннары дөбердәп бер мәртәбә борылып куя. Җыелышкан малайларның күзләре шар була. «Җавабыңны әйт, җавабыңны», — дип кычкыра алар. «Агач», — ди Ибрай, сөенеченнән нишләргә белмичә.

— Инде икенче табышмагыңны әзерлә, — ди аңа ишек төбендәге Бакыр сакал.

Ибрай күп көттерми:

Тәңкә-тәңкә чулпы таккан
Зәңгәр күзле кыз бала.
Җем-җем иткән чулпысын ул

Кич кия, иртән сала, —

ди һәм кызыксынучыларга җавабын да әйтеп ачкычны янә бер тапкыр бора. Табышмакның җавабы болай икән: чулпысы — йолдызлар, зәңгәр күзле кыз бала — күк йөзе. Ибрайның табышмагы ишек төбендәге малайларга гына түгел, ачкыч биреп торучы картка да ошый.

— Инде өченчесен әйт, өченчесен, — дип кычкыра алар аңа төрле яктан.

Бакыр сакаллы карт та Ибрайга көч бирергә теләгәндәй, малайның җилкәсеннән кагып куя. Ибрай басуда тирбәлеп үскән йомшак, рәхәт дулкыннарны күз алдына китереп болай ди:

Шаулый, ләкин урман түгел,
Йомшак, ләкин юрган түгел.

Шулай ди дә ачкычны өченче мәртәбә борып җибәрә. Ишек матур музыка тавышлары чыгарып ачылып китә, һәм Ибрай, сихерләнгәндәй, тупса катында басып кала. Бераздан һушын җыйгач кына эчкә таба үтә ул. Ә эчтә ниләр генә юк икән. Гаҗәеп иркен заллар дисеңме, Ибрай исемнәрен-атамаларын да белмәгән әллә нинди хикмәтле приборлар дисеңме! Иркен бүлмәләрнең кайсына гына керсәң дә малайлар, кызлар мәш килә. Ибрай да шулар арасына керә. Айлар буе, еллар буе төрле гыйлемнәргә өйрәнә. Инде ул таңнарның нилектән атканын да, ни сәбәптән сулар акканын да белә башлый. Ләкин бакыр сарайда бөтен нәрсәләрне дә белеп бетерү мөмкин түгел икән. Монда китаплар да юкарак, өйрәтү әйберләре дә гадирәк икән.

Бакыр сарайда бөтен серләргә төшенгәч, бер төркем бакыр чәчле малайларны, кызларны җибәрәләр көмеш шәһәргә. Алар арасында урман иле вәкиле Ибрай да була. Озак вакыт бакыр шәһәрдә гыйлем алып, бакыр урамнарда шар тәгәрәтеп йөргәнгәме, башкалардан аерылып тормаган ул.

Көмеш шәһәр аларны көмеш кыңгыраулар кагып каршы ала. Шәһәрнең көмеш урамнарын таптап, мондый җиргә килеп җитә алуларына чын-чынлап куанышып бик озак йөриләр алар. Гаҗәеп якты тәрәзәләр дә, үрелеп карасаң түбәтәең төшәрлек биналар да, саксызрак атласаң таеп егылырлык тигез урамнар да — бөтенесе-бөтенесе бик ошый аларга. Мул җимешле бакчаларда ял итеп, тәмле сыйлы ашханәләрдә тамак туйдырып, күргән тамашаларга сокланып йөргәннән соң бик күркәм, бик мәһабәт көмеш сарай каршына килеп туктыйлар алар. Ишек янындагы көмеш сакаллы картка баш иеп, түбәтәй салып сәлам биргәч, үзләрен эчкә кертүләрен сорыйлар.

— И балалар-балалар, — ди Көмеш сакал, — һәрнәрсәнең шарты бар, һәр ишекнең карты бар. Менә сезгә көмеш ачкыч, әнә ишектә йозак. Өчәр мәгънәле сүз әйтеп, шул йозакны өч мәртәбә борыгыз да керегез дә китегез.

Картның көмеш ачкычына берьюлы бик күп куллар сузыла. Һәркем, теленә килгән беренче сүзне әйтеп, ачкычны бормакчы була. Әмма йозак бик хикмәтле шул. Сирәк кешеләр генә үтә ала бу сарайга. Ибрай пошаманга төшә. Үзенең кыюсызлыгы аркасында ул ачкычны да беренчеләрдән булып эләктерә алмый. «Бөтен күп мәгънәле сүзләрне әйтеп бетерәләр инде, миңа калдырмыйлар да», — дип хафалана ул. Үз чираты җиткәч тә ачкычка тотынырга курка әле. Шул вакыт арттан бер шук малай: «Әллә син төш күрәсеңме, Ибрай?» — дип кычкырып куя. «Төш» дип кабатлый Ибрай һәм сөенеп ачкычка үрелә. Ачкыч зыңгылдый-зыңгылдый бер тапкыр борылып куя. Икенче сүзне дә Ибрай тиз уйлап таба. «Өн», — дип тагын бер мәртәбә бора малай ачкычны. Йозак янә матур тавышлар чыгарып зыңгылдый. Бу тавыш малайны дәртләндереп җибәрә. Өстәвенә ишек катындагы Көмеш сакал да Ибрайның җилкәсеннән кагып болай ди: «Улым, син бик зирәк күренәсең, хәзер каушамый гына өченче сүзеңне әйт. Шуннан соң ишек ачылыр». «Яшь», — дип әйтүе була Ибрайның, ишек ачылып китә. Көмеш сарайның эче бакыр сарайныкы кебек кенә түгел икән. Монда заллар да биегрәк, зиннәтләр дә кыйммәтлерәк, бүлмәләр дә яктырак икән.

Сары көзләрне, карлы кышларны шушы көмеш сарайда гыйлем өйрәнеп үткәрә Ибрай. Көмеш сакаллы картлар, көмеш толымлы апалар аның кулыннан җитәкләп белем патшалыгына алып керәләр. Торган саен үзен көчлерәк, акыллырак сизә башлый Ибрай. Җем-җем иткән йолдызларның серен, үзе таптап йөргән җирнең хәзинәләрен дә өйрәнә ул. Дөньяның киңлегенә, галәмнең серлелегенә, җирләрнең юмартлыгына хәйран калып бик күп белемнәр алып чыга ул көмеш сарайдан. Инде моннан да артыграк белү мөмкин түгелдер дип уйлый Ибрай. Ләкин аңа көмеш сарайдан чыкканда болай диләр:

— Бездә әле син бик аз өйрәндең. Хәзер инде алтын шәһәргә юл тот. Анда гыйлемнең диңгездәй тирәненә чумарсың. Башыңдагы меңләгән сорауларга җавап табарсың.

Юл капчыгын ала да китә Ибрай тагын сәфәр чыгып. Олыларча зур-зур атлап, һәр урында әдәп саклап бара торгач, килеп җитә алтын шәһәргә. Алтын шәһәрнең нәкъ уртасында, җимешләре җиргә асылынып торган гүзәл бакча эчендә, алтын баганалы искиткеч сарай күрә ул. «Бик бәхетлеләр генә керә аладыр монда», — ди ул, чиксез сокланып. Шулай диеп әйтүе була, аның каршына алтын сакаллы карт килеп тә чыга. «Сүзләрең хак, балам, монда бәхетлеләр генә керә ала, — ди ул. — Әгәр теләгең зур булса, син дә

бәхетеңне сынап кара. Әнә ишек янындагы өстәлдә өч калын китапны күрәсеңме? Шуларны күтәреп бусага аша үтә алсаң, алтын сарайга кергәнеңне сизми дә калырсың».

Ибрай: «Һи, шартлары бик җиңел икән», — дип, китапка барып тотына. Җәһәт-җәһәт кенә китапларны юл капчыгына тутырып эчкә үтмәкче була. Әмма китапны урыныннан да кузгата алмый. Көчәнсәң, билең генә сынып чыгар. Алай итеп тотынып карый Ибрай, болай итеп ябышып карый: юк, китаплар селкенмиләр дә. Аптырагач-йөдәгәч, ничек итеп күтәрергә белмәгәч, алтын сарайга керүдән өметен өзеп, өстәл янына барып утыра ул. «Күтәрә алмаган күтәрә алмаган инде, ичмасам, берәр битен укып карыйм әле», — дип, Ибрай китапның тышын ачып җибәрә һәм дөньясын оныта. Әллә көн укый, әллә ел укый, анысы мәгълүм түгел, әмма шунысы ачык: китаплардан һич аерыла алмый ул. Ә соңгы китапның соңгы битен япканда башын калкытып караса, үзен алтын сарай эчендә күрә. Гаҗәпләнеп, аптырап ишек янындагы картка сүзката ул.

— Әйтче, гыйлем иясе, мине нишләп монда керттеләр?

— Чөнки син куелган шартны үтәдең. Бу китаплар өстәлгә кадаклanganнар, аларны беркем дә күтәрә алмый. Бары тик син эшләгәнчә «башка салып» кына алып керергә мөмкин аларны.

Сөенеченнән нишләргә белмичә, кулларын чәбәкләп җибәрә Ибрай. Һәм шул көннән башлап тирән диңгезгә — гыйлем диңгезенә чума. Айлар укый, еллар укый, җәйләр укый, кышлар укый, бөтен нәрсәләр турында белә башлагач кына укудан туктый. Хәер, алтын сарайда өйрәтеп бетермәгән хикмәтләр дә күп иде әле дөньяда. Ул серләрне инде үзең ачарга кирәк, ди. Шул серләрне ачар өчен алтын сарайдан кулыңа тылсымлы ачкыч тоттырып чыгаралар, ди. Уйлан, иҗат ит һәм тылсымлы ачкычыңны яңа буыннарга тапшыр.

## КЫЗЫЛ АЛМА

Бер бик киребеткән кыз булган, ди. Әти-әниләре аңа нинди матур уенчык алып кайтмасын, «Ямьсез!» дип аны атып бәрә икән. Әллә нинди тәмле ризыкларны да «Тәмсез!» димичә ашамый, ди. Әтиләре, әниләре кызларының көен табар өчен ничек кенә тырышмасыннар — кыз һаман үзенекен тукый биргән: «Ямьсез!», «Тәмсез!», «Кирәкми!»

Әллә чирле микән дип, кызны докторларга алып барып караганнар. Докторларның ак сакаллысы да, кара сакаллысы да, мыеклысы да, мыексызы да караган моны, әмма кыздан бернинди чир тапмаганнар болар.

Кызның әнисе нишләргә белмәгән. Хәлен ул таныш-белешләренә, дус-ишләренә сөйләп караган. Алар да акыллы гына киңәш бирә алмаганнар.

Шулай бермәлне күңелсезләнеп кайтып килгәндә, кызның әнисе алма сатучыга очраган. Алма сатучы үз алмаларын болай дип мактый икән: «Алмаларым кып-кызыллар, бик матурлар. Җәйге таңнар аларга үзләренең аллыгын, кояш — кайнарлыгын, җир бар тәмен биргән. Мондый алмаларны сез бүтән беркайда да таба алмассыз. Беткәнче алып калыгыз, алмасагыз, бик нык үкенерсез. Хикмәтле алмалар алар. Алыгыз, ал! Ә хикмәтен ашап карагач белерсез».

Алма сатучының бу сүзләрен ишеткәч, моның янына бик күп кеше җыелган. Һәркемнең бу хикмәтле алманы аласы килгән. Әлеге кызның әнисе дә тизрәк чиратка баскан. Алданрак басучыларга алма күбрәк эләккән. Ә кызның әнисенә нибарысы бер генә алма калган.

— Ярар, — дигән ул сөенеп. — Берәү эләккәч тә бик рәхмәт. Анда әле ала алмый калучылар да никадәр булды. Тизрәк кайтыйм да кызыма тоттырыйм әле. Бигрәк матур, бигрәк кызыл алма бит. Моның хикмәте, мөгаен, шушы матурлыгындадыр. Матур нәрсә күреп кем сөенмәс.

Киребеткән кызын, ниһаять, бер елмайта алуына өметләнеп, ана йөгерә-йөгерә өенә кайткан. Алманы бер генә булса да кабып карыйсы килүдән авызына сулар җыелган. Ләкин ул алманы капмаган, тешләмәгән. Чөнки бөтен килеш, матур килеш кызына җиткерәсе килгән.

Шулай ашыга-ашыга кайткан кызның әнисе. Кайтып керсә, кызы үз кирелегенә чыдый алмый дөнья бетереп елап утыра икән.

— Мәле, кызым, менә бу алманы, — дигән әнисе, кызның яшьле күзләрен сөртеп, — аны ашасаң, битләрең шулай кызарыр. Иреннәреңә елмаю кунар.

— Кирәкми, тәмсез ул! — дип, кыз әнисе сузган алманы атып бәргән һәм тагын да катырак еларга тотынган. Ә кызыл алма идән буйлап тәгәрәп киткән, үзен болай кадерсезләгән өчен ул бик-бик рәнҗегән. Бу өйдә бер генә минутка да каласы килмәгән аның. Ул идәндә тәгәрәп йөргән-йөргән дә өйдән чыгып киткән. Башта кечкенә сукмакка, аннары олы юлга чыккан.

Бара икән, бара икән кызыл алма тәгәрәп, бара торгач, юлда аңа кечкенә малай җитәкләгән бер хатын очраган. «Әнием, — дигән кечкенә малай, — кара әле нинди матур алма. Алып ашыйм әле шуны».

— Юк, юк! — дигән хатын, малаеның кулыннан әләктереп, — күрмисеңмени, ул ничек пычранып, тузанланып беткән.

— Тузанын мин аның чалбарга сөртәм, — дигән малай, һаман алмадан күзен ала алмыйча.

— Юләрләнмә, — дигән аңа әнисе, — кибеттән мин сиңа моннан да матурларын алып бирермен. Күп итеп.

— Моннан матур булмый! — дигән малай, үзсүзләнеп. Ләкин ничек кенә үзсүзләнсә дә әнисен җиңә алмаган.

Хатын белән малай китеп баргач, алма тагын алга таба тәгәрәгән. Юлында түмгәкләр очраса, урап үткән, күлдәвекләр күрсә, йөзеп чыккан. Шулай тәгәри торгач, кызыл алма урман юлына килеп кергән. Юлда аңа Керпе очраган.

— Әй, кызыл алма, — дигән Керпе, — болай ашыга-ашыга кая барасың?

— Кая күз күрсә — шунда! — дигән кызыл алма.

— Нишләп алай төнгә каршы берүзең юлга чыктың? — дигән Керпе.

— Бик рәнҗеттеләр мине, — дигән кызыл алма. Һәм кыз белән булган хәлне Керпегә сөйләп биргән.

— Әйе, — дигән Керпе, — хәлең әйбәт түгел икән шул. Тик кая барып чыгарсың икән соң? Юл да белмәгән килеш.

— Кая барсам да барып чыгармын, әмма теге киребеткән кыздан ераграк кына булыйм. Мин үземне кадерсезләгәннәрен бер дә яратмыйм. Чөнки мине хуҗам бик иркәләп үстерде. Әз генә сусый башласам, тәмле сулар эчерде, явыз кортлар шуышып миңа таба якынлаша башласалар, ул явызларны юк итте. Һәр көн хуҗам сокланып минем үскәнемне күзәтте. Мин, кайгыртучан хуҗамның күңеле булсын өчен, тизрәк үсәргә тырыштым. Иртәдән кичкә кадәр кояш нурларында коендым, чык сулары белән һәр иртәне битем юдым. Җәйнең иркә җилләре мине гел сыйпап китәләр иде. Кояш нурларын эчеп үскәнгә, минем битләрем кызыл, йомшак җил гел сыйпап торганга, шулай ялтырап торам мин.

— Әйе, — дигән Керпе, — син бик матур. Бу тиклем матур алманы минем күргәнем юк иде. Сине атып бәргән кыз йә бөтенләй сукырдыр, йә артык иркәләүдән бозылгандыр. Мин кешеләрне бераз беләм, нигә дисәң, кайчандыр мин үзем дә берәүнең өендә беркадәр яшәп алдым. Гөнаһларына керер хәлем юк, сине ыргыткан кебек ыргытмадылар. Бакчага иләп кенә чыгарып куйдылар да онытып гына. Ә мин хуҗа малай сөт чыгарыр дип озак көттем. Ләкин сөт чыгаручы булмады. Шуннан соң мин дә синең кебек үпкәләп чыгып киттем. Бара-бара туып үскән урманыма кайтып җиттем. Ярый әле әткәм-әнкәм өйрәтеп калдырган һөнәрне онытмаганмын икән. Урманга кайту белән үземә оя ясап куйдым, тычканнар ауларга тотындым. Хәзер тормышым гөрләп бара. Әгәр теләсәң, бездә кал. Бергә-бергә яшәрбез.

— Рәхмәт, Керпе, — дигән Кызыл алма. — Мин ераккарак китим әле. Рәнҗү-үпкәләрем онытылырлык урынга. Бәлки, берәр җирдә мине эзләүчеләр бардыр. Берәрсе сине кулына алып чын күңеленнән сокланса, кысылган иреннәрендә елмаю барлыкка килсә, нинди рәхәт була бит. Андый кешенең авызында бал булып эрисе килә. Безнең гомернең озынлыгы да шунда бит.

Шулай дигән дә алма яңадан тәгәрәп киткән. Ай барган, ел барган. Кара урманнарны, шаулы елгаларны кичеп чыккан. Юлда төрле ташларга бәрелеп аның бераз гына йөзе шадраланса да, элеккеге матурлыгын, элекке кызыллыгын җуймаган. Юлында очраган һәртөрле җан ияләре: «Нинди матур алма!» — дип сокланып карап калганнар аңа.

Ә теге Киребеткән кыз нишләгән дисезме? Ул һаман үзгәрмәгән: «Тәмсез!» — дигән, «Ямьсез!» — дигән. Ни бирсәләр, шуны ыргыткан. Йә елап, йә киреләнеп әтиләрен куркыткан.

Көн арты көн үткән. Таң аткан да кич булган. Менә шулай яшәп ятканда кыз бик каты чирләп киткән. Кызны дәваларга әти-әниләре докторларның кара сакаллысын да, ак сакаллысын да, мыеклысын да, мыексызын да чакыртып караганнар. Әмма ләкин берсе дә кызны дәвалый алмаган. Кыз күзгә күренеп сулган, ап-ак битләренә сары йөгергән, куллары күләгәдә үскән гөл сабагыдай, нәзекләнгән. Тавышы зәгыйфьләнгән. Ул инде хәзер киреләнеген дә оныткан. Әниләре «аша» дип тәмле ашлар тотып килгәндә, элеккечә кашыкны идәнгә ыргытып бәрмәгән. «Бик ашар идем дә, ашыйсым килми шул», — дип кенә җавап биргән.

Кызларының кайнар кояш астына әләккән май кебек кими, ябыга баруын әти-әниләре тыныч кына карап тора алмаган. Алар төрле чаралар эзләгәннәр. Тирә-якка хәбәр таратканнар: «Кем дә кем кызыбызның чиренә дәва таба ала — шуңа гомеребез буена рәхмәт укыр идек», — дигәннәр. Боларның бәхетенә каршы андый кеше табылган. Бер сукыр карт икән ул. Әллә ни еракта да түгел, күршедә генә яши икән үзе.

— Йә, балакай, кай җирең авырта? — дигән әлеге бабай, кызның йомшак чәчләреннән сыйпап. Кыз дәшмәгән. Чөнки кай җирен тотса — шул җире авырта икән. Әллә бабайның йомшак итеп чәченнән сыйпавыннан, әллә болай күңеле тулып, кызның күзләреннән яшь тәгәрәгән.

— Елама, кызым, — дигән гыйлем иясе. Кызның әти-әнисе бабайның бу сүзләренә бик гаҗәпләнгәннәр.

— Аның елаганын син ничек күрдең? — дип сораганнар.

— Кайгы белән шатлыкны күрер өчен маңгай күзе кирәкми, — дигән карт. — Кайгы белән шатлык иң беренче кеше йөрәгенә килеп бәрелә. Күз яше булып тәгәрәп төшкәнче аның кайнар дулкыны минем күңелемә бәрелеп өлгергән иде инде.

— Өмет бармы? — дип сораганнар кызның әти-әниләре. — Ул бит безнең бердәнберебез.

— Өмет барын бар, ләкин бераз соңаргансыз. Кызыгызның чире тирәнгә киткән, — дигән карт.

— Инде нишлик соң? — дигән ата-ана.

— Кызга кып-кызыл алма ашатырга кирәк, — дигән карт. — Тик ул алмада энә күзе кадәр дә башка төс булмасын. Хәтта сабак төбенә кадәр кызыл булырга тиеш ул. Шундый алма ашаса, кызыгыз терелер. Тик шуны кабатлап әйтәм: алма тигез кызарган булырга тиеш.

Картның бу сүзләрен ишетүгә, кызның әти-әниләре сөенешеп кибеткә чыгып йөгергәннәр. Көне буе йөргән алар, ләкин кайсын гына алып карасалар да, алмада йә берәр яшькелт, йә аксыл сызык була икән. Кып-кызыл дигәнең дә кайсыдыр җирендә йә кара-кучкыл, йә сыек кызыл тап була икән. Ничек кенә сайлама — бөтен җире тигез кызарган алма юк икән. Читтән караганда кызыл буяуга манып алган кебек алмалар кулга тотуга гүяки үзгәрәләр, ямьсезрәк булып күренергә тырышалар, ди. Инде таптым, бусы инде батып баручы кояш кебек дип сөенә-сөенә үлчәүгә саласың, ләкин шул вакыт сабак төбендәге чокырда нindидер аксыл төс күзеңә ташлана да тагын синең хыялларыңны җимереп куя, ди.

Бөтен кибетне бетереп тә эзләгән алманы таба алмагач, базарга киткән алар. Базарда алма бик күп икән. Әле бер өемгә, әле икенче өемгә ташланган болар. Йөри торгач, теге вакыт үзенең алмаларын хикмәтле алма дип мактап сатып торган кеше янына килеп чыкканнар. Тик бу юлы алма сатучы үзенең алмаларын алай кычкырып мактамый икән. Алмалары да элекке төсле кып-кызыл түгел, яшелләр, ди.

Кызның әнисе, бу алма сатучыны танып:

— Теге вакыт мин синнән бик матур кызыл алма алган идем. Шул алмаларың юкмы? — дигән.

Алма сатучы күңелсезләнеп:

— Юк шул, — дигән, — ул алмагачым корыды минем. Күрәсең, аның җимешен берәрсе кадерсезләгәндер. Шуны күтәрә алмагандыр. Без үзебез дә бит, балаларыбызны җәберләсәләр, кара кайгыга батабыз. Агачлар да шулай. Мин аны аеруча иркәләп, аеруча кадерләп үстергән идем.

— Син аны хикмәтле алма дип саткан идең. Сер булмаса, шуның хикмәтен әйтмәссеңме?

— Әйтәм, нигә әйтмәскә? — дигән алма сатучы. — Җан җылысын бирә торган алмалар иде алар. Ә кешенең җанында җылылык беттеме — бөтен чирләр алырга гына тора аны. Ул чирләрнең берсеннән котыласың, икенчесе эләктереп ала, икенчесеннән котыласың — өченчесе...

— Миңа шул алмаларның берсен генә булса да табып бирә алмассыңмы? — дигән кызның әнисе. — Кызым авырып түшәккә егылды. Шуны ашаса терелер иде.

— Бик бирер идем, — дигән алма сатучы. — Теге чакта миннән алган алманы кызың ашаган идеме соң? Ул бит аны ашаган булса чирләмәскә тиеш иде.

Кызның әнисе хәлнең дөресен сөйләп биргән. Алма сатучы белән алар озак кына сүзсез утырганнар. Бераздан алма сатучы болай дигән:

— Бәлки әле, ул алманы табарсыз. Әйе, соңарырга ярамый. Алманы эзли чыгарга кирәк.

Кызның әнисе йөгерә-йөгерә өенә кайткан. Кызының саргаеп, ямьсезләнеп калган йөзен күреп, ананың йөрәге телгәләнгән. Тагын ул теге гыйлем иясе карт белән киңәшкән.

— Тизрәк юлга чык, — дигән карт.

— Әтисен генә җибәримме? Аның адымнары эрерәк, егәре күбрәк, — дигән ана.

— Юк, — дигән гыйлем иясе, — юлга үзең чык. Ана кешенең күңеле сизгер була. Юкса алманың эзе югалуы мөмкин.

Кызның әнисе юлга чыгып киткән. Бара икән, бара икән, бара торгач ул бөтерчектәй малай житәкләгән хатынга очраган. Хатын улы белән әрләшеп бара икән.

— Туганкайлар, — дигән кызның әнисе боларга, — сез ерактан киләсезме?

— Бик ерактан киләбез, — дигән хатын. — Без юлга чыкканда минем малаем тездән иде, инде менә үзең күрәсең, бот буе булып бара.

— Юлда берәр тәгәрәп баручы кызыл алма күрмәдегезме? — дигән кызның әнисе.

Хатын авызын ачарга өлгергәнче малай җавап биргән.

— Күрдек, күрдек. Шундый матур, шундый кызыл иде ул.

— Әйе, — дигән малай җитәкләгән хатын. — Күрдек без ул алманы. Малаем белән шуның өчен әрләшеп бара идек әле.

— Нигә? — дигән кызның әнисе.

— Улым ул алманы ашарга теләде, ә мин бирмәдем. Шуннан бирле малаема әллә ни булды. Үземә каршы әйтә. Киреләнә, көйсезләнә.

— Ул алманың кайсы якка тәгәрәгәнен күрмәдегезме?

— Күрдек, — дигәннәр болар. — Урманга таба тәгәрәде.

Боларның шул сүзләрен ишетүгә, хатын юлга ашыккан. Озакламый урман юлына килеп чыккан. Анда ул Керпене очраткан.

— Тәгәрәп барган кызыл алманы күрмәдегезме? — дигән ул Керпегә.

— Күрдем, — дигән Керпе. — Тик син аны таба алырсың микән.

— Кайсы якка киткәнен генә әйт, — дигән кызның әнисе. Керпе алма киткән якка күрсәткән.

— Эзне югалтсаң, җиргә ятып иснә, — дигән Керпе. — Алма тәгәрәгән җирдә алма исе калмый булмас. Ул бик хуш исле алма иде.

Ана кеше Керпегә рәхмәт әйтеп ары киткән. Карурманнар, шаулы тау-елгаларны үтеп чыккан. Ачыккан, арыган. Юлда очраган аю-бүреләр дә куркыта алмаган аны. Шулай бара торгач, бик зур диңгез янына килеп чыккан ул. Диңгезнең дулкыннары юлбасардай өскә сикереп торалар икән. Кызның әнисе бу дулкыннардан куркып калмаган, диңгез кичеп юлын дәвам итәргә уйлаган. Ләкин шул вакыт аның борынына әллә каян бик тәмле алма исе килеп кергән. Ана сикерергә әзерләнгән җиреннән туктап калган. Як-ягына каранган. Караса, шунда диңгез яры өстендә кып-кызыл алма тора икән. Әгәр бер генә секундка соңгарса да алма диңгезгә сикереп төшәсе булган, әмма кызның анасы бик вакытлы килеп җиткән. Килеп җиткән дә кызыл алманы кулына алган. Сөенечтән аккан күз яшьләре алма өстендәге тузанны юып төшергән. Алма яңа гына агачыннан өзеп алгандай матурланып, ялтырап киткән. Бәхетле ана өенә шатлык канатларында гына очып кайткан. Кайтып керү белән ул кызының караваты янына тезләнеп кулындагы кызыл алманы сузган. Кыз әнисе югында тагын да ныграк хәлсезләнгән, инде соңгы сулышын алып яткан булган. Куллары әнисе сузган алманы көчкә-көчкә авызына китереп җиткергән.

Алманы бер тешләүгә, иреннәрендә елмаю чаткылары күренә башлаган, ике тешләүгә, битенә алсулык йөгергән, ә соңгы кабымны капканда инде ул торып ук утырган.

Кыз терелгән. Әмма кирелеген бөтенләй оныткан. Ә теге кызыл алманың төшен болар өй янындагы бакчага утырткаННар. Алмагач ел үсәсен көн үсеп, алма бирә башлаган. Хәзер инде бу кызыл алмаларны кешеләргә өләшә икән. Әгәр сезгә әниегез берәр вакыт кызыл алма алып кайтып бирсә, ашыйсыгыз килмәсә дә, идәнгә ыргытырга ашыкмагыз. Иплән кенә, кадерләп кенә берәр җиргә алып куегыз, аның хикмәтле алма булуы бар.

## ХӘКИМ УРМАНЫ

Җирнең нәкъ кыл уртасында зур да түгел, кечкенә дә түгел бер авыл булган, ди. Бу авылның кырыенда түбәләре күккә тигән таулар да, дөньяның бер читеннән икенче читенә сузылырлык елгалар да юк икән. Авылның бердәнбер карап торганы — кечкенә генә каенлыгы икән. Бу каенлыктагы каеннар елмайган сабый йөзедәй ап-якты, ап-аклар, әгәр озаграк карап торсаң, күзләрне камаштыра, ди. Ә каеннарның нинди төз, нинди сылу икәнлекләрен күрсәң, сокланудан күкрәкләр кысыла икән. Ләкин бу каенлыкның тагын бер ягын әйтмәсәң, авыл кешеләре миңа чын-чынлап үпкәләрләр иде. Анысы нәрсә, дисезме? Анысы — каеннарның бик зур сергә, сихри көчкә ия булулары. Әйе, бу каенлыкка картлар килсә — яшәрә, авырулар килсә — савыга, сукырлар — күрә, чукраклар ишетә башлый икән.

Менә шуңа күрә дә авыл халкы бу каенлыкны күз карасыдай саклый торган булган. Ягарга утыннары бетеп, салкын өйдә утырган чакларда да каеннарга балта күтәрергә һичбер кешенең башына килмәгән.

Әмма көннәрдән бер көнне авыл халкы каенлыкта агачларның сирәгәя башлавын сизеп алган. Бу хәбәр телдән телгә, колактан колакка, йөрәктән йөрәккә күчкән. Кешеләр хафага калган. Киңәш сорап авылның иң акыллы, иң зирәк картына — Хәким бабайга килгәннәр.

— Нишлибез? Бир үзеңнең берәр төпле киңәшеңне, — дигәннәр.

Хәким карт ак сакалын учлап озак кына уйланып утырган. Аннары җыелган кешеләрдән болай дип сораган:

— Каенлыкның сирәгәйгәнен ничек белдегез? Киселгән төпләр күрдегезме?

— Юк, киселгән төпләр күрмәдек, — дигән бер агай, алгарак чыгып.

— Киселгән төпләр булмагач, бәлки, сирәгәя дип хафалануыгыз юккадыр? — дигән Хәким карт.

— Бер дә юкка түгел, — дигән баягы агай. — Мин элек каеннар арасыннан ат белән үтә алмый идем. Арбаның күчәре әле бер агачка, әле икенче агачка эләгеп җәфаланып бетә идем. Ә беркөнне каенлык артындагы болынга печән чабарга барганда, атым чаптырып туп-туры каенлыкка кереп китте. Арбамның күчәре ник бер агачка эләксен...

— Әйе, әйе, — дип элеп алган бу агайның сүзен икенчесе. — Мин дә сизеп йөрим: каенлыгыбыз сирәгәя. Элек куяннар, койрыкларына китереп басмыйча, безне күрми торганнар иде. Ә хәзер ярты чакрымнан күреп кача башлыйлар.

Хәким карт уйга калган. Аннары болай дигән:

— Киселгән агач төпләре юк дисез инде алайса?

— Юк, юк!

— Ә чокырлар, үлән үсмичә каралып торучы убыр авызыдай чокырлар күрмәдегезме?

— Андый чокырлар күрдек, — диешкәннәр кешеләр, бер-берләрен бүлдереп.

— Алайса, бу — аждаһалар эше! — дигән Хәким карт. — Адәм заты агачны йолкып алалмый.

— Аждаһаларга безнең каеннарыбыз нигә кирәк булды икән соң? — дип аптырашканнар кешеләр.

— Нигә икәнен әйтә алмыйм, әмма алар эше булуына тамчы да шигем юк.

— Каеннарны коткарырга кирәк, — дигәннәр кешеләр. — Әгәр без шундый матур, шундый серле, шундый күркәм каенлыкны җуйсак, каткан күңелләребезне эретерлек, җыерылган йөзләребезне язарлык, сызлаган йөрәкләребезне басарлык урынны каян табарбыз?

— Шулай, карендәшләр, шулай, — дигән Хәким карт. — Сүзләрегез хак. Мин инде болай да кешеләр йөзендә нишләп җыерчыклар арта башлады икән дип уйлап йөри идем. Хәзер аңладым: каеннар сирәгәйгән саен арта бара икән алар. Нигә дисәң, каеннар бит тамырлары белән җиргә генә түгел, безнең йөрәкләребезгә дә береккән. Аждаһалар тамырлары белән каеннарны йолыкканда, һәммәбезнең йөрәк итләрен дә умырып алалар.

Авыл халкы киңәшкән-уйлашкан да каенлыкны чиратлап сакларга булганнар. Беренче көнне авылның иң гаярь егете киткән. Менә ул каенлыкка килеп җиткән дә иң биек, иң матур каен төбенә сузылып яткан. Төн бик якты икән. Офыкның әле бер башында, әле икенче башында йолдызлар атылган. Аҗаганнар уйнаган. Егет күкнең матурлыгына, серлелегенә сокланып күпме яткандыр, бервакыт сап-сары кабактай айның кырыенда әллә нинди койрыклы болыт әйләнеп йөри башлаган. Төн кинәт караңгыланып киткән. Салкын җил исеп куйган. Ә теге ай тирәсендә әйләнә торган койрыклы болыт һаман саен түбәнгәрәк төшә икән. Озакламый аның койрыгы — егет төбендә яткан каенның очына тигән. Каен калтырап куйган. Каенның калтыравы егеткә дә күчкән. Куркуыннан ул чытырдатып күзләрен йомган.

Ә һушына килеп күзләрен ачканда, теге койрыклы болыт та, әле генә төбендә егет яткан иң дәү, иң матур каен да булмаган. Бары тик каен үсеп утырган урында бик тирән чокыр гына авызын ыржайтып тора икән.

Егетнең бераздан куркуы узган. Хәзер инде аның күңеленә: «Кешеләр күзенә ничек күренермен?» — дигән шөбһәле уйлар килгән. Болай булса, аның батыр егет дигән исеме югалачак. Җитмәсә әле, шушы көннәрдә авылның иң гүзәл кызына өйләнергә йөри иде. Гүзәл кыз куркак егеткә кияүгә чыгармы? Ул бит әллә кайлардан, диңгез артларыннан килгән күпме егетләрне борып җибәрде. Ә ул егетләрнең киемнәре генә дә күзеңнең явын алырлык, атланган атлары гына да Дөлделләрдән[1] болайрак иде. Юк, бармаячак хәзер гүзәлкәй аңарга. Ул гына да түгел, авылның иң ямьсез, иң дәрәҗәсез саналган кызлары да аны үз янынынан куачаклар. Чөнки бу авылда бары тик батырларны, саф җанлыларны гына яраталар. «Ә бәлки, каеннан калган чокырны җир белән тигезләп куяргадыр? Агачларны бит беркемнең дә санаганы юк. Кайтырмын да, каенлыкка килүче булмады, диярмен».

Егет, башына мондый фикер килүенә сөенеп, чокырны тигезләргә керешкән. Таң атарга әле шактый ерак булган. Бик-бик тырышкан егет. Тиз арада чокырны тигезләп куйган. Чокыр урыны каралып тормасын өчен каенлык артындагы болыннан яшел чирәм кубарып алып килеп җәйгән. Таң ата башлауга эш тәмамланган. Бу урында каен үскәнлеген беркем белерлек булмаган. Инде өенә кайтып китәргә дип кенә торганда әллә нинди бер кайнарлык егетнең тамырлары буйлап йөгереп үткән: «Мин бит болай итеп кешеләрне икеләтә алдыйм. Минем алдаганымны кешеләр шундук беләчәкләр. Чөнки һәр агач йолкынган саен, кешеләрнең маңгайларында бер сыр арта бара. Юк, кешеләр йөзенә карый алмаячакмын мин», — дигән ул үз-үзенә һәм авылга әйләнеп кайтмаска булган.

Егетне авылдашлары көне буе көткәннәр. Алар инде, бер-берләренең маңгайларына карап, тагын бер каенның йолкынып алуын белгәннәр.

Кич җиткән, егет кайтмаган. Авыл халкы каенлыкны сакларга икенче егетне җибәргән. Бу егет белән дә нәкъ шундый ук хәл булган. Күп тапкырлар шушы хәл кабатлангач, кешеләр уйга калганнар: «Болай булса

каеннарыбызны гына түгел, асыл егетләребезне дә югалтып бетерәчәкбез. Безнең җирләребезне кем сөрер, икмәгебезне кем үстерер?» — дигәннәр. Һәм тагын Хәким картка киңәшкә килгәннәр.

— Киңәшеңнән ташлама, — дип ялварган алар.

Хәким карт үзе дә аптыраштa калган. Бигрәк тә егетләрнең югалуы гаҗәпкә калдырган аны.

— Аждаһа урлагандыр аларны, — дигәннәр кешеләр.

— Мин шуңа аптырыйм, — дигән Хәким карт, — нишләп каеннарны йолкып алган урында чокыр калмый хәзер?

— Бәлки, каеннарыбызны урламый башлаганнардыр, — дигәннәр кешеләр.

— Ә маңгайдагы җыерчыклар?

— Алар егетләребезне югалткангадыр.

— Анысы да мөмкин, — дигән Хәким карт. — Әмма ләкин үзегез күреп торасыз бит, карендәшләр, чокыры калмаса да каенлыгыбыз сирәгәйгәннән-сирәгәя. Җәнлекләр яшеренер урын да бетеп бара. Озын сүзнең кыскасы шул, карендәшләр, бүген каравылга үзем чыгам. Соңгы вакытларда мине барыбер йокы алмый башлады.

Авыл халкы Хәким картны каравылга җибәрергә һич кенә дә теләмәгән.

— Сине дә аждаһалар урласа, киңәшкә кемгә килербез? — дип әйтеп караганнар.

— Мин бит барыбер дөньяга гомергә килмәгән, — дигән Хәким карт. — Инде үзегезчә яши башларга вакыт. Гел-гел кеше киңәше белән генә яшәргә ярамый. Тормышта кеше барыбер кайчан да булса язмышы белән күзгә-күз кала. Менә минем шундый көнем җитте.

Шулай дигән дә Хәким карт, авылдашлары белән хушлашып, төнге каравылга киткән. Барып утырган ул иң матур, иң мәһабәт каен төбенә. Аждаһалар тегенди-мондый сихер белән йоклатып калдырмасыннар дип, билбавы белән каенга үзен бәйләп куйган.

Һәрвакыттагыча төн аяз, күк йолдызлы икән. Хәким карт, җидегән йолдызның койрыгы таңга таба борыла башлагач, үзендә ниндидер калтырау сизгән. «Бераз селкенгәләп алырга кирәктер, ахрысы, утыра-утыра каннар оеп киткәндер, күрәсең», — дип уйлаган ул һәм билбавын чишмәкче булган. Тик шул вакыт күккә күтәрелеп караса, ни күзе белән күрсен, ул утырган каенның өстендә җиде койрыклы бер аждаһа кара болыт төсле бөтерелеп тора икән.

— Әһә, килдеңме? — дигән Хәким карт.

— Килдем шул, — дигән Аждаһа, авызыннан утлар чәчеп. — Әгәр дөньяда тагын бераз яшисең килсә, читкәрәк кит. Мин хәзер бу каенны йолкып алам.

— Юк, — дигән Хәким карт. — Сиңа хәзер каен бирү бетте.

— Нәрсә синең белән сөйләшеп вакыт әрәм итәм соң? — дигән Аждаһа. — Миңа бит таң атканчы кайтып җитәргә кирәк.

Шулай дип үзенең җиде койрыгы белән чытырдатып каенга ябышкан. Хәким карт та хәлсез куллары белән каенны кочаклаган. Аждаһа аның юләрлегеннән кычкырып көлгән. Аждаһаның көлүеннән агачлар шаулаган, күкләр күкрәгән, хәтта зәңгәр бишегеннән ай егылып төшә язган.

— Ярый алайса, — дигән Аждаһа, — әгәр синең гомерең кадерле түгел икән, каеныңны кочаклый бир. Ә мин сине каеның-иең белән кеше яшәми торган утрауга алып китәм.

Аждаһа каенны йолкырга тотынган. Айкаган-чайкаган, әмма каен бирешмәгән. Аждаһаның җиде маңгаеннан җитмеш җиде бөртек тир тамып төшкән. Артык көчәнүдән хәтта аның койрыклары тирләгән, юешләнгән. Өскә тартылган саен, юешләнгән койрыклар каен кәүсәсе буйлап шуып чыга икән.

— Әй карт җүләр, — дип кычкырган Аждаһа, — кит әле ул каен төбеннән, юкса койрыгым белән берне сылармын.

— Мин монда китәр өчен килмәдем, — дигән Хәким карт. — Әйе, син койрыгың белән миңа берне түгел, икене сылый аласың. Хәтта мине үтерергә дә көчең җитәр. Әмма каеннан ычкындыра алмассың. Чөнки мин каенга бау белән генә түгел, йөрәгем белән бәйләнгән. Ә минем йөрәкне күтәрергә синең көчең җитмәс. Анда йөз елның кайгысы, йөз елның шатлыгы бар.

— Ә мин бүтән каенны да суырып ала алам бит, — дигән Аждаһа. — Тик кочаклап утыр үзеңнең каеныңны.

Аждаһа койрыкларын ычкындырып икенче каенга күчүгә, Хәким карт та йөгереп барып ул каенны кочаклаган. Төне буе шулай итеп йөреп, алар икесе дә арып беткәннәр. Арыган-алҗыган Аждаһа Хәким картка ялына башлаган.

— Зинһар, кит син моннан. Телисеңме, мин сиңа бер тау алтын китерәм.

— Алтын белән мин нишлим? — дигән Хәким карт.

— Алтын — бәндәләрнең иң кызыккан нәрсәсе инде, — дигән Аждаһа. — Мин дөньяда синең кадәр генә яшәмим. Кешеләрнең нәрсәгә табынганын беләм. Алтын өчен агачны гына түгел, җаннарын сатучылар бар.

— Бәхәсләшмим, бардыр, — дигән Хәким карт. — Әмма безнең бу каеннарыбыз җаннан кыйммәтрәк. Җан ул бүген җирдә, иртәгә күктә. Ә бу каеннар мәңгелек. Алар кешеләргә матурлык турында, изгелек турында, җирдә яшәүнең мәгънәсе турында сөйли. Буыннарны буынга, хәтерләрне хәтергә ялгаучылар. Әгәр кешеләр матурлыкка карап соклана белмәсәләр — җирдә мәхәббәт бетәр, сөенеч бетәр, җаннар буш булыр. Буш җанның нинди кыйммәте бар? Җан ул үзе кыйммәтле сыйфатлар тутыра торган капчык кына.

— Мин андый нәрсәләрне аңламыйм, — дигән Аждаһа. — Башым җиде булса да акылым ярты гына минем. Тик мин шуны яхшы беләм: миңа буш кайтырга ярамый.

— Нәрсәгә соң сиңа — Аждаһага — каен? — дип сораган Хәким карт . — Матур кызларны, батыр егетләрне урлаган аждаһалар турында күп ишеткәнем бар, ләкин агач урлаучы аждаһалар бардыр дип белми идем.

— Хәзер бездә кеше урлау кайгысы калмады шул, — дип күрсенгән Аждаһа. — Безгә агач кирәк. Яши торган урыныбыз бик сирәгәйде. Үзең беләсең, без бары тик куе урманнарда гына яши алабыз. Сездән урлап алып кайткан каеннарны без үзебезнең урманыбызга утыртабыз.

— Үсәләрме?

— Үсәләр, ләкин ни өчендер ике-өч көннән кап-кара булалар. Ап-ак каенның кинәт кенә кап-карага әйләнүенә бик аптырыйбыз.

— Туган-үскән җирләреннән аерылганга ул, — дигән Хәким карт.

— Инде нишләргә соң миңа? — дигән Аждаһа. — Син — акыллы кеше, бер киңәш бир. Җирдә бит безнең дә үз нәселебезне бетерәсебез килми. Ә урманыбыз сирәгәйгәннән-сирәгәя. Йә янгыннар ялмап китә, йә җил-давыллар иң шәп агачларыбызны егып сала. Инде качып балалар үстерер җиребез дә бетеп бара.

— Хәлегез бик мөшкел икән шул, — дигән Хәким карт. — Әмма болай агач урлап кына урман ясап булыр микән соң?

— Урламыйча үстерә торган чарасын өйрәт алайса, — дигән Аждаһа.

— Өйрәтүен өйрәтермен, тик минем белүемчә, сезнең хәтер ягы шәптән түгел бугай.

— Анысын дөрес сукалыйсың, адәми зат, бая әйткәнемчә, баш җидәү булса да, акыл ярты гына. Ә хәтер дигән нәрсә бөтенләй юк. Без бары тик явызлыкны гына онытмыйбыз. Без бит бар яклап та кешеләрнең киресе.

— Ничек ярдәм итәргә икән соң сезгә? — дип сакалын учлап уйга калган Хәким карт. Күктә ике йолдыз атылганчы уйлаганнан соң ул мондый карарга килгән. — Әйдә алайса, алып кит мине үзең белән. Баргач бирер нәрсә уйлап табарбыз, — дигән.

— Мин сине күтәрә алырмынмы соң? — дигән Аждаһа.

— Алырсың, — дигән Хәким карт, — чөнки мин кайгы-сагышларымны, сөенеч-уңышларымны туган җиремә күмеп калдырам. Мондагылар монда калырга тиеш. Юкса мин сезнең илегездә бик тиз саргаеп үләчәкмен.

Хәким карт җанына җыелган бөтен нәрсәсен бушата башлаган. Җаныннан алынган кайгы-сагышлары бер тау, шатлык-сөенечләре зур диңгез хасил иткән. Авыл кешеләре йокыларыннан уянып каенлыкка килеп карасалар, түбәсендә бер үлән дә үсмәгән биек тау белән кояш нурларында җемелдәшеп яткан энҗеле диңгез күреп шаккатканнар. Ә Хәким карт аждаһаның сыртына әйбәтләп менеп утырган, егылып төшеп билен кузгатмас өчен үзен билбавы белән бәйләп куйган. Таң алдыннан алар көч-хәл белән аждаһалар иленә килеп җиткәннәр. Аждаһа аны күтәреп бара-бара кара тиргә баткан.

— Син бөтен нәрсәңне дә туган җиреңә күмеп калдырмагансың, ахры, — дигән ул Хәким картка. — Нинди олы каенны күтәреп кайтып та моның кадәр арыган юк иде.

— Әйе, бар нәрсәмне калдырмадым, — дигән Хәким карт. — Акылны үзем белән алдым. Ансыз мин сезнең илдә бернигә ярамаячакмын.

Аждаһа үз иленә кайтып җиткәч, Хәким картны туп-туры Баш Аждаһа янына китереп төшергән. Баш Аждаһа моның агачсыз кайтуын күреп бик каты ачулана башлаган. Хәтта күзләре фонарь кебек янарга тотынган. Кече Аждаһа көч-хәл белән генә аңарга хәлне аңлатып бирә алган. Шулай да әле Баш Аждаһаның ярсуы бик озак басылмаган. Күзенә таң нуры төшкәч кенә тынып калган ул. Чөнки Аждаһалар яктылыктан куркалар бит.

Башлык бүтәннәрнең сүзенә колак салыр хәлгә килгәч, Хәким карт аның каршына барып болай дигән:

— Илегез өстеннән очканда мин күрдем: хәлегез мактанырлык түгел икән шул. Инде болай итәргә кирәк...

— Йә, йә, тизрәк әйт, — дип ашыктырганнар Хәким картны.

— Әйбәт эшләр ашыгып эшләнми ул, — дигән Хәким карт. — Сез сабыр гына тыңлап, мин кушканны эшләсәгез, хәлегез төзәлмәслек түгел әле.

— Йә, йә? — диешкәннәр аждаһалар.

— Хәзер бик тиз арада урманыгызда нинди җәнлек, нинди кош-кортлар барлыгын белергә кирәк. Кемнең нинди эшкә яраганын мин үзем тикшерермен.

Баш Аждаһа җиде авызына җиде койрыгын тыгып җиде тапкыр сызгырган икән, барлык җәнлек, барлык кош-кортлар җыелышып беткәннәр. Хәким карт тиеннәрне чикләвек җыярга җибәргән.

— Карагыз аны, — дип кисәткән ул, — имән чикләвеген дә, нарат-чыршыныкын да, адәми затлар ашый торган чикләвекләрне дә җыегыз.

— Ярар, ярар, без монысын булдырабыз, — дип, тиеннәр урманга таралышкан.

Тиеннәр эшкә тотынуга, Хәким карт кабан дуңгызларын чакырып алган:

— Сез буразна-буразна итеп борыныгыз белән җир сөрегез, — дигән ул.

Чират төлкеләргә, бүреләргә җиткән.

— Ә сез нишли беләсез? — дип сораган Хәким карт алардан.

— Ашый беләбез! — дигәннәр алар.

— Моннан соң ашар өчен эшләргә кирәк булачак, — дигән Хәким карт. — Беләм, сез әле эшкә өйрәнмәгән, ләкин, тиз арада бөтенләй кырылып бетәсегез килмәсә, эшкә өйрәнергә туры килер. — Шулай дип ул бер юкәне каезлап алган да элмәк ясап бүреләрнең, төлкеләрнең муенына кидерткән. Аннары бер эче буш агачны аударып, озын юкә белән бүреләрне шушы агачка бәйләгән. «Хәзер, — дигән ул, бүреләрнең сыртына берне сыптырып, — инештән су ташыгыз. Бу агачның менә бу турында тукран тишкән тишеге бар. Суны шуннан тутырыгыз. Тик карагыз аны, кайтканда йөкне тигез тартыгыз. Тагын шунысын онытмагыз: агачның тишекле ягы гел өстә булсын».

Бер өер бүре бер яктан, бер өер төлке икенче яктан куыш агачны өстерәп инешкә киткәннәр. Кабан дуңгызлары җир сөргән, тиеннәр чикләвек ташыган, бүреләр су китергән, кошлар буразнага чикләвек сала барган. Аждаһалар койрыклары белән буразнаны күмеп йөргәннәр. Урманда эш кайнаган. Бер генә җан иясе дә тик тормаган. Эшләү җәнлекләрнең үзләренә дә ошап киткән.

Агачлар шулкадәр тиз үсә башлаганнар: бер караганда тубыктан булса, икенче караганда тезгә, аннары билгә җиткән. Хәким картны хәзер аждаһалар күтәреп кенә йөрткәннәр. Бүреләр аңа еррактан ук сәлам биргән, төлкеләр дөнья серләрен күбрәк төшенеп калырга тырышып аңардан төрле хикәятләр сөйләткәннәр. Тиеннәр чикләвек ватып биргәннәр.

Көн артыннан атналар, атна артыннан айлар, ай артыннан еллар үткән. Урман гөрләп үскән, җилләр шаулап искән. Җәнлекләр урманга карап сөенеп туя алмаганнар. Ләкин Хәким картның гына хәле көннән-көн начарлана барган. Иң татлы җимешләр, иң шифалы чишмә сулары да аның хәлен җиңеләйтә алмаган.

— Әллә соң өеңә илтеп куйыйкмы үзеңне? — дигәннәр аждаһалар. — Безнең өчен сине җибәрү җиңел түгел, әмма ләкин болай газаплануыңны күрү тагын да кыенрак.

— Юк инде, — дигән Хәким карт, — юл газапларын кичерерлек хәлем калмады минем. Аннары җанымны мин бит инде туган туфрагыма күмеп калдырдым. Монда минем акылым белән гәүдәм генә килде. Яши-яши миңа бу җирләр дә якынайды. Шушында гына үләрмен инде мин.

Хәким карт шул сүзләрне әйтеп бетергән дә үлеп киткән. Аны күмгәч, бөтен җәнлекләр өч көн буена авызларына берни капмаганнар. Бүреләр көне-төне улаган, төлкеләр җирне тырный-тырный елаган. Аждаһалар моннан соң кеше затына һичнинди зыян китермәскә ант иткәннәр. Хәтта берничә көн кояш та күктә күренмәгән.

Көн артыннан тагын көннәр үткән. Кайгы болытларын шатлык җилләре куалаган. Өр-яңадан яп-якты булып кояш чыккан. Һәр агач башында кошлар сайраган. Иң кызыгы тагын шул икән: аждаһалар шушы көннән алып начарлыкны гына түгел, яхшылыкны да онытмый башлаганнар. Әгәр кайвакыт таза тәннәрендә каннары кайнап, кешеләргә берәр яманлык кылырга уйласалар, келт итеп исләренә Хәким карт килеп төшә икән дә, үз уйларыннан үзләре оялып, өннәренә посалар икән.

Ә теге каенлыктагы агачлар, аждаһалар тими башлагач, бик нык җәелеп, тагын да матурланып киткән, ди. Аны тирә-юньдәге бөтен кешеләр дә «Хәким урманы» дип йөртә башлаган, ди.

## АК КАЗ

Алайдырмы-болайдырмы, җайсыздырмы-уңайдырмы, ямьсездерме-чибәрдерме, акыллымы-юләрме, яшәгән ди бер авылда бик карт кына бер кортка. Иртәсен дә, кичен дә ашаган, ди, ул ботка. Боткасы зур

табакта ди, үзе карый як-якка, ди, ике кулда кашыгы, ди, ашый кортка бу ботканы ике куллап ашыгып, ди. Ә ботка гел кимеми, ди, кортка ашап өлгерми, ди. Үзе ашап бетерми, ди, бүтәннәргә бирдерми, ди. Бу ботканың уртасында бар икән, ди, зур май күле. Май күлендә казлар йөзеп йөриләр, ди, көне-төне. Бу казларның бик күбесе ала булган, тик берсе ак, тагын берсе кара булган. Ак каз гел-гел җырлап йөргән. Күңеле аның бик көр икән, аның өчен бөтен нәрсә кызыклы һәм гел сер икән. Ул җырласа, май күлләре моңга тулган, ә Ак казның җыры менә болай булган:

Ап-ак минем канатларым,
Ап-ак минем түшләрем.
Ап-ак минем хыялларым,
Ап-ак минем тешләрем.
Кыйгак-кыйгак,
Кыйгак-кыйгак!
Иртәсен дә коенам,
Кичләрен дә коенам.
Көннәр буе кайтып кермим
Май күленең буеннан.
Кыйгак-кыйгак,
Кыйгак-кыйгак!
Өсләремә тузан кунмый,
Каурыйларым ялтырый.
Минем болай аклыгыма
Бөтен казлар аптырый.
Кыйгак-кыйгак,
Кыйгак-кыйгак!

Бу Ак казның күңеле һәрчак шат булуга, тәне гел ап-ак булуга Кара каз бик көнләшкән, ди. Бу Ак казны ничек итеп бер акылга утыртырга икән дип, ала казлар белән озак киңәшкән, ди. Ала казлар Кара каздан көлгән генә: «Җырлый икән җырлый бирсен, тик куансын, май-көзгегә карасын да тик юансын. Аның җыры беркемгә дә зыян итми, ул бит бездән һичбер төрле мактау көтми, яклау көтми».

Кара казның бу сүзләргә ачуы килгән, ачуыннан боткага кереп баткан, ди, ул башта боттан, аннан билдән. Ала казлар аны көчкә тартып чыгарганнар. Май күленә чумдырганнар, чистартканнар. Каурыйларын шомартканнар. «Менә син дә бик матур бит, — дигән алар. — Канатларың елык-елык килеп тора, түшеңдәге тамчыларда кояш үзе көлеп тора. Кара әнә май-көзгегә: бер килмәгән җиреӊ юк бит, хәтта синең борының да каратут бит».

Кара казның күңеле бераз йомшый төшкән, тынычланыр өчен күлдән кайнар майлар төшеп эчкән. Әмма үче аның барыбер бетмәгән, ди. Бугазыннан кайнар төер китмәгән, ди. Ак каз исә, уйламыйча аны-моны, тирә-якка тараткан, ди, шатлык моңы. Хуҗабикә дә яраткан аның җырын, тыңлаган ул аны кайчак ятып кырын. Кара казның бәгырьләре кискәләнгән, көнләшүдән бәргәләнгән, өзгәләнгән. Тик үз хәлен сиздерергә курыккан ул, хәлен әйтеп, хуҗа күңелен биздерүдән курыккан ул. Казларга да белдермәгән — ачуын йоткан, тик Ак казга эчендә гел бер үч токкан.

Май күлендә йөзгән казлар шулай көн-төн, хәвеф-хәтәр килер диеп уйлап карамаган беркем. Әмма берчак шомлы хәбәр таралган, ди, имеш, тауның аръягында ниндидер бер сукыр дию яралган, ди. Сукыр дию урлый икән төнлә килеп авылдагы егетләрне. Кайда авыл барлыкны ул тавыш буйлап таба икән, кайсы яктан тавыш килсә, тизрәк шунда чаба икән.

Хәзер инде төн җитүгә, бар тавышлар калган тынып, дию кайтып китә икән авылларны табалмыйча өмете сынып. Ә Ак казны хуҗа бик кисәтеп куйган: «Кара аны, әгәр-мәгәр ялгыш кына кычкырсаң да тотып суям. Бүген дию безгә таба киләсе, — ди. — Сүзең булса таң аткачтын сөйләрсең», — ди.

Озакламый кичләр җиткән, эңгер төшкән. Кара болытлар кубарып җилләр искән. Ай чыкмаган, ә йолдызлар йоклаган, ди. Сукыр дию йокламаган, үз гаскәрен туплаган, ди.

Төн уртасы килеп җиткән, гаскәр тәмам җыелып беткән. Дию үзенең койрыгына атланган да гаскәр белән чыгып киткән. Барган болар, барган болар, бара-бара арган болар. Бик күп юллар таптаганнар, тик авылны тапмаганнар. Кайтырга дип торган чакта, койрыкларны борган чакта, кинәт алар ишетеп алган бер каз тавышы:

Кыйгак-кыйгак,
Килегез, килегез монда таба.
Авылыбыз бай, күлебез — май,
Чишмәбездән баллар ага.

Бу җырны шул кара каз җырлаган, ди, чөнки күңелен гел көнчелек тырнаган, ди. «Мактанмасын әле Ак каз җыры белән, җырны аны мин дә беләм. Юкса хуҗа аны ныграк ярата бит, җыры белән ул үзенә карата

бит. Менә хәзер дию мине ишетсен дә әйләндерсен авылыбызның астын-өскә. Иртәгесен хуҗа суяр бу Ак казны, аннан миңа бирер бөтен иркә-назны».

Шулай дигән дә Кара каз торган бераз, аннан җыр башлаган киереп бугаз:

Кыйгак-кыйгак,
Җырым чишмә булып ага.
Авылыбызны эзләүчеләр
Җырым буйлап эзләп таба.

Казның бу җырын ишеткәч, сукыр дию бик куанган, шатлыгыннан чатан-ботан биеп алган. Аннан киткән авылга дип, барысын кырып салырга дип. Беркемне дә җәлләмәгән ваткан-кырган, бар авылны пыр туздырган. Көчсезләрне камчылаган, көчлеләрне үзенә ялчыга алган, сукыр дию узганнан соң авылның тик хәрабәсе генә калган.

Иртән торгач, бу казларның хуҗалары — хәлсез кортка — ике кашык белән ашаган да бераз ботка, сораган ул казларыннан:

— Йә, әйтегез, кайсыгыз тыймады телен? Әйтегез, әйт, дөресен белим. Синме Ак каз, сөрән салдың, дошманнарны чакырып алдың?

— Юк, юк, — дигән Ак каз шунда чын күңелдән, — бер аваз да чыгармадым бүген телдән. Авызымны ачмадым мин таңга кадәр, валлаһи, дим, билләһи, дим, чын-чын әгәр.

— Алдаша ул, — дигән Кара каз, каңгылдап, — ул кычкырмый кем кычкырсын. Мин бит үзем тордым тыңлап.

Бәхәс купкан: кыйгак-кыйгак! Мөмкин түгел хәтта барсын тыңлап тормак.

Ала казлар әйтә икән:

— Без йокладык, төне буе уянмадык, кыймшанмадык. Аннан без бит җырларга да әвәс түгел. Ник җырлыйк ди, безгә болай да бик рәхәт, бик-бик җиңел.

Шулай итеп, Ак казга төшкән бөтен шик. Син чакыргансың дошманны, хәзер мин сине суям, дип кереп киткән хуҗа карчык өйләренә. Аннан пычак алып чыккан, үткен пычак. Ләкин Ак каз канатларын кагынган да кинәт шулчак, күтәрелгән югарыга, болытларга. Һәм җырлаган болай диеп соңгы тапкыр:

Кыйгак-кыйгак, кыйгак-кыйгак,
Рәхмәт, хуҗам, тоттың сыйлап.
Моңа кадәр кайгы белми,
Үстем уйнап, үстем җырлап.
Кыйгак-кыйгак, кыйгак-кыйгак,
Инде китәм ерак-ерак.
Сагынуларга түзалмасам
Бер кайтырмын, бәлки, урап.

Ак каз шулай җырлаган да, туган ягын җиде тапкыр ураган да очып киткән күз күрмәгән ерак җиргә. Хуҗасының ышанмавы аның күңелен бик рәнҗеткән, бик кимсеткән. Рәнҗүеннән елый-елый күзләрендә яше кипкән. Мәңге кайтмыйм дип сүз биргән ул үзенә. Һәм сүзендә бик нык торган, озак түзгән. Йөгерә-йөгерә атналар һәм айлар узган. Менә бермәл аның күңелен сагыш баскан. «Их, — дигән ул, — туган якка яз килгәндер. Йөзеп үскән безнең күлләр бик тирәндер. Бер чумасы иде шунда элеккечә, кагынасы иде тамчы чәчә-чәчә. Безнең якның төннәре дә йолдызлырак, ай да тора майлы боткадай ялтырап. Нишләп әле монда йөрим мин каңгырап?»

Уйлаган да Ак каз менә шундый уйлар, чыгып киткән кайтыр юлга, озын юлга. Кычкырган ул үзе һаман кыйгак-кыйгак. Рәнҗүләрен онытткан, ди, илен уйлап. Кайтып җиткән, оя корган кайткан шәпкә, ә аннары чыгарган, ди, алты бәбкә. Бәбкәләре үсеп җиткән бик тиз генә, бар да аклар, тимәсен, ди, тик күз генә.

Балалары үсеп җиткәч, Ак каз тагын исенә алган үзенең рәнҗетелгән чагын. «Харап, — дигән, — балаларымны тотсалар. Бер гөнаһсызга суям дип куркытсалар. Юк, юк, — дигән, — монда калу ярамастыр, кешеләр безгә барыбер әйбәт карамастыр».

Китеп барган ап-ак казлар җылы якка, рәнҗетмәгәйләре дип гел нахакка. Ләкин алар түзә алмый сагынуга, кайтып төшә тагын язлар кабынуга. Китә-кайта яши алар хәзер шулай. Үпкәләрен һаман онытмыйлар бугай. Нахак сүзне онытып булмый: кыйгак-кыйгак, әнә казлар китеп бара офык буйлап. Артларыннан балалары тезелеп бара, туган якта тавышлары өзелеп кала. Кыйгак! Кыйгак!

## ЗӘҢГӘР КҮЛДӘ АЙ КОЕНА

Төннәрен барлык кешеләр йоклап беткәч, бакалар бакылдаудан, кошлар сайраудан, яфраклар шаулаудан, җилләр исүдән туктагач, Зәңгәр күлгә төшеп Ай коена икән. Чөнки ул чисталыкны бик яраткан. Бөтен тәнен исле сабын белән ышкый-ышкый икән дә күлнең иң тирән җиренә чума-чума рәхәтләнә икән. Шулай әллә ничә тапкыр тәнен сабынлап, әллә ничә тапкыр чумып чыкканнан соң ул күп итеп төнбоек чәчәкләре җыярга тотына икән. Чәчәкләрнең дә төрлесен түгел, иң акларын, тәмам ачылып җиткәннәрен генә җыйган ул. Ике учы тулганчы төнбоек чәчәкләре җыйганнан соң, Ай үзенең болыттан ишеп ясаган баскычының йомшак басмаларына сак кына баса-баса күккә күтәрелә икән. Күккә менеп җиткәч, кулындагы төнбоек чәчәкләрен әле бер якка, әле икенче якка ыргытып уйнарга тотына икән. Ә ул ыргыткан төнбоек чәчәкләре күкнең түшәменә кадалып йолдыз булып яна башлыйлар, ди. Әгәр төн уртасында урамга чыгып күккә карасагыз, Айның чәчәкләрне күккә кадап йөрүен күрер идегез, мөгаен. Ул чагында төн көндезге кебек яп-якты була, чөнки яңа гына Зәңгәр күлдә коенып чыккан Айның тәне чип-чиста, җилләр йоклагач, болытлар да бүредән курыккан сарык көтүедәй чабышып йөрми, ояларында әкият тыңлап тыныч кына ята бирәләр. Ә Айга рәхәт, ашыкмый гына дөнья гизә, йолдызлар бер-берләренә зә-бәрҗәт ташлар ыргытышып уйный башласалар: «Әй, балалар, артыгын шашмагыз. Ыргыткан ташларыгыз җиргә килеп төшәр дә берәрсен һәлак итәр. Шуннан соң кешеләрнең безгә ачуы чыгар», — дип, йолдызларны тыеп тора икән.

Һәркөн шулай төн артыннан төн туган, күкнең биек түшәмендә йолдызлар җемелдәшкән, һәр төн шулай Зәңгәр күлдә коенырга Ай төшкән.

Ә бер төнне, гадәттәгечә, Ай күлдә чума-чума коенып ятканда, кинәт кенә җил уянган, чөнки җилнең җирдәге койрыгына ялгышып бер сукыр тычкан китереп баскан. Җил койрыгы авыртуга түзә алмыйча үрле-кырлы сикергән. Аннары авырткан җиренә сулышын өрергә тотынган. Җил койрыгына шулкадәр өргән, ди, аның өрүеннән күл читендәге камышлар шаулый башлаган. Әнә шулай итеп сукыр тычкан җилне, җил — камышларны, камышлар су өстендәге дулкыннарны уяткан. Йокысыннан вакытсыз уянган дулкыннар күл өстендә галәмәт тавышлар чыгарып чабышканнар. Кайбер усалраклары күлдә үсеп торган төнбоекларны йолыккан, кайберләре кулы авыртканчы ярны кыйнаган, ә кайберләре су читендәге бака ефәкләрен йолкып-йолкып эчкәрәк, Ай коенып ята торган төшкәрәк китергән. Ай, су керүе белән мавыгып, җилнең йокыдан уянуын да, дулкыннарның ачуланышып төрле якка йөгерешүләрен дә күрми калган. Ә инде күргәч судан атылып чыгыйм дигән икән, яр буеннан дулкын куып китергән бака ефәгенә уралган да калган. Ай әле тегеләй ыргылган, әле болай ыргылган, әмма бу ефәк җәтмәдән ычкына алмаган. Айның тыны бетә башлаган.

— Коткарыгыз, батып үләм, — дип кычкырган ул бар көченә. Аның тавышын иң беренче булып карт Чуртан ишеткән.

— Нәрсә төнне куркытып кычкырасың? — дигән ул Айга.

— Чуртанкай, — дигән Ай, — зинһар, коткара күр. Синең тешләр бик үткен, бу ефәкне «әһ» дигәнче ерткалап атачаксың.

— Бик коткарыр идем дә тешләрем сызлап тора шул, — дигән Чуртан, Айның батуына сөенеп. Чөнки ул Айның шундый матур, шундый якты булуына, бөтен дөньяны сокландырып торуына бик көнләшеп йөргән икән. Аннары Айның ашамыйча-эчмичә яши алуына бик тә эче пошып йөргән булган Чуртанның. — Без монда көн саен тамак туйдыру турында уйлыйбыз, әллә кемнәрнең кармакларына эләгәбез. Ә син эшләмичә рәхәт кенә яшисең, — дигән Чуртан.

— Минме эшләмим? — дигән Ай. — Мин, беләсең килсә, төне буе бөтен дөньяны яктыртам. Мин булмасам, төнге юлчылар барыр юлларын таба алмаслар, диңгезләрдә кораблар батар, караңгыда юлбасарлар, караклар бер гөнаһсыз кешеләрне таларлар.

Чуртан аның сүзен бераз гына тыңлап торган да Айның һаман саен тирәнрәк бата баруын күреп, бәладән башаяк дип китеп барган.

Ай тагын бар көчен җыеп кычкырган:

— Коткарыгыз, батып үләм.

Бу юлы Айның тавышын бер бик тә чатан аяклы, карлыккан тавышлы Гөберле бака ишетеп килгән.

— Әй, син нәрсә, — дигән ул Айга, — безнең ефәкне урларга килдеңме әллә?

— Коткарчы, зинһар, — дигән Ай, — тыным бетә. Күктә ялтырап торыр вакытым җитә. Кешеләр күктә минем юклыкны күрерләр дә хафага калырлар. Ә минем кешеләрне бер дә кайгыга саласым килми.

— Ярар, коткарырмын, — дигән Гөберле бака, — тик башта син минем тавышымны тыңлап кара. Матур сайрыйммы мин?

Бака әллә нинди тавышлар чыгарып бакылдарга тотынган. Тавышы аның авызына су кабып гөбердәткән кешенеке кебек гөбердәгән-бакырдаган.

— Йә, матур сайрыйммы? — дигән Гөберле бака. — Тавышым минем сандугачныкыннан матуррак бит, әйеме?

— Сандугачныкыннан матур дип булмый инде анысы, — дигән ялганларга өйрәнмәгән Ай. — Ләкин син аңа бер дә борчылма. Син бит бака: баканың үз җыры, сандугачның үз җыры.

— Ә-ә, шулаймы? — дигән Гөберле бака. — Әгәр бөтен күлгә ишеттерерлек итеп: «Гөберле баканың тавышы сандугачныкыннан матуррак», — дип кычкырмасаң, сиңа бу күлдән чыктым юк. Йә, кычкырасыңмы, мин көтәм. Өчкә хәтле санаганчы авызыңны ачалмый торсаң, китеп барам. Йә, башладык: бер... ике... өч...

— Юк инде, — дигән Ай, — мин ялганлый алмыйм. Ялганласам, минем йөзем каралачак, ә кара йөзле Айның кемгә кирәге бар?

— Алайса, үзеңә үпкәлә, — дигән дә китеп барган Гөберле бака.

Ай соңгы көчен җыеп тагын кычкырып җибәргән:

— Әй-әй-йй! Коткарыгыз, батып үләм.

Бу Зәңгәр күл буенда гына бер балыкчы яши икән, балыкчының Айсылу исемле кызы булган. Шушы балыкчы кызы Айсылуның ни өчендер ике як битенә дә уч төбе кадәрле кап-кара миң үскән булган. Үзенең шул миңнәреннән оялып Айсылу урамга да төннәрен генә чыга икән. Менә шушы Айсылу исемле кыз күл буенда:

Битләремдәге миңнәрем
Бетми күпме юсам да,
Бәхетлерәк булыр идем
Бака булып тусам да, —

дип моңаеп җырлап йөргәндә, Айның ярдәм сорап кычкырганын ишеткән. Ишеткән дә аны-моны уйлап тормастан күлгә таба йөгергән. Айның инде ныклап кычкырыр хәле дә калмаган булган. Ул бер баткан, бер калыккан.

— Әй, сөйкемле Ай, матур Ай, — дигән Айсылу, әз генә түз. Мин хәзер... — Кыз бөркәнеп чыккан шәлен иңеннән алып ыргыткан да, йөзә белмәвен дә онытып, суга ташланган. Ике чумып, бер калкуга ул инде Ай янына барып җиткән. Тик аның үзенең дә кулларына, муеннарына бака ефәге уралган. Әмма кыз үзе турында уйламаган, тизрәк Айны коткарырга тырышкан. Калын бака ефәген ул бөтен көченә ерткаларга, өзгәләргә тотынган. Менә бермәлне ефәк арасыннан Айның түп-түгәрәк, яп-якты йөзе күренгән.

— Рәхмәт, чибәркәй, — дигән Ай чын күңеленнән, — коткардың.

— Алай димә, — дигән Айсылу, — мин чибәр түгел, мин ямьсез кыз. Шул ямьсезлегемнән оялып, мин көндезләрен урамга да чыкмыйм.

Ай үзенең баскычы буйлап күккә таба үрмәли башлаган, Айсылуга әллә нинди матур сүзләр әйтәсе килгән аның, ләкин вакыты бик аз калган булган. Чөнки күккә менеп йолдызларны кабызыр вакыт җиткән. Күккә менеп җитә язгач, ул түбәнгә караган да Айсылуга болай дип кычкырган:

— Чибәркәй дип мин ялганламадым. Син чынлап та дөньяда иң-иң чибәр кыз. Әгәр минем сүзләремә ышанмасаң, йөгереп өеңә кайт та көзгегә кара.

Кыз йөгерә-йөгерә өенә кайткан. Ут кабызган. Курка-курка көзге каршына килгән. Озак кына көзгегә карарга йөрәге җитми торган. Ә караса... Ә караса, көзгедә гүзәлләрнең гүзәле бер кыз басып тора икән. «Мин түгелдер, бу бүтән берәр кыздыр», — дип, Айсылу үзенең битләренә кагылган, көзгедәге кыз да шул ук хәрәкәтләрне кабатлаган. Айсылу озын толымнарын сүтеп иңнәренә тараткан, көзгедәге гүзәл дә шуны ук эшләгән.

Бик озак ышана алмаган Айсылу моның үзе икәнлегенә. «Битемдәге олы ямьсез миңнәр кая китте икән соң?» — дип уйлаган ул.

Мин дә башта, кызның миңнәре кая китте икән соң, дип уйлаган идем. Хәзер белдем инде. Ай аның йөзенә үзен коткарган өчен якты нурларын ягып калдырган икән. Шуңа хәзер иң матур кызларга:

Ай туганда тудыңмы әллә,
Ай нуры бар йөзеңдә, —

дип җырлыйлар бит. Ә Ай үзенең якты нурын бары тик күңеле матур кешеләрнең йөзенә генә яга ала. Чын-чын. Әгәр минем сүзләремә генә ышанмасагыз, кемгә дә булса яхшылык эшләп карагыз, шунда сез айның тылсымлы нурларында коенгандай матурланып китүегезне күрерсез.

## КОЯШТАГЫ ТАП

Еракта, бик еракта, Каф тавының аръягында, кояш һәр көн йокларга кайта торган җирдә яшәгән, ди, бер малай. Малайның бары тик әнисе генә булган, ди. Малайның әнисе кояш белән бергә торган, кояш белән бергә яткан. Ул көннәр буе нидер чәчкән, нидер урган, нидер төзәткән, нидер яңарткан. Ә улы аңардан юри генә дә: «Әнием, син көннәр буе бил турайтмыйча ниләр эшлисең?» — дип сорамаган, гел уйнаган да уйнаган.

Менә көннәрдән бер көнне малайның әнисе авырып түшәккә егылган. Шунда ул урамда болытларга ук атып йөрүче улын өенә чакырып керткән дә болай дигән:

— Улым, үзең күрәсең, хәлем кинәт начарланып китте. Хәтта суга барырга да өлгерми калдым. Ә минем бик-бик эчәсем килә. Иреннәрем кара көеп чыкты. Берәр чиләк су гына алып кайтчы, балам.

Малай, үзен кызыклы уеннан бүлдергән әнисенә канәгатьсезлек белән карап:

— Суны иртән тору белән апкайтып куйсаң булмый идемени? — дигән.

— Иртүк алып кайтсам, көне буе җылынып бетәр дигән идем. Син бит кичләрен уеннан арып кайткач салкын су эчәргә яратасың, — дигән малайның әнисе.

Малай бик авырлык белән генә суга барырга ризалык белдергән.

— Улым, — дигән әнисе аңарга, — суны теге Көймә тавы артындагы чишмәдән ал. Аның суы тәмле дә, салкын да, шифалы да.

Малай чиләген күтәреп урамга чыккан. Кулын кашына куеп, Көймә тавына таба караган. Көймә тавы бик-бик еракта, зәңгәр офыклар артында булып күренгән аңа. Җитмәсә, кояшы өтеп алырдай итеп кыздыра икән.

«Мондый кызуда шултиклем еракка барып йөргәнче, суны менә шушы якындагы чишмәдән алсам да ярар әле», — дип уйлаган малай һәм, чиләген бер читкә куеп, өр-яңадан уйнарга тотынган. Үзенең дә бик каты эчәсе килгәч кенә, суга барырга кирәклеге исенә төшкән.

Менә ул бермәлне тирләп-пешеп судан кайтып кергән. Әнисе аның чәчләреннән сыйпап: «Рәхмәт, улым, бик зур рәхмәт», — дигән. Һәм йотлыгып-йотлыгып суны эчә башлаган. Эчкән саен күкрәгендә көч арта баруын сизгән. Бераздан инде бөтенләй сәламәтләнеп җиткән. Малай сөенә-сөенә урамга чыгып йөгергән.

«Белмәде, әнием суның кайсы чишмәнеке икәнлеген белмәде», — дип уйлаган ул. Шулай дип уйлавы булган, күктә яп-якты булып янучы кояш кинәт карала башлаган. Дөнья коточкыч ямьсезләнеп киткән. Кош-кортлар куркышып ояларыннан качканнар. Шомлы итеп, елап-елап этләр өрергә тотынган. Малай ни уйларга да белмичә, курка-курка өенә чапкан.

— Әни, — дигән ул, сулышын көчкә-көчкә алып, — нишләптер кояшның йөзе каралды. Әнә тышка кара әле.

Әнисе кояшка караган да болай дигән:

— Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш, улым. Кояшның шул кеше өчен оялудан йөзе каралып чыккан. Чөнки җирдә кояш күрмәгән бер генә эш тә юк.

— Әни, — дигән малай, башын түбән иеп, — мин суны Көймә тавы артындагы чишмәдән алмаган идем, гафу ит мине.

Малай мөлдерәмә яшьле күзләре белән әнисенә караган. Әнисе улын күкрәгенә кыскан. Шул вакыт кояштагы караңгылык кими башлаган. Дөнья әкренләп яктырган, кошлар, кереп поскан ояларыннан чыгып, агач ботакларына кунганнар, этләр елый-елый өрүләреннән туктаган. Бар нәрсә элекке хәленә кайткан, бары тик кояштагы тап кына бөтенләй бетеп җитмәгән.

Әйе, дөньяда бер генә яманлык та, бер генә ялган да эзсез калмый шул. Яманлыкны хәтта кояш та яндырып бетерә алмый икән.

## КАНАТЛЫ АТ

Мәскәүдәме, Казандамы, Баулыдамы, Чаллыдамы — ниндидер бер зур калада, борын заманнарда түгел, нәкъ бүгенге гади көндә уенчыклар кибетендә булган бу хәл. Кем ишеткәндер бу хәлне, кем күргәндер, кемнәр сөйләгәндер аны, белмим хәзер. Ә вакыйга болай булган: матур-матур уенчыклар белән беркөн кибет тулган. Вертолетлар, самолетлар, пистолетлар, аю-бүре, куян-төлке, чүпрәк этләр — бөтенесе киштәләрдә өелеп торган, кибеткә кергән балалар боларга гел үрелеп торган. Кемдер автомат сораган, кемдер — танк, кемдер курчак сатып алган бик шатланып. Уенчыклар кулдан-кулга күчә торган, малайлар һәм кызлар шулай уйный-уйный үсә торган. Кибеттәге уенчыклар алышынган, уенчыклар беткән чакта

кибет тынган. Балалар да шау-гөр килеп шауламаган, тегене ал да моны ал дип, һичбер бала әнкәсеннән уенчыклар дауламаган.

Әйе, шулай, уенчыклар бетә торган — пистолетлар, вертолетлар, самолетлар илнең төрле почмагына берәм-берәм китә торган. Тик уенчык атны һичкем алмаган, ди. Алу түгел, һичкем күз дә салмаган, ди. Тора-тора аны тәмам тузан сарган, ат, мескенкәй, айлар-еллар буе торып бик тә арыган. Яман ачуы килгән аның мондый эшкә. Әгәр, дигән, алмасалар, бүген кичкә башны алып качачакмын бу кибеттән. Җитте, дигән, бүтән мондый кибетләрдә мин интекмәм.

Көн тиз узган, кич тә җиткән. Атны алучы булмаган кибеттән. Шалтыр-шолтыр япканнар да ишекләрне кайтып киткән сатучылар, ияртеп эт-көчекләрне.

Кибет тынган, курчакларның керфегенә йокы кунган. Пистолетлар кереп яткан тартмаларга, вертолетлар кунаклаган иң өстәге такталарга. Тик ат кына йокламаган, уяу торган, моннан чыгып качар өчен бер уй корган. Менә бермәл бөтен шәһәр йокыга талган. Күктә Ай да, кибеттә ат торып калган.

— Вакыт җитте! — дигән, ди, ат, ныклы итеп. — Бик күп яттым бу кибеттә хуҗа көтеп. Алмадылар, барыбер мине алмадылар. Алмый китеп, өметемне алдадылар. Бүтән монда бер минут та яши алмыйм, мин бит монда чаба алмыйм, кешни алмыйм.

Сикергән ат ачык калган форточкадан, җиргә төшкәч, озак кына карап торган. Аннан киткән шәһәр буйлап кешни-кешни. Әй бара, ди, бу матур ат урам буйлап, әллә нинди матур-матур уйлар уйлап. Хыялында иркен-иркен болыннар, ди. Болыннарда атлар, тайлар, колыннар, ди. Ялкайларын җилфер-җилфер җил тарый, ди, тоякларын җил ныгыта, юл кайрый, ди. Әй чаба, ди, бу ярсу ат, бу җитез ат, иңнәренә үсеп чыккан ике канат.

Әрле-бирле әнә шулай чаба торгач, ал таң аткан, кояш чыккан. Һәм шәһәрдә әллә нинди мәхшәр купкан. Трамвайлар узалар, ди, шалтыр-шалтыр, утлар кабынып китә икән ялтыр-йолтыр. Машиналар агыла, ди, чаш-чош итеп, кешеләр дә чабыша, ди, нидер тотып.

Ә безнең ат, канатлы ат һаман барган. Трамвайлар авызын ачып карап калган. Машиналар аңа күзен кысып киткән, светофорлар юл күрсәтеп нурлар сипкән. Тик канатлы атны беркем туктатмаган. Минеке бул, әйдә безгә дип әйтмәгән. Канатлы ат хуҗа эзләп озак йөргән, тар урамга, ишегалларына кергән. Йөри торгач, мәктәп янына килеп чыккан, малайларга һәм кызларга ул сүз кушкан.

— Танийсызмы, мин Канатлы ат бит, дуслар. Мин элдереп чабып китсәм, куып җитә алмый мине хәтта кошлар. Тоякларым ут чыгара баскан җирдән, ялларымны таратамын искән җилдән. Йә килегез, атланыгыз, шатланыгыз! Кемнәр батыр, кемнәр кыю — күрик әле, дөнья гизеп, рәхәтләнеп йөрик әле.

Малайлар һәм кызлар аннан көлгән генә.

— Хәзер безгә нигә кирәк ат, — дигәннәр. — Хәзер инде машиналы чак, — дигәннәр. — Выж иттереп кабызасың да — элдерәсең. Кирәкмәсә, колагын борып сүндерәсең. Машина ул арымый да, чирләми дә. Синең кебек лычма булып тирләми дә. Ә бит синең ялларыңнан тамчы тама, кая инде машинага җитү сиңа.

Канатлы ат бик рәнҗегән балаларның сүзләренә, ачы яшьләр тулган аның күзләренә. Китеп барган кешни-кешни, дулый-дулый, эчтән генә әнә шулай елый-елый. Киткән ул бик ерак-ерак болыннарны эзли-эзли, үзе кебек атлар, тайлар, колыннарны күзли-күзли. Озак йөргәч, барып чыккан бер болынга. Болын җәелеп ята икән зур, матур елга буенда. Сусыл, тәмле үләннәре күмелерлек, үзәннәре көне буе йөгерерлек. Тик монда да бер ат та юк, бер колын да, тракторлар үлән чаба ди болында. Кешнәп карый Канатлы ат бар көченә, кешнәвеннән әллә ничә кибән ишелә. Атлар гына күренмиләр ләкин бер дә, әллә соң мин актык атмы, ди ул, җирдә.

Кешнәп-кешнәп ишетмәгәч аның тавышын, йөрәгенә яшереп үзенең сары сагышын, тагын китә Канатлы ат бүтән якка, китмәс иде, хыяллары ерак тарта. Ялгыз башың яшәп булмый бит дөньяда, иптәш кирәк бит сиңа да һәм миңа да.

Йөри икән Канатлы ат дөнья гизеп, дус табудан бетерми ди өметен өзеп. Әле килеп чыга, ди, ул далаларга, нидер әйтеп китә, ди, ул балаларга. Кемдер аны авылларда күргән диләр, кемдер аны давылларда күргән диләр. Мин ышанам әле аның эзләгәнен табасына, дустын табып, ишен табып хыялына бергә-бергә чабасына. Очрашырсыз аның белән сез дә, бәлки, җәйге берәр сабантуйда, ат сөюче дустым, син дә өметең җуйма. Ә бер күрсәң, һичшиксез, син аны бик яратырсың, исемеңне данга күмеп дөньяларга таратырсың.

## РӘССАМ КЫЗ

Борын-борын заманда, бәп-бәләкәй авылда, ун тәрәзле бер өйдә яшәгән, ди, үзенең нәни кызы белән бер карчык. Таң нурлары офыкларга таралуга, урманнарда, болыннарда сандугачлар уянуга, карчык өйдән

чыгып китә икән. Китмәс иде, карын икмәк таләп иткән. Баз шикелле кап-караңгы, җәй көне дә кояш күрмәгән сап-салкын өйдә кыз һәр көнне ялгызы калган. Чыгар иде, ул да башкалар шикелле сикерә-сикерә уйнар иде, йә булмаса урманнарда кош сайравын тыңлар иде, кияренә күлмәк юк — шунысы бәла. Шулай да кыз боекмый, үзенә уен уйлап таба. Тычканнар һәм күселәр белән качыш уйный, аларга ияреп ишекле-түрле чаба.

Чаба торгач, йә тычканнар арып егыла, йә кыз үзе. Аннан инде бөтен җан иясенең көлдә пешкән бәрәңгегә төшә күзе. Кыз эченнән болай уйлый: «Ярый әле иптәшкә тычканнар бар, алар да булмаса, ялгызың шашар идең», — һәм ул үзенең дусларын бәрәңге кабыгы белән сыйлый. Әмма тычканнар да комсыз, риза булмыйлар коры кабыкка, үрелергә тырышалар бәрәңгеле савытка. Кыз актык бәрәңгесен дә боларга бирә. Тик тегеләр туя белмиләр, ипи сорап өй әйләнеп йөриләр. Эш чыкмагач сорап-сорап, тычканнар калмый аптырап, тотыналар өйнең почмакларын кимерергә, әйтерсең алар сүз куешкан черек өйне җимерергә. Почмакларны тишкәннән соң, кимерер нәрсә беткәннән соң, ташлап китәләр алар бу фәкыйрь йортны.

Кыз бөтенләй ялгыз кала. Бер елап, бер җырлап ала. Һич үткәреп җибәрә алмый озын көннәрне. Бәрәңгесе калмаганмы дип, кат-кат актара учактагы көлләрне. Табып ала ул шунда бер күмер, уйланып тормастан бик күп гомер, төрле рәсем ясый башлый. Рәсемнәр белән тула бөтен идән. Кызга бу эш кызык күренә, ныклап төшенәсе килә аның рәсем ясауның серенә. Сөртеп ала да бөтенесен, ясый тагын. Шунда сизә ул үзендә гаҗәеп талант барын. «Эһ» дигәнче идән уртасында пәйда була бик бай табын. Иң уртада олы булып ипи тора, көлдә пешкән бәрәңгеләр ерактан күзне кызыктыра. Самавырда гөбер-гөбер чәйләр кайный. Кыз үзе ясаган рәсемнәрдән күзен алмый. Кара булса да ипие дә, бәрәңгесе дә шундый тәмле төсле, боларны ашап туяр иде күпме кеше!

Авызыңнан сулар килә башлагач, ачыгуга түзәр әмәле калмагач, чүпрәге белән селтәнеп, рәсемнәрен юк итә ул. Аннан инде табын түгел, урман ясый. Аюын да, бүресен дә, төлкесен дә — калдырмый ул берсен дә. Бөтен агач башларына кошлар кундыра, аланнарга чәчәкләр сибә, тау астыннан чишмә чыгара. Аннары бик матур итеп, төрле тарафка нур тараттырып, тәрәзәләргә туры караттырып кояш ясый. Ләкин кояш, күмер белән ясаганга, кара була, өйгә ямьсез салкын нурлар тула.

— Болай булмый, — дип уйлый кыз, — ясарга кирәк кояшны актан. Яктыртсын караңгы почмакларны, җылытсын ут күрмәгән учакларны.

Табып ала да бер кисәк акбур, кояшны ясый яңадан. Бу юлы кояшы була ак һәм матур. Бөтен почмакка җәелә ап-ак нур.

Бу эш белән ул бик мавыга, рәсемнәре дә көннән-көн матуррак чыга. Өйләренең стенасын, түшәмнәрен, мичләрен һәм идәннәрен тутыра искиткеч рәсемнәр белән. Менә берчак аның рәсемнәре җанланалар: ботакларда кошлар сайрап җибәрә, гөлләр һәм чәчәкләр йомшак җилләрдә тирбәлә, чишмәләре чылтыр-чылтыр ага башлый, бал кортлары чәчәкләрдән ширбәт ташый. Түшәмгә эленгән кояш нур сибә, алмагачтагы алмалар ботакларын җиргә ия. Әллә кайда мул уңышлы иген кыры дулкынлана, югарыда җырчы тургай канат кага. Ындырларда көшел-көшел ашлык тора, арыш-бодай белән тула һәрбер бура. Кая гына карасаң да муллык, байлык. Ипи авырлыгыннан киштәләр сыгылган, әйтерсең бөтен дөнья байлыгы монда җыелган.

Рәссам кызның даны бик тиз бөтен дөньяга тарала. Чит патшалыклардан да киләләр рәсемнәрен карарга. Күргән берсе хәйран кала. Хәйран калмаслыкмыни соң?! Кыз агачлар ясаса — алар шауларга тотына, диңгез рәсемен төшерсә — дулкыннар ярларга кагыла, күккә йолдызлар таратса — яктысыннан күзләр чагыла, тәрәзәсез өйләргә акбур белән тәрәзә сызса — өйләргә якты нур тарала.

Чакыралар рәссам кызны патша сарайларын бизәргә. «Әйдә, — диләр, — муллык эчендә йөзәргә. Анда, — диләр, — буяуларның төрлесе бар, ярдәм итеп торыр, — диләр, — бик күп коллар. Табыннарда өелеп торыр тәмле сыйлар, безнең белән барсаң, — диләр, — эшең уңар».

Тик рәссам кыз кызыкмый бу байлыкларга. Әйтә: «Кирәк түгел миңа сезнең һичнәрсәгез. Үзегезгә булсын алар бар да. Буяуларым минем болай да күптөрле. Пумаламны манамын салават күперенә, кирәк икән — янда гына учак күмере дә. Шатлыгымны язар өчен бар акбурым, хәсрәтемне күрсәтергә — мичтә корым, рәсемнәргә җан кертергә — оста кулым. Теләсәм, мин подвалларны патша торган сарайлардан матур итәм. Бүгеннән мин авылдагы һәрбер йортка кояш кертәм. Тәрәзәсез өйләргә зур тәрәзә уям, корымга каткан түшәмнәргә ай-кояшлар элеп куям. Матурлыкны күрсеннәр дә, хәсрәтләрен онытсыннар, бәхеткә юлыксыннар. Авырып ятучылар рәсемнәремә сокланып түшәкләреннән торсыннар, суыктан калтыраучылар җылынсыннар. Сукырларның күзе ачылсын, телсезләргә тел килсен, көлүне онытучылар рәхәтләнеп көлсен».

Шулай дигән дә рәссам кыз киткән авыллар буйлап. Буяуларын алган үзе белән, ә буявы җитмәгән чакта аңа табигать ярдәмгә килгән. Алсу төсне бүләк иткәннәр таңнар, яшел төсне — болыннар һәм таллар,

сары буяуны — кешеләрнең сагышлы йөзе. Пумала ясарга кошлар каурыйларын биргән. Кыз аяк баскан һәрбер өй ямьләнеп киткән. Стеналар киңәйгән, түшәмнәр биегәйгән.

Кыз ясаган рәсемнәргә кешеләр таң калганнар:

— Дөнья нинди гүзәл икән! — дип сокланганнар.

— Моңа кадәр караңгыга батып утырган өйләрдә кояш нурын күрми интеккәнбез, матурлыкны аңламыйча көн иткәнбез, — дигәннәр алар.

— Инде хәзер күрдек-белдек барчасын да — җимешләрдән сыгылып торган бакчасын да, зәңгәр нурлар таратучы таңнарын да, биек-биек тауларын да. Беркемгә дә бирмибез байлыгыбызны, рәхмәт рәссам кызга, уятты ул аңыбызны.

Ләкин кешеләрнең куанычы озакка бармаган. Залим патша үзенең башкисәрләре белән боларның байлыкларын талый башлаган. Кояшларын сүндергән, үзләрен бөлдергән, игеннәрен яндырган, бөтен халыкны ач-ялангач калдырган. Әмма бәхет тәмен татып карарга өлгергән кешеләр явыз патшага буйсынырга теләмәгәннәр. Киңәшкәннәр, сөйләшкәннәр дә, бергә-бергә берләшкәннәр дә явызлыкка каршы көрәшкә чыкканнар. Кылычлар айкалган, мылтыклар шартлаган, дөньяны бер мәлгә кара төтен каплаган. Башкисәрләр җиңелгән, җәбер-золым артка чигенгән. Яңадан зәңгәр күктә кояш балкыган. Бакчалар чәчәккә күмелгән, басуларда мул иген өлгергән. Билләр турайган, күкләр биегәйгән, дөнья киңәйгән. Рәссам кызның бөтен хыяллары чынга ашкан.

## БИЮЧЕ БАКА

Кайдадыр еракта бер илдә кечкенә генә күлдә яшәгән, ди, бик оста биюче бака. Ул һәр көнне иртән тору белән төнбоек яфрагы өстенә чыгып баса да биергә тотына икән. Баштарак ул ике аякта биегән. Тора-бара сыңар аякка күчкән. Ләкин аңа сыңар аякта бию дә әз тоелган. Ул бөтен көчен, барлык сәләтен куеп сыңар аягының баш бармагында биергә өйрәнгән. Бер бармакта шундый матур итеп биюче бу бакага күлдәге барлык бакалар бик сокланганнар. Аңа Башбармак дип исем кушканнар. Башбармак дигән исем күлдәге иң хөрмәтле, иң атаклы бакаларга гына бирелә торган булган.

Башбармак биергә чыгып басуга, күлнең барлык җан ияләре җыелышып аны карарга киләләр һәм такмаклар әйтеп торалар икән:

Тыпыр-тыпыр биисең,
Ару-талу белмисең;
Сиңа карап аккошлар да
Көнләшерләр димисең.
Бас, бас катырак,
Күлләр торсын калтырап.
Очкан кошлар зәңгәр күктән
Карап торсын аптырап.

Башбармакның такмак әйтүчеләргә бик-бик күңеле була. Ул, үзенең җиңел гәүдәсе белән яфрактан яфракка сикереп, төнбоек чәчәкләре җыеп ала да такмак әйтүчеләрнең түшләренә кадап чыга икән. Башбармактан чәчәк алучы бака егетләре үзләрен дөньядагы иң бәхетле җан ияләренә санап, төннәр буе матур хыялларга чумып ята торган булганнар.

Кызларының көннән-көн зуррак уңышлар яулавына ата-аналары да бик сөенгән. Көннәрдән бер көнне Башбармакның әнисе кызына болай дигән:

— Кызым, син безнең күлдә бер генә. Синең кебек матур биюче юк. Үзеңнең башкалардан өстен икәнлегеңне белеп яшә. Теләсә нинди бака егетләренең түшенә чәчәк кадама. Югыйсә үз бәяңне төшерерсең.

Башбармак әнкәсенең сүзләреннән көлгән генә:

— Үзеңнең дусларыңа чәчәк биргәнгә бәя төшә димени? Алар бит минем бергә уйнап, бер суда коенып үскән күлдәшләрем, иптәшләрем.

— Шулаен шулай, — дигән әнкәсе, — ләкин сәләт теләсә кемгә бирелми. Мин ышанам: син әле бу күлдә генә калмаячаксың. Мондый гүзәллекне, мондый осталыкны бер кечкенә күлдә яшереп яту гөнаһ булыр иде.

Һәм чынлап та Башбармакның искитмәле оста бию турындагы хәбәр күлдән күлгә, илдән илгә таралган. Аны төрле ярышларга чакыра башлаганнар. Кая гына бармасын, нинди генә ярышта катнашмасын, ул гел беренчелекне алган. Аңа зур-зур энҗе-мәрҗәннәр, кочак-кочак гүзәл чәчәкләр бүләк иткәннәр. Ә инде йөзек эченнән узарлык нәфис ефәкләрдән тегелгән күлмәкләрнең, өрсәң болытларга

очарлык яулык-шәлләрнең, укалар белән бизәлгән һәм алтын-көмешләр белән йөгертелгән туфлиләрнең исәбе-хисабы юк икән.

Бака егетләре Башбармакны мактап җырлар чыгарганнар. Аның йөргән юлларына чәчәкләр түшәгәннәр. Ләкин Башбармак аларга элеккечә елмаймаган, түшләренә чәчәкләр дә кадамаган. Үзенең дөньяда бердәнбер икәнлегенә ул һаман саен ныграк ышана барган. Һәм озакламый алтын сарай салдырган. Алтын сарай эчендә музыкантлар бию көйләренең төрледән-төрлесен уйнап торган. Башбармак үзенең алтын сарае эчендә диңгез аръягыннан килгән иң дәрәҗәле кунаклар алдында гына биегән. Әгәр күлнең гап-гади бакалары алтын сарайга якынлашсалар, капка төбендә торучы сакчылар аларны куып җибәргәннәр.

Үз күлләрендә туып үскән гүзәл биюче Башбармакның алтын сараен күпләрнең күрәсе килгән. Сарайның эченә берничек тә керә алмагач, бакалар җыелышып Гөберле янына килгәннәр.

— Гөберле, — дигәннәр алар, — син бит безнең Башбармакның кендек әбисе. Сине ул сараена кертми калмас. Алтын сарай нинди була икән, анда җыелган диңгез аръягы кунаклары ни кыяфәтле, безнең Башбармагыбыз бии торган урын төнбоек яфрагыннан кай җире белән артык — син шуларның бөтенесен карап чык. Аннары безгә сөйләрсең. Тагын шуңа игътибар ит: алтын сарайдагылар нәрсә ашый, нәрсә эчәләр. Үзеңне сыйлаган тәм-томны берәр җиреңә яшереп алып чык. Без дә авыз итеп карарбыз.

— Чирләп тора идем бит әле, туганнар. Нишләргә икән соң инде? — дигән Гөберле.

— Сарай капкасына кадәр сине үзебез камыш көймәгә утыртып алып барырбыз. Син капка гына кагарсың, — дигәннәр аңа.

— Алай дисезме?

— Шулай дибез.

— Ярый алайса. Мин хәзер җыенам.

Гөберле өс-башларын алыштырган арада, бака егетләре камыш көймәне китереп тә җиткергәннәр.

— Син Башбармак белән капка төбендә озаграк сөйләшеп тор, — дигән бака малайлары, — без яшеренеп кенә аны карарбыз. Юкса күптән инде күргәнебез юк үзен. Нindirәк икән безнең Башбармагыбыз?

— Ярар, — дигән Гөберле. — Тик ул мине күрү белән кочагыма ташланыр. Әмма сез борчылмагыз, мин, берәр җаен табып, аның йөзен сезнең яккарак борырга тырышырмын.

Камыш көймә алтын сарайның капка төбенә килеп туктаган. Гөберле, батыраеп, капканы каккан. Ул арада капка ачылып киткән һәм эчке яктан ике сакчы килеп чыккан.

— Әй син, хәерче, — дигәннәр сакчылар. — Нигә капка кагасың? Ниең калды монда?

— Мин хәерче түгел, — дигән Гөберле, — мин Башбармакның кендек әбисе.

Сакчылар шаркылдап көләргә тотынганнар:

— Ха-ха-ха! Шундый гүзәл Башбармакның синең кебек килбәтсез кендек әбисе була димени? Бар, бар, буталып йөрмә. Юлыңда бул.

— Хәзер үк чакырып чыгарыгыз үзен, — дигән Гөберле. — Югыйсә начар булыр.

— Аның көндезге йокы вакыты.

— Уятыгыз. Кендек әбиең килгән дисәгез, йөгереп чыгар.

— Вакытсыз уятсаң, безгә бик каты эләгәчәк, әбекәй, — дигән сакчылар, бераз йомшара төшеп.

— Киресенчә, уятмасагыз эләгәчәк сезгә.

Сакчылар уйга калган. Пышын-пышын үзара киңәшеп алганнар. Шуннан соң берсе Башбармакны уятырга кереп киткән. Ә бераздан Башбармакны ияртеп килеп чыккан.

— Нихәл, кызым? — дип, Гөберле колач җәеп Башбармакка якынлашкан. Ләкин Башбармак аны күрүгә чигенә башлаган.

— Кем син? Нишләп йөрисең монда? — дигән ул, авызын олы итеп ачып иснәп. — Йокымны бүлеп йөрисең.

— И-и, танымыйсыңмыни, кызым? — дигән Гөберле. — Мин бит синең кендек әбиең — Гөберле.

— Минем берниндидә кендек әбием юк, — дигән Башбармак. Һәм сакчылар ишетмәсен өчен пышылдап болай дип өстәгән: — Кара инде үзеңнең кыяфәтеңә. Ничек оялмыйча мин сине алтын сараема кертим? Анда бит минем барлык идәннәргә затлы келәмнәр түшәлгән. Бормалы баскычлар мәрмәрдән эшләнгән. Һәр бүлмәдә зәңгәр сулы бассейннар. Ул бассейннарга суны мин ерак диңгезләрдән китерттем. Шушы кәкре тәпиләрең белән оялмыйча минем алтын сараемда йөрер идеңме? Башыңдагы яулыгыңны күрүгә, кунакларымның авызларыннан аш төшәчәк.

— Мин синең шул гүзәл сараеңны күрергә дип килгән идем, — дигән Гөберле. — Күлдәге бөтен баканың авызында шул сүз: Башбармакның сарае нинди икән?

— Юк, кертә алмыйм, — дигән Башбармак. — Диңгез арты кунаклары сине күрсә, оятымнан йөрәгем ярылыр. Мә, менә моны ал да тизрәк тай моннан.

Башбармак Гөберлегә бер кисәк алтын сузган. Гөберле аның алтынын аяк астына салып таптаган да хурлыгыннан күз яшьләрен агызып кайтып киткән. Көймәдәге бака егетләренә ул: «Бу хәлләрне беркемгә дә сөйләмәгез», — дигән. Егетләр сөйләмәскә сүз биргәннәр.

Гөберле кайткач, күл бакалары аның янына җыелган. «Йә, ничек яши анда безнең Башбармагыбыз? — дигән алар. — Сарае нинди? Табындагы ризыклары ничә төрле?»

— Андагы хәлләрне сөйләп бетерерлек кенә түгел, кардәшләр, — дигән Гөберле. — Алтын сараена килеп керү белән күзем камашты — берни күрмәс булдым. Диңгез аръягыннан китерелгән ризыклары эчемә ярамады. Шуңа күрә артыгын сораштырмагыз инде, эчем авыртып тора. Үз өемә кереп ятыйм мин.

— Үзе ничек? Башбармагыбыз тагын да матурланганмы, шул турыда гына берничә сүз әйт инде, — дигәннәр тегеләр.

— Үземе? Үзе сөйләп бетерерлек кенә түгел. Өстендә кытай ефәге. Бөтен тәне үтә күренмәле. Бармакларында энҗеле балдаклар. Мине күрү белән кочагыма ташланды. Артык кысып кочаклаудан кабыргаларым сына дип торам...

Әйе, Гөберле үзенең күлдәш дусларына ялганнарга мәҗбүр булган. Чөнки аның Башбармакны начар итеп күрсәтәсе килмәгән. Гади күлнең гади бакалары үзләре арасыннан шундый атаклы биюче чыгуга бик шатланганнар.

— Безнең Башбармагыбыз һаман шулай гади һәм нечкә күңелле икән әле, шөкер, — дип үзара сөйләшкәннәр.

Ә Башбармакның һаман саен даны арта барган. Каф тавы артындагы патша егетләренә кадәр барып җиткән аның дан-шөһрәте. Башбармакка төрле яктан зур-зур корабларга төяп бүләкләр җибәргәннәр. Башбармак алтын сараен тагын да зурайткан, биегәйткән. Үзе турында иң матур җыр чыгаручыга бүләкләр биргән. Хәзер инде барлык шагыйрьләр аны мактап җырлаганнар. Музыкантлар иң шәп әсәрләрен аңа багышлаган. Бары тик Дәүавыз исемле бака егете генә Башбармак турында җыр җырламаган. Ә ул әлеге күлнең иң матур җырчысы булган. Үзен данларга теләмәүче Дәүавызга Башбармакның бик ачуы килгән. Ул үзенең сакчыларына Дәүавызны тиз арада чакырып китерергә кушкан. Сакчылар Дәүавызны өстерәп алып килгәннәр.

— Әй син, — дигән Башбармак, — күлнең барлык бакалары мине данлап җырлауны олы хөрмәткә санаганда, шушындый зур авызың була торып нигә мине мактамыйсың? Әллә син минем дөньяда иң шәп биюче икәнемне белмисеңме?

— Беләм, — дигән Дәүавыз. — Әйе, син шәп биисең, анысына сүз әйтеп булмый. Бака яфрагы өстендә биегән чакларыңда синнән күзем алмыйча көннәр буе үзеңә карап тора идем.

— Шулай булгач бигрәк тә, — дигән Башбармак, — син минем яшьтән үк шәп биюем, иң кешелекле, иң акыллы, иң матур булуым турында барлык күлгә ишеттерерлек итеп җырларга тиешсең.

— Мин бары тик дөресен генә җырлый алам, — дигән Дәүавыз. — Ялган җырласам, шул көнне үк гарьлегемнән егылып үләчәкмен.

— Нинди ялган? — дигән Башбармак. — Әллә мин начар биимме? Үземне мактаучыларга хакны әз түлимме? Ата-анамны рәнҗетәмме? Беләсең килсә, атам-анам минем алтын сараемның иң биек катында яшиләр. Энҗе-мәрҗәннәр белән бизәлгән күлмәкләр кияләр. Мин аларны болганчык күлдә чебен-черки тоттырып йөрмим.

— Анысы шулайдыр. Әмма үзенең кендек әбисен сараена кертмәүчене кешелекле дип буламы? Гөберле бит сиңа бишек җырларын җырлап, чирләгән чакларыңда җанының яртысын ярып биргән кеше. Яисә Сорыкүзне исеңә төшер. Ул бит сине иң беренче булып йөзәргә өйрәтте. Ничә тапкыр сине батып үлүдән коткарды. Бервакыт, үзеңне Чуртан авызыннан тартып алганда, Чуртан тешләренә эләгеп аягын имгәтте. Ә син шуны: «Минем алтын сараем гарип-гораба җыелу урыны түгел», — дип, өеңә кертми җибәргәнсең. Сорыкүз карышып маташкач, сакчыларыңнан кыйнаткансың. Шундый икәнлегеңне белә торып, сине мактап җырлыйммы?

— Ә-ә, шулаймыни? — дигән Башбармак. — Син мине мактап җырларга теләмисеңмени? Сакчылар, ябыгыз үзен төрмәгә. Кайчан мине мактап җырлый башлый, шунда чыгарырсыз.

Сакчылар Дәүавызны төрмәгә ябып куйганнар. Башбармакның бөек җырчыны җиңә алмавына бик нык кәефе киткән. Дәүавыз аны мактап җырласа, дан-шөһрәт агачының иң югары ботагына менеп җитәр кебек тоелган. Ул шулай байтак вакыт сагышланып йөргән. Ләкин үзен уратып алган ялагай җырчылар, бер карашы өчен әллә ни бирергә торган шагыйрьләр, аның авызыннан чыккан һәр авазны нотага салырга әзер торучы музыкантлар Башбармакның сагышын тиз онытгырганнар. Ул яңа дәрт белән биергә тотынган. Үзенең нинди шәп биегәнлеген күрсен өчен Дәүавызны да богаулатып янына китертә торган булган.

Башбармакның бию мәйданы алтын белән йөгертелгән, ялтырап торган түгәрәк дәү өстәл икән. Шул өстәлдә биегәндә, әллә башы әйләнеп, әллә аягы таеп ул егылып төшкән. Алтын сарайның идәне каты мәрмәрдән түшәлгәнлектән, Башбармак бик каты егылган. Аның сыңар аягы белән ике кабыргасы сынган.

Бу хәбәр тиз арада бөтен дөньяга таралган. Диңгез аръякларыннан, Каф тавы артларыннан, Дию патшалыкларыннан иң оста табиблар чакырылган. Төрледән-төрле дарулар кулланганнар. Әкрен-әкрен кабыргалар төзәлсә дә, сынган аяк элекке хәленә кайтмаган. Чөнки, мәрмәр идәнгә бәрелеп, сөяге артык чәрдәкләнгән булган. Хәзер инде бу аяк белән бию турында хыяллану буш нәрсә икәнен Башбармак яхшы аңлаган. Бии алмый башлагач, дәрәҗәле кунаклар да төрлесе төрле хәйлә табып, Башбармакның өеннән китү ягын караган. Башбармак үзенең бу хәлгә төшүенә хурланып көне-төне елаган. Аның хәтта күз яшьләрен сөртер кешесе дә калмаган. Алтын сарайның алтын капкаларын саклаучы сакчылар эләктерә алган кадәр алтынны урлап качканнар. Аш-су пешерүчеләр — тәмле ризыкларны, бүлмәләрне җыештыручылар зиннәтле келәмнәрне чәлдереп тайган. Алтын сарай тәмам ташландык абзарга әйләнгән. Башбармак япа-ялгызы калган. Кычкырса, тавышы, буш диварларга бәрелеп, үзенә кайткан. Аны мактап җыр чыгаручы шагыйрьләр хәзер инде Башбармактан көлеп такмак чыгарганнар. Рәссамнар кәкре аяклы итеп аның карикатурасын ясаганнар. Башбармак бу хәлгә бик гарьләнгән һәм алтын сараеның иң югары балконына менгән дә дөнья белән саубуллашмакчы булып түбәнгә сикергән. Әмма әҗәле җитмәгән булганмы — күлнең тирән урынына төшкән, үлмәгән. Күлгә төшүгә, аның янына иң беренче булып Гөберле килеп җиткән.

— Балакаем, — дигән ул, Башбармакны башыннан сыйпап, — нәрсә булды? Ялгыш егылып төштеңме әллә?

Башбармак Гөберленең күкрәгенә башын куеп елап җибәргән. Аннан һәммәсен сөйләп биргән.

— Кичер мине, әбекәем, — дигән ул, үксеп.

— Ярар, үткәннәрне искә төшермик, — дигән Гөберле. — Ул чагында син түгел, синең тәкәбберлегең күңелеңә хуҗа иде. Ә аягың өчен борчылма. Ничек тә төзәтербез. Элекке кебек үк бии алмассың, бәлки, әмма чарасын табарбыз.

Һәм Гөберле Башбармакның аягын дәвалый башлаган. Сорыкүз ерак урман-болыннардан шифалы үләннәр җыеп кайткан. Гөберле алардан төрле-төрле дарулар ясаган. Алтын сарайның ишекләре ачылгач, күлнең атаклы җырчысы да иреккә чыккан. Ул да, барлык үпкәләрен онытып, биючене дәвалауда катнашкан.

Күлнең барлык бакалары тырыша торгач, Башбармак тәмам савыгып аякка баскан. Сынган аягы элекке хәленә кайткан. Ул элеккедән дә матуррак бии башлаган. Ләкин инде хәзер диңгез аръягыннан килгән кунаклар өчен түгел, үз күленең бакалары өчен биегән. Бию мәйданы да төнбоек яфрагы икән. Үз күлдәшләрең, үз кардәшләрең өчен хезмәт итүдән дә мактаулырак эш югына чын күңелдән шулай ышанган Башбармак.

## АКАЙКҮЗ

Бервакыт урман патшасы Акайкүз исемле аюның тик ятудан эче поша башлаган. Ул янына барлык вәзирләрен чакырып китергән дә болай дигән:

— Кем дә кем минем кәефне ачарлык, эч пошуымны басарлык нәрсә уйлап таба, шуңарга үзем бал ашый торган тәпәннең төбен яларга рөхсәт итәчәкмен. Йә, Карт бүре, беренче булып син әйтеп кара.

— Урмандагы бөтен җан ияләрен бергә җыеп, син ашый барсаң, мин сөякләрен кимерсәм, иллә дә кызык булыр иде, падишаһым.

— Баш белән түгел, авызың белән уйлыйсың. Болай да көчкә тын алып утырам, кай җиремә ашыйм тагын? — дигән Акайкүз патша, кәкре тәпиләре белән корсагын угалап. Бүредән рәтле җавап ишетмәгәч, ул үзенең икенче вәзире — Кәкре койрык төлкегә мөрәҗәгать иткән.

— Барлык кыр тавыкларын җыеп, хор оештырыйк, падишаһым-солтаным, — дигән Төлке. — Әтәчләрен бию курсларында укытып кайтырбыз. Менә дигән булыр!

— Ярыйсы булырдай күренә, — дигән Акайкүз, — әмма яшерен-батырын түгел, мин сәнгатьне аңлап бетермим.

— Т-т-туй ясарга кирәк, — дигән шул вакыт өченче вәзир Кылый куян, куркудан дер-дер калтырап.

— Нинди туй? Кемне өйләндерәбез?

— Юк-юк, өйләндермибез. Сабантуй ясарбыз. Бервакыт безнең әнә теге түгәрәк аланда кеше атлы җан ияләре сабантуй ясадылар. Аннан да кызык, аннан да шәп бәйрәмне күргәнем юк иде әле.

Акайкүз күңеленә бик хуш килгән бу. Һич кичекмичә сабантуйны әзерли башларга боерык биргән.

Иң беренче бик һәйбәтләп алан сайлап алганнар. Ап-ак каеннар белән уратылып алынган ямь-яшел алан булган ул. Бер якта тешләрне сындырырлык салкын сулы чишмә ага икән.

Төлкеләр, талдан үрелгән кәрзиннәр күтәреп, кошлардан йомырка җыярга чыгып киткәннәр. Куяннар, озын усакларны тешләре белән кимереп, колга шомартканнар. Тиеннәр, килгән кунакларны сыйларга дип, чикләвек җыйган. Аюлар йөгерешчеләр өчен юл әзерләгән. Бүреләр барча җанварларның сәламәтлеген тикшерүче санитарга әверелгән.

Менә берзаман әзерлек эшләре беткән. Сайланган аланга чыгып, сабантуйны башлап җибәрергә генә калган. Акайкүз патша алан уртасындагы кәкре каен башына менеп утырган. Моннан бөтен тирә-як уч төбендәге шикелле күренә икән. Акайкүз җыелган җанварларга карап алган да әмер биргән:

— Башларга!

Шомартылган колга башындагы кыр әтәче кычкырып җибәргән. Кошлар дәррәү кул чабарга тотынганнар.

Йөгергәндә комачауламасын өчен, куяннар, ыштан балакларын сызганып, койрыкларын тагын да күтәреп бәйләгәннәр.

Сабантуйның баш судьясы итеп Кылыйкай сайланган. Судьяга сыбызгысыз ярамас дип, аның кулына тал сыбызгы тоттырганнар. Әмма уеннар башланганчы ук, дулкынланудан, ул сыбызгысының яртысын кимереп бетергән. Хәер, Кылыйкайга сыбызгының әллә ни кирәге дә калмаган. Чөнки ул, үзенең судья икәнлеген онытып, йөгерешчеләр төркеменә кушылып киткән. Акайкүз, аның беренче килүен күреп:

— Их-ма! — дип акырып җибәргән һәм Кылыйкайның кулына саескан йомыркасын тоттырган. Кылыйкай аны үзенең маңгаена бәреп ваткан да эчеп җибәргән. Тик йомыркасы гына чәберчек булып чыккан.

Йөгерешчеләр килеп беткәч, капчык сугышы уеннары башланган. Моны аю малайлары башлап җибәргән, тиеннәр дәвам иткән, керпеләр тәмамлаган. Аюларга бүләккә бер кушуч чикләвек, тиеннәргә — какланган сукыр тычкан, керпеләргә бал тәпәне эләккән. Шулай да үпкә белдерүче булмаган.

Сабантуй гөрләгән. Бәйрәм дәвам иткән. Әтәч кунаклаган колга тирәсендә урманның бөтен төлкесе җыелган. Гайрәтлеләре, йөрәклеләре колгага менеп-менеп тә караганнар, әмма, яртысына да җитә алмыйча, кире шуышып төшкәннәр. Аларның выжлап шуып төшүләреннән Акайкүз рәхәтләнеп көлгән. Ә шулай да иң кызыгы көрәш мәйданында барган. Урманның барлык батырлары монда көч сынашканнар. Билбаулар өзелгән, билләр бөгелмәгән. Егылганнар да торганнар, тагын көрәшергә тотынганнар.

Менә бервакыт иң соңгы батыр булып Тимербил исемле аю гына калган.

— Йә, Тимербилгә каршы чыгучы бармы? — дип сораган Кылыйкай.

Мәйдан тынып калган.

— Бүтән көрәшүче булмаса, Тимербилне урман батыры итеп игълан итәбез, — дигән Кылыйкай.

Шул вакыт Акайкүз урманны яңгыратып акырып җибәргән:

— Син, Кылыйкай, әллә акылыңнан яздыңмы? Бу урманда миннән дә батыр кем булсын тагын?

— Батыр икәнсең, көрәшеп күрсәт, — дигән Кылыйкай. Салкын чишмә суын чамасыз эчеп җибәргәнлектән, аның бераз башына киткән икән. Шунлыктан патшадан да курыкмаган. Ә куян тикле куян патшага каршы әйткәч, бүтәннәр бөтенләй батырайганнар.

— Көчеңне мәйданда күрсәт, — дигәннәр алар.

— Күрсәтермен! — дигән Акайкүз һәм кәкре каен башыннан сикереп төшкән. — Биленә тотынсам, билең бөгелер, кулыңа тотынсам, кулың өзелер, кай җиреңнән эләктереп һавага чөйим икән!

— Каян тотсаң да ирек, тик аяк чалма, хәрәмләшмә, — дигән Тимербил.

— Көчсезләр генә хәрәмләшә. Ә мин үземдә җир җимерерлек көч сизәм. Әйдә, алыштык!

— Алыштык!

Тимербил белән Акайкүз билбауларның иң ныкларын сайлап алганнар да көрәшә башлаганнар. Беренче алышудан ук икесе дә сыйрактан батканнар. Әле берсе күтәреп алган, әле — икенчесе. Билбау белән кысып тотудан икесенең дә сырт йоннары коелып беткән. Колаклары уттай кызган. Тәннәреннән яңгыр булып тир тамчылары коелган. Каргалар, көрәшүчеләргә артык эссе булмасын дип, канатларын җилпеп, көрәш мәйданын җилләтеп торганнар. Сабантуйдагы барлык җан иясе бу кызыклы көрәшне карарга мәйдан тирәсенә җыелган. Кылыйкай арыган көрәшчеләргә йомырка эчереп торган, аларны маңгаена бәреп вата-вата аның инде башы күбеп беткән.

Көрәш тәмам кызган. Акайкүз, соңгы көчен җыеп, Тимербилне җирдән күтәреп алган да башаркан алып аткан. Әмма Тимербилне сыртына сала алмаган.

Тимербил:

— Бездә менә болай итәләр аны! — дип, Акайкүзне эләктереп алган да, бөтереп, сырты белән җиргә салган. Җир тетрәп куйган.

Акайкүзнең башы әйләнгән. Урмандагы һәрнәрсәнең асты өскә килгән. Акайкүз аңына килгәнче, Кылыйкай Тимербилне, иң биек төп башына бастырып, батыр дип игълан иткән.

Сабантуй таралган. Акайкүзне моннан соң беркем дә патша итеп санарга теләмәгән. Акайкүз үзе дә Тимербил нишләсә шуны эшләп, батыр артыннан күзәтә икән. Сабантуй аңа бик зур сабак биргән. Хәзер инде ул тик ятып кына көч җыеп булмаслыгын аңлаган һәм җилкәләрендә бүрәнә ташый башлаган. Яңа сабантуйларда Тимербил белән көрәшеп, югалган данын кайтармакчы ди. Менә быел тагын шул аланда сабантуй булмакчы икән. Әле генә бер чыпчык, тәрәзәмнән кереп, чакыру кәгазе ташлап китте. Кайсы җиңәр икән: Акайкүзме, әллә Тимербилме?

Бармый булмас инде.

## КЫЯДАГЫ ОЯДА

Биек-биек тау башында, текә кыя читендә бер бөркет оясы бар икән. Язгы таңда ул ояда берсеннән-берсе матур өч бала дөньяга килгән. Әнкә бөркет көннәр буе балаларына җим ташыган, җил-давыллар купса, канаты белән ояны каплап, бәгырь кисәкләрен хәвеф-хәтәрләрдән саклаган.

Бөркетнең балалары көнләп түгел, сәгатьләп үскән. Үскән саен ашарларына күбрәк кирәк булган. Әнкә бөркет көннәр буе балаларына ризык ташып тәмам арыган, алҗыган. Ә беркөнне балалары янына бүреләр тарафыннан ботарланган кабан дуңгызының зур кабыргасын күтәреп кайтканда, кинәт давыл купкан. Көчле давыл мең яшьлек имәннәрне тамырлары-ниләре белән һавага чөйгән, карурман эчендәге күлләрдә тыныч кына яшәп яткан аждаһаларны суырып алып күкнең җиденче катына илтеп ыргыткан. Бөтен дөньяда мәхшәр купкан. Оясына җим күтәреп кайтучы әнкә бөркет бу мәхшәрдә берни күрмәс булган. Давыл аны әле тегеләй, әле болай чөеп йөртә торгач, тауның бер очлы кыясына китереп бәргән. Бөркет шунда ук һәлак булган.

Бөркетнең балалары әнкәләрен көн көткәннәр, төн көткәннәр. Көтә-көтә арып беткәннәр. Аптырагач-йөдәгәч, ни уйларга белмәгәч, болай дип кычкырырга тотынганнар: «Әнкәй, әнкәй, син кайларда йөрисең? Синнән башка миңа бик кыен. Агач ботакларында җилләр сызгырса да, ишелеп-ишелеп болытлар акса да оя төбенә посабыз. Кара төннәр безне йотар, авыр болытлар өстебезгә ишелеп төшеп сытар, явыз кошлар урлап качар дип куркабыз. Ә иң авыры — без ачыктык. Үлеп-үлеп ашыйсыбыз килә. Әнкәй, әнкәй, ишетәсеңме безне? Ишетсәң, тизрәк кайт. Без сине көтәбез, кө-тә-ә-без!»

Әмма боларның моң-зарларын әнкәләре ишетмәгән. Сары томшыклардан саркылып чыккан бу тавышлар кыя-тауларга бәрелеп аларның үзләренә әйләнеп кайткан.

Ә вакыт елгасы аккан да аккан. Кыядагы оя өстендә очлы күзле тилгәннәр бөтерелгән, чукмар башлы яңгыр тамчылары өскә төшеп тәпәләп киткән, җилләр оя төбендәге соңгы уч җылыны да тартып алырга теләп тишек-тошыклардан эчкә үтәргә тырышкан. Бөркет балалары тәмам хәлсезләнгән. Алар шыңшый, елаша башлаганнар.

Ә боларның оясы янындагы зур таш астында чыбыркы буе Кара елан яшәп ята икән. Ул бөркет балаларының елашканын ишетеп, муенын ояга сузган:

— Йокларга ирек бирмисез, нигә акырышасыз? — дигән.

— Әнкәбезне сагындык, — дигән бөркет балалары. — Менә ничәнче көн инде әнкәбез кайтмый, ашыйсыбыз килә. Куркабыз.

— Әллә ничә көн кайтмагач, димәк, сезнең әнкәгез давылда һәлак булган инде, — дигән Кара елан.

— Юк, юк, безнең әнкәбез һәлак булырга тиеш түгел. Аның бит әле безне үстерәсе бар. Безнең әнкәбез көчле, гайрәтле, — дигән бөркет балалары.

— Әйе, — дигән Кара елан, — сезнең әнкәгез бик гайрәтле һәм куркусыз. Менә миңа карагыз әле. Нигә минем күзем берәү генә дип уйлыйсыз?

— Белмибез.

— Сез белмисез, ә мин беләм, — дигән Кара елан. — Бер күземне минем сезнең әнкәгез чукып алды.

— Юк, юк, — дигәннәр бөркет балалары, — безнең әнкәбез дөньяда мәрхәмәтлеләрнең дә мәрхәмәтлесе. Ул беркемнең дә күзен чукымас.

— Карт башым белән мине алдашып утыра дип уйлыйсызмы? — дигән Кара елан. — Сезнең әнкәгез үз оясы янына бернинди җан иясен якын җибәрми иде шул. Ә мин беркөнне, карыным бик ачкач, сезнең берәрегезне кабып йотыйм микән әллә дип, оягыз янына килгән идем. Шунда әллә каян гына әнкәгез очып килде дә миңа ташланды. Ярый әле таш астына качып өлгердем, юкса икенче күземне дә чукып ала иде. Хәер, бу күзем минем электән үк начар күрә. Дөньяга карый торган якты тәрәзәм булган уң күземне

әнкәгез чукып алгач, минем өчен дөнья бөтенләй караңгыланып калды. Менә сезне дә көчкә-көчкә генә шәйли алам.

Бөркет балалары Кара еланны кызганганнар.

— Ләкин бит син үзең гаепле, әгәр безне ашарга килмәгән булсаң, әнкәбез синең күзеңне чукымас иде, — дигәннәр алар.

— Бу дөньяда кем көчсез — шул гаепле, — дигән Кара елан. — Менә сезнең әнкәгез һәр көн сезгә тычкан-күсе күтәреп кайта. Уйлап карагыз әле: тычкан-күселәрнең ни гаебе бар? Алар бит көчсезлекләре аркасында гына сезнең әнкәгезнең тырнагына эләгәләр.

— Без әле андый катлаулы сорауларга җавап бирә алмыйбыз. Безнең бик ашыйсы килә, тизрәк үсәсебез килә, — дигән бөркет балалары.

— Ярар, — дигән Кара елан, — мин сезне үскәнче ашатып торырмын. Ләкин минем бер шартым бар...

— Без теләсә нинди шартыңны үтәргә риза, тик безне тизрәк ашат кына, — дигән бөркет балалары.

— Ашыкмагыз ул кадәр, — дигән Кара елан. — Уйламыйча вәгъдә бирмәгез.

— Безнең уйлап торырга вакытыбыз юк, син безне тизрәк ашата башла. Үсеп җиткәч, әнкәбез төсле көчле булгач, без синең теләсә нинди шартыңны үти алачакбыз.

— Ярый алайса, тик карагыз аны, соңыннан үкенергә туры килмәсен.

— Килмәс, килмәс, — дигән бөркет балалары, — соңыннан, ни теләсәң — шуны эшләрбез. Ә хәзер син безнең тамакны туйдыр.

Шушы көннән Кара елан бөркет балаларын ашата башлаган. Авызларына һәр көн ризык кереп торгач, болар күзгә күренеп үскәннәр, матурайганнар. Шәрә түшләре йомшак мамык белән капланган. Канатлары ныгыганнан-ныгый барган. Инде ояларын ташлап очып китәргә дә күп калмаган. Ләкин шул вакыт Кара елан авырып киткән. Ул инде хәзер бөркет балаларына ризыклар китерә алмый башлаган. Бөркет балалары аңарга үзләренең үпкәләрен белдереп болай дигәннәр: «Үзең без үсеп җиткәнче ашатып торырга вәгъдә бирдең, үзең вәгъдәңне үтәмисең. Безгә бит инде оча башларга күп калмады. Ике-өч көнгә түз».

— Мин түзәр идем дә, чир түзмәде шул, балалар, — дигән Кара елан. — Селкенерлек тә хәлем юк. Ә барыбер вәгъдәне үтәргә кирәк, сез дөрес әйтәсез. Вәгъдә бозу — иман бозу. Ә иманны бозарга ярамый.

Кара елан шулай дигән дә үз койрыгын тешләп өзеп бөркет балаларына ашарга биргән. Өч көн буена яшь бөркетләрне шулай туйдырып торган ул. Болар зурайган саен Кара елан кечерәя барган. Тора-бара аның башы белән муены гына калган.

Ниһаять, бөркет балалары тәмам үсеп, очып китәр хәлгә килгәннәр.

— Рәхмәт сиңа, Кара елан, безне ашаттың, үстердең. Инде үзеңнең шартыңны әйт, — дигәннәр.

— Шартым шул: һәрберегез миңа үзегезнең иң кадерле бер нәрсәгезне бирегез. Мәсәлән, берегез канатларыгызны, икенчегез — күзегезне, өченчегез — тәпиләрегезне.

Кара еланның бу сүзләреннән яшь бөркетләр өнсез калган.

— Еланга канатлар нигә? — дигән берсе.

— Күзләремне сиңа бирсәм, мин үзем нишләрмен? — дигән икенчесе.

— Корычтай тырнаклы тәпиләрем булмаса, табышымны ничек күтәреп кайтырмын, — дигән өченчесе.

— Анысы инде сезнең эш, — дигән Кара елан. — Сез бит минем шартымны тыңлап та тормастан, теләсә нәрсә эшләргә вәгъдә бирдегез.

— Безнең бик ашыйсыбыз килгән иде шул, — дигән бөркетләр.

— Хәлегезне аңлыйм, — дигән Кара елан, — ләкин сез дә мине аңларга тырышыгыз. Минем дә бит гомеремдә һич югы бер тапкыр сезнең кебек канат кагып зәңгәр күккә күтәреләсем, очлы үткен күзләр белән дөньяга туйганчы карыйсым, көчле тырнакларыма үз корбанымны эләктереп ояма кайтасым килә. Үзегез күреп торасыз: минем бит хәзер шуышып йөрергә койрыгым да калмады.

Бөркетләр Кара еланга караганнар. Ул чынлап та бик хәлсезләнгән, бик картайган. Бердәнбер күзеннән туктаусыз яшь ага, бер урыннан икенче урынга күченергә теләгәндә гәүдәсен ыргытып, көч-хәл белән генә кузгала икән.

Бөркетләр яшертен генә әле үзләренә, әле Кара еланга күз салганнар. Тәмам бөрешкән, бетерешкән Кара елан кызганыч, әлбәттә, аңа ярдәм итсәң бик әйбәт булыр иде, әмма канат тикле канатыңны, күз тикле күзеңне ничек бирәсең инде. Юк, юк, Кара еланнан качарга кирәк. Хәзер алар ныгыдылар, үстеләр, һавага очып китсәләр, Кара елан түгел, ук та куып җитә алмаячак. Качарга, тизрәк качарга!

Алар шулай уйлашып кыя читенә тезелеп басканнар. Кара елан бөркетләрнең уйларын сизенеп болай дигән:

— Әлбәттә, сез хәзер еракка-еракка очып китә аласыз. Көчле давылларга чыдарлык канатларыгыз, юлыгызны кара төннәр аша күрерлек үткен күзләрегез, корбаныгызны ычкындырмаслык гайрәтле тәпиләрегез бар. Кая гына китсәгез дә, мин куа бармам. Тик шуны онытмагыз: аучы укларыннан, яшен

утларыннан качып котыла алсагыз да, үзегездән үзегез кача алмаячаксыз. Намусыгыз сезне һәрвакыт ээәрлекләп йөрер. Ә минем өчен борчылмагыз. Мин ашасын ашадым, яшәсен яшәдем. Үлгәнче җирдә бер яхшылык эшләп калдырасым килгән иде — аны да эшләдем. Хәзер минем җаным тыныч. Кара еланнарның да күңелләре ак икәнлеген раслый алдым. Йә, хушыгыз, балакайларым! Бәхетле булыгыз!

Кара еланның бу сүзләреннән соң бөркетләргә бик-бик оят булып киткән. Алар башларын иеп Кара елан каршына килгәннәр.

— Кичер безне, Кара елан. Начар уйларыбыз өчен кичер. Син безнең әнкәбез булдың: ашаттың, эчерттең, җил-давыллардан саклadың. Моның өчен без сиңа мәңге бурычлы. Ләкин әле бу синең яхшылыгыңның берсе генә. Икенче яхшылыгың: син безнең намусларыбызны уяттың. Монысы өчен инде бернәрсә дә җәл түгел.

Бөркетләр шулай дигәннәр дә берсе канатларын, икенчесе күзләрен, өченчесе тәпиләрен Кара еланга китереп биргәннәр.

Кара елан аларның канатларын, күзләрен, тәпиләрен алып үзенә таккан һәм кыя читенә басып чиксез киңлекләргә текәлгән. Аның әле һичбер вакыт мондый ераклыкка карый алганы, күкрәгендә мондый көч-гайрәт ташыганы булмаган. Тау-тау булып аккан ак болытлар, иксез-чиксез киң офыклар аның күңелен алгысыткан. Ул очып китмәкче булып талпынып-талпынып куйган. Ләкин вакытында тыелып калган.

— Тукта, ярсыма, йөрәгем, — дигән ул үз-үзенә. — Әгәр мин хәзер очып китсәм, кылган яхшылыгымнан берни калмаячак. Яхшылыкны әҗәткә эшләмиләр. Ул бары тик эчкерсез генә эшләнергә тиеш. Нәфесне җиңә дә белергә кирәк.

Кара еланның кыя читенә басып уйланып торуын күреп, бөркетләр аңа болай дип дәшкән:

— Оч инде, оч, вакытыңны әрәм итмә. Гомер буе авыр таш астында ятып син бит берни күрмәгәнсең. Дөнья киң ул, матур ул. Оча башлагач безнең сүзләрнең хаклыгына үзең дә ышанырсың.

— Мин болай да ышанам, — дигән Кара елан. — Ләкин мин очу уеннан кире кайттым инде. Канатларыгыз, күзләрегез, тәпиләрегез өчен рәхмәт сезгә. Мәгез аларны. Сезнең әле бөтен гомерегез алда: сезгә канатлар да, күзләр дә, тәпиләр дә күп тапкырлар кирәк булачак.

Һәм Кара елан бөркетләрнең кадерле нәрсәләрен үзләренә кайтарып биргән. Бөркетләр аңа мең рәхмәтләр укып һавага күтәрелгәннәр. Кара елан, кыя ташына басып, аларның матур итеп очуларын сокланып күзәткән. Аннары аларга болай дип кычкырган:

— Кайда гына йөрсәгез дә, нинди юллар үтсәгез дә шуны исегездә тотыгыз: эшнең шартын белми торып вәгъдә бирергә ашыкмагыз. Вәгъдәне бирү җиңел, ләкин үтәве авыр. Вәгъдә — күңелнең иманы. Ә иман — һәр җан иясенең кыйбласы. Әгәр кыйблаң булмаса, күзле килеш тә күрмәскә, канатлы килеш тә оча алмаска мөмкин. Шуны онытмагыз, балакайларым! Онытма-а-гы-ыз!

## ИҢ БӘХЕТЛЕ КӨН

Ялгандырмы-чындырмы, булгандырмы-юктырмы, авылда түгел, шәһәрдә, шушы безнең көннәрдә яшәгән, ди, бер юаш малай. Бик оялчан, бик юаш булганга аны малайлар дус итмәгән, кызлар иш итмәгән. Малайлар дус, кызлар иш итмәгәнгә юаш малайның бик-бик хәтере кала икән. «Их, бүтәннәр белән бергә-бергә уйныйсы, шаярасы иде, — дип хыялланган ул. — Егылып аста калсам да, куеныма кар йомарлап салсалар да еламас идем. Уйнасыннар гына иде минем белән!»

Әмма малайлар, кызлар аның белән уйнамаганнар, юаш малайның күкрәгендә бөркет барлыгын аңламаганнар. Ул килеп уенга кушылса, читкә сибелгәннәр, сүз башласа, егыла-егыла көлгәннәр, кар бабай ясап куйса, җимереп ташлаганнар, сагыштан җырлап җибәрсә, үртәгәннәр.

Юаш малайның моңа бик-бик хәтере калган, ачудан йодрыклары йомарланган, күзләреннән очкыннар чәчрәгән, әмма үзен рәнҗетүчеләргә каршы чыгарга кыюлыгы җитмәгән. Чөнки ул кешеләрне рәнҗетүдән бик-бик курка торган булган.

Таң артыннан таңнар аткан, җилләр искән, сулар аккан. Ә бу вакыт эчендә ишегалды малайлары бер-берләре белән утыз тапкыр ачуланышырга, кырык тапкыр дуслашырга өлгергәннәр, тик әлеге юаш малай гына үзенә иптәш таба алмаган.

Көннәрнең берендә ишегалдының усал малайлары, чәрелдек кызлары уйный-уйный арып өйләренә таралышкач, күктә йолдызлар кабынгач, болытларны аралап ай калыккач, бөркет җанлы юаш малай чыккан да җепшек кардан бик матур итеп Кар кызы ясап куйган. «Без синең белән мәңге дуслар булырбыз. Бергә-бергә тау шуарбыз, тәгәри-тәгәри уйнарбыз, яме», — дигән ул Кар кызына.

— Мин риза, — дигән Кар кызы. Һәм алар җитәкләшеп тауга менеп киткәннәр. Итекләрен чана иткәннәр. Чаналарына төнге җилләрне җиккәннәр. Егылсалар, берсен-берсе тартып торгызганнар,

арысалар, иңгә-иң куеп ял иткәннәр, күктәге йолдызларга карап сокланганнар. Юк кына нәрсәдән дә кызык табып тәгәри-тәгәри көлгәннәр. Шатлыктан күңелләре тулып ташыса — җырлап җибәргәннәр. Куеннарына суык кереп, тәннәрен чеметкәли башласа — рәхәтләнеп биегәннәр. Алар биегәндә, җилләр такмак әйткән, маэмайлар өреп үзләренең соклануларын белдергәннәр, кош-кортлар агач ботакларына утырып тамаша кылган. Бер генә җан иясе дә авыз ерып көлмәгән, үртәмәгән, үчекләмәгән.

— Их! — дигән юаш малай, хискә бирелеп, — дөньяда дустың булу нинди рәхәт икән.

— Әйе, — дигән Кар кызы, — синең кебек батыр малай белән дус булуыма мин бик шат.

— Юк шул, — дип кире каккан аны малай, — мин батыр түгел.

— Син батыр! — дигән Кар кызы. — Чөнки син кара төннән курыкмыйча берүзең урамга чыктың. Аннары әле генә минем күзләремә карап: «Мин батыр түгел», — дип әйтә алдың. Үзеңә карата мондый сүзне әйтер өчен дә батырлык кирәк.

Кар кызының бу сүзләре юаш малайның күңелендә әллә нинди уйлар кузгатып җибәргән. Моңа кадәр әле аңа бер генә кешенең дә «син батыр» дип әйткәне булмаган. Кеше йөрәгенә яшерелгән батырлыкны күрү өчен күзең очлы, күңелең әйбәт булу кирәк шул. Шушы минуттан башлап юаш малай бернидән дә курыкмый башлаган.

— Әйдә синең белән шәһәр әйләнәбез, — дигән ул Кар кызына.

— Әйдә. Минем төнге шәһәрне бик-бик күрәсем килә.

Алар төнге шәһәр урамы буйлап атлап киткәннәр. Аяк астында ак кар җырлаган, баганадагы утлар серле итеп күз кысышкан, туптай түгәрәк ай алдан тәгәри-тәгәри аларга юл күрсәтеп барган. Урамнар — урамга, юллар юлга ялганган. Һәрберсендә алар кызык тапканнар, яңа матурлыклар күргәннәр. Җилләр ялап шомарткан шугалакларда шуганнар. Табаннарына каткан боз барлык төр тимераяклардан шәбрәк шуган. Шуып туйгач, юлларын тагын дәвам иткәннәр. Юлда аларга төрле бакчалар очраган. Бөркет җанлы юаш малай белән Кар кызы атынчыкларга утырып атынганнар. Атынчыкның әле кыз утырган ягы, әле малай утырган ягы күккә тигән. Әле малай, әле кыз күктән йолдыз үрелеп алып бер-берләренә бүләк иткәннәр.

Бу төндә алардан да бәхетле кеше булмаган. Шулай бәхетләрен күкрәкләренә сыйдыра алмый йөргән чагында бик матур бизәлгән чыршы янына килеп чыкканнар.

— Нинди гүзәллек! — дигән Кар кызы. — Ботак саен җәнлекләр, ылыс саен йолдызлар. Мондагы йолдызлар күктәге йолдызлардан да яктырак яна.

— Әйе, — дигән малай, — тиздән Яңа ел бәйрәме. Ул бәйрәмгә сине дә чакырачаклар.

— Мине? — дигән Кар кызы, малайның сүзләренә ышанып җитмичә.

— Сине. Чөнки бер генә Яңа ел да Кар кызыннан башка узмый. Ә син дөньядагы кар кызларының иң-иң әйбәте, иң-иң матуры. Кыш бабай сине җитәкләп чыршы янына килеп җитүгә, бөтен малайларның күзе синдә булачак.

— И-и, — дигән Кар кызы, малайның сүзләреннән оялып, — син үзең әйбәт булганга гына мине мактыйсың.

Алар бәхәсләшеп киткәннәр. Һәркем үзенең дустының матурлыкларын күбрәк табарга тырышкан. Ә күңел күзе белән караганда кеше җанының иң эчкәре почмакларына яшеренгән матурлыкларын да табарга була икән.

Төне буе шәһәр буйлап алар озак йөргәннәр. Шаярганнар, көлгәннәр. Бер-берләренә иң яшерен серләрен чишкәннәр. Йөреп туйгач, иңгә-иң куеп сүзсез генә утырганнар. Кайдадыр йолдыз атылган, кайдадыр серле утлар җемелдәшкән. Берәм-берәм тәрәзәләр яктыра башлаган.

— Бәхетле көн үтеп тә китте! — дигән малай, көрсенеп. — Яңадан бервакытта да мин болай бәхетле булалмам инде.

— Булырсың, — дигән Кар кызы, — чөнки синең күңелең бай. Ә күңел байлыгы — зур бәхет ул.

Кар кызы шулай дигән дә шаянланып малайның җилкәсенә суккан: «Син үзеңнең батыр икәнлегеңне онытма, батырлык иң беренче йөрәктә туа».

Һәм чынлап та шушы көннән башлап бөркет җанлы юаш малай батырларның батырына әйләнгән. Көчсезләрне рәнҗетсәләр, яклашыр өчен арага атылып кергән, уенда иң беренче үзе башлап йөргән. Кешеләрнең кимчелекләреннән көлүчеләр булса, канга батканчы сугышкан.

Хәзер инде ишегалдында ул ясап куйган Кыш бабайга да, Кар кызына да беркемнең кагылырга батырлыгы җитмәгән. Әти-әниләре: «Безнең малаебызга ни булды соң?» — дип сокланып та, аптырап та карап куялар икән. Ә бөркет җанлы юаш малай, үзенең тугры дусты Кар кызына тәрәзә аша күз кысып: «Рәхмәт, дустым, син мине көчлелегемә, үземнең бүтәннәрдән ким түгеллегемә ышандырдың. Мин хәзер күкрәгемдә таулар күчерерлек гайрәт сизәм. Мин бик-бик бәхетле, әйе-әйе, бәхетле, чөнки синең кебек әйбәт дусты булган кеше бәхетсез дә, кыюсыз да, куркак та була алмый», — дип эндәшә икән.

## ХӘТЕРСЕЗ КҮКЕ

Сезнең җәй көннәрендә урманга барганыгыз бармы? Барганыгыз булса, мөгаен, агачтан агачка кунып «Күк-күк! Күк-күк!» дип кычкыручы күкене күргәнегез бардыр. Әгәр аның тавышына игътибар итсәгез — анда ниндидер сагыш, моң, өзгәләнү, чакыру авазлары ишетерсез. Нигә өзгәләнә, нигә сагышлана икән соң күке? Урманның барча кошлары эчләренә сыймаган шатлыкларын тирә-юньгә җыр итеп тараткан чакта ни өчен күке болай моңлана икән?

Шушы соравыма җавап табарга теләп, беркөнне мин урманга киттем. Урман тып-тын иде. Җилләр агач күләгәсенә сузылып ятып мыш-мыш йоклый. Аюлар юкә балы белән тәмләп чәй эчеп утыралар. Куяннар, чәчәкле аланга җыелып, сикереш ярышы уздырып яталар. Җырчы сандугачлар таң алдыннан бик каты сайрап арыганнар, хәзер кипкән тамакларын чылатыр өчен яфраклардан чык суы эчеп йөриләр. Бары тик күкеләр генә әле бер агач башына, әле икенчесенә күчеп: «Күк-күк! Күк-күк!» — диләр. Шунда мин иң матур, иң төз, иң биек каен башына кунган күке янына килдем дә:

— Әй, Күке! Ни өчен болай моңаясың? Әйтергә яраса, миңа сереңне әйт әле.

Минем тавышымны ишетеп, күке кычкыруыннан туктады. Канат очы белән күз яшьләрен сыпырып алды. Аннары болай диде:

— Ничек инде мин моңаймыйм?! Эчем тулы сагыш бит минем. Сез, кешеләр, безнең сагышны аңламыйсыз. Безне башка кошлар оясына күкәй салган өчен гаеплисез. Балаларын үстерергә яратмый, дисез. Йә, кем инде үз баласын яратмасын.

— Алайса, нигә соң чит кошларның ояларына күкәй саласыз? — дидем мин.

— Хәтерсезлектән бу, — дип көрсенде Күке. — Хәтеребез бик начар безнең. Үз оябызны таба алмыйбыз. Аннары инде аптырыйбыз да башка кошлар оясына күкәй салабыз. Икенче күкәй салыр вакыт җиткәнче теге кошның оясын да югалтабыз. Менә бермәлне безнең утырыр вакытларыбыз җитә. Әле анда сугылабыз, әле монда бәреләбез. Бөтен урманны бетереп оябызны эзлибез. Арып-алҗып бетәбез. Шулай эзли торгач, агач башында бер оя күреп алабыз. Сөенә-сөенә шунда кереп утырабыз, ләкин безнең сөенечебез озакка бармый, бу ояга йә берәр саескан, йә карга килә дә: «Бу нинди чакырылмаган кунак? Минем өемдә нишләп утырасың?» — дип тавыш куптара.

Оятыңнан нишләргә белмичә тизрәк моннан чыгып китү ягын карыйсың. Аннан инде икенче оя эзләп табасың, әмма аннан да сине куып җибәрәләр. Җитмәсә әле кайбер кошлар сине бөтен урман алдында мәсхәрә итә. Оя ясарга иренәсең, балаларыңны теләсә кемгә ташлап калдырасың, диләр. И-и, аңламыйлар безне, аңламыйлар. Кошлар гына түгел, кешеләр дә безне иң юньсез җан иясенә саныйлар. Ә безнең күңелебездә бернинди мәкер юк бит. Без: «Күк-күк! Күк-күк!» — дип, көннәр буе үзебезнең балаларыбызны чакырабыз. Тавышыбызны бер ишетмәсәләр, икенче ишетеп яныбызга килерләр, дибез. Безнең дә үз балаларыбыз турында кайгыртасыбыз, аларның үскәннәрен, канат ныгытканнарын күреп сөенәсебез килә. Үз балаң турында кайгыртудан да ләззәтлерәк мәшәкать бармыни дөньяда!

Күк-күк! Күк-күк!

Шулай диде дә күке очып китте. Озакламый ул икенче агачка кунып кычкыра башлады: «Күк-күк! Күк-күк!» Мин озак кына аның тавышын тыңлап тордым. Күңелгә әллә нинди сагыш, моң тулды. Үзем дә сизмәстән күзләремне сөртеп куйдым. Хәзер инде миңа күкеләр турында начар уйлавым өчен оят иде.

## ЮЫЛМАС ХУРЛЫК

Биек-биек тау битендә, зәңгәр офыклар читендә үлән утлап йөри икән бер Колын белән бер Ат. Күк йөзендә кояш янып тора икән, тау битендә чишмә агып тора икән, агачларда кошлар чут-чут сайрашканнар, ал чәчәкләр үз телендә аңлашканнар. Дөнья шундый матур икән, якты икән, яшен үлән шундый тәмле, татлы икән.

— Әй, әнием, — дигән Колын бу матурлыкка сокланып, — нинди рәхәт. Чабам, уйныйм, йөгерәм-сикерәм. Күкрәгемдә көч-гайрәтем ташып тора, әрәмәләр колачларын ачып тора. Бер сикерсәм, тауга менеп баса алам. Бу дөньяда юктыр миннән җитез колын, чабар өчен җитми миңа бу тар болын.

— Бик мактанма әле, улым, — дигән аңа сабыр ана. — Җитезләрдән җитезләр бар, көчлеләрдән көчлеләр бар.

— Юк, юк, — дигән уйнак Колын әнкәсенә, — сүзләремә ышанмасаң кара менә!

Уйнак Колын чабып киткән болын буйлап, хәтта җиргә тими икән каты тояк. Ә әнкәсе карап торган аңа сөенеп, минем улым инде үсеп җитте диеп.

Болын буйлап йөгерә торгач, сикерә торгач, әнкәсеннән ерак киткән җитез Колын. Әнкәсе кычкырган аңа: «Улым, улым! Берүк алай ерак китмә, озак йөрмә».

Колын аны тыңламаган, озак йөргән, бернәрсә дә уйламаган. Менә бермәл кинәт кенә давыл купкан, күк күкрәгән, зур имәнне яшен суккан. Шунда гына Колын кайтыр юлга чыккан.

— Әнием! — дип кычкырган ул, үргә менеп. Һәм шул чакта үз әнкәсен алган күреп. Ә әнкәсен ач бүреләр алган камап, аралары өч-дүрт аркан буе калган.

Әнкәсе улын чакырган кешни-кешни:

— Улым, улым, ярдәмгә кил, коткар мине. Син бит җитез, уздырмыйсың хәтта җилне. Бүреләрне үз артыңнан ияртеп чап, алар сине тоталмаслар, калыр туктап.

Әнкәсенә ярдәм итмәк булып Колын бүреләргә таба чапкан бар көченә. Ә бүреләр улаганнар, чинаганнар. Һәм Колынның курку йөгергән эченә. Шуннан соң ул туктап калган кинәт кенә, куаклыкка кереп поскан иплә кенә. Утырган ул куаклыкта куркып байтак, давыл узган урман-болыннарны айкап. Бүреләр дә уламаган, тынган дөнья, шунда гына Колын чыккан кайтыр юлга. Кайтып җитсә, нәрсә күрә — әнкәсе юк. Ул урында ята бары сөяк-сынык. Бер як читтә аунап ята аның башы, күзләрендә катып калган соңгы яше.

Баш янына килә Колын елый-елый, ләкин елап үткәнне кайтарып булмый.

— Әнкәм, әнкәм! Куркып калдым, кичер мине. Мактандым мин уздырмыйм дип хәтта җилне. Әнкәм, әнкәм, әгәр белсәң миңа өйрәт, батыр булып үсәр өчен нәрсә кирәк?

Шул чагында атның башы телгә килгән:

— Улым, улым, соңгы сүзем тыңла, — дигән, — батыр булыр өчен җанда шәфкать кирәк. Батыр була бары мәрхәмәтле йөрәк. Шәфкатьлеләр аямыйлар үз-үзләрен, яклый алар зәгыйфьләрне, көчсезләрне. Шәфкатьсезләр батыр булмый һичбер чакта. Уйла, улым, яши-яши шушы хакта.

— Әнкәм, әнкәм, — дигән Колын, — мин ант итәм: явызлардан куркып калмам бүтән. Ташланырмын утка-суга, давылларга. Беркемне дә рәнҗеттермәм җаным барда.

Һәм сүзендә торган Колын, батыр булган. Бик гайрәтле көтү башы айгыр булган. Саклаган ул ат көтүен һәр ерткычтан. Күзе аның очлы булган бөркет-коштан. Күкрәгендә йөз арыслан көче булган. Әгәр типсә, дәү имәннәр шартлап сынган. Көтүлеккә ерткыч бүреләр килмәгән. Ул барында беркем дә курку белмәгән.

Сабантуйда ярышларда гел ул җиңгән. Мактаганнар аны төшермичә телдән. Ләкин айгыр шатланмаган моңа бер дә. Зур үкенеч йөрткән чөнки ул күңелендә. Әнкәсен бит яклашмады бүреләрдән, андый хурлык юыламыни күңелләрдән. Менә шуңа ул һәрвакыт боек булган, шатлык гөлен хурлык кылычы кыеп торган.

## АЛСУ ЧӘЧӘК

Борын-борын заманда, биек таулы, карурманлы авылда кечкенә сеңлесе белән бер абый яшәгән. Абыйсының аяклары авырта икән. Шуңа күрә бөтен эшне бәләкәй сеңлесе эшләгән. Салкын чишмәләрдән сулар алып кайтып, тәмле-тәмле чәйләр кайнаткан, болыннардан кызарып пешкән җиләкләр җыеп абыйсын сыйлаган. Һәр көн тәрәзәләрен ачып өйләрен җилләткән, сап-сары иттереп идәннәрен юган. Абыйсы аңа: «Ярый әле, сеңлем, син бар, югыйсә мин нишләр идем», — дигән.

— И абый, — дигән кыз, — миңа эшләү берни түгел. Чишмәләргә барган саен, мин кояш нурларыннан салават күперләре сузам, болыннарга чыксам, күбәләкләр белән куышам, урманнарга керсәм, кошлар тавышын тыңлыйм. Шуннан бөтен аруларым басыла. Тагын да күбрәк эшлисем килә башлый. Әгәр кулымнан килсә сине терелтер идем. Тау башына менәр идең дә күзләрең арыганчы кояшка карар идең. Аннан соң мин сине үзем генә белә торган җиләкле аланнарга алып барыр идем. Ничек кенә синең аякларыңны йөри торган итәргә икән, абый?

— Аның бер чарасы бар-барын, — дигән абыйсы. — Хәтереңдәме, безгә бервакыт сихерче карчык килгән иде. Шул миңа сөйләде. Имеш, әнә теге биек тау башында бер алсу чәчәк үсә. Көннең иң озын, төннең иң кыска вакытында шул чәчәкне өзеп алып кайтып аякларыңны сыйпасаң, авыруны гел булмаган кебек иттерә икән...

— Абый, — дигән кыз, шатланып, — ул тауны беләм ич мин. Барам да алсу чәчәкне өзеп алып кайтам. Көннәр генә озынайсын.

— Юк, сеңлем, ул тауга болай гына менеп булмый. Анда бара торган сукмакны авызы бәрәңге базы хәтле аждаһа саклый. Ә ул аждаһаны һични белән дә җиңмәле түгел, ди. Безнең авылның батырлары булат кылычлар тагып менеп-менеп карадылар инде. Әмма кылычларын сындырып, үзләре кара канга батып кайттылар.

— Алайса анда сукмаксыз җирдән менәргә кирәк, абый, — дигән кыз, — мин ул урманның бөтен чытырманлыкларын, бөтен уравыч юлларын беләм. Җиләк җыйган чакта куяннар сукмагыннан да, аюлар эзеннән дә йөрергә туры килгәләде. Тик бер җирдә аждаһа очрамады.

— Ул аждаһа көннәрнең иң озынайган чагында гына сакка чыга, ди, шул. Шуңа күрмәгәнсеңдер. Чөнки шул вакытта гына алсу чәчәк шифалы суларга туенып җитә. Ә син беләсеңме соң, көннәрнең иң озын, иң кыска вакыты кайчан булганын?

— Беләм, абый. Юкәләргә бал төшкән, болыннар гөлгә күмелгән июньдә була.

— Шулай, сеңлем. Гөлләр чәчәкләрен атып өлгерсен, кошлар балаларын тизрәк үстерсен өчен, иң җылы чакта көннәр озыная. Менә тиздән тагын кояшлы җәй килеп җитәр. Болыннарда ак болыттай ак күбәләкләр уйнар, җылы яңгырлар басуларны сугарыр, күктән җиргә бал явар, муллык явар.

— Шул вакыт теге алсу чәчәк тә үсеп чыгар, абый, әйеме?

Кызның күңелен алсу чәчәк шундый дулкынландырган, хәтта ул аны төшләрендә күрә икән. Ә җәй житеп, җилләр дөньяга хуш исләр таратып, кояш нурлары үләннәрнең йомшак чәчләрен сыйпап йөри башлагач, кыз түзмәгән, көн саен урманга чыккан да күзләре авыртканчы тау ягына караган. Эзли торгач, йөри торгач, ул тау башына илтүче туры сукмакны да тапкан. Сукмак уртасында, өй хәтле кара таш астында подностай олы күзләрен ялтыратып, аждаһа ята икән. Кыз әллә нинди уравыч юллардан, куе чытырманлыклардан тауга менмәкче булып караган, ләкин барлык юллар да ахыр чиктә шушы аждаһа янына китереп чыгарган. Ә аждаһа яныннан үтеп китүне уйларлык та түгел, ди. Кыз алай да итеп караган, болай да итеп караган, ләкин бер хәйлә дә тапмаган. Әмма аның абыйсын терелтәсе килү теләге шундый көчле икән, шифалы чәчәкне өзми торып һич кенә дә өенә кайтасы килмәгән. Әйләнгән дә шул сукмакка килеп чыккан ул, әйләнгән дә килеп чыккан. Шулай аптырап йөргәндә, тау итәгендә ялтырап яткан бер нәрсә күреп алган. Ул әйбергә һич кенә дә туры карап булмый, күзне чагылдыра икән. Озаграк карасаң, хәтта күзләрдән яшь ага башлаган.

Читкә борыла-борыла гына ул ялтыравыклы әйбер янына йөгергән. Барып җитсә, ни күзләре белән күрсен, җем-җем итеп яткан нәрсә гап-гади пыяла икән. Кыз аны ачу белән читкә атмакчы булган, тик шул вакыт башына бер уй килеп атмый калган.

— Кара әле, — дигән ул, — пыяла минем күзне чагылдыргач, аждаһаның күзләрен дә чагылдырырга тиеш бит. Кояш нурларын аждаһага таба җибәрәм дә, күзләре яшьләнгәч кенә үтәм дә китәм. — Сөенеченнән нишләргә белмичә, кабат аждаһа яткан сукмакка йөгергән ул. Күк йөзендә һичбер болыт әсәре юк икән. Бөтен дөнья күзне камаштырырлык якты, ди. Кояш та, кызга ярдәм итәргә теләгәндәй, нурларын бер дә кызганмыйча урманга, болыннарга сипкән. Кыз каушаудан дерелдәгән куллары белән якты нурларны үзенең пыяласы аша явыз аждаһага юнәлткән. Аждаһа, бу ни хәл дигән кебек челт-челт күзләрен йомган. Тора-бара аның күзләре яшьләнеп, ялт-йолт итә башлаган, әйтерсең аларга утлы яшеннәр кереп тулган да, менә-менә гөлт итеп кабынырга торалар. Аждаһаның күзләре еш йомылган саен, ныграк кыюланган кыз. Ниһаять, аждаһа яшьле күзләрен йөнтәс койрыгы белән ныклап уарга тотынган. Шул вакыт кыз яшь болан тизлегендә аның яныннан үтеп тә киткән. Ә тау шундый биек икән, югарыга күтәрелгән саен, сукмагы да тарая барган. Кызның тез буыннары калтыраган, йөрәге атылып чыгарга җитешеп ярсып типкән. Әмма яшь батыр туктамаган, хәтта артына борылып карамаган. Артына борылып караса, теге аждаһа куа киләдер кебек тоелып котын очырган.

Инде хәлсезләнеп егылам дигәндә генә тау башына менеп җиткән ул. Һәм андагы иркенлекне күреп хәйран калган. Монда мәһабәт кошлар тау башына утырып ял итәләр, тиеннәр агач башларында тирбәлеп агачлардан чикләвек коялар. Ә кояш шундый якын: зуррак кыяга басып кулларыңны сузсаң, буең җитәр төсле. Әмма кызга мондагы матурлыклар белән хозурланып йөрергә ярамый шул. Аны авыру абыйсы көтә. Тизрәк шифалы чәчәкне эзләп табарга да абыйсын терелтергә кирәк!

Кыя ташына утырып бераз хәл җыйгач, теге чәчәкне эзләргә дип торып баса ул. Ләкин шул вакыт әллә каян гына котырынган җил чыга. Урман шомлы тавыш белән шауларга тотына. Кошлар куркышып ояларыннан качалар. Көн караңгылана. Үләннәр күзгә күренеп бөрешә. Ә барлык чәчәкләр шайтан таягына әверелә. Шунда каяндыр ерактан, агачларга-ташларга бәрелеп, тау хуҗасының ямьсез тавышы ишетелә.

— Ха-ха-ха! Минем сакчымны хәйләләп үттең дә хәзинәмне алып китмәкче булдыңмы? Алмый тор! Мин аны ерак яшердем. Әнә күрәсеңме чәнечкеле шайтан таягын? Шуның берсе алсу чәчәк. Танысаң — ал!

Кыз, тавыш килгән якка карарга да куркып, баскан урыныннан кузгалмый тора. Күзләрен куллары белән каплап кирегә, өйләренә чабасы килә. Тик урыныннан тора алмыйча сызланып ятучы абыйсын уйлап ала да батырланып шайтан таякларына таба юнәлә.

— Бөтенесен өзеп кайтсам кайтырмын, әмма чәчәкне тапмый калмам, — ди ул, үзсүзләнеп, һәм шайтан таякларын йолкып кочагына җыя башлый. Энәдәй каты чәнечкеләр аның кулларына кадала, бармакларын каната, уч төпләрен җәрәхәтли. Тик ул туктамый. Шул заман әллә каян гына бер тиен кызның алдына сикереп төшә.

— Исәнме, иске таныш? — ди ул кызга. — Әллә танымыйсың инде?

— Гафу ит, тиенкәй, танымыйм. Сез барыгыз да бертөсле бит.

— Хәтереңдәме, былтыр син мине капкыннан коткарган идең?

— Синең бит, тиенкәй, арт тәпиең аксап калган иде, ничек төзәлде?

— Шушы таудагы алсу чәчәк белән сыйпадым, шуның шифасы тиде.

— Мин ул чәчәкне таба алмам инде, — ди кыз һәм кайгысын тиенгә сөйләп, елап җибәрә.

— Кайгырма, — ди тиен, — җаен табарбыз. Әнә тегендә өзелгән кәлтә койрыгы ята. Шуны барып ал әле. Селкенәме?

— Юк, селкенми.

— Селкенмәгәч бигрәк әйбәт. Хәзер шул кәлтә койрыгын тот та шайтан таякларының чәчәкләренә тидереп чык. Кайсысына тигәч кәлтә койрыгы селкенә башласа, шунысы шифалы алсу чәчәк булыр.

Шулай ди дә тиен китеп бара. Кыз аңарга рәхмәт әйтергә дә өлгерми. Тиен китү белән, ул эшкә керешә: койрыкны әле бер чәчәккә, әле икенче чәчәккә тидереп карый. Инде бөтенесенә диярлек кагылып чыга, әмма койрык селкенми. Бары тик бер читтә ике-өч кәрлә үсенте генә кала. Кызның күңеле суына. Теләр-теләмәс кенә теге үсентеләр янына килә. Салмак хәрәкәтләр белән койрыкны чәчәккә сыйпап җибәрүе була, койрыкка җан кереп, уч төбендә тыпырчына башлый. Куанычыннан кулларының авыртуын да онытып, бу чәчәкне өзеп ала ул. Бары тамырлары гына җирдә кала.

Кулга шундый хәзинә төшергәч, аруын да, ачыгуын да онытa. Хәтта аждаһа ята торган өй хәтле кара ташны да сикереп кенә үтә.

Әйтерсең аңа кемдер канатлар куйган, очып кына кайта. Кайтып кергәндә, куанычының иге-чиге булмый.

— Абый, — ди ул, — алсу чәчәкне таптым бит. Моннан соң бервакытта да авырмассың инде.

Шулай сөйләнеп, абыйсы янына килә һәм аякларын ачып чәчәге белән сыйпап җибәрә. Башта бармаклар әкрен генә селкенә башлый, аннары хәрәкәт тез буыннарына күчә. Күзгә күренеп аяклар җанлана. Ә инде күпмедер вакыт үтүгә, кызның абыйсы бер дә авырмаган кебек торып баса. Торып баса да сеңлесен һавага чөя. Шуннан соң инде алар дөньядагы иң бәхетле кешеләр булып яшиләр, ди...

## ИҢ ОШАГАН БҮЛӘК

Элек-элек, бик тә элек, кояш гел көлеп торганда, чишмәләр саф сулы чакта, болыннарда йөз-мең төрле гөл үскәндә, тугайларда рәхәт һәм саф җил искәндә, һәр агачта кош булганда, һәрбер җәнлек үзара бик дус булганда, яшәгән, ди, бер авылда гүзәл бер кыз. Кызның йөзе кояш кебек нур сипкән, ди, ә ул йөргән сукмакларда гөл үскән, ди. Җыр башласа, кошлар туктап тыңлаганнар, кырга чыкса, күбәләкләр аның белән чәбәк-чәбәк уйнаганнар. Суга барса, чиләгенә кояш кунган, кер чайкаса, тез башларын дулкын юган. Шулай, дуслар, кыз чибәр һәм уңган булган. Ерак киткән аның даны, бик-бик ерак. Күп егетләр килә икән кызны сорап. Егетләрнең кайсы батыр, кайсы бик тә укымышлы, кайберләре төскә-биткә бик килешле. Кайберләре байлык белән дан алган, ди, кайберләре патша нәселе саналган, ди.

Ләкин бу кыз һичбер кемгә карамаган: батырны да, матурны да үзенә тиң санамаган.

— Кызым! — дигән әнкәләре аңа беркөн. — Нишләп әле ошамый сиңа беркем? Инде үстең, балигъ булдың, акыл керде, кешеләрнең телләренә чибәр кыз дип атың керде. Син шуны бел: чибәрлекнең гомере кыска, җәйнең гүзәл гөлләре дә сула кышка. Җиткән кыз ул бал шикелле: артык озак сакладыңмы — ачый башлый, җиткән кыз ул сөт шикелле: артык озак кайнаттыңмы — ташый башлый.

— Сүзләрең хак, әнием, — дигән кыз шул вакыт. — Күптән йөрим бераүне мин бик яратып. Тик ул хакта ул үзе дә белми әле, арабызда сандугачлар йөрми әле. Аның өчен кульяулыклар чиккәнем бар, аны уйлап күз яшьләрем түккәнем бар, яннарыннан су күтәреп үткәнем бар. Ә ул күрми, мин чыктыммы — борыла читкә, аның уе әллә җирдә, әллә күктә. Мин карыймын матур гөлгә, ә ул күлгә, мин карыймын уйнак-йөгерек дулкыннарга, ә ул карый упкыннарга. Мин аптырыйм, гаҗиз калам ошбу хәлгә, бик үк чибәр түгел микән мин соң әллә? Әллә инде кимчелегем бармы берәр, әллә соң мин җилбәзәкме яки юләр?

— Юк, юк, кызым, — дигән ана, — хафаланма. Әнә кара көзгеләрдән, син бер алма. Алманың да кып-кызылы, өлгергәне — өсләренә таң нурлары йөгергәне. Йөзең синең тулган айга тиңләшерлек, билләреңә зифа таллар көнләшерлек. Акылың камил, зиһенең ачык, уең йөгерек, бар яктан да җиткән чагың бик өлгереп.

Ана һәм кыз озак кына сөйләшкәннәр, эткәләре белән утырып киңәшкәннәр. Ата кеше — авылның шәп тимерчесе — чүкече белән киңәш итеп алган да, ди, түбәтәен бераз кыңгыр салган да, ди, әйткән сүз:

— Без, җәмәгать, болай итик, аптырамыйк. Бар дөньяга хәбәр салыйк җайлап кына, кызыбызны үстердек дип назлап кына. Хәзер җитте башлы-күзле итәр вакыт, асыл кошыбыз оясына китәр вакыт. Кызыбызның бер шарты бар егетләргә: һәрбер егет килсен берәр бүләк алып, кем бүләге кызга ошый — кызыбыз шуңар. Бирербез без шәп иттереп, ясап туйлар.

— Ә мәхәббәт? — дигән, ди, кыз, авыр сулап. — Мин яшәсәм гомер буе Аны уйлап? Колагымда торса яңгырап Аның тавышы, йөзләремне басып китсә сагыну сарысы? Аны уйлап томаланса минем зиһенем, бар дөньяга гамьсезләнсә минем күңелем?

— Алай булмас, кызым, — дигән ата кеше. — Мин тормышны бераз беләм, миңа таян, сөйгән егетең килеп җитәр әллә каян. Бүләкнең дә сайлар синңа ошардаен, йөридер ул сүз катарга тапмый җаен. Ул егеткә менә шундый җай бирик без — ат алырбыз, ә хәзергә тай бирик без.

Килешкәннәр өчесе дә шушы шартка. Киткән хәбәр уңга-сулга, алга-артка. Кошлар илткән аны диңгез - артларына, җилләр илткән тау илләре якларына. Агымсуның дулкыннары хәбәр салган далаларга, телеграфлар хәбәр иткән калаларга. Кабатлаган бер үк сүзне бар да, бар да. «Егетләрнең асыллары, көчлеләре, куркаклары, йомшаклары, хислеләре — һәммәгез дә ашыгыгыз тизрәк, тизрәк! Мондый хәлләр дөньяларда була сирәк. Бәхетнең бу алмасын өзеп ала алмасаң да үрелеп карау бик тә кирәк. Егетләрнең буйсызлары, буйлылары, көчлеләре, уйсызлары, уйлылары! Ашыгыгыз, ашыгыгыз, тизрәк, тизрәк! Чибәр кызны шаккатырсын сезнең бүләк».

Бу хәбәрне ишетүгә, барча егет юлга чыккан бәхет сынап карыйк диеп. Бер хан улы кәрван-кәрван байлык алган, кәрванына алтын салган, көмеш салган. Сандык саен ефәк, атлас күлмәкләр, ди, кайсын алма, искитәрлек бүләкләр, ди.

Килеп кергән ханның улы, сәлам биргән, бүләкләрен кыз каршына китереп өйгән. Бүләкләре шундый затлы һәм кыйммәтле, бар да әйбәт, барчасы да бик зиннәтле. Йөзектәге асылташлар йолдызларга тиң, ефәкләре дулкын-дулкын диңгезгә тиң. Беләзекләр салават күпере кебек бар да, муенсалар шәфәкъ нуры сирпеп яна. Карап торсаң, күзкәйләрең камаша, ди, кыз алдында менә шундый тамаша, ди.

Караган кыз бүләкләрне тотып-тотып, егет торган эчтән генә утлар йотып. Чөнки бу кыз каршысында асылташларның да төсе киткән, алтыннарның-көмешләрнең көче беткән.

— Әйбәт! — дигән карагач кыз бүләкләрне. — Күргәнем юк иде мондый зиннәтләрне. Тик гафу ит, болар миңа кирәкми һич. Инде, егет, юлга җыен, җитә бит кич.

Егет киткән горур башын түбән иеп, кәрванына байлыкларын кире өеп. Ул арада кич җиткән дә таңнар аткан. Иртәгесен тагын берәү капка каккан.

Кияү егетенең бусы килгән алты кораб белән, кораблары тулы булган ризык белән, шәраб белән. Бер бәлешне күтәргән, ди, туксан кеше, бар дөньяга таралган, ди, тәмле исе. Күккә очкан затлы шәраб бөкеләре, зыңлап торган бәллүр савыт-рюмкалары. Авыл халкы болыт булып агылган, ди, һәркемгә дә тәмле ризык табылган, ди. Егет әйткән чибәр кызга: «Йә, сүзең әйт, ошадымы минем бүләк? Миңа чыксаң, ашарсың гел тәмле генә, көннәребез үтәр безнең ямьле генә».

Кыз шул вакыт күздән кичереп бүләкләрне, әйткән болай: «Ашаган юк иде мондый нигъмәтләрне, тик гафу ит — болар минем өчен түгел. Мин бер гади авыл кызы, якын күрәм мин болардан ипи-тозны».

Егет киткән башын иеп, яшен тыеп.

Тагын килгән әллә кемнәр, әллә кемнәр. Тәрәзәсен ачык тоткан кызлы өйләр. Күп егетләр каккан башка капкаларны һәм яр иткән чибәр сеңел-апаларны.

Безнең кызыбыз көткән һаман җан сөйгәнен, көткән аның янына килеп баш игәнен. Һәм беркөнне егет килгән, сәлам биргән. Тик кулында һичбер төрле бүләге юк, әллә инде өйләнергә теләге юк?

Кыз бик рәнҗеп әйткән аңа: «Нигә, егет, йөрисең син бу кадәрле миннән көлеп? Кулларыңда һичбер төрле бүләгең юк, әллә инде өйләнергә теләгең юк? Әллә инде мин бүләккә тормаслыкмы, йә таләбем һич тә үтәп булмаслыкмы?»

— Бүләгем бар, — дигән егет, — кара менә. — Һәм түшеннән тартып алган нәзек энә.

— Энә? Нигә энә?

— Шуңа энә, чөнки синең кулларың бик шәп эш белә. Тегәсең син, чигәсең син. Ертыкларны ямыйсың син, кисекләрне ялгыйсың син. Олау-олау зиннәтләрне кире бордың, олау-олау нигъмәтләрне кире бордың.

Чөнки белдең — байлык бары бер айлык ул. Байлык бетә, һөнәр кала, һөнәр — үлми. Һөнәре бар — ярлы булмый, алар — бөлми.

Бик ошаган чибәр кызга мондый җавап, энәне дә бик яратып куйган кадап. Ярый, дигән, бүләгеңне бик яраттым, әмма сиңа бар, егетем, тагын шартым.

— Шартыңны әйт, Чибәркәем, тартынма һич, күкрәгемдә дәрт җитәрлек, беләктә — көч.

— Ярый, егет, ышандырдың. Ә шарт болай: миңа читек тегеп китер, булсын уңай. Зур булмасын, кысмасын да — булсын таман, ардырмасын йөгерсәң дә һаман-һаман. Тик аякны үлчәтергә итмим рөхсәт, үлчәмичә тегә алсаң — миннән рәхмәт.

— Бу шарт безгә берни түгел, — дигән егет. Тиз арада читекне дә биргән тегеп. Чибәр кызга бик ошаган егет эше: үзе таман, үзе уңай, матур төсе. Моны кигәч йөгерәсе килеп торган, кызның җитез аяклары биеп торган.

— Үлчәвен дә алмадың бит аягымның, ничек болай таман итеп тегә алдың?

Егет әйткән кош сайратып телләрендә: «Синең эзләр күптән минем йөрәгемдә. Турыбыздан суга барган чакларыңда карап кала идем синең артларыңнан. Үтә идең йөрәгемә баса-баса, карый идем коймаларга кача-кача. Сүз катсам да рәнҗерсең дип курка идем, күз атсам да рәнҗерсең дип курка идем. Син бит патша малайларын каратырлык, син бит чибәр — бөтен дөнья яратырлык».

Егет һәм кыз аңлашканнар шушы көннән. Туйларына кунак килгән бөтен илдән. Оркестрлар көне-төне торган уйнап, егет һәм кыз кунакларны торган сыйлап. Теләгәннәр шәраб эчкән мичкәсеннән, теләгәннәр ит кимергән түшкәсеннән.

Бу парларның туйларында мин булмадым, самолетта очкан идем — бик соңладым. Чөнки, күккә күтәрелгәч, бензин бетте, болытларга утырып өч көн бензин көттек. Очып кына киткән идек, төштек тагын — бер шәһәрдә сатыла иде карбыз, кавын. Алдык аны барыбыз да күпләп-күпләп һәм төядек самолетка йөкләп-йөкләп. Төйи торгач әйберебез китте күпкә, безнең очкыч меналмады кабат күккә. Киттек җәяү капчыкларны иңгә салып, йөрдек озак, ни сатсалар, шуны алып. Кай шәһәрдә озак-озак тордык чират, кай җирләрдә юл булмагач, үттек урап.

Мин барганда тәбрикләргә дип боларны, йөгереп йөри иде инде бер уллары. Соңарсам да үкенмәдем барганыма, эләктем мин сыйларының калганына. Туйга пешкән бәлеш төбе калган иде, хәтта әле суынмаган, кайнар иде.

## КАРАЧКЫ

Бакча уртасындагы түтәлдә кулларын җәеп як-якка, карашын төбәп еракка, бер Карачкы тора икән. Баш очында яшен кылычлары уйнаса да, ярсып-ярсып яңгыр тамчылары кыйнаса да, сулышына ут кабарлык итеп кояш кыздырса да, әллә нинди куркыныч тавышлар белән җилләр сызгырса да урыныннан кузгалмаган ул. Төннәр буе, көннәр буе, җәйләр буе, көзләр буе гел бер урында басып торып аның аяклары бик тала икән, шуңа күрә ул йөгереп киткән балаларга кызыгып карап кала икән.

— Их, — ди икән ул, көрсенеп, — менә шушы юл тузанына манчылып уйнаган малайлар арасына килеп керәсе, табаннарга ут капканчы йөгерәсе, тирләп пешкәч, ярдан сикерә-сикерә су керәсе, аннан комга сузылып ятып тән киптерәсе иде. Өйгә озаграк кайтмасаң — борчылып көтсеннәр, кирәк икән — кыйнасыннар, тик синең турында уйласыннар иде. Юк шул, аны назламыйлар да, тиргәмиләр дә, югалтмыйлар да, эзләмиләр дә. Аның иңнәренә хәтта кошлар да кунмый, чөнки ул ямьсез, чөнки ул куркыныч. Ә бит аның кыяфәте ямьсез булса да, күңелендә матур-матур уйлар яши, тик ул дәшми, чөнки белә: ямьсезләрнең матур сүзләреннән дә бит күпләр көлә. Ә Карачкының бер дә үзеннән көлдерәсе килми, шуңа күрә матур уйларын беркемгә дә белдерәсе килми. Әмма матур уйларын кешеләргә сөйләмәсә дә, күңелен чишәргә теләмәсә дә, җанын сагыш сарган чакта, яшәп-яшәп арган чакта эчтән генә булса да бер җырламый түзә алмаган ул. Ә җыры аның аккан болытлар, искән җилләр, үскән гөлләр, йолдызлы төннәр, кояшлы көннәр турында икән. Карачкы үзенең җырын кешеләр ишетмәсен өчен караңгы төннәрдә генә җырлаган, әгәр кешеләр ишетсә, көләрләр дип уйлаган. Әмма бик сак кыланса да, әкрен генә моңланса да, беркөн аның җырын Ләлә чәчәге ишетеп алган, ишетеп алган да хәйран калган.

— Әй, Карачкы! — дигән Ләлә, җыр тынгач. — Синең тавышың нишләп бу кадәр сагышлы? Бу җырны сиңа кемнәр өйрәтте?

— Белмим, — дигән Карачкы, — җыр ул ярадан саркып чыккан кан кебек күңел түреннән чыга, аны кешедән өйрәнеп кенә булмый.

— Минем синең җырларыңны тыңлаган саен тыңлыйсым, кайчакта үземнең дә кушылып җырлыйсым, ә кайчакта үксеп-үксеп елыйсым килә, — дигән Ләлә Карачкыга. — Әйдә, җырла әле озак итеп.

Карачкы, үзен тыңлаучы табылуга куанып, бер уйланып, бер моңланып җырлаган да җырлаган. Лалә аның җырын бөтен күңелен салып тыңлаган. Кайчагында үзе дә ул Карачкыга кушылып куйган, чөнки җырның тәмен, җырның ямен җаны-тәне белән тойган.

Хәзер инде Карачкы белән Лалә кара төннәрне көтеп ала башлаганнар. Берсе җырлаган, икенчесе тыңлаган. Җырлаучысы — җырлаудан, тыңлаучысы тыңлаудан рәхәт тапкан. Тик боларның бәхетләре озакка бармаган, бакчага болар турында төрле сүзләр таралган.

— Ишеттегезме әле? — дигән Нәркиз чәчәге үз кырыендагы зәңгәр күзле кыңгырауларга. — Карачкы белән Лалә дуслашкан, ди.

— Ха-ха-ха! — дип кычкырып көлгәннәр кыңгыраулар һәм тиз арада боларга карата такмак та чыгарып өлгергәннәр.

Карачкының күлмәгендә
Сиксән ямау бар икән,
Берсе җырлый, берсе тыңлый —
Бигрәк килгән пар икән.
Ха-ха-ха-ха, ха-ха-ха-ха,
Бигрәк килгән пар икән.

Үзләренә чыгарган бу такмакны ишетмәс өчен, Лалә колакларын куллары белән каплаган, әмма дусларының «ха-ха-ха» дигән көлү авазы бармаклары аша саркып барыбер эчкә кергән. Лалә өзгәләнгән, аннан ачынып дусларына болай дигән:

— Юкка көләсез сез миннән, дусларым. Карачкының җыры искиткеч матур. Анда безнең тамырларыбызны сугаручы чишмә моңы да, зеңгел-зеңгел итеп җилләрдә тирбәлүче кыңгыраулар чыңы да, таңнар сафлыгы да, көннәр аклыгы да бар. Әгәр дә сез аның җырын күңел биреп бер тыңласагыз, миннән көлмәс идегез. Әйе, аның җыры алтын, тавышы көмеш.

Чәчәкләр Лаләдән тагын көләргә тотынганнар:

— Ха-ха-ха! Ямьсез карачкы матур җырлар җырлый, имеш. Имеш, аның җыры алтын, тавышы көмеш...

Һәм яңадан бакча буйлап киткән көлеш. Таралган сүз бер колактан бер колакка, Лалә мескен гарьлегеннән елаган ятып сукмакка. Ә Карачкы якын дустын мондый хәлгә калдырганга гаять тә нык кыенсынган, янган-көйгән, ашамаган, йокламаган. Үзенең шулай ямьсез булып тууына бик кимсенгән, китәсе килгән аның бу бакчадан бик еракка, күз күрмәгән, сүз йөрмәгән берәр якка. Һәм караңгы төн җиткәчтен җырлаган ул мондый бер җыр:

Алчы мине, әй кара төн,
Эрим әле кочагыңда.
Яныйм әле таңнар булып
Синең кайнар учагыңда.

Тик кара төн Карачкыны тыңламаган: учагында яндырмаган, кочагында калдырмаган. Көн белән төн килә торган, китә торган, гомер җебен урый торган, сүтә торган. Ә Карачкы ялварудан эш чыкмагач кара төнгә, ялварырга тотынган ул искән җилгә:

Җилләр, җилләр, ныграк исегез,
Җитәрлек бит сезнең көчегез.
Йолкыгыз да мине алыгыз,
Упкыннарга илтеп салыгыз!

Әмма җилләр Карачкыны йолкып алмаганнар, упкыннарга илтеп салмаганнар. Үз җайлары белән генә искәннәр дә искәннәр, дөньяларны кичкәннәр дә кичкәннәр.

Ә чәчәкләр, көн тудымы, Лалә белен Карачкы турында яңадан-яңа такмак чыгарганнар. Ул такмакларны берсе башлаган, икенчесе күтәреп алган. Мыскыллы көлү авазлары белән бакча тулган, аларны тыңлый-тыңлый Карачкының башы тубал булган. Бигрәк тә Нәркиз гөле Карачкыга нык каныккан. Карачкы мескен тәмам ябыккан, сөякләре калыккан, күзләре гел эчкә баткан, йөзләренә сырлар яткан. Шунда ул эчке бер сагыш белән, тетрәндергеч тавыш белән болай диеп җырлап җибәргән:

Каян алыйм матурлыклар
Матур булып тумагач?
Кемгә барып зарым сөйлим
Язмышымнан уңмагач?

Нәкъ шул вакыт бакча турысыннан бер матур кош очып бара икән. Карачкының җырын ишеткән дә ул, янына төшкән.

— Әй, Карачкы, — дигән кош, — нигә болай моңаясың? — Башыңа кайгы килдеме, берәрсе синнән көлдеме?

— Кайгыларның миндә зуры, — дигән Карачкы, — булдым тәмам адәм хуры. Бөтенесе миннән көлә, чөнки күрә — мин бик ямьсез, бик иләмсез. Йә әйт үзең, моннан да зур бәхетсезлек бармы тагын?

— Кайгың чынлап та зур икән, — дигән аңа бу матур кош. — Ләкин минем кайгым белән чагыштырсаң, синең кайгы бик кечкенә.

— Сөйләмә юкны, — дигән Карачкы, — синең нинди кайгың булсын? Әнә бит син нинди матур, канатларың, каурыйларың җем-җем итә. Сиңа тик бер карасаң да йөрәкләргә рәхәт булып китә. Тагын шунысы: очам дисәң, канатың бар — син ирекле.

— Анысы шулай, — дигән Карачкыга бу матур кош, — каурыйларым минем аллы-гөлле. Тәпиләрем, томшыкларым бик килешле. Очам дисәм, канатым бар — мин ирекле.

— Шулай булгач, сиңа тагын нәрсә кирәк?

— Минем, дускай, тавышым юк, җырлый алмыйм.

— Әй тапкансың кайгырыр нәрсә, — дигән аңа Карачкы. — Кыяфәтең матур булгач җыр нигә ул?

— Җырсыз яшәү бик-бик авыр, — дигән, ди, кош Карачкыга. — Кайчагында күрәсең дә матур җирләр, матур телләр, күңел сөенеч белән тула. Шундый чакта әй җырлыйсы килә, әй җырлыйсы. Килә бик тә сөенечеңне күбрәк җиргә таратасы, җырың белән бар дөньяны авызыңа каратасы. Җырлыйм диеп омтыласың — тавышың чыкмый. Беркемгә дә шатлыгыңны әйталмагач, шатлык үлә күңелеңдә. Ә бу авыр, гаҗәп авыр. Хәтта моны аңлатып та биреп булмый.

— Шулаен ул, бәлки, шулайдыр, — дигән Карачкы. — Тик бит җырлый белмисең дип синнән көлмиләр. Нәфрәтләнмиләр, йөз чөермиләр. Җырлый алмау кимчелек түгел.

— Юк, кимчелек! — дигән кош, бәхәскә кереп. — Җыр бит ул — җан. Җырсыз күңел ул — буш күңел. Син менә, башыңа кайгы килгәндә, җырлый аласың. Хәсрәтеңне җырың белән таратасың. Ә мин нишлим? Кайгымны җилләргә дә сөйли алмыйм, төннәргә дә сөйли алмыйм. Сөйләмәгәч, ул авыр таш булып һаман җыела эчкә. Аны күтәреп йөрергә җитми башлый һичбер көч тә.

— Син, ичмасам, теләсә кая оча аласың, — дигән Карачкы аңа каршы.

— Очуын мин оча алам, — дигән кош, — ләкин, дускай, очып кына үз-үзеңнән качып булмый. Күпме очма, кая китмә — синең кайгың йөри барыбер синең белән.

— Алай булгач, әйдә алышабыз язмышларны, — дигән Карачкы. — Син бир миңа матурлыгыңны — мин җырымны.

— Ярый-ярый, — дигән бу кош Карачкыга, — мин бик риза.

Алмашканнар болар шулай, килешкәннәр. Максатларына ирешеп сөенешкәннәр. Матур кош үзенең киемен салган, Карачкының киемен алган. Кыяфәте аның бик-бик ямьсезләнеп калган. Шулай да ул кайгырмаган, борчылмаган, чөнки күңеленә кайнар агым булып җыр тулган. Тора-бара бу җыр аның бөтен җанын биләп алган, кош шул вакыт хисләренә түзә алмый җырлап җибәргән. Кошның матур җырын ишетеп, күктәге йолдызлар әйлән-бәйлән уйнарга керешкәннәр. Айбикә дә үзенең ап-ак күлмәк итәген чеметеп тотып биеп алган. Җилләр исүдән туктаган, яфраклар хәйран калып җырны тыңлаган.

Ә Карачкы нишләгәнме? Ул, алланып таң атуга, гүзәл гөлгә әверелгән. Аны күреп барлык гөлләр «аһ» иткәннәр. Хәзер инде һәркем аның белән дуслашырга теләгән, ди. Тик Карачкы мондый хәлгә сөенмәгән дә, көенмәгән дә. Чөнки аның җыры белән күңеленнән бар да чыккан, бар да очкан. Аның эче буп-буш калган.

Шуннан соң нәрсә булганмы? Шуннан, дуслар, җәйләр үтеп көзләр җиткән. Әкрен-әкрен бакчадагы гөлләр сулган, Карачкы киеменең дә төсе уңган. Шунда аңлаган Карачкы матурлыкның мәңгелек түгеллеген. Ләкин инде бик соң булган: мәңгелек җыр вакытлыча матурлыкка алышынган.

Бу хәлгә Карачкы бик үкенә икән, елый икән, әмма күпме еласа да күзеннән яшь чыкмый икән. Ә күзеннән яшь чыкмагач, хәле бер дә җиңеләйми, ди.

Әйе, шулай. Сүзләрем чын, әкиятем чын: бу дөньяда мәңгелек тик җыр белән моң.

## ХЫЯЛЫЙ ЧЕБЕШ

Борын-борын заманда, матур яшел аланда, язның аяз көнендә, шәп куаклык төбендә бер чебеш дөньяга килгән. Чыккан да ул, йомырканың кабыгын ватып, караган, ди, бар дөньяга исе китеп, шаклар катып. Бик

күп икән иркә урман тавыклары, тиеннәре, куяннары, аюлары һәм урманның бүтән халыклары. «Пип-пип» дигән чебеш. Аның тавышын карурман көчәйтеп җибәргән, җилләр еракка илткән. Үз тавышын беренче кат ишеткәнлектән, гаҗәп матур, гаҗәп яңгыравык булып тоелган чебешкә. Ул тагын да куәтлерәк итеп кычкырган: «Яшел урман, син нинди киң, нинди иркен! Бу дөньяга килүемә нибарысы әле бер көн. Ә шулай да яраттым мин сине мәңге. Аланнарың шундый ямьле, җиләкләрең шундый тәмле. Үләннәрең йомшак синең келәмнәрдәй, чык суларың — энҗе-мәрҗән...»

Хыялый чебешнең бу сүзләрен ишеткән дә бер тилгән, очып якынрак килгән һәм чебешкә болай дигән: «Дөнья күргәнең юк синең, мескен чебеш. Чык сулары энҗе-мәрҗән, куаклыклар, чытырманлык матур, имеш. Синең, чебеш, очканың, киңлекләрне кочканың юк. Канат җилпеп күккә менсәң, гүзәллекне өстән күрсәң әйтер идең: кояшны зур алтын диеп, офыкларны ялкын диеп. Без алмаз йолдызлар белән туенабыз, ак болытка сузылып ятып кызынабыз, ут уйнатып яңгыр яуса — коенабыз. Мин сине, чебешкәем, бер очыртып карар идем, менә шунда матурлыкны аңлар идең».

«Юк, сөйләмә, җитәр, — дигән аңа чебеш, — син мине һавага күтәр, күрим әле бөтенесен, гомерем дә җәл түгел гүзәллекне күрер өчен».

Тилгән аны төшеп алган. Күтәргән, ди, зәңгәр күккә, бик биеккә. Чебешкәйнең болытларга башы тигән. Чынлап та, күк ай-яй матур, зәңгәр офыклар киң, сулышлар киң, тынга иркен. Кошларның бик күп төрлесе оча икән төркем-төркем. Болытлар да ефәк шәлен болгыйлар, ди, кошлар арыгач, болытларга утырып җил тавышын тыңлыйлар, ди. Бу зурлыкка, хозурлыкка хәйран калып, күкрәгенә бик күп итеп сулыш алып, очып китмәкче булган, ди, чебеш үзе. Бер талпынган, бер кагынган. Тилгән аны шулчак ялгыш ычкындырган. Чебеш мескен бик әз генә очып барган. Һәм түбәнгә егылып төшкән. Егылып төшкәч, башын тишкән. Ләкин башы тишелсә дә үкенмәгән, чөнки бит ул белгән очыш тәмен. Күргән анда биек-биек күкләр ямен...

Инде чебеш үсеп җиткән, тавык булган. Әмма һаман онытмый, ди, шул очышны. Озатып кала, ди, көрсенеп һәрбер кошны.

## ҮЛЕМСЕЗ ЭТ

Бер бик Карт эт булган. Ул инде үзенең ничә яшьтә икәнен, хуҗасының кем булуын, элек кайларда яшәгәнлеген — бөтенесен-бөтенесен оныткан. Артык картаюдан аның кайчандыр елкылдап торган йоннары коелган, төлкенеке кебек кабарынкы койрыгы көтүче чыбыркысыдай нечкәргән. Колагы катыланган, борыны сизгерлеген, тәпиләре җитезлеген югалткан. Хәзер инде аның башыннан сыйпаучы да булмаган. Хуҗалары ишегалдын сакларга икенче яшь эт алып кайтып куйганнар. Карт эт, үз оясын яшь эткә биреп, абзар почмагына кереп урнашкан. Аны күргән кеше күргән, күрмәгән кеше юк.

— Болай яшәгәнче үлүең мең тапкыр артык, — дип уйлаган Карт эт һәм әҗәлен эзләп карурманга чыгып киткән. Бара икән, бара икән — бара торгач моңа биш ач бүре очраган. Ач бүреләрне күргәч, Карт эт бик сөенгән. Болар мине һичшиксез ботарлап ташлаячаклар инде, дип уйлаган. Әмма Карт этне күрүгә, бүреләр икенче якка борылып китә башлаганнар. Карт эт, ач бүреләргә чын күңеленнән рәнҗеп, болай дип кычкырган:

— Әй, бүреләр! Туктагыз, качмагыз миннән. Тотып ашагыз мине. Әз булса да тамагыгыз туяр.

— Синең карт сөягеңне кимереп теш сындырасыбыз килми әле, — дигәннәр бүреләр.

— Бүтән нәрсә югында карт сөяк тә ярап куя ул, — дигән Карт эт. Һәм бүреләр артыннан ияргән.

— Йөрмә безнең арттан, — дигәннәр бүреләр, — барыбер без сине ашамыйбыз, чөнки син безнең туганыбыз. Шуны исеңнән чыгарма: бүреләр үз туганын ашамыйлар.

Шулай дигәннәр дә бүреләр китеп барганнар. Карт эт, алардан аерылгач, аю сукмагына таба борылган. Бара икән, бара икән — бара торгач моның каршысына алпан-тилпән атлап бер аю килеп чыккан.

— О-о, кемне күрәм, — дигән Аю, — ничек безнең урманнарга килеп чыктың? Син бит кайчандыр бик шәп йортның умарталарын саклый идең.

— Мин әҗәлемне эзләп йөрим, — дигән Карт эт. — Яши-яши бик арыдым. Инде үләсем килә. Ботарлап ташла син мине, аю дускай.

— Син кем дип белдең мине? — дип, чын-чынлап үпкәләгән Аю. — Дөрес, теге вакыт син минем сыйракны нык умырып алган идең. Әмма ләкин сыйрак төзәлгәч, сиңа ачуым бетте. Бигайбә, сине ботарлый алмыйм.

Шулай дип Аю үз юлына киткән.

Карт эт Аю киткән юлга моңсуланып озак кына карап торган. Аннан алга таба юл тоткан. Бара икән, бара икән — бара торгач моңарга бер Кабан дуңгызы очраган. Карт эт сөенә-сөенә Кабан дуңгызының каршысына йөгергән.

— Кая ашыгасың болай? — дигән Кабан дуңгызы.

— Әҗәлемә, — дигән Карт эт.

— Кызык, — дигән Кабан дуңгызы, — әҗәленә ашыгучыны үз гомеремдә беренче күрәем.

— Тотып аша мине, Кабанкай, — дигән Карт эт.

— Туктале, тукта, — дигән Кабан дуңгызы, — тиктомалдан сине тотып ашарга әллә мине юләр дип белдеңме? Синең бит миңа бернинди дә зыян китергәнең юк.

— Алайса, мин сиңа хәзер зыян китерәм, — дигән Карт эт һәм Кабан дуңгызының арт сыйрагын барып тешләгән. Әмма аның тешләре күптән коелып беткәнлектән, Кабан дуңгызы бу тешләүне сизмәгән дә.

— Юкка маташма, — дигән Кабан дуңгызы, — иң яхшысы, син миңа ни өчен үләргә теләвеңне сөйлә. Ашарыңа азык табалмыйсыңмы? Әгәр шулай икән — мин сиңа булышырмын. Мин бер аланда бүреләрдән калган болан ите күрдем. Алып барам, тамагыңны туйдырырсың.

— Юк, юк! — дигән Карт эт. — Эш тамакта гына түгел. Тамак туйдырырлык ризыкны чүплектән дә табарга була.

— Бәлки, сиңа торырга оя кирәктер?

— Эш ояда гына да түгел, — дигән Карт эт. — Дөньяда ташландык оялар җитәрлек. Әле мин менә бик матур бер аю өне күрдем. Хуҗасы үзенә икенче оя ясаган, ахры. Бусын ташлап киткән. Оя кирәк булса, шунда кереп яшәргә дә мөмкин.

— Алайса, мин берни дә аңламыйм, — дигән Кабан дуңгызы, — бәлки, аңлатыбрак сөйләрсең.

— Сөйләргә мөмкин, — дигән Карт эт, — ләкин минем сүзем шактый озын, сине ялыктырмасмы соң?

— Әйдә, сөйлә, минем ашыгыр җирем юк, — дигән Кабан дуңгызы.

Карт эт яшел чирәмгә сузылып яткан да сүз башлаган:

— Минем хәтер капчыгым хәзер бик нык искерде инде. Күп нәрсәне оныттым. Шулай да мәңге истән чыкмый торган вакыйгалар да була икән. Бервакыт шулай әле көчле, гайрәтле чагымда хуҗа малае мине үзе белән су буена алып төшеп китте. Көн бик кызу. Комга бассаң — табаннар пешә. Хуҗа малае киемнәрен өстеннән тиз генә йолкып атты да суга чумды. Мин яр башында киемнәр саклап калдым. Минутлар арты минутлар үтте, әмма суга чумган малай кире калыкмады. Мин бик каты өрергә тотындым. Минем өрүемне ишетеп, яныма малайлар җыелды. Алар бик озак эшнең нәрсәдә икәнен аңламый тордылар. Елганың бөтерчек җирендә малайның башы калкып чыккач кына алар минем өрүемнең серенә төшенделәр. Ләкин малайны коткарырга берсенең дә йөрәге җитмәде. Чөнки елганың агымы бик көчле, малай эләккән бөтерчек урын аны эчкә суырганнан-суыра бара иде. Шунда мин үзем суга сикердем. Хуҗа малаеның сыйрагыннан каптырып ярга таба өстери башладым. Әмма көчле бөтерчек агым минем үземне дә төпкә тартканнан-тарта барды. Яр буена малайны алып чыгып җиткергәндә, аякларым дер-дер калтырый, колакларга су тулган иде. Малайны көч-хәл белән терелттеләр. Ә миңа бу батырлыгым өчен Хуҗа тәмле-тәмле ризыклар ашата башлады. И-и, ул чакта кимергән сөякләрнең тәмлелеге! Аны сөйләп кенә бетерә торган түгел. Хуҗа миңа хәтта яңа оя да ясап бирде... Бу хәлдән соң авылдагы бөтен малайлар минем сыртымнан сыйпап китә торган булдылар.

Карт эт сөйләвеннән бер мәлгә туктап торды.

Кабан дуңгызы аңардан:

— Башың шундый кадерле булгач, нишләп яшәүдән туйдың соң? — дип сорады.

— Бөтен эш тә шунда шул, — дип дәвам итте Карт эт. — Хуҗам үлде, аның малае каядыр читкә китте. Минем даным онытылды.

— Гафу ит, дускай, — диде Кабан дуңгызы, — мин синең соңгы сүзләрне аңламадым. Нәрсә соң ул дан?

— Данмы? — диде Карт эт, бик гаҗәпләнеп. — Дан ул хуҗаңа кылган яхшылыкның телдән телгә сөйләнүе.

— Ә нәрсәгә кирәк соң ул? — диде Кабан дуңгызы.

— Ничек инде нәрсәгә кирәк? Без бит, этләр, кешегә хезмәт итәр өчен яратылган. Яхшы хезмәт итсәң — сине мактыйлар, кадерлиләр, олылыйлар. Менә шул дан була инде. Бездә, этләр арасында, һәркем мактауга ирешергә тырыша.

— Алай икән, — диде Кабан дуңгызы, һаман берни аңламыйча. — Менә безне беркем дә мактамый, аңа карап үзебезне һич тә ким-хур сизмибез.

— Сез бит кабан дуңгызлары, — диде Карт эт, — сезнең бурыч башка, эш башка.

— Йә, ярар, — диде Кабан дуңгызы, — башыңнан үткәннәрне сөйләп бетер. Бәлки, шуннан соң берәр нәрсә аңлармын.

Карт эт сөйләвен дәвам итте:

— Элекке хуҗам үлгәч, мине икенче кешеләр алды. Гөнаһларына керә алмыйм, болар да мине әйбәт ашатты. Какмадылар, сукмадылар. Аларның яхшылыгына үземнең дә яхшылык белән җавап бирәсем килә иде. Һәм моңа җай да чыкты. Беркөнне төн уртасында Хуҗаның өен яшен сукты. Өй түбәсе дөрләп яна башлады. Моны күреп, мин тәрәзәне тырный-тырный өрергә тотындым. Хуҗа бик каты арып эштән кайткан иде. Һич кенә дә уянмады. Мин аны берничек тә уята алмагач, тәрәзәне күкрәгем белән бәреп кердем дә киеменнән тышка өстери башладым. Шунда гына ул уянып китте. Үзе уянгач, кычкырып бөтен авылны уятты. Төн бик җилле иде. Утны көчкә сүндерделәр. Иртәгесен, авылны саклап калучы дип, яше-карты миңа төрле сыйлар китерде. Шуннан соң кайсы йортка кермә — мине гел сыйлап чыгардылар, сыртымнан сыйпап иркәләделәр. Ә иркәләнү — бик рәхәт нәрсә. Ул хәтта сөяк кимерүдән дә татлырак.

Аннан соң да авыл кешеләренә күп кенә яхшылыклар эшләргә туры килде. Һәр яхшылыгымнан соң кешеләр мине әйбәтләп сыйладылар һәм: «Гомереӊ озын булсын, мәңге яшә!» — дип аркамнан сыйпыйлар иде. Мин кешеләрнең бу теләгенә бик нык сөендем. Мәңге яшәүдән дә шәбрәк нәрсә юктыр дип уйлый идем. Хәзер шуны аңладым: бу бер дә шатланырлык нәрсә түгел икән.

— Ничек инде шатланырлык булмасын? — диде Кабан дуңгызы, гаҗәпләнеп. — Миңа шундый теләк теләсеннәр иде әле.

— Кешеләрнең теләкләре кабул булды, — дип дәвам итте Карт эт. — Мине бернинди дә әҗәл алмады. Озак яшәдем. Минем данлы эшләремне белүчеләр үлеп беттеләр. Ә данлыклы эшләрне көн саен эшләп торып булмый. Шулай итеп даным әкрен-әкрен үлде. Үзем картайдым. Көчем бетте. Күкрәгеңдә гайрәтең, борыныңда сизгерлегең, тәпиләреңдә җитезлегең калмагач, яшәүнең бер кызыгы да юк икән.

— Үткәндәге даныңны уйлап яшә, — диде Кабан дуңгызы.

— Юк шул, үлгән данны терелтеп булмый. Көч-гайрәтем бетүгә дә, сизгерлегем югалуга да бу кадәр кайгырмыйм мин. Ә менә җылы сүз ишетмәсәң, сыртыңны яратып, иркәләп сыпыручы булмаса, яшәүнең бер кызыгы да калмый икән. Кайчандыр без дә менә сезнең кебек кыргый булганбыз. Кешеләр безне иркәләп, назлап кулга ияләштергән. Без иркәләүгә, назлауга өйрәнгәнбез, шунсыз яши алмас хәлгә килгәнбез.

— Ә бит син ниндидер дан дисең, — диде Кабан дуңгызы.

— Әйе, — диде Карт эт, — дан да иркәләүнең бер төре. Йоныңнан сыпырганда тәнгә рәхәт, мактаганда җанга рәхәт. Менә шушы яхшылыкларың үзеңнән алда үлсә — яшәүнең бер мәгънәсе дә калмый. Кешеләр миңа «мәңге яшә» дигәндә изге нияттән чыгып әйткәннәрдер, билгеле. Ә минем мәңге яшисем килми. Чөнки инде мин хәзер үземне яраттырырлык эшләр эшли алмыйм.

— Алай, алай, — дигән Кабан дуңгызы, — сезнең тормыш бик мактаулы икән. Дөрес, мин сине бик аңлап бетермәдем. Ә бәлки, аңламавым яхшырактыр да. Йә, хуш, мине гаепләмә.

Кабан дуңгызы китеп барган.

— Әгәр юлыңда үз корбанын эзләп йөрүче әҗәлне очратсаң, монда җибәр, — дигән аңа Карт эт һәм китеп барган. Ләкин аны упкыннар да йота алмый, чытырманлыклар да йота алмый икән. Ул һаман үзенең ни өчен яшәгәнен дә онытып, уттан суга, судан утка ташланып, әҗәлен эзли икән.

## КАРЛЫГАЧ, АККОЛАК ҺӘМ ТЫЧКАН

Акколак дигән песи өй түбәсенә менеп кояшта кызынып ятарга бик ярата икән. «Их, — дип уйлый икән ул, зәңгәр күккә карап, — син диңгез булсаң иде, шуннан ап-ак балыклар сикереп төшсен иде дә туп-туры минем авызга кереп китсен иде. Тыпырдап торган балыклар белән тамак туйдыргач, кояшка сыртны куеп, биш-алты сәгать черем итеп алыр идем. Балыклар бик күп коелса, ашаганнан калганын хуҗа бабайга кертеп бирер идем. Ә ул минем юмартлыгымнан күңеле булып, төннәрен мине үз янына яткырыр иде. Юкса артыгын усалланды. «Тычкан тотмыйсың» дип сүгә, «мендәрләрне изеп бетерәсең» дип тирги. Йомшак яраткач нишлим соң инде? Өелеп торган мендәрләр барында ишек төбендәге камыш палас өстендә йоклыйсы килми шул. Тычканнарын әйтер идем: идән астына ояламасалар ярамыйдыр. Йөрсеннәр иде минем кырыйда чабышып, ничек тә берәрсен эләктерер идем».

Акколак, шулай хыялланып ята торгач, йоклап китте. Ә уянып күзләрен ачып караса, келәт кыегында карлыгач оясы күреп алды. «Менә, ичмасам, табыш!» — дип уйлады ул һәм, морҗа артынарак посып, ояны күзәтә башлады. Бер сәгать күзәтте, ике сәгать, әмма ояда җан иясе күренмәде. Артык тырышып караудан Акколакның күзләре әлҗе-мөлҗе килә башлады. «Буш оя гына булды, ахрысы, бу, — дип көрсенеп куйды

ул. — Иң яхшысы, тизрәк төшим дә бабакайның сөтле чәен эчеп меним. Мөгаен, ул чынаягындагы чәен яртылаш эчкән килеш йоклап киткәндер. Бәлки әле, табында кортлы мае да калгандыр. Тиз генә ялтыратып куйыйм да, йөрсен бабакай боларны кайчан ашадым икән соң дип».

Акколак посып яткан җиреннән чыгам гына дип торганда, келәт кыегындагы ояга уктай атылып, Әнкә карлыгач кайтып керде. Әнкәләрен күргә дүрт сары борын өскә сузылды. Алар дүртесе дә авызларын киереп ачканнар һәм: «Миңа, миңа!» — дип, әнкәләренең җименә үреләләр. Әнкә карлыгач алып кайткан җимен бер баласының авызына салды да, якында куркыныч барлыгын күрмичә, яңадан очып китте. «Менә хәзер сыйланырга була, — диде Акколак, телләрен ялмап. — Нинди җайлы урын. Келәт почмагыннан менеп эчкә кулыңны тык та берәм-берәм тартып ал».

Шулай дип уйлады Акколак, ләкин үзе корбаннарына ташланырга ашыкмады. «Әйдә, бераз үссеннәр әле. Болар белән авыз пычратканчы, бабакайның сөтле чәен чөмереп меним, булмаса».

Акколак түбән төшеп китте.

Шушы көннән башлап һәр көнне иртәдән кичкә кадәр морҗа артына посып карлыгачларны күзәтә торган булды. Күзәтә торгач, шактый гына ачышлар да ясады. Әнкә карлыгач һич кенә дә ялгышмыйча балаларының авызына җимне чиратлап сала икән. Акколак шунысын да искәртте: карлыгач балалары бик чиста. Алар хәтта үзләренең оя тирәләрен дә пычратмыйлар. Әнкәләре аларның пычракларын томшыгына эләктереп читкә чыгарып ташлап бара икән.

Озаграк күзәткән саен, Акколакның аларга карата мәхәббәте арта барды. Хәтта ул аларга үзенчә исемнәр дә кушты. Ә карлыгач балалары көннән-көн үстеләр, матурайдылар. Кайвакыт алар, оя читенә басып, канатларын каккалап ала башладылар. Акколак бик-бик ашыйсы килгән чакта да үзен тыеп кала алуына чын-чынлап сөенә иде. Аны бары тик бер генә нәрсә борчыды: менә озакламый карлыгач балаларының канатлары ныгып җитәр, алар үзләренә сокланып яшәгән Акколак барлыгын бөтенләй белмәсләр. Алар очып киткәч, Акколакка бик ямансу калыр.

Әнә шундый уйларга бирелеп ятканда, һавада Әнкә карлыгачның чырылдап кычкырганын ишетеп алды ул. Караса, ни күзләре белән күрсен, Әнкә карлыгачны Карчыга куып килә. Әнкә карлыгач Карчыганы үз оясына якын китермәс өчен чырылдап кычкыра да читкәрәк оча. Ләкин үзе ерак китми. Карчыга аны менә totам, менә тотам дип артыннан ташлана. Алар шулай куышып йөриләр. Акколак Әнкә карлыгачны якларга дип яшеренгән җиреннән атылып чыкты. Аның Карчыгага чиктән тыш ачуы килгән иде.

— Читкә оч, ояңны үзем саклармын, — дип кычкырды ул Карлыгачка. Әллә Акколакның тавышын ишетеп каушаудан, әллә арудан Әнкә карлыгач бер мизгелгә очышын әкренәйтте. Карчыгага шул гына кирәк иде, ул «эһ» дигәнче Әнкә карлыгачны эләктерде, ләкин үзе дә ерак китә алмады: Акколакның тырнакларына килеп капты. Әмма соң иде инде: Әнкә карлыгачның башын явыз Карчыга чукып өлгергән иде. Акколак Карчыганың бу явызлыгын кичерә алмады: сыңар йонын да калдырмыйча аны ашап куйды. Җирдә соңгы сулышын алып ятучы Әнкә карлыгачка карап утырганда, өйдән Акколакның бабакае килеп чыкты.

— Аһ, оятсыз, аһ, җүнсез, — диде ул, Акколакның сыртыннан эләктереп алып. — Мин аны ашатам, эчертәм. Җылы өемдә йоклатам, ә син менә нишләп йөрисең икән.

Бабай Акколакның сыртын каезларга тотынды.

— Мин түгел, бабакай, — диде Акколак. — Карлыгачны Карчыга эләктерде. Мин Карлыгачны якларга ташландым. Тик өлгерә алмадым.

— Комсызлыгың гына җитмәгән, әле алдашасың дамыни? — дип, бабай Акколакны тагын да ныграк - кыйнарга тотынды, һәм зинданга ябып куйды. Зиндан эче караңгы һәм салкын иде. Акколак бабакаена дөреслекне аңлата алмавына бик үртәлде. Барыннан да бигрәк ул әнкәсез калган карлыгач балалары өчен борчылды: «Ачка үләрләр инде, мескенкәйләр. Шундый матур булып үсеп киләләр иде. Кем ашатыр, кем карар инде аларны? Их, моннан чыгып булса, ничек тә бер җаен табар идем».

Шулай уйланып ятканда, Акколак зиндан почмагында бер кыштырдау ишетте. «Тычкан!» — дигән уй үтте аның башыннан һәм ул сагаеп калды. Озакламый тычкан үзе дә күренде. Акколак яшен тизлеге белән аңа ташланды, һәм бер сикерүдә корбанын эләктереп тә алды.

— Җибәр мине, зинһар, — диде Тычкан, — ни кушсаң — шуны үтәрмен.

— Алдамассыңмы? — диде Акколак.

— Валлаһи, билләһи алдамыйм. Әгәр алдасам, баскан урынымда җир йотсын.

— Тыңла алайса, — диде Акколак, — менә бу зиндан кырыенда агач келәт бар. Шул келәтнең кыегында карлыгач оясы күрерсең. Ояда дүрт бала булыр. Аларның әнкәләрен Карчыга ботарлады. Хәзер ул балалар ач утыра. Син шуларны ашат.

— Нәрсә ашатыйм соң мин аларга? — диде Тычкан. — Үзем дә ач бит мин.

— Үзең ачмы, тукмы, анысын белмим. Әмма әйткәнне тыңламасаң, гомерем белән саубуллаштым дип уйла. Ә теләгәндә ашатыр нәрсә җитәрлек: җир тулы суалчан, корт. Шуларны җыеп ашат. Кара аны: әгәр качарга уйласаң, җир тишегеннән булса да эзләп табармын.

Тычкан үзе генә белә торган җир асты юлыннан тышка чыгып китте. Ул кич соң гына арып-талып кайтып керде.

— Ай-һай аппетитлары шәп икән, һич ташып өлгертмәле түгел, — дип зарланып алды ул һәм, песинең йомшак койрыгына башын салып, гырлап йоклап китте.

Бу эш атна буе дәвам итте. Карлыгач балаларының канатлары тәмам ныгыды.

Бабай, Акколакны зинданга япканын хәтерләп, йозакны ачып җибәрде.

— Чык, — диде ул Акколакка, — хәзер сине хөкемгә тартабыз. Мондый явызлык җәзасыз калырга тиеш түгел.

Ул Акколакны казыйга алып китте.

— Моңа нинди җәза бирәбез, хәзрәти казый? — диде карт һәм Акколакның гаебен сөйләп бирде.

— Минем китабымда үлемгә — үлем диелгән, — диде казый. — Ташлар белән атып үтерергә кирәк үзен. Башкаларга сабак булсын. Ул бит бер ана карлыгачны тотып ашап, аның сабыйларын да үлемгә дучар иткән. Моңа икеләтә, өчләтә үлем фарыз.

Акколак үзен яклап нидер әйтергә теләгән иде, тик аның сүзен тыңлаучы булмады. Аны урамга алып чыгып киттеләр. Анда казыйның хезмәтчеләре кулларына ташлар тотып хөкем карарын үтәргә әзер торалар иде. Акколакны урамга алып чыгуга, дөбер-дөбер барабаннар кагарга тотындылар. Акколак өстенә ташлар яудырырга дип кенә торганда, мышкылдый-мышкылдый Тычкан килеп җитте.

— Тимәгез Акколакка. Ул үтерүче түгел, ул карлыгачларны үлемнән коткаручы, — диде, сүзләрен көчкә-көчкә әйтеп.

— Син аны каян беләсең? — диде казый.

Тычкан шунда һәммәсен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

— Минем сүзләремә ышанмасагыз, әнә күккә карагыз.

Җыелган халык күккә күтәрелеп карады. Анда дүрт карлыгач сызгыра-сызгыра, һавада төрле-төрле элмәкләр ясап очып йөри иде. Боларның матур очышларын күреп, барчасының йөзләрендә елмаю балкыды. Шунда Акколакның бабакае үзенең яраткан песиен күтәреп алды да:

— Гафу ит мине, карт юләрне, — диде. — Мин синең алда зур гөнаһлы. Чөнки ышанмау — үтерү кебек үк зур гөнаһ. Ышанмавым аркасында сине чак кына һәлак итмәдем бит.

— Ярар инде, — диде Акколак, — үткәннәрне искә алмыйк. Әйдә, өйгә кайтыйк.

Карт бер кулына Тычканны, икенче кулына Акколакны җитәкләп, өенә кайтып китте. Аларны матур очышлары белән һәркемне сокландыручы карлыгачлар озатып калды.

— Без тиздән җылы якларга китәбез, хушыгыз, — диделәр алар. — Без яңадан килгәнче исән-сау яшәгез.

— Сез дә исән-сау әйләнеп кайтыгыз, — дип калды аларга Карт, Акколак һәм Тычкан

## САЛПЫКИКРИК ҺӘМ ВЕЛОСИПЕД

Кечкенә генә бер авылда, ишегалдының уң ягында, агач келәттә, туеп сыйга-нигъмәткә яшәгән, ди, бер Тавыкбикә белән Кызылкикрик әтәч. Булган, ди, аларның сигез кызлары һәм игез уллары. Кызлары әдәпле һәм бик күркәм гадәтле икән. Иртән торуга, әткәләре «кикрикүк» дип кычкыруга, кунакчадан сикереп төшеп, җим эзләргә йөгерәләр, ди. Ә малайларын уятыр өчен әтәч абзыйның кычкыра-кычкыра тамаклары бетә, ярты көн үтә, ди. Торгач та киерелеп-сузылып, тирес өстендә кызынып тик яталар икән малайлар. Хәер, алар тик кенә ятмаганнар: талашканнар, сугышканнар, кикрикләрен йолкышканнар. Бигрәк тә Салпыкикрик усал булган. Ул үз туганы Шомакикрикне гел җәберләгән, аңа гел усаллык кылган. Башка кешеләрнең ишегалларына керсә дә сугышып кайткан, кайчан карама авыз-борынын канаткан. Сугыша-сугыша каурыйлары коелып беткән, кикрикләре салынып төшкән. Андый чакта: «Бүтән алай булмам», — дип, ул чын-чынлап тәүбә иткән, ләкин иртән тәүбә итсә, оныта торган булган кичтән. Әткәсе белән әнкәсе бик кайгырышкан бу хәлгә, безнең Салпыкикриктән чыкмас дигән рәтле бәндә. Салам белән суктырып та, өч көн рәттән ач калдырып та рәтләнмәгәч, кул селтәгән моңа бар да. Өйгә кайт та димәгәннәр, йокларга ят та димәгәннәр. Канга батып керсә дә күрмәгәннәр. Алай ит тә, болай ит дип торучы булмагач, Салпыкикрик башта бик шатланган. Әле кыланып чүплек башына менгән, әле койма башына атланган. Ләкин ялгыз уйнау тиз туйдырган. Ә туганнарыннан гафу үтенү аңа түбәнлек тоелган. «Их, — дигән ул, —

чыгып китсәң иде ерак-ерак, калсыннар иде бөтенесе елап-елап. Әмма кая китәргә дә, ничек кызык итәргә соң?»

Шулай уйлап йөри торгач, ишегалды уртасында күреп алган бер велосипед. Шуңарга тиз генә менеп атланган. Чыгып кына китим дисә, койрыгы чылбырга эләгеп капланган. Тик сер бирмәгән Салпыкикрик, тагын атланган сикереп һәм олы юлга чыккан да очкан гына. Иң усал этләр дә күрми калган. Күз ачып йомган арада, ул әллә никадәр юл алган. Юллар да бик такыр, әйбәт икән. Бара-бара Салпыкикрик урманга килеп җиткән. Карурманда төрле-төрле кошлар җырлый, һәр яфрак көй чыгара, агачлар матур итеп шаулый икән. Җырлап торган карурманны күргәч, Салпыкикрикнең дә җырлыйсы килеп киткән. Һәм ул, күңеле күтәрелеп, болай дип җырлап җибәргән:

Быж-быж итеп барамын,
Юллар бетсә, саламын.
Усал җилләр каршы килсә,
Башын бәреп ярамын.

Кемнәр тели — утыртам,
Утыртам да сыпыртам.
Курыкмыймын текә үрдән,
Курыкмыймын чокырдан.

Салпыкикрикнең җырлап килгәнен ишеткәч, елый-елый бер аю баласы урман арасыннан килеп чыккан.

— Нигә елыйсың? — дип сораган аннан Салпыкикрик.

— Адаштым! — дип үксегән аю баласы. — Без монда җәйге лагерьда ята идек.

— Ә-ә, — дигән әтәч малае Салпыкикрик, — димәк, син аюлар яслесеннән. Ишеткәнем бар иде шул, аю балаларына карурманда ясле ачканнар дип. Ә син бер дә кайгырма, Караборын, мин барында югалмассың. Менеп утыр да артыма, гел карап бар алдыңа. Сөртеп бетер яшьләреңне, табарбыз ишләреңне.

Быж-быж итеп киткәннәр, бер саплам җир үткәннәр. Тиз арада яслегә килеп тә җиткәннәр. Иптәшләрен табып китергән өчен андагы аю балалары Салпыкикриккә хор белән:

— Рәхмәт сиңа, Салпыкикрик. Мең-мең рәхмәт, — дигәннәр.

Салпыкикрик бик куанган. Үзенә дә бик рәхәт булып киткән. Чөнки әле үз гомерендә аның беренче рәхмәт ишетүе икән. Карыны ачуын да онытып, ул тагын юлга чыккан һәм җырлап дәвам иткән:

Кемнәр тели — утыртам,
Утыртам да сыпыртам...

Салпыкикрикнең җырын ишетеп, карт керпе кул күтәргән:

— Һе-һе-һей, — дигән ул. — Утырт әле мине.

— Керпе бабай, кая барасың? — дигән Салпыкикрик.

— Менә оныгымның оныгы туган. Шуларга бәби ашы илтә идем, юлга чыккач кына сыңар тәпием атламас булды.

— Кайгырма, Керпе бабай, артыма утыр давай. Быж-быж иттерермен, хәзер илтеп җиткерермен.

Велосипедның артына менеп утырган да карт Керпе, киткәннәр тагын алга карап. Алар белән исәнләшеп калган бөтен юкә, нарат. Карт Керпенең авырткан аягы язылырга өлгергәнче килеп тә җиткәннәр оныгының оныгына. Туры килгәннәр болар мәҗлеснең иң кызган чагына. Карт Керпене утырткannar түр башына, ә Салпыкикрикне аның каршына. Бик зур хөрмәт күрсәткәннәр, ашатканнар-эчерткәннәр һәм мең рәхмәтләр әйтеп үз юлына озатканнар. Рәхмәт ишетеп, Салпыкикрик бик сөенгән, ничек чыгып киткәнен дә сизми калган Керпе өеннән. Юлга чыккач, тагын җырын башлаган ул:

Кемнәр тели — утыртам,
Утыртам да сыпыртам...

Шуны гына көткәндәй, бер Ана бүре юлга йөгереп чыккан.

— Кызамык белән ята ике балам, докторга барам. Утыртасыңмы, Салпыкикрик?

— Кайгырма син, Ана бүре, докторны алып килермен бире.

Шулай дигән дә очкан гына. Тәгәрмәче тигән җиргә тигән, тимәгән җиргә юк. «Эһ» дигәнче докторның иң шәбен бүре өенә китереп тә куйган. Ана бүренең хәтере чуалган вакыт булганга, рәхмәт әйтергә дә оныткан, тик барыбер Салпыкикриккә рәхәт булып киткән. Хәзер инде башкаларның сөенече аны сөендергән. Әнә шулай күп йөргән ул: берәүләрне алып кайткан, икенчеләрен илткән. Йөри торгач, үзенең дә өенә кайтыр вакыты җиткән. Ләкин кайтыр юлга борылгач кына тәгәрмәче шартлаган. «Инде нәрсә

эшләргә соң? Хуҗа малай мәктәптән кайтканчы, велосипедны ишегалдына куярга кирәк бит», — дип уйлаган Салпыкикрик. Күзеннән яшьләрен сөртеп, күтәрелеп караса, каршысында бөтен кош-кортларны һәм киекләрне күреп исе киткән. Кемдер нарат сагызы китергән, кемдер тәгәрмәчне салдырган. Берәүләре ямаган, икенчеләре тын тутырган, ә өченчеләре тотып торган. Салпыкикрикнең бу яхшылыкка бик күңеле булган, тамагы да туеп киткәндәй тоелган. «Рәхмәт сезгә», — дигән ул яңа дусларына, берәм-берәм алып кочагына.

— Үзеңә рәхмәт, — дигәннәр җәнлекләр. Бөтенесе бертавыштан әйткәнлектән, аларның авазы кара урманнан яңгырап кире кайткан һәм Салпыкикриккә бик озак ишетелеп торган. Ул җырлый җырлый өенә кайтып киткән:

Һәрбер телдә Рәхмәт икән,
Рәхмәт ишетү рәхәт икән,
Тра-ля-лям, тра-ля-лям.
Тиргәлүләр газап икән,
Әйбәт булу гаҗәп икән,
Тра-ля-лям, тра-ля-лям.

## ИКЕ ЧӘЧӘК

Борын-борын заманнарда түгел, менә хәзерге көннәрдә — урамнарда машиналар, күктә самолетлар гөрләп торган заманнарда, урмандагы якты бер аланда таң нурларыннан алсулык алып, җәйнең хозурлыгыннан матурлык табып, үсеп утыра икән ике чәчәк. Алар дөньяга килгән беренче көннән үк елмайган йөздәй якты кояшка, ана кулы кебек йомшак җилләргә, шатлыктан чыккан күз яшьләре кебек чык тамчыларына гашыйк икән.

— Кара әле, сеңлем, — дигән көннәрдән бер көнне өлкәнрәк чәчәк, — дөнья нинди матур! Бөтен җирдән матурлык, яхшылык бөркелеп тора. Без рәхәтләнеп үссен өчен җир-әнкәбез тамырларыбызны салкынча дым белән туендыра, җилләр тирбәтеп сабакларыбызны ныгыта, таңнар йөзләребезгә алсулыгын яга, кошлар сайрап, күңелләребезгә моң сала, аҗаганнар уйнап, хисләребезне кузгата.

— Әйе, — дип килешкән аның белән сеңлесе. — Бу җирдә бары тик яхшылык кына яшидер. Шушы матур дөньяда мәңге яшисе иде.

Шул вакыт чәчәкләр үсеп утыра торган бу аланга бер бүре килеп чыккан. Ул, чәчәкләрнең сүзләрен ишеткән дә, тешләрен ыржайтып, сырт йоннарын тырпайтып көләргә тотынган. Аның иләмсез ачы тавыш белән көлүеннән җиргә шыбыр-шыбыр агач яфраклары коелган, ояларыннан кошлар чыгып качкан. Көлеп арыгач, ул, чәчәкләр каршысына килеп, болай дигән:

— Их сез, акыл чишмәсеннән авыз итмәгән исәрләр! Дөнья яхшылыктан тора, имеш. Баш очыңда дөрләп янып утырган менә бу кояш ул сезне җылытып үстерер өчен түгел, ә көйдереп үтерер өчен. Җилләр сезнең сабакларыгыз ныгысын өчен исмиләр, ә сез аяктан егылсын дип исәләр. Ә яшеннәр, аҗаганнар болар орлыкланырга өлгергәнче җаннарын үтереп калыйк дип тырышалар. Башлары болытка тигән менә бу агачлар да бервакыт ава. Чишмәләр кибә, күкрәгенә кояшны яшерүче таулар уала. Ә сезгә — хәчтерүшләргә — җәйнең бер кыравы җитә. Дөньяда мәңгелек бернәрсә дә юк. Шуны онытмагыз.

Шулай дигән дә бүре китеп барган. Чәчәкле алан өстеннән болытлар аккан. Бүренең сүзләреннән соң моңсуланып калган чәчәкләр әкренләп сагышларын оныта башлаганнар. Тик шул вакыт ешкынлыкта яшеренеп яткан җил күлмәк изүләрен ерта-ерта агачлар арасыннан килеп чыккан да, бар нәрсәне дер селкетеп, урман аланнарын урап йөрергә тотынган. Ул коточкыч зур авызын һава шарыдай итеп кабартып, әле агачларга өргән, әле мендәр мамыгын очыргандай итеп кош ояларын очырган. Аның шаукымы йөз яшьлек имәннәргә дә, йөз көнлек үләннәргә дә тигән. Әлеге аланда үсеп утырган ике чәчәк басып тора алмыйча җиргә ауганнар.

— Апам! — дигән кечкенә Чәчәк. — Әллә бүренең сүзе дөрес микән? Бу егылудан без инде яңадан аякка баса алмабыз. Минем буыннарым калтырый. Көчем кимегәннән кими бара. Ни өчен җил безне бу кадәрле җәберли икән?

— Юк, сеңлем, җил безне җәберләми, сыный гына. Менә күрерсең, элеккедән дә матуррак булып кояш чыгар. Кошлар ояларына кайтырлар. Без яңадан торып басарбыз.

Өлкән чәчәкнең сүзләре дөрескә чыккан. Җил дулаган-дулаган да, нәп-нәзек чәчәкләрне дә йолкып ата алмавына гарьләнеп, кире үзенең ешкынлыктагы оясына кереп качкан. Чәчәкләр кояш нурларына тотынып, әкрен генә аякларына басканнар.

— Апам, — дигән сөенеченнән күзләре яшьләнгән Сеңел чәчәк, — тирә-юнь тагын да матурайган, әйеме?

— Әйе, сеңлем. Әнә аяк очынарак басып кара әле: ике тауны салават күпере тоташтырган, күктә зәңгәрлек арткан, җирдә ямь күбәйгән.

— Бүренең сүзләре дөрес түгел, дөрес түгел, — дип кулларын чәбәкләргә тотынган Сеңел чәчәк. Без мәңгелек, без үлмибез. Дөнья яхшылыктан яратылган.

— Анисы шулай, — дигән Чәчәк. — Тик без әле сынауларның берсен генә үттек. Бүренең сүзләрендә хаклык бөтенләй юк түгел. Алдагы сынауларга да әзер торыйк.

Сеңел чәчәк апасының сүзләренә әллә ни игътибар итмәгән. Ул, җилнең шаян малайлары килеп кагылуга, кет-кет көлгән, аккан болытларга кул болгаган. Сандугачлар сайрап җибәрсә, тын калып тыңлаган, һәр көн аңа яңа сөенечләр китергән. Ул инде башларыннан кичкән авыр сынау турында да онытыкан.

Әмма көннәрнең берендә чәчәкләр йокыларыннан калтыранып уянганнар. Ямь-яшел яфраклар һәм чуп-чуар болыннар өстенә ниндидер аклык төшкән.

— Апам, — дигән Сеңел чәчәк, дер-дер калтырап. — Бу дөнья нишләп болай суынган? Мин туңам. Керфекләремне күтәрерлек, күзләремне ачарлык хәлем калмады.

— Миңа сыенарак төш, — дигән Өлкән чәчәк. Ул үзе дә бик өшегән. Калтыравын чак-чак тыеп утыра икән. Сеңлесе килеп сыенгач кына бераз хәл кергәндәй булган, — һәрвакыт бер-беребезгә якынрак утырырга тырышыйк, — дигән ул сеңлесенә, — шул вакытта, бәлки, исән калырбыз.

— Минем үләсем килми, — дигән Сеңел чәчәк, сулышын көчкә алып. — Нигә соң безгә болай сынау арты сынау килә?

— Күрәсең, мәңгелеккә юл җиңел түгелдер, — дигән өлкән чәчәк. — Беренче җилдән үк егылганнар, беренче кыраудан ук сулганнар тиз онытылалар. Озак яшисең килсә — түз.

— Безнең өстебезгә төшкән бу аклык эрер микән?

— Эрер. Әнә күрәсеңме, тау артыннан кызарып кояш чыга. Кояшның җитез нурлары безнең өстебезгә капланган ак пәрдәне җыеп алырлар. Без яңадан җылынырбыз.

Чәчәкләр салкынлыкка чыдый алмыйча җиргә бөгелеп төшәм-төшәм дип торганда, тау артыннан кояш күтәрелгән. Күтәрелгән дә далага җылы, рәхәт сулышын өргән. Аның сулышыннан бар нәрсә җанланып киткән: күбәләкләр, бал кортлары оча башлаган. Агачлар иңнәреннән бөтен салкынлыкны кагып төшергәннәр, гөлләр турайган.

Әлеге чәчәкләр дә исән калуларына сөенеп көлеп җибәргәннәр. Тагын көн артыннан көн агылган. Боларның йөзләренә таңнарның матурлыгы һаман саен ныграк ягылган. Җәй үзенең төсен, йолдызлар бөтен чибәрлекләрен, көннәр үзләренең назларын чәчәкләргә биреп калдырырга тырышканнар.

Менә бервакыт биектән торналар очып үткән. «Көз килә, салкыннар җитә», — дип хәбәр иткәннәр алар.

— Нәрсә ул көз? — дигән Сеңел чәчәк.

— Көзме? — дигән Өлкән чәчәк. — Көз ул — безнең гомеребезнең азагы.

— Юк, юк! — дигән Сеңел чәчәк. — Минем яшисем килә. Әнә кара: минем әле бер генә керфегем дә саргаймаган, бер генә яфрагым да шиңмәгән. Мин генә түгел, син дә яшь-яшь, матур. Без үләргә тиеш түгел. Без яшәргә тиеш, мәңге-мәңге яшәргә тиеш.

Әйе, чәчәкләрнең бик-бик яшиселәре килгән. Ләкин алар мәңге яшәүнең серен белмәгәннәр.

Шул вакыт болар яшәп яткан аланга бер егет белән кыз килеп чыккан. Егетнең күзләрендә кызга нидер әйтергә теләү, ләкин шуны әйтә алмау газабы чагыла икән. Аның гүзәл кыз каршында тел тирбәтерлек хәле юк икән. Урмандагы сандугачлар аңа: «Йә инде, егет, сүз белән әйтә алмасаң, хисләреңне җырлап аңлат, кыз бит синнән беркем әйтмәгән сүз көтә», — дигәннәр. Кыз чынлап та озын керфекләре арасыннан еш-еш күз ташлап нидер көтә икән. Аның йөзендә инде түземсезлек чаткылары күренгәли башлаган. Алсу иреннәре күбәләк кунган гөл төсле дерелдәп куйгалый икән.

Егет көчсезлектән, сүзсезлектән гаҗиз калган. Нинди генә сүз белән әйтсә дә, хисләрен аңлатып бирә алмас, әйтелгән сүз аларны бары тик тоныкландырыр гына кебек тоела икән.

Ул үзендә сандугачлар теле, давыллар кыюлыгы булмавына үкенеп түбән караган һәм шунда бөтен аланны ямьләндереп үсеп утырган теге чәчәкләрне күреп алган. Башта ул аларга сокланып карап торган. Егетнең сокланулы карашыннан чәчәкләр тагын да матураеп киткәннәр. Кызның да күзе чәчәкләргә төшкән.

— Нинди матурлар! — дигән ул, чәчәкләрнең башларыннан сыйпап. — Тик гомерләре генә бетеп килә гүзәлкәйләрнең. Бүген-иртәгә көзнең сарысы аларның йөзләренә ягылыр, бу гүзәлкәйләрнең керфекләре түбән салыныр.

— Юк! — дигән егет, кискен итеп. — Чәчәкләр синең күкрәгеңдә мәңге яшәргә тиеш. Алар минем мәхәббәтем шикелле.

Егеттән күптән көтелгән сүзне ишетүгә һәм күкрәгендә янып торган чәчәк күрүгә, кызның үпкәләүдән кысыла башлаган иреннәрендә елмаю чагылган. Йөзенә чәчәкләрнең матурлыгы йөгергән, күңеленә сандугачлар назы тулган, тамырларына урман шавы кергән. Чәчәкләр исә егет белән кызның йөрәгенә тамыр җәйгәннәр, хисләреннән кайнарлык алганнар һәм мәңге шиңмәс мәхәббәт гөлләренә әверелгәннәр. Аларга хәзер бар нәрсәне көйдерүче кояш та, аждаһа авызлы давыллар да, салкынлыгы белән йөзләргә кара ягучы кыраулар да куркыныч түгел икән. Чөнки мәхәббәт давыллардан көчле, кояштан кайнар, тормышның үзе кебек мәңгелек бит.

## ПЕППИ

Җир шарының үзәгендә, бер елганың үзәнендә булган, ди, бер әрәмәлек. Әрәмәдә зифа буйлы таллар үскән, аланында тәгәрәшеп җиләк пешкән. Болынында бер-берләрен куыша-куыша чәчәкләр йөгерешкән. Җилнең шаян малайлары, тал ботакларын атынгыч итеп, арыганчы тирбәлгәннәр. Кошлар сайраган, әрәмәдә тормыш кайнаган. Йомырка салганнар. Монда чыпчыкка да, песнәккә дә, каргага да, саесканга да урын җитәрлек булган. Илләре иркен булгач, тормышлары гөрләп торгач, кошлар бер-берләре белән тату, дус яшәгәннәр. Саесканнар чит оядан күкәй урламаганнар, тилгәннәр кош балаларын чәлмәгән, каргалар әдәплелек турында китап кына укып ятканнар. Шуңа күрә әрәмәне кошлар, сандугачлар үз иткән. Язын кайтканнар, көзен киткәннәр. Талларда тирбәнгәннәр, сайрарга өйрәнгәннәр. Күпләп бала чыгарганнар. Шатланганнар, куанганнар.

Әмма шушы шат илдә дә тормыш түгәрәк кенә, җаннар күбәләк кенә булмаган. Кемнеңдер оясын җилләр тузгыткан. Кемнәрдер яшенле яңгырга эләгеп һәлак булган. Ә менә Сарытүш исемле сандугач бәхетсезләрнең дә бәхетсезе икән. Чөнки ничә ел рәттән шушы гүзәл әрәмәгә килеп тә бер генә дә бала чыгара алмый икән. Йә йомыркалары чәберчек була, йә оя ясаган әремен җилләр егып китә, йә тагын әллә нинди бәла-казалар килеп, Сарытүшнең оясын туздыра икән. Сарытүш моңа бик-бик кайгырган. Ялгыз башы моңаеп көннәр буе болай дип җырлап утыра икән:

Күзләремдә кайнар яшьләр
Гөлләргә тамып тора.
Эчләремдә сагыш уты
Туктамый янып тора.

Сарытүшнең бу җырын ишеткән кошларның күзләреннән мөлдер-мөлдер яшьләр тәгәрәгән. Барысы да аңа ярдәм итәргә тырышканнар. Юатканнар, күңелендә өмет уятканнар.

Һәм, ниһаять, язларның берсендә Сарытүш оясы төбендә «пип-пи» дигән хәлсез генә тавыш чыгарган. Бу тавышны ишетүгә, Сарытүшнең җанына рәхәтлек йөгергән, ул оясының читенә басып барлык дусларына болай дип белдергән:

— Дусларым, якыннарым! Көмешләрем, алтыннарым. Килегез, шатланыгыз, күрегез — сокланыгыз. Балам туды, өем бәхет белән тулды. Бер булса да бишкә торырлык ул, әрәмәнең күрке булырлык ул. Томшыклары сары балавыздай, ә күзләре аның пар йолдыздай.

Дуслары Сарытүшне котлаганнар, баласын мактаганнар. Кайсылары балага исем сайлаган, кайсылары аның баш астындагы мендәрен җайлаган. Кемдер бәби ашы китергән, кемдер әлли-бәлли иттергән.

Сарытүш үзенең бердәнберенә исем эзләп бик озак баш ваткан, баш вата торгач эзләп тапкан. Исемнең дә тегенди-мондыен гына түгел, беркемдә дә югын. Пеппи дип куйган. Чөнки аның бәбкәсе дөньяга килү белән «пип-пи» дип аваз салган, шул аваз әнкәсенең күңеленә сеңеп калган.

Пеппи ай үсәсен көн үскән. Тәмледән-тәмле ризыклар ашаган, чык сулары гына эчкән. Әнкәсе җимне гел ташып торган. Пеппи авызын гына ачып торган.

Таң артыннан таңнар аткан, җилләр искән, сулар аккан. Пеппи үскән, матурайган, канатлары ныгыган. Ул инде хәзер оя читенә басып талпынып-талпынып куйгалый башлаган. Очарга омтылган. Ә беркөнне Сарытүш кадерле Пеппиенең оя читенә басып очарга маташуын күреп алган, күреп алган да куркудан йөрәге ярыла язган.

— Нишлисең, балакаем? — дигән ул, һушына килгәч.

— Менә, — дигән Пеппи, — чыгып бастым әле. Канатларны тикшереп карыйм, бәлки, очып китәрмен.

— Берүк юләрләнә күрмә, — дигән аңа әнкәсе. — Син әле бик яшь. Канатларың ныгымаган. Егылып төшәрсең.

— Соң бит инде әнә теге оядагы сарыборыннар да минем белән бергә туган булганнар. Алар оча башлаган. Әнкәләренә ияреп азыкка киткәннәрен үзем күреп калдым, — дигән Пеппи.

— Алар очсын, — дигән Сарытүш, — әмма син бу турыда авыз ачасы булма.

— Ни өчен? — дигән берни аңламаган Пеппи.

— Ни өченме? — дигән Сарытүш, — чөнки алар үз көннәрен үзләре күрә башларга тиешләр. Юкса биш баланы бер әниләре ничек туйдырсын?! Алар бит зуррак үскән саен күбрәк ашыйлар.

— Ә мин? — дигән Пеппи.

— Күпме генә ашасаң да мин синең тамагыңны туйдыра алам. Син минем бердәнберем, — дигән Сарытүш үзенең бердәнберенә.

— Ә минем очасым килә, — дигән Пеппи.

— Вакыты җиткәч очарсың, бер дә кайгырма, — дигән аңа әнкәсе. — Аша, эч, канатларыңны ныгыт. Дөнья мәшәкатен күрергә өлгерерсең әле.

Әнкәсенең шушы сүзләреннән соң Пеппи мамык түшәлгән оясына кереп яткан. Әнкәсе һич тә авырсынмыйча аңа җим ташыган. Пеппи егылып имгәнә күрмәсен дип оя тирәсенә үләннәр түшәгән. Ә Пеппи биектә очкан кошларга сокланып оясында утыра биргән. Ул тагын берничә мәртәбә очарга талпынып караган. Күкрәгендә көч, канатларында ныклык сизгән, әмма әнкәсе аңа авыз ачарга да ирек бирмәгән. «Юк, юк, — дигән, — дөньяның кадерен белеп кенә утыр», — дигән.

Тора-бара Пеппи үзе дә бу тормышка бик күнегеп киткән. Кызу кояш астында әлсерәп ашарга эзләп йөрүгә караганда күләгәдә әнкәсе алып кайткан ризыкларны ашап яту җиңелрәк икәненә төшенгән. Кайвакыт җилләр, яңгырлар аркасында әнкәсе тоткарланып, озаграк кайтып җитә алмый торса, Пеппи аны ачуланып каршы алган. Алып кайткан җимнәрен ашамыйча киреләнгән. Мондый чакларда Сарытүш үзен бик-бик гаепле санаган. «Башка вакытта боз яуса да соңармый кайтып җитәргә тырышырмын» дип акланган.

Әнкәсе бик озак ялынгач кына Пеппиның ачуы басыла икән. Ул әнкәсе алып кайткан ризыкларны да: «Синең күңелең булсын өчен генә ашыйм инде», — дигән кебек итеп, сайланып, кыстатып кына ашаган.

Шулай әкрен генә көн артыннан көннәр үткән. Пеппи әнкәсе өйдә юк чакларда оясыннан очып чыккалый башлаган. Гел тәмле ашап-эчеп кенә ятканлыктан, гәүдәсе юан булган аның. Шуңа күрә бик югары оча алмаган. Тиен шикелле бер ботактан икенче ботакка сикергәләп кенә йөргән. Аның бу кыланышыннан чыпчыклар тәгәрәшеп-тәгәрәшеп көләләр икән. Пеппиның чыпчыкларга бик нык хәтере калган.

— Әй сез, тинтәкләр, — дигән ул чыпчыкларга. — Миннән көлгән буласыз. Ә менә үзегез минем кебек итеп җырлый да алмыйсыздыр әле.

— Нишләп җырлый алмыйк без, — дигәннәр чыпчыклар. — Менә тыңлап кара:

Чырык-чырык, чык-чык,
Чырык-чырык, чык-чык.

— Һәй, шушы да булдымы җыр! — дигән Пеппи. — Сез хәзер менә мине тыңлагыз. Шул чакта үзегезнең җырыгыз өчен оялырсыз.

Шулай дигән дә Пеппи әнкәсе төсле моңлы итеп җыр сузып җибәрмәкче булган. Тик ни хикмәттер, аның җыры бер дә әнкәсе җырлый торган җырга охшамаган. Күпме генә тырышмасын, «пип-пи», «пип-пи» диюдән уза алмаган. Тавышы тонык, җыры моңсыз булган аның. Пеппи тамагын да кыргалап караган, агачларның биегрәгенә дә менеп караган, әмма җыр, бугазга утырган таш кебек, тышка чыгарга ашыкмаган. Пеппи үзенең җырлый алмавына, чыпчыклар алдында хурлыкка калуына бик каты гарьләнгән. Хәтта күзләреннән яшьләр атылып чыккан.

— Мактанчык, мактанчык, — дип көлгәннәр аннан чыпчыклар. Шул арада болай дип такмак та чыгарып өлгергәннәр:

Чырык-чырык, чып-чырыйк,
Пеппинең үз җыры юк,
Тавышын йоткан җим белән,
Күзен сөртә җиң белән.

Пеппи елый-елый өенә кайткан. Кайтса, анда аның әнкәсе хафаланып көтеп тора икән. Ул кызы Пеппинең исән-сау икәнлеген күргәч, сөенеченнән нишләргә белмәгән, тизрәк кызны кочагына алырга ашыккан. Аннары Пеппиның керфекләренә эленгән яшьләрен сөртеп болай дигән:

— Бәбкәм, кайда йөрдең? Нишләп болай күзләрең чыланды? Кем рәнҗетте?

Пеппи озак кына әнкәсе кочагында үксеп утырганнан соң:

— Мин чыпчыклар алдында көлкегә калдым, җырлый белмим икән бит мин, — дигән.

— Ала-ай! — дигән әнкәсе, уйга калып. — Нишләп җырлый белмисең икән соң син? Безнең бит бөтен нәсел-нәсәбебез җырчы булган. Бәлки, әле тавышың ачылып җитмәгәндер. Көтик бераз.

Һәм Сарытүш кадерле кызы Пеппиның тавышы ачылганын яшерен өмет белән көтә башлаган. Үзе, Пеппи сагышка бирелеп күңелсезләнмәсен өчен аны тагын да ныграк сыйлаган, кадерләгән. Пеппиның мамыклары-йоннары ялтырап торсын өчен томшыгы белән аның каурыйларын чистарткан, яңгыр суларында коендырган. Пеппи чынлап та бик чибәр булып үскән. Агач ботагына кунып кичке шәфәкъ нурларында коенып утыруын күргән чыпчык егетләре күзен ала алмыйлар икән. Пеппи үзенең матурлыгы белән кәпрәергә, мактанырга яраткан. Үзен күрсеннәр, сокландсыннар өчен агачларның иң-иң биегенә менеп утыра торган булган. Әмма ничек кенә матур булмасын, үзенең башка сандугачлар кебек, урмандагы барлык җан ияләрен таң калдырырлык итеп җырлый алмавына күңелендә аның бер кимсенү йөргән. Башка кошлардан качып, урман ешлыкларында көннәр буе тамагы карлыкканчы җырлар өйрәнергә маташып караган. Тырышып-тырышып та берни барып чыкмагач, әнкәсе аңа:

— Ярар, кызым, хафаланма, — дигән. — Син үзеңнең җырлый белмәгәнеңне очраган бер җан иясенә сөйләп йөрмә. Әнә, күрәсеңме, агач ботагы саен никадәр сандугач сайрап утыра. Син шулар янына бас та алар авызларын ачканда, авызыңны ач, япканда — яп. Күп тавыш арасында синең җырлаганыңны-җырламаганыңны һичкем белмәячәк.

Әнкәсенең бу хәйләсен Пеппи оста файдаланган. Тора-бара аның җырлый белмәвен кошлар оныта башлаган. Кайвакыт Пеппиның ялгызын гына очраткан чыпчык егетләре: «Бер җырла әле, чибәркәй», — дип ялваралар икән. Ләкин хәйләкәр Пеппи андый вакытларда: «Беркем җырламаганда мин берүзем җырлап утырсам, мине үзегез үк юләргә санар идегез бит», — дип котыла икән.

Менә шулай гомер елгасы әкрен генә аккан. Көзләр якынлашкан. Сандугачлар, төркемнәргә тупланып, җылы якларга китәргә әзерләнгәннәр. Тик Пеппи гына алар төркеменә кушылмаган. Ул күбрәк чыпчык егетләре белән чытлыкланган. Бер карауда теләсә кайсы чыпчык егетенең йөрәгенә ут сала, гыйшык кабыза алуына ул бик канәгать икән. Чыпчык егетләре белән мавыгып йөри торгач, Пеппи бүтән сандугачларның җылы якка китүләрен сизми дә калган. Китәр алдыннан аны әнкәсе бик озак эзләгән, бердәнберем харап була бит инде дип кайгырган. Төрле якларга хәбәр таратып караган. Әмма Пеппи кайтмаган, күренмәгән. Сарытүш: «Кызым берәр ерткычның тырнагына эләгеп һәлак булгандыр инде, күрәсең», — дип, өч көн елап утырган да дүртенче көнне соңгы төркем сандугачларга ияреп җылы якка очкан.

Әнкәсе очып китүгә, ачыгып, талчыгып Пеппи кайтып кергән.

— Әнкәй! — дип аваз салган ул дөньяга. — Син кайда? Минем ашыйсым килә! Ишетәсеңме, минем ашыйсым килә!

Пеппи күпме генә көтсә дә, әнкәсе кайтмаган. Пеппиның бу хәлгә бик ачуы килгән. Әнкәсе күзенә күренүгә, ничек итеп үч алырга төрле явызлыклар уйлаган. Карыны да бик каты ачкан. Азык эзләп чыгып китәр иде, азыкның кайдан табылганын белмәгән. Шул вакыт ул балан куагына кунган бер песнәкне күреп алган. Песнәк ике чукый да бер читкә карый, ике чукый да бер читкә карый икән.

— Әй, песнәк, — дигән аңарга Пеппи, — нишлисең син?

— Балан ашыйм, — дигән песнәк.

— Ә нигә ике чукып бер карыйсың? — дигән Пеппи.

— Карыным бик ачты, — дигән песнәк. — Артык ачыкканда мин ике чукып бер карыйм, тамагым туя башлагач, бер чукыйм да ике карыйм, — дигән.

Пеппи песнәк янына килгән дә балан авыз итеп караган. Әмма балан тәмсез, әче тоелган.

— Ничек ашыйсың син шундый тәмсез нәрсәне? — дигән ул песнәккә.

— Тора-бара әче баланнары да бетәчәк әле, — дигән песнәк.

— Ә мин ачка үлсәм дә моны авызыма алачак түгелмен, — дигән Пеппи. Шулай дигән дә бөтен әрәмә буйлап әнисен эзләргә тотынган. Ләкин җиде чакрымлы әрәмәне җиде тапкыр әйләнсә дә, әнисен тапмаган. Җылы якка ялгыз гына очып китәр иде, юлны белмәгән. Чөнки башка кошлар үз балаларын кояшка, йолдызларга карап юл табарга өйрәткәндә, Пеппи мамык түшәлгән ояда кырын ятып ял иткән. Ә көннәр салкынайганнан салкыная барган. Пеппи хәзер әче балан, миләшләрне дә яратып ашый башлаган, ләкин алар да гел табылып тормаган. Пеппи өзелеп-өзелеп әнкәсен сагынган. Ә беркөнне ул салкын яңгыр астында шәбәреп озак-озак азык эзләп, бер валчык та таба алмагач, җан ачысы белән болай дип җырлап җибәргән:

Кая барып сыеныйм,
Ниләр ашап туеныйм?
Әнкәм килер якка карап,
Талды инде муеным.

Ни гаҗәптер, шушы минутта Пеппи үзенең күңелендә моң ярала башлавын тойган. Ул әллә ялгышаммы дип тагын җырлап караган.

Авыр минем хәлләрем,
Өши минем тәннәрем.
Бер кечкенә бәхетне дә,
Язмыш, нигә җәлләдең?

Әйе, чынлап та Пеппиның җыры җырга охшый башлаган. Хәтта аны кызганудан чыпчыклар елашып алганнар. Шунда берсе Пеппи янына килеп болай дигән:

— Ул кадәрле кайгырма әле, Пеппи дускай. Без менә җылы якларга китмибез бит. Әмма аңа карап ачка да үлмибез, салкынга да кырылып бетмибез. Дөрес, синең янында әниең юк, туганнарың юк, ләкин син бөтенләй ятим түгел. Синең туган илең бар. Дус кирәк булса, менә без бар.

Чыпчыкның бу сүзләреннән соң Пеппи җылынып киткәндәй булган.

— Исемең ничек синең, әйбәт кош? — дигән ул.

— Исемем минем Уткүз, — дигән чыпчык. — Әйдә, дус булыйк. Бергә-бергә яшәрбез. Мин сине кайдан азык табарга өйрәтермен. Бергә-бергә яшәгәндә, суыклар да куркыныч түгел. Минем өем бит ышык түбә астында.

Пеппи Уткүзгә ияреп киткән. Уткүзнең өе чынлап та бик әйбәт икән. Алар иртәдән кичкә кадәр бергәләп азык эзләгәннәр, төннәрен бер-берләренә арка терәп йоклаганнар. Салкыннар аларны куркытмаган. Үз өең, якын дустың булуның никадәр әйбәт икәнлеген Пеппи шунда аңлаган.

Менә шулай бәхетле генә яшәп ятканда, кояш нурлары дөньяны көннән-көн ныграк яктыртканда, кышның буе биш-алты колач кына калып барганда, Уткүз белән Пеппи өй түбәсенә менеп уйный, шаяра башлаганнар. Берсе качкан, икенчесе гөрләгән, берсе югалган, икенчесе эзләгән. Боларның дөнья бетереп уйнап йөргәннәрен бер мәче күреп алган да почмак буйлап үрмәләп түбәгә менгән, аннары, морҗа артына посып, күзәтеп утыра башлаган. Менә бермәлне Пеппи гөрләп калган, Уткүз морҗа артына качмакчы булган, һәм, явыз мәче тырнагына килеп капкан. Пеппи аның җан ачысы белән чырылдап кычкыруын гына ишетеп калган.

Пеппи якын дустын югалтуны бик-бик авыр кичергән. Күңеленнән кайнар чишмә булып моң агылган. Пеппи, күзеннән агып чыккан яшьләрен дә тыймыйча, эчтән ургылган моң чишмәсенә ирек куйган. Пеппиның җырын ишеткән барлык җан ияләре таң калган. Очар кошлар очуыннан, агар болытлар агуыннан, исәр җилләр исүеннән туктап, аны тыңлаган. Пеппиның җырыннан хәтта кыш буе йоклаган агачлар уянганнар, җиргә җәелеп яткан кар да, яз җиткән икән бит, озак йоклаганмын дип сикереп торган. Гөрләвекләр балакларын сызганып елгага, елгалар кием-салымнарын яр читләренә ыргыта-ыргыта диңгезгә йөгергән. Бөтен дөнья хәрәкәткә килгән. Җылы якка киткән кошлар урап кайткан. Ә Пеппи җырлаган да җырлаган. Аның даны бөтен дөньяга таралган. Пеппиның җырын бер генә мәртәбә булса да ишетергә теләп әллә кайлардан сандугачлар килгән. Күпләр аның төсле итеп җырларга тырышып караган. Пеппиның җырын тыңларга килгән кошлар арасында Сарытүш тә бар икән. Ул озак кына итеп Пеппига карап торган. Шунда алар бер-берләрен танып алганнар. Пеппи да, аның әнкәсе Сарытүш тә сөенечләрен күкрәкләренә генә сыйдыра алмаганнар, парлашып шатлык җыры сузып җибәргәннәр. Аларның җырына башкалар да кушылган. Дөнья шатлык җырына, бәхет җырына күмелгән.

Шушы көннән алып Пеппи шатлык җырын да, кайгы җырын да иң оста башкаручы булып танылган.

Ул әрәмәдә мин дә булдым. Җиләк җыярга дигән тубалыма җыр тутырып кайттым. Җыр кирәк кешеләр миңа килсен! Тубалдагы җырларымны тыңлатырмын. Кирәк икән көлдерермен, кирәк икән елатырмын.

## КАРА БӘХЕТ

Бик тә биек тауның башында, кояшның нәкъ каршында, кыяның иң зур ташында утыра, ди, бер карт. Картның алдында олы капчык, ди, капчыгының авызы шып-шыр ачык, ди. Ә карт үзе авызын бер ачып та бер каплап әйтеп утыра, ди, мондый такмак:

Җир йөзендә күп яшәдем,
Уйламадым үләремне.
Капчыгыма сала бардым
Иң бәхетле көннәремне.
Хәзер менә өләшәмен
Шул көннәрне уңга-сулга.
Кемгә кирәк минем бәхет,

Менегез, мен, менә монда.

Картның такмагын ишетеп, агыла башлаган кешеләр тауга, менәләр, ди, кайберәүләр атланып таякка, кайберәүләр тотынып бауга. Ләкин тау бик-бик текә, ди, аяклар таеп китә, ди, йөзләр тырналып бетә, ди. Шулай да һәркем менә, ди, кем көндез, кемнәр төнлә, ди, чөнки бәхетне һәркемнең алып каласы килә, ди.

Карт утырган тау башына олысы һәм кечесе агылган. Кем менсә дә капчык төбеннән берәр бәхет табылган. Менә шулай, эчендәге байлыкны һәркемгә өләшә торгач, картның капчыгы бушап калган, ул бер ай ашамаган бүренең корсагына охшап калган. Китәргә дип торганда гына карт үзенә таба үрмәләп менүче бер егетне күреп алган, күреп алган да кузгалмыйча туктап калган.

Егет яшь тә түгел, карт та түгел, боек та түгел, шат та түгел, биек тә түгел, тәбәнәк тә түгел, чирле дә түгел, сәламәт тә түгел икән. Менә егет карт янына менеп җиткән, сәлам биргән, билен бөккән. Карт аның сәламен алган, түш кесәсенә салган һәм болай дип эндәшкән:

— Әй, егеткәй, исемең ничек? Нәрсә кирәк? Әйт син тизрәк. Юкса минем соңгы юлга китеп барыш. Күрәсеңме, ике тауның арасында минем юлым тик бер карыш.

— Исемем минем бик-бик гади, — дигән егет. — Биктимер мин. Ә һөнәрем — иген игү. Шуның белән көн күрәмен күп гомер мин. Ләкин бәхет никтер мине үтә читләп, әгәр шуны эләктерсәм, тотар идем өйдә бикләп. Калыр идем иң бәхетле бер көнемдә, йөзәр идем гомер буе шул бәхетнең диңгезендә.

— Ала-ай, — дигән моңарга карт, тирән сулап. — Кара аны, егеткәем, эшлә уйлап. Үкенмәссең микән соңрак бу эшеңә? Яшәр өчен бәхет кенә җитми кешегә.

— И-и, бабакай, — дигән егет, сүзен өзеп, — бәхет булгач башка нәрсә кирәк тагын. Булдыралсаң ярдәм ит син, бабакаем. Яшимче бер рәхәтләнеп эчеп балын, ашап маен.

— Ярар, — дигән карт шул вакыт, — теләгәндә вакытны була туктатып. Менә сиңа бер чикләвек, тик югалтма. Иң бәхетле көнеңдә син шуны аша, ләкин ватма, йоткан чакта су да капма. Шулай итсәң, синең өчен вакыт туктар, ә бәхетең куеныңа кереп йоклар. Калырсың син иң бәхетле шул көнеңдә, ни буласын белмим калган гомереңдә.

Шулай диеп әйткән дә карт чикләвеген егетнең учына салган. Шул арада үзен аның ай күргән дә кояш алган. Егет калган шунда басып авызын ачып. Тау өстеннән җилләр искән, җилнең шаян малайлары үзәннәргә комнар ишкән. Чыккан болыт кара булып, яуган яңгыр шыбыр-шыбыр. Күк күкрәгән дөбер-дөбер, шатыр-шотыр, кылыч айкап күктә йөзгән яшен батыр. Ә Биктимер тауда озак басып торган. Сизмәгән ул яңгырны да, җилләрне дә, күрмәгән ул тауда үскән гөлләрне дә. Учындагы чикләвекне күргән бары, шуннан башка нәрсә кирәк аңа тагы?

Исенә килгәч, егет кайткан, учак яккан. Пычак кайрап, сарык суйган. Киеменең иң матурын киеп куйган. Аннан чапкан авылның иң чибәр кызы Гөлсылуга һәм җитәкләп алып кайткан аш булуга.

— Син хатыным булырсың, — дигән ул кызга, һәр көн сарык ите булыр алдыбызда. Өебез җылы, тамагыбыз сыйлы булыр. Киемебез тузмас өстә, яңа торыр. Шуннан артык нәрсә кирәк тагын безгә?

— Әйе, — дигән Гөлсылу да, аны раслап, — бәхет бит ул бер-береңне яшәү аңлап. Бер-беребезне сөешәбез инде күптән, бу көнне бит син дә, мин дә зарыгып көткән. Инде менә бергә булдык, без кавыштык, язмышларны мәңгелеккә бергә куштык. Казанда ит кайнап торсын гөбер-гөбер, яшик шушы мул тормышта гомер-гомер.

Теләкләре бер булганга сөенә-сөенә, егет йоткан чикләвекне төелә-төелә. Һәм ышанган картның сүзе хаклыгына, бәхет булган гел-гел болар яклы гына. Һәрчак шулай казанда ит кайнаган, ди, берсен-берсе болар сүзсез аңлаган, ди. Йөзләреннән елмаюлар китмәгән һич, өй җылы һәм гел ягулы булган, ди, мич. Ә кешеләр сөенгәннәр, нәрсәгәдер көенгәннәр, мәш килгәннәр, эшләгәннәр, елаганнар һәм көлгәннәр, баеганнар һәм бөлгәннәр. Алар өчен вакыт аккан, сырсыз йөзләргә сырлар яткан, нурсыз йөзләргә нурлар капкан. Кемдер чирләгән, кемдер терелгән. Кемдер туган, кемдер үлгән. Кемдер шөһрәт яулаган, кемдер акча санаган.

Кояш чыккан, кояш баткан, болытларга утырып көннәр аккан, гөрләвекләр булып гомер чапкан. Язны — җәйләр, җәйне көзләр алыштырган. Һәр яңа көн кемнәрнедер табыштырган, кемнәрнедер кавыштырган. Тик Биктимер белән Гөлсылу өчен генә вакыт туктаган, көннәр йоклаган, сәгать телләре һаман бер үк санны чутлаган. Биктимер дә, Гөлсылу да бәхеткә бик күнеккәннәр, кайгыруны онытканнар. Алар картаймаган да, яшәрмәгән дә, ашкынмаган да, шашынмаган да. Йөзләрендә бер елмаю катып калган, күзләрендә соңгы очкын батып калган.

Башта аларга кешеләр кереп йөргән. Кемдер зарын сөйләгән, кемдер моңын. Кемдер үзенең кызын мактаган, кемдер — улын. Ләкин болар ишетмәгән кеше зарын, кешеләрнең кайгысына ерганнар тик авызларын.

Тора-бара читләшкән алардан һәркем. Икәү генә торып калган ир һәм хатын. Бер үк сүзне сөйләгән, ди, алар гел-гел, бер үк җырны көйләгән, ди, алар гел-гел.

Бер кеше дә кермәгән, ди, өйләренә, яшәгән, ди, болар гел үз көйләренә. Ит ашаган, яңа кием кигәннәр, ди, башкалар елаганда да көлгәннәр, ди. Болар да еларлар иде — күзләреннән яшь чыкмаган, йөрәкләрен май баскан, ди, җаннарыннан гамь качкан, ди.

Мин дә булдым аларда бер юлым төшеп. Сарык ите чыккан иде яңа пешеп. Бот кимерә иде ире шатыр-шотыр, шулпа чөмерә иде хатыны шапыр-шопыр. Йөзләрендә тирләр иде бөрчек-бөрчек, ә почмакта бәйдә тора иде көчек. Көчекләре чиный-чиный өрә иде, чөнки алдында итсез сөяк һәм бер ярмасыз өйрә иде. Мин дә тордым озак басып, кергән идем карыным ачып. Ләкин мине күрмәделәр, бер кабым ит бирмәделәр. Чыгып киттем уа-уа ач корсакны. Әйе, дуслар, булдым анда мин берчакны. Ашамаган итләре тешемә кысылды, эчмәгән шулпалары түшемә коелды. Бәйдәге көчекләре барды артымнан өреп, котылдым аңардан бары үземә дә эләкмәгән итне биреп.

## БЕР ЯРЛЫ БЕЛӘН БЕР БАЙ

Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, бака плотник, үрдәк үрәтник булган заманда яшәгән, ди, бер ярлы егет. Исеме аның Батырҗан булган, ди. Батырҗанның торырга өе, ашарга ипие, йокларга түшәге, җигәргә ишәге, кияргә бишмәте юк икән. Шуңа күрә ул кешедә ашаган, күршедә торган, берәр кая барасы булса, тәпиләрен җиккән, йокысы килсә, баш астына йодрыгын салып йоклап киткән.

Менә шушы Батырҗаннар авылында Һарун дигән бер бай яшәгән. Артык саран, артык комсыз булганга аны бөтен кеше Карун дип йөрткән. Көннәрдән бер көнне ярлы егет Батырҗан Карунга эшкә ялланырга килгән.

— Нинди эш эшли беләсең, егет? — дип сораган аңардан Карун.

— Мин белмәгән эш юк, — дигән Батырҗан, күкрәгенә сугып.

— Бик әйбәт, — дигән Карун бай, — миңа шундый егетләр кирәк. Мин ни кушсам, шуны үтәрсең. Сүземә карышмасаң, торган җирең җылы, тамагың тук булыр.

— Ә өскә кием? — дигән Батырҗан.

— Торган җирең җылы булгач, өскә кием кирәкми, — дигән Карун бай.

— Ярар алайса, — дигән Батырҗан, аның белән килешеп. Кулга кулны сукканнар, сүзләрне ныгытканнар. Карун Батырҗанга мунча ягарга кушкан. Су ташырга ике уймак биргән. «Шушы уймаклар белән ерак инештән су китер», — дигән. Батырҗан, уймакларны учында сикерткәләп:

— Чиләкләрең зурлыкка бераз зуррак икән дә, йә, ярый, минем җилкә моны гына күтәрер әле, — дип, байның өennән чыгып киткән. Чыгу белән ул уймакларын мунча тәрәзәсе төбенә куйган да уймак төсле итеп ясаган ике мичкәне бәләкәй арбага утыртып инешкә суга киткән. Батырҗан ишегалдына кайтып керүгә, каршысына Карун бай килеп чыккан:

— Ә, — дигән ул Батырҗанга, — син минем сүземне шулай үтисеңмени?

— Ничек? — дигән Батырҗан, бик аптыраган кыяфәткә кереп.

— Соң, мин бит сиңа суны уймак белән ташырга куштым, ә син мичкә белән ташыйсың, — дип ярсый башлаган Карун бай.

— Сиңа гына мичкә булып күренә ул, — дигән Батырҗан. — Менә кара: мичкәне шулай уч төбенә генә салып күтәреп буламы?

Батырҗан байның күз алдында, ике мичкәне ике учына утыртып, мунчага кереп киткән.

— Чынлап та мичкә кадәр мичкәне ике уч төбенә утыртып йөрерлек адәм булмас, күзем ялгышадыр, — дигән Карун.

— Әйе, ялгыша, — дигән Батырҗан, байның сүзләрен ишетеп, — әгәр ышанмасаң, хәзер өеңә керәбез дә ашарга утырабыз, шунда үзеңнең ялгышканыңны тагын бер кат күрерсең.

Алар өйгә кереп киткәннәр. Карунның өстәлендә бер табак ботка белән бер бөтен ипи тора икән. Батырҗан табагы белән ботканы күтәргән дә авызына каплап куйган. Аннары бөтен ипине кабып йоткан. Шуннан соң Карунга болай дигән:

— Сиңа бу, бай абзый, бер табак ботка булып күренгәндер, мөгаен.

— Соң, әлбәттә, — дигән Карун. — Табак тулы иде бит.

— Синең табак дигәнең табак түгел ул, чикләвек кабыгы гына, ә бөтен ипи дигәнең бер валчык иде. Биргән кешегә һәрвакыт биш булып күренә, — дигән Батырҗан.

— Алай, алай, — дигән Карун, бик аптырап.

— Шулай, — дигән Батырҗан, — әгәр һаман күзләреңнең ялгышуына ышанмасаң, тагын бер исбатлап күрсәтермен.

— Ничек итеп? — дигән бай.

— Мин сиңа хәзер бер әйбер бирәм. Ул сиңа, мөгаен, бик кечкенә булып күренер.

Батырҗан кесәсеннән кульяулыгын чыгарып байга сузган:

— Мә, бай абзый, менә бу ашъяулыкны берәр җиргә алып куй, мине үзегезгә эшкә алуыңа рәхмәтем билгесе булыр.

— Ашъяулык? — дигән бай, гаҗәпләнеп. — Бу нинди ашъяулык булсын?! Кульяулыкны ашъяулыктан гына аера алам әле мин.

— Менә-менә! — дигән Батырҗан. — Биргәнгә биш тә күп, алганга алты да аз, дип юкка гына әйтмәгәннәр шул. Йә, ярый, бай абзый, сөйләштек, инде тамак туйдырырга вакыт.

— Әле генә табагы белән ботканы каплап куйдың лабаса, — дигән Карун, — җитмәсә, бер бөтен ипине кабып йоттың. Болай булса мине ике-өч көндә бөлдерәчәксең син.

— Без бит кулны кулга сугыштык: тамагың тук, урының җылыда булыр, диде̧ң. Сүздә торырга кирәк, бай абзый, юкса мин үзем яккан мунчаны үзем өреп сүндерергә дә күп сорамам.

Карун бай Батырҗанны туйганчы ашатырга мәҗбүр булган. Чөнки ул мунчаны бик ярата икән. Атнаның алты көнендә мунча яктырган, һәр мунчаны алты хатынының берсе белән кергән. Атнаның җиденче көнендә генә мунча яктырмаган, нигә дисәң, җиденче хатыны булмаган. Шуңа күрә ул үзен бик ким сизгән.

Көннәрдән бер көнне Карун бай Батырҗанны каршысына утырткан да болай дигән:

— Бүгеннән миңа бик шәп итеп өй сала башла, егет.

— Өен салуын салырбыз, — дигән Батырҗан. — Тик синең алты өең бар бит инде.

— Ә миңа җидәү кирәк, — дигән Карун. — Җиденче өй әзер булу белән, җиденче хатын алып җибәрәм.

Карунның авылдагы иң чибәр, иң акыллы кыз Зөһрәгә күзе төшеп йөри икән. Ә Зөһрә белән Батырҗан күптән инде вәгъдәләшеп куйган булганнар. Карунның Зөһрәгә өйләнергә уйлавын белгәч, Батырҗан кара кайгыга баткан. Үзенең кайгысын авыл картларына сөйләгән, ләкин алар да акыллы гына киңәш бирә алмаганнар.

— Үрәтниккә барып кара, — дигән берсе. — Бәлки, ул яклар.

— Ай-һай, — дигән икенчесе, — карга күзен карга чукыр микән?

Батырҗан нишләсен, үрәтниккә барган. Хәлен сөйләп биргән.

Ләкин үрәтник аңардан көлгән генә. «Өстеңә кияргә алмаш күлмәгең юк бит синең, йолкыш, җитмәсә, өйләнергә йөрисең, — дигән. — Бар хәзер үк кайт та яман уйларың өчен баеңнан аягына егылып гафу сора. Ә менә бусы үзеңнең тамагыңны туйдырып торган кеше өстеннән зарланып йөргәнгә миннән күчтәнәч булыр», — дип, үрәтник Батырҗанны яткырып камчылаган. Батырҗан, сызлаган тәннәрен уа-уа, Карун байның мунчасына кайтып егылган. Әйе, тору урыны шунда булган аның. Эшкә алган чакта, урының җылыда булыр дип, Карун бай аны алдамаган.

Батырҗан мунча ләүкәсенә менеп яткан да уйга чумган. Нишләргә? Зөһрәне Карун байдан ничек коткарырга? Карун бай эшлим дигән нәрсәсен эшләми кала торганнардан түгел. Әллә соң Зөһрәне алып берәр якка качаргамы? Качып та кая барасың? Карун байның аргамаклары бик җитез, ике авыл үткәнче артыңнан килеп җитәчәкләр.

Батырҗан эчендә кайнаган сагышына чыдый алмыйча бабасыннан калган иске гармунын уйнап җибәргән. Гармун сыкраган, елаган, ыңгырашкан. Сагышлы моң мунча эченә генә сыеша алмыйча, тәрәзәдән чыгып, болытларга үрләгән. Болытлар ул сагышны күтәрә алмаган — яңгыр булып яуган. Сагышлы тамчы тамган җирдә сары чәчәкләр калыккан. Ә Батырҗан уйнаган да уйнаган. Шулай моңга чумып уйнап утырганда, бермәлне ул мунча ләүкәсендә кемнеңдер мышык-мышык елаганын ишеткән.

— Әй, — дигән Батырҗан, — кем бар анда?

— Бу мин, — дигән ләүкәдәге тавыш, — мунча иясенең кече малае Пәриҗан булам.

— Моңарчы нишләп соң синең бер дә тавыш-тының ишетелми иде, Пәриҗан?

— Моңарчы синең бу тиклем сагышлы итеп гармун уйнаганың юк иде. Бүген синең уйнавыңны ишеткәч, елап җибәргәнемне сизми дә калдым.

— Кайгым бик зур, Пәриҗан, — дигән егет һәм үзенең хәлен сөйләп биргән.

Пәриҗан аны бүлдерми тыңлап торган һәм Батырҗанны юатырга тотынган:

— Кайгырма, егет, берәр җаен табарбыз. Безнең кодрәт кешеләрнекенә караганда зуррак. Без әфсен-төфсен гыйлеменең барлык нечкәлекләрен беләбез. Менә әле син мине күрмисең, тавышымны гына ишетәсең. Телисеңме, мин синең күзеңә күренә торган булам?

— Телим.

— Тик курыкма, егет.

Пәриҗан авыз эченнән ниндидер әфсен укыган да шалт итеп Батырҗанның каршысына килеп баскан. Моның күзләре мунча ташыдай кап-кара, авызы мич кадәр ачылган, башы ләгәндәй зур икән. Бары тик аяклары гына каз аягы кебек зәгыйфь һәм хәлсез икән.

Батырҗан аны күреп:

— Нишләп синең аякларың болай үсми калган? — дип сораган.

— Мин бит гомеремне мунчада гына уздырам, — дигән Пәриҗан, — миңа беркая чыгарга ярамый. Пәри-җеннәр арасында һәр мунча бүленгән. Бер җеннекенә икенчебез керергә ярамый.

— Ә нәрсә ашап торасың соң син? — дигән Батырҗан.

— Без — җеннәр, сезнең кебек авыз белән ашамыйбыз. Без ис белән туенабыз. Кешеләр тәмле ризыклар пешергәндә, дөньяга бик татлы, бик туклыклы ис тарала. Без шуны иснибез.

— Сезнең хәл җиңелрәк икән, — дигән Батырҗан.

— Алай дип әйтмәс идем, — дип каршы төшкән аңа Пәриҗан. — Кешеләрнең пешерергә ризыгы булмаса, безгә дә авыр. Әзмени көненә бер тапкыр да ризык исе таратмаган өйләр?!

— Әйе! — дип килешкән Батырҗан Пәриҗан белән. Алар шулай озак кына ләүкәдән аякларын салындырып сөйләшеп утырганнар. Батырҗан үзенә иптәш табылуына бик куанган. Дуслашып киткәннән соң, Пәриҗан егеткә болай дип ялына башлаган:

— Батырҗан дускай, үзең кебек моңлы итеп гармунда уйнарга өйрәт әле мине. Синең эшләр җайлы: йә җырлап, йә гармунда уйнап, сагышыңны таратасың. Ә безгә җырларга ярамый — кешеләр ишетә. Гармун турында хыяллана да алмыйбыз. Без бары тик морҗа аша сызгыра гына беләбез. Ләкин сызгырып таралмый торган сагышлар да бар бит дөньяда.

— Шулай, дускай, — дигән Батырҗан, — менә минем сагышым гармун уйнап та таралмый әле.

— Мин сиңа ярдәм итәрмен, — дигән Пәриҗан, — тик син мине гармун уйнарга өйрәт.

Батырҗан белән Пәриҗан кулга кул сугышканнар, сүзләр ныгытканнар. Шул көннән башлап ялчы егет Пәриҗанны гармун уйнарга өйрәтергә тотынган. Пәриҗан ярыйсы гына сәләтле икән, берничә көн дигәндә «Кара мунча» көен әйбәт кенә сиптерә башлаган.

— Ярый, — дигән Батырҗан көннәрдән бер көнне. — Инде бармакларың гармун телләрен үзләре эзләп таба белә. Осталык уйный-уйный килер. Хәзер син мине һөнәреңә өйрәт. Юкса анда Карун бай Зөһрәгә өйләнергә ашыга.

— Минем һөнәргә өйрәнү озак түгел, — дигән Пәриҗан. — Менә монда кил әле.

Пәриҗан ярлы егетне сулы ләгәнгә алып килгән.

— Менә шушы ләгәндәге суга бер уч карама утынының көлен сибеп ярты сәгать буе бер керфек какмыйча карап торсаң, кем кыяфәтенә керергә телисең — шул буласың. Тик шул кешенең төсен-битен бик яхшы күз алдына китерергә кирәк.

— И-и, — дигән Батырҗан күңеле кайтып, — аңардан миңа ни файда?

— Башың белән уйла, юләр кеше, — дигән Пәриҗан, ачуланып. — Болай итсәң, син бит теләсә кемнән үч ала аласың. Йә, әйт, кем кыяфәтенә кертим үзеңне?

— Үрәтник кыяфәтенә, — дигән Батырҗан, эшнең нәрсәдә икәнен төшенә башлап.

— Алайса, әйдә ләгәндәге суга кара. Тик берүк керфек кага күрмә. Бөтен эшне бозарсың. Ә кире үз хәлеңә кайтыр өчен менә бу әфсен догасын өч тапкыр авыз эчеңнән кабатларсың.

Әфсен-төфсен,
Ылсым-тылсым;
Кыяфәтем тагын
Үзем төсле булсын.

Батырҗан ләгәндәге суга бер уч карама көле сипкән дә керфек какмыйча карап тора башлаган. Күз алдына аның чалгы мыеклы, ыржайган авызлы үрәтник килеп баскан. Бик озак карап торган ул.

Әгәр Пәриҗан иңенә кагылып:

— Җитте инде, җитте, — димәсә, тагын торыр иде әле.

— Үрәтниккә ошадыммы инде? — дигән Батырҗан.

— Нәкъ үзе! — дигән Пәриҗан. — Менә кыяфәтеңне көзгедән карап җибәр әле. — Пәриҗан егеткә җиз комган төбе сузган. Мунча ташына ышкып ялтыратылган җиз комган төбе көзгеләрдән шәбрәк күрсәтә икән. Батырҗан, көзгедә чалгы мыеклы, ыржайган авызлы үрәтникне күреп, хәтта бераз куркып калган.

— Шүрләмә, егет, — дигән Пәриҗан, аның җилкәсенә шап итеп сугып. — Баең янына кереп, хәзер теләсә ни кылана аласың.

Батырҗан кулына каеш камчы алган да Карун бай өенә кереп киткән:

— Әйдә, әйдә, үрәтник туганкай, түрдән уз, — дип бишкә бөгелеп сәлам биргән аңа Карун бай. Һәм тиз арада хатыннарына табын әзерләргә кушкан. Байның алты хатыны алты төрле сый әзерләп өстәлгә куйган. Карун Батырҗанның астына бәрхет тышлы мендәр салып табынга чакырган.

— Аштан олы булып булмас, — дигән Батырҗан, чалгы мыегын бөтереп, — башта ашап алыйк, аннан эш турында сөйләшербез.

Батырҗан өстәлгә куелган ашларны табагы белән генә чөмергән. Кыздырылган тавыкларны сөягеннән аралап тормаган, балыкларның койрыгыннан тоткан, башыннан капкан. Күз ачып йомганчы өстәлдә буш савытлар гына тезелеп калган. Карун бай үрәтникнең ашавына шаккатып, коры кашык кимереп калган.

— Син бүген минем ялчым Батырҗан төсле ашадың, — дигән Карун.

— Ә-ә? — дип сикереп торган Батырҗан, — нәрсә дидең?

— Юк, юк, үрәтник абзыкаем, ялгыш кына телемнән ычкынды. Син бүген бер дә ашый алмадың.

— Сузылып ят сәкегә! — дип кычкырган Батырҗан, каеш камчысы белән селтәнеп. — Хәзер синең йомшак җиреңне каты итәм. Юкса бик әтәчләнә башладың. Дөрес булса, Зөһрәгә өйләнергә йөрисең, диләр.

— Соң, үрәтник абзыкаем, үзең фатиха бирдең бит.

— Алдашма! — дигән Батырҗан һәм Карунның чалбарын төшереп йомшак җиренә камчысы белән тарткан. Карун үрле-кырлы сикереп куйган. — Өйләнәсеңме? — дигән Батырҗан.

— Кызы бик чибәр бит, үрәтник абзыкаем, ничек шундый чибәр кызны ятларга калдырырсың, — дигән Карун бай.

— Алаймы? Мә алайса тагын берне! — Батырҗан Карун байга янә берне тамызган.

— Бетте, бетте, өйләнмим, — дигән Карун бай, камчы төшкән җирен уып. — Моннан соң өйләнү турындагы уйларны башыма да китерәчәк түгелмен. Үзен күрсәм, күземне йомып үтәчәкмен. Берүк кичерә күр, үрәтник абзыкаем.

— Синең гөнаһларың бик күп җыелган, диләр. Хезмәтче Батырҗанны туйганчы ашатмыйсың, өстенә кияргә кием бирмисең икән. Монысы шуның өчен, — дип, Батырҗан тагын шәпләп кенә Карунга берничә тапкыр төшереп алган.

— Менә үземнең иң матур чапанымны бирәм, тик камчыңны гына ераккарак ыргыт, — дигән Карун бай, еландай бөтерелгәләп.

Батырҗан аның ефәк чапанын, әйбәт күнитек һәм эшләпәсен алган да Карунның каршысына ыргыткан.

— Үз кулың белән биргәнлеккә мөһерле кәгазьгә язу яз. Яңадан дәгъвалап йөрерлек булмасын, — дигән. Карун сандык төбеннән мөһерле кәгазь алган һәм калтыранган куллары белән: «Ошбу киемнәрне ялчым Батырҗанга үз теләгем, үз кулым белән бирәм», — дип язу язган. Язуы янына әле тагын берничә алтын да өстәгән.

— Кара аны, — дигән Батырҗан, камчысын уйнатып, — Зөһрә турында оныт.

— Оныттым, оныттым, — дигән Карун бай. — Исемен дә телгә алачак түгелмен.

Батырҗан, бай биргән киемнәрен култык астына кыстырып, өйдән чыгып киткән. Мунчага кереп Пәриҗан өйрәткән доганы өч тапкыр кабатлаган икән, янә үз кыяфәтенә кайткан. Хәзер инде ул үрәтниктән ничек итеп үч алырга уйлап йөри башлаган. Монда аңа озак баш ватарга туры килмәгән. Шул көннәрдә генә каладан үрәтникләргә зур бер түрә төшкән. Түшләренә таккан калайлары аның үрәтникләрнең үрәтниге генерал Бушбугазов икәнлеген әйтеп торган.

Генерал Бушбугазов тирәсендә үрәтник тә, байлар да түш белән генә шуышып йөргәннәр. Бу олы түрәне сыйларга авылның старостасы кеше саен кереп тавык-каз, бал-май җыеп йөргән. Үрәтник бик әйбәт итеп мунча яккан. Генерал Бушбугазовны атлас мендәр салынган кәнәфигә утыртып мунчага илтеп куйганнар.

Батырҗан исә аның мунчага киткәнен күрү белән мунча ишеген тышкы яктан әйбәтләп терәтеп куйган һәм тиз генә, Пәриҗан өйрәткәнчә эшләп, Бушбугазов кыяфәтенә кергән. Яңа гына мунчага киткән түрәнең кире әйләнеп кайтуын күргәч, үрәтник пошаманга төшкән:

— Ваше благородие! — дигән ул, үрә катып, — әллә мунча ошамадымы?

— Ошамады! — дигән Батырҗан, авызыннан ут чәчеп. — Артык кызу яккансыз. Мине янып үлсен дигәнсездер.

— Ваши благороди...

— Дәшмә! — дип кычкырган Батырҗан. — Мунчаны кем якты?

— Мин үз кулларым белән, — дигән үрәтник.

— Сузылып ят, — дигән Батырҗан.

— Ә син, Карун бай, — дигән ул боларга кунакка килгән Карунга, — кулыңа сыек чыбык ал да үрәтникне бик яхшылап каезла.

— Була ул! — дигән Карун бай. Теге көннән бирле үрәтниккә ачуы кайнап йөргән бай мондый җай чыгуга сөенеп эшкә керешкән. Чыбыкның әйбәтен, усал тешли торганын сайлап, үрәтникне рәхәтләнеп ярган.

— Арыдыңмы? — дип сораган аңардан Батырҗан.

— Арыдым, — дигән Карун бай, маңгаеннан тирләрен сөртеп.

— Арысаң, хәзер син сәкегә сузылып ят, — дигән Батырҗан. — Үрәтник сиңа сыек чыбык белән хәл кертер.

Түрәсенең бу сүзләрен ишеткәч, үрәтник сузылып яткан җиреннән сикереп торып сыек чыбыкка ябышкан. Кешеләрдән тавык-каз җыеп йөргән старостага да өлеш чыккан.

Соңыннан Батырҗан өстәлдәге сый-нигъмәтләргә күрсәтеп:

— Боларны кемнән алсагыз — шуларга илтегез. Карагыз аны, бер аягыгыз монда, икенчесе тегендә булсын. Тавыкларына бер алтын өстәп бирергә онытмагыз, — дигән. Үрәтник, староста, Карун бай авыл буйлап халыктан таланган әйберләрне таратып йөргәннәр. Ә шул арада Батырҗан мунча кереп ятучы түрәнең генерал киемнәрен җыеп алып мичкә ыргыткан. Киеме булмагач, аның түрә икәнлегенә кем ышансын. Алай кычкырган ул, болай кычкырган. «Мин генерал Бушбугазов» дип күкрәк каккан, ләкин аңардан көлгәннәр генә. Үрәтник тә, староста да буйсынмаган аңа. Бер кешене дә үзенең генерал Бушбугазов икәненә ышандыра алмагач, ялангач түрә, караңгы төшкәч, су буйлатып кына шәһәргә сыпырткан. Анда бәхетенә каршы икенче киемнәре бар икән, тиз генә шул киемнәрен киенеп алган. Аннары ике мөһер сугылган кәгазенә үрәтникне дә, старостаны да, Карун байны да авылдан кудырырга дигән әмер язган. Әмерне тиз арада авылга җибәргән. Авыл халкы югарыдан килгән бу әмерне бик рәхәтләнеп үтәгән. Явызлар авылдан куылган. Шушы көннән башлап бу авыл түрәләрсез генә яши икән.

Батырҗан үзенең Зөһрәсенә өйләнеп җибәргән. Аларның туйларында мин дә булдым. Сыйлары артык күп булганлыктан, өстәлләргә генә сыймаган иде. Өстәлләргә сыймагач, беркем берни куймаган иде. Шулай да туй шәп үтте. Пәриҗан гармунда сипте. Картлар билләрен тота-тота биеде, яшьләр сакал сыпырып утырды, бәбиләр туктаусыз җырлады. Батырҗан үзенең Зөһрәсеннән, Зөһрә Батырҗаннан күзен ала алмады. Алар бер-берсеннән күзен алган вакытта, туй таралган, таң яралган иде инде.

## ИМЕШ-МИМЕШ

Имеш-мимеш, аккан, ди, бер инеш, ул инешнең яры алтын, суы булган, ди, көмеш. Имеш-мимеш, үскән, ди, бер урман, ул урманда һәрбер агач оста җырчы булган. Имеш-мимеш, булган, ди, бер алан, ул аланда үскән, ди, кып-кызыл җимешле балан.

Әй, юк, дөрес түгел, имеш түгел, мимеш түгел, инеше булган — көмеше булмаган, аланы булган — баланы булмаган. Бу аланда төрле-төрле гөлләр үскән. Алар бер-берләре белән бик дус яшәгәннәр. Бергә уйнаганнар, бергә яңгыр суында коенганнар, бергә кояшта кызынганнар. Кайвакыт бу чәчәкле аланга озын колак Куян килеп чыга икән. Ул Куянны инде үзегез беләсез, ул качышлы уйнарга бик ярата. Шуңа күрә бу аланга Куян килеп керү белән, чәчәкләр уен уйнарга тотыналар икән. Куянның күзен каплап карурманга каратып бастыралар да гөрләргә кушалар, ди. Куян күзен бәйләгән яулыкны чишәргә тырышып болай дип гөрли, имеш:

Гөр-гөр гөрлимен,<br>
Вакыт күпме — белмимен.<br>
Вакыт күпме — белер идем,<br>
Сәгать тагып йөрмимен.<br>
Гөр-гөр гөрлимен,<br>
Мин бит сезне күрмимен.<br>
Инде озак гөрләдем,<br>
Моннан ары түзмимен.

Куян шулай гөрләп торган арада, чәчәкләр төрле якка качып бетәләр. Куян, күзләрен ачып, чәчәкләрне эзли башлый, ди. Чәчәкләрнең кайсын яфрак астыннан, кайсын куак артыннан табып ала икән ул. Бөтен чәчәкләрне дә табып, аларны гөрләтеп калдырып, үзе кача. Качкан чакта үзе болай дип такмаклый, ди:

Әй чабамын, чабамын,<br>
Җиргә тими табаным.<br>
Боланнарны өркетәм,<br>
Аюларны куркытам,<br>
Ябалакны очырам,

Бүреләрне качырам,
Бер сикерәм, бер басам,
Йә, табыгыз, мин качам.

Куянның соңгы сүзен ишетүгә, чәчәкләр күзләрен ачып җибәрәләр, төрлесе төрле якка таралышып эзли башлыйлар. Иртәсен эзлиләр, кичен эзлиләр, җилләрдән сорыйлар, болытлардан сорыйлар, әмма таба алмыйлар. Шуннан соң чәчәкләр, Куянга үпкәләп, бүтән уен уйнарга тотыналар. «Әйлән-бәйлән» дә калмый, «Без-без-без идек» тә — бөтенесен уйнап чыгалар. Барлык уеннарны уйнап бетергәч, арып-алҗып үз урыннарына таралышалар. Беразга алан тынып кала. Тик бу тынлык озакка бармый. Кыңгырау чәчәк зеңгел-зеңгел итеп бер чыңлап куюга, аландагы дуслары йокымсырап утырган җирләреннән җанланып китәләр. Сөйләшергә тотыналар, ди.

— Уйныйбыз, җырлыйбыз, — дип әйтә икән Кыңгырау чәчәк, — ләкин җанга нидер җитми. Ямансу.

— Шулай, бик дөрес әйтәсең, — дип кушыла, ди, аңа Энҗе чәчәк. — Кай чагында әллә кайларга китәсе килә. Безнең бит шушы аланнан башка беркая барганыбыз юк.

— Ә дөнья киндер ул, — дип көрсенеп куя, ди, Лалә чәчәк.

Аланда тавыш куба икән. Ромашкалар, лаләләр, энҗеләр, кыңгыраулар, миләүшәләр — бөтенесе берьюлы сөйләргә тотыналар. Кемнең ни әйткәнен бары тик алан янындагы карт каеннар белән карт имәннәр генә ишетәләрдер, мөгаен.

Ә чәчәкләр гөрләшеп-сөйләшеп күңелләрен басалар да яңадан беразга тынып калалар. Шулай да аларның җаннарындагы ашкыну бөтенләй үк сүнми. Бигрәк тә болытлы, караңгы көннәрдә сагышлары кузгала. Шунда берсе ишелеп-ишелеп аккан болытка карап:

— Әй, болыт, син кая таба агасың? Безне дә үзең белән ал әле, — дип кычкыра.

Болыт агышыннан туктап түбән карый һәм:

— Сезне үзем белән бик алыр идем, ләкин мин бит җилдән башка берни эшли алмыйм. Сез җилдән рөхсәт сорагыз. Ул сезне минем янга күтәрсен, — ди.

Чәчәкләр җилгә дәшәләр:

— Әй, җил, безне болытларга күтәрче, зинһар. Безнең дөнья гизәсебез килә. Дөнья киңдер, иркендер, матурдыр. Без монда яшәп бик туйдык. Безнең монда бер ямь дә юк.

— Әйе, дөнья матур, киң, иркен, — ди җил. — Мин бик күп җирләрдә йөрдем. Мин сезне рәхәтләнеп, болытларга утыртып, дөнья гизәргә чыгарып җибәрер идем. Тик мин сезнең янга төшә алмыйм. Төштем исә, койрыгым агачларга урала. Аннары оча алмыйм. Ә мин булмасам, болытлар агуыннан туктап җиргә егылып төшәчәк. Урман шаулаудан туктаячак. Мин шундый җаваплы эшемне ничек калдырыйм инде?

— Алай икән, — дигәннәр чәчәкләр, — эшең чынлап та бик җаваплы икән.

— Ә сез бер дә борчылмагыз, — дигән чәчәкләргә җил. — Сезнең аланыгыз һичбер җирдән ким түгел. Күрәсезме, янәшәгездә генә инеш агып уза. Пәһлевандай имәннәр яныгызда көне-төне сакта тора. Кояш сезне иркәләп туймый.

— Алаен алай да, — дигәннәр чәчәкләр, — тик барыбер күңелне көтмәгәндә сагыш баса. Уеннарның кызыгы бетә. Каядыр китәсе килә. Туйдык без монда яшәп.

— Әгәр инде бик ашкынасыз икән, мин сезгә ярдәм итә алам, әлбәттә, — дигән җил. — Тик моның өчен сезгә бик дәү булып үсәргә кирәк. Үзегезне урап алган имәннәрдән, каеннардан биек үскәч, мин сезне йолкып алып китәрмен дә илдән илгә йөртермен.

Чәчәкләр бу хәбәрне ишеткәч бик шатланганнар. «Без үсәчәкбез, һичшиксез, дәү булып үсәчәкбез, син генә биргән вәгъдәңне онытма», — дигәннәр.

— Онытмам, — дигән җил, — сез үсә торыгыз, мин урап килермен.

Шулай дигән дә үз юлына киткән җил. Чәчәкләр бик тырышып үсәргә тотынганнар. Моның өчен алар күп итеп чык сулары эчкәннәр, кояш нурларына тотынып югары үрмәләгәннәр.

Тырышу бушка китмәгән, бермәлне алар агач биеклегенә күтәрелгәннәр. Җиргә егылмас өчен һәркайсы үз янәшәсендәге каенга яки имәнгә таянган. Инде алар, аяк очларына баса-баса, кайчан җил килеп чыгар икән дип, тирә-якны күзәткәннәр. Җил озак көттермәгән, урмандагы иң биек агачларның башларыннан сикерә-сикерә болар янына килеп җиткән. Килеп җиткән дә койрыгына урап чәчәкләрне йолкып алган.

Туып-үскән җирләреннән йолкынган чагында чәчәкләрнең әллә кай төшләре авырткан, күзләреннән ирексез рәвештә яшьләр тамган. Шулай да алар сагышка бирелмәгәннәр, чөнки җил аларны бер болыттан икенче болытка чөйгән. Айкаган-чайкаган: әле диңгез өстенә алып киткән, әле чүлләр-сахралар буйлап бөтереп йөрткән. Чәчәкләргә баштарак болай йөрү кызыклы тоелган. Алар урмандагы иң биек агачлардан да югары менүләре белән горурланганнар. Җирдә үскән барлык үсемлекләргә бераз кимсетүле караш белән караганнар.

Ә җилләр искән дә искән. Чәчәкләр туып үскән аланнарыннан торган саен ерагая барганнар. Бәреләсугыла йөри-йөри арыганнар, алҗыганнар. Җиргә төшәселәре килә башлаган. Алар җилгә:

— Зинһар, безне үз аланыбызга төшер, болай йөрергә көчебез калмады, — дип ялварганнар.

Ләкин җил чәчәкләргә:

— Юк инде, — дигән. — Сезнең күккә күтәреләсегез килгән иде — күтәрдем. Илләр гизәргә теләгән идегез — гиздердем. Башкасын сорамагыз. Юкса ачуымны чыгарырсыз. Ачулансам, мин беркемне дә жәлләмим.

Җил үзенең ачуы нинди көчле икәнен күрсәтү өчен койрыгы белән диңгезгә бәргән. Диңгез кайнаган, дулкынланган. Су өстендә кораблар кечкенә йомычка төсле чайкалганнар, ярсу дулкыннар кораб хәтле балыкларны ярга чыгарып ыргыткан. Кайдадыр балыкчыларның көймәләре шартлап ярылган, җилкән баулары өзелгән.

— Менә күрдегезме? — дигән җил.

— Күрдек, — дигәннәр чәчәкләр, — ләкин безнең барыбер өйгә кайтасыбыз килә.

— Сезнең хәзер өегез юк, — дигән җил. — Мин сезне тамырыгыз белән йолкып алдым.

Чәчәкләр елашырга тотынганнар. Җил аларның елавына яман ачуланып, үзенең сиксән чакрым озынлыгындагы койрыгын күккә селтәгән. Чәчәкләр, аның койрыгыннан ычкынып, биеккә-биеккә менеп киткәннәр. Бераздан җилнең ачуы басылган, һава тынган, ләкин инде чәчәкләр җиргә төшә алмаганнар. Чөнки алар бик югары менгән булганнар. Әгәр сезнең төннәрен күктә җем-җем итеп балкучы йолдызларны күргәнегез булса, белегез, алар йолдызлар түгел, чәчәкләр. Бу чәчәкләр, төне буе күз йоммыйча, үзләренең туып-үскән җирләрен күзлиләр. Кайберләре, җаннарына җыелган сагышка түзә алмыйча, кинәт түбәнгә атылалар. Тик алар да җиргә төшеп җитә алмый, якты эз калдырып янып бетәләр.

Әйе, шулай, шуның белән әкиятем дә бетте бугай. Ә теге инеш һаман ага, имеш. Яры алтын, суы көмеш. Ә теге урман тагы да зуррак булган. Ә теге алан — ул чәчәксез калган. Сүзем дөрес, әкиятем ялган.

## БУАР ЕЛАН

Карурманда бер Буар елан яшәгән, ди. Юанлыгы бүрәнәдәй, озынлыгы дилбегәдәй, күзләре табактай, маңгае кабактай булган аның. Ә инде көч-гайрәт ягына килгәндә, карурманда аның белән тиңләшерлек җан иясе булмаган. Бөтен урман халкы аңардан куркып яшәгән. Аю тиклем аюлар да Буар елан торган урынны читләтеп үтәргә тырышканнар. Нигә дисәң, ул кемне эләктерсә — шуны буып үтергән. Урмандагы җанварлар гына түгел, агачлар да, аңардан куркып, дер калтырап торганнар. Чөнки ул, көчен кая куярга белмәгән чакларда, агач башларына үрмәли дә агачларны дер-дер селкетергә тотына икән. Ул селкетә башласа, имәннәрнең җитлекмәгән килеш чикләвекләре коелган, усакларның кәүсәләре шартлап сынган, меңьяшәр наратларның тамырлары какшаган. Үзенең шундый көчкә ия булуы белән Буар елан бик масаерга яраткан. Кемнәрнедер рәнҗетү аңа җан рәхәте биргән. Хәтта ул үзенә болай дип җыр да чыгарган:

Исемем минем Буар елан буладыр,
Бөтен дөнья миннән куркып торадыр...

Кәефе бик шәп чакларда, Буар елан шушы җырны җырларга яраткан.

Бервакыт шулай койрыгын имән ботагына урап, башын түбән асылындырып үзе чыгарган әлеге җырын җырлап ятканда, Буар елан янына бер Сукыр тычкан килеп чыккан. Килеп чыккан да, Буар еланга әйләнеп тә карамаган килеш, яфраклар арасыннан кыштыр-мыштыр нәрсәдер эзләнергә тотынган. Буар еланның, моны күреп, тыны кысылган.

— Әй, син! — дигән ул Сукыр тычканга. — Нишләп йөрисең монда?

— Азык эзлим, — дигән Сукыр тычкан, тыныч кына.

— Ничек син миннән курыкмыйсың әле? — дип ыслаган Буар елан.

— Ни өчен мин синнән куркырга тиеш? — дигән Сукыр тычкан.

— Чөнки миннән бөтен җан ияләре курка, — дигән Буар елан.

— Ә менә мин курыкмыйм, — дигән Сукыр тычкан.

Сукыр тычканның бу сүзләренә Буар елан ни дип тә җавап бирергә белмәгән. Аның ачуы кабарган, ике уйлап тормастан Сукыр тычканны кабып йотарга уйлаган. Әмма аны кабып йотудан гына күңеленә тынычлык килмәсен уйлап, бераз сабыр итәргә булган. Сукыр тычканның ни өчен үзеннән курыкмавын бик беләсе килгән аның.

— Әй, син, — дигән ул Сукыр тычканга. — Минем кыяфәтемне күрүгә үк, бөтен җан ияләре дер калтырый башлый. Күзләренә туры карасам, качып китәргә дә куркып, үзләре туп-туры авызыма килеп керәләр. Киселгән имән төбедәй аюлар, тешләре белән теләсә нинди хайванның сөяген көл итүче бүреләр мине күрүгә шүр җибәргәндә, мыек очына элеп атарлык гәүдәң белән нишләп син миннән курыкмыйсың, ә?

— Мин бит сине күрмим, күрмәгәч курыкмыйм, — дигән Сукыр тычкан.

Сукыр тычканның бу сүзләрен ишеткәч, Буар елан үзе асылынып торган агачны дер селкетеп көләргә тотынган.

— Хи-хи-хи, күрмим диген, ә?

— Күрмим шул.

— Ә беләсеңме мин нинди?

— Нинди соң?

— Гәүдәм иң-иң юан арканнан да озынрак.

— Нәрсә соң ул аркан? — дигән Сукыр тычкан.

— И аңгыра, — дигән Буар елан, — арканны да белмәгәч, ни генә беләсең соң син?

— Суалчаннарны беләм, җир кортларын.

— Тинтәк! — дигән Буар елан. — Дөньядагы бөтен суалчаннарны җыйсаң да минем хәтле була алмый. Мин зур, мин көчле, мин батыр. Аңладыңмы инде?

— Аңладым, — дигән Сукыр тычкан.

— Йә, әйтеп кара алайса — мин нинди?

— Синме? — дигән Сукыр тычкан, — минем уйлавымча син песи төслерәк булырга тиешсең.

— И надан! — дигән Буар елан. — Синең песине күргәнең бармы соң?

— Юк, күрергә туры килмәде, — дигән Сукыр тычкан, — ләкин күзле тычканнарның сөйләшеп торганнарын ишеткәнем бар. Иң елгыр, иң көчле, иң батыр нәрсә дөньяда песи дип сөйләнделәр алар.

Сукыр тычканны үзенең дөньяда иң гайрәтле җан иясе икәнлегенә ышандыра алмавына Буар еланның җен ачулары чыккан. Ул үзе асылынып торган агачны дер-дер селкетергә тотынган. Агач ботаклары шартлап сынган, яфраклары давыл вакытындагы кебек шаулаган. Бу агачның шаулавына башка агачлар да кушылган. Бөтен урман ду купкан. Канатлы кошлар куркышып һавага күтәрелгән, канат чыгарырга өлгермәгәннәре ояларыннан җиргә егылып төшкән.

Буар елан, шундый дәһшәтне кузгатып, карурманның астын-өскә китерүе белән мактанып, Сукыр тычканга болай дигән:

— Менә күрдеңме инде минем гайрәтне? — дигән.

— Күрдем, — дигән Сукыр тычкан.

— Син бит сукыр, ничек күрә алдың соң син аны? — дигән Буар елан, үз-үзеннән бик канәгать калып.

— Һи, — дигән Сукыр тычкан, — юньсезлекне күрер өчен күз кирәкмени? Тозсыз белән юньсезне күзсез дә белә.

Шулай дигән дә Сукыр тычкан сызгыра-сызгыра өенә кайтып киткән. Ә Буар елан Сукыр тычканны куркыта алмавына гарьләнеп, бу якларны ташлап качкан. Хәзер инде бу урманда теләсә нинди җәнлек-җанварлар рәхәтләнеп йөриләр, ди. Ә Сукыр тычкан кышкы озын кичләрдә, туган-тумачаларына, дус-ишләренә кич утырырга кереп, Буар елан белән очрашуы турында сөйли икән. Тик дус-ишләре, туган-тумачалары Сукыр тычканның сүзләренә әкият дип кенә карыйлар, ди. Менә шуңа гына Сукыр тычканның бераз кәефе китә икән.

## ЙОКЫБАЙ

Борын-борын заманда бер карурманда Соры аю яшәгән, ди. Аның ике баласы булган. Аю балаларының берсе бик-бик елгыр, бик-бик җитез икән. Әнкәсе аңа берәр нәрсә әйтергә уйлап авызын ача башлауга, йөгереп килеп җитә икән дә: «Әнием, ни боерасың?» — дип, әнкәсенең йомышын үтәргә әзер тора икән. Шулай елгыр, шулай өлгер булганга әнкәсе аңа Елгырҗан дип исем кушкан. Соры аюның икенче малае Елгырҗанның бөтенләй киресе икән. Иртәләрен әнисе аны йокысыннан уята алмыйча сәгатьләр буе баш очында утыра, ди:

— Балакаем, тор инде. Әнә бит кояш агач буе күтәрелде. Әнә тау башына менеп бара, — ди икән.

— Менсә төшәр әле, — ди икән дә икенче ягына әйләнеп ята икән Йокыбай. Әйе, йокыны бик яратканга Соры аю малаена шулай дип исем кушкан.

Тукраннар барабан какса да, каргалар, саесканнар каркылдашып бөтен урманны яңгыратса да, чебеннәр-кигәвеннәр килеп борынын тешләсә дә, уянмый икән Йокыбай. Бары тик Сукыр тычкан моның борын тишегенә койрыгын тыгып сигез тапкыр болгаса гына уяна торган булган Йокыбай. Соры аю Йокыбайны уятырга Сукыр тычкан янына килә дә:

— Изгеләрнең изгесе, шәфкатьлеләрнең шәфкатьлесе, берүк минем малаемны уята күр, — дип ялына икән.

Ә Сукыр тычкан үз дәрәҗәсен белеп кенә, тамак төбен кырып кына:

— Ярар, синең хакка тагын бер тапкыр сүзеңне тыңлыйм, тик кара аны, бусы — соңгысы, — дип, Соры аюның култык астындагы күчтәнәчен алганнан соң, Йокыбайны уятырга китә икән.

Һәм чынлап та Сукыр тычкан үзенең тузанлы койрыгын Йокыбайның борын тишегенә тыгып сигез тапкыр болгавы була, Йокыбай «әпчехи-әпчехи» дип сигез мәртәбә төчкереп җибәрә икән. Шуннан соң инде Йокыбайның йокысы ачыла, киерелеп сузыла, йомшак чирәмгә ятып аунап ала, һәм... тагын йоклап китә, ди.

— Әй, улым, улым, — ди Әнкә аю, — болай булсаң син нишләрсең? Ничек тамагыңны туйдырырсың?

— Йокы туйса, тамак туяр иде әле, — дип әйтә икән дә Йокыбай, алгы тәпиләрен баш астына салып, тагын йокыга чума икән.

Үзен гел-гел уятып җәфаламасыннар өчен ул качыбрак йокларга тырыша башлаган. Көннәрдән бер көнне бик шәп, бик биек итеп өелгән кырмыска оясы күргән дә шуның өстенә менеп яткан. Әнкәсе күрмәсен дип өстенә чыбык-чабыклар ябынган. Ай йоклаганмы, көн йоклаганмы — анысын әйтүе кыен, менә бермәлне билләрен сары каеш белән кысып буган сап-сары кырмыскалар, тешләрен кайрый-кайрый, тырнакларын үткенли-үткенли, Йокыбайны уратып алганнар. Сыңар күзле, чатан аяклы Башлык кырмыска үзенең салам таягын күккә күтәреп бер болгаган да: «Башладык, оланнар, ягез, тотыныгыз!» — дигән. Шушы әмерне генә көткән сары гаскәр күз ачып йомганчы Йокыбайны төрле яклап чеметкәләргә тотынган. Кайсылары колагына, кайсылары борынына тулган. Борыны эчендә яу-яу булып кырмыскалар йөри башлагач, Йокыбай шундый итеп төчкереп җибәргән, хәтта ябалаклар агач башыннан егылып төшкән, ул гынамы соң — йөз ел буе берни ишетмәгән чукрак керпенең колагы ачылып киткән һәм ул тычканнарның аяк очларына гына басып йөрүләрен дә ишетә башлаган. Ә Йокыбай үзе нишләгән дисезме? Йокыбайның да йокысы ачылып киткән. Һы, ачылмас сиңа: борын эчендә кырмыскалар сабантуй ясап ятсыннар әле, өстәвенә бу сары шайтаннар шултикле каты тешлиләр, бөтен урманны яңгыратып үкерсәң дә куркып та карамыйлар, ди. Йокыбай колагына-борынына кереп тулган кырмыскаларны селтәп атмакчы булып тегеләй сикергән, болай сикергән. Арт тәпиләрендә титаклап, башын әле бер якка, әле икенче якка кыйшайтып караган. Мәтәлчек аткан. Әмма кырмыскалар үзләренең кармак төсле бармаклары белән Йокыбайга шулчаклы нык ябышканнар — сикермәгәең, гармунга биесәң дә төшәргә уйлап та карамаганнар. Йокыбай бөтен тәнендә меңләгән кырмысканың мыжлап йөрүенә чыдый алмыйча, күзе кая караса, шул якка чапкан. Көн чапкан, төн чапкан — чаба торгач, бер зәңгәр күлгә килеп чыккан. Зәңгәр күлне күрүгә, ике уйлап тормастан, текә ярдан башы белән суга чумган ул. Күлнең төбе бик-бик тирән икән. Төшкән дә төшкән Йокыбай. Менә бермәлне кырмыскаларның тыннары бетә башлаган. Чыдар хәлләре калмагач, алар, Йокыбайны ташлап, өскә күтәрелгәннәр. Ә Йокыбайның үпкәсе зур, су астында әле ул озак кына тамаша карап йөргән. Сары шайтаннардан котылгач, рәхәтләнеп, корсагын үзле балчык белән уа-уа су кергән.

Тәннәренең әрнүе басылгач, ярга чыгыйм дисә, Йокыбайның койрыгына зур чуртан килеп ябышкан, ди. Йокыбай, койрыгын селтәп, чуртанны зәңгәр күлнең иң тирән җиренә ыргытмакчы булган. Ләкин чуртанның корыч кадактай тешләре Йокыбайның койрыгына шултиклем тирән кергән — чуртан, үзе теләсә дә, койрыктан ычкына алмаган. Ярга чыккач, Йокыбай бу чуртанны бик озак өстерәп барган. Бер чытырманлык арасыннан үткәндә генә чуртанның казык теше сынып, төшеп калган. Башта Йокыбай моңардан котылуына бик сөенгән, әмма башын бераз кыңгыр салып уйлап торганнан соң, мондый фикергә килгән: «Юк, мондый шәп табышны калдырып китәргә ярамас. Алып кайтып әнкәйгә күрсәтергә кирәк. Йоклап йөрсәң, ачка үләрсең, дип ачулана иде. Шаккатсын. Ә Елгырҗанның күзе ут яначак, әле аның мондый чуртанны төшендә дә күргәне юктыр».

Йокыбай шулай уйлап чуртанның сыртыннан капкан да өенә кайтырга чыккан. Кайта икән, кайта икән, шулай кайта торгач, аңарга бер Төлке очраган.

— Ай-яй, Йокыбай, — дигән Төлке, аны ерактан ук танып, — ничек эләктердең бу хәтле зур чуртанны? Йокыбай аңа сөйләп биргән. Төлке исә телләрен ялмый-ялмый Йокыбай тирәсендә бөтерелгән:

— Бик авыр түгелме, күтәрешергә кирәкмиме?

— Авыррак шул, — дигән Йокыбай, маңгаендагы тирләрен сул тәпие белән сыпырып.

— Арысаң, ял ит, — дигән Төлке, — нигә ашыгырга?

— Ял итеп алсаң ярый, — дигән Йокыбай, чуртанны җиргә куеп.

Төлке әле чирәмдә яткан чуртанга, әле мыш-мыш итеп утыручы Йокыбайга карап куя икән. Ничек итеп бу табышны кулга төшерергә? Ничек итеп Йокыбайны йоклатырга? Әһе, болай итәргә — бишек җыры җырларга кирәк.

Һәм Төлке, Йокыбай тирәсендә әйләнеп, болай дип җырларга керешкән:

Эй Йокыбай, Йокыбай,
Йокы — бал ул, йокы — май.
Бер туйганчы йокласаң,
Карын ачмый нәкъ бер ай.

Йокыбайның Төлке халкы турында әнкәсеннән ишеткәне булган инде, шуңа күрә монық хәйләсенә бирешмәскә кирәк, дип утырган. Әмма Төлке хәйләләргә һич уйламаган кебек, ул йомшак, ягымлы тавыш белән, чуртан ягына әйләнеп тә карамыйча, җырлый биргән:

Батыр безнең Йокыбай,
Тапкыр безнең Йокыбай:
Нинди чуртан каптырган,
Дөньяны шаккатырган,
Ай-һай, Йокыбай,
Йокы — бал ул, йокы — май.

Төлке шушы җырны берничә тапкыр кабатлауга, Йокыбай гырылдый да башлаган. Төлкегә шул гына кирәк тә, чуртанны алып тизрәк өенә сыпырган ул.

Әллә өч, әллә биш көн йоклаганнан соң, Йокыбай бик каты ашыйсы килүдән уянып киткән. Башын күтәреп кояшка караган. Кояш нәкъ шул урында тора икән. «Кояш ике агач арасы җир китмәгән, ә мин ай буе ашамаган төсле ачыкканмын. Тизрәк теге чуртанны ялтыратыйм әле. Әнигә күрсәтергә башы белән койрыгы калса ярар» дип уйлаган ул һәм, як-ягына каранып, чуртанны эзли башлаган. Шунда гына аның төлкене күрүе исенә төшкән. «Алдаган хәйләкәр таз, — дигән ул, эчен уып. — Ярар, очрарсың әле».

Ай киткән, ел киткән, унлап үрне, биш чокырны узып киткән, әмма әнисен таба алмаган Йокыбай: «Их, — дигән шуннан соң, үкенеп, — әнине бер табуын тапсам, яңадан бөтен сүзен тыңлар идем. Уятса, сикереп торыр, ашарга чакырса, йөгереп килер идем».

Бик-бик озак эзли торгач, инде егылам, инде үләм дигәндә, әнисе белән Елгырҗан туганы янына кайтып җиткән ул. Кайтып җиткәндә шулхәтле ябыккан булган, әгәр уң колагында тиен күзе чаклы кара миңен күрмәсә, әнисе улын танымаган да булыр иде.

Өйгә кайткач, тамак туйгач, Йокыбайның күңеле күтәрелеп киткән. Алар Елгырҗан белән көрәшергә тотынганнар. Икесе бер көнне тусалар да, Елгырҗанның биле Йокыбайныкына караганда шактый нык икән. Йокыбайны ул бер селтәгән — ике еккан. «Менә йокымны гына туйдырыйм, аннары кемнең көчлерәк икәнен күрсәтермен мин сиңа», — дигән Йокыбай туганы Елгырҗанга һәм бер печән күәсе өстенә менеп йокларга яткан. Елгырҗан белән әнисе аның кая киткәнен дә күрми калганнар.

Йокыбай печәнгә күмелеп җиденче төшен күреп ятканда, бу печән күбәсе янына бер атлы кеше килеп туктаган. «Кайткач бахбайга ашарга булыр, бу печәнне арбага салыйм әле», — дигән ул һәм күбәне күтәреп арбасына салган. «Авыр, рәхмәт төшкере, эченә җеннәр оялаган диярсең», — дигән атлы агай, печән өстенә утырып.

Атлы агай өйләренә кайтып җиткәндә, караңгы төшеп килә икән. Ул тиз генә атын тугарып, арбадагы печәнгә кушкан да өенә кереп киткән.

Ат печән ашап калган.

Төн үзенең бер офыктан икенче офыкка җитәрлек кара канатларын җир өстенә җәеп җибәрүгә, ишегалдында әллә нинди тамаша башланган. Ат арбага бәйләнгән тезгенен өзеп, ике метрлы койма аша урамга сикергән. Рәхәтләнеп тычкан тотармын дип төнге ауга чыккан ала мәче антенна киртәсенең иң очына менеп киткән. Хәтта авызына капкан тычканын йотарга да оныткан. Ишегалдының тугры сакчысы — Сарбай, чылбырга тагылган оясын өстерәп, бәрәңге бакчасына шылган.

Сез инде, әлбәттә, бу әкәмәтләрнең нилектән башланганын белеп алдыгыз. Әйе, ат печән ашаганда Йокыбайны күреп өреккән, атның өркүе ала мәченең котын алган. Кара төннән дә курыкмый ауда йөри торган ала мәче булып ала мәче антенна киртәсенә менеп кунаклагач, әле бер яше яңа гына тулып узган Сарбай ничек курыкмасын?

Ә Йокыбай нишләгән дисезме? Ул арбада икенче ягына әйләнеп яткан да тагын йокыга киткән. Әмма ләкин аңарга озак йокларга туры килмәгән, ала мәченең тере тычканы, тыпырчына торгач, корбаны авызыннан ычкынып, арбага егылып төшкән. Егылып төшкән дә, ераккарак качыйм әле дип, арба

төбендәге печәнгә чумган. Ә печән астында без Йокыбайның йоклап ятканын беләбез инде. Әмма курыккан тычканга ул аю булып түгел, бер түмгәк булып кына күренгән. Посар җир эзли торгач, тычкан Йокыбайның киң итеп ачылган борын тишекләрен күреп алган. «Башта койрыгымны тыгып бу чокырның тирәнлеген үлчим әле, үзем качарлык микән?» — дип, тычкан Йокыбайның борынына койрыгын тыгып берничә мәртәбә болгап җибәргән. Йокыбай шундый итеп төчкереп җибәргән, антенна өстендәге ала мәче, егылып, койрыгын тайдырган. Өй түбәсенең ике ярым калае, кубып, диңгез аръягына очып киткән. Куначадан егылып төшеп, әтәч кикриген сындырган. Тагын әллә ниләр, әллә ниләр булган. Ә Йокыбай үзенең төчкерүенә үзе уянып киткән дә: «Кайда ятам икән мин? — дип күккә караган. Күктә ай нәкъ үз урынында икән. — Болай булгач, озак йокламаганмындыр әле. Тик нишләп бу кадәр ашыйсы килә? Нәрсә капкаларга икән?» — дигән.

Йокыбай, арбадан сикереп төшеп, ашарга эзли башлаган. Абзар алдында гына бер чуен чүлмәктә Сарбайга дип салып куелган итле аш бар икән, шуны ялтыратырга тотынган ул. Ашый-ашый чүлмәкнең төбенә төшеп җиткән. Соңгы кабым итне кабып, инде башны алыйм дисә — менә сиңа мә — баш чүлмәктән чыкмаган. Тегеләй болгаган башын Йокыбай, болай болгаган — юк, ә баш чыгарга уйламаган да.

Чапкан Йокыбай ишегалды бетереп: әле ләгәнгә барып бәрелгән, әле лапаска барып кергән. Лапаска керүе булган — моны күреп, бөтен көтүнең котын алып йөрүче кәҗә тәкәсе һуштан язып егылган. Ә Йокыбайга нәрсә — ул үзе беркемне дә күрмәгән, әгәр күрсә, сыер тикле сыерның мөгезләрен сәнәк итеп үзенә таба килүен тыныч кына карап тора алыр идеме икән? Юк, карап тора алмас иде, качар иде. Ә күрмәгәч, качмаган, качмагач, сыер үзе куркып, лапас почмагына поскан.

Башына чүлмәк кигән килеш лапасны җиде кат урагач, бермәлне ул башы белән баганага килеп бәрелгән. Чүлмәк чәлпәрәмә килгән. Йокыбайның күзеннән төлке койрыгы хәтле булып очкыннар чәчрәгән. Маңгаена чебен гөмбәсе зурлыгында шеш чыккан. Күзләр әлҗе-мөлҗе килгән. «Их, — дигән Йокыбай, — исән-имин өйгә кайтып җитсәм, әниемнең бөтен сүзен тыңлар идем. Уятканда, сикереп торыр идем».

Күзләреннән аккан кайнар яшьләрен әрекмән белән сөртә-сөртә урманга юнәлгән ул. Бара-бара арып беткән. Ә үзенең башында бертуктаусыз бер уй чуала икән: «Нишләп ул печән күбәсе монда авылга кайткан? Әллә төнлә аждаһалар китереп куйдылар микән?»

Ике утырып бер атлый торгач, урманга килеп җиткән Йокыбай. Әмма урманда юллар шулхәтле күп икән, кайсыннан китәргә белмичә, бер минут та ике көн баш ваткан ул. Соңыннан «агач башына менеп карарга кирәк» дигән фикергә килгән. Менеп киткән агачның иң биегенә. Караган як-ягына. Монда бөтен дөнья уч төбендәге кебек ап-ачык күренә икән. Үзләренең зәңгәр аланын да күреп алган ул. Әллә ни ерак китмәгән икән — бер адым да җитмеш җиде чакрым гына, ди.

Инде агачтан шуып төшеп, өйгә сыпыртам дип торганда, янәшәдәге агач башында бал кортларының мәш килеп очуларын күреп алган Йокыбай.

«Болай булгач өйгә буш кайтмыйм икән, — дип сөенгән ул. — Әнигә күрсәтим әле үземнең кемлегемне. Елгырҗанның да ике күзе дүрт булсын».

Йокыбай барлык бал кортларының, сары тубалларын күтәреп, татлы ширбәт җыярга чыгып китүләрен сабыр гына көтеп торган да баллы агачка үрмәләгән. Балны кая салырга дип баш ватмаган ул, янәшә ботактагы иске карга оясының төбенә әрекмән яфрагы җәеп, кәрәзле балны шунда тутырган.

Әй, кайта, ди, Йокыбай. Кулга мул табыш төшерүенә шатлыгыннан биеп тә җибәргәли, ди. Ә бал, Йокыбайны юри котырткандай, тәмле исләрен төрле якка тарата, ди. Йокыбайның авызыннан сулар килгән. «Әй, бер генә кабып карыйм әле», — дигән ул, борынына кергән тәмле искә түзә алмыйча. Һәм балны бер ялап алган. Бераз кайткач тагын ялаган. «Әле монда әниләргә кала, тагын бер генә кабыйм булмаса», — дип янә ялап алган. Кайта-кайта балның өчтән бер өлеше генә калган. «Бусына тимим инде, — дигән Йокыбай, чын күңелдән ышанып, — юкса әниләр ышанмас». Һәм Йокыбай, балның исе борынга кереп тамакны котыртмасын өчен, аны катлы-катлы итеп әрекмәнгә төргән дә култык астына кыстырган.

Шулай әйбәт кенә кайтып килгәндә, аңа тагын теге Төлке очраган.

— Култык астыңда нәрсә ул? — дигән Төлке.

— Бал! — дигән Йокыбай горурлык белән. — Әниләргә апкайтам.

— Әй, шәп тә инде син, — дигән Төлке. — Әниләре турында кайгыртучылар хәзер бик сирәк. Әниең сөенер инде. Менә бит нинди акыллы малай үстергән ул.

Төлкенең мактавына Йокыбайның күңеле булган. Хәтта бал төргәген чишә башлаган.

— Кирәкми, кирәкми, чишмә төргәгеңне. Мин бит бал ашамыйм, — дигән Төлке.

— Бер генә кап инде, — дип кыстаган Йокыбай Төлкене, — бик тәмле ул.

— Юк, юк, — дигән Төлке. — Теге вакыт синең чуртаныңны саклап кала алмавым өчен дә үземне һич кичерә алмыйм әле.

— Ничек саклап кала алмадың? Аны син апкитмәдеңмени?

— Әй беркатлы Йокыбай. Нишләп мин алып китим? Мин синең уянганыңны көтеп утырдым-утырдым да, бик ачыккач, өйгә кайтып киттем. Мин китүгә, аны бүре эләктереп тайган.

— Бүре эләктергәнен каян белдең?

— Бүренең балалары тукран оясы янында чират торалар иде.

— Нәрсәгә?

— Соң шуны да белмисеңмени? Чуртанны ашаганда, тамакларына кылчык утырган. Тукран шуларның кылчыкларын чүпләп тора иде. Әле үзләрен тиргәп тә киттем, кеше өлешенә тисәң, шулай була ул, дидем.

Төлкенең бу сүзләреннән соң, Йокыбай аңа тәмам ышанган. Менә бермәлне алар ял итәргә утырганнар. Чөнки Йокыбайны йокы баса башлаган.

— Мин әз генә черем итеп алыйм әле, — дигән ул, Төлкегә бал төргәген тоттырып. — Син моны сакла. Бүре килә башласа, мине уятырсың.

— Бер дә борчылма, — дигән Төлке, — мин барында тыныч йоклый аласың.

Төлке Йокыбайның баш астына хуш исле үләннәр йолкып салган. Йокыбай, борынын үләнгә төртүгә, гырылдый ук башлаган. Ә Төлке, юл төргәген култык астына кыстырып, шунда ук шылган. «Әй, тинтәк тә инде бу Йокыбай, — дигән ул үз-үзенә. — Балны ашамасам, аны мин урманыбыз ханы аксак аюга кайтарып бирә алам лабаса. Ә хан мине үзенең вәзире итәр. Ә вәзирләр ханның үзеннән дә яхшы яши. Нигә дисәң, һәр күчтәнәч безнең кул аша үтә. Менә шулай ул дөнья, Йокыбай!»

Йокыбай бер минут та өч тәүлек йоклаганнан соң, бик ачыгып уянып киткән. Уянгач, тагын үзенең алданганлыгын белеп, гаять үкенгән. «Әниләрем янына исән-сау кайтып җитсәм, бөтен сүзләрен тыңлар идем. Теләсә кайда ятып йокламас идем», — дип елый-елый кайткан ул.

Өйләренә бик арып, бик йончып кайтып кергән Йокыбай. Әнисенең аны кызганудан күзләреннән яшьләр атылып чыккан. Йокыбайны кыстый-кыстый ашаткан, иң тәмле сыйлар белән сыйлаган. Күпкән маңгаена ниндидер шифалы үсемлекнең яфрагын ябып, улының башын бәйләгән. Койрыгына ябышкан тигәнәкләрен чүпләгән. Әнисенең кайгыртуы, иркәләве Йокыбайның җанын кузгаткан. «Әнием-бәгырем, — дигән ул, чын күңелдән ачынып, — мин бер дә йокламас идем, йокым килә бит. Булсын иде шундый берәр дару — чиләкләп эчәр идем дә, чебен куган кебек итеп, йокыны куар идем. Юк бит андый дару».

— Андый дару бар ул, — дигән Әнкә аю. — Әмма ләкин бик-бик еракта.

— Өйрәт кенә, — дигән Йокыбай, дәртләнеп, — еракта булмагае. Каф тавы артында булса да, мин аны барып табармын.

— Ярый алайса, тыңла, — дип сөйли башлаган Әнкә аю. — Ерак-еракта, урманның иң куе җирендә гамь агачы үсә. Ул гамь агачының җимеше төн уртасы узып, таң җилләре зәңгәр офыкларга таба йөгерә башлагач өлгереп җитә. Чөнки ул агач үзенең җимешен беркемгә дә бирергә теләми. Җимешемне өзеп бетерсәләр, нәселем корыр дип курка. Ә таң алдыннан бөтен җан иясе татлы йокыга чума. Шул агачның җимешен иң өлгергән чакта өзеп ашасаң, йокыңны онытырсың. Тик, балам, шуны бел: бу җимешне ашагач, бөтен тынычлыгыңны югалтачаксың.

— Югалсын! — дигән Йокыбай, — туйдым инде мин болай йоклап йөрүдән. Шушы йоклавым аркасында, үсә дә алмый калдым. Әнә Елгырҗан нинди таза, нинди дәү. Көрәшә башласак, мине сыңар тәпие белән генә селтәп ата. Бүтән аю балалары да: «Йокы чүлмәгенең төбенә төшеп җитеп буламы әле?» — дип көләләр.

— Ярар алайса, улым, юлга җыен, — дигән әнкәсе һәм Йокыбайның юл капчыгына ашамлыклар тутыра башлаган.

— Юк, әнием, — дигән Йокыбай, — ашарга берни дә алмыйм. Ашасам, минем йокым килә. Юлда ни тапсам, шуны ашармын. Ачка үлмәм.

Шулай дигән дә юлга чыгып киткән Йокыбай. Әнкәсе күз яшьләрен сөртеп озатып калган.

Көн барган, төн барган, туктамыйча, йокламыйча гел барган. Кайда гөмбә, кайда җиләк ашап тамагын туйдырган. Бара-бара бик арыган, үтереп йокысы килә башлаган. Күз кабаклары баллы тубал элгәндәй авырайган. «Әллә соң әз генә ятып торыйм микән», — дип уйлаган Йокыбай һәм ял итәр өчен уңайлырак урын эзли башлаган. Шунда янында гына бер бик әйбәт, бик олы түмгәк күреп алган ул. «Монда корырактыр, юкса сазлыклар ерып барып пычранып беттем» дип уйлаган Йокыбай, һәм әлеге түмгәк өстенә менеп ныклап кагынып алган. Шул вакыт, җир тетрәгәндәге шикелле, Йокыбай менеп яткан түмгәк кинәт әле тегеләй, әле болай чайкалырга тотынган. Чайкалып кына да калмаган, сикереп торган да җан-фәрманга чабып киткән. Йокыбайның түмгәк дигәне ял итеп ятучы әкәмәт олы Болан булган икән. Йокыбай Болан өстеннән егылып төшмәс өчен алгы тәпиләре белән моның мөгезенә ябышкан.

Сыртындагы җан иясен тәгәрәтеп төшереп калдырырга теләп, Болан әле томырылып чапкан, әле кинәт туктап калган. Алай гына да котыла алмаган, ешкынлыклар арасына кереп киткән. Агачларга ышкылып караган. Әмма Йокыбай аның саен ныграк тотынган. Аның инде хәзер йокысы да ачылган.

Болан күпме тырышып та сыртындагы Йокыбайны чөеп ата алмагач, туктап болай дигән:

— Әй син, җан иясе, кем син, кая барасың?

Йокыбай бөтенесен аңлатып биргән.

— Ә-ә, — дигән Болан, — беләм мин ул гамь агачын. Анда барып җитәргә күп калмады инде. Тик ул бит бик зур елганың аръягында. Аны йөзеп чыгарга, ай- һай, көч күп кирәк. Хәтта без дә чыгып җитә алмыйбыз аның аргы ягына.

— Баргач күз күрер, — дигән Йокыбай, — син мине шул елга буена чаклы илт инде.

Болан Йокыбайны яр буена китереп куйган. Елга котырып-котырып ага икән, дулкыннары аждаһа шикелле өскә сикереп тора, ди. Йокыбайның елгага карагач хәтта башы әйләнеп киткән. «Теләгемә ирешә алмам, ахры», — дигән ул, көрсенеп.

Шулай елгага карап кайгырып утырганда, дулкыннар өстендә тирбәлә-тирбәлә йөзеп аргы яктан бирге якка чыгып килүче бер Кондызны күреп алган. Кондыз бүрәнә өстенә менеп утырган да дулкыннарга күкрәген куеп йөзүен белә, ди.

— Әй, Кондыз, — дигән Йокыбай, — миңа бүрәнәңне биреп тормассыңмы икән? Бик кирәк иде.

— Алай бик кирәк булгач, мә, — дигән Кондыз. — Минем тешләр пычкы кебек, теләсә кайсы агачны «эһ» дигәнче кисеп аудара алам. Тик менә көч-куәт бераз чамалы. Әгәр бик ашыкмасаң, мин кискән агачларны яр буена ташыр идек.

— Әйдә, — дигән Йокыбай, — син кис, мин ташый торам.

Вакытны озакка сузмый, алар эшкә тотынганнар. Берсе кискән, икенчесе ташыган. Күзне бер йомып, ике тапкыр ачканчы яр буе агачлар белән тулган.

— Инде миңа китәргә дә ярыйдыр, — дигән Йокыбай.

Алар җан дуслар булып аерылышканнар. Йокыбай бүрәнәгә атланып елганың аръягына чыгып киткән. Гамь агачын бик тиз танып алган ул, чөнки бөтен агачлар төп-төз утырганда, моның башы түбәнрәк иелеп тора икән.

Инде йокламыйча таңга чаклы көтәргә генә калган. Ә йокы килә икән, чөнки юлда бик арылган булган. Зур кыенлыклар аша шушы кадәр җир килгәч йоклап китсәң, кайтып әнкәңнең күзенә ничек күренерсең? Юк, юк, йокламаска! Уяу булырга! Ә ничек?

Йокыбай болай эшләгән: якындагы бер агачның сыгылмалы ботагына менеп утырган да атынырга тотынган. Тирбәлгәндә йокысы килсә дә, курыкмаган ул, чөнки йоклаган килеш бу нечкә ботактан бик тиз егылып төшәчәксең. Ә егылып төшкәч уянасың.

Шулай итеп Йокыбай таң алдын көтеп җиткергән. Менә бермәлне әкрен генә җил исеп куйган. Гамь агачының яфраклары шыбырдашырга тотынган, һәм күзгә күренеп җимешләре зурая, тулылана барган. «Инде вакыты җитте бугай», — дип, Йокыбай гамь агачына менеп киткән. Иң биек ботактагы иң зур җимешне өзеп ашаган. Шунда ул тамырлары буйлап канының тизрәк ага башлавын, йөрәгенең катырак тибүен тойган. Йокысы да кинәт ачылып киткән. Әнисе белән туганы Елгырҗан исенә төшкән. «Минем өчен кайгыралардыр, тизрәк кайтырга кирәк. Әнә ич, мине озаткан чакта әниемнең күзләреннән нинди эре яшьләр тамды. Кайтып тизрәк шатландырыйм әле үзләрен», — дигән ул, һәм, ял да итеп тормыйча, юлга чыккан. Кайтышлый әнисе белән Елгырҗан туганына дип күп итеп кура җиләге җыйган.

Моңа кадәр Йокыбай урманда һичбер төрле җәнлекләрнең тавышына колак салмый торган булган. Ә гамь агачының җимешен ашагач аңа әллә нинди тавышлар ишетелә башлаган. Каядыр тиен елаганы колагына чалынган. Йокыбай тавыш килгән якка чапкан. Барып җитсә, ни күзе белән күрсен, бер агач ботагы яртылаш сынган да тиеннең койрыгын кыскан икән. Йокыбай агач башына менеп тиенне бу бәладән коткарган. Тиен аңа рәхмәт әйтергә дә өлгермәгән, Йокыбай ары киткән. Кайта-кайта ул тагын әллә кемнәргә ярдәм иткән: бер куянны бүреләрдән коткарып калган, өенә юл таба алмыйча елаудан күзләре шешенеп беткән төлке баласын өенә илтеп куйган.

Шулай әллә кемнәргә ярдәм итеп йөри-йөри өенә көчкә кайтып җиткән ул. Кайтып җитсә, әнисе авырып түшәккә егылган, ди. Йокыбай үзе җыеп алып кайткан кура җиләкләрен әнкәсе алдына куеп:

— Менә боларны аша әле, әнием, терелерсең, — дигән.

Улы әнисен кыстый-кыстый ашаткан, төннәрен күз дә йоммыйча баш очында утырган. Иң тәмле чишмәдән су алып кайтып, чәйләр кайнатып эчергән, һәр җан иясеннән нинди үләннең, нинди җимешнең файдалы икәнен белешкән. Шуларны җыеп алып кайтып, әнисен дәвалаган. Йокыбайның әнисе әкренләп аякка баскан, урман аланына чыгып йөри ала башлаган. Йокыбай да, Елгырҗан да бик шатланганнар.

Йокыбай күзгә күренеп үскән. Елгырҗан белән көрәшкән чакларда аста калмый башлаган. Элекке кебек көне-төне йокламаса да, ул үзен һич тә бәхетсез сизмәгән. Уйлый белүенә, бүтәннәргә килгән бәлане ишетә һәм кирәк чакта үзенең гайрәтле күкрәге белән аларны каплый алуына сөенеп яшәгән ул. Әгәр урманда йөргәндә уң колагын җиргә куеп төрле авазларны тыңлаучы пәһлеван гәүдәле берәр аю очратсагыз — курыкмагыз, ул Йокыбай булыр. Адашсагыз, сезгә ул әле юл да күрсәтеп калыр.

## БЕР МАЛАЙ ҺӘМ ИКЕ УРЫНДЫК

Борын-борын заманда, кәҗәләр сакалсыз, песиләр мыексыз, үгезләр мөгезсез, маэмайлар койрыксыз чакта яшәгән, ди, бер карт белән бер карчык. Аларның булган, ди, ике урындыклары. Бу урындыкларга бик-бик күңелсез икән. Чөнки аларны кайбер көннәрдә урыннарыннан кузгатучы да юк икән. Кем кузгатсын: карт көннәр буе сызлаган билен җылытып мич башында ята, карчык кыштыр-кыштыр казан тирәсендә кайнаша, ди.

Болыт булып көннәр агыла торган, учак булып шәфәкъ кабына торган. Төнне — көннән, язны — көздән, кышны җәйдән аермаган урындыклар. Менә шулай аркаларын стенага терәп ярым йокымсырап яшәп ятканда, карт белән карчык бер малай апкайтканнар, ди. Малай боз белән судан агып килгәндерме, таш булып таудан тәгәрәп төшкәндерме, су алганда чиләккә утырып коедан килеп чыккандырмы — ничек кенә булмасын, ул бик тере, тиктормас нәрсә икән. Алып кайткан көнне үк ята торган мендәренең почмагын тешләп өзгән дә мамыкларын аккош итеп һавага очыра башлаган. Соңгы аккошны тәрәзәдән чыгарып җибәргәч, урындыкларны күреп алган ул:

— Ә-ә, сез менә кайда икәнсез! — дигән малай һәм бер урындыкны идән буйлап өстерәп киткән. — Сез бүгеннән урындыклар түгел, кәҗә тәкәләре, — дигән ул. — Ә кәҗә тәкәләре сөзешергә тиеш.

Урындыклар сөзешү ничек була икән соң дип уйларга өлгергәнче, малай аларның берсенә берсен китереп тә дөңкегән. Урындыкларның маңгайларыннан ут чәчелгән. Әмма алар зарланмаганнар, чөнки кәҗә тәкәсе булу аларга ошап киткән. Малай аларга авырткан маңгайларын ышкып алырга да ирек бирмәгән — сөзештергән, тыңламасалар, чыбыклап ташлаган яки бездәй бармаклары белән сыртларын чеметкән.

Күмер күзле, ялкын йөзле бу малай үзенең кәҗә тәкәләреннән өйдәге бөтен нәрсәне сөздереп бетергән: кече яктагы савыт-сабалар да, стенадагы әби йөзедәй саргайган көзгә дә, сәкегә өелгән мендәр-ястыклар да калмаган. Инде чират өйнең яртысын биләп торган мичкә җиткән.

— Бу мич түгел, сихерләнгән тау, — дип аңлаткан малай үзенең кәҗә тәкәләренә, — тау артында яшел болын бар. Болын буйлап челтерәп чишмә ага. Әгәр шушы тауны сөзеп аударсагыз, әнә шул чишмәле болынга чыгачаксыз.

Кәҗә тәкәләренең уртасыннан чишмә агып яткан яшел болынга бик-бик чыгасылары килгән, һәм алар маңгайларын кызганмыйча сихерле тауны сөзәргә тотынганнар. Әмма күпме генә тырышмасыннар — тау урыныннан кузгалмаган.

— Юкка көчәнәсез, — дигән аларга мич башында ятучы карт. — Күрмисезмени, тау өстендә мин ятам. Ә минем үзем белән йөз еллык гомерем ята. Ул йөз еллык гомердә йөз пот кайгы, йөз пот шатлык бар.

Картның бу сүзләрен ишеткәч, кәҗә тәкәләре сөзешүдән туктаганнар. Ләкин күмер күзле, ялкын йөзле малай аларга тик кенә торырга ирек бирмәгән.

— Бүгеннән сез ат буласыз, — дигән ул, аларның әле берсенә, әле икенчесенә атланып. — Атларның аяклары таймасын өчен аларны дагалыйлар. Хәзер мин сезне дагалыйм.

Малай тиз арада чүкечен, кадагын күтәреп килеп җиткән. «Эһ» дигәнче атларын дагалап ташлаган. Урындыкларның берсе артлы, берсе артсыз икән.

Артсыз урындыкка малай:

— Син колын булып арттан иярересең, — дигән. Шулай дигән дә үзенең каралып пешкән чия төсле атына менеп атланган: — Әллүк!

Ат, Ат артыннан Колын томырылып урамга чапканнар. «И-ха-ха-хай», — дип кешнәп җибәргән Ат, күктәге яктылыкка, җирдәге матурлыкка исе китеп.

Күмер күзле, ялкын йөзле малай үзенең аргамагын урман юлына борган. Иң беренче алар җил белән узышканнар, җил урман юлында арып егылгач, һавадагы кошлар белән көч сынашканнар. Күмер күзле, ялкын йөзле малайның каралып пешкән чия төсле аргамагы агып яткан елгаларны сикереп кенә чыккан, каршысында таулар очраса, арт аякларына басып югарыга томырылган. Аңардан Колыны да калышмаган. Урманнарны, болыннарны кичкән алар, өч инештән, биш елгадан су эчкәннәр. Бу иркенлекне, бу

хозурлыкны ташлап берсенең дә өйгә кайтасы килмәгән. Малай Аты белән Колынын болынга җибәргән дә үзе елгага су коеныргa йөгергән.

— Ерак китмәгез, адашырсыз, — дигән ул атларына. — Мин сезне сызгырып чакырырмын.

— Ярар, — дигәннәр атлар.

Иркен болында үзләре генә калгач, алар сөенечләреннән тагын бер кешнәп җибәргәннәр. Кешнәү тавышы, урманнарга, тауларга бәрелеп, аларның үзләренә кайткан.

— Колын булып яшәү нинди күңелле! — дигән Колын.

— Ат булу да бик рәхәт, — дигән Ат. — Юкса мондый болыннарны, мондый урманнарны кайчан күрер идек без. Мин хәзер тибәм икән — тояк астымнан чишмә чыгарам, кешнәп җибәрсәм — тауларны селкетәм, чапсам — сулышымнан агачларны җиргә аударам.

— Ә мин, — дигән Колын, — мин сикерсәм, болытларга җитәм, ятып аунасам, давыл кубарам, койрык чәнчеп чаба башласам, бөтен елгаларны артта калдырам.

Алар шулай сөйләнә-сөйләнә болында йөргәннәр. Берсе типкән — чишмә чыгарган, икенчесе ятып аунаган — давыл кубарган. Берсе кешнәп тауларны селкеткән, икенчесе сикереп болытларны куркыткан.

Кешни-кешни, чабыша-чабыша күпме йөргәннәрдер, менә бермәлне күмер күзле, ялкын йөзле малайның сызгырган тавышы ишетелгән: «Фю-фю-фю!»

— Хи-хи-хи, — дип кешнәп җибәргән Колын, — без монда. Хәзер яныңа барабыз.

— Тукта! — дип боерган җилбәзәк Колынга салкын акыллы Ат. — Ашыкмый тор. Кайтмыйбыз.

— Ничек кайтмыйбыз? — дип гаҗәпләнгән беркатлы Колын. — Безне бит хуҗабыз чакыра.

— Чакырсын, — дигән Ат. — Кайтып тагын шул кысан өйгә бикләнәсең киләмени? Хәзер инде без ирекле.

— Ә малай? — дигән йомшак күңелле Колын. — Аңа бит бездән башка бик күңелсез булыр.

— Аның әбисе бар, бабасы бар, — дигән Ат.

— Юк-юк, — дигән Колын, — без кайтмасак, малай елар. Ә мин аның елавын теләмим. Әйбәт малай ул. Безне ул кәҗә тәкәсе итте, колын итте.

— Анысы шулай, — дип килешкән Ат, — малай башлы, хыялы гел яңарып тора. Мин менә шуңардан куркам да. Кем белә, бәлки, ул безне, мунча пәрие итеп, караңгы мунчага ябып куяр. Анда ята-ята йөзләребезне корым басар, тәннәребез төтенгә ысланыр, якты дөнья күрмәбез.

Атның бу сүзләреннән соң, Колын сискәнеп куйган, мондый язмышны күз алдына китерүдән сырт йоннары кабарган.

— Ярар алайса, кайтмыйбыз, — дигән ул. — Тик бездән башка малайга күңелсез булыр инде. — Малайны кызганудан Колынның күзеннән ике тамчы яшь тәгәрәп төшкән. Атның да күңеленнән нindидер икеләнүле уйлар дулкыны йөгерен узган, ләкин ул аларны бик тиз куган.

— Әгәр без шундый чакны кулдан ычкындырсак, гомер буе үкенәчәкбез, — дигән ул. — Сыпырыйк тизрәк урманга. Әнә күрәсеңме, йомшак юкәләр безгә кул изи. Без шулар астына кереп качарбыз.

Колын белән Ат чәчәкле болыннарга, шаулап аккан елгаларга, күктәге кояшка, офыктагы тау-тау болытларга берара карап торганнар да урманга таба чапканнар. «Фю-фю-фю», — дип, малайның сызгырган тавышы ишетелеп киткән. Болар туктамаганнар. Малай тагын да көчлерәк итеп сызгырган — болар һаман туктамаганнар. Ләкин урманга килеп җиттек дигәндә генә әллә нинди сихри көч аларның иңнәренә баскан, аяклар атламас булган. Колын белән Ат бер-берләренә күтәрелеп карасалар — син күр дә мин күр — болар яңадан урындыкка әйләнгәннәр. Ә малай болынның әле бер башына, әле икенче башына барып сызгырган. Урындыклар: «Без монда!» — дип аваз бирмәкче булганнар, әмма тавышлары чыкмаган, аяк очларына басып, малайга кул изәргә теләгәннәр, тик биек үләннәр аларны каплап киткән.

Малай үзенең йөгерек атларын озак эзләгән, кайвакыт урындыклар янына килеп җитәргә дә ике-өч адым гына калган. Әмма җиттем дигәндә генә, нindидер көчкә буйсынгандай кире борылып киткән.

Урындыклар үзләренең күмер күзле, ялкын йөзле малай хыялыннан башка ат та, кәҗә тәкәсе дә була алмауларын шунда гына төшенгәннәр.

Күктән әкрен генә болытлар аккан. Карурманны моңга күмеп, көне-төне кошлар сайраган, болыннарда колыннар кешнәгән, чәчәкләрнең башларыннан сыйпап җилләр искән, ләкин боларның шатлыгына урындыклар кушыла алмаганнар.

Ә көннәр үткән дә үткән. Кәҗәләргә сакал, үгезләргә мөгез, песиләргә мыек, этләргә койрык чыккан, бары тик урындыкларга гына хыял канатлары үсмәгән.

## ТИЕН МАЛАЕ ТИМ-ТИМ

Карурманның карасында, җир белән күк арасында, бер биек агач башында яшәгән, ди, тиен малае Тим-Тим. Көне буе ботактан ботакка сикереп уйнаган ул. Әллә үзе бик шаян һәм шук булганга дуслары бик якын иткән аны. Тим-Тим агачның иң-иң югары ботагына менеп бер сызгыруга, аның барлык дуслары җыелып җитә икән.

— Йә, нәрсә уйныйбыз? Качышлымы, сикерешлеме?

— Бишташлымы, туплымы?

Чикләвекне бишташ итеп бишташлы да уйнаганнар алар, качышлы да уйнаганнар, сикерешле дә. Ә инде бөтен төрле уеннар уйналып беткәч, дуслары таралышкач, Тим-Тим, агач ботагына чалкан ятып, болытларга чикләвек ыргыта башлый икән.

Тим-Тим белән янәшә агачта гына Кар-Кар дигән ана карга дөнья көтеп ята икән. Кар-Кар түти көне буе нидер эшләгән: әле оясын төзәткән, әле балалары өчен җимгә чапкан, әле үзенең канатларын чистарткан. Көннәрдән бер көнне Кар-Карның кинәт кенә бик каты теше сызлый башлаган.

— Әй, Тим-Тим, — дип кычкырган ул, теш арасыннан сүзләрен көчкә-көчкә чыгарып. — Беразга минем балаларымны карап тора алмассыңмы? Тук-тук Тукранычка барып тешне суыртып кайтырмын дигән идем.

— Бар, бар, рәхәтләнеп суырт, — дигән Тим-Тим. — Балаларыңны карармын, ояңны туздыртмам.

— Менә рәхмәт, — дигән Кар-Кар. — Юкса кемгә әйтергә икән дип иртәдән бирле баш вата идем.

— Мин барында бер дә кайгырма, Кар-Кар түти.

— Хәзер кайгырмыйм инде, күңелем тынычланды, — дигән Кар-Кар. — Син бик әйбәт бит, сүз тыңлаучан. Минем балаларым да синең кебек әйбәт булып үсәрләр. Мин аларга кичләрен тиен малае Тим-Тим турында хикәятләр сөйләрмен, Тим-Тим шикелле ярдәмчел булыгыз, диярмен.

Тим-Тим, бу сүзләрдән бик канәгать булып:

— Бүтәннәргә ярдәм итү рәхәт кенә ич ул, — дигән.

Кар-Кар балаларының авызларына җим каптырган да: «Карагыз аны, Тим-Тим абзагызның сүзен тыңлагыз, бик чыркылдашмагыз, юкса әнә теге тауда бөркетләр мыжлап тора. Тавышыгызны ишетеп килерләр дә җитәрләр», — дигән.

— Якын гына килеп карасыннар, — дигән Тим-Тим. — Мин аларның чикләвек белән бәреп башларын тишәрмен. Әйе, шулай, Кар-Кар түти, мин ике уйлап тормам.

Тим-Тимнең шул сүзләреннән соң Кар-Кар, тәмам тынычланып, теш врачы Тук-Тук Тукранычларга киткән. Кар-Карның очып китүен генә көткәндәй, каяндыр куаклар арасыннан куян малае Төзкойрык килеп чыккан. Килеп чыккан да, яңа гына киселгән агач төбенә басып, төрлечә сикерергә, биергә тотынган.

— Нишлисең анда, әй, Төзкойрык? — дип сораган Тим-Тим.

— Физзарядка ясыйм бит, күрмисеңмени? — дигән Төзкойрык.

— Нигә ясыйлар соң ул физзарядканы? — дигән Тим-Тим.

— Һи, надан, — дигән аңа Төзкойрык. — Шуны да белмисең. Физзарядканы аны көчле булыр өчен ясыйлар.

— Ә көч нәрсәгә кирәк? — дигән Тим-Тим. Чөнки ул моңа кадәр иң кирәк нәрсә җитезлек, җиңеллек дип санап йөргән булган.

— Син тормыштан бөтенләй артта калгансың икән, — дигән Куян малае Төзкойрык. — Көч нигә кирәк, имеш. Синең әле, бәлки, теге түгәрәк аланда көн саен батырларның көч сынашуын да ишеткәнең юктыр?

— Батырларның көч сынашуын? Нигә сынашалар соң ул көчне?

Тим-Тимнең бу соравына Төзкойрыкның җен ачулары чыккан.

— Томана, — дип сүгеп ташлаган ул Тим-Тимне. — Көчне ни өчен сынашканнарын да белми яшә инде бу дөньяда!

— Соң әйт, әйткәч белермен.

— Әйткәч аны тинтәк тә белә, — дигән Төзкойрык.

— Йә, әйт инде, — дигән Тим-Тим, — әйтсәң, үзеңә бер уч чикләвек төше бирәм.

— Йә, ярар, әйтсәм әйтим алайса, китер чикләвек төшеңне. Тик син, чикләвек төшенә сатылды бу дип уйлама. Дуслык хакына гына әйтәм.

— Йә, сузма инде.

— Көчне аны, дустым, беренче чыгар өчен сынашалар, — дигән Төзкойрык.

— Ә беренчелеккә чыккач ни була? — дигән Тим-Тим.

— И-и, бу тиклем дә аңгыра булырсың икән; бөтенесен җиңгәч, син дөньяда иң көчле буласың. Ә көчлеләргә бөтенесе баш ия.

— Баш ия?

— Әйе, баш ия!

— Ә нигә ияләр соң башны?

Тим-Тимнең бу соравы Төзкойрыкны тәмам чыгырыннан чыгарган:

— Аңгыра баш, тинтәк, ахмак, — дип тезеп киткән ул. — Сиңа аңлатып торган мин юләр. Башны нигә ияләр, имеш. Менә хәзер минем каршыма килеп аюлар, бүреләр баш исен иде әле.

— Шуннан? — дигән Тим-Тим, һаман берни аңламыйча. Чөнки ул моңа кадәр дөньяда барлык җан иясе дә тигез булырга тиеш дип санаган булган. Төзкойрык Тим-Тимнең бу кадәр беркатлылыгыннан хәтта көнләшеп куйган.

— Ярар, — дигән ул, — беренчелекне барыбер син бервакытта да ала алмаячаксың, һич югы көрәш карап торырсың. Әйдә, көрәш мәйданына киттек. Аюның бер-ике кабыргасын сындырып кайтыйм әле. Аннан соң белерсең дустыңның кем икәнен. Әйдә, киттек.

Тим-Тим Төзкойрык янына сикереп төшкән. Ул Кар-Карның оясы турында бөтенләй оныткан. Төзкойрык Тим-Тимне култыклап алган да болай дип җырлап җибәргән:

Әйдә киттек көрәшергә,
Бер җиңеп кайтыйк әле:
Аю чыкса мәйданнарга,
Баш аркан атыйк әле.

Төзкойрыкның җырына Тим-Тим дә кушылган. Шулай урман яңгыратып җырлап барганда, боларга керпе кызы Энәкәй очраган.

— Кая барасыз, егетләр? — дигән Энәкәй. Үзләрен зурлап «егетләр» дип әйткәнгә Төзкойрык белән Тим-Тимнең башлары күккә тия язган.

— Без кая барабызмы? — дигәннәр алар, бер-берсенә серле карашып. — Без көрәш мәйданына, түгәрәк аланга барабыз. Бүренең билен сындырып, аюны аланда аунатып, боланны мөгезе белән җир сөрдереп кайтырга дип чыктык әле. Шулаймы, Тим-Тим?

— Шулай, Төзкойрык.

— Ай-яй, егетләр, бигрәк гайрәтле икәнсез.

— Мин ни өчен төн йокыларымны жәлләми физзарядка ясадым? — дигән Төзкойрык, күкрәк кагып.

— Физзарядка?

Моның нәрсә икәнен Энәкәйнең дә ишеткәне юк икән.

Энәкәйгә Тим-Тим физзарядканың ни икәнен болай дип аңлатып биргән:

— Физзарядка шундый нәрсә, шундый нәрсә. Әгәр дә мәгәр, кем дә кем, ничек тә булса...

— Бик озынга китте синең сүзең, — дигән Энәкәй.

— Әгәр дә мәгәр, — дип дәвам иткән Тим-Тим, — кем дә кем шул физзарядка дигән нәмәрсәне ясый, шундук моның гайрәте ташый башлый, ди. Әйе, ышанмасаң, әнә Төзкойрыктан сора.

— Дөрес аңлатасың, дускай, — дигән Төзкойрык һәм шап иттереп Тим-Тимнең җилкәсенә суккан. — Әгәр дә мәгәр физзарядка ясасалар, тычканнар мәчене сугып егар, куяннар аюны бишкә бөкләп өненә кертеп салыр иде. Белдеңме инде физзарядканың ни икәнен?

— Белдем, — дигән Энәкәй, чын-чынлап куркуга калып. — Тик сез, егетләр, физзарядка атлы тылсым беләбез дип кенә алай каты кыланмагыз инде. Бүреләрнең билен сындырып бетерсәгез, аюларны аланда аунатып мәсхәрә итсәгез, урманда кем генә калыр?

— Менә син калырсың, Энәкәй, — дигән Төзкойрык. — Тагын Тим-Тим белән без калырбыз.

Төзкойрык Тим-Тимнең җилкәсенә кулын салган да тагын җырлап җибәргән:

Без урманнан үткән чакта,
Дер калтырый бүреләр.
Дер калтырамый карасын —
Без бит менә нindиләр!

Төзкойрык белән Тим-Тим күкрәк кагып куйганнар. Ә Энәкәй ныклап ук курка башлаган.

— Әрәм итмәгез инде аю-бүреләрне, — дип ялварырга тотынган ул. — Алар да җан иясе бит.

— Әрәм итмәскә дисең инде алайса? — дигән Төзкойрык. — Әллә соң чынлап та бер юлга аю-бүреләрне калдырып торыйк микән, Тим-Тим?

— Калдырыйк, үзләре генә көрәшсеннәр, — дигән Тим-Тим. — Без беразга агач күләгәсендә ял итик тә өйгә кайтырбыз.

— Менә нинди әйбәт, менә нинди акыллы икәнсез сез, — дигән Энәкәй, сөенеченнән сикерә-сикерә. — Әйдәгез, безгә керик, салкын әйрән эчеп чыгарсыз. Ял итәрсез.

Тим-Тим белән Төзкойрык бик рәхәтләнеп риза булганнар. Керпе кызы Энәкәй аларны төрле-төрле сыйлар белән сыйлаган. Озак кына кунак булып, ныклап хәл җыйгач, ике дус өйләренә кайтып киткәннәр.

Тим-Тим җырлый-җырлый өенә кайтып килгәндә ерактан ук кемнеңдер елаганын ишетеп алган. «Кар-Кар түти тавышы бит бу, — дип уйлаган ул, — әллә тешен бик авырттырып алдылар микән?»

— Һей, Кар-Кар түти, нигә елыйсың? — дип сораган ул, Кар-Кар түтигә якынлашкач. — Әллә тешеңне бик авырттырып суырдылармы?

Кар-Кар түти аңа берни дә эндәшмәгән, хәтта Тим-Тимгә борылып та карамаган. Тим-Тим тәмам аптырашка төшкән.

— Йә инде, Кар-Кар түти, — дип юатырга тырышкан ул күршесен. — Төзәлер әле. Бервакыт минем дә тәпиемә шырпы кадалган иде, тора-бара бетте. Хәзер мин менә ничек сикерә алам.

Тим-Тим ботактан-ботакка сикереп күрсәткән. Кар-Кар түтинең күңелен ачар өчен төрлечә мәтәлчекләр атып караган, әмма Кар-Кар түти һаман елавын белгән.

— И-и, балакайларым минем, ерткыч авызына ризык булыр өчен дип чыгарган идеммени мин сезне?! Бигрәкләр дә матурлар иде бит бәбекәчләрем. Җим алып кайтып оя читенә басуга, сап-сары авызларын ачып муеннарын суза башларлар иде матуркайларым. Өчесенә өч матур исем дә сайлап куйган идем. Никләр генә киттем икән — никләр генә шул вөгъдәсез Тим-Тимгә ышандым икән?

Кар-Карның шулай дип елавын ишеткәч кенә, Тим-Тим эшнең нәрсәдә икәнен аңлаган. Кар-Кар түтине шундый авыр хәлгә куюына ул бик-бик кыенсынган.

— Кар-Кар түти, — дигән ул, ялварулы тавыш белән, — берүк гафу итә күр. Яңадан гел уяу булырмын, Кар-Кар түти. Бу юлга гафу ит тә елама.

— Менә син гафу ит дисең, — дигән Кар-Кар түти Тим-Тимгә. — Йөрәгемдә канлы яра була торып, ничек инде мин сине гафу итә алыйм?

— Яраң бер төзәлер әле, Кар-Кар түти.

— Бөркет авызыннан балаларым исән-сау чыкса гына яраларым төзәлер минем. Менә шул вакытта мин сине гафу итә алырмын. Ә хәзергә мин сине берничек тә кичерә алмыйм.

— Соң бит, — дигән Тим-Тим, — мин сиңа мондый яманлыкны юри эшләмәдем. Әгәр Төзкойрык килеп чыгып, мине көрәш мәйданына чакырмаган булса, мин синең ояң яныннан китмәгән булыр идем.

— Яманлык нинди генә нияттән эшләнсә дә яманлык инде ул. Әгәр дә аучы бөркеткә атам дип сиңа тидерсә, сиңа җиңел булыр микән?

Кар-Кар шулай дигән дә тагын елый башлаган. Әле күккә менеп, әле җиргә төшеп елаган ул. Аның күз яшьләре тамган җирдә үләннәр көйгән, гөлләр каралган, чишмәләр тозланган. Берничә көн шулай елап урман әйләнгәннән соң, ул ятим калган оясын ташлап каядыр китеп барган.

Ә Тим-Тим беркадәр вакыт күңелсезләнеп йөргән дә Кар-Кар турында бөтенләй оныткан. Ул тагын элеккечә ботактан-ботакка сикереп уйнаган, агач башында атына-атына җырлаган. Шулай сикерә-сикерә уйнаганда, ул көннәрдән бер көнне кайдадыр еракта чинап-чинап куйган тавыш ишеткән. Тавыш килгән җиргә барып караса — ни күрсен — куак төбендә төлке тәгәрәп-тәгәрәп мәш килә икән.

— Нәрсә булды, Көлтә койрык? — дигән Тим-Тим.

— Менә сунарчы капкынына килеп каптым, — дигән Көлтә койрык. — Капкынга эләккән аягым бик сызлый, шуны һич ычкындыра алмыйм.

— Бәлки, мин ярдәм итә алырмын, — дигән Тим-Тим, — минем тешләр бик үткен. Шартлаттым — өздем булыр капкыныңны.

— Син ярдәм итә алырсың, — дигән төлке, койрыгы белән күз яшьләрен сөртеп, — тик үткен теш белән генә эш барып чыкмастыр, монда акыл кирәк.

— Анысы кемдә бар икән соң?

— Капкын ача торган серне минем ерак туганым Акылбай абзый гына белә. Зинһар, барып әйт Акылбай абзыйга. Килсен, коткарсын ул мине.

— Барабыз аны, әйтәбез аны, — дигән Тим-Тим, ике уйлап тормыйча һәм агач башына сикереп менеп китә дә башлаган.

— Тукта, — дигән Көлтә койрык, — син бит әле аның кайда торганлыгын белмисең. Юлын өйрәтим үзеңә.

— Өйрәт алайса.

— Акылбай абзыйларның өйләре урманның уң ягында, аланның сул ягында. Кыек та барма, туры да барма. Елга күрсәң, сикереп үт, болын күрсәң, йөгереп үт. Юлың җуйсаң, айдан сора, ай юл күрсәтә алмаса, барып җиткәч, аны Акылбайдан сора. Менә шул, ә хәзер тизрәк чап.

Тим-Тим Көлтә койрыкның өйрәтүе буенча юлга чыгып киткән. Кыек та бармаган, туры да бармаган. Әнә шулай бара торгач, бер бик матур күл буена барып чыккан. Ә анда, мин сиңа әйтим, эре-эре чуртаннар яр читендәге комда кызынышып яталар икән. Тим-Тимнең мондый хәлне бер дә күргәне булмаган, шуңа күрә бик гаҗәпсенеп:

— Нишлисез сез? — дип сораган.

— Комда кызынабыз бит, — дигәннәр чуртаннар.

— Ә нигә кызыналар соң ул комда?

— Чыныгырга! — Чуртаннар, шуны да белмисең, дигән шикелле аңа сәерсенеп карап куйганнар. -- Әйдә, сузылып ят безнең янга, бик рәхәт нәрсә ул кояшта кызыну.

Тим-Тим тиз генә күлмәген салып аткан да, ап-ак корсагын кояшка күрсәтеп, кайнар комга сузылып яткан. Кайнар ком аны бермәлгә куырып алган.

— Пешерә бит бу, — дигән ул чуртаннарга, — ничек түзәсез бу кадәр кызуга?

— Башта гына пешерә ул, — дигәннәр чуртаннар, — бер өйрәнгәч үзеңнең дә китәсең килмәс әле. Менә безнең сыртлар нинди кап-кара булып бетте инде. Хәзер безгә кыш көне бернинди томау да төшмәячәк. Ә теге грипп дигән явыз нәрсә безнең каралган сыртларыбызны күргә, әллә каян күлебезне урап узачак.

— Ә мин ул грипптан болай да курыкмыйм, — дигән Тим-Тим.

— Синең шул туның җылы, ә безнең өс-башны үзең күреп торасың — менә бит нинди юка, — дигәннәр чуртаннар.

Тим-Тим чуртаннарны кызганып куйган. Аның туны чынлап та бик җылы шул. Ояңа кереп ятасың да койрыгыңны ябынып йоклыйсың.

Ул шулай уйлый-уйлый комда аунаган. Чуртаннарга төрлечә сикереп күрсәткән. Чуртаннар аның бу кадәр оста итеп сикерә белүенә хәйран калып авызларын ачканнар. Ә Тим-Тимгә шул гына кирәк тә: ул яңадан-яңа кызыклар уйлап тапкан. Чуртаннар, казыктай тешләрен ыржайтып, шырык-шырык көлгәннәр.

Тим-Тим үзенең булдыклылыгына үзе сокланган. Чуртаннарга охшарга тырышып, әллә ниләр кыланган. Комда да чуртаннардан ким кызынмаган ул. Артык пешерә башласа, чуртаннар белән суга чумган. Чуртаннарның сыртына атланып күлнең бер ягыннан икенче ягына йөзүләр аңа әйтеп бетергесез рәхәтлек биргән. Ул үзенең кая баруын, ни өчен бу күл буена килеп чыгуын тәмам онытып торган. Кояшның кызуы сүрәнләнеп, салкынча җил исә башлагач кына Көлтә койрык исенә төшкән аның. Исенә төшкән дә йөрәге «жу» итеп куйган.

— Их, нишләдем мин тагын? — дигән ул һәм ашыга-ашыга киенә башлаган.

Чуртаннар аңа:

— Тагын кил, Тим-Тим, бергә-бергә кызынырбыз, — дип калганнар.

— Ярар, — дигән Тим-Тим. Шулай дигән дә китеп барган. Караңгы төшә башлаганлыктан юлын да җуйган ул. Шунда Көлтә койрыкның: «Юлны җуйсаң айдан сора», — дигән сүзләре хәтеренә килгән. Ботактан-ботакка сикерә-сикерә иң биек агач башына менеп озак кына айны күзәткән Тим-Тим. Ай болытлар арасында чишенеп, күлмәкләрен юып ята икән, шунлыктан бик озак чыкмый торган. Тим-Тим сызгырып җил кузгатканнан соң гына, болытлар төрле якка таралышып киткәннәр. Ай, үзенең юеш күлмәген алдына каплап, Тим-Тимгә кычкырган:

— Йә, нәрсәгә сызгырынасың? Нишләп йокларга ятмыйсың?

— Айсылу, — дигән Тим-Тим, — миңа юл гына өйрәтче! Акылбай абзыйларга ничек барырга?

— Нәрсәгә кирәк булды әле сиңа Акылбай? — дигән Ай.

Тим-Тим бутала-бутала эшнең нәрсәдә икәнен аңлата башлаган. Шул вакыт ул, шарт-шорт басып килүче аяк тавышлары ишетеп, артына борылган. Ә анда — син күр дә, мин күр — җилкәсенә Көлтә койрыкны салып, аучы өенә кайтып бара икән. Тим-Тимнең, Көлтә койрыкны жәлләүдән күзләре яшьләнгән. «Яңадан болай ваемсыз булмам, биргән вәгъдәмне үтәрмен», — дип ант иткән ул үз-үзенә.

Җитез җилләр канатына утырып көннәр оча торган. Әкрен-әкрен Тим-Тим бу кайгыларын оныткан. Уйнаган, шаярган, дөнья бетереп чапкан. Тагын ул әллә кемнәргә вәгъдә биргән, тагын сүзендә тора алмыйча дусларын, якыннарын кыен хәлгә куйган. Бигрәк тә болан кызы Биксылуны авыр хәлдә калдырган ул.

Ә бу хәл болай булган. Тим-Тим гадәттәгечә агачтан агачка сикереп уйнап йөргәндә, бер кечкенә ачыклыкта кая барырга белмичә аптырап торучы болан кызы Биксылуны күргән.

— Нишләп торасың анда, Биксылу? — дигән аңарга Тим-Тим.

— Адаштым, — дигән Биксылу. — Әнкәмне нindiдер ике аяклы явыз җанварлар куып китте. Ул миңа пышылдап кына: «Шушында тор, бераздан үзем килеп алырмын», — дигән иде. Менә өч тапкыр кояш чыгып, өч тапкыр батты инде, һаман әнкәем юк.

— Теге ике аяклы җанвар дигәнең — аучы булгандыр ул, — дигән Тим-Тим. — Кулында саргылт саплы, кара башлы таягы юк идеме?

— Бар иде. Әллә нинди коточкыч тавышлар чыгара торган таягы да бар иде.

— Алайса, әниеңне көтмә инде син, — дигән Тим-Тим.

Биксылу еларга ук тотынган.

— Ярар, елама әле, — дигән Тим-Тим. — Бәлки, ул үзе сине эзләп йөридер. Хәзер мин агач башына менәм дә әниеңне караштырам. Әниең күренмәсә, бәлки, берәр туган-тумачаңны табарбыз. Мин барында югалмассың, Биксылу.

— Рәхмәт, Тим-Тим абзыкай, — дигән Биксылу, яшьле күзләрен сөртеп.

Үзенең шундый әйбәт эш эшләвенә сөенеп, Тим-Тим күкрәк кагып куйган:

— Без менә шундый инде, — дигән ул, — ә син елап торасың. Хәзер синең әниеңне табарбыз. Ә син шушыннан беркая да китмә.

— Юк, китмим, — дигән Биксылу. — Син әниемне күрсәң, миңа килеп әйтерсең.

— Әйтермен.

Тим-Тим китеп барган. Ә Биксылу аны бер көн көткән, ике көн көткән. Бәлки әле, биш көн дә көткән булыр иде, әмма бер кара төндә бу урман ачыклыгына бик алама ач бүре килеп чыккан.

— Кабып йотам мин сине, — дигән ул, ач күзләрен елтыратып, — минем инде ике атна ашаганым юк.

— Кабып йотмый торсаң иде бераз, — дигән Биксылу, — мин әниемне бик сагындым. Менә шушында ничә көн кузгалмыйча да көттем инде аны.

— Моңынчы килмәгәч — аның килмәве инде алайса, — дигән ач бүре. — Исән булсалар, аналар үзләренең балаларын алай озакка ташлап китмиләр. Кабып йотам инде мин сине, Биксылу.

— Тагын бер генә көн түз инде, бүре абзый, — дигән Биксылу. — Әгәр тагын бер көннән әнием яки Тим-Тим килмәсә, кабып йотарсың.

— Ярый алайса, — дигән ач бүре, — ачыгуын, әлбәттә, бик ачыктым. Әмма ләкин болай әйбәтләп сорагач, тагын бер көнгә түзәрмен. Тик шуны истә тот, Биксылу: тегеләй-болай хәйләләмәскә!

— Нинди хәйлә ди ул, бүре абзый, — дигән Биксылу, — авызыңны ачып торырсың, үзем үк кереп китәрмен. Әни булмаса дөньяда яшәүнең барыбер кызыгы юк!

Ач бүре белән Биксылу арка терәшеп ятып йоклаганнар. Биксылуның әнисе икенче көнне дә килмәгән. Инде тәмам караңгы төшкәч, Биксылу ач бүрегә:

— Әйдә, кабып йот мине, — дигән.

— Әллә соң башка җирдән берәр азык эзләп карыйм микән? — дигән ач бүре. — Бергәләп йоклагач, хәзер син миңа туганым кебек тоела башладың. Ашарга кызганыч үзеңне.

— Син кызганма, аша, — дигән Биксылу, — син ашамасаң, берәр тук бүре килеп ботарлар барыбер. Ә минем комсыз нәфесен басар өчен генә ботарлаучы тук бүре корбаны буласым килми. Аша әйдә мине. Исән калырсың, ичмасам. Берәр вакыт әниемне урманда бүреләр эзәрлекләвен күрсәң, коткарырга тырыш.

— Ярый инде алайса, — дигән ач бүре һәм Биксылуны кабып йоткан.

Сез инде, әлбәттә: «Ә Тим-Тим кайда йөргән соң?» — дип сорарсыз. Әйе, Тим-Тим Биксылу яныннан киткәч, берничә биек агач башына менеп караган, — әмма һичбер җирдә болан кызчыгының әнисен күрмәгән. Шунда, урман янындагы бер басуда, әрлән малайлары качыш-качыш уйнап йөриләр икән, Тим-Тим урманда ялгыз калган Биксылу турында бөтенләй онытып, әрлән малайлары белән качышлы уйнарга тотынган. Әрлән малайлары бу уенга шулкадәр остарып җиткәннәр, ди, мин сиңа әйтим, әллә кайдагы чокыр-чакырларга качалар да бетәләр икән. Тим-Тим аларны эзләп хәлләрдән тайган. Ә әрлән малайлары, Тим-Тим күзен йомып торган арада, үзләренең ояларына кереп посалар икән дә, чыгарга бөтенләй онытып, ояларында йоклап ук калалар икән.

Тим-Тим берничә көн уйнап хәлдән тайгач, ачыккач кына Биксылуга биргән вәгъдәсен исенә төшергән. «Их, тагын нәрсә эшләдем инде мин, — дигән ул, чын күңелдән үкенеп. — Тизрәк Биксылуның әнкәсен эзләргә кирәк».

Шулай дигән дә агач башына сикереп менгән Тим-Тим. Бер озын кураны күзәткеч торба итеп як-ягына караган. Шунда аның күзенә иреннәрен ялый-ялый килүче бер бүре чалынган.

— Әй, бүре! — дип кычкырган ул, — берәр җирдә боланнар очратмадыңмы?

— Юк, боланнар очратмадым, — дигән бүре, — әмма ләкин бер болан баласы белән сыйланырга туры килде.

— Ах, оятсыз, — дигән Тим-Тим, — син Биксылуны ашагансыңдыр әле.

— Шуны ашадым шул, әллә син аның әнисен эзләргә китүче Тим-Тимме?

— Әйе, мин —Тим-Тим.

— Сине бик көткән иде Биксылу, — дигән бүре һәм китеп барган. Тим-Тим үзенең шундый вәгъдәсез булуына ачуы килеп, өенә кайтып киткән. «Моннан соң үлсәм дә вәгъдәмә тугрылыклы булырмын», — дип антлар эчкән.

Әмма берничә көн үтүгә, бу антын да оныткан. Тагын шулай төрле уенга мавыгып яши башлаган. Тик, ни хикмәттер, соңгы вакытта аның дуслары бетеп киткән. Куян малае Төзкойрык та аның белән уйнамаган.

Керпе кызы Энәкәй исә аны күрүгә тизрәк өенә кереп китү ягын караган. Ә Кар-Кар түтинең кардәш-ырулары Тим-Тимне бөтенләй читләтеп үткәннәр. Шулай итеп Тим-Тим карурманда япа-ялгызы калган. Ә ялгызы бер уенның да кызыгы юк икән.

Беркөнне ул юлда Төзкойрыкны очраткан да:

— Әйдә безгә керәбез, үзеңне бик тәмле чикләвек белән сыйлармын. Аннары бергә-бергә уйнарбыз, — дигән.

— Рәхмәт, чикләвегеңне үзең генә аша, — дигән Төзкойрык. — Мин вәгъдәсезләр белән дуслашмыйм.

Төзкойрык китеп баргач, Тим-Тим бик озак басып торган. «Минә ни өчен читләшәләр икән аңардан! Инде нишләргә?»

Өендә байтак вакыт кайгырып яткан Тим-Тим. Аннары сикереп торып: «Әй, уйнамасагыз бик исем киткән иде, — дигән. — Менә мин сезгә үземнең кем икәнне күрсәтермен әле».

Карурманны шаккатырырлык берәр нәрсә эшлисе килгән Тим-Тимнең. Тик нишләргә? Шул соравына җавап эзләп, карурман буйлап сәяхәткә чыгып киткән ул. Бара икән шулай, бара икән, бара торгач, өй салып ятучы кырмыскалар янына килеп чыккан. Кырмыскалар җыйнаулашып салам, кура ише нәрсәләр ташыйлар икән.

— Кая, үзегезгә ярдәм итим әле, бу саламның мин бер учын берьюлы күтәрә алам. Ә сез аның берсен әллә ничәү җыелып өстерисез.

— Рәхмәт, ярдәмең кирәкми, — дигәннәр кырмыскалар. — Үз сүзендә тормаганнарга без эш кушмыйбыз.

Кырмыскалар шуның белән сүзне беттегә санап янә үз эшләренә тотынганнар.

— Эшләтмәсәгез бик исем китми әле, — дигән Тим-Тим. — Беләсегез килсә, мине әллә кайларда куш куллап көтеп торалар.

— Алайса, көткән җиргә кит, — дигәннәр кырмыскалар.

Тим-Тим юл капчыгын асып китеп барган.

Бара икән шулай, бара икән, бара торгач, имәннән чикләвек җыючы балаларга юлыккан бу. Малайларның иң йөрәклеләре дә агачның башына ук менеп җитә алмый икән. Тим-Тим юл капчыгын җиргә куйган да сикереп имән башына менеп киткән.

— Ярдәм итим әле үзегезгә, — дигән ул, — югыйсә чикләвекләрегезнең яртысы агачында кала. — Тим-Тим учлап-учлап чикләвек сипкән. Ләкин бер бала да аның чикләвегенә кагылмаган.

— Алыгыз, ал, — дигән Тим-Тим, — сезнең өчен ыргытам бит мин аларны.

— Безгә вәгъдәсезләрнең чикләвеге кирәкми, — дигәннәр балалар.

Тим-Тимнең бик нык хәтере калган. Ярдәмнән баш тарткан кешеләрне һич аңламаган. Юри генә кыланалардыр дип уйлаган. Чикләвек җыючы балалар яныннан киткәч тә бик күпләргә булышырга теләгән белдергән. Хәтта әҗәл белән тартышып ятучы Ябалак та аның ярдәмен алырга теләмәгән.

— Бер уч су китереп авызыңа салыйм, бәлки, рәтләнерсең, — дип караган аңа Тим-Тим.

— Юк, юк, — дигән Ябалак, — су китерәм дип китәрсең дә онытырсың. Ә мин өметләнеп көтеп ятармын. Син суга дип киткәч, мин йомышымны башкаларга да әйтә алмам. Берәр ышанычлырак ярдәмче килеп чыгар әле. Ә син бар, юлыңда бул.

Тим-Тим, аякларын көчкә сөйрәп, өенә кайткан. Өендә дә һич ямь таба алмаган ул. Ябыккан, тамактан язган. Тәрәзәдән карап ята-ята күзләре талган. Шулай бик озак ята торгач, ул, катгый итеп:

— Болай яшәү мөмкин түгел, китәргә кирәк моннан, — дигән. — Башка җирдә мине белмиләрдер әле. Яңа урманда яңа дуслар табармын. Аларны инде мин бервакытта да андый кыен хәлгә куймам. Яңа дусларымның ышанычын яулар өчен бөтенесен эшләрмен.

Шулай дигән дә, туып үскән урманы белән саубуллашып, юлга чыгып киткән Тим-Тим. Чынлап та, ул яңа җирдә яңа дуслар тапкан. Бөтен тырышлыгын куеп аларның ышанычын яулаган. Тамагы тук, өе җылы, ди, Тим-Тимнең. Тик күңелендә мәңге таралмый торган сагышы гына аны бар яктан да бәхетле итәргә мөмкинлек бирми икән. Ул нинди мәңге таралмый торган сагыш соң дисезме? Туган илен сагыну сагышы ул, дуслар. Шул сагышын таратыр өчен Тим-Тим, төннәрен барлык дуслары йоклап беткәч, кайчандыр үзенең яшьлеге үткән карурман ягына карап болай дип җырлый икән:

Шатлык яшем тамган җирем
Калды инде, калды инде.
Кайгы яшем тамган җирем
Калды инде, калды инде.
Шул якларга карый-карый,
карый-карый
Күзкәйләрем талды инде,

талды инде.
Өметләрем дөрли-дөрли
Янды инде, янды инде.
Йөрәгемә кара каннар
Sауды инде, сауды инде.
Туган илдән истәлеккә,
истәлеккә
Сагышым гына калды инде,
калды инде.

Инде без дә Тим-Тим белән саубуллашыйк. Сагышлансын, моңлансын. Сагыш һәм моң җанны сафландыручы саф чишмә ул. Бәлки әле, безнең Тим-Тимебез, җаны тәмам сафлангач, моң һәм җыр канатларына утырыр да туып үскән карурманына кайтыр. Күңеле сафланганын күргәч, бәлки, дуслары да аңардан баш тартмас. Әйе, мөгаен, шулай булыр.

## СӨРМӘКҮЗ

Төлке һәр көнне ау сәфәренә чыгып киткәндә, бердәнбер кызы Сөрмәкүзгә болай ди икән:

— Кызым, кара аны, алай-болай уйнарга чыксаң, үзеңнең кем икәнлегеңне белеп йөр. Әллә нинди алама куян малайларына иярмә. Дәрәҗәң төшәрлек булмасын. Әнә бит син нинди матур, нинди сылу. Акылың, зиһенең турында әйтеп тә тормыйм. Әгәр инде бик уйныйсың килә икән, Аюҗан абзаңның балалары беләнрәк уйнарга тырыш.

— Алар бит, әни, уйный белмиләр, — дигән Сөрмәкүз, — беркөнне Аюҗан абзыйның теге Камытаягы койрыгымны өзеп чыгара дип торам. Тарта да тарта, тарта да тарта. Ярый әле ычкынып өлгердем. Хәзер мин аның белән уйнарга теләмим.

— Син, кызым, дөньяның серләрен белеп бетермисең әле. Аюҗан абзаң урман башлыгы, ә башлыкларның күзенә чалынгалап тору хуп. Вакыт ул үтә дә китә: менә үсеп җитәрсең, эшкә урнаштырырга кирәк булыр үзеңне. Әйе, кызым, Аюҗан малае Камытаякның нинди икәнлеген мин яхшы беләм, ләкин нишләмәк кирәк: юләргә — син акыллы, ямьсезгә син матур дияргә туры килә. Шулай дими генә югары күтәрелеп булмый. Ә мин синең зур урында эшләвеңне телим, кызым.

— Ә зур урында эшләгәч ни була? — дип сораган Сөрмәкүз.

— Зур урында эшләсәң, кызым, көн саен минем кебек азык эзләп чыгып чабарга туры килмәячәк. Ул чагында сиңа ризыкның тәмлесен, киемнең матурын өеңә китереп бирәчәкләр.

— Кемнәр?

— Кемнәр дип, зур урынга утыра алмаганнар инде.

— Анысы әйбәт икән, — дигән Сөрмәкүз.

— Әйбәт шул, — дигән әнкәсе. — Йә, ярый, кызым, мин әйткәннәрне исеңнән чыгарма. Аюҗан малае Камытаякны үпкәләтмә. Син акыллы, син матур дип әйт.

— Ямьсез һәм юләр булса дамы?

— Ямьсез һәм юләр булса да. Чөнки ул синең сүзләреңне өенә кайткач, һичшиксез, эти-әнисенә әйтәчәк. Ә эти-әниләре улларының һәрбер сүзен күңел түрләренә сала барачаклар. Дөнья шулай ул, кызым. Ә хәзер мин киттем, акыллы бул.

Төлке, ау сәфәренә чыгып киткәндә, кызына һәр көн әнә шундый сүзләр тукыган. Сөрмәкүз экрен-экрен ямьсез аю малаена — сылукай, усал бүре кызына акыллыкай дияргә өйрәнгән. Камытаяк кайвакыт аның авырттырып-авырттырып колагын тешләсә дә яки койрыгын тартса да түзгән, еламаган. Хәтта әле яшь аралаш булса да көләргә тырышкан.

Әллә көн саен колагыннан тартып торганга, Сөрмәкүз ел үсәсен ай үскән. Ул тагын да сылуланган, чибәрләнгән. Бервакыт Сөрмәкүзне куян кызы Гөлгел күреп алган да:

— Сөрмәкүз, син шундый сылу, син шундый чибәр, әйдә икәү уйныйбыз, — дигән.

Сөрмәкүз, Гөлгелнең мактавына күңеле булса да, аның белән уйнарга теләмәгән.

— Синең белән бик уйнар идем дә, синең бит койрыгың кыска, — дип көлгән ул Гөлгелдән. Гөлгелнең Сөрмәкүзгә нык хәтере калган.

— Аюҗан абзый малае Камытаякның да аягы кәкре, аның белән уйныйсың бит, — дигән ул.

— Әйе, уйныйм, — дигән Сөрмәкүз, — чөнки аның атасы зур урында эшли. Ә синең атаң кем? Аюҗанның туксан тугызынчы йомышчысы. Җитмәсә әле, синең шулар өстенә тешләрең дә сирәк.

Гөлгел кайчандыр агач төбенә абынып тешләрен койган булганлыктан, үзенең бу кимчелегеннән бик гарьләнеп йөри икән. Сөрмәкүзнең шулай йөзгә бәреп «тешләрең сирәк» дип торуы аны чиктән тыш рәнҗеткән. Күзләренә — яшь, бугазына кайнар төер утырган.

— Ә син мактанчык, мактанчык, — дигән ул.

— Мин мактанчык булсам — син кылый, — дигән Сөрмәкүз. Бу сүзләрдән соң Гөлгел Сөрмәкүз янында бер минут та тора алмаган, чөнки аның иң-иң яратмаган кушаматы «кылый» булган. Кешеләр ни өчендер аңа шундый ямьсез кушамат такканнар. Бәлки, аларның тере куянның күзен күргәннәре дә юктыр әле.

Нык рәнҗегән Гөлгел Сөрмәкүзгә. Яңадан аның ягына әйләнеп тә карамаган. Ә Сөрмәкүз исә һаман чибәрләнгәннән-чибәрләнгән.

— Инде хәзер, кызым, буй-сыныңа тиң килерлек эш табарга кирәк, — дигән аңа беркөнне әнкәсе, һәм үзенең таныш-белешләре, туган-тумачалары, кода-кодачалары аша җайлы һәм майлы эш эзли башлаган. Эзли торгач, сораша торгач, Аюҗанга секретарь кирәклеген белеп алган ул.

— Кызым, — дигән Төлке, Сөрмәкүзгә сокланып карап. — Безнең бәхет сәгатебез сукты. Аюҗан абзаңның элекке секретаре пенсиягә киткән. Шуннан да әйбәт урынны елап эзләсәң дә таба алмаячаксың. Соңарма, әзерләнә башла.

— Ничек итеп әзерләним соң мин? — дигән Сөрмәкүз.

— Ничек дип инде, анысын гына үзең беләсеңдер. Әнә койрыгыңны бик әйбәтләп шампунь белән юып тара, күзнең явын алырлык булсын. Күкрәгеңә берәр чәчәк кадап җибәр. Аннары Аюҗан абзаңа бал исе аңкып торган урман чәчәкләреннән букет җыеп алып барсаң да зыян итмәс. Дөрес, ул утын түмәре, матурлыкны аңлый торган нәрсә түгел, шулай да үзен зурлаганны аңламый калмас.

Сөрмәкүз көне буе әзерләнгән. Юынган, чистарынган, бизәнгән. Койрыгына иң тәмле хушбуйларын бөркегән. Һәм икенче көнне иртүк Аюҗанның конторасына киткән. Шырт-шырт басып, бөтен урманга хушбуй исе таратып бик озак барган ул. Юлда аңа Бүребәк кызы Тизйөрер очраган:

— Кая барасың болай киенеп-ясанып? — дигән ул Сөрмәкүзгә.

— Син ишетмәдеңмени әле, — дигән Сөрмәкүз, — мине бит Аюҗан түрә үзенә секретарь итеп чакырды. Менә шунда барышым.

— Шулаймыни? — дигән Тизйөрер. — Бик әйбәт, ул урынга синнән дә лаеклыны эзләп торасы да юк. Үзең чибәр, үзең акыллы.

Башка вакытта Тизйөрер Сөрмәкүзне гел үртәп, төрлечә мыскыллап тора иде, бүген әнә ничек үзгәргән. Димәк, чынлап та Аюҗан түрә секретарь итеп Сөрмәкүзне алырга телидер. Бәлки инде, бу хакта урман халкына хәбәр дә таратып өлгергәндер. Әнә бит Тизйөрер: «Юлыңа ак җәймә», — дип калды.

Сөрмәкүз тагын алга киткән. Бер атлый да, уң аягының баш бармагына басып, ике тапкыр бөтерелеп ала икән. Аның шулай барышын агач ботагына кунган чыпчыклар карап торганнар да болай дип такмаклаганнар:

Матур апа кая бара, кая бара
Чәчәк тотып кулына шул, кулына?

Сөрмәкүз җырчы чыпчыкларга болай дип җавап биргән:

Үз бәхетемне эзләп барам, эзләп барам,
Бәхет каршы чыгар минем юлыма.

Шулай дигән дә Сөрмәкүз ары киткән. Чыпчыклар аның җырын кабатлап калганнар:

Матур апа китеп барды
Чәчәк тотып кулына шул, кулына.
Бәхет каршы чыгар микән, чыгар микән
Колач җәеп юлына шул, юлына.

Бара торгач, Сөрмәкүз керпе малайларының тычкан тотышлы уйнап яткан кечкенә аланына килеп чыккан.

— Чибәр апа, кая барасың? — дигәннәр алар, дәррәү телгә килеп.

— Ишетмәдегезмени әле, — дигән Сөрмәкүз, — мине бит Аюҗан түрә үзенә секретарь итеп алды.

— Шулаймыни? Ишетмәгән идек шул.

— Ишетмәсәгез ишетегез инде алайса: Сөрмәкүз апагыз бүгеннән урман патшасының уң кулы булачак.

Керпе малайлары Сөрмәкүзне уртага алганнар да әйлән-бәйлән уены башлап җибәргәннәр.

Патшабызның уң кулыдыр Сөрмәкүз,

Сөрмәкүз.
Сөрмәкүзгә начар карый күрмәгез,
күрмәгез.
Сөрмәкүзгә әгәр начар карасак,
карасак,
Нәрсә әйтер безгә Аю түрәбез,
түрәбез.
Чибәрләрнең чибәредер Сөрмәкүз,
Сөрмәкүз,
Зирәкләрнең зирәгедер Сөрмәкүз,
Сөрмәкүз.
Патшабызның терәгедер Сөрмәкүз,
Сөрмәкүз.
Карурманның йөрәгедер Сөрмәкүз,
Сөрмәкүз.

Керпе малайларының бу җыры Сөрмәкүзгә бик-бик ошаган. Мондый сөйкемле малайлар яныннан һич тә китәсе килмәгән аның. Ул, керпе малайларының тырпайган чәчләреннән сыйпап:

— Сөйкемлеләрем минем, йомшакларым минем, — дигән, — сезнең җырыгыз искиткеч матур, гел сезнең яныгызда гына калыр идем, әмма минем барасым бар. Аюҗан абзыйны озак көттерү ярамас.

— Аюҗан патшага бездән сәлам әйт, — дип калганнар керпе малайлары.

— Әйтермен, һичшиксез әйтермен, — дигән Сөрмәкүз һәм тагын юлын дәвам иткән. Аңа әле яңадан да күп кенә җирдә тукталырга, үзенең секретарь булуын аңлатырга туры килгән. Аюҗан конторасына Сөрмәкүз кичкә таба гына килеп җиткән. Ул килеп җиткәндә, Аюҗан патша, олы портфелен култык астына кыстырып, кабинетыннан чыгып килә икән. Сөрмәкүз аңа иелеп-бөгелеп сәлам биргән. Әмма Аюҗан моның сәламен алып тормаган.

— Мин бүген ун кешенең сәламен алдым инде, шуннан артыгын ала алмыйм, бигайбә, — дигән ул.

— Бу мин — Сөрмәкүз бит, — дип караган Төлке кызы, елардай булып.

— Йомышың булса, әнә секретарьга әйт, — дигән Аюҗан, түземсезләнә башлап. — Минем ял вакытым җитте.

— Секретарьга?

Сөрмәкүзнең кулындагы чәчәкләре Аюҗанның аяк астына чәчелгән. Аюҗан аларны таптый-таптый чыгып киткән. Ә Сөрмәкүз һушын җыя алмый ишек төбендә басып калган. Әгәр ниндидер таныш тавыш ишетеп сискәнеп китмәсә, бу хәлдән чыга алмый бик озак торган булыр иде әле. Ә теге таныш тавыш исә тагын кабатланган:

— Сөрмәкүз, син түгелме соң бу?

— Мин, — дигән Сөрмәкүз, юешләнгән күзләрен ышкый-ышкый. — Ә син кем?

— Мин куян кызы Гөлгел бит, танымыйсыңмыни?

— Ә син нишләп йөрисең монда? — дигән Сөрмәкүз.

— Менә патшабызга секретарь итеп чакырдылар үземне. Бик кирәсем килмәгән иде дә, Бүребәк вәзир үзе ялынып килгәч, ризалыгымны бирергә туры килде. Инде менә бер көн эшләдем.

— Бер көн эшләдең? Бүребәк вәзир үзе килеп чакырды?

Бу хәбәр Сөрмәкүзне тәмам аяктан егып ташлый язган. Шундый күркәм, шундый сылу Сөрмәкүз барында ничек инде шул өтек куян кызы Гөлгелне секретарь итеп алмак кирәк?! Аю патшаның күзе сукырдыр, югыйсә койрыксыз Гөлгелне янына да китермәс иде. Уф, инде нишләргә?

Сөрмәкүз озак кына баш ваткан, аннары, үзенең горурлыгын җиңеп, Гөлгелдән сораштыра башлаган:

— Әйт әле, дустым, ничек Аюҗан абзый сине секретарь итеп алырга булды?

— Моның үзенә күрә сере бар, — дигән Гөлгел.

— Йә, йә, — дигән Сөрмәкүз, — әйт инде. Без бит синең белән бик якын дуслар идек, бергә-бергә уйнап үстек. Шул дуслыгыбыз хакына әйт инде сереңне.

— Әйе, безнең дуслыкка исе китмәгән кеше юк иде, — дигән Гөлгел, хәйләкәр көлеп. — Әйтсәм әйтим алайса.

Сөрмәкүз, колагын шомрайтып, Гөлгелне тыңларга җыенган. Ә Гөлгел исә үзенең тырпайган кыска койрыгын сыйпап, бик көттереп кенә болай дигән:

— Тик син, дускаем, серемне берүк бүтәннәргә ычкындыра күрмә, яме.

— Юк, юк, — дигән Сөрмәкүз. — Серең эчемдә үләчәк, әйт кенә.

— Серем шул, — дигән Гөлгел, пышылдауга күчеп, — безнең Аюҗан патшабыз озын койрыклыларны бер дә яратмый икән. Бүген икебез баллап чәй эчеп утыра идек, шунда үзе ычкындырды.

— Аюҗан абзый белән баллап чәй эчеп утырганда?

— Синсез чәемнең тәме юк, утыр, дигәч утырдым инде, дустым.
— Алай, алай, — дигән Сөрмәкүз. — Озын койрыклыларны яратмый диген, ә?
— Яратмый, дустым, яратмый. Озын койрыклыларны күрсә, җен ачулары чыга.
— Ә сезнең монда миңа ярардай тагын ниндирәк эшләрегез бар соң әле?
— И, дустым, урыннар күп монда, — дигән Гөлгел, — әле менә Аюҗан абзый икенче тапкыр баллап чәй эчкәндә, сер итеп кенә колагыма болай диде...
— Икенче тапкыр баллап чәй эчкәндә?
— Икенче тапкыр баллап чәй эчкәндә әйтте: «Гөлгел матурым, — ди, — үзең кебек кыска койрыклы бирәрсен тап әле миңа, — ди. — Киңәшчемнең теле тотлыга башлаган, шуңа алмашчы кирәк иде», — ди.
— Тәгаен кыска койрыклы дип әйттеме?
— Тәгаен шулай дип әйтте, дустым.
Сөрмәкүз, Гөлгелнең бу сүзләрен күңеленә салып, өенә кайтып киткән.
— Тизрәк койрыкны кистереп ташларга кирәк, әнкәй, — дигән ул керә-керешкә.
— И-и, кызым, — дигән аңа әнисе, — ни сөйлисең син? Синең бөтен матурлыгың койрыкта бит.
Сөрмәкүз әнкәсенә эшнең нәрсәдә икәнен сөйләп биргән.
— Алайса кисәргә кирәк, — дигән әнисе. — Андый әйбәт урын өчен бер койрык җәл түгел. — Һәм ул балта алган да Сөрмәкүзнең койрыгын кисеп ыргыткан. Сөрмәкүз авыртуга түзә алмыйча өч көн дә өч сәгать буе урын өстендә елап яткан.
Әнкәсе аңа:

Кызым минем — Сөрмәкүзем —
Түрә булыр, түрә булыр.
Түрә булгач, тәпән-тәпән
Баллар-майлар килеп торыр, —

дип җыр җырлаган. Әнкәсенең бу җыры әз генә вакытка булса да койрык сызлауларын басып торган. Әнкәсе җырлаудан туктаса, Сөрмәкүз:
— Тагын җырла, тагын, — дип, әнкәсенә ялварган.
Әнисе җырын дәвам иткән:

Кызым минем — Сөрмәкүзем
Ачар бәхет сарайларын.
Килер аның кулын сорап
Зур-зур патша малайлары.
Кызым минем — Сөрмәкүзем
Йөзәр бәхет күлләрендә.
Аның исеме яңгырап торыр
Җырчы кошлар телләрендә.

Сөрмәкүзнең әнисе өч көн һәм өч сәгать буена кызына шундый җырлар җырлаган. Җырның шифасы тигәнме — койрыкның авыртуы басылган. Шуннан соң Сөрмәкүз сикереп торган һәм көзге каршысына басып үзенең яңа кыяфәтенә караган.
— Йә, ничегрәк, әнием, — дигән ул. — Хәзер мине Аюҗан үзенә киңәшче итеп алыр микән инде?
— Хәзер дә алмаса, эчендә җаны булмас, — дигән Төлке, һәм күңеле нечкәрүдән күзләре яшьләнгән. — Киен, кызым. Соңара күрмә.
Сөрмәкүз киенгән, ясанган. Иреннәрен кызарткан, хушбуйларын сипкән. Түшенә өр-яңа чәчкә кадаган һәм Аюҗан тарафына юнәлгән.
Бусагадан атлап керүгә үк аның каршысына Гөлгел килеп баскан.
— О-о, кемне күрәм! Синме соң бу, дустым Сөрмәкүз? — дигән ул, колачын җәеп. — Нинди чибәрләнгәнсең, танымый да торам үзеңне. Болай булгач, Аюҗан абзый сине киңәшче итеп алачак та алачак инде.
— Шулаймы, дустым? — дигән Сөрмәкүз һәм Гөлгелгә үзенең нәни сумкасыннан алып бүләк биргән.
— Хәзер Аюҗан янына керергә ярыйдыр бит? — дигән ул, ишеккә таба атлап.
— Туктале, дустым, — дигән Гөлгел, — безнең хуҗаның холкы кырысрак. Башта үзем белешеп чыгыйм. Син шушында утырып тор.
Гөлгел, шарт-шорт басып, хуҗа бүлмәсенә кереп киткән. Бик озак торып чыккан ул анда. Сөрмәкүзнең көтә-көтә карыннары ачып беткән, арыган, алҗыган. Ниһаять, ишектә секретарь Гөлгел күренгәч, түземсезләнеп:
— Йә, ничек? — дип сораган. — Аламы?

— Әйе, — дигән Гөлгел, хәйләле елмаеп, — эшләр пешәр төсле күренә. Тик менә... — Гөлгел сүзен ярты юлда өзеп туктап калган

— Нәрсә, нәрсә? — дигән Сөрмәкүз. — Әйтеп бетер.

— Йә, ярый алайса, ахири, үзең үтенгәнгә генә әйтәм. Миңа хәтерең калмасын. Хуҗа миңа синең тешләреңне карарга кушты.

— Тешләремне?

— Әйе, дустым.

— Анысы нәрсәгә икән тагын? — дигән Сөрмәкүз.

— Тешләре куе микән, сирәк микән, ди.

— Куе, куе. Менә кара. Энҗедәй тезелеп тора. — Сөрмәкүз авызын ачып тешләрен күрсәткән. Тешләре аның чынлап та бик куе, матур икән. Аның тезелеп торган тешләрен күргәч, Гөлгел көрсенеп куйган.

— Нәрсә, әллә куе түгелме? — дигән Сөрмәкүз.

— Куе шул, артыгын куе, — дигән Гөлгел, аны кызгангандай. — Ә безнең хуҗа сирәк тешлеләрне ярата. Менә минеке кебек тешләр ошый аңа.

Сөрмәкүз боегып өенә кайткан. Хәлне әнкәсенә сөйләп биргән. Әнкәсе, кызын юатырга тырышып:

— Нишлисең инде, кызым, кирәк икән — сирәкләрбез, — дигән. — Сирәкләү әле ул, чүтеки, куертырга караганда җиңелрәк. Тешләрең сирәк булып, арасына казык кагып чыгарга туры килсә нишләр идең.

Әнкәсе, тимерчедән төрле кораллар алып кайтып, тиз арада эшкә тотынган. Сөрмәкүз үрле-кырлы сикергән. «Юк, минем түрә буласым килми», — дип кычкырган ул. Әмма әнкәсе аның ай-ваена карамаган. Берәм-берәм кызының авызыннан тешләрен суыра торган.

— Менә шулай, кызым. Бу газаплар вакытлы гына, ә түрәлек — мәңгелек. Аюҗан абзаңа киңәшче булып алсаң, бөтен урман халкын үз кубызыңа биетәчәксең. Моның өчен бөтен тешләреңне суыртырга була. Ә син елап торасың. Еларга түгел, көләргә кирәк, кызым.

Тешләр сирәкләнеп, яңакларның шеше кайткач, Сөрмәкүз тагын Аюҗан тарафына киткән. Ул бу юлы Гөлгелгә күренми генә Аюҗан кабинетына кермәкче булып караган. Әмма Гөлгел, аның юлын бүлеп:

— Кая ашыгасың, дустым? — дигән.

— Ә-ә, син мондамыни әле? — дигән Сөрмәкүз, гаҗәпләнеп. — Мин әллә син юкмы икән дигән идем.

— Мин бар һәм булачакмын! — дигән Гөлгел, каты итеп. — Йә, сирәкләттеңме тешләреңне?

— Сирәкләттем, ахирәт. Нәкъ синеке төсле булды. Менә кара. — Сөрмәкүз Гөлгелгә тешләрен күрсәткән. Гөлгел канәгатьләнеп елмаеп куйган.

— Булган бу, дустым. Хәзер хуҗа янына кереп сөйләшеп чыгам. Ә син менә бу чикләвекләрне ашый тор. Теш авыртканда бик файдалы нәрсә.

Гөлгел кереп киткән. Бу юлы ул артык озак тормый әйләнеп чыккан.

— Йә, нәрсә? — дигән Сөрмәкүз. — Аламы?

— Ала, дустым, тик хуҗаның тагын бер шарты бар. Менә шунысын ничек үтәрсең икән дип уйлап тора идем әле.

— Нинди шарт, әйт тизрәк?

— Әйтергә дә кыен инде, дустым, тик яшереп тә кала алмыйм, — дигән Гөлгел һәм озак кына сүзсез торган. Сөрмәкүз сумкасыннан ниндидер бүләк чыгарып биргәч тә ул: — Эш андамыни, дустым, — дигән. — Миңа хәтта әйтергә дә кыен: хуҗа бит бу юлы болай ди...

— Йә, йә?

— Аның, ди, күзе кылыймы, ди. Кылый булса гына мин аны үз яныма эшкә алам, ди.

Гөлгелнең бу сүзләреннән Сөрмәкүз тәгәрәп китә язган. Әнисе янына көчкә генә кайтып егылган ул. Бары тик икенче көнне генә эшнең нәрсәдә икәнен аңлата алган. Әнисе кызының сүзләренә каршы:

— Бер дә борчылма, кызым, — дигән. — Турыны кыеклап була. Кыекны гына турылау авыр ул.

Шулай дип әйтүен әйтсә дә, Сөрмәкүзнең күзләрен ничек кылыйлатырга икән дип озак вакыт баш ваткан. Вата торгач, бернәрсә уйлап тапкан.

— Менә нәрсә, кызым, — дигән ул. — Син болай ит: әнә теге якты аланда бер галәмәт зур имән үсә бит, әйеме?

— Әйе.

— Шул имәнгә таба бөтен көчеңә йөгереп бар да башың белән сөз.

— Син нәрсә инде, әни? — дигән Сөрмәкүз. — Ә башым ярылса?

— Икенең берсе инде, кызым, — дигән карт Төлке. — Йә түрә буласың, йә... — Ул сүзен тәмамламаган килеш туктап калган. Кызын бик-бик түрә итәсе килгән аның. Кызы белән ана кочаклашып елашып та алганнар.

Икенче көнне иртүк торып, Сөрмәкүз пәһлеван имән үскән якты аланга барган. Барган да озак итеп карап торган. Башыннан төрледән-төрле уйлар кичкән. «Их, — дип уйлаган ул, — әгәр дә мәгәр Аюҗан абзыйның киңәшчесе булып алсаммы. Иң беренче итеп Гөлгел кылыйны эштән кудырачакмын. Аннары теге Бикбүренең эзен себерттерәчәкмен. Беркөнне нәрсә дип торган була бит, хәчтерүш. Койрыгыңны йоклап ятканда тычканнар ашап киттеме әллә, имеш. Һи, ашаса соң! Синең ни эшең бар анда?»

Сөрмәкүз хуҗаның баш киңәшчесе булгач тагын кемнәрдән ничек үч алу, кемнәрне үзенә иптәш итү хакында озак кына хыялланган. Әмма хыял хыял, әле бит Аюҗанның соңгы таләбе үтәлмәгән. Күрәләтә баш белән колач җитмәслек имәнгә барып бәреләсе килми шул.

Әллә ничә тапкыр йөгереп килеп, әллә ничә тапкыр туктап калган инде Сөрмәкүз. Әгәр дә янына Җилнең төпчек оныгы Орчык килеп чыкмаган булса, бәлки әле, йөрәге җитми кире дә кайтып киткән булыр иде. Орчык Сөрмәкүзнең болай маташуын күптән күзәтеп торган икән, ул, бик гаҗәпсенеп:

— Син нишлисең монда, Төлкебикәнең өтек кызы? — дигән.

Сөрмәкүзнең бу сүзләргә бик тә ачуы чыккан.

— Син үзең өтек, — дигән ул. — Беләсең килсә, мин хәзер менә бу имәнне сөзеп егачакмын.

— Имәнне?

— Әйе шул. Ә син өтек дисең? — Сөрмәкүз үзенең шундый тапкыр җавап таба алуына шатланып Орчыкка караган. — Белдеңме инде, энем?

— Әйдә алайса, сөзеп кара, — дигән Орчык.

Сөрмәкүз гайрәтләнеп йөгереп килгән дә тагын шып итеп туктап калган.

— Булмый синнән, — дигән Орчык, Сөрмәкүзне үчекләп. — Әйдә, йөгереп кил. Имәнгә якыная башлагач мин дә булышырмын.

Сөрмәкүз бу юлы ун чакрым ераклыктан йөгереп килгән. Килә-килә шундый кызган бу, Орчык этешмәсә дә туктап кала алмаган булыр иде, ләкин Орчык вәгъдәсендә тора торган кеше икән — Сөрмәкүзгә ярдәм итешкән.

Менә бер мәлне, күк күкрәгән тавышлар чыгарып, биш йөз яшьлек имән шартлап сынган. Сөрмәкүзнең күзләреннән очкыннар чәчрәгән, колагыннан төтеннәр ургыган. Әз-мәз рәткә килгәч, ул Орчыкка:

— Менә күрдеңме инде? — дигән.

— Әйе, — дигән Орчык, — гайрәт бар икән үзеңдә.

— Хәзер минем күзләремә кара, — дигән Сөрмәкүз, — кылыйланганнармы?

Орчык Сөрмәкүзнең күзләренә караган һәм куркып артка чигенә башлаган.

— Йә, нәрсә? — дигән Сөрмәкүз, Орчыкның чабуыннан эләктереп. — Кылыйланганмы?

— Моннан да кылыйрак нәрсә күргәнем юк иде, — дигән Орчык. — Сулъяк күзең бөтенләй юк бугай синең. Анда бер тирән чокыр гына күренеп тора.

— Бик шәп, — дигән Сөрмәкүз, — болай булгач, эш пешәчәк. — Һәм ул, өенә дә кайтып тормыйча, Аюҗанның эш сараена юнәлгән.

— И-и, эттәгенәсе, — дип каршылаган аны Гөлгел, — бу кадәр дә чибәрләнсәң чибәрләнерсең икән.

— Инде хәзер мине хуҗа үзенә киңәшче итеп алыр микән? — дигән Сөрмәкүз.

— Алыр, алыр, дустым, — дигән Гөлгел. — Бар, җаныкаем, кер үзе янына. Ул сине көтә.

Гөлгел Сөрмәкүзне хуҗаның кабинетына кертеп җибәргән дә ишекне өстәл белән терәтеп куйган.

Хуҗа яңарак кына умарталыктан кайткан булган. Анда аның бөтен җирен кортлар чагып, бик каты пешереп җибәргәннәр икән. Аюҗан бал тәпәне кадәр булып шешенгән борынын ышкый-ышкый елап утырганда, Сөрмәкүз килеп кергән.

— Син кем, нишләп йөрисең монда? — дип үкереп җибәргән Аюҗан патша. Үкергән чакта аның корт чагып мендәрдәй кабарган теле авызыннан атылып чыккан да яңадан авызына сыймый җәфалаган. Патшаның мондый чагын бер дә күрмәгән Сөрмәкүзгә кинәт куркыныч булып киткән.

— М-мин, — дигән ул көчкә-көчкә, — галиҗәнап әфәндем, эшкә урнашырга килгәнием. Сезки галиҗәнап әфәндегә баш киңәшче кирәк дигәннәр ие.

— Во-он! — дип акырган галиҗәнап патша, аяк тибеп.

Сөрмәкүз куркып ишеккә ташланган, ләкин ишек ачылмаган.

Ул арада тәмам котырынып җиткән Аюҗан галиҗәнаплары аны типкәли үк башлаган. Мескен Сөрмәкүз ачык форточкадан көчкә чыгып котылган.

Явыз патша тырнагыннан котылгач, ул урмандагы иң куе ешкынлыкка кереп бик озак елаган. Елый торгач, аның зиһене яктырып киткәндәй булган. «Карале, — дигән ул үз-үзенә, — барысына да мин үзем гаепле бит. Кайчандыр мин куян кызы Гөлгелдән көлгән идем. Шуның өчен миннән үч алган. Их, үткәннәрне кире кайтарып булса...»

Шулай дигән дә тагын җир тырнап еларга тотынган ул. Җирне көне-төне тырный торгач, урман ешкынлыгында тирән чокыр хасил булган. Шушы чокыр төбеннән бер мәлне салкын чишмә бәреп чыккан. Сөрмәкүз пычранып беткән битләрен шул чишмә суында юган. Һәм, сиңа ялган, миңа чын, Сөрмәкүзебез элекке хәленә кайткан: койрык үскән, тешләр куерган, күзләр туп-туры карый башлаганнар.

Тора-бара Сөрмәкүз түрә булу турындагы уйларын башыннан ук чыгарып ташлаган. Үзе кебек гап-гади бер төлке егетенә кияүгә чыккан. Туйларында миңа да булырга туры килде. Табында бер казан аш бар иде. Ләкин ашка беркем дә кагылмады, чөнки Аюҗан патшаның улы Камытаяк өйләнгәнлектән, дөньядагы бөтен кашыкларны шунда җыеп алып киткәннәр иде. Әмма без, ашамасак та, тук идек, чөнки ул чакта әле без бик яшь һәм бик нык идек.

## БӨКРЕ УРМАН САКЧЫСЫ

Борын-борын заманнарда икмәк котырып уңган якта, һәр ботакка сайрар кошлар кунган чакта, әкият, тылсым яңа гына туган чакта, җирнең гүзәл ноктасында, тар басмада, елганың нәкъ уртасында кармак салырга ярата икән бер малай. Исеме аның Айдар булган, йөрәге бик кайнар булган. Йөзе чибәр, гәүдәсе төз, бәхете тигез, шатлыгы йөз булган аның. Ай үскән ул, көн үскән ул, туктамыйча гел үскән ул. Гел уйнаган, кармак салган, беркемгә берни бирмәгән, бары тик алган. Кечеләрне якламаган, олыларны санламаган, ямьсезләрне-гарипләрне кешегә дә санамаган. Йөзе аның балкып торган, сөенече артып торган, беләгендә көч уйнаган, ул шаяра башладымы — аны тыярлык көч булмаган. Уйнап кына, көлеп кенә кемгәдер китереп кундырган, кемнеңдер тәпиен сындырган, көче ташудан ташлар аткан, тәрәзә ваткан. Авылдагы кәҗәләрнең койрыкларын тартып йөргән, кыяр түтәлләрен таптап, бозып йөргән.

Менә шулай көче ташып торган җирдән Айдар кинәт чирләп киткән. Чирнең дә моңа бик яманы, бик ямьсезе эләккән икән. Зифа буйлы шундый чибәр егеткәйнең аркасында уйламаган-көтмәгәндә бөкре үскән. Сөлек кебек малайның кинәт кенә шундый хәлгә төшүенә хафаланудан өйдәге һәммә кешенең йокысы качкан. Врачларның акыллыдан акыллыракларын, остадан остаракларын чакыртып караганнар, әмма бөкрене турайтырлык әмәл табучы булмаган. Шулай да берсе, кыюланып: «Мин кисеп ташлый алам моны!» — дигән. Ата-ана моңа шатланып риза булган. Малайны машинаның очып кына йөри торганына салып, больницага алып киткәннәр. Китереп салганнар операция өстәленә, иснәткәннәр әллә нинди тәмсез исле дарулар һәм караңгы йокы патшалыгына кертеп җибәргәннәр. Малай авыр-авыр сулыш алып йокыга талган, ә врачлар җиң сызганып эшкә тотынганнар. Әй кисәләр икән моның бөкресен, әй кисәләр икән, ләкин ни гаҗәп — бөкренең элеккесен кисеп төшерүгә, аннан да зуррак булып икенчесе үсеп чыга икән. Бу хәлгә врачлар бик аптыраган. Тагын шунысы да бик гаҗәпләндергән аларны — кискән җирдән кан чыкмый икән.

— Әллә соң бу берәр сихер эше микән? — дигән шулчак яши-яши бармак башы хәтле генә калган карт профессор.

Тик яшь профессорлар аңардан көлгәннәр генә:

— Син, Хәким ага, артык күп белүдән җиңеләя башладыңмы әллә? Хәзерге заманда нинди сихер булсын инде?

— Нишләп, алайса, кискән җирдән кан чыкмый? — дигән карт профессор. — Үз гомеремдә сигез мең сигез йөз сиксән сигез операция ясап мондыйны күргән юк иде.

— Бәлки, малайның бөтенләй каны юктыр?

— Ничек инде каны булмасын? Бармагыннан канын алып үзегез тикшердегез ләбаса.

— Әйе шул, — дигәннәр яшь профессорлар, уйга калып. — Инде нишлибез соң? Көне буе моны кисеп утырып булмас. Болай да санитарлар без кисеп ташлаган бөкреләрне ташый-ташый арып беттеләр.

— Туктатырга туры килер, — дигән карт профессор һәм үзенең перчаткаларын сала башлаган. Аның артыннан яшь докторлар да халатларын салганнар.

Айдарны кире үз палатасына чыгарганнар. Ул уянмыйча саташа-саташа бик озак йоклаган. Иртәгесен уянгач, аркасына кулын тидереп караса — бөкресе һаман үз урынында икән. Бөкренең үз сыртыннан төшәргә теләмәвен күргәч, малайның тәне кайнарланып киткән, сулышы буылган. Үзен кызганудан бугазына кайнар төер утырган. Ул врачларның булдыксыз булуларына чын-чынлап рәнҗегән. Юри терелтергә теләмиләр дип сыкранып яткан. Аннары палатада беркем дә калмагач, караватында тәгәри-тәгәри еларга тотынган. Үзе елаган, үзенең күңеленнән бер сорау китмәгән:

— Нигә, нигә чыкты бу хәшәрәт нәрсә минем аркама? Миңа чыкканчы теге сукыр Таҗига чыкса ни була? Ул бит барыбер үзен күрми.

Елый-елый малайның мендәрләре юешләнеп беткән. Ул тора-бара барлык кешеләрне күралмас булган. Шәмдәй төз малайларга, кызларга шундый матур, шундый сылу гәүдәле булулары өчен ачуы чыккан аның. Ә инде үзе кебекләрне ямьсезлекләре өчен сөймәгән.

Больницадан кайткач, ул бөтенләй урамга чыкмый башлаган. Яшьтәшләренең урамда чыр-чу килеп уйнауларын карап торганда, күзләреннән кайнар яшьләр тәгәрәп-тәгәрәп төшкән. Үзенең дә кайчандыр шулар кебек уйнап йөрүе, шаяруы-көлүе, барган уңайга киемнәрен салып ташлап суга чумулары, су кереп туйгач, комда кызынулары хәтерендә яңарган. Хәтерендә яңарган да тагын шул сорау тел очына килгән.

— Нишләп, нишләп чыкты бу нәмәрсә минем сыртыма?

Үз-үзенә шушы сорауны биргәннән соң, Айдарның күз алдына кинәт моннан бер ел элек чамасы булган вакыйга килеп баскан. Ул теге вакыйганы куалап җибәрергә теләгәндәй чәбәләнә башлаган. Аның тавышына әти-әниләре йөгереп кергән.

— Нәрсә булды, балакай? Әллә начар төш күреп уяндыңмы?

Айдар аларга җавап бирмәгән. Илереп-илереп еларга тотынган. Ата-ана малайны берничек тә юата алмаган. Аларның күңелен дә туктаусыз шул ук сорау кимереп торган.

— Нигә? Нинди гөнаһларыбыз өчен мондый бәла килде безнең башка? Шундый чибәр, шундый сылу малай иде бит. Караган саен сөенмичә карап булмый иде үзенә.

Ата-ана бу чирдән коткаручы табылса әллә ниләр вәгъдә итеп тирә-юньгә хәбәр тараткан. Менә шулай өзгәләнеп йөргәндә, аларга бер юлаучы карт килеп кергән.

— Әссәламегаләйкем! — дип сәлам биргән ул. — Сезнең бик зур кайгыгыз бар дип ишеткән идем.

— Әйе, кайгыбыз зур, — дип сөйләп киткән ата-ана, бер-берләрен бүлдерә-бүлдерә. — Яшь тал кебек зифа буйлы булып үсеп килгән малаебыз кинәт кенә әллә нишләде. Хәтта әйтергә тел әйләнми.

Алар елап җибәргәннәр. Юлаучы бу бәхетсез җаннарны ничек тә юатырга тырышкан.

— Безнең ул егетебез үзе кайда соң әле? — дигән юлаучы.

— Мич башыннан төшереп булмый аны хәзер, — дигәннәр аңа. — Улым, Айдар, төш әле. Менә бу мөсафир абзаңның сине күрәсе килә.

— Мине күрәсе килсә, мунчага барсын да мунча пәриен карасын. Мин шуның төсле инде, — дигән Айдар, ачу һәм нәфрәт белән.

— Алай тупас кыланма, улым. Синең алай булуыңа мөсафир абзыйның гаебе юк бит.

Бергәләшеп бик озак үгетли торгач кына Айдарны мич башыннан төшерә алганнар. Юлаучы карт Айдарны бик җентекләп караган, аннары авыр сулап болай дигән:

— Дөресен әйтергә кирәк, мин бераз табиблык эшләрен беләм. Мондый авырулар белән дә очрашырга туры килде...

— Йә, йә, — дигәннәр аңа, — ничек соң, терелтә алдыңмы мондыйларны?

— Булгалады, — дигән мөсафир, уйчан гына. — Терелүчеләр дә булгалады.

— Без бөтенесен дә эшләр идек.

— Монда сезнең ярдәм файдасыз булыр, мөгаен, — дигән мөсафир. — Егетебез үзе тырышса гына инде.

Айдарның күзләрендә очкыннар кабынып киткән.

— Әйт кенә, абзыкай, — дигән ул, — бөтенесен син дигәнчә эшләрмен. Дию пәриенә каршы сугышырга кирәк булса — аңа каршы да сугышачакмын. Гомер буе аркамда бу хәшәрәтне күтәреп йөрткәнче, Дию белән сугышып үлүем яхшырак.

— Кыюлыгың миңа ошый, — дигән мөсафир карт. — Ләкин...

— Бөтен байлыгыбызны бирербез, — дигәннәр Айдарның әти-әниләре, — тик малаебызны гына терелт. Ул бит безнең бердәнберебез.

— Авыруны дәвалый башлаганчы иң беренче аңа дөрес диагноз куярга кирәк бит әле, — дигән мөсафир. — Миңа калса, улыгыз кемне дә булса бик каты рәнҗеткән булырга тиеш. Минем шуны беләсем килә. Белмәгән килеш эшкә тотынсам, дәвамның файдасы тимәс дип куркам. Чөнки һәрбер чир башта кешенең җанында башлана. Йә, егеткәй, сөйләп бир. Бармы гөнаһың?

— Син ни сөйләгәнеңне беләсеңме? — дип тотынганнар мөсафирга Айдарның ата-аналары. — Безнең фәрештә кебек улыбыз нишләп кеше рәнҗетсен. Кеше түгел, ул мәче баласын да рәнҗетмәс.

— Әгәр шулай икән, бик әйбәт, — дигән юлаучы, — күңеле сафларны терелтү җиңелрәк. Әмма Айдар үзе ни әйтер бит әле.

— Малаебызга яла ягып, син безне хурлыйсың, — дигәннәр мөсафирга. — Бар, чыгып кит, без сине тыңларга теләмибез.

— Ярый, мин чыгып китәрмен, малаегызга ярдәм итеп булмасмы дигән идем.

Юлаучы капчыгын иңенә асып ишеккә юнәлгән, шул вакыт Айдар атылып килеп аның каршысына баскан:

— Китмә, абзый. Мин барысын да сөйлим. Тик әти-әниләр чыгып торсын.

— Юк инде, балакай, — дигән мөсафир, — барыбыз алдында сөйлә. Синең һәр эшеңне ата-анаң белергә тиеш. Шулай булмаганда, бу чирне төзәтергә ышандыра алмыйм.

Айдар авыр сулап куйган да сөйләп киткән:

— Әйе, көчсезләрдән, яклаучысыз кешеләрдән күп көлдем мин. Күпләрнең шулай үз-үзләрен яклый алмаулары, бер сукканга сыгылып төшүләре минем өчен кызык кына иде. Йодрыгыма йодрык белән җавап бирүчеләрне генә хөрмәт иттем. Ә андыйлар ни өчендер миңа сирәк очрады.

Ә беркөнне, гадәттәгечә, елга аркылы салынган тар басма өстендә кармак салып утыра идем. Көн матур. Күктә кояш кыздыра. Балык кына ни өчендер ул көнне бик озак чиертми аптыратты. Инде кармакларны ыргытам да суга чумам дип кенә торганда, тәлтәвечем елга өстендә уйнаклый башлады. Нәкъ менә балык чиертергә тотынгач кына әллә каян бер бөкре карчык килеп чыкты бит. Килеп чыкты да:

— Кая әле, улым, юл бир, теге якка чыгып китим әле, — диде.

Шундый вакытсыз чакта басмага килеп кергән бу карчыкка минем бик ачуым килде. Чөнки тәлтәвечем уйнаклый-уйнаклый су өстендә йөзә иде. Күренеп тора: бер хәйләкәр балык кармагым тирәсендә чуала. Әгәр хәзер мин урынымнан кузгалсам, бар да бетәчәк, балыгым ычкыначак. Шуңа күрә мин басма өстендә сабырсызланып торган бөкре карчыкны терсәгем белән читкәрәк этеп җибәрдем. Ә ул, ялварып:

— Бик ашыга идем бит, балам, — диде.

— Кая, үләргәме? — дидем мин, ачуланып.

— Барасы җирем ерак иде.

Карчык яны беләнрәк минем янымнан үтмәкче булды. Шул вакыт аның сулышы битемә бәрелгәндәй итте. Мин аның сулышыннан җирәнеп, йөземне читкә бордым. Гомеремдә мондый ямьсез кеше күргәнем юк иде. Шундый ямьсез башы белән минем яныма килеп басарга батырчылык иткәне өчен моңа өр-яңадан ачуым кабарды.

— Теге якка чыгасың килсә, әнә басма астыннан чык, анда юл киң, — дидем мин һәм ачу белән басманы селкетергә тотындым. Чөнки моның белән сөйләшеп торган арада балык кармагымны өзеп качкан иде.

— Селкетмә, балам, башым әйләнә, суга егылып төшүем бар, — диде карчык.

— Егылып төшсәң, дөньяда убырлы карчык кимер, — дидем мин, басманы торган саен ныграк тирбәтеп.

Ул минем җиңемә ябышты.

— Зинһар, чыгарып кына җибәр, — диде.

Ә мин аңа:

— Әнә бөкреңә атлан да чык та кит, бөкрең бик шәп бит, — дидем. Минем шул сүзләремнән соң бу әби кинәт артка чигенә башлады. Үзе авыз эченнән догага охшаган ниндидер сүзләр пышылдый, үзенең күзләре уттай яна. Менә ул бер мәлне күзгә күренеп эреп юк булды, басма өстендә карчыкның аркасындагы бөкресенә охшаган бер нәмәрсә генә калды. Мин аны суга тибеп төшермәкче булып аягым белән кизәндем һәм шул вакыт үземнең аркамда бик каты авырту тоеп катып калдым.

Малай сөйләп биргәч, барысы да бермәлгә сүзсез тордылар.

— Дөресен сөйләвең өчен рәхмәт, балакай, — диде мөсафир карт, — югыйсә нәрсәдән авырганыңны белми торып дәвалап булмас иде.

— Ә хәзер ничек, дәвалап булырмы? — диде Айдар.

— Ничек? Ничек? — диделәр башкалар да... — Без мал-мөлкәтебезне җәлләмәс идек.

— Их, бөтен нәрсәне дә мал-мөлкәт белән генә алып булса икән. — Юлаучы карт хуҗаларның үзенә текәлгән ялварулы карашларыннан арынып өчен башын читкә борды. — Йә, ярый, мин кулдан килгәнне эшләргә тырышырмын. Тик, егеткәй, күп нәрсә синең үзеңнән торачак.

— Әмәлен генә өйрәт, бөтенесен эшләрмен, — диде Айдар, кайнарланып.

— Бүгеннән юлга җыен, — диде аңарга юлаучы. — Кайнар диңгез уртасында бер утрау бар. Шул утраудагы зәңгәр күлгә иң кыска төннәрнең берсендә ике аккош төшә. Шул аккошларның берсенең канат астында кара каурый бар. Сиңа шул каурыйны кулга төшерергә кирәк. Синең авыруыңның дәвасы әнә шул кара каурыйда. Ә теге карчык ул тылсымчы карчык булган. Аның сине сынап карыйсы килгән.

— Их, аның шулай мине сынавын белгән булсам!

— Тормыш безне кайчан һәм ничек сынаячагын беребез дә белми шул, — диде мөсафир. — Шуның өчен дә кешеләр һәрвакыт яхшы, кешелекле булырга тиешләр.

Алар шулай төрле хәлләр турында сөйләшкән арада, Айдарның әнисе юлга төрле-төрле тәмле ризыклар пешерергә тотынды. Әтисе малаеның туфлиләрен рәтләштерде, юл капчыгының ныграгын эзләп алып керде.

Улларын сәфәргә озатыр алдыннан һәммәсе бергә җыелып ныклап тамак туйдырдылар. Ризыкларның иң тәмлеләре мөсафир карт алдына куелды, һәммәсе әзер булып, уллары чыгып китә башлагач, ата-ана:

— Без дә синең белән барыйк, улым, — диделәр, — бергә-бергә җиңелгәрәк килер. Син сабый гына бит әле. Юлда адашуың яки явыз бәндәләр кулына эләгеп харап булуың бар.

Ләкин мөсафир аларның дәртен бик тиз сүрелдерде.

— Әгәр улыгыз үз бәхетен үзе тапсын дисәгез, аңа комачауламагыз, — диде ул, катгый итеп. — Баланы гомер буе ата-ана җитәкләп йөртеп бетерә алмый. Малаегыз юлдашларны юлда үзе табар, үзе сайлар. Юлаучы Айдарга текәлеп карап торды да болай дип өстәде: — Сиңа шуны әйтергә оныткамын икән әле, балакай.

— Йә, йә, мин тыңлыйм сине, абзый.

— Юлда сиңа ике кеше очрар. Берсе аның сиңа ук бирер, берсе — җәя.

— Ниндирәк кешеләр соң алар, абзый?

— Менә анысын мин әйтә алмыйм инде, улым. Аларның сиңа кайда очраячакларын да, нинди кыяфәттә буласыларын да мин белмим. Әмма алар сине очратып ошата калсалар, җәя-укларын сиңа бирәчәкләр. Бәлки әле, үзеңне диңгез уртасындагы күлгә дә илтешерләр. Син шул җәядән ук атып зәңгәр күлдәге аккошның кара каурыена тидерергә тиешсең. Шул каурый белән әнкәң аркаңны сыйпагач, элеккедән дә зифарак буйлы егеткә әверелерсең. Менә шулай, егетем, ә хәзер — юлга.

Айдар әти-әнисе белән саубуллашып чыгып киткән.

Әй бара, ди, бу, әй бара, ди. Карурманнар, агымсулар һаман саен артта кала, ди. Үзенең шулай шәп баруына сөенеп җырлап та җибәргәли икән. Әллә күңеле күтәренке булганга, ул хәтта үзенең бөкре икәнлеген дә оныткан. Бу әле аның аркасына бөкре үсә башлаганнан соң беренче мәртәбә шулай онытылып җырлавы икән. Аның җырына җилләр кушылган, кошлар куәт өстәгән. Кояш аны озата барган.

Шулай бара торгач, аны озатып килүче җилләр арып артта калган. Кояш өреп шар кабартучы малайның бите төсле кызарган, зурайган да көче бетеп тау артына кереп яткан. Айдарның да хәле бетә башлаган. Үзе һаман як-ягына каранып ала икән. Менә-менә юлаучы абзый әйткән юлдашлар килеп чыгар да, аңа җәя белән ук китереп тоттырыр кебек тоелган. Ә ничек таныр соң Айдар ул кешеләрне? И-и, шуны да белми тора икән: әлбәттә инде, кулларындагы ук белән җәяләреннән таныр. Үзләре дә алар тегенди-мондый гына түгел, пәһлеван кешеләр булырлар. Бүтәннәргә ярдәм кулы сузучылар, һичшиксез, пәһлеван булырга тиеш.

Уйларына бирелеп бара торгач, Айдарның каршысына хәерче генә киемле аксак бер кеше килеп чыккан. Кулында моның камыш юанлыгы гына таяк икән. Тик, аксак булса да, таягына таянмый икән.

— Әссәламегаләйкем! — дигән ул Айдарга, түбәнчелек белән. — Кай тарафларга юл тотасың, егет?

Айдар, каршысында басып торучы бу бәндәнең сәламен дә алып тормыйча, юлын дәвам итәргә теләгән.

— Һәй, егет, — дигән сукбай, — миңа ярдәм итмәссеңме икән? Ерак туганыма барырга чыккан идем дә, аягыма болан басты, һич атлый алмыйм. Рөхсәт итсәң, бераз синең иңеңә таянып барыр идем.

— Таягыңа атланып бар, — дигән Айдар, — таягың бик шәп күренә. Ә минем синең белән маташырга вакытым юк.

— Таягыма да атланыр идем анысы, — дигән сукбай, — әмма ләкин сынар дип куркам. Ә минем аны сындырмаган килеш берәүгә тапшырасым бар. Бик-бик кирәк ул аңа.

— Сынса, икенчене ясап бирерсең, — дигән Айдар һәм китеп барган.

— Туктале, егеткәй, — дип кычкырып караган сукбай, — бу таякта бит кеше язмышы...

Әмма Айдар туктамаган. Бер кырмыска түмгәгенә абынып егылгач кына бүтән бер адым да атлар хәле калмаганлыгын төшенгән. Ул, иңендәге капчыгын да салып тормыйча, йокыга киткән. Кайдадыр ач бүреләр улаган, төнне сискәндереп ябалаклар кычкырган, тик Айдар боларның берсен дә ишетмәгән.

Иртән кырмыскалар бөтен тәне буйлап йөгерешә башлагач кына уянып киткән ул. Уянган да үләндәге чык суында кулларын-битләрен юган. Капчыгындагы ризыклар белән тамагын туйдырган. Тамак туйгач, тәнгә хәл кергәч, яңадан юлга кузгалган.

Әй бара, ди, бара, ди, бу. Барган саен, таныш җирләр артта кала, ди. Шулай бертуктаусыз бара торгач, кайнар ком чүленә килеп чыккан бу. Кояш та монда бик усал икән, нурлары тимерчыбык кебек чәнчә, ә җил әйтерсең Айдарны үчекләргә чыккан: суларга дип авызыңны ачтыңмы — учлап-учлап авызыңа ком тутыра да куя. Ком теш араларына кереп шытырдый, сулыш юлына тулып тын алырга комачаулый. Җитмәсә, юлы да үрле дә үрле. Ком тавына менеп кенә җиттем дисең, ә ул ишелә башлый да сине үзе белән түбәнгә алып төшеп китә. Ичмасам, теге мөсафир абзый әйткән юлчылары да тизрәк очрамый. Кулга җәя белән ук керсә дә күңел күтәрелеп китәр иде. Ә алар юк та юк.

Бик озак барган Айдар. Бара-бара көннәр кичкән, төннәр кичкән. Әллә ничә тапкыр утырып ашаган, эчкән. Инде аның капчыгындагы ризыклары да бик аз калган. Ә юлның очы-кырые күренми икән. Айдар хәлсезләнгәннән-хәлсезләнгән. Менә авам, менә егылам дип барганда, аңа теге сукбайдан да ямьсезрәк бер кеше очраган. Бу кешенең ике кулында ике чиләк, чиләкләре тулы су, ди. Үзе ни өчендер, иңендә көянтәсе була торып, чиләкләрен кулына күтәреп бара икән. Айдарны күргәч, ул туктаган. Сәлам биргән. Ләкин Айдар аның сәламен алмаган.

— Йолкыш, — дип мыгырданып куйган ул авыз эченнән. — Җыен сукбай, җыен йолкыш миңа очрый. Кара инде моны. Сыйраклары эт кимергән сөяк төсле, башы казык башына элеп куйган чүлмәк. Җитмәсә, шул нәрсәдер эшләп йөргән була.

— Егеткәй, — дигән юлчы, кипкән иреннәрен ялап, — миңа ярдәм итмәссеңме икән? Бик арыдым, бик алҗыдым.

— Арысаң тукта да ял ит, — дигән Айдар.

— Юк, миңа ял итәргә ярамый, — дигән әлеге кеше. — Мин бу суымны тизрәк кирәкле урынга алып барып җиткерергә тиеш. Үзем әле, бәлки, атлар идем дә, ләкин кулларның куәте калмады, туганкай. Өзелеп төшәргә торалар.

— Чиләкләреңне көянтәңә эл, — дигән Айдар.

— Сындырырмын дип куркам шул.

— Сынса ни дә, сынмаса ни. Барыбер файдаланмыйсың бит.

— Алай түгел ул, туганкай. Мин бу көянтәмне берәүгә сынмаган килеш тапшырырга тиеш. Ә барасы җирем ерак минем. Ә-ә-нә тегендә, ком тавының иң-иң биегендә әткәм-әнкәмнең кабере бар. Шул кабер өстенә мин ике агач утырттым. Әгәр дә һәр көнне шул агачларга берәр чиләк су китереп сипмәсәм — корыячаклар.

— Юк, — дигән Айдар, — сиңа ярдәм итә алмыйм. Үземнең барасы җирем бик ерак. Хәлем дә беткәннән-бетә бара.

Айдар шулай дигән дә китеп барган. Бераз баргач борылып караса, чиләкләр күтәргән теге кешедән җилләр искән. «Әллә күземә генә күренде микән бу?» дип уйлаган Айдар.

Тагын берничә көн дә берничә төн барган ул. Ләкин кулларына җәя-ук тотып килүче күренмәгән. Айдар арып, хәлсезләнеп бер диңгез буена килеп чыккан. Ашарына ипие, эчәренә суы калмаган аның. Башын түмгәк өстенә салып йокларга тырышып караган, тик йокы да алмаган.

— Алдакчылар, бар да алдакчылар! — дип кычкырган ул, нәфрәтләнеп. — Теге абзый да алдады.

Шул вакыт кинәт кенә салкынча, рәхәт җил исеп куйган да әллә каян гына теге юлаучы пәйда булган:

— Юк, мин сине алдамадым, егеткәй, — дигән ул.

— Алдамагач, кая соң синең теге җәя-ук бирергә тиешле кешеләрең?

— Син алар белән очраштың бит, дустым. Хәтереңдәме, карурман юлында сиңа бер аксак сукбай очраган иде. Кулында аның камыштай төз таяк бар иде. Ә бит ул гади таяк түгел, сиңа бирергә дигән ук иде. Ул аны сындырмыйча сиңа бирер өчен аксак булса да таяк итеп файдаланмады.

— Алайса, нигә соң ул аны миңа бирмәде? — дигән Айдар. — Юк, юк, ул әллә нинди сукбай иде. Үзе әле миннән ярдәм сорап маташты.

— Менә-менә, — дигән юлаучы, — ярдәм сорап ул синең күңелеңдә яхшылык уятырга теләгән. Ә бит мин сиңа теге вакытта әйттем: «Иң беренче җандагы бөкрене бетерергә кирәк», — дидем. Эчтәге бөкрене бары тик яхшылык эшләп кенә бетереп була.

Айдар, өзгәләнеп:

— Белмәдем бит мин, әгәр аның миңа ук бирергә тиешле кеше икәнен белгән булсам, ни сораса да үтәр идем, — дигән.

— Син һаман берни дә аңламыйсың әле, — дигән мөсафир карт Айдарга, — яхшылыкны аны алмашка эшләмиләр. Син аңардан үз кирәгеңне алыр өчен генә эшләнгән яхшылык яхшылык түгел. Ул инде алыш-биреш була. Яхшылык яки ярдәм — үз җаныңның бер кисәген бирү ул, туганкай. Билгеле, мин сине аңлыйм: син анда арыган идең, ашыга идең. Әмма кеше нәкъ менә шундый чакта сынала, дустым.

— Ә икенчесе? — дигән Айдар. — Җәя бирергә тиешле кеше нигә очрамады?

— Ул да очрады. Ком чүлендә ике чиләк су күтәргән кеше нәкъ шул иде. Иңендәге көянтәне хәтерләдеңме — ул бит көянтә түгел, сиңа дигән җәя иде.

Айдар үкенүдән җаны әрнеп чирәмгә тәгәри-тәгәри еларга тотынган:

— Инде нишләргә соң миңа? Гомер буе шушы бөкре белән яшәргәмени, ә? Нигә мине беркем дә жәлләми соң? Нигә дөньяда бөтен кеше шундый каты бәгырьле? Нигә миңа мондый гомерлек җәза?

— Көчсезләрне рәнҗеткәннәр бервакытта да җәзасыз калмыйлар. Аларның каргышы йә менә шулай бөкре булып аркага үсеп чыга, йә бүтән бәхетсезлек булып өстеңә ишелә. Ә син соңгы вакытта бик күпләрне елаттың, һәр кешенең күз яше синең җаныңа тама барган. Син аны үзең генә белми йөргәнсең. Көз көне тамчы тамып торган җирне күзәткәнең бармы? Тамчы тама-тама нинди олы боз хасил итә. Синең дә җаныңда әнә шундый боз тавы барлыкка килгән, ә инде ул, артык зураеп эчкә генә сыймый башлагач, аркаңа чыккан. Шулай ул, дустым, һәр кеше үзенең кылганын үз иңе белән күтәрергә тиеш.

Айдар үкенүдән тыелгысыз рәвештә елаган. Аннан соң мөсафир карт алдына тезләнгән дә ялвара башлаган:

— Кайтар мине элекке хәлемә, зинһар, кайтар. Бөтен гомеремне кешеләргә яхшылык эшләргә багышлармын. Көчсезләрне кыерсытмам, олыларны олылармын.

— Тор, егет, аяк астында аунама. Түбәнсенү егет кеше эше түгел, — дигән мөсафир. — Әлбәттә, ярдәм итәр идем мин сиңа. Тик үз гомереңдә бер генә мәртәбә дә яхшылык эшләп карамаган кеше алдында барлык тылсымнар көчсез икән. Әгәр үзгәрә алсаң, үзгәрергә тырышып кара. Бәлки әле, очрашырбыз да. Ә хәзергә хуш.

— Мин яхшырачакмын, — дигән Айдар, җан авазы белән.

— Бик әйбәт, — дигән мөсафир карт һәм китеп барган. Ә Айдар кайнап торган диңгез буенда япа-ялгызы торып калган. Ашарына ипие, эчәренә суы булмаган аның.

Ә шуннан соң нәрсә булганмы? Шуннан соң нәрсә булгандыр, анысын белмим. Әмма күптән түгел бөкре урман сакчысы турында нindидер сүзләр ишетергә туры килде миңа. Имеш, нindидер бер мәмләкәттә кул тимәгән, бер агачы да киселмәгән бик шәп урман бар икән. Ул урманда бүреләр куяннар белән җитәкләшеп уйнарга чыгалар, аюлар бал кортларына бал җыешалар, күкеләр үзләренә-үзләре оя ясап бала чыгаралар, тилгәннәр кош балалары үстерешәләр, төлкеләр җырлап-биеп урмандагы җәнлекләрнең күңелен күтәрәләр икән. Бер генә җан иясе дә икенчесен җәберләми, бар да бер-берсе белән дус, иптәш икән. Ишетүемчә, бу урманның сакчысы нindидер бөкре егет икән. Аюлар да, бүреләр дә, иң хәйләкәр төлкеләр дә бу егетне олылап ханыбыз-солтаныбыз дип кенә йөртә, ди. Әгәр дә мәгәр урман патшалыгында берәр гаделсезлек эшләнсә, бөкре сакчы шундук килеп җитә икән дә кыерсытучыга каты җәза бирә икән. Чөнки ул аюның сыңар тәпиеннән тотып болытларга чөярлек көчле кеше икән.

Ә икенче берәүләр бу урман сакчысын төз гәүдәле, матур йөзле, зифа буйлы дип сөйләделәр. Бәлки, боларның сүзе дөрестер. Башкаларга яхшылыклар эшли-эшли безнең героебызның аркасындагы бөкресе беткәндер. Мөгаен, шулайдыр. Чөнки дөньяда явызлыкка караганда яхшылык көчлерәк бит. Моның чынлап та шулай икәненә чын күңелдән ышанырга һәм яхшылык җиңсен өчен кулдан килгән кадәре көрәшергә генә кирәк.

## ЯҢА ЕЛ ТӨНЕНДӘ

Борын-борын заманда, диңгез артындагы кара урманда зифа буйлы, купшы тунлы чыршылар үсә икән. Әлеге гүзәл чыршылык диңгез аръягында булганлыктан, андагы агачларны беркем дә барып кисә алмый икән.

Яңа ел җитәргә берничә көн калгач, Таһир исемле батыр малай белән Зөһрә исемле матур кыз, әтиләре янына килеп:

— Әтием, Яңа елга чыршыны теге диңгез аръягындагы урманнан алып кайтыйк әле, — дигәннәр.

Әтиләре балаларының бу сүзеннән курка калган.

— Юк, ярамый, балалар, — дигән ул.

— Нигә ярамый? — дигән Таһир.

— Нигә ярамый? — дигән Зөһрә дә.

— Нигәме? — дигән әтиләре. — Беренчедән, ул урмандагы һәр чыршы кеше кебек сөйләшә. Моңайганда җырлый, кайгырганда елый, шатланганда көлә, ди.

— Безгә шундый чыршы кирәк тә, — дигән Зөһрә белән Таһир, кулларын чәбәкли-чәбәкли.

— Икенчедән, — дип дәвам иткән аларның сүзен ишетмәмешкә салышкан әтиләре. — Икенчедән, диңгез аръягына чыгарга безнең корабыбыз юк.

— Ә безгә кораб кирәкми, — дигән Таһир.

— Әйе, кирәкми, — дип җөпләгән аны Зөһрә дә.

— Алайса, сез ул урманга очып барырга уйлыйсызмы әллә? — дигән әтиләре.

— Әйе, очып барабыз.

— Очар өчен канат кирәк бит, балакайлар.

— Ә безнең канатыбыз бар.
— Кая соң ул?
— Әнә абзарда.
Әтиләре абзарга күз салган.
— Безнең канатыбыз шул Акбүз атыбыз инде, әти, — дигән Таһир. — Ул самолетлардан да тизрәк оча ала.
— Юкны сөйләмәгез әле, балалар.
— Юкны сөйләмибез, әти, — дигән Зөһрә. — Безнең Акбүз атыбыз оча белә. Без аның белән әллә ничә тапкыр карурманнар өстеннән очып урап кайттык инде.
— Әйе, — дигән Таһир. — Мин Акбүзнең муенына атланып ялларына ябышам, Зөһрә сыртына менеп утырып миңа тотына. Менә шулай гел очабыз без.
Балаларының сүзеннән соң әтиләре уйга калган. Үзенең дә күңелендә шаян балачагы тыпырдап куйган. Нәкъ шул чакта, боларның уйларын белгәндәй, абзарда Акбүз ат кешнәп җибәргән. Аның тавышы балаларын яраткан ата колагына: «Очабыз, диңгез аръягына очабыз», — дип ишетелгән.
— Ярар алайса, җыеныгыз, — дигән дә Акбүз атын иярләргә чыгып киткән. Таһир белән Зөһрә, тиз генә әзерләнеп, әтиләре янына чыкканнар. Аларның һәр икесенең кулында берәр телем ипи икән. Әтиләренең сораулы карашын тоеп:
— Диңгез өстеннән очкан чакта Акбүзебез арый башласа, без аңа шушы ипи телемнәрен каптырабыз, аларда синең күкрәк көчең, әниебезнең кул җылысы, җәйге җилләрнең уйнаклыгы, җиребезнең гайрәте бар, — дигәннәр.
Эшне озакка сузмыйча Акбүз атка өчәүләшеп менеп атланганнар да очып киткәннәр. Акбүз ат, шул вакыт телгә килеп: «Күзләрегезне йомыгыз, юкса диңгез өстеннән очканда куркып төшеп калуыгыз бар», — дигән.
Өчесе дә чытырдатып күзләрен йомганнар. Алар Акбүз атның җирдән күтәрелүен сизми дә калганнар. Бары тик колакларына диңгез шаулавы, җилләр сызгыруы, ниндидер кошлар кычкыруы гына ишетелгән. Күп тә үтмәгән, Акбүз ат: «Ә хәзер күзләрегезне ачыгыз», — дигән. Күзләрен ачып җибәрсәләр, ни күрсеннәр, каршыларында сихри урман шаулап утыра. Һәр чыршы итәкләре кабартылган туй күлмәге кигән кыз кебек купшы, матур. Ә иң таң калдырганы шул: алар чынлап та сөйләшә белә икән.
Әнә берсе, Таһир белән Зөһрәнең каршысына йөгерә-йөгерә:
— Безгә кунаклар килә, безгә кунаклар килә! — дип колачын җәйгән.
Икенче чыршы:
— Сез безнең белән Яңа ел бәйрәме каршыларга килдегезме? — дип сораган. Һәм Таһир белән Зөһрәнең җавабын да көтмичә: — Менә рәхмәт, болай булгач, безнең Яңа ел бәйрәмебез бик күңелле булачак, — дигәннәр дә аларны урман эченә җитәкләп алып кереп киткәннәр. Боларга Таһир белән Зөһрәнең әтиләре дә ияргән. Аның күңеленнән: «Ярый балта алырга онытканмын, юкса бу чибәркәйләр күзенә ничек карар идем», — дигән уй узган.
Ә чибәр чыршы кызлары урман аланындагы бик дәү пар чыршы янына килеп туктаганнар да:
— Кадерле әниебез, кадерле әтиебез! Менә безгә кунакка кемнәр килде! — дигәннәр.
Чыршы кызлары кунакларны дәү пар чыршы каршысына бастырган. Аландагы дәү чыршылар, икесе берьюлы иелеп: «Исәнмесез, кунаклар!» — дигән. Кунаклар үз чиратында:
— Исәнмесез! — дип җавап биргәннәр.
— Безне зурлап, безнең белән бәйрәм итәргә килүегез өчен мең-мең рәхмәт сезгә, — дигән пар чыршы. — Юкса балаларыбызга күңелсез булыр иде. Күптән инде аларның берәр Яңа ел бәйрәмен яхшы күңелле, саф җанлы кешеләр белән үткәрәсе килә иде.
— Без... — дип сүз башларга теләгән әти кеше. Таһир белән Зөһрә әтиләренең ни әйтергә теләвен шундук сизеп алган. Һәм алар кызарышып башларын түбән игәннәр.
— Бе-ез... Бе-езне гафу итегез, чыршыкайлар. Без сезне кисеп алып кайтырга дип килгән идек, — дигән Таһир белән Зөһрә, көчкә-көчкә телләрен әйләндереп.
— Юк, юк, — дигән пар чыршы, — сез шаяртасыз. Әнә бит кулларыгызда балта түгел, ипи телемнәре. Сез безнең кырда үскән икмәк исләрен, дала җилләренең шавын, аналар кулының җылысын сагынганыбызны белгәнсез. Шуңа бу хуш исле ипи телемнәрен алып килгәнсез. Рәхмәт сезгә, кадерле кунаклар.
Пар чыршы кунакларга башын игән. Шул вакыт Таһир белән Зөһрә кулларындагы ипи телемнәрен аларга сузганнар.
— Күчтәнәчебез зур түгел инде...
— Күчтәнәчнең кечкенәсе, зурысы булмый, — дигән дәү Чыршы. — Зур итеп алсаң, зур була ул.

Һәм ни гаҗәп, ипи телемнәре алан уртасындагы пар чыршы кулына күчүгә, тулган Ай зурлыгындагы түп-түгәрәк күмәчкә әверелгән. Дәү чыршылар бу күмәчне үзләре тирәсендәге яшь чыршыларга сындырып-сындырып бирә башлаган. Күбрәк өләшкән саен, күмәч зурая гына икән.

Таһир белән Зөһрәнең гаҗәпләнүен күргән дәү чыршы:

— Шатлык ул шундый нәрсә: яшереп яткырсаң — кими, кешеләргә өләшсәң — арта. Сезнең ипи телемнәрегез менә үзегезгә дә калды әле.

Чыршы боларның ипиләрен үзләренә сузган:

— Алыгыз, ал, кыенсынмагыз. Хәзер бергәләп бәйрәм итә башлыйбыз.

Ул шулай диюгә, әллә кайлардан тиеннәр сикерешеп килеп ботакларга кунган. Койрыгы белән яңа яуган карларны себерә-себерә бер төркем төлке килеп чыккан. Алар артыннан ук Аю белән Бүре тәпәне белән балны, икесе-ике ягыннан күтәреп, алан уртасына шап иттереп китереп куйган. Ап-ак тунлы бер көтү куян күренүгә, хәтта бераз буран тузгып алган.

Барлык кунаклар җыелып беткәч, бәйрәм башланып киткән. Ул бәйрәмнең кызыклыгын, күңеллелеген сөйләп кенә бетерә торган түгел. Моның өчен үзең шул урманга бару кирәк, ләкин биленә балта кыстырып түгел, учларыңа бәйрәм күчтәнәче тотып. Әйе, әйе, нәкъ шулай. Чөнки без Яңа ел бәйрәмендә бүләкләр, күчтәнәчләр көткән кебек, серле урман да бездән бүләк-күчтәнәч көтә. Әгәр урманга алып барырга күчтәнәчебез юк икән, һич югы, җылы кулыбыз белән чибәр чыршыларның башларыннан сыйпыйк. Без яратып башларыннан сыйпасак, алар тагын да матурланыр һәм шушы гүзәллеге аларның безгә рәхмәте, бүләге булыр. Мин ышанам, алар әле сезне җыр җырлап озатып та калырлар.

Җиребез бер генә, күгебез бер генә,
Бергәләп төшеник шуларның серенә.
Җиребез хакына, күгебез хакына
Мәрхәмәт саклыйк без күңелләр түрендә.

# Әкият-пьесалар

## ИСЕМСЕЗ КЫЗ

Алып баручы

Борын заманда кара урманда
Гомер сөргән, ди, карт белән карчык.
Дәү наратларны кисәргә җәлләп,
Корганнар алар балчык алачык.
Ничә ел шунда яшәгәннәрен
Күкеләр генә барганнар санап.
Озак яшәүнең серен аларга
Өйрәткән, имеш, мең яшьлек нарат.
Дәү имәннәрдән ныклыклар алып,
Кошлар җырыннан шатлыклар табып,
Торганнар болар уйнап та көлеп,
Матур тормышның кадерен белеп.
Күп еллар үткәч, кызлары туган,
Кыз гүзәл икән, китәр, ди, исең.
Ата-анасы үлеп киткән, ди,
Үз кызларына кушалмый исем.
Үксез, исемсез диеп тормаган,
Каеннарга ул тотынып үскән.
Урман иленең тәмле һавасы,
Саф чишмәләре аңа килешкән.
Куяннар белән әбәкле уйнап
Йөргән чаклары калганнар артта.
Ерак сәфәрләр, билгесез илләр
Башлаган аның күңелен тарта.
Ләкин сәфәргә чыгып китәргә
Аның бит әле исеме булмаган.
Уйлана торгач, кыз болай иткән:
Бар җәнлекләрне җыйган кунакка.
— Дусларым, — дигән, — мин бит исемсез,
Исем кушыгыз сузмый озакка.

Куян

Дөрес әйтәсең, гүзәл кыз,
Исемсез булмый яшәп.
Әйдә сиңа Куян кушыйк,
Куян исеме бик тә шәп.

Төлке

Куян да булдымы исем,
Надан булма шулчаклы.
Төлке дип кушабыз аңа,
Минем исем бик затлы.

Бүре

Юк, җәмәгать, матур кызга
Кушабыз матур исем:
Моннан соң аны һәр җәнлек

Олылап Бүре дисен.

Аю

Сез нәрсә сөйлисез монда,
Куян да Бүре, имеш.
Кыз минем шикелле матур,
Исеме дә һичбер сүзсез
Аю булырга тиеш.

Болан

Юк, кардәшләр, болай булмый,
Бер ныклап уйлыйк тагын.
Исем гомергә бирелә,
Ялгышып куймыйк тагын.
Нинди исем сайласаң да,
Кирәк аңа тугрылык,
Исемең белән җисемең
Аерылмас булырлык.

Кыз

Бишекне минем җилләр тирбәткән,
Әгәр көйсезләнсәм — кошлар юаткан.
Авырган чакта сердәш каеннар
Чык суы белән иренем чылаткан.
Урман шаулавы күңелемә салган
Җир һәм күкләрне ярату хисен.
Ата-анамнан бай дөнья калган,
Калмаган бары бер нәрсә — исем,
Әйтегез миңа: инде нишләргә?
Исемсез яшәү кыен, бик кыен.
Нәкъ үзем өчен яраклы булган
Исем табуда минем бар уем.

Алып баручы

Бәхәсләшкәннәр җәнлекләр,
Тавыш купкан урманда.
Бер фикергә килү читен
Тавышлар күп булганда.
Сүзгә кушылган тиеннәр,
Саесканнар, каргалар.
Тик үз исемен атаудан
Ерак китмәгән алар.
Исем кушу алар өчен
Ят бернәрсә булганга,
Исем кушучы булмаган
Ошбу кара урманда.
Ялварган кыз исем сорап
Каеннарга, талларга.
Тик алар да һичбер исем
Табалмаган аларга.

Кыз

Әй Карурман, Карурман,
Ник хәлемә кермисең?
Юкмы сер капчыгыңда
Миңа дигән бер исем?

Карурман

Юк шул, балам, капчык буш,
Саран да бу дисеңме? —
Җәнлекләр алып бетерде
Миндә булган исемне.

Кыз

Җилләр, җилләр, бәлки, сез
Бер исем китерерсез.
Бер исем китерерсез дә
Бәхетле иттерерсез.

Җил

Әй чибәр кыз, әйттең сүз,
Без бит бик тә хәтерсез.
Башыбыз юк уйларга,
Тик койрык бар уйнарга.

Кыз

Кемнән исем сорыйм инде,
Ярдәм итегез миңа.
Исемсез килеш яшәгәч
Күңелсез миңа дөнья.
Җирдә бит яши кешеләр
Исем алып, ат алып.
Исемсезләр кала алмый
Хәтерләрдә сакланып.
Әй Аккошым, әгәр китсәң
Диңгез аръякларына,
Алып кайт әле бер исем
Салып канатларыңа.
Ул исемгә тап төшерми,
Тотармын саклап кына.
Яшәрмен матур эш белән
Исемемне аклап кына.

Аккош

Нәрсәгә сиңа ул исем,
Яшә шулай исемсез...

Кыз

Исемсез яшәп булмый шул,
Яшәсәң дә киемсез.
Исемем булса, исемем белән
Дәшәр иде һәрбер җан.
Кайтавазларда кабатлап
Торыр иде карурман.
Ә исемем булмагачтын
Әллә бар мин, әллә юк,
Үзем дә белмим үземне —
Әллә боз мин, әллә ут.

Алып баручы

Барлык җәнлекләр

Исемсез кызны
Бик тә жәллләгән.
Ләкин берсе дә
Ярдәм итәрдәй
Чара белмәгән.
Кыз елый-елый
Күз яшьләрендә
Эреп беткән, ди.
Ә ул күз яше
Җирнең куенына
Кереп киткән, ди.
Кышлар үткәчтен,
Язлар җиткәчтен
Бу тамчы тулып,
Карлар астынан
Килеп чыккан, ди,
Бер чәчәк булып.
Кешеләр аңа
Умырзая дип
Кушканнар исем.
Кыз бик шат икән
Дөньяга язлар
Китергән өчен.
Яз чәчәгенә
Әйләнүенә
Үкенми, ди, кыз.
Чөнки ул хәзер
Ак кар өстендә
Исемле йолдыз.

Тәмам.

## ХӘЗИНӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакча. Хәким карт йорты. Тышкы яктан бик матур җимеш бакчасы күренә. Өйнең эче гади генә җиһазланган. Хәким карт авырып түшәккә егылган. Улларын үз янына чакыра.

Хәким *(караватына торып утыра).* Улларым! Хафиз, Алмаз! Керегез әле монда. (*Үрелеп тәрәзә кага.*) Улларым, дим, улларым! Керегез әле.

Хәким картның уллары керә. Хафизның кулында кызыл алма.
Алмазның кулында көнбагыш.

Хафиз *(алмасын каба да).* Нәрсә, әти?

Алмаз *(көнбагышын берәм-берәм авызына җибәреп).* Нигә чакырдың тагын?

Хәким. Килегез әле мондарак. Утырыгыз әле яныма. *(Уллары карават янындагы урындыкка утыралар.)* Менә нәрсә, улларым. Һәр ишекнең биге була, гомернең чиге була дигәндәй, минем дә бу дөнья белән саубуллашыр көнем килеп җитте. Авызымда — телем, башымда акылым барында сезгә бер серемне әйтеп калдырасым килә.

Хафиз *(алмасын тешләп).* Нинди сер ул, әти?

Алмаз *(көнбагыш чиертеп).* Сер нәрсә соң ул, әти?

Хәким. Сер ул — сез белмәгән нәрсә, балалар.

Хафиз. Кызык! Без белмәгән нәрсә бар икән дөньяда? Мин инде өй кыегындагы чыпчык оясында ничә бала барын да беләм.

Алмаз. Һи, чыпчык баласы нәрсә ул! Ә мин үзебезнең песинең ничә мыегы барын беләм.

Хафиз. Белсәң әйт: ничәү?

Алмаз. Siксән җиде ярым.

Хафиз. Сиксән җиде ярымга кадәр саный да белмисең әле син.

Алмаз. Син үзең белмисең. Мин инде сиксән җидене генә түгел, алтмыш алтыга кадәр саный беләм.

Хәким. Туктагыз әле, балалар. Мин бит сезгә бик җитди нәрсә әйтергә җыенам.

Малайлар икесе бергә. Җитди нәрсә ни була тагын?

Хәким. Аннан башка яшәп булмый торган нәрсә.

Хафиз. Алайса, ипи инде ул. Ә мин инде ипине ашый беләм.

Алмаз. Ипине аны сындырып та ашап була.

Хафиз. Булса соң! Мин кисеп ашыйм. Кискән ипигә май ягу җайлырак.

Алмаз. Ә мин авызга бер уч көнбагышны кабам да шуларны берәм-берәм ярып ашыйм. Минем авызым бик акыллы: көнбагышны кабыклы килеш йотмый.

Хафиз. Минем авыз тагын да акыллырак — тәмлене тәмсездән шундук аера. Тешләрем дә корычтан каты. Теләсә нинди чикләвекне шалт кына итәм.

Хәким. Авызларыгызның — «акыллы», тешләрегезнең үткен икәнлеген беләм, балалар. Ләкин яшәр өчен алар гына җитми. «Акыллы» авызларыгызны һәр көн туйдырып торыр өчен эшчән куллар кирәк.

Хафиз *(кулын әтисенә күрсәтә).* Әти, мин беркөнне шушы кулларым белән менә моның кадәрле *(кулларын җәеп күрсәтә)* шалканны йолкып чыгардым. Берүзем. Тамырларының шатыр-шотыр итеп йолкынуын үзең дә ишеткәнсеңдер.

Хәким *(көлемсерәп).* Беркөнне нәрсәдер дөбер-шатыр килгән иде шул. Мин берәр дию пәрие әллә йөзьяшәр имәнне тамыры белән умырып алдымы дигән идем.

Хафиз. Юк, әти, минем шалкан йолкыганны ишеткәнсең син.

Хәким. Алай икән, алай.

Алмаз. Минем куллар, әти, тагы да көчлерәк: ташка бәрсәм — таш ватыла, башка бәрсәм — баш ватыла.

Хәким. Ярый алайса, балалар, кулларыгызның — көчле, авызыгызның «акыллы» икәненә ышандырдыгыз. Болай булгач, мин тынычланып үлә алам.

Уллары шыңшый башлый. Юк, үлмә, әти. Без сине бик яратабыз.

Хәким. Юк, балалар. Дөньяда качып котылып булмый торган ике нәрсә бар: берсе — әҗәл, икенчесе — үзеңнең намусың. Намусым, Аллага шөкер, чиста булды. Инде менә сезгә бая әйтергә теләгән серемне чишәм. Мин үлгәч, тормышларыгыз авыраеп китсә, болай эшләгез. *(Хәким картның хәле китә. Ул куллары белән күкрәген тота, еш-еш сулый башлый.)*

Хафиз *(еламсырап).* Әти, әти, үлмә инде.

Алмаз. Бөтен сүзеңне дә тыңларбыз. Үлмә, әти!

Хәким. Уф, хәлем бетте. Әйтәсе сүзем шул, балалар: бакча артында бер тау бар, тау артында бер тал бар. Шул талдан ерак түгел бер таш ятар. Тормышларыгыз авыраеп китсә, әнә шул таш астын казыгыз. Анда сезнең гомерегезгә җитәрлек хәзинә яшерелгән.

Шул сүзләрне әйтүгә, Хәким карт түшәгенә егыла. Алмаз белән Хафиз елаша башлыйлар.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хафиз белән Алмаз алмагач төбендә яталар. Әтиләре үлгәннән соң күпмедер вакыт үткән.

Хафиз. Алма пеш, авызга төш. *(Шул вакыт бер алма Хафизның авызына килеп төшә.)* У-у, шулчаклы каты төшмәсәң ярамыймыни? *(Алманы бер тешли дә читкә атып бәрә.)* Туйдым мин бу алмадан, бүтән нәрсә ашыйсы килә.

Алмаз. Минем дә авызым тәмлерәк нәрсә сорый.

Хафиз. Нәрсә ашарга икән? Әтидән калган бәрәңге бетте.

Алмаз. Кишер-шалкан беткән.

Хафиз. Чияләрнең яфраклары саргайды.

Алмаз. Көнбагыш та калмады.

Хафиз. Ипи пешерер идек, онны күселәр ашап бетерде.

Алмаз. Әти үлгәч, бакчадагы бөтен нәрсә корыды.

Хафиз. Бердәнбер шушы алмагач калды.
Алмаз. Әнә аның да кайбер ботаклары корып килә.
Хафиз. Алмагачыбыз да корыса, нәрсә ашарбыз инде? *(Шыңшый башлый. Аңа Алмаз да кушыла. Алмагач төбендә елашып утырганда, дөп итеп бер алма өзелеп төшә. Малайлар югарыга карыйлар. Ә анда бер алма да калмаган.)*
Хафиз. Соңгы алма да өзелеп төште.
Алмаз. Инде нишлибез? Бакча бит безне ашатып тора иде.
Хафиз. Әйе. Аның җимешләрен кешеләр сатып ала иде.
Алмаз. Акча булгач, тәмле-тәмле нәрсәләр сатып алып була иде.
Хафиз *(көрсенеп).* Бар да бетте.
Алмаз. Карале, Хафиз, әти бит үлгән чакта ниндидер хәзинә турында әйткән иде.
Хафиз *(җанланып).* Әйе шул. «Таш астында гомерегезгә җитәрлек хәзинә бар» диде.
Алмаз. Әйдә, көрәкләр алабыз да шунда китәбез!
Хафиз. Әйдә!

Сикереп торалар да коймага сөяп куелган көрәкләрне алалар. Җырлап атлыйлар.

Хафиз. Хәзинә ул алтындыр...
Алмаз. Хәзинә ул көмештер.
Икесе бергә.
Алтын булса да,
Көмеш булса да,
Безгә тигән өлештер.
Хафиз. Хәзинәне казырбыз.
Алмаз. Гомерлеккә баербыз.
Икесе бергә.
Алтын-көмешкә
Иртә дә, кич тә
Прәннекләр алырбыз.

Тау артында тал астындагы таш янына килеп җитәләр.

Хафиз. Менә ул таш!
Алмаз. Менә хәзинә!

Казый башлыйлар. Ләкин көрәкләре җиргә керми.

Хафиз *(маңгаен сөртеп).* Уф, каты!
Алмаз. Әти шуны бераз йомшартып та калдырмаган.
Хафиз. Әйтмә дә! Карале, Алмаз, әйдә ташын каерып карыйбыз.
Алмаз. Әйдә.

Ташны каерып алырга маташалар. Такмак әйтеп каералар.

Һоп-һоп бер булды.
Һоп-һоп ике булды.
Икедән соң өч булыр.
Таш күтәрер көч булыр.
Һоп! Юк!

Күпме маташсалар да, таш кузгалмый. Малайлар арып таш өстенә утыралар.

Алмаз. Инде нишләргә? Казыр идең — җире каты. Күтәреп алыр идең — ташы авыр.
Хафиз. Теге вакыт әти алдында бик мактанган идең бит.
Алмаз. Нәрсә дип?
Хафиз. Ташка бәрсәм — таш уала, башка бәрсәм — баш уала дип кем әйтте?
Алмаз. Әйтсә соң?! Бик ачуны китерсәң, тотармын да ватармын.
Хафиз. Сөйләшеп торган буласың. Чикләвек тә вата алмыйсың бит син.
Алмаз. Минме ваталмыйм?! Китер чикләвегеңне, ватып күрсәтәм.
Хафиз. Син ташны ватып күрсәт.

Алмаз. Ватып күрсәтсәм, нишләрсең?
Хафиз. Күрермен.
Алмаз. Күр алайса! *(Бар көченә йодрыгы белән ташка китереп суга.)* Ай-вай, кулым үлде!
Хафиз. Кая?
Алмаз. Менә! Йодрыгым ачылмый.
Хафиз. Китер, хәзер ачабыз аны. *(Алмазның кулына кычыткан тидерә. Алмаз үзе дә сизмәстән йомарланган йодрыгын ачып җибәрә.)* Ай-яй каты суктың син. Кая әле, таш ярылмады микән?

Ташка карыйлар. Таш ярылган. Ярыктан тамчылап кына су саркып чыга.

Алмаз *(күкрәгенә сугып).* Ташны ярганмын бит, ә!
Хафиз. Әйдә тагын бер сук инде алайса. Бер бәреп су чыгардың, ике бәрсәң, хәзинә чыгар.
Алмаз. Сугабыз аны. *(Кизәнеп ташка суга. Таш астыннан су чаптырып чыга башлый.)*
Хафиз. Һи, һаман су да су. Хәзинәсе кая икән соң моның?
Алмаз. Таш астындадыр. Әйдә, ташларны кубарып алып ташлыйк та хәзинәсен тартып чыгарырбыз.

Бергәләп ташка ябышалар.

Каерабыз, ватабыз, һоп!
Аннан баеп ятабыз, һоп!
Конфет булыр авызда, һоп!
Акча булыр сагызга, һоп!
Бал ашарбыз кашыклап, һоп!
Чәй эчәрбез катыклап, һоп!
Тау-тау булыр прәннек, һоп!
Әйдә-әйдә күтәрик, һоп!

Ташны каерып ташлыйлар. Ләкин аннан һаман саен су гына бәреп чыга. Таш астыннан чыккан су әкренләп бакчага таба юл ала. Малайлар хәзинә таба алмауларына күңелсезләнеп, арып-талып ташка утыралар.

Хафиз. Карале, Алмаз, әллә эти безне алдады микән?
Алмаз. Син нәрсә? Әтинең безне кайчан алдаганы булды?
Хафиз. Алайса, хәзинә кайда соң?
Алмаз. Алайса, берәрсе алып киткәндер.
Хафиз. Юк, алмаган.
Алмаз. Каян беләсең алмаганнарын?
Хафиз. Җир казылмаган, таш кузгалмаган бит.
Алмаз. Баш бар икән синдә.
Хафиз. Минем баш кына түгел, авыз да бар. Ә авызның ашыйсы килә.
Алмаз. Минеке килми дип беләсеңме әллә?
Хафиз. Нишлибез соң инде?
Алмаз. Белмим.

Башларын аска иеп таш өстендә утыралар. Шул вакыт кош сайраган тавыш ишетелә. Малайлар башларын күтәрәләр.

Хафиз. Кош сайрый түгелме соң?
Алмаз. Әйе, кош сайрый шул.
Хафиз. Бакча корыгач, кошлар да безнең агачларга кунмый башлаган иде бит.
Алмаз *(бакчага таба күз сала һәм кычкырып җибәрә).* Карале, кара, Хафиз. Безнең бакча яшәргән бит.
Хафиз. Чынлап та, бөтен агачлар терелгән. Чәчәкләр башларын күтәргән.
Алмаз. Ур-ра! Болай булгач яшибез.
Хафиз. Бакча терелгән. Бакчага кошлар кайткан.
Алмаз. Беләсеңме нәрсәдән бу?
Хафиз. Нәрсәдән?
Алмаз. Менә бит *(агып ята торган чишмәгә күрсәтә),* әтинең хәзинә дигәне шушы чишмә булган икән.
Икәүләп кычкыралар: Әти, без синең хәзинәңне таптык. Рәхмәт хәзинәң өчен, әти. Мең-мең рәх-мәт!

Тәмам.

# КАРАКНЫҢ БҮРЕГЕ ЯНА

Катнашалар:

Көтүче яки Хуҗа.
Алабай.
Соры.
Кәҗә бәтиләре.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә уртасында көтүче куышы. Еракта бик матур су буе күренеше. Бормаланып-бормаланып елга ага. Яр буйлары ямь-яшел таллык. Еракттан зәңгәрләнеп тау күренә. Тау итәгендә кәҗә бәтиләре утлап йөри. Пәрдә ачылганда, көтүче чыбыркы ишеп утыра. Хуҗалары янына Алабай белән Соры сузылып яткан. Алларында кимерелеп шәп-шәрә калган сөяк. Көтүче моңлы җыр суза.

Иртә таңнан кояш баткангача
Көтү көтеп уза көннәрем.
Гүзәл табигатьнең бер улы мин —
Һәр җәнлекнең беләм телләрен.
Кошларга мин кош телендә дәшәм,
Чәчәкләргә — чәчәк телендә.
Бар дөньямны күңелемә сыйдырып,
Яшим серле әкият илендә.

Соры *(кимерелгән сөяген күтәреп, көтүче янына килә).* Хуҗам, ә, Хуҗам?

Көтүче. Нәрсә, Сорыкай?

Соры. Менә бу сөякнең син берәр итле җирен күрәсеңме?

Көтүче *(сөякне алып әйләндереп карый).* Юк, күрмим. *(Сөякне Сорыга суза.)*

Соры. Мин дә күрмим шул. Монда чебен кунса да таеп егылачак. Корсакны алдалап булмасмы дип, көне буе шуны кимергән булам. Юк. Корсак алданмый, һаман ит сорый. *(Корсагын уа.)*

Көтүче. Ит сорый диген, ә?

Соры. Әйе, ит сорый, Хуҗам.

Көтүче *(Алабайга).* Синеке дә ит сорыймы, Алабай дус?

Алабай. Минеке дә ит сорый, Хуҗам.

Көтүче *(хыялга бирелеп).* Ит, ит! Ә беләсезме, дусларым, көзгә безнең кәҗә бәтиләребез үсеп җитәр. Әгәр аларны комсыз бүреләрдән урлатмыйча саклап үстерә алсак, кыш буе җылы куышыбызда ит ашарбыз.

Соры. Кыш көне туйганчы сыйлармын дигәнгә генә тамак туймый бит, Хуҗам.

Алабай. Әйе. Безгә ит бүген кирәк.

Көтүче. Ярый алайса. Бик ачыкканда гына ашатырмын дип саклап торган ике калҗа итем бар иде. *(Куышына кереп китә дә ике калҗа ит алып чыга.)* Мәгез, ашагыз. Ә мин ерак урманга барам. Бәлки, берәр киек җанвар аулап булыр.

Соры. Мин дә синең белән барам, Хуҗам.

Алабай. Мин дә.

Көтүче. Юк, дусларым. Сез көтү көтәргә каласыз. Юкса кәҗә бәтиләребез урманга качып бетәрләр.

Соры *(күңелсезләнеп).* И-и, минем синең белән барасым килә иде, Хуҗам. *(Койрык болгап Хуҗа янында бөтерелә.)*

Көтүче *(Сорының башыннан сыйпап).* Ярамый, дустым. Көтү таралыр да, кышка ач калырбыз. Йә, ярый, дусларым. Миңа китәргә вакыт. Калҗагызны берьюлы ашап бетермәгез. Әгәр дә кояш әнә теге тау артына өч тапкыр батып, өч тапкыр калыкканнан соң да мин кайтмасам — мине эзләргә барырсыз. Карагыз аны, көтүне әйбәт саклагыз!

Хуҗа китеп бара. Этләр Хуҗа биргән калҗаны ашап калалар.

Соры. Хуҗа сиңа калҗаның олырагын бирде бугай. Кая әле, күрсәт калҗаңны.

Алабай. Менә кара: тигез бит инде.

Соры. Юк, синеке олырак.

Алабай. Әйдә, алайса алмашабыз.

Этләр калҗаны алмашалар. Соры, комсызланып, берничә каба да яңадан янына килә.

Соры. Юк, үземнекен кире бир.

Алабай. Син үзеңнекенең яртысын ашадың бит инде.

Соры. Ашамадым, иснәдем генә.

Алабай. Мә алайса. *(Калҗаны бирә.)*

Соры *(канәгатьсез тавыш белән)*. Итләрегезне саклап тотыгыз, имеш. Моның нәрсәсен саклап тотасың?! Кабам да йотам мин моны!

Алабай. Ашыкмыйк әле, Соры дус. Әлегә бит бераз түзәргә була. Мин үземнекен куышка яшереп торам. *(Итен куышка кертеп куя.)* Бик ачыккач ашармын.

Соры. Син теләсәң ни эшлә. Мин ашыйм әле. *(Комсызланып калҗасын ашап бетерә.)* Хәзергә тамак туйды. Эшкә куарга Хуҗа юк. Рәхәтләнеп йоклап алырга була. *(Җиргә сузылып ята.)*

Алабай. Тор, тор, ятма. Хуҗа бит безгә көтүне сакларга кушты. Бәтиләр таралышып бетсәләр, Хуҗага ни дип җавап бирербез?

Соры. Гомер буе Хуҗа, Хуҗа дип калтырап яшәргә димәгән лә. Безгә дә ял кирәк. Мондый җай гел-гел чыкмас. Рәхәтләнеп йоклыйк, ял итик. Бәлки әле, безнең аланга берәр адашкан куян килеп чыгар, аны эләктерербез. *(Хыялланып.)* Карале, Алабай, әгәр куян эләктерсәк, аны ничек итеп ашарбыз икән? Бәлешен пешерепме, әллә шул килеш кенәме?

Алабай. Тотмаган куянның бәлешен пешереп утырмыйк әле. Әйдә, көтү янына китик.

Соры. Ә минем көне буе әлсерәп көтү көтеп йөрисем килми. Рәхәтләнеп ял итәсем, тәмле сыйлар белән сыйланасым килә. Ә беләсеңме, Алабай, дөньяда шундый бәхетле этләр бар икән: алар җылы өйдә генә яшәп, ак мендәрләрдә генә йоклыйлар икән.

Алабай. Кем әйтте сиңа аны?

Соры. Беркөн Саескан шулай сөйләп торды.

Алабай. Саескан ни белә ул! Кем инде этне ак мендәргә яткырсын?

Соры. Яткыралар икән шул менә. Әле ул гынамы? Аларның алларында без исемнәрен дә белмәгән, ишетмәгән әллә нинди тәмле ризыклар, ди. Их, шундый Хуҗага эләгеп булмады.

Алабай. Хуҗаны сайлап алмыйлар.

Соры. Шулай да минем бер рәхәт тормышта яшәп карыйсым килә. Ит дип уйлауга ук, алдыңа майлы калҗа килсен. Сөт дип уйлауга, сөт елгасы агып торсын иде. Шунда мин сөяктән шәп сарай салып куяр идем. Телисең икән — сараеңның бер почмагын кимер, бу почмагы ошамаса — теге почмагын кимер. Йоклаганда баш астына да сөяк салып ятар идем. Их!

Алабай. Юк хыяллар белән баш ватмыйк әле. Көтү таралганчы, бәтиләр янына китик. Юкса Хуҗага нәрсә дип җавап бирербез.

Соры. Исең киткән икән. Табарбыз әле берәр хәйлә.

Алабай. Гомер буе Хуҗабызга тугры булдык, бүген генә хәйләләмәбез бит. Әйдә, дустым, ялкауланма! *(Сорыны төрткәләп диярлек алып чыгып китә.)*

Этләр чыгып китүгә, сәхнәгә ике кәҗә бәтие керә. Алар сәхнәдә чабышып йөриләр.

Беренче бәти. Без көтүдән качтык. Кызык иттек. Эзләсеннәр әле безне.

Икенче бәти. Әйе. Эзли-эзли арып бетсеннәр. Ә без синең белән әбәкле уйныйбыз, яме!

Беренче бәти. Әйе. Әйдә башлыйбыз.

Әбәк-чәбәк, көрәк-сәнәк,
Тота алсаң, булыр әйбәт.

Әбәкли дә йөгереп китә. Икенче бәти аны тота, ул да әбәкли. Болар шулай әрле-бирле чабышып йөргәндә, еракта бүре улаган тавыш ишетелә. Бәтиләр кинәт уйнаудан туктыйлар.

Беренче бәти. Мин куркам *(урманга күрсәтә)*. Анда бүре бар.

Икенче бәти. Мин дә куркам.

Беренче бәти. Әйдә тизрәк көтүгә, әти-әниләр янына чабыйк.

Икенче бәти. Ә көтү кайсы якта соң? Мин кайта белмим.

Беренче бәти. Мин дә белмим.

Икенче бәти. Без адаштык. *(Шыңшый башлый.)*

Беренче бәти. Инде нишлибез? *(Ул да елый башлый.)*

Икенче бәти. Безнең батыр көтүчебез кайда икән соң?

Беренче бәти. Менә бит аның куышы. Әйдә, шунда керәбез. Көтүче куышына бүреләр дә керергә куркырлар.

Икенче бәти. Син алдан кер.

Беренче бәти. Ни өчен мин алдан?

Икенче бәти. Чөнки синең мөгезең очлырак.

Беренче бәти. Ә синең сакалың олырак, шулай булгач, син алдан керергә тиеш.

Икенче бәти. Бар инде, бар. Син алдан кер, мин монда бүреләр килмиме дип карап торам.

Беренче бәти. Тик кара аны, минем арттан ук кер. *(Беренче бәти куышка башын тыга да куркып кире чигенә.)* Ай, ай!

Икенче бәти. Нәрсә бар?

Беренче бәти. Анда караңгы.

Икенче бәти *(куышка карый).* Ай! Анда нидер кыштырдый бугай. Үлән астыннан бүре хәтле тычкан килеп чыкса...

Беренче бәти. Инде нишлибез? Алабай белән Сорыкай да күренми, ичмасам.

Икенче бәти. Әйттем мин сиңа, урман эченә кермик, дип.

Беренче бәти. Үзең бит, качып кызык итәбез, дидең.

Икенче бәти. Минме?

Беренче бәти. Син булмыйча, кем булсын?

Икенче бәти. Их, эти-әниләребез йөргән көтүне тапсак, яңадан еракка китеп йөрмәс идек.

Беренче бәти. Сүзләрен тыңлар идек.

Болар шыңшып елашып утырганда, Соры кайтып керә.

Соры. Менә кайда икәнсез! Ә без Алабай белән ялан бетереп аларны эзлибез. Уф! Табаннар ут яна. Ух сезне! *(Бәтиләргә ырлый.)*

Бәтиләр. Безне гафу ит инде, Сорыкай. Без ялгыш кына. Адашып кына.

Соры. Ялгыш, имеш. Адашып, имеш. Күрсәтермен мин сезгә ничек адашырга. *(Ырлап куя.)*

Бәтиләр. Бер юлга гафу ит инде, Сорыкай. Яңадан бер дә сүзеңнән чыкмабыз.

Соры. Йә, ярар. Минем йомшаклыгымның рәхәтен күрегез инде. *(Як-ягына карана. Бәтиләргә.)* Сез икегез ике якка карап торыгыз. Алабай күренсә, тиз генә хәбәр итәрсез. Ә мин ул яшергән калҗа белән сыйланып алыйм. *(Калҗаны куыштан алып чыгып ашый.)* Аһ, тәмле булды! *(Авызларын сөртеп куя. Бәтиләргә бармак янап.)* Карагыз аны, Алабай кайтып ит турында сораса, күрмәдек, диегез. Юкса...

Бәтиләр куркышып калалар.

Беренче бәти. Без алдаша белмибез бит.

Икенче бәти. Әйе, алдашу бик начар, ди әнием.

Соры. Ә-ә, шулаймы? Алай алдашудан курыксагыз, мин сезне әнә теге карурманга куам да кертәм. Төнгә каршы анда бүреләр дә җыела. Ашап бетерсеннәр үзегезне.

Бәтиләр. Сорыкай, зинһар, безне урманга кума.

Соры. Юк инде, мин әләкчеләрне яратмыйм.

Беренче бәти. Дөресен әйтү әләкләү булмый.

Икенче бәти. Әйе, без күргәнебезне генә әйтәчәкбез.

Соры. Әле һаман үзегезнекен сөйлисезмени?

Бәтиләр. Без ялганлый алмыйбыз.

Соры. Алайса, мин сезне кызык итим әле.

Бәтиләрне берәм-берәм куып тота да телләрен тартып ала. Бәтиләр кычкырышалар, елашалар.

Соры. Менә моннан соң ялганны да, хакны да сөйли алмассыз инде.

Бәтиләр бә-ә, бә-ә киләләр. Шул вакыт Алабай кайтып керә.

Алабай. Уф, арыдым. Бәтиләрне абзарга көчкә кертеп бетердем. *(Шул вакыт теге бәтиләрне күрә.)* Ә сез кайда йөрдегез? Сезне эзли-эзли табаннар төште бит.

Беренче бәти. Бә-ә.

Икенче бәти. Бә-ә.

Алабай. Нәрсә, телегезне йоттыгызмы әллә? Бә-ә дә бә-ә килеп торасыз.

Соры. Мин кайтып кергәндә, аларны ике бөркет егып салып телләрен йолкып тора иде.

Алабай. Син шулардан йолкытып тордыңмы?

Соры. Син нәрсә? Мин шунда ук көрәшкә ташландым. Ләкин соң иде шул инде. Бөркетләр хәтта синең куышка яшергән калҗаңны да ашап бетергәннәр иде.

Алабай. Калҗамны? Ә мин шуны ашарга дип өметләнеп кайткан идем. Их, инде нишләргә? Шундый ачыктым. *(Бәтиләргә.)* Тормагыз әле юлымда. Барыгыз, әнә куыш артынарак барып ятыгыз. Иртәгә әнкәләрегез янына илтермен. *(Бәрәннәр куыш артына китә.)* Кара әле, Сорыкай, ашыйсы килә бит, нишләргә икән?

Соры. Минем дә бик ашыйсым килә, Алабай.

Алабай. Хуҗа да кайтмый, ичмасам.

Соры. Кояш теге тау артына ничә батып, ничә калыкты соң әле?

Алабай. Бер батып, бер генә калыкты шул әле.

Соры. Беләсеңме, Алабай, әйдә болай итәбез. *(Як-ягына карана.)*

Алабай. Ничек?

Соры. Тотабыз да бер бәтине ашыйбыз.

Алабай. Син нәрсә?! Хуҗа безгә ышанып көтүне калдырды, ә без аңа хыянәт итикме?

Соры. Син теләсәң нишлә, мин бер бәтине тотып ашыйм. *(Куыш артына бара башлый. Алабай аңа каршы төшә. Алар сугышып китәләр. Соры җиңә. Алабай егылып кала. Соры куыш артына китә.)*

Алабай *(аксаган аягын уып).* Хуҗа гына кайтсын. Бер көн дә тоттырмыйм, кудыртам. Мондый оятсызлыкка, мондый юньсезлеккә ничек түзмәк кирәк?

Соры, авызларын ялмап, куыш артыннан чыга.

Соры. Ай-яй, тәмле! Сөякләренә чаклы ялт иттердем. Хәзер иртәгегә кадәр яшәргә була. *(Алабайга.)* Кара аны, Хуҗага әләклисе булма. Югыйсә дөнья белән бәхилләшәсеңне көт тә тор.

Алабай. Әллә шушы хыянәтеңне яшереп калырмын дип уйлыйсыңмы?

Соры *(җиргә сузылып ята).* Әләклә әйдә, әләклә. Әләкчегә кем ышаныр дип беләсең?

Алабай. Әләкләмим мин, дөресен генә әйтәм.

Соры. Алайга китсә, мин аңа бәтине син ашады диярмен. Ашамаганлыгыңа ышандырып кара.

Алабай. Хак сүзгә дәлил кирәкми. Сукыр булмаса, ышаныр.

Соры. Ярар. Юк сүз белән башымны катырма. Минем йокым килә. Тамак туйдымы, мине йокы баса башлый. Күрәсең, мин синең кебек урам эте генә түгелдер, берәр затлы нәселдәндер.

Соры җиргә сузылып ята, гырылдап йокыга да китә. Алабай урман ягыннан килгән тавышка колак сала. Анда бүреләр улаган тавышлар ишетелә.

Алабай. Абзар тирәләрен урап килим әле. Бәтиләрне бүреләр чәлә күрмәсен. Көтү башлыгы Кәкремөгез дә бик картайды.

Алабай китә. Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук көтүче куышы. Пәрдә ачылганда, Алабай белән Соры эчләрен уып утыралар.

Соры. Ашыйсы килә, каһәр суккыры.

Алабай. Минем эчәгеләр берсенә берсе ябышып бетте бугай инде.

Соры. Кояш та өч тапкыр батып, өч тапкыр калыкты. Ә Хуҗа һаман юк.

Алабай. Бәлки, берәр бәлагә юлыккандыр?

Соры. Безне ач калдырыпмы?

Алабай. Бәлки, инде ул исән дә түгелдер?

Соры. Рәтле Хуҗа, үлгәнче, безне кайтып ашатыр иде.

Алабай. Син һаман үзеңне генә уйлыйсың.

Соры. Карале, Алабай, әйдә, икенче бәтине дә ашыйбыз.

Алабай. Син нәрсә? Тегесе өчен дә Хуҗа башыңнан сыйпамас әле.

Соры. Берне ашадың ни, икене ашадың ни! Ике гөнаһка бер җавап. Мин ашыйм. *(Куыш артына китә башлый, ләкин Алабай аңа каршы төшә.)*

Алабай. Юк инде, үзем исән чакта мондый гаделсезлеккә юл куймам.

Соры. И хәчтерүш. Синең ише ач корсакларны без менә болай гына итәбез.

Соры Алабайны этеп җибәрә. Алабай егыла, ләкин Сорының сыйрагын тешләп ала. Соры чинап җибәрә. Алар пыр тузып сугышып ятканда, Хуҗа кайтып керә.

Хуҗа. Бу нинди тамаша? Нәрсәгә сугышасыз?

Соры *(ялагайланып).* Хуҗам-падишам, менә бу оятсыз син югында бер бәтине ашап куйды. Инде менә икенчесен ашарга бара иде, юлына төштем. Ә ул сыйрагымны тешләп алды. *(Еламсырап, сыйрагын Хуҗага күрсәтә.)* Менә теш эзләре ничек батып кергән.

Хуҗа таягы белән кизәнеп Алабайга суга.

Хуҗа. Ах, оятсыз, ах, җирбит! Кит хәзер үк моннан! Хыянәтчегә минем өемдә урын юк.

Алабай. Туктале, Хуҗам, тыңла мине.

Хуҗа. Туктамыйм да, тыңламыйм да. Алдакчыларны тыңларга минем вакытым юк... Мин сине тугры хезмәтчем дип йөрдем. Гомер буе тамагыңны туйдырдым. Әле дә менә аудан куян ите алып кайткан идем. Моннан соң сиңа бер кабым да ризык булмаячак. Мә, Сорыкай, аша. Бу ризыклар сиңа гына тиешле. *(Сорыга ризыкларын бирә. Соры, бер читкә китеп, комсызланып ашый. Хуҗа Алабайга.)* Ә син кит, мин өемдә хыянәтчеләр тотмыйм. *(Алабайны куа.)*

Алабай. Тукта әле, Хуҗам, тыңла әле. Бәтине бит мин түгел, Соры ашады.

Хуҗа. Әле син минем тугры хезмәтчемә яла да ягасыңмы? Мә шуның өчен, мә!

Хуҗа Алабайны кыйный. Алабай шыңшып әле бер, әле икенче якка чаба. Шул вакыт куыш артыннан бәти килеп чыга.

Бәти. Бә-ә, бә-ә. *(Ул Хуҗага нидер аңлатырга тели, ләкин Хуҗа аны аңламый.)*

Хуҗа. Нәрсә бә-ә дә бә-ә киләсең? Телең кая соң синең? Моңа тиклем мин бит сезнең барыгызның да телен аңлый торган идем. Ни булды сезгә?

Бәти. Бә-ә, бә-ә! *(Авызын ачып күрсәтә. Хуҗа аның авызында теле юклыгын күрә.)*

Хуҗа *(гаҗәпләнеп).* Телеңне кем өзде?

Бәти, бә-ә дип, Сорыны килеп сөзә.

Хуҗа. Нәрсә, телеңне Соры өздемени?

Бәти, «әйе» дигәнне аңлатып, башын селки.

Хуҗа. Ә-ә, синмени әле бу әшәкелекне эшләүче?

Соры. Юк, Хуҗам, юк. Яла яга ул. Аның телен бөркет тартып өзде. Үзен дә күтәреп китә иде әле, мин генә коткарып калдым. *(Бәтигә ырлап куя. Хуҗа икенче якка караганда, бәтине тешләп тә ала.)*

Хуҗа *(үз-үзенә).* Монда ни дә булса бар. Ничек итеп хакыйкатьне белергә соң, ә? Кемнән сорарга? Бәлки, Алабайны юкка кыерсыткanмындыр. Әгәр шулай булса, Алабай миңа гомере буе рәнҗер. Уф, башым катты, нишләргә дә белмим. *(Уйланып йөри. Шул вакыт аның башына бер фикер килә.)* Әһә, таптым! Болай эшләргә кирәк. Әй, Алабай, Соры! Килегез әле минем янга. Тиз булыгыз!

Этләр Хуҗа янына киләләр.

Хуҗа. Менә нәрсә, дусларым. Сез икегез дә үзегезне гаепсез димәкче буласыз. Хәзер мин сезнең кайсыгыз гаепле икәнен беләчәкмен.

Соры *(куркынып).* Ничек итеп?

Хуҗа. Хәзер күрерсез. Миңа тиз генә ике чыбык табып китерегез.

Соры. Безне кыйнаргамы? Юк инде, мин үземне кыйнатырга чыбык алып килмәячәкмен.

Алабай. Хәзер үзем алып киләм.

Соры. Ялагайлан әйдә, ялагайлан. Барыбер бәтине мин ашады дип исбатлый алмассың.

Хуҗа. Исбатлавын үзем исбатлыйм мин. Сез чыбык китерегез.

Алабай. Ниндирәк озынлыкта кирәк?

Хуҗа. Нинди озынлыкта булса да ярый. Ләкин икесе тигез булсын.

Алабай чыбыклар алып килә.

Алабай. Бик үк тигез булмады инде болар, Хуҗам.

Хуҗа. Зарар юк. Тигезлибез аны. *(Алабайдан чыбыкларын ала да тип-тигез итеп сындыра.)* Ягез, икегез дә килегез әле монда! *(Этләр Хуҗа янына киләләр.)* Карагыз әле, менә бу чыбыклар тигезме?

Алабай. Тигез.

Хуҗа. Син дә тигез дип раслыйсыңмы, Соры?

Соры. Тигез инде, тигез.

Хуҗа чыбыкларның үлчәмен алып кесәсенә сала.

Хуҗа. Инде хәзер менә бу чыбыкның берсен — берегез, икенчесен икенчегез авызыгызга кабыгыз.

Соры. Нигә, Хуҗам? Бу бит авызга сыймый.

Хуҗа. Очын гына кабыгыз. Очын капсаң, шул җитә.

Алабай. Кызык, кызык. Бу чыбык хакыйкатьне ничек ачар икән?

Соры. Авызга кабып күпме тотарга соң моны?

Хуҗа. Кайчан алырга икәнен вакыты җиткәч үзем әйтермен. Тик шуны белегез: бу чыбык гаепленең авызында озыная башлый. Безнең борынгы бабаларыбыз гаепле кешене шулай ачыклаганнар.

Соры *(куркынып).* Ә күпмегә озыная соң ул?

Хуҗа. Күпмегә озынайганын чагыштырып карагач күрәбез инде. Йә, ярый, чыбыкларыгызның бер башын кабыгыз. Ә мин бәтине тиз генә көтүгә илтеп кайтам. Карагыз аны, хәрәмләшә күрмәгез. Кайткач чыбыкларыгызны үлчәп карармын. Менә шунда инде бәтине кем ашаганлыгы беленер.

Хуҗа бәтине ияртеп чыгып китә. Сәхнәдә Алабай белән Соры гына кала. Алабай тыныч. Соры, киресенчә, бик борчулы. Ул әрле-бирле йөренә.

Алабай. Менә хәзер ялганың ачылачак инде.

Соры. Иртә шатланасың әле. Хуҗа сиңа түгел, миңа ышана. Ничек тә бер җаен табарбыз.

Алабай. Хәйлә белән ерак китеп булмый ул.

Соры. Карале, Алабай, әйдә моннан качабыз, ә?

Алабай. Хуҗаны япан кырда берүзен калдырыпмы?

Соры. Калдырса соң! Көтсен үзенең көтүен бездән башка. Без бүтән хуҗага ялланырбыз.

Алабай. Юк инде. Бер урлашып ашаган бәндәнең яңадан урлашмаса тамагы туймый. Синең белән беркая да китмим мин. Теләсәң, үзең кит. Әнә урманга, бүреләр арасына.

Соры. Шаярма, миннән алай гына котыла алмассың. Бүреләр арасына үзеңне кудыртам әле. Минем баш эшли. Син генә ул аңгыра...

Соры читкәрәк китә. Алабай күрмәгәндә, авызыннан чыбыгын алып, беразын сындырып ташлый.

Соры. Менә шәп булды. *(Җырлап йөри. Чыбыкны авызыннан әле бер, әле икенче ягына күчерә.)*

Алабайны кудыртам, кудыртам,
Хуҗабызны котыртам, котыртам.
Үзем генә калсам әгәр, калсам әгәр,
Бәтиләрне сыпыртам, сыпыртам.
Их, бар әле рәхәттә яшисе көннәр.

Хуҗа кайтып керә.

Хуҗа. Йә, китерегез әле чыбыкларыгызны. Кайсыгызныкы озынайды икән?

Алабай белән Соры, чыбыкларын авызларыннан алып, Хуҗага сузалар. Хуҗа аларны ала да үлчәп карый.

Соры *(кычкырып җибәрә).* Алабайныкы озын, Алабайныкы озын.

Хуҗа. Әйе, Алабайныкы озын.

Соры. Әйттем бит, бәтине Алабай ашады, дип. Ә син телсез бәтинең бәэлдәвенә карап шикләнгән булдың. *(Үпкәләгән булып.)* Үзеңнең иң гадел, иң тугры хезмәтчеңнән шикләндең. Болай миңа шикләнеп карасаң, мин синнән китәрмен дә. Мин гаделлек яратам.

Хуҗа. Мин дә гаделләрне генә яратам шул. Кил әле, Алабай, монда. Менә бу озын чыбык синеке бит, әйеме?

Алабай *(башын иеп).* Минеке, Хуҗам.

Соры. Ай, оятсыз, ай юньсез. *(Хуҗага.)* Тизрәк куыйк үзен моннан. Юкса ул бөтен көтүеңне харап итәр. Өйдәге карак урмандагы бүредән дә яманрак. Бүре килсә бер килә, ә бу астыртын эшен көн саен эшләп ятар.

Хуҗа. Дөрес әйтәсең, Соры. Мин бүген өйдәге каракны урманга, бүреләр арасына куарга булдым.

Соры *(Алабайга).* Бар тизрәк, ялтырат табаныңны.

Хуҗа. Тукта, Соры, ашыкма, мин бит каракны, хыянәтчене куарга дидем.

Соры. Соң, кемнең карак икәнлеге ачыкланды лабаса. Алабайның чыбыгы озынайган бит.

Хуҗа. Бөтен хикмәт тә шунда шул: Алабайның чыбыгы озынаймаган, синеке кыскарган. Озынаюыннан куркып кыскарткансың син аны. Каракның бүреге яна, дип, дөрес әйтәләр икән. Гаебе булмагач, Алабай чыбык озынаер дип курыкмаган бит. Шуңа күрә кыскартмаган да. Сүзләремә ышанмасагыз — дәлилем дә бар. *(Кесәсеннән бер чыбык чыгара.)* Мин сезнең чыбыкларны үлчәгән идем. Менә Алабайныкы минем үлчәм белән тигез, синеке — кыска. *(Сорыга.)* Инде моннан соң да алдашырсыңмы?

Соры. Гафу ит, Хуҗам, мин гаепле. Карыным бик ачкач, түзмәдем, ашадым шул. Бүтән мондый эшне мәңге эшләмәм. Гафу итә күр. *(Еламсырап, Хуҗа янында бөтерелә.)*

Хуҗа. Карының ачкач, ашавыңны, бәлки, гафу да итәр идем, әмма үзеңнең аркадаш дустыңа гаебеңне аударуыңны кичерә алмыйм. Синең яла ягуың аркасында мин бер гаепсез Алабайны рәнҗеттем. Бар кит, күземнән югал! Сиңа бүреләр дус булсын. *(Соры башын иеп чыгып китә.)* Ә син, Алабай дустым, гафу итә алсаң, гафу ит. Мин синең алдыңда гаепле.

Алабай *(койрык болгый).* Һау-һау.

Тәмам.

## БӘХЕТ АЧКЫЧЫ

Катнашалар:

Салсал карт — сандыклар ясаучы оста.
Сим-Сим — картның песие.
Былбыл — тутый кош, шул ук Куаныч.
Моңсар — тутый кош.
Карчык.
Карт юлбасар.
Яшь юлбасар.

Пәрдә ачылганда, Салсал карт сандык ясап утыра. Аның аяк очына Сим-Сим сузылып яткан. Бер як иңенә Былбыл кунган. Салсал карт шактый йончылган, хәлсез. Аның кулыннан йә чүкече, йә кадагы төшеп китә.

Сим-Сим. Бабакай, арыгансың инде, ял ит.

Былбыл. Ял ит, ял ит.

Салсал. Юк, дусларым, ял итәр чаклар алда әле. Ә бүген сандыкны ясап бетереп, базарга алып чыгарга кирәк.

Сим-Сим *(сандыкка сокланып).* Бигрәк матур ясыйсың инде, бабакай.

Былбыл. Ма-тур, ма-тур!

Салсал. Матурлыкны күрә белүегез өчен рәхмәт, дусларым. Ә бит күпләр матур белән ямьсезне аера белми.

Сим-Сим. Аны аерырга син өйрәттең, бабакай.

Салсал *(сандыгына соңгы кадагын кагып).* Менә бетте дә. Йә ничек, ошыймы, дусларым?

Былбыл, Сим-сим. Искиткеч!

Салсал. Үземә дә ошый. *(Бераздан көрсенеп куя.)* Тик, дусларым, моннан соң сандыклар ясый алмам инде. Такталарым, калайларым, кадакларым бетте. Аларны алырга акчам да юк. Ә иң яманы — беләкләрдә гайрәт бетте. Үз һөнәремә өйрәтеп калдырырга, ичмасам, берәр улым да булмады. *(Күңеле йомшый, күзләреннән яшь чыга.)*

Сим-Сим. Телисеңме, бабакай, үзем өйрәнәм сандык ясарга. Мин чүкеч тота беләм инде. *(Ул чүкечне барып ала да кадакка сукмакчы була, ләкин кадакка түгел, кулына эләгә.)* Ай-яй, бетте кулым. Үлде.

Салсал. Маташма. *(Сим-сим кулыннан чүкечне ала.)* Дөньяга һәр җан иясе үз һөнәре белән яратыла. Син песи — синең һөнәр тычкан тоту.

Сим-Сим. Мин өйдәге бер тычканны да калдырмадым инде, бабакай.

Салсал. Әйбәт, әйбәт. Тырыш бит син.

Былбыл. Ә мин? Ә мин?

Салсал. Кошларның эше — сайрау.

Былбыл. Ә мин сайрый да алмыйм шул, күңелем үсми. Кешеләр миннән җыр көтә... Ә мин сагышлы.

Салсал. Борчылма, Былбыл. Җанны мәҗбүр итеп булмый. Без бит тәнне генә нәрсәдер эшләргә мәҗбүр итә алабыз, җанны юк. Ә җыр җаннан чыга. Җыр ул — җан авазы.

Былбыл. Рәхмәт, бабакай. Шундый рәхимле, киң күңелле булуың өчен рәхмәт.

Салсал. Йә, ярый, дусларым. Мин базарга барып бу сандыгымны сатып кайтыйм әле. Базар уңышлы булса, үзегезгә тәмле-тәмле ризыклар алып кайтырмын.

Чыга башлый, шул вакыт ишектә бер карчык пәйда була.

Карчык. Әссәламегаләйкем!

Салсал. Вәгаләйкемәссаләм! Хуш киләсең, түрдән уз.
Карчык. Узам, узам. *(Кереп өйне караштырып йөри.)*
Салсал. Гаеп итмә, кем, кортка, самавыр куяр идек — чәебез беткән чакка туры килдең.
Карчык. Борчылмагыз, борчылма. Тамагым тук. *(Өйне каравын дәвам итә. Тутый кош янында озаграк туктала. Тутый кошның башыннан сыйпап ала.)* Әйе, бай яшисез дип булмый.
Сим-Сим *(Былбылга).* Йөри шунда. Миңа бу кортка ошамый.
Былбыл. Тсс! Миңа да. Кулы бик салкын. Башымнан сыйпаганда өшеп киттем.
Карчык. Менә нәрсә, Салсал кордаш. Бик мохтаҗлыкта яшисез икән.
Салсал. Кешегә зарланган юк, шөкер.
Карчык. Сат миңа менә бу тутый кошыңны. Бер тамак кимер.
Салсал. Юк, сатмыйм.
Карчык *(акча чыгарып).* Бәясеннән тормыйм. Озак уйлама, карт. Юкса оттыруың бар.
Салсал. Башка сүзең булмаса, хуш, кортка. Минем барасы җирем бар. *(Чыга башлый.)*
Карчык *(аның юлына аркылы төшеп).* Тукта, ашыкма, карт. Менә сиңа ун алтын. Бу алтынны син ун сандык ясап та ала алмыйсың.
Салсал. Юк инде, моңа кадәр алтынсыз яшәдек, шөкер, моннан соң да яшәрбез.
Карчык. Мә инде, алайса, илле алтын. Бир миңа тутый кошыңны.
Былбыл. Бабакай, сатма мине. Миңа бу карчык ошамый.
Салсал. Сатмыйм, сатмыйм. Миндә сатыла торган җан ияләре юк.
Карчык. Ныклабрак уйла, карт. Соңгы тапкыр әйтәм: менә сиңа йөз алтын — сат миңа кошыңны.
Салсал. Бар, бар, кортка, йөрмә монда. Сатмыйм булгач сатмыйм. Тутый кош әнә базар тулы. Бар да ал.
Карчык *(үз-үзенә).* Карт юләр, миңа базардагысы түгел, монысы кирәк. Шуны аңламый исәр баш.
Салсал *(ишекне ачып).* Бар, бар, юлыңда бул.
Карчык. Ярый инде, сатмыйсың икән сатма. Ләкин миңа шуны әйт: нигә шулкадәр бәягә дә сатмыйсың син аны? Йөз алтын бит синең үзең үлгәч тә әллә кемнәргә калыр иде. Картайган көнеңдә сандык ясап йөрмәс идең. Нинди хикмәт бар синең сатмавыңда?
Салсал. Бер хикмәте, бер сере юк аның. Дусларны сатмыйлар, бары шул гына. Ә Былбыл минем өчен гади тутый кош кына түгел, дус та.
Карчык. Бигайбә инде алайса. Мин киттем. Тик шуны бел, картлач, сиңа яңадан моның кадәр бәя бирүче булмас. Ачыга башласаң, бер телем ипигә сатачак син аны.

Чыгып китә.

Салсал *(җиңел сулап).* Уф, тәмам җелеккә төште.
Былбыл. Рәхмәт, бабакай.
Сим-Сим. Мең яшә, бабакай. Былбылны сатсаң, миңа иптәш калмый иде.
Салсал. Ярый, дусларым, базарга соңга калам. Нәрсәләр алып кайтыйм үзегезгә?
Сим-Сим. Каймак, тере балык.
Салсал. Ә сиңа, Былбыл?
Былбыл. Минем берни ашыйсым килми, бабакай.
Сим-Сим. Чикләвек алып кайт аңа, чикләвек.
Салсал. Сәүдәләр уңышлы булуын теләгез, дусларым. *(Чыгып китә. Дуслары кул болгап кала.)*
Былбыл. Тиз кайт, бабакай. Синсез безгә күңелсез.
Сим-Сим. Баеп кайт. Тәпән-тәпән каймак алып кайт, мондый *(кулы белән күрсәтә)* балыклар.
Былбыл. Әйбәт тә инде безнең хуҗабыз.
Сим-Сим. Бабай каймак апкайта, бабай каймак апкайта. *(Җырлый.)*

Каймак ашыймын туйганчы,
Бигрәкләр тәмле каймак,
Сыек каймак,
Куе каймак,
Баллы каймак,
Балсыз каймак —
Ашыйсың ялап-ялап.
Каймактан соң балык була.
Шәп тә соң тере балык!
Тере балык —
Серле балык,

Менә болай тотып алып
Ашыйсың майга манып!

Былбыл. Ничек җырлыйсың килә шулай?

Сим-Сим. Каймакның исемен ишетсәм дә күңелем күтәрелә минем.

Былбыл. Ә минем күңелем бервакытта да күтәрелмәс инде.

Сим-Сим. Бүген мин бер төш күрдем әле, Былбыл.

Былбыл. Нинди төш?

Сим-Сим. Имеш, мин бер иске йортның подвалында йөрим икән. И анда әйбер, анда иске-москы! Керсәң батарлык инде менә.

Былбыл. Шул да булдымы төш!

Сим-Сим. Тыңлап бетер син, тыңлап бетер.

Былбыл. Ә син сүзеңне иң кызыклы җиреннән башла.

Сим-Сим. Иң кызыгы шул: бөтен чүп-чар, бөтен алам-салам арасында тычкан мыжлап тора, имеш. Әле бу әйбер астыннан, әле теге әйбер астыннан тычканнар чыгып тора, ә мин аларны шап — эләктереп торам.

Былбыл. Алайса, синең тамагың тук икән.

Сим-Сим. Иң гаҗәбе дә шунда шул: тагы да ныграк ашыйсы килә. Ә син, Былбыл, төшләр күрәсеңме?

Былбыл. Күрәм.

Сим-Сим. Сөйлә әле, бүген нинди төш күрдең?

Былбыл. Минем гел бер төш инде.

Сим-Сим. Нинди төш?

Былбыл. Үземнең туган якларымда Каку-Маку утрауларында, урманнарда очып йөрдем. Анда минем җан дустым Моңсар калды бит. Шуны очраттым.

Сим-Сим. Һаман шул дустыңны сагынасыңмы?

Былбыл. Сагынмаган кая ул! Безне бит Сак белән Сок дип йөртәләр иде.

Сим-Сим. Синең чын исемең ничек соң?

Былбыл. Чын исемем минем Куаныч.

Сим-Сим. Куаныч?! Нинди матур исем.

Былбыл. Әйе, аны Моңсар кебек матур итеп әйтүче юк инде. Ул миңа, син минем Куанычым, ди иде.

Сим-Сим. Ә сиңа ник соң Былбыл дип исем куштылар?

Былбыл. Кешеләр бик кызык бит алар: күрәсең, мине былбыл итеп сайратмакчы булганнардыр.

Сим-Сим. Былбыл итеп сайратырлык булгач, былбыл алсыннар иде.

Былбыл. Кешеләрне аңлау кыен шул. Тутый кошны былбыл итмәкчеләр, былбылны, бәлки, тутый кош итеп сөйләштерергә теләүчеләр бардыр.

Сим-Сим. Әйе. Кешеләр бик сәер. Бер карыйсың, башыңнан сыйпыйлар, икенче караганда, тибеп очыралар. Ярый әле безнең хуҗабыз андый түгел.

Былбыл. Әйе, Салсал карт әйбәт. Ул көчләп сайратмый. Җаннарыбызны аңлый ул безнең. Элекке хуҗам мине ничек кенә җәберләми иде.

Сим-Сим. Элек син ирektә чакта нәрсә турында җырлый идең?

Былбыл. Ирек турында. Җан дустым Моңсар турында. И, ул чаклар мәңге яңадан кайтмас инде. *(Елый.)*

Сим-Сим. Елама, Былбыл. Бәлки, күрешерсез әле.

Былбыл. Күрешүләр насыйп булмас инде, Сим-Симкәй. Мин җимгә алданып ятьмәгә эләктем. Ә Моңсар — горур, ул җимгә алданмас.

Сим-Сим. Җимгә алданмаса, башка юлын табарлар. Кешеләр тозагына капмаган җәнлек юк.

Былбыл. Анысы шулай. Моңсарны да эләктерүләре бик мөмкин. Тотарлар да сатарлар. Сайратырга тырышырлар.

Сим-Сим. Кешеләр бөтен нәрсәне саталар. Алар безнең кебек тамаклары туюга гына риза түгелләр. Аларга алтын-көмешләр, энҗе-мәрҗәннәр кирәк.

Былбыл. Алтын-көмешләре күбәеп, аны җыюдан кызык тапмый башласалар, күңелләрен ачар өчен кошлар аулыйлар: без аларны сайрап юатырга тиеш.

Сим-Сим. Карале, дустым. Әллә хуҗа өйдә югында качабызмы? Бәлки, җан дустың Моңсарны эзләп табарсың.

Былбыл. И-и, Сим-сим дус, минем канат очларымны кистеләр шул. Мин хәзер оча алмыйм.

Сим-Сим. Агачтан-агачка, коймадан коймага сикергәләп булса да барырсың. Бәлки, Моңсар якында гынадыр. Син тавыш бирерсең. Ул сине тавышыңнан таныр.

Былбыл. Күңелемне ымсындырма инде, Сим-сим. Хуҗа да бик җәл. Аны ничек ташлап китәсең?!

Сим-Сим. Сүзең хак, хуҗадан уңдык. Үзе ашамаса ашамый, безне ач итми.
Былбыл. Кешеләрнең дә төрлесе бар шул.
Сим-Сим. Дөрес, Былбыл дус, картайган көнендә бабабызны калдырып чыгып качсак, без кем булабыз аннары?

Дөбер-дөбер ишек кага башлыйлар. Сим-Сим белән Былбыл шым кала.

Ишек артындагы тавыш. Әй, карт пәри, нигә ачмыйсың? Ишегеңне җимереп керәбез бит.
Сим-Сим. Мин куркам.
Былбыл. Мин дә.

Дөбердәү, ишек артында кычкыру дәвам итә.

Сим-Сим. Әйдә качабыз.
Былбыл. Кая?
Сим-Сим. Мин беркөн тычкан тотканда, әнә теге почмакта чоланга чыга торган зур тишек күргән идем.
Былбыл. Әйдә, алайса, тизрәк!

Качалар. Болар көчкә-көчкә качып өлгерә: өйгә ике юлбасар килеп керә. Аларның кулларында сандык. Сандыкны берсе — бер ягыннан, икенчесе икенче ягыннан күтәргән. Керүгә сандыкны идәнгә куялар.

Яшь юлбасар *(тирләрен сөртеп).* Уф, арыдым.
Карт юлбасар. Буының сыек шул синең. Үз башыма гына алдым сине. Юлбасарлыкка таш йодрыклы, тимер бәдәнле ирләр кирәк.
Яшь юлбасар. Аның каравы минем башым таш. Менә кара. *(Карт юлбасарны сөзә.)*
Карт юлбасар. Нишлисең, тинтәк? Сукыр эчәгемнең сул кабыргасын сындырасың бит.
Яшь юлбасар. Башымның таш икәненә ышандыңмы инде?
Карт юлбасар. Хәзер карарбыз. Ташмы ул, кабакмы? *(Яшь юлбасарны тотып алып бот арасына кыстыра да тегенең такыр башына шарт-шорт чиертә. Яшь юлбасар тыпырчына, акыра.)* Таш түгел, кабак икән. Чиерткән саен яңгырап тора. *(Яшь юлбасарны этеп җибәрә, тегесе шыңшый.)* Нәрсә, юлбасар башың белән шыңшып торасыңмы?
Яшь юлбасар. Бетте-бетте, боеручым. Менә кара: күзләрем коп-коры. Иреннәрем көлә. *(Ясалма рәвештә көлә.)*
Карт юлбасар. Ярар, җитте. Без монда синең башыңның ныклыгын тикшерергә килмәдек. *(Кычкыра.)* Әй син, сандыкчы! Кая олактың?
Яшь юлбасар. Базардадыр ул, боеручым. Ул бит сандык сатып көн күрә.
Карт юлбасар. Сандык сатып баеп буламыни, тинтәк карт.
Яшь юлбасар. Тинтәкнең тинтәге инде.
Карт юлбасар. Кем әйтте сиңа аны тинтәк дип? Салсал картның кулы да, башы да эшли аның. Сиксән ел акыл җыйган карт ул.
Яшь юлбасар. Әйе, акылы бар инде карт ахмакның.
Карт юлбасар. Кем әйтте сиңа акыллы дип? Акылы булса, сандык сатып йөрмәс иде.
Яшь юлбасар. Ахмакның ахмагы инде, боеручым. Ахмак булмаса, безнең кебек юлбасарлыкка чыгар иде.
Карт юлбасар *(бармак янап).* Шаярма, ахмакка акыл сорап килмиләр. Ә без килдек менә.
Яшь юлбасар *(сандыкка тибә).* Шушы киребеткән сандыкны кайчаннан бирле күтәреп йөрибез инде. Эчен ачып караган юк. Нәрсә бар анда? Алтынмы?
Карт юлбасар. Алтын-көмеш нәрсә ул! Аларны күп күргән инде.
Яшь юлбасар. Алайса, төргәк-төргәк акчадыр.
Карт юлбасар *(көрсенеп).* И-и, акча да булдымы әйбер. Акча — тузан бит ул. Өф дисәң, оча да китә.
Яшь юлбасар. Алайса, нәрсә соң?
Карт юлбасар. Нәрсәме? Анда гап-гади бер тутый кош.
Яшь юлбасар *(кәефе китеп).* И-и, боеручым, шул тутый кошны күтәреп йөрибезмени без?
Карт юлбасар. Әйе. Җитмәсә, телсез әле ул.
Яшь юлбасар. Ә син аны ничек беләсең?
Карт юлбасар. Чөнки мин аны бу сандыкка үзем яптым.
Яшь юлбасар. Алайса, ачкычын үзеңнән эзләргә кирәк.
Карт юлбасар. Анысын гына мин дә беләм. Әмма ачкычы эчендә калды шул аның.
Яшь юлбасар. Ә-ә!

Карт юлбасар *(үртәп).* Мә-ә!

Яшь юлбасар. Ә нигә яптың соң син аны?

Карт юлбасар. Сөйләшмәгән өчен.

Яшь юлбасар *(берни аңламый).* Сөйләшмәгән өчен?

Карт юлбасар *(уйланып).* Миңа аны бер карчык саткан иде. Каку-Маку утрауларыннан тотып алып кайтылган кош ул. Алар икәү булган. Аларны Сак белән Сок дип йөрткәннәр.

Яшь юлбасар. Ә сиңа аны сандыктан чыгару нигә кирәк?

Карт юлбасар. Нигәме? Чөнки ул бәхет ачкычының кайда ятканлыгын белә. Миңа моны тылсымчы карчык әйтте.

Яшь юлбасар. Үзең аны телсез диդең бит, галиҗәнап боеручым.

Карт юлбасар. Әйе, телсез. Ләкин аның телен ачтыруның әмәлен дә өйрәтте ул.

Яшь юлбасар. Йә, йә, боеручым, ничек?

Карт юлбасар. Аны дусты белән очраштырырга кирәк.

Яшь юлбасар. И-и, без бөтенләй булмастай эш белән йөрибез икән. Ул кошын каян табасың аның?

Карт юлбасар. Мин әмәлен белдем инде.

Яшь юлбасар. Йә, йә, боеручым, әйтеп җибәр.

Карт юлбасар. Менә моны *(сандыктагы кошка ымлап)* күтәрәбез дә кош базары буйлап йөрибез. Кайсы кошны күргәч, теле ачылса, шул аның дусты була.

Яшь юлбасар. Бәлки, аны бөтен дөнья буйлап эзләргә туры килер. Бәлки, ул үзенең Каку-Маку утравындадыр?

Карт юлбасар. Шуның өчен дә бәхет ачкычы диләр аны. Диңгезләр, дәрьялар кичәрмен, карурманнар үтәрмен, әмма бу кошның дустын тапмый туктамам. Нәрсә икән ул бәхет? Беләсе иде шуны.

Яшь юлбасар. Әйдә, алайса, тизрәк ватыйк бу сандыкны.

Карт юлбасар. Мин аны ватып-ватып карадым инде. Булмады. Нәрсә белән генә сандыкка сукма — үз коралың үзеңә китереп тондыра. Менә башларымны тишеп бетердем. *(Башын күрсәтә.)*

Яшь юлбасар *(аның башын карый).* Йодрык сыярлык тугыз тишек, галиҗәнап боеручым.

Карт юлбасар. Шул шул. Инде менә бөтен өмет Салсал картта. Ул — сандыкларның серен белгән кеше. Ул ачса гына.

Яшь юлбасар. Синең Салсал картың кайчан кайта әле ул? Ә минем тизрәк бу серле кошны күрәсем килә. Бәлки, мин ача алырмын, галиҗәнап боеручым.

Карт юлбасар. Карап кара.

Яшь юлбасар, өлкән юлбасардан фатиха алгач, Салсал картның өеннән берәр эш коралы эзли башлый. Ул бер тартма янына килә, аннан чүкеч табып ала. Сөенә-сөенә сандык янына килә.

Яшь юлбасар. Менә хәзер күрсәтәм мин сиңа ничек ачарга кирәклеген. *(Кизәнеп сукмакчы була, ләкин сандыкка тигәнче үк, кемдер эткәндәй, кулы киргә китә, һәм чүкеч яшь юлбасарның маңгаена тондыра.)* Беттем, беттем. Үлдем, үлдем! *(Маңгаен угалый һәм ачу белән сандыкка китереп тибә. Ләкин кемдер чөеп җибәргәндәй тәгәрәп китә.)* Юк, мин тотынсам болай гына калдырмыйм. Минем башым таш. Мин сине сөзеп эчәгеңне чыгарам. *(Егылып яткан җиреннән торып, башта сандыктан арткарак чигенә, аннары йөгереп килеп сандыкны сөзә, әмма мәтәлчек атып барып төшә.)* Ай-ай, үлдем. Чынлап үлдем. Әнә җаным чыгып очып китте. *(Елый.)*

Карт юлбасар. Калай этәчләнмиләр аны. Хәзер ят инде менә шыңшып. Җитмәсә, үзеңне юлбасар дип йөргән буласың.

Яшь юлбасар. Юлбасар шул. Менә башым гына сандык сыярлык тишелгән... бугай.

Карт юлбасар. «Бугай» белән «дыр» йоклый, ди, гыр-гыр. Ә син йоклама, әйдә тизрәк тор. *(Яшь юлбасарны тартып торгыза.)*

Шул вакыт Салсал карт кайтып керә. Кулында ризыклар.

Салсал. О-о, бездә кунаклар бар икән.

Яшь юлбасар. Без кунак түгел, юлбасарлар.

Салсал. Юлбасарлар юл баса, ә сез минем өемдә. Димәк, кунак. Кая әле, самавыр куеп җибәрик, күчтәнәчләр белән чәй эчәрбез. *(Самавырына барып тотына.)*

Карт юлбасар. Кирәкми, Салсал карт. Без кунак булырга килмәдек. Менә бу сандыкны гына ачып бир дә, без китәбез.

Салсал *(сандык янына килә).* Мин ясаган сандык бит бу! Яшь чакта, гайрәтле чакта ясалганы күренеп тора.

Карт юлбасар. Ачкычы бармы, ачкычы?
Салсал. Ачкычы?
Карт юлбасар. Әйе, безгә моны тизрәк ачарга кирәк.
Салсал *(хәтеренә төшерергә тырышып).* Ачкычы диген, ә? *(Әрле-бирле йөренә.)* Хәтер капчыгы тишелгән бит, туганкай, хәтер капчыгы...
Карт юлбасар. Шулай да башыңны эшләтергә туры килер сиңа, картлач.
Яшь юлбасар. Юкса сандык сыярлык тишек башым белән сөздем ыргыттым булыр.
Карт юлбасар. Ә син этәчләнми тор. *(Тегенең башына чиертә.)*
Яшь юлбасар. Шаярганны да аңламыйлар. *(Үпкәләп читкә китә.)*
Салсал. Ә-ә, исемә төште.
Карт юлбасар. Кая, китер тизрәк.
Яшь юлбасар. Кыймылда, картлач, кыймылда.
Салсал. Әйе, исемә төште. Мин бит аны сандыгы белән саткан идем.
Карт юлбасар. Анысын беләбез. Ләкин синдә икенче ачкычы калырга тиеш.
Салсал. Юк, мин һәр сандыгыма берәр генә ачкыч ясый идем. Аларның берсе икенчесенә ярамый.
Карт юлбасар *(өметсезләнеп).* Инде нишлибез? Бөтен өмет синдә иде бит.
Салсал. Каяле, үзем карыйм әле шуны. *(Сандыкка сокланып карап тора.)* Шәп ясалган бу. Хәзер булдырып булмый инде. *(Сандыкның йозак тишекләрен караштыргалый һәм капкачын күтәреп җибәрә.)* Ачык икән бит сандыгың.

Сандык эченнән тутый кош килеп чыга. Бар да аһ итә.

Карт юлбасар. Кара син аны, ачык сандыкны ачалмый йөргәнбез диген, ә? Менә тутый кош та исән. Хәзер мин аны дөнья буйлап йөртергә алып чыгып китәм. Дустын күрсен дә, теле ачылсын.

Шул вакыт яшеренгән җирдән Сим-Сим килеп чыга.

Сим-Сим. Туктагыз, тукта, алып чыгып китми торыгыз. Аның дусты менә монда. *(Чоланга таба карап кычкыра.)* Әй, Былбыл, чык әле. Монда бик кызык нәрсә бар.
Былбыл *(як-ягына каранып).* Нәрсә?
Сим-Сим. Менә моңа ныклабрак кара әле. *(Сандыктан чыккан тутый кошны моңа табарак этә.)*
Былбыл. Моңсар? Синме соң бу? Әллә саташам?
Моңсар. Куаныч! Син дә исәнмени? *(Бер-берләренең кочакларына ташланалар.)*
Карт юлбасар. Кошыбызның теле ачылды. Димәк, эзләгәнебез шушы.
Моңсар *(җырлый).*

Сине югалтудан телсез калдым,
Тавышсыз калдым.
Читлекләрдә бәргәләнеп
Елады җаным.

Куаныч.

Синсез минем көнем көн булмады,
Бәргәләнде йөрәк.
Һәрбер таңны өзелеп-өзелеп көттем,
Кавышуны теләп.

Икесе бергә.

Инде хәзер бер-беребезне таптык,
Аерылмабыз бер дә.
Сөю җыры, дуслык җыры гына
Булыр безнең телдә.

Боларның җырлашу-сөенешүләрен һәммәсе карап тора. Салсал картның шатлыктан күңеле тула. Ул сиздермичә генә күзләрен сөртеп ала.

Карт юлбасар. Бәхетлеләр киң күңелле була, диләр. Инде безгә сереңне ач. Кайда ул бәхет ачкычы?
Моңсар *(як-ягына каранып).* Әйтим микән?

Барысы да «әйт», «әйт» диләр.

Салсал. Белсәң яшермә, дустым. Кешеләрне бәхетле итү — үзе бәхет бит ул.
Моңсар. Әйтим алайса. *(Бар да тын калып аңарга карый.)* Бәхет ачкычы ул сез уйлаганча әллә кайларда, диңгез артларындагы утрауларга күмелмәгән.

Карт юлбасар. Якында булса бигрәк әйбәт. Урынын гына күрсәт, хәзер йөгерәм.

Моңсар. Анда йөгерәсе дә юк.

Яшь юлбасар. Бу нәрсәдер маташтыра, галиҗәнап боеручым. Әллә таш башым белән бер сөзимме үзен?

Карт юлбасар *(аны читкә этеп).* Кермә әле арага. *(Моңсарга.)* Ә син хәйләләмә. Юкса мин сезне кире аерачакмын.

Моңсар. Хәйләләмим. Чынлап та бик якында ул бәхет ачкычы.

Карт юлбасар. Тизрәк урынын күрсәт!

Моңсар *(йөрәген күрсәтә).* Урыны менә монда.

Карт юлбасар. Нәрсә, синең йөрәгеңдәмени?

Моңсар. Минем йөрәгемдә — үз бәхетемнең ачкычы гына. Сезнең бәхет ачкычыгыз үз йөрәгегездә!

Карт юлбасар. Үз йөрәгебездә?

Яшь юлбасар. Алдый ул, алдый. Менә минем йөрәгемдә бернинди ачкыч та юк.

Моңсар. Алдамыйм. Дөньяда никадәр кеше булса — бәхет шуның кадәр төрле була. Берәүләрне — сөю-сәгадәт, икенчеләрне — мәрхәмәт һәм шәфкать, өченчеләрне — көрәш һәм җиңү, дүртенчеләрне — ирек һәм азатлык, бишенчеләрне тагын әллә ниләр бәхетле итә.

Карт юлбасар *(үз-үзенә).* Дөрес сукалый бит бу шайтан.

Моңсар *(Карт юлбасарга).* Менә синең кулдан күпме алтын-көмешләр, кызыл маллар үтте. Ә бәхетеңне тапмадың. Ә бит күп кенә кешеләрне таланган байлык та бәхетле итә. Сине ни өчен бәхетле итмәде, әйтимме?

Карт юлбасар. Яле, яле, әйтеп җибәр.

Моңсар. Чөнки әле синең күңелеңдә мәрхәмәт үлеп өлгермәгән. Шуңа күрә таланган байлык сине бәхетле итмәде.

Карт юлбасар *(күзләрен сөртеп).* Бәлки, синең сүзләрдә хаклык бардыр.

Моңсар. Бар, бар! Моннан соң син юлбасарлыгыңны ташлаячаксың. Бүтәннәр шатлыгы өчен куанудан күзенә яшь бөртеге чыккан кеше юлбасар була алмый.

Моңсар Карт юлбасарның битеннән үбеп ала.

Моңсар. Рәхмәт безне кавыштырганың өчен. Юкса минем телем мәңге ачылмас иде. Ә бит телсез килеш сагыш-кайгыларны тышка чыгарып булмый. Алар күңелдә таш булып утыра. Рәхмәт! *(Тагын бер кат үбә.)*

Карт юлбасар *(күзеннән яшьләр чыга).* Моңарчы миңа дөньяда беркемнең дә рәхмәт әйтеп битемнән үпкәне юк иде. Нинди рәхәт сүз икән ул — рәхмәт. Никадәр алтыннарым барында да минем мондый шатлык кичергәнем булмады.

Куаныч. Сезнең күңелегездә мәрхәмәт калган дип Моңсар дөрес әйтә. Сез чынлап бүген безгә бәхет бүләк иттегез. *(Ул да Карт юлбасарны үбә.)* Рәхмәт сезгә. *(Карт юлбасарның күзеннән яшь елга булып ага.)*

Яшь юлбасар. Ә минем күңелдә нәрсә бар?

Моңсар. Синең күңелдә әлегә берни дә юк. Ул бераз пычрана башлаган, ләкин аны юып, мәрхәмәт орлыгын салсаң, синең дә бәхет агачың үсәчәк.

Яшь юлбасар. Алайса, мин бүгеннән юлбасарлыгымны ташлыйм. *(Салсалга.)* Ал мине, Салсал бабай, үзеңә. Өйрәт үзең кебек сандыклар ясарга.

Салсал. Менә рәхмәт, улым. Үзем белән бергә һөнәрем дә үләр дип кайгыра идем. Хәзер һөнәремне биреп калдырыр кеше табылды. Ышан, дустым, мин синнән шундый оста ясармын — даның бөтен дөньяга таралыр. Салсал картның җегәре бетсә дә, осталыгы калды әле.

Сим-Сим. Болай булгач, үземә генә дигән каймак белән чәй эчәбез инде. *(Җырлый-җырлый өстәл әзерли.)*

Әй тәмле чәй, тәмле чәй —  
Каймагы бар, балы бар.  
Рәхәтләнеп ашыйк-эчик —  
Тәпәннәрдә тагын бар.

Сим-Симнең җырына башкалар да кушыла. Табынга утырышалар.  
Гомуми шатлык, җанланыш.

Тәмам.

# БАЗ БАКАСЫ

Катнашалар:

Алып баручы.
Баз бакасы.
Сыер.
Сарык.
Кәҗә.
Эт һәм песи.
Тавык, каз.
Хуҗа.

Ишегалды. Анда Сыер, Сарык, Кәҗә, Тавык, Каз. Бер читтә эт оясы. Сарбай оясыннан башын тыгып ишегалдын күзәтә. Киртә өстендә Песи утыра. Аның исеме Сим-Сим. Баз бакасы ишек төбендәге таш астында ята. Таш астыннан аның олы авызы гына күренә.

Алып баручы

Борын, борын, борында
Базда, җайлы урында
Яшәгән Баз бакасы,
Баканың да атасы.

Бервакытны бу Бака
Каранып ята-ята
Төшкән майлы чүлмәккә
Һәм сикергән чиләккә.

Ә чиләктә сөт икән.
Монда сөт бик күп икән.
Бакага күл булган ул,
Сөт эченә чумган ул.

Хуҗа төшсә сөткә дип,
Сөт эчәрмен кичкә дип,
Сөт эчендә Бака, ди,
Бер бата, бер калка, ди.

Моны күргәч, хуҗаның
Ачуы чыккан яман.
Тотып аткан Баканы
Кычытканлыкка табан.

Шуннан соң Баз бакасы,
Баканың да атасы
Торган ишегалдында
Күзәткәләп барын да.
Инде без дә күз салыйк —
Ни бар ишегалдында?
Баз бакасы белән без
Очрашырбыз тагын да.

Ишегалды күренеше. Сирәк-мирәк эт өреп куя. Сыер мөгри. Кәҗә, Сарык кычкыргалап ала. Боларның тавышларына өйдән Хуҗа чыга.

Хуҗа

Малкайларым, җанкайларым,
Ачыккансыздыр, беләм.

Хәзер мин сезне сыйлармын
Бик тәмле сыйлар белән.

Сыер

Му-му, му-му, му-му, му-му,
Әйбәт эш ул сыер булу.
Үлән белән сыйланасың,
Тамак туйгач уйланасың.

Кәҗә

Кики-мики, мә-ә, мә-ә,
Җитми инде кәбестәгә.
Әй ашыйсың кетер-кетер,
Аннан инде уйна, сикер.

Сарбай

Һау-һау, һау-һау, мин гел уяу,
Торам сакта, янда капка.
Миңа берни кирәк түгел,
Алда майлы сөяк ятса.

Тавык

Кот-кот-котый, кот-кот-котый,
Тирес тибеп ярма чыкмый.
Бодай, борчак, тары, ясмык —
Бөтенесе миңа тансык.

Каз

Га-га-га-га, га-га-га-га,
Бодай күрсәм, йөрәк кага.
Ашыйм ипи, бәрәңге дә
Вак-вак кына каба-каба.

Сим-Сим

Мияу-мияу, мияу-мияу,
Мин дә көне-төне уяу.
Алда торса каймак кына,
Ашар идем җайлап кына.

Хуҗа

Ник дәшмисең син, Сарыгым,
Әллә ачмады карының?

Сарык

Беләсең бит, мин бик тыйнак,
Һичбер нәрсә йөрмим сорап.

Хуҗа

Ярый, ярый, малкайларым,
Малкайларым, җанкайларым.
Хәзер сыйлыйм барыгызны,
Туйдырырсыз карыныгызны.

Хуҗа һәммәсенә азык өләшә. Азык биргән чакта кайсының — башыннан, кайсының сыртыннан сыйпап ала. Бу күренешне Бака бик җентекләп һәм көнләшеп күзәтеп тора.

Хуҗаның малларына азык өләшү күренеше. Ул музыка белән барырга мөмкин.

Хуҗа
*(Сыерга печән сала)*

Аша, аша, Сөтбикәм,

Сөт бирерсең кич, иртән.

Сыер

Рәхмәт, Хуҗам, му-му-му,
Сыең тәмле у-у-у.

Хуҗа
*(Кәҗәгә кәбестә суза)*

Син дә аша, Кәҗәкәй,
Син бит әле бәләкәй.

Кәҗә
*(баш иеп)*

Рәхмәт, рәхмәт.
Кәбестәңне «урырмын»,
Сыер кадәр булырмын.

Хуҗа
*(Сарбайга сөяк бирә)*

Синең ничек эшләрең,
Авыртмыймы тешләрең?

Сарбай

Әйбәт минем эшләрем,
Тимер кебек тешләрем.

Хуҗа кулындагы сөякне эләктереп ала.

Хуҗа
*(Тавыкка җим сала)*

Чуаркаем, җим чүплә,
Торма анда бер читтә.

Тавык

Кытый-кытый, кыт-кытый,
Хуҗам мине онытмый.

Хуҗа
*(Каз янына килә)*

Син дә, озын муеным,
Тәмен таты сыемның.

Каз

Га-га-га, кыйгак-кыйгак,
Ашарбыз торгач сыйлап.

Хуҗа
*(Песигә)*

Ә сиңа, тәмлетамак,
Кирәктер инде каймак.

Сим-Сим

Әй каймак, каймак, каймак,
Каймакны ашыйм майлап.

Хуҗа
*(Сарыкка)*

Сарыгым син, сабырым,
Сиңа ачы камырым.

Сарык

Рәхмәт, Хуҗам, бә-ә-ә,
Килмәсен йортка бәла-ә.

Хуҗа китәргә җыена. Бака аның каршысына чыга.

База бакасы

Бака-ка-ка, ба-ка-ка,
Оныттың минем хакта.

Хуҗа

Ә син нишлисең монда?
Бар кит, уралма юлда.
Пычраттың сөтемне,
Кызарттың син битемне.

Баканы читкә этеп җибәрә дә өйгә кереп китә.
Баканың моңа бик ачуы килә.

Бака

Ярар, ярар, карарбыз,
Берәр әмәл табарбыз.
Мин бака, усал бака,
Эчемдә ачу ята.
Үчләләр явыз була,
Ачудан авыз тула.
Ачуны йотып булмый,
Саклап та торып булмый.

Тавык

Тамак туйды, әллә биеп алабызмы?

Тавышлар.

Биибез, биибез.

Сыер

Йә, әйдәгез, кем башлый?

Тавык

Кем иң өлкән — шул башлый.

Сарбай

Ыр-ыр, иң өлкәне Сыердыр.

Сарык

Кәҗә такмак әйтеп торыр.

Кәҗә

Әйтер идем дә такмак,
Бетеп киткән шул тамак.

Сим-Сим

Тамагыңны ачарбыз,
Тыпыр-тыпыр басарбыз.

Сыер уртага чыга, Кәҗә такмак әйтә, аңа бүтәннәр дә кушыла.

Тыпыр-тыпыр итәсең,
Әйбәт Сыер икәнсең.
Тагы да каты бас әле,
Күңелләрне ач әле.

Сыер уртага Сарыкны чыгара. Һәммәсе такмак әйтә.

Әй Сарык, Сарык, Сарык,
Егыла күрмә арып.
Бие, бие тизрәк,
Торма әле изерәп.

Сарык биеп туктый да уртага Кәҗәне чакыра. Кәҗә үзенә такмак әйтеп бии.

Тыпыр-тыпыр биибез,
Бии белмим димибез.
Биер идем остарак,
Коерыгым кыскарак.

Бака уен барган җиргә килә.

Бака

Беләсезме, сез кемнәр?

Сыер

Йөрмә әле уралып,
Йә өстеңә басармын.

Бака

Сез һәммәгез җүләрләр.

Сим-Сим

Андый сүзләр сөйләсәң,
Тотармын да ашармын.

Бака

Әй ахмаклар, ахмаклар,
Хуҗа явыз ният тән
Сезне ашатып тота.

Тавык

Кыт-кыт-кыт, юк-юк-юк.
Хуҗа безнең явыз түгел.

Сарбай

Һау-һау, шулай
Хуҗа әйбәт, өе уңай.

Бака

Хуҗа усал. Хуҗа явыз.
Булмагыз сез ачык авыз.
Качыгыз, кач тизрәк моннан,
Юкса үкенерсез соңнан.

Сим-Сим

Мыр-мыр, мырый,
Мыр-мыр, мырый.
Хурлыйсың Хуҗаны юри.

Бака

Ахмакның да ахмагы сез,
Бернәрсәне аңламыйсыз.

Ишегалдында тавыш куба. Һәммәсенең Баз бакасына ачуы чыга.

Сыер

Әйтеп сөйлә, кемнәр ахмак?
Юкса ташлыйм хәзер таптап.
*(Бакага таба килә башлый.)*

Бака

Әйттем бит: һәммәгез ахмак,
Йөрисез Хуҗаны яклап.
Ә ул явыз, ул мәкерле,
Явызлыгы төрле-төрле.

Кәҗә

Микки-мики, мә-ә, мә-ә,
Син ачыклабрак сөйлә.

Сарбай

Шулай-шулай. Әйе. Һау-һау,
Яман эш кешене хурлау.

Бака

Ба-ка-ка-ка, ба-ка-ка-ка,
Сөйлим инде сезнең хакка.
*(Сыерга.)* Беләсеңме, мичкә корсак,
Хуҗа сине ник ярата?

Сыер

Әйтеп кара,
Тик Хуҗага якма яла.

Бака

Ул бит сине көн дә сава,
Сөт, май, каймак кирәк аңа.

Сыер

Саусын, миндә сөт җитәрлек,
Май да, каймак та итәрлек.

Бака

Бозавыңны суеп ашый,
Сөякләрен эткә ташлый.

Сыер уйга кала. Бака Сарыкка дәшә.

Бака
*(Сарыкка)*

Хуҗа синең йоның ала,
Чирләп китсәң, тотып чала.

Сарыкның да күңеленә шом керә.

Сарбай
*(Бакага)*

Коткы салма, юньсез убыр,
Юкса каптым-йоттым булыр.

Бака

Коткы, имеш, уйлап кара,
Балаларың синең кая?

Сарбай

Белмим, белмим.

Бака

Ә мин беләм.

Аларны бит синең Хуҗаң
Суга салды туу белән.

Тавык

Кыт-кыт-кытый, кыт-кыт-кытый,
Араны бу юри бутый.

Каз

Авызың тулы синең ялган.

Сим-Сим

Кит, ялтырат моннан табан.

Бака

Ха-ха-ха-ха, ба-ка-ка-ка,
Хуҗа сезне суя, сата.
Тирегездән тун тектерә,
Кирәкмәсә — юк иттерә.
Үзем күрдем, Хуҗа анда
Пычакларын кайрап куйган.
Җаныгыз кадерле булса,
Таралыгыз тизрәк моннан.

Ишегалдында шау-шу куба. Сыер-сарыклар кычкыра, Эт өрә, Мәче мыраулый, бар көченә Тавык кытаклый. Бака, болар арасында шундый тавыш кубара алуына сөенеп, бер читтән карап тора.

Кәҗә

Качарга, качарга!

Сыер

Капкаларны бәреп ачарга! *(Сөзә.)*

Сим-Сим

Кирәк түгел сөте-майлары,
Кирәк миңа балакайларым.

Сөзә торгач, Сыер капканы аудара. Бөтенесе капкадан чыгып чабалар. Аларның качуын күреп, өеннән Хуҗа йөгереп чыга.

Хуҗа

Малкайларым, малкайларым,
Нишлисез сез, җанкайларым!
Кая болай чабышасыз?
Чыгып китеп ялгышасыз.
Таралмагыз...

Әмма аның сүзен тыңлаучы юк. Маллар таралыша, ишегалды бушап кала. Хуҗа, башын тотып, ишек бусагасына утыра.
Бака ишегалды уртасында бии-бии такмаклый.

Бака

Явызлыктан көч алдым, көч алдым,
Хуҗабыздан үч алдым, үч алдым.
Менә нинди көчле мин, көчле мин,
Юлбарыслар төсле мин, төсле мин.

Хуҗа моның бии-бии җырлаганын ишетә дә Баканы, ботыннан тотып, ерактагы сазга ыргыта.

Озак яшәдең базда,
Инде яшә син сазда.
Ичмасам, азык булырсың
Ач үрдәккә йә казга.

Хуҗа, кулын юып, өенә кереп китә. Алып баручы чыга.

Алып баручы

Яхшылар дөньяны төзи,
Ә явызлар җимерә.
Никадәр көчле булса да,
Явызлык бер җиңелә.
Хуҗага кайтыр маллары,
Кайтыр алар ашкынып.
Дөнья бетәр иде күптән
Җитми калса яхшылык.

Тәмам.

## БҮРЕ БЕЛӘН ТӨЛКЕ

Урман аланы. Төп башында карт Бүре утыра. Ул бик кәефсез.

Бүре

Их, бар иде яшь чакларым,
Җен-пәридәй шәп чакларым.
Төннәр ерып чаба идем,
Һәрчак ризык таба идем.
Көтү тулы симез сарык,
Керә идем шунда барып.
Китә идем иң симезен,
Шалт иттереп, сыртка салып.
Их!

Аланга Төлке керә.

Төлке

Нигә болай көрсенәсең,
Нәрсә булды, Бүре абзый?

Бүре

Яши-яши арыдым,
Бик тә ачты карыным.
Бер кабуда йотар идем
Бер көтүнең сарыгын.
Юк шул, булмый, картайдым,
Йөри алмыйм сунарга.
Симез сарыклар турында
Калды бары уйларга.

Төлке

Күрәм, шәп түгел эшең,
Бөтенләй качкан төсең.

Бүре

Ничек инде шәп булсын,
Ничә көн ашаган юк...

Төлке

Ә минем тамагым тук,
Ә минем тамагым тук.
Тамагым тук, кәефем шәп,
Дөньяда бер кайгым юк.

Иртән пылау ашадым,
Көндез пилмән ашадым.
Казанымда әле дә
Кайнап тора ашларым.
Сиңа да бирер идем дә,
Савытым юк салырга.
Базардан алыр идем дә,
Вакытым юк барырга.

Бүре

Торма әле каршымда
Ачуымны китереп.
Тотармын да ашармын
Сине пилмән иттереп.

Төлке

И Бүрекәй, Бүрекәй,
Күрче, мин нинди ябык.
Сөякләрем калырлар
Тамагыңа кадалып.
Сиңа сарык ите кирәк,
Яшь сарык, йомшак сарык.
Булсын ул чәйнәми генә
Кабарлык та йотарлык.
Бар көтүгә, тот бер бәти,
Уртак булыр табышың.
Тамагыңны бер туйдырсаң,
Калмас һичбер сагышың.

Бүре

Картайдым шул, картайдым,
Хәлсезләнде сыйраклар.
Хәзер сарык абзарларын
Урап үтәм еPактан.
Беркөн барган идем шулай
Бер авылга сунарга —
Этләр сизеп алдылар да
Тотындылар куарга.
Әй куалар, әй куалар,
Көчкә качып котылдым.
Тәпиләрем канап бетте,
Таландым һәм йолкындым.
Менә кара, койрыгымның
Бер йоны юк — шәп-шәрә...

Төлке

И Бүрекәй, сине тәмам
Иткәннәр бит мәсхәрә.

Бүре

Инде нишлим, әйт, Төлке дус,
Эшләт әле башыңны.
Әллә инде сарык кебек
Үлән ашый башлыйммы?

Төлке

Ярый алайса, дуслык хакына
Эшләтеп карыйм башны чак кына.
Әгәр дә мәгәр болай иттерсәк?
Сарык тиресе сиңа кигерсәк?

Бүре

Син нәрсә, Төлке, миннән көләсең?
Холкымны минем яхшы беләсең.
Ишетсәм тагын мондый сүзеңне,
Каптым да йоттым булыр үзеңне.

Төлке

Ашыкма, картлач, тыңла син элек,
Бу киңәшемне әйтмәдем көлеп.
Ябынсаң әгәр сарык тиресен,
Картлык көнеңдә рәхәт күрерсең.

Бүре

Һични төшенмим, аңлатып сөйлә,
Минем тизрәк ашыйсым килә.

Төлке

Сарык тиресен ябынып алсаң,
Болыннар буйлап авылга барсаң,
Сине беркем дә бүре дип белмәс,
Усал этләр дә «һау-һау»лап өрмәс.
Кушылырсың шунда берәр көтүгә,
Рәхәтләнерсең сарык итенә.

Бүре

Аһ син хәйләкәр, баш бар үзеңдә,
Дөреслек бар бит синең сүзеңдә.
Сарык тиресен иңгә салыйм да
Китим тизрәк берәр авылга.

Төлке

Кара аны, чамалап йөр,
Як-якка күз салгалап йөр:
Бу эшеңне сизмәсеннәр,
Кабыргаңны измәсеннәр.

Бүре

Рәхмәт сиңа, Төлке дускай,
Йөрермен мин җайлап кына.
Бәтиләрнең япь-яшьләрен
Ашармын сайлап кына.
Болай булгач, эшләр пешә,
Авызыма калҗа төшә.
Берәм-берәм тотам-йотам,
Тотам-йотам, тотам-йотам.

Чыгып китә.

Төлке

Тагын бер Бүре җибәрдем
Сарыклар арасына.
Миңа да өлеш чыгачак
Тәмле ит калҗасыннан.
Бүреләр белән дус булсаң,
Яшәве җиңелерәк.
Хәйләсез — дөнья файдасыз,
Кайда да хәйлә кирәк.
Яшәр өчен һәркемнең дә
Үз җае, үз сере бар.
Сез, сарыклар, сак булыгыз,
Арагызда бүре бар.

Тәмам.

## ӘМӘК БЕЛӘН ШӘМӘК

Катнашалар:

Әмәк.
Шәмәк.
Дәүавыз.
Козгын.
Әбү-вәзир.
Балыкчы карт.
Хезмәтче.
Пешекчеләр.
Гаскәр башлыгы.
Зөһрә.
Палач.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хан сарае. Уртада иң биек җирдә алтын тәхет. Ул буш. Пәрдә ачылганда, сәхнә артында кәнизәкләр җыры ишетелә.

Йөзгә чаклы яшәдең, бөек хан.
Яшен булып яшьнәдең, бөек хан,
Җирләр, сулар яуладың, бөек хан.
Тәхетеңне данладың, бөек хан.
Бөек ханга мәңге дан,
Мәңге дан!
Тыныч йокла кабереңдә, бөек хан,
Улларың кала җирдә, бөек хан,
Алар даның арттырыр, бөек хан,
Илне чәчәк аттырыр, бөек хан.
Бөек ханга мәңге дан,
Мәңге дан!

Елаша-елаша Әмәк белән Шәмәк керә.

Әмәк *(елавын дәвам итеп).* Әти үлде. Инде хәзер нишләрбез? И-и-и!
Шәмәк. Әти мине бөтенегездән дә ныграк ярата иде. *(Мышык-мышык елый.)*
Әмәк *(яшьләрен сөртеп).* Юк шул, юк шул, әти мине ныграк ярата иде.
Шәмәк. Ул миңа каеш камчы бүләк итте.
Әмәк. Ә миңа җәя белән ук.
Шәмәк. Мин каеш камчым белән синең угыңны бәрәм дә төшерәм.
Әмәк. Төшерттеләр ди, көтеп тор. Минем угым күктә оча. Синең камчың елан төсле җирдә сөйрәлә!

Шәмәк. Ә-ә, шулаймы? Мә алайса! *(Әмәккә китереп суга.)*

Әмәк. Синдә бар йодрык миндә юк дип белдеңме?! Мә! *(Шәмәккә суга.)*

Болар бер-берләре белән төрткәләшә башлыйлар. Көчләре һәр икесенең бер чама. Тарткалашып туйганнан соң, тагын елашырга тотыналар. Шул вакыт карт Вәзир керә.

Әбү. Нигә елашасыз, ханчыкларым?

Әмәк. Хәзер без нишлибез инде?

Шәмәк. Безне кем ауга алып чыгар?

Елыйлар.

Әбү. Еламагыз, ханчыкларым. Хан малайлары еламыйлар.

Әмәк. Әтиләре үлгәч тәме?

Әбү. Әтиләре үлгәч тә.

Шәмәк. Ә нишлиләр соң?

Әбү. Әтиләре үлгәч тә, үзләре хан булалар.

Әмәк. Ә безнең хан буласыбыз килми.

Әбү*(бармагын иренenә куеп)*. Шыпырт! Тс-с! Мондый сүзне яңадан әйтәсе булмагыз. Стеналар ишетә күрмәсен.

Шәмәк. Стеналар ишетә димени, юләр.

Әбү. Хан сараенда стеналарның колагы бар, түшәмнәрнең — күзләре. Тс-с!

Һәммәсе сагаеп тыңлап тора. Аннары Әбү аяк очларына гына басып чыгып китә.

Әмәк. «Минем ханлыгымда иң юләр кеше — Әбү» дип әйтә иде әти, дөрес икән.

Шәмәк. Алайса, нигә куып җибәрмәгән соң ул аны?

Әмәк. Каян белим мин. Кызык өчен тоткандыр. Ул бит Әбүдән гел көлә иде.

Шәмәк. Әйдә, әбәкле уйныйбыз.

Әмәк. Әйдә.

Тәхет тирәли йөгерешеп уйныйлар.

Әмәк*(чабуына эләктереп, тәхетне аудара).* Ах, әтинең урындыгы ауды.

Шәмәк. Урындык түгел, бу — тәхет.

Әмәк. Ә тәхет ни өчен?

Шәмәк. Әти утырыр өчен.

Әмәк. Әти булмагач, урындык та кирәкми, әйдә ватабыз.

Шәмәк *(аның белән килешеп).* Әйдә! *(Тәхетне типкәли башлыйлар. Шунда ул аягын авырттыра.)* Уф, аягым сынды! *(Титаклап йөри.)*

Әмәк. Башың белән сөз, ташбаш бит син.

Шәмәк. Көлмә кешедән, авызың өшегән.

Әмәк. Көләм, көләм. Мин бит синнән күбрәк беләм.

Шәмәк. Белсәң, әйт алайса: кәҗәгә мөгез нигә чыга?

Әмәк. Чирәмгә бәйләп куяр өчен.

Шәмәк *(кулларын чәбәкли).* Белмәдең, белмәдең. Аңа мөгез сыртына менеп атлангач тотынып утырыр өчен.

Әмәк. Кем әйтте сиңа алай дип?

Шәмәк. Карт Вәзир.

Әмәк. Синең ул Вәзиреңнең кәҗәнеке хәтле дә акылы юк. Икегезнең акылын бергә кушсаң да, минеке хәтле булмас.

Шәмәк. Ха-ха-ха! Каян килгән акыллы баш! Алай бик белдекле икәнсең, шуны әйт: кошлар нигә очалар?

Әмәк. Атып төшерсеннәр өчен.

Шәмәк. Этләр нигә өрәләр?

Әмәк. Өрмичә тора алмаганга.

Шәмәк *(нинди сорау бирим икән дип уйланып тора).* Ә-ә, менә сиңа тагын бер сорау...

Әмәк. Юк инде, хәзер сорауны мин бирәм.

Шәмәк. Һи, синең сорау ул минем өчен каз боты кимерүдән дә җиңел.

Әмәк. Йә, әйт: безнең хан сараенда ничә бүлмә бар?

Шәмәк *(кәефе китеп).* Аны син үзең дә белмисең бит.
Әмәк. Санап күрсәтимме?
Шәмәк. Күрсәт.
Әмәк. Менә бу тәхет бүлмәсе бер булдымы?
Шәмәк. Бер булды.
Әмәк. Җәза бүлмәсе икеме?
Шәмәк. Ике.
Әмәк. Тагын күңел ачу бүлмәсе. Бусы белән биш булдымы?
Шәмәк. Тукта-тукта! Нәрсә саныйсың син?
Әмәк. Бүлмә саныйм.
Шәмәк. Санасаң, дөрес сана. Нигә ике артыннан биш дисең?
Әмәк. Биш булганга.
Шәмәк. Биш түгел шул.
Әмәк. Ә ничә соң?
Шәмәк *(шуны да белмисең дигән кыяфәт белән).* Җиде!
Әмәк. Ха-ха. Җиде. *(Мыскыллап көлә.)*
Шәмәк. Ышанмасаң, бармакларың белән санап кара.
Әмәк *(бармакларын берәм-берәм бөкләп саный).* Баш бармак берәү. Имән бармак икәү. Урта бармак бишәү...
Шәмәк. Тагын бишәүме?
Әмәк. Минем кулда шулай: ике артыннан биш.
Шәмәк. Алайса, синең бармакларың дөрес куелмаган. *(Үзенең йодрыгын Әмәкнең борын төбенә китереп ала да саный башлый.)* Баш бармак берәү. Имән бармак дүрт, әй, түгел, ике. Урта бармак җиде.
Әмәк. Бер кулда җиде бармак буламыни?
Шәмәк. Минекендә җиде генә түгел, өчәү дә булыр.
Әмәк. Өчәү? Көлдереп үтерәсең бит. Өч ул, беләсең килсә, җидедән әз була.
Шәмәк. Ә мин әйтәм — күп.
Әмәк. Ә мин әйтәм — әз.
Шәмәк *(йодрыгын тегенең борын төбенә китерә).* Санап кара.
Әмәк *(ул да йодрыгын йомарлап).* Мә, минекен үзең сана.

Бер-берләренең йодрыкларын этешәләр, шул вакыт алар тавышын ишетеп карт Вәзир керә.

Әбү. Нәрсә булды? Нигә сугышасыз, ханчыкларым?
Әмәк. Менә бит, менә Шәмәк әйтә: «Өч бармак җиде бармактан күп», — ди.
Шәмәк. Күп булгач әз диммени?
Әмәк.Әнә карт Вәзир әйтсен: өч җидедән күпме, әзме?
Әбү *(уйлана).* Ничек дип әйтергә икән? Күп тә, әз дә.
Әмәк, Шәмәк *(бергә).* Ничек инде: күп тә, әз дә?
Әбү. Шулай ул, ханчыкларым. Ханның өч алтыны хәерченең җиде алтыныннан күбрәк була.
Әмәк. Бармаклар турында әйт син.
Шәмәк. Әйе, бармакларның алтыны, бакыры юк.
Әбү. Бармаклар да шулай ук. Ханның бер бармагы хәерченең йөз бармагыннан артык.
Әмәк*(аяк тибеп кычкыра).* Син сорауга җавап бир: өч күпме, җидеме?
Әбү *(бил бөгеп).* Өч тә күп, җиде дә күп. Кем соравына карап.
Шәмәк. Нәрсә аңардан сорап торырга. Башы булса, ул шушы гомер яшәр идемени?
Әбү. Әйе, ханчыкларым. Башым юк минем. Башың булса, барыбер ханнар кисә, вәзиргә аяклар гына кирәк.
Әмәк. Ә муен өстендә нәрсә соң? Чүлмәкмени?
Әбү. Әйе. Күз күргәнне, колак ишеткәнне яшереп баручы чүлмәк.
Әмәк. Әйдә ватып карыйбыз. Анда ниләр бар икән?
Шәмәк. Нәрсә белән ватабыз?
Әмәк. Мин белмим. Үзеннән сорыйк. Әбү, башны нәрсә белән ваталар?
Әбү. Һәрбер ханның үз ваткычы була. Әткәгез мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын, гайрәтлерәк чакта адәм башларын йодрыгы белән вата иде. Куәте кими төшкәч, каты имән агачыннан гөрзи ясатты. Ә инде бөтенләй хәлсезләнгәч, палач яллады.
Әмәк. Безнең йодрык бәләкәй әле.

Шәмәк *(көрсенеп).* Гөрзи юк.

Әбү. Палач яллагыз.

Әмәк *(уйланып).* Дөньяда иң кызык уен нәрсә?

Әбү. Кемгә ничек. Әткәгез мәрхүмгә, авыр туфрагы җиңел булсын, иң кызык нәрсә — кешеләр елату иде.

Шәмәк. Әйттең сүз. Кешеләр елаганда кызык була димени?

Әбү. Кешеләр елаганда, ханнар көлә. Шулай булгач, кызыктыр инде.

Шәмәк. Нишләтсәң кешеләр елыйлар?

Әбү. Чыбык белән суктырсаң, күтәрә алмаслык налог салсаң, улларын сугышка алсаң, кызларын закладка салсаң.

Әмәк *(Шәмәккә).* Әйдә без дә чыбык сугышлы уйныйбыз.

Шәмәк. Әйдә.

Әмәк. Әбү, алып кил безгә кешеләр.

Әбү. Баш өсте, ханчыкларым. Ничәне китерим?

Шәмәк. Минем бармаклар санынча китер.

Әмәк. Юк, синең кулда бармаклар буталып беткән. Санына чыга торган түгел. Минем кулдагы бармаклар санынча китер.

Шәмәк. Юк, Әбү, аны тыңлама.

Әмәк *(Шәмәкне этеп алга чыга).* Мине тыңла, Әбү.

Шәмәк. Ә ни өчен сине тыңларга тиеш ул?

Әмәк. Мин булган өчен. *(Тарткалашалар.)*

Шәмәк. Әйдә, алайса, Әбү әйтсен, ул аңгырарак. «Акыллы сүзне аңгыра гына әйтә ала» ди иде әти.

Әмәк. Әйт, Әбү, кем кемне тыңларга тиеш?

Әбү. Сез, ханчыклар, игезләр, икегез дә тигезләр.

Шәмәк. Юк, Әбү, тигез түгел, минем башым зуррак.

Әмәк. Ә минем корсагым зуррак.

Шәмәк. Корсак та булдымы әйбер. Кешегә баш кирәк.

Әмәк. Юк, корсак ныграк кирәк. Корсак булмаса, ничек ашар идең?

Шәмәк. Ә баш булмаса, ничек ашар идең? Бөтенесе дә авыздан китә. Авыз — башның аш сала торган чокыры.

Әмәк. Бөтенесе дә корсакка җыела. Корсак — бөтен ашны җыючы капчык.

Әбү. Туктагыз әле, ханчыклар. Икегезнең дә сүзегез дөрес. Ханнарга баш та, корсак та бер дәрәҗәдә кирәк.

Шәмәк. Әйттем бит.

Әмәк. Юк, мин алдан әйттем.

Әбү. Әйе, икегез дә әйттегез: баш та ашау өчен, корсак та ашау өчен.

Шәмәк. Ул алдан әйткән. Ха-ха-ха. Син миннән ярты сәгать арттан тугансың әле. Син туганчы мин ярты сәгать акырганмын инде.

Әмәк. Мин туып акыра башлагач, бөтен хан сарае селкенеп торган. Шулаймы, Әбү?

Әбү. Шулай, шулай, ханчыгым.

Шәмәк. Мин алдан тугач, мин хан булырга тиеш. Минем сүзем хан сүзе. Боерам.

Әмәк. Боермый тор. Минем тавышым катырак. Кемнең тавышы көчле — шул боера. *(Кычкыра башлый. Аны җиңәргә тырышып, Шәмәк кычкыра.)*

Әбү. Ханчыкларым, туктагыз. Болай итеп эш чыкмый.

Әмәк. Нишләргә соң?

Шәмәк. Әйт тизрәк.

Әбү. Сез болай эшләгез: бер көнне берегез ханлык итегез, икенче көнне — икенчегез.

Шәмәк. Бүген мин хан. *(Тәхеткә менеп утырырга маташа, ләкин аның ауган икәнен күргәч, Әбүгә эндәшә.)* Әбү, утырт тәхетне.

Әбү. Баш өсте, ханым-солтаным. *(Тәхетне утыртып куя.)*

Әмәк, вакыттан файдаланып, Шәмәктән алдан тәхеткә менеп утыра.

Әмәк. Бүген мин хан.

Шәмәк *(аны өстери башлый).* Башта мин әйттем.

Әмәк. Әбү, вәзир булсаң, вәзир бул. Ханыңның әмерен тыңла.

Әбү. Ни боерасың, ханым-солтаным?

Әмәк *(Шәмәккә күрсәтеп).* Менә бу сугыш чукмары минем күземнән югалсын.

Әбү. Тыңлыйм, ханым-солтаным. Тәхеттәге кешенең һәр сүзе миңа әмер. *(Шәмәкнең колагыннан тотып тарта.)*

Шәмәк *(чинап).* Нәрсә эшләгәнеңне беләсеңме син, карт пәри? Моның өчен мин сине тәхеткә утыргач куеныңа кычыткан тутыртам.

Әбү. Тәхеткә утыргач, теләсә нишләтерсең. Бүген мин әнә *(Әмәккә күрсәтә)* аны тыңлыйм.

Әмәк. Җәза бүлмәсенә кертеп, иптәшкә бер көтү күсе җибәрергә. Күселәрне бик ярата ул.

Әбү. Тыңлыйм, ханым-солтаным. *(Шәмәкне алып чыгып китә. Шәмәк, артына борылып, Әмәккә бармак яный. Әмәк аңа телен чыгарып күрсәтә.)*

Әмәк *(горурлык белән).* Менә мин хан булдым. Хәзер нишләргә икән? *(Кыңгыравын алып кага. Вәзир керә.)*

Әбү. Ни боерасың, ханым-солтаным?

Әмәк. Мин — хан!

Әбү. Әйе, син хан.

Әмәк. Ә ханлык нәрсәдән башлана?

Әбү. Ашаудан.

Әмәк. И, ашаудан болай да туеп беткән. Хан тагын нишләргә тиеш?

Әбү. Тагын ашарга, ханым-солтаным.

Әмәк. Ашап туйгач, нишләргә тиеш, дим мин?

Әбү. Ашап туйгач тагын ашарга тиеш. Бабаң мәрхүмдә егерме ел вәзир булдым, ул да шулай эшли иде. Атаң мәрхүмгә утыз биш ел хезмәт иттем. Ул да ашый, ашый иде дә ашап туйгач тагын ашый иде.

Әмәк. Мин ашарга теләмим. Теләмим!

Әбү. Ашамасаң, син ханлык дәрәҗәңә тап төшерәсең. Меңнәрчә коллар синең өчен иген игә, меңнәрчә сугышчылар синең өчен яңа җирләр яулый. Син һәммәсен ашап бетереп барырга тиеш.

Әмәк. Ә ашаудан туктап торган чакларда нишлиләр?

Әбү. Йоклыйлар, ханым-солтаным.

Әмәк *(аяк тибеп).* Минем йокым килми.

Әбү. Йокың килсен өчен күзләрең томаланганчы ашарга кирәк.

Кыңгыравын кага. Вәзирнең хезмәтчесе керә.

Хезмәтче. Ни боерасыз, бөек ханнарның бөек вәзире?

Әбү. Бөек ханга аш алдыннан капкаларга бер тәпән каймак китер. Каймак эчендә коймак булсын. Ул тамакны шомарта.

Хезмәтче. Тыңлыйм, вәзирләрнең вәзире.

Әбү. Биш сыер итен парда парлатып, утта каралтып китер. Анысы эчне тазарта.

Хезмәтче. Сез дигәнчә булыр, вәзирләрнең вәзире. Тагын ни?

Әбү. Тагынмы? Тагын бер казан уылдык. Берәм-берәм чүпләп вакытны үткәрергә шәп.

Хезмәтче. Уылдык.

Әбү. Аннары эчеп куярга өч чүмеч тавык мие. Бусы зиһенне яңарта.

Хезмәтче. Тагын ниләр китерергә?

Әмәк. Җитте инде. Чыгып кит тизрәк.

Хезмәтче. Тыңлыйм, бөек хан. *(Чыгып китә.)*

Әмәк. Әллә син боларның барысын да миңа ашатып бетерергә уйлыйсыңмы?

Әбү. И ханым-солтаным. Боларны гына түгел, бөтен бер дәүләтне ашап бетерергә була. Мин ышанам әле.

Кулларына савыт-сабалар тотып, аш пешерүчеләр керә. Берсендә казан, берсендә чүмеч, берсендә табак белән сыер телләре, берсендә каймак тутырылган тәпән. Алар Әмәкнең тәхетен әйләнеп җырлап йөриләр. Ике кеше каймаклы тәпәнне ханга суза.

Кара сыер сөтеннән
Ап-ак каймак аердык,
Чүмеч белән тутырдык,
Калак белән каердык,
Аша, аша, хан-солтан.

Әмәк *(каймакны кабып карый).* Әче бит бу, кирәкми. Ашамыйм. *(Тәпәнне этеп җибәрә, каймак түгелә.)*

Икенчеләре сыер теле салынган табакны тотып хан каршына киләләр.

Гөбер-гөбер кайнаттык,
Ашар өчен җайлаттык:
Тышын өч кат тунадык —
Вак-вак итеп турадык,
Аша-аша, хан-солтан.

Әмәк *(бер кисәк алып каба).* Чәйнәп булмый бит моны. Ашамыйм. *(Табакны этеп җибәрә.)*

Өченче кешеләр килә. Алар да җырлап үз савытларын ханга сузалар.

Чыж-чыж итеп сыздырдык,
Сыздырдык та кыздырдык.
Капсаң, эри телләрдә —
Аша-аша, хан-солтан.

Әмәк *(үрелеп ала, ашый. Туйгач этеп җибәрә).* Кирәкми, ашамыйм! *(Аяк тибеп кычкыра.)* Чыгып китегез хәзер үк.

Әбү. Ханым-солтаным, тавык миен генә эч инде, зиһенең яктырыр, акылың артыр. *(Пешекчеләргә.)* Китерегез бөек ханга тавык миен. Сусавын да бассын, акылы да артсын.

Чүмеч белән тавык миен күтәреп, хан каршына киләләр.

Бусы чуар тавыктан,
Бусы кара тавыктан.
Чуар тавык — галимдер,
Кара тавык — хакимдер —
Эчеп җибәр, хан-солтан.

Әмәк *(бер чүмечне алып эчеп җибәрә).* Бусы ярый.

Пешекчеләр. Бөек хан хаким булды.

Әмәк икенче чүмечне дә күтәреп эчә.

Пешекчеләр. Бөек хан галим булды.

Пешекчеләр һәммәсе бергә тәхетне әйләнеп җырлап йөриләр.

Булды, булды, булдырдың, бөек хан,
Бар ханнардан уздырдың, бөек хан.
Куркып-өркеп калмадың, бөек хан,
Ерак китәр даннарың, бөек хан.

Җырлый-җырлый чыгып китәләр.

Әмәк *(корсагына суккалап).*
Ашадым да ныклап,
Корсак тулды шыплап,
Әллә инде хәзер
Алыйм микән йоклап?

Әбү. Йокла-йокла, ханым-солтаным. Тәхетеңә ят. Күп эшләдең, күп тырыштың, хәзер йоклау бик кирәк.

Әмәк. Ә чынлап та күп эшләдем, Әбү, ә?

Әбү. Әйе, әйбәт башладың. Тик шулай да хәтереңә авыр алма, атаңнан нык калыштың әле.

Әмәк. Чынлапмы?

Әбү. Чынлап булмаган кая! Ул бөтен ханлыкның сарыгын бер елда ашап бетерде.

Әмәк. Бер елда мин дә ашап бетерермен әле.

Әбү. Бүгенге кебек кенә тырышсаң, атаңны куып җитә алмассың дип куркам. Һәрбер киләчәк буын элеккесеннән уздырырга тиеш. Юкса ахырзаман җитмәс.

Әмәк. Уф, йокым килә. Туктап тор әле.

Әбү *(тәхетне тирбәтә).*
Йокла, ханым, йом күзең,
Төшеңдә күр җен кызын:
Берсе сиңа пар булсын,
Бер күрергә зар булсын.
Әлли бәү, бәлли бәү.

Әмәк *(кинәт сикереп тора).* Әбү!

Әбү. Нәрсә, ханым-солтаным?

Әмәк. Миңа бит йокларга ярамый.

Әбү. Нигә?

Әмәк. Тәхеткә Шәмәк менеп утырыр.

Әбү. Бүгенге көн синеке, ханым-солтаным.

Әмәк. Әйе шул. Шулай да хан булган көнне йокларга ярамый. Күбрәк кызык күреп калырга кирәк.

Әбү. Сүзләрең хак, ниятең шәп, ханым-солтаным.

Әмәк. Кешеләрне елату кызык дигән идең, алып кил, Әбү.

Әбү. Баш өсте, ханым-солтаным. Ничә кеше китерим?

Әмәк *(кулына карап).* Менә моның кадәр.

Әбү, болай булгач, күпме алып килергә үзем белермен дигән кыяфәт белән елмаеп куя. Чыга башлый да тукталып сорый.

Әбү. Берәм-берәм китеримме, барысын бергәме?

Әмәк. Бергә. Кайсы шәбрәк акырса, шунысына күбрәк сугарбыз.

Әбү. Чыбыкның — озынын, кешеләрнең кызыгын алып килермен, ханым-солтаным. *(Чыгып китә.)*

Әмәк *(тәхетеннән аякларын селкетеп җырлый).*
Мин тәхеттә, тәхеттә,
Йөзәм генә бәхеттә.
Ни кушсам да үтәлә —
Тра-лә-лә, әлләл-лә.

Әбү керә, үзе белән өч кеше алып кергән.

Әбү. Әмерең үтәлде, ханым-солтаным. Бармакларың саныңча кешеләр китердем.

Әмәк *(бер үзенең бармакларына карый, бер — кешеләргә, санына чыга алмагач, кул селти).* Болар кемнәр инде, Әбү?

Әбү *(бер кешене алгарак төртеп чыгара).* Менә монысы ханлыкта иң күп эшләүче.

Әмәк. Күп эшләгәнгә дә суктыралармыни?

Әбү. Ничек кенә әле!

Әмәк. Ә нигә?

Әбү. Күп эшли икән, димәк, ул ханның игътибарын тели. Ә ханның игътибары — чыбык!

Әмәк *(җиңел сулап).* Шулаймы? Алайса, аңа күп эшләгәне өчен сыртына талчыбыктан ун бүләк.

Әбү *(икенчесен алга этеп).* Бусы ялкауларның ялкавы.

Әмәк. Шуның өчен ун чыбык җәза.

Әбү *(өченчесен төртеп).* Бусы кушканны гына эшләүче.

Әмәк. Кушканны гына үтәгәне өчен ун чыбык.

Әбү. Унның бишесе ханның бүләге, бишесе — җәзасы.

Әмәк. Чыбыклар китерегез, суга башлыйм.

Әбү. Ханым-солтаным, син бер генә, алар күбәү, һәрберсенә үзең суга башласаң — кулсыз калырсың. Әй, Палач, алга чык.

Яшеренеп торган җиреннән Палач чыга. Кулында чыбыклар.

Палач. Мин монда, ханым вә вәзирем. *(Бөтерелеп йөри.)*
Чыбыкларым пешерелгән,
Сыртка сугып тикшерелгән.
Бер селтәнсәм сикертә,
Ике суксам йөгертә.

Әбү *(караңгы почмакка күрсәтә).* Әнә тегендә сузып яткырыгыз үзләрен. *(Палач кешеләрне Әбү күрсәткән якка алып китә. Җәзалау процессын күрсәтергә дә, күрсәтмәскә дә мөмкин.)*

Палач. Бер-бер, бер булды.

Әмәк. Ике-ике, ике булды.

Палач. Ике-ике, ике булды.

Әмәк. Ике-ике, ике булды.

Палач. Өч-өч, өч булды.

Әмәк *(тәхетеннән сикереп тора).* Юк, Палач, өч-өч, өч түгел, биш-биш, биш була.

Палач. Ялгышасың, ханым-солтаным. Ике артыннан — өч.

Әбү. Ничек җөрьәт итеп ханга сүз әйтә аласың син? Ике артыннан биш икәнне оныттыңмыни?

Палач *(башына сугып).* Ах бу карт хәтерне. Ялгыштырды. Кичерә күр, ханым-солтаным. *(Әмәк каршына тезләнә.)*

Әбү *(ханның колагына).* Кичермә. Йомшаклыгыңны күрмәсеннәр.

Әмәк *(аяк тибеп).* Кичермим, бүгеннән сине палачлыктан алам.

Әбү *(Палачка).* Ханның күзеннән югал. Ике артыннан биш дип, маңгаеңа язып куй.

Палач. Маңгаема да язармын, оныкларымның оныкларына да әйтеп калдырырмын, палачлыктан гына алма, бөек хан. *(Хан каршына тезләнә.)*

Әбү *(хан урынына җавап бирә).* Ханның сүзе бер булыр. Башың исән чакта күздән югал.

Палач *(еламсырап).* Вәзирләрнең вәзире. Тыңлап бетерче сүземне. Мин бит гомерем буе кешеләр җәзаладым. Шуннан тәм таптым. Кешеләрнең газаплы тавышлары минем күңелемә матур сорнай тавышы булып тоела иде. Шул эшемнән аерсагыз, мин нишләрмен?

Әбү. Теләсәң нишлә. Ханның саруын кайнатып монда торма. Әгәр җәзалау тавышы күңелеңә хуш килсә, үзеңне җәзалап карарбыз. Үз тавышың ничек яңгырар икән? *(Этkәләп чыгарып җибәрә.)*

Әмәк *(җәзаланган кешеләргә күрсәтә).* Боларын да чыгарып җибәр. Кызык түгел.

Әбү. Беренче көнне генә кызыксыз тоела ул. Әгәренки бер өйрәнеп китсәң, аннан кызык уенны таба да алмассың.

Әмәк *(аяк тибеп).* Чыгарып җибәр дидем мин сиңа.

Әбү. Тыңлыйм-тыңлыйм, ханым-солтаным. *(Теге кешеләргә.)* Әй, сез, башларыгызны култык астыгызга кыстырыгыз да, артыгыздан җилләр исеп калсын. *(Кешеләр чыгарга кузгала башлагач, һәрберсенә чыбык белән сугып кала.)*

Тегеләр сүзсез генә чыгып китәләр.

Әмәк *(еламсырап).* Әбү, Әбү, берәр кызык нәрсә уйлап тап.

Әбү. Мине уйларга өйрәтмәделәр. Вәзирләр ханнарның әмерләрен үтәр өчен генә.

Әмәк. Алайса, уйламыйча гына кызык тап.

Әбү. Тап дисәң, табам. Әмерне үтәмәскә хакым юк. Син, ханым-солтаным, өйлән.

Әмәк. И, аның нинди кызыгы булсын?

Әбү. Мин сиңа гүзәлләрнең гүзәле бер кыз табып бирәм.

Әмәк. Гүзәл кыз нинди була соң ул?

Әбү. Тукмак борынлы, табак авызлы була.

Әмәк *(кызыксынып).* Табак авызлы, тукмак борынлы кешеләр дә буламыни?

Әбү. Була, ханым-солтаным. Ул минем җиденче хатынымның унҗиденче кызы.

Әмәк. Китер алайса тизрәк. Чәченнән йолыкканда акырамы?

Әбү. Акыра, ишәк тавышлары чыгара. Хәзер алып килә́м, үзең дә күрерсең. *(Чыгып китә башлый.)*

Шул вакыт, кулларына күсәкләр тотып, Шәмәк һәм эшеннән куылган Палач керә.

Шәмәк. Палач, тондыр менә моның маңгаена. Ул минем тәхетемә менеп утырды. *(Әмәккә күрсәтә.)*

Әмәк. Ә-ә, шулаймы, бүген синең көн түгел, минем көн.

Шәмәк. Синең көнең үтте инде. Әнә тышка кара, таң атты.

Әмәк. Шундый тизме?

Шәмәк. Сиңа тиз. Әнә күселәр оясында ятып кара. Тиз булыр микән? *(Палачка.)* Тартып төшер шуны.

Палач Әмәкне тәхетеннән тартып төшерә. Әмәк кыңгыравын кагарга итә, ләкин аны Шәмәк тиз генә тартып ала һәм тәхеткә менеп утыра.

Палач *(Әмәкне тотып тора).* Ни боерасың, ханым-солтаным?

Шәмәк. Каршымда бер биет үзен.

Палач *(кулларын чәбәкләп такмак әйтә).*

Бие, бие син, Әмәк,
Боерадыр хан — Шәмәк.

Безнең олуг бурыч ул
Хан каршында биемәк.

Әмәк башта теләмичәрәк, ә соңыннан җәзаның җиңеллегеннән шатланып, сикеренгәләп биеп китә. Палач такмагын дәвам итә.

Бас, бас, каты бас,
Басканыңны хан күрсен.
Басканыңны хан күрсен дә
Дәрәҗә һәм дан бирсен.

Әмәк. Уф, арыдым.

Палач *(Шәмәккә карап).* Инде ни боерасың, ханым-солтаным?

Шәмәк. Мине япкан бүлмәгә ябып куярга боерам.

Палач. Тыңлыйм, ханым-солтаным. *(Әмәкне алып чыгып китә башлый.)*

Шәмәк *(аларны туктатып).* Бүлмәсенә миллион черки тотып җибәрергә! Черкиләр белән шаярырга бик ярата ул. *(Тегеләр чыгып китә башлагач.)* Палач, тукта. Миллионны гына түгел, җидене!

Палач. Әмерең эһ дигәнче үтәлер, ханым-солтаным. Ханлыктагы бөтен кешене черки тотарга куачакмын.

Әмәкне алып чыгып китә башлый, ләкин каршысына Вәзир килгәнлеген күреп, туктапып кала. Вәзир кәкре аяклы, тукмак борынлы, олы авызлы бер кыз җитәкләгән. Монда уенчыга маска кидерергә мөмкин.

Әбү *(ханнарның алмашынганын күреп).* Бу нинди тамаша, әллә күзем алдашамы?

Шәмәк. Күзләре ялгышмасын өчен карт Вәзирнең сыртына ун салам!

Палач. Арыш саламымы, бодаймы?

Шәмәк. Арышлы-бодайлы булса тагын да шәбрәк.

Палач. Тыңлыйм, ханым-солтаным. Тик ун гына аз булмасмы?

Шәмәк. Уннан да зур нинди сан бар соң?

Палач *(ни әйтергә белми аптырабрак кала).* Уннан зур сан җидеме, тугызмы шунда...

Шәмәк. Аларның кайсы зуррак? Син аңлатып сөйлә.

Палач. Ахырдан башка таба санасаң тугызы зур, баштан ахырга санасаң — җидесе.

Шәмәк. Алайса, менә боларның *(Вәзир белән Әмәккә күрсәтә)* берсенә ахырдан башка таба, икенчесенә баштан ахырга таба санап җиде-тугыз салам «ашатырга»!

Палач. Шушындамы, алып чыгыпмы?

Шәмәк. Алып чыгып. Минем саныйсым килми. Кара аны, санаганда ялгышма! Ялгышсаң, сорарга миңа кер.

Палач. Тыңлыйм, ханым-солтаным. *(Тегеләрне алып чыгып китә.)*

Шәмәк *(кызга).* Ә син кем?

Кыз. Гүзәлләрнең гүзәле — Дәүавыз.

Шәмәк. Сине монда кем китерде?

Дәүавыз. Әтием — Әбү.

Шәмәк. Нигә?

Дәүавыз. Ханга кияүгә бирергә.

Шәмәк. Кайсысына?

Дәүавыз. Ханнарның ханына, адәмнәрнең солтанына.

Шәмәк *(канәгать булып).* Алайса, миңа инде.

Дәүавыз *(мыскыллап).* Һи, син ханмыни?

Шәмәк *(күкрәк кагып).* Хан булмыйча! Әнә бит әтиең дә минем алда бөтерелеп кенә йөри. Палач булып Палач миңа баш ия.

Дәүавыз. Ә ханнарның акылы буламы?

Шәмәк. Ханга акыл нигә кирәк? Боерырга тел булгач җиткән.

Дәүавыз. Мин яратам шундый акылсыз кешеләрне.

Шәмәк. Үзеңнең акылың булмагангадыр.

Дәүавыз. Мин сиңа кияүгә чыккач, беләсеңме нишләрмен?

Шәмәк. Йә, әйтеп кара, нишләрсең икән?

Дәүавыз. Тәхетеңә үземнең яраткан курчагымны утыртырмын.

Шәмәк *(үртәп).* Акылың алтын икән. Тәхетне мин беркемгә дә бирмәячәкмен.

Дәүавыз. Анда курчак утырыр, үзең минем белән уйнарсың, тәхеттә нәрсә утырса да барыбер инде.

Шәмәк нидер әйтергә теләп урыныннан кымшанып куя, ләкин башын түбән иеп кереп килгән Гаскәр башлыгын күрә дә тәхетенә

җайлап утыра.

Шәмәк. Син кем? Нигә керәсең?

Гаскәр башлыгы. Мин — гаскәр башлыгы.

Шәмәк. Мин сине чакырмадым.

Гаскәр башлыгы. Галиҗәнап ханым! Кара хан безгә каршы сугыш ачты.

Шәмәк. Сугыш? Менә бу шәп, ичмасам!

Гаскәр башлыгы. Безнең сугышчыларыбыз чигенә.

Шәмәк. Шәп чигенәләрме?

Гаскәр башлыгы.Сыпыралар гына.

Шәмәк. Артка йөгергәннәрен карау кызыктыр. Карап торырга мин дә барам.

Гаскәр башлыгы. Юк, галиҗәнап ханым. Кара ханның укчылары бик мәргәннәр. Берәрсенең угы килеп тияр.

Шәмәк. Сиңа тимәгән бит әле.

Гаскәр башлыгы. Сугыш барганда мин бит тимер киемемне киеп качып ятам.

Шәмәк. Мин дә качып ятармын.

Дәүавыз. Качып яткач, кызыгын ничек күрерсең?

Гаскәр башлыгы. Әйе шул, галиҗәнап ханым, кызыгын күрмәссең.

Шәмәк. Кызыгын күрсәтмәслек булгач, нигә монда килеп аны әйтеп торасың?

Гаскәр башлыгы. Мин киңәшкә килдем, галиҗәнап ханым.

Шәмәк. Нәрсә соң ул киңәш?

Гаскәр башлыгы. Син әйткәнне мин тыңлау буладыр инде.

Шәмәк. Анысы аның әмер була.

Гаскәр башлыгы. Ә-ә, әмер икән шул. Киңәш ничек була иде соң әле? Әһә, таптым-таптым!

Шәмәк. Тапсаң әйт. Минем ашыйсым килә башлады. Ашыйсым килгәндә минем колагым ишетми.

Гаскәр башлыгы. Акыллы фикерләр озак туа ул, галиҗәнап хан. *(Чыгып китә башлый да туктап кала.)* Мин монда нигә килгән идем әле? Ә-ә, киңәшкә, галиҗәнап хан.

Шәмәк. Тагын нәрсә инде? Җитте, мине борчымагыз. Ашыйсым килә. *(Кыңгыравын кага.)*

Палач. Ни боерасың, ханым-солтаным?

Шәмәк. Ашарга китерсеннәр!

Палач. Тыңлыйм, ханым-солтаным. «Аш» дигәнче аш пешәр, «баш» дигәнче баш пешәр. *(Чыгып китә.)*

Гаскәр башлыгы. Галиҗәнап хан, гаскәр чигенгәндә, ни эшләргә икән?

Шәмәк *(уйлап тормастан)*. Ашарларына бирмәскә. Ач булсалар, дошманга каршы ачулырак сугышалар.

Гаскәр башлыгы. Менә ичмасам хан сүзе бу. Мин киттем, галиҗәнап хан. Бүгеннән бер генә сугышчыга да аш-су бирү юк. Ачулырак булырлар. *(Чыгып китә.)*

Дәүавыз. Акылың булмаса да, башың бар икән.

Шәмәк *(бик канәгать рәвештә)*. Тикмәгә генә мине кабак баш димиләр лә.

Дәүавыз. Болай булгач, мин сиңа кияүгә чыгам.

Шәмәк. Чәчеңне йолыкканда, санарга кушмасаң гына алам.

Дәүавыз. Санарга мин үзем дә яратмыйм. Әти мине санарга өйрәтә башлаган иде, карт хан үлеп китте дә, арифметика үзгәрде. Әти әйтә: «Һәр ханның үз арифметикасы була», — ди.

Шәмәк. Анысы шулай.

Дәүавыз *(шатланып)*. Син дә икенче арифметика яздыр, санамый торганны.

Шәмәк. Санап җәфалана торганы белән маташмыйм инде мин. Нишләп соң әле һаман миңа ашарга кертмиләр? *(Кыңгыравын кага.)*

Кулларына ашлы савытлар күтәреп, аш пешерүчеләр керә. Алар тәхетне әйләнеп җырлап йөриләр.

Тәкә башы мөгезле, бөек хан,
Мөгезләре сигезле, бөек хан.
Тәкә башын кимерсәң, бөек хан,
Егалырсың үгезне, бөек хан.

Шәмәк тәкә башын алып кимерә башлый. Башта яратып ашый, ләкин ашыгып ашаудан телен тешли.

Шәмәк. Уф, телемне тешләдем. Әллә нинди кимереп булмый торган баш керткәнсез. *(Башны атып бәрә.)*

Пешекчеләрнең башкалары, Шәмәк янына килеп, үз ашларын бирәләр.

Кабартмалар табада, бөек хан,
Үрел әле аңа да, бөек хан.
Кар шикелле ап-актыр, бөек хан,
Мамык кебек йомшактыр, бөек хан.

Шәмәк кабартмаларны ашый. Авызын пешерә.

Шәмәк. Кайнар бит бу! Ачуымны китерсәгез, ашамам да. *(Кабартмаларны пешекчеләргә ыргыта.)* Башка нәрсәләр әзерләгез миңа. Кайнар да булмасын, суык та булмасын. Пешкән дә булмасын, чи дә булмасын.

Аш пешерүчеләр һәммәсе бергә җырлый.

Майлы да булмас, майсыз да булмас,
Тәмле дә булмас, тәмсез дә булмас.
Әче дә булмас, төче дә булмас,
Тышы да булмас, эче дә булмас.
Шундый аш әзерләрбез сиңа, бөек хан.

Чыгып китәләр.

Пәрдә ябыла. Беренче күренеш тәмам.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хан сарае җимерелгән. Хәрабәләр өстендә Әмәк белән Шәмәк утыра. Аларның өс-башлары сәләмә. Йөзләре ямьсезләнгән, пычранган.

Әмәк *(хыялланып)*. Их, мин хан булган чакларда...
Шәмәк. Юк, мин хан булган чакларда... Бөтен кеше янымда бөтерелеп, тәлинкә тотып йөри иде.
Әмәк. Ә миңа тотмый идеме?
Шәмәк *(аның сүзенә игътибар итми)*. Табакта тәкә башы...
Әмәк. Тустаганда бозау телләре...
Шәмәк. Табада итле бәлеш.
Әмәк *(эчен уып)*. Чүмечтә тавык мие. Бер чүмеч эчеп җибәрсәң, биш чүмеч акылың арта.
Шәмәк. Артыр, көтеп тор. Син, тавык мие эчкән нәрсә, ханлыкны таркаттың.
Әмәк. Мин таркатмадым, син үзең таркаттың. Син хан булып торганда, безгә Кара хан сугыш ачты.
Шәмәк. Син хан булып торганда, бөтен вәзирләр качты.
Әмәк. Иген чәчкән көнне син тәхеттә идең, шуңар уңмады.
Шәмәк. Урып алганда син идең, шуңа күрә булганы да урылмады.
Әмәк. Син казнаны таладың.
Шәмәк. Син кешеләрне ачка кырдың.
Әмәк. Ә син нәрсә карап тордың?
Шәмәк. Синең исәрлегеңне карап тордым.
Әмәк. Минме исәр? *(Шәмәккә селтәнә.)*
Шәмәк. Синдә бар кул миндә дә бар. Кулыңнан күп сорасаң. *(Әмәкне этеп җибәрә, тегесе егыла яза. Көрмәкләшеп китәләр.)*

Болар тарткалашкан чакта Козгын килеп чыга.

Козгын. Кар! Кар! Сез һаман үлмәдегезмени әле?
Әмәк *(таш ыргытып)*. Безгә чаклы син үләрсең.
Шәмәк. Хәзер сине суеп ашыйбыз.
Козгын. Кулыгыз кыскарак. *(Читкәрәк очып китә.)*
Әмәк. Кузгалырга гына көч юк.
Козгын. Көч җыяр өчен ашарга кирәк.
Шәмәк *(Козгынны үртәп)*. Ашарга икәнен корсак та белә. Нәрсә ашарга икәнен әйт син.
Козгын. Үләксә.
Әмәк. Үләксә ашарга безне үзең дип белдеңме әллә?

Козгын. Ханнар белән козгыннар икесе бер нәселдән.

Шәмәк. Ах, азгын карга. Нәрсә дип тора. Ханнарның козгын кебек үләксә чукыганнарын кайчан күргәнең бар?

Козгын. Безнең белән сезнең арада бераз гына аерма бар барын. Без үләксә чукыйбыз, ә сез — тере кешеләрнең итен. Итен генә дә түгел — җаннарын.

Әмәк. Каркылдап торсаң, башыңа таш тондырырмын.

Козгын. Тондырыр өчен ташны иелеп аласы бар. Ә сез аңарга өйрәнмәгән.

Шәмәк *(онытылып китеп).* Вәзир! Палач! Тотыгыз шуны.

Козгын. Ха-ха-ха. Сез бит әмер генә бирә беләсез! Сезнең әмерр-ргә хәзер кар-рга да кунмый.

Әмәк. Әйе. Без әмер бирәбез, син үтә.

Козгын. Ни өчен мин үтәргә тиеш?

Шәмәк. Син безнең ханлыкның козгыны. Шуның өчен.

Козгын. Мин күк патшасына гына буйсынам.

Әмәк. Күп сөйләнмә, ашарга китер!

Козгын. Ашар-рга? Ха-ха-ха. Сез нәрсә яратасыз соң?

Әмәк *(җанланып).* Парда пешкән сыер теле.

Козгын. Эзләп кар-рагыз. Бер-рәр сыерның теле төшеп калмады микән?

Шәмәк. Тәкә башы.

Козгын. Мөгезе корсагыңны тишмәсме соң?

Әмәк. Тавык мие булса да ярар.

Козгын. Яр-рамас! Болай да акылың юк.

Шәмәк. Алайса, шулпалы бәлеш.

Козгын. Кайнар-р булыр-р. Авызыңны пешер-рерсең.

Әмәк *(ачуланып).* Үртәмә!

Козгын. Үр-ртим! Мин тук — сез ач. Туклар-р ачлар-рны үрти.

Шәмәк. Без тук чакта да кешеләрне үртәмәдек.

Козгын. Үр-ртәдегез. Үзегез табак-табак ит кимергәндә, ач ялчыларыгыз кар-рап торды.

Әмәк. Бу үртәү түгел.

Козгын. Үр-ртәү. Ач кешегә ул иң зур җәза.

Шәмәк. Алар бит кеше түгел, ялчылар иде.

Козгын. Ялчылар кемнәр алар?

Әмәк. Безнең әмерне үтәүчеләр.

Козгын. Ә сез кемнәр-р?

Әмәк, Шәмәк *(икесе бергә).* Без — ханнар.

Козгын. Ялчылар-р белән ханнар-р ар-расында нинди аер-рма бар-р?

Әмәк *(җилкәсен җыера).* Белмим.

Шәмәк. Мин дә белмим.

Козгын. Белмисезме?

Әмәк. Белдем, белдем: ханнар тәхеттә утыра.

Козгын. Кая соң тәхетегез?

Әмәк. Вәзирләр урлап качты.

Шәмәк. Ханнарның гаскәре була.

Козгын. Кая соң гаскәрегез?

Шәмәк. Кырылып бетте.

Козгын. Алайса, сез ханнар түгел хәзер-р.

Шәмәк, Әмәк *(икесе бергә).* Ә кем соң?

Козгын. Ялчылар-р.

Әмәк. Юк, минем ялчы буласым килми.

Шәмәк. Минем дә! *(Елаша башлыйлар.)*

Козгын. Акыр-рышмагыз! Мин сезгә бер-рәр акыл өйр-рәтәм.

Әмәк. Өйрәт, Козгын.

Шәмәк. Тизрәк бул.

Козгын. Козгыннар-р үзләр-ренең яшәүләр-ре белән ханнар-рга бур-рычлы.

Әмәк. Чынлапмы?

Шәмәк. Алайса, син безнең ялчы бул.

Козгын. Сез хәзер-р хан түгел.

Әмәк. Ә ни өчен бурычлы?

Козгын. Ханнар булмаса, сугышлар-р булмас иде, сугышлар-р булмаса, үләксәләр булмас иде. Үләксәләр-р булмаса, козгыннар ачтан үләр-р иде.

Шәмәк. Бурычлы булгач, бурычыңны түлә: ашарга китер.

Козгын. Бур-рычымны түлим, ашар-рга китер-рмим.

Әмәк. Безгә ашарга кирәк.

Козгын. Ашар өчен кешеләр-р эшлиләр-р.

Әмәк. Без эшли белмибез.

Шәмәк. Без кешеләр түгел, ханнар.

Козгын. Белмәсәгез өйрәнерсез.

Әмәк. Шулмы бурыч түләвең?

Козгын. Әйе. Эшләп кар-рагыз. *(Очып китә.)*

Шәмәк. Нәрсә икән ул эш?

Әмәк. Берәр тамак туйдыра торган әйбердер. Ләкин аны каян табарга?

Шәмәк. Эзләп карыйк.

Әмәк. Әйдә, алайса киттек! *(Баралар.)*

Шәмәк *(җирдә үсеп утыручы җиләкләрне күреп ала).* Әмәк, карале, җиләкләр.

Әмәк. Әйе шул. Ә нишләп алар көмеш табакта түгел? Безгә бит аны вәзирләр көмеш табак белән китерә торганнар иде.

Шәмәк. Монда берәрсенекеннән чәчелеп калгандыр. *(Иелеп җиләкне ала да авызына каба.)* Ай-яй тәмле!

Әмәк *(ул да шулай эшли).* Тәмле! Тәмле! Минем беркайчан да мондый тәмле җиләк ашаганым юк иде.

Шәмәк. Минем дә.

Сөйләнә-сөйләнә җиләк ашап йөриләр.

Әмәк. Мондагы җиләк нишләп сабакка ябышып тора икән?

Шәмәк. И юләр, шуны да белмисең: җиргә тәгәрәп төшмәс өчен.

Әмәк. Әйе шул. Аны вәзирләр шулай берәм-берәм ябыштырып куйганнардыр.

Шәмәк. Безне ашатыр өчен нәрсә генә уйлап тапмый бу вәзирләр! Берәр чокырга су да тутырып калдырганнардыр әле.

Әмәк *(еракка карап тора да кинәт сикереп куя).* Шәмәк! Шәмәк!

Шәмәк. Нәрсә бар?

Әмәк. Ә-әнә тегендә кара әле. *(Кулы белән күрсәтә.)* Әллә нәрсә ялтырап ята.

Шәмәк *(ул күрсәткән якка карый).* Су бит ул!

Әмәк. Су? Менә ичмасам шәп булды. Җиләк ашап эчәсе килә башлаган иде.

Шәмәк. Әйттем бит! Вәзирләр берәр чокырга су тутырып калдырганнардыр дип. *(Күлгә таба китәләр.)*

Әмәк *(күл өстенә карап тора).* Шәмәк, кара әле, бер балык сикерде.

Шәмәк. Пешкәнме?

Әмәк. Юк, кыздырылган. Кып-кызыл иде.

Шәмәк *(күлгә карап тора).* Әнә тагын сикерде, пешкән балык бит, син кыздырган дисең.

Әмәк. Ә мин әйтәм: кыздырылган.

Шәмәк. Син үзең кыздырылган. Беләсең килсә, кыздырылган балык табада була. Ә монда шулпа эчендә.

Әмәк. Ә-ә, әйе шул. Пешкән балык икән. Мин кыздырылганны ныграк яратам.

Шәмәк. Ә мин — пешкәнне. Әйдә тотып алабыз да ашыйбыз.

Әмәк. Ничек тотабыз? Тотканчы чокырына төшәргә кирәк, төшәр өчен ярын ишәргә кирәк.

Шәмәк. Ишәрбез дә, төшәрбез дә.

Әмәк. Анысы шулай. Тик аның шулпасы да кайнардыр әле.

Шәмәк. Бигрәк акылың юк синең. Бернәрсә дә өрмичә генә суынмый инде. Әйдә, ярын бераз сөзәклик тә. *(Аягы белән ярны ишәргә маташа.)*

Әмәк. Менә монда агачлар ята. Шуның белән җайлырак ишелмәсме?

Шәмәк. Бигрәк тупас башлы бит болар.

Әмәк. Очлыйк.

Шәмәк. Корсак кына түгел, баш та бар үзеңдә. Ә нәрсә белән очлыйбыз?

Әмәк. Очлы таш белән. *(Әмәк җирдән таш сайлап ала да агачның башын юна. Шәмәк тә шулай ук эшли.)*

Шәмәк *(очлап бетерә).* Булды бу! Хәзер ярны рәхәтләнеп ишәргә була. *(Ишә башлый.)*
Әмәк. Минеке дә булды.

Икәүләп эшкә керешәләр. Такмаклыйлар.

Һоп, һоп, һоп әйдә,
Күсәгеңне тот әйдә.
Киртләчләрне юк итик,
Шулпаларны суытыйк.

Шәмәк *(сөенеп).* Ур-ра! Хәзер төшеп була.

Әмәк *(күсәген атып бәрә).* Балык шулпасын ашыйбыз. *(Күлгә карап өрергә тотына. Аңа Шәмәк тә кушыла.)*

Шәмәк.
Тәмле балык казанда, өф-өф,
Тәти кашык базарда, өф-өф.

Әмәк.
Чыгып бетсен парлары, өф-өф,
Чөмерербез аннары, өф-өф.

Болар күлгә өреп азапланганда, бер карт килеп туктый. Аның кулында кармак, кармагында тере балык тырпылдый.

Карт. Әй сез, адәм балалары! Нишлисез?
Шәмәк, Әмәк *(икесе бергә).* Балык шулпасын суытабыз.
Карт *(хәйләкәр елмаеп куя).* Ә-ә-ә, шулаймыни?
Шәмәк *(картның кармагындагы балыгын күреп).* Әмәк, карале, теге бая сикергән балык.
Әмәк. Әйе шул. Ничек тоттың аны, бабай?
Шәмәк. Шулпасы бик кайнар түгел идеме?
Карт. Кайнар булгандыр, күрәсең, әнә бит әле дә тырпылдап тора.
Әмәк. Китер, ашыйк. Өреп суытырбыз.
Карт. Мәгез алайса, ашагыз. *(Балыгын бирә.)*
Әмәк *(балыкның сыртын тешли. Балык койрыгы белән аның яңагына суга).* Әбәү, сугыша бит бу!
Шәмәк. Бир әле, мин дә кабып карыйм. *(Балыкны ала да тешли, балык аның да яңагына чабып җибәрә.)* Бабай, нигә яңакка суга ул?
Карт. Белмим шул.
Әмәк. Әһә, мин белдем: аның сырты каты. Шуңа суга.
Шәмәк. Әйе шул. Без ашаган балыкларның сырты бик йомшак була иде.
Әмәк. Йомшак булгач авыртмаган, авыртмагач сукмаган.
Карт. Карап-карап торам да, балалар, сез бик зирәк күренәсез. Кая юл тотасыз? Шөгылегез нинди?
Әмәк. Нәрсә ул шөгыль, бабай?
Карт. Эшегез дип әйтәм.
Шәмәк. И бабай, без әнә шул эшне эзлибез дә инде.
Карт. Алай икән.
Әмәк.Бабай, эшнең нәрсә икәнен син беләсеңдер?
Карт. Мин, балалар, гомерем буе шушы күл буенда яшәдем. Балык тоттым. Шуның белән тамак туйдырдым. Сез эзләгән эшнең ни икәнен белмим.
Шәмәк. Бабай, чокырдагы су күл дип аталамыни?
Карт. Әйе, балалар. Дөньядагы һәрнәрсәнең үз исеме бар. Урманнар, күлләр, диңгезләр, чүлләр, чокырлар, таулар.
Әмәк. Бабай, безне дә балык тотарга өйрәтмәссеңме?
Карт *(сөенеп).* Ай, балалар, сөенә-сөенә өйрәтермен. Үз һөнәремнең серләрен үзем белән кабергә алып китәрмен, ахры, дип кайгыра идем. Килеп чыгуыгыз өчен рәхмәт! Дөньяда һәр ата үзе белгән нәрсәләрен балаларына өйрәтеп калдырырга тиеш.
Әмәк. Ә балаларың кая соң синең?
Карт *(көрсенеп).* Аңгыра һәм явыз ханнарның үзара ызгышып торулары аркасында җирдә ялан-ялан сугышлар булып тора. Сугышлар безнең балаларыбызны тартып ала. Менә мин дә картаймыш көнемдә япа-ялгыз калдым. Һөнәремне дәвам иттерүчем юк. Кешеләр үзләре үлгәндә дә, җирдә һөнәр үлмәскә тиеш.

Икенче күренеш тәмам.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук күл буе. Әмәк белән Шәмәк елашып утыралар. Җил сызгыра. Җепкә тезеп, киптерергә элгән балыклар җилдә тирбәлә.

Әмәк. Үлде.

Шәмәк. Әйе, кармагына эләккән балыгын да тартып ала алмады.

Әмәк. Шәп җаен капкан иде. Икәү көчкә өстерәп чыгардык.

Шәмәк. Ул җаенне күрсә, нинди шатланган булыр иде.

Әмәк. Без тоткан балыкка ул тагын да ныграк шатлана иде.

Шәмәк. Әйе. Мин беренче мәртәбә менә моның хәтле *(урта бармагын күрсәтә)* бер кәрәкә эләктергәч, сакалы буйлап күз яшьләре агып төште. Шул чагында мин аңардан: «Нигә елыйсың, бабай?» — дип сорадым. «Шатлыктан, балам», — диде ул. «Шатлыктан елыйлармыни?» — дип сорагач, «Шатлык ул, балам, тау астында яшеренеп яткан чишмә кебек үзенекен итә, барыбер ургылып чыга», — диде.

Әмәк. Күп нәрсәләргә өйрәтте ул безне.

Шәмәк. Ул булмаса, күптән ачка үлгән булыр идек.

Әмәк. Хәзер нишлибез инде?

Шәмәк. Бабайның әйткән сүзен үтик. Ул бит безгә: «Мөмкин кадәр күбрәк белергә тырышыгыз!» — диде.

Әмәк. «Күбрәк белер өчен, күбрәк күрергә кирәк, күбрәк күрер өчен, күбрәк йөрергә кирәк», — диде ул.

Шәмәк. Вакытны үткәрмик, кузгалыйк.

Әмәк. Әйдә, юл капчыклары әзер.

Җитәкләшеп кузгалалар. Җырлыйлар.

Без барабыз, барабыз,
Менә безгә карагыз.
Барган саен ераклаша
Үткәннәргә арабыз.

Шәмәк *(барган җиреннән туктап)*. Әмәк, карале, ә-әнә тегендә бер бабай күренә.

Әмәк *(ул күрсәткән якка карый)*. Гел безнең балыкчы бабай төсле. Ап-ак сакаллы.

Шәмәк. Әйдә янына барабыз. Ул үзе дә бу якка килә.

Җилкәсенә тубал аскан иген чәчүче карт керә. Ул, эш белән мавыгып, Әмәкләрне күрми. Тубалыннан учлап бодай ала да такмаклап җиргә сибә.

Бер бөртегә ун булсын, ун булсын,
Сый-нигъмәтләр мул булсын, мул булсын.
Илгә афәт килмәсен, килмәсен,
Кешеләр нужа күрмәсен, күрмәсен.

Карт. Уф, арыдым. Картлык басты. Тамакка валчык капмаганга да өченче көн. Әҗәлем якынлаша бугай, тизрәк чәчеп бетерәсе иде.

Әмәк белән Шәмәк карт янына киләләр.

Әмәк, Шәмәк *(икесе бергә)*. Исәнме, бабакай?

Карт *(кулын каш өстенә куеп)*. Әллә күзләрем ялгыша инде, әллә чынлап та адәм балалары?

Әмәк. Бабакай, без чынлап та адәм балалары.

Карт. Юктыр, юктыр! Картлыгым белән саташамдыр.

Шәмәк. Саташмыйсың, бабай.

Карт. Сакалымның берсен йолкып карагыз әле, авырту сизсәм, төш кенә түгелдер.

Әмәк. Сакалны йолкымый да белеп була аны, бабай.

Карт. Ничек итеп?

Әмәк. Менә безнең капчыкта бик тәмле балык бар. Шуны ашап җибәрсәң белерсең. *(Балык суза.)*

Шәмәк. Әйе, бабай. Ашап җибәр. Төштә ашасаң тамак туймый, өндә ашасаң туя.

Карт. Бәрәкалла! Бәрәкалла! *(Балыкны ала.)* Саташуым гына түгел, ахрысы, балыктан нинди тәмле ис килә.

Әмәк. Аша, бабай, аша. Безнең капчыкта андый балыклар күп әле.

Карт. Рәхмәт яусын сезгә, адәм балалары. *(Ашый.)* Чынлап та өн икән бу. Бер кабу белән тәнемә сихәт йөгерде. Икенче кабуда арыганлыгымны бетерде. *(Тагын каба.)* Өченче кабуда эчәсемне китерде.

Шәмәк *(савыт белән су бирә).* Мә, бабай, су да эч. Шушы балык үскән күл суы.

Карт *(суны эчә).* Рәхмәт, балакайлар. Инде мин кузгалыйм. Күкрәгемә көч керде. Икмәгемне чәчеп бетерергә кирәк.

Әмәк. Нәрсә соң ул икмәк, бабай?

Карт. Икмәк ул, балалар, тереклек. Күктә — кояш, җирдә — икмәк. Кояш сүнсә дә тереклек бетә, икмәк үлсә дә тереклек бетә.

Шәмәк. Икмәк үләмени?

Карт. Үлә. Саклый белмәсәң, кадерен белмәсәң, икмәк тә үлә, балалар. Икмәкнең дә җаны бар. Менә күрәсезме минем тубалымдагы бөртекләрне! Алар әле тубалда чакта гына тик яталар. Ә шуларны җиргә күмсәң, алар җирне тишеп чыга. Аннары кояшның нечкә нурларына тотынып күккә үрелә башлыйлар. Илгә шатлык килгәндә, алар җырлыйлар, афәт килгәндә, елыйлар...

Әмәк. Елыйлар?

Карт. Әйе, елыйлар. Җаннары булмаса, алар еларлар идемени? Ә бит аларга соңгы елларда бик еш еларга туры килде.

Шәмәк. Нигә, бабай?

Карт. Нигәме? Саный китсәң, сәбәпләре күп инде аның, балалар. Әнә бит бөтен тирә-юньдә җимереклек. Акылсыз ханнар сугыш белән мавыктылар. Җир кешесенә кадер бетте. Гомер-гомергә иген игеп үскән кешеләрне коллыкка алып киттеләр.

Әмәк белән Шәмәк башларын түбән иеп тыңлыйлар.

Карт *(аларга карап).* Монда сез гаепле түгел, балалар.

Әмәк. Без гаепле...

Карт. Юк, юк. Сезнең кем балалары икәнегезне белмәсәм дә күреп торам, әйбәт балалар сез. Кулларыгызда — сөял, күңелегездә хөрмәт бар.

Әмәк. Ханнарның бөтенесе дә акылсыз гына буламыни, бабай?

Карт. Юк, акыллылары да була. Ләкин тәхеткә менеп утырганнан соң, аларның халык турында уйларга вакытлары калмый. Акылларын май баса. Берәүләре сугышларда үзенә дан яуларга тырыша, икенчеләре халыкка бәла-каза китереп...

Шәмәк. Ә халык кем ул, бабай?

Карт. Халык ул, балалар, илне үз җилкәсендә күтәреп баручы баһадир. Ул әле үзенең шундый баһадир икәнен белеп кенә бетерми, белсә, үз җилкәсендә эрәмтамак ханнарны, вәзирләрне йөртмәс иде.

Әмәк. Ул баһадир кая соң, бабай?

Карт. Җиргә ятып көч җыя. Гелән-гелән талап торсаң, батырлар да көчсезләнә. Менә бу бөртекләрне мин шул баһадир өчен чәчәм. Мин аларны чит ил баскыннарыннан да, үз илемнең явызларыннан да саклап калдым. Өч көн буена авызыма валчык та капмаган чакта да ашамадым. Алар — бәхет орлыклары, тереклек орлыклары. Эшли алган яхшылыкны эшләп калдырырга кирәк.

Шәмәк. Бабай, син үлсәң, бу икмәкне кем чәчеп калдырганын да белмәячәкләр бит.

Карт. Яхшылык җирдә ятмый, балалар. Берәү килер дә, мин чәчеп калдырган икмәкне ашап, арыган тәненә көч җыяр. Шунда аның күңеле күтәрелер, үзенең дә матур-матур эшләр эшлисе килер. Шулай итеп, яхшылык буыннан буынга күчәр.

Әмәк. Безнең дә яхшылык эшлисебез килә. Без чәчеп бетерик әле шул икмәгеңне.

Карт. Ай рәхмәт төшкерләре! Буыннарымны яза алмый азапланып утыра идем. *(Тубалны салып Әмәккә бирә.)* Мә, балам.

Шәмәк. Ничек чәчәргә икәнен син күрсәтеп торырсың, бабай.

Карт. Бик рәхәтләнеп күрсәтермен, балалар. *(Урыныннан кузгала.)* Һәр уч орлыкны җиргә сипкәндә догасын әйтергә онытмагыз! *(Тубалдан орлыкларны ала да җиргә сибә. Әмәк белән Шәмәк тә аның хәрәкәтләрен кабатлыйлар. Карт үзенең догасын әйтә, тегеләр кабатлый.)*

Бөртекләрем үсегез, үсегез,
Җир суларын эчегез, эчегез!
Сабагы булсын камыштай,
Башагы булсын карыштай!

Әмәк. Бабай, тубалда орлык бетте дә.

Шәмәк. Чәчәргә өйрәнә башлагач кына.

Карт. Өйрәнерсез, балалар. Болай булгач, мин сезнең өйрәнәчәгегезгә ышанам. Сезнең әле гомер башлана гына. Ә хәзер юлыгызда булыгыз. Сезне алда зур сынаулар көтә.

Әмәк. Сынау нәрсә ул, бабай?

Шәмәк. Әйе, сынау нәрсә?

Карт. Сынау ул, балалар, тормыш куйган сорау. Тормыш кешегә гомер буена сорау бирә, һәркем ул сорауларга җавапны үзе табарга тиеш. Сорау кайчагында бик мәкерле була. Кеше ялганнан чынны аера алмый аптырап бетә. Әмма күңелендә сафлык очкыны сүнмәгән кеше дөрес җавапны барыбер таба. Күңелдәге сафлыкка хыянәт итмәгез, балалар!

Әмәк. Без һәрвакыт синең сүзләрне истә тотарбыз, бабай.

Карт. Мин ышанам сезгә, балалар. Ә хәзер барыгыз, юлда булыгыз! Йөз дәрьяны кичми торып тынычланмагыз.

Шәмәк. Хуш, бабай. *(Китәләр.)*

Карт. Хушыгыз! *(Кул болгап кала.)*

Өченче күренеш тәмам.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бик матур йортның рәсеме сәхнә түренә эленгән. Элекке вакыйгалардан соң байтак вакыт узган. Әмәк белән Шәмәк үскәннәр, борын асларына мыек шытып чыга башлаган. Өй янындагы эскәмиядә Әмәк белән Шәмәк егышлы уйнап утыралар. Маңгайларыннан тир тама. Үзләре мыш-мыш киләләр.

Әмәк. Уф, туктале, әзрәк кенә ял итик.

Шәмәк *(хәл алырга җай чыгуга сөенеп).* Туктасак туктыйк алайса. *(Кулларын ычкындыралар.)*

Әмәк. Без ничә көн көрәшәбез инде?

Шәмәк. Җиде көн дә җиде төн.

Әмәк. Нәрсә өчен башладык без бу көрәшне, ә?

Шәмәк *(уйланып).* Һы, чынлап та, нигә көрәшәбез соң әле без? Ә-ә, белдем! Кайсыбызның көчлерәк икәнен беләсебез килде.

Әмәк. Болай да билгеле ич инде ул.

Шәмәк. Алайса әйт: кайсыбыз көчлерәк соң?

Әмәк. Син, әлбәттә. Өй салганда бүрәнәнең юан башыннан гел син күтәрдең бит.

Шәмәк. Юк, син көчлерәк. Син култык астыңа кыстырып ташыган нигез ташларын мин көчкә тәгәрәтеп китерә идем.

Әмәк. Ә син балтаң белән бер селтәнсәң, урмандагы ун агач ава иде.

Шәмәк. Аударуын аның җил дә аудара. Ә менә син күпме агач утырттың!

Әмәк. Мин утыртканда син дә карап тормадың.

Шәмәк. Кискән агач урынына яңаларын утыртырга кирәк, дип, иң беренче син әйттең.

Әмәк. Юк, син әйттең.

Шәмәк. Мин әйтмәдем, син әйттең.

Әмәк. Ә, шулаймы?

Шәмәк. Шулай шул. Мин әйттемме?

Әмәк. Син әйттең.

Бер-берләренең билләренә барып ябышалар. Ләкин беркем дә берсен-берсе егарга теләми, киресенчә, үзе аста калырга тырыша. Әмма икенчесе аның хәйләсен тиз аңлап ала һәм иптәшенә егылырга ирек бирми. Әүмәкләшәләр, тәгәрәшәләр. Егылсалар, бергә егылалар, торсалар, бергә торалар, мышнап бетәләр. Әле берсе, әле икенчесе җиңе белән маңгай тирләрен сыпырып төшерә.

Шәмәк. Уф, туктале, минем искә бернәрсә килеп төште.

Әмәк *(Шәмәкнең билен ычкындырып).* Нәрсә?

Шәмәк. Без җиде көн дә җиде төн ашамаганбыз икән бит.

Әмәк. Әйе икән шул. Әйдә алайса, ашап алыйк.

Шәмәк. Әйдә. *(Капчыктан бер көлчә тартып чыгара да икегә бүлә. Кечерәк ягын үзенә алып кала, зурысын Әмәккә бирә.)*

Әмәк *(көлчәне алып).* Карале, син үзеңә бәләкәйрәк ягын алгансың бит.

Шәмәк. Нишләп бәләкәй ягы булсын, менә бит. *(Көлчәсен күрсәтә.)*

Шул вакыт Әмәк аның көлчәсен тартып ала да үзенекен Шәмәккә бирә. Шәмәк үзенең көлчәсен Әмәктән алмакчы була, тегесе йөгереп китә. Куыша башлыйлар. Әмәк йөгерә-йөгерә көлчәсен ашый. Шәмәк тә үз кулындагысын кабып-кабып куя. Бер-берсен куыша-куыша көлчәләрен ашап бетерәләр. Болар куышып йөргәндә, сәхнәгә бер кыз керә. Ул башта Әмәк белән Шәмәккә гаҗәпләнеп карап тора, аннары шаркылдап көлә башлый. Кызның көлү тавышын ишетеп, егетләр йөгергән җирләреннән шып туктыйлар.

Шәмәк. Әй, кем бар анда, нигә көләсең?

Кыз *(болар каршына чыгып).* Кызык булганга көләм.

Шәмәк. Ә нигә кызык?

Кыз. Кызык булганга кызык. Әнә күрмисезмени: күктә кояш көлә. Болында чәчәкләр көлә. Офыкта таулар көлә. Ха-ха-ха. *(Кызның көлүеннән егетләр дә көләләр. Бөтен дөнья көлү авазларына чума.)*

Әмәк *(беренче булып көлүдән туктый).* Әй, кызык кыз, исемең ничек синең?

Шәмәк. Әйе, исемнәрне әйтеп сөйләшик әле.

Кыз. Чын исемем минем Таңсылу.

Әмәк. Ялган исемең дә бармыни?

Кыз. Бар. Ханнар сараенда мине Дәүавыз дип йөртteләр.

Әмәк белән Шәмәк. Дәүавыз? Ә нигә андый ямьсез исем кушканнар?

Кыз. Минем әтием ханда вәзир булган. Ә ханнар бөтен нәрсәнең дә иң яхшысын үзләренә генә алырга тырышканнар. Хәтта исемнәрне дә. Ханнарның ачуы чыгудан куркып, әтием мине Дәүавыз дип йөртте. Берәрсе ялгыш Таңсылу дип эндәшсә, ул кешенең авызына әтием тизрәк бүреген тыгарга гына тора иде.

Әмәк *(нәрсәнедер исенә төшерергә теләп).* Тукта, тукта. Син әллә Әбү кызы Дәүавызмы?

Кыз *(гаҗәпләнеп).* Әйе. Ә сез минем әтиемне каян беләсез?

Шәмәк. Карале, карале, син чынлап та шул Дәүавызмы?

Кыз *(турсаеп).* Юк, мин Дәүавыз түгел, Таңсылу.

Әмәк. Безне дә бел алайса: менә бу батыр егет Шәмәк булыр. *(Шәмәккә күрсәтә.)*

Шәмәк. Ә менә бу әзмәверне Әмәк диләр. *(Әмәккә күрсәтә. Егетләр берәм-берәм кызның кулын килеп кысалар.)*

Кыз. Әмәк дисезме? Шәмәк дисезме?

Егетләр *(берьюлы).* Шулай дибез.

Кыз *(куркуга төшеп).* Сез, алайса, ханнар?

Әмәк. Нинди хан булыйк ди без.

Шәмәк. Без ул заманнарны оныттык инде.

Әмәк. Без хәзер иген үстерәбез.

Шәмәк. Балык тотабыз.

Әмәк. Өйләр салабыз.

Шәмәк. Көтү көтәбез.

Кыз. Әйе, сез нык үзгәргәнсез.

Әмәк. Син дә бик нык үзгәргәнсең. Чибәрләнгәнсең. Ничек шулай матурлана алдың?

Кыз. Чөнки миңа элек ханнар алдында ханнардан чибәр булырга ярамый иде.

Шәмәк. Акыллылангансың.

Кыз. Ханнар үзләреннән акыллырак кешеләрне дә кичерә алмыйлар. *(Кызның сүзләреннән соң Шәмәк белән Әмәк башларын ияләр.)* Ә сез башларыгызны имәгез, егетләр, сез бит хәзер ханнар түгел. Бирегез әле кулларыгызны. *(Егетләр Таңсылуга кулларын сузалар. Кыз аларның учларын карый.)* Менә бит, кулларыгызда сөял, ханнар кулында сөял булмый.

Әмәк *(учындагы сөялен сыйпап куя).* Рәхмәт сиңа, Таңсылу.

Таңсылу. Ни өчен?

Әмәк. Шундый акыллы булганың өчен.

Шәмәк. Беләсеңме, Таңсылу, син бездә кал, ә! Әнә нинди матур өй салып куйдык. Син калсаң, өебез тагын да матуррак булачак.

Әмәк. Әйе, кал, Таңсылу. Синнән берни эшләтмәбез. Өебездә хуҗа булып кына утырырсың.

Таңсылу. Юк инде, әгәр мин сездә калам икән, бары тик бер шарт белән генә калам.

Шәмәк. Әйт шартыңны. Ни әйтсәң дә, үтибез.

Әмәк. Үтибез, Таңсылу, үтибез.

Таңсылу. Алайса тыңлагыз! Шартым шул: бу өйдә хуҗа да, ялчы да булмаячак. Бу булды бер.

Әмәк, Шәмәк *(бармакларын бөкләп).* Бу булды бер!

Таңсылу *(дәвам итә).* Кайсыгыз мине ярата — шуңарга кияүгә чыгып кына кала алам. Бу булды ике.

Әмәк, Шәмәк *(бармакларын бөкләп).* Бу булды ике!

Таңсылу. Инде өченче шартым: миңа иптәшкә бүгеннән үк бер кыз табасыз.

Әмәк. Беренче шартны үтәү безнең өчен берни тормый. Үтибез.

Шәмәк. Өченче шартны да үтәп булыр. Ә менә икенчесе кыенрак.

Таңсылу. Ни өчен?

Шәмәк. Чөнки мин күреп торам, Әмәк синнән күзен алалмый.

Әмәк. Шәмәкнең дә сине күргәч битләренә ут капты.

Шәмәк. Әмәк тә сине ярата.

Әмәк. Шәмәк тә сине ярата.

Таңсылу. Кайсыгызның мине ныграк яратканын сынап карыйбыз алайса.

Әмәк. Ничек итеп?

Шәмәк. Әйе, ничек итеп?

Таңсылу. Мин сезгә хәзер бер табышмак әйтәм: кем шуңа җавап таба, шул мине ныграк ярата. Яратмаган кеше аңа җавап таба алмаячак.

Әмәк *(өмет белән)*. Әйт табышмагыңны, Таңсылу.

Таңсылу *(Әмәккә серле карый).*

Китап түгел, дәфтәр түгел,
Язылмаган — укып була.
Күңелең саф булса гына
Кулларыңда тотып була.

Шәмәк *(башын кашып).* Авыр табышмакка охшый бу. Язылмаган нәрсәне ничек укып булыр икән?

Әмәк *(өскә карый).* Әнә күк, анда йолдызлар бар, ай бар. Кеше шуларны «укый» бит. Адашса, йолдызларга карап юл таба.

Шәмәк *(Әмәкнең җилкәсенә суга).* Карале, баш бар икән бит синдә.

Таңсылу. Әйе, Әмәкнең җавабы тапкыр, әмма табышмагымны әйткәндә, мин аны күз алдында тотмаган идем.

Егетләр өр-яңадан уйлана башлыйлар.

Шәмәк. Монда без табышмакның икенче өлешен истән чыгарганбыз. «Күңелең саф булса гына кулларыңда тотып була» диелә бит анда.

Әмәк. Ә-ә, әйе шул.

Шәмәк. Нәрсә икән соң ул саф күңелләр генә кулларында тота торган хикмәт? Әһә, таптым.

Әмәк *(күңелсезләнеп).* Таптың?

Шәмәк. Әйе, таптым. Бәхеттер бу, мөгаен.

Әмәк. Бәхет ул пычрак күңелләр кулына да бик еш төшә. Шулай бит, Таңсылу?

Таңсылу. Шулай, Әмәк. Пычрак җаннар кулына эләккән бәхет мәңге ычкына алмый. Андый кешеләр әшәкелекне күбрәк эшләгән саен үзләрен бәхетлерәк тоялардыр, мөгаен.

Шәмәк. Алайса, нәрсә икән соң бу?

Әмәк. Алайсамы, мәхәббәт була бу!

Таңсылу. Дөрес, мәхәббәт! Чөнки мәхәббәтне язылмаса да укып була. Күңелең саф булса гына кулда тотып була.

Шәмәк *(кәефе китеп).* Юк, мин моңа риза түгел.

Әмәк. Җавапкамы?

Шәмәк. Юк, җавабың тапкыр анысы.

Әмәк. Ә нәрсәгә риза түгел соң?

Шәмәк. Таңсылу тагын берәр табышмак әйтсен.

Таңсылу. Ярый алайса, тагын берне әйтәм.

Җирдә дә түгел,
Күктә дә түгел,
Күбрәк булган саен
Күтәрергә җиңел.

Шәмәк. И-и, бусы бигрәк авыр табышмак инде.

Таңсылу. Егетләренә күрә соравы.

Әмәк *(табышмакны кабатлый).*

Җирдә дә түгел,
Күктә дә түгел,
Күбрәк булган саен

Күтәрергә җиңел.
Күтәрергә җиңел. *(Уйланып.)* Җирдә дә булмагач, күктә дә булмагач, кайда икән соң ул?

Шәмәк *(сөенеп)*. Таптым, таптым!

Таңсылу. Әйтеп кара.

Шәмәк. Җирдә дә булмагач, күктә дә булмагач, ул инде кеше күңелендә. Күңелдә нәрсә арткан саен безгә җиңелрәк? Шатлык! Дөресме, Таңсылу?

Таңсылу. Дөрес, Шәмәк. Башың бар икән. *(Шәмәкнең башыннан сыйпап куя.)*

Әмәк *(күңелсезләнеп)*. Болай дөрес булмый бит инде, Таңсылу.

Таңсылу. Әйе, икегез дә берәр сорауга җавап бирдегез. Болайга киткәч, өченче табышмакны да әйтми ярамас.

Әмәк *(җанланып)*. Әйт, Таңсылу. Бусына үзем табачакмын.

Шәмәк. Алдан кычкырган күкенең башы авырта, ди.

Таңсылу *(уйланып эченнән нидер сөйләнә)*.

Тыңлагыз, егетләр, әйтәм.
Юләр ташлар, акыллы алыр.

Шәмәк. И-и, бу бик җиңел... Кием!

Әмәк. Киемне юләр ташлый димени?

Шәмәк *(уйланып)*. Алайса, алайса... Алайса, ни була икән соң бу?

Әмәк. Алайсамы? Бу, минемчә, акыл, киңәш. Чөнки юләргә нинди акыл-киңәш бирмә, ул аны колагына да элми. Ә акыллы кеше башкалар киңәшен бервакытта да аяк астына салмый. Шулаймы, Таңсылу?

Таңсылу. Шулай, Әмәк. Җавабың бик дөрес.

Әмәк *(Таңсылуны килеп җитәкли)*. Син миңа кияүгә чыгасыңмы инде, Таңсылу?

Таңсылу. Чыгам. Мин нәкъ менә синең җавап табуыңа ышанган идем дә.

Шәмәк. Ә мин?

Таңсылу. Син үзеңә башка кәләш табарсың, Шәмәк. Әйбәт егет бит син.

Шәмәк *(бераз үпкәләп)*. Бик ачуымны китерсәгез, айдан Зөһрә кызны алырмын да төшәрмен.

Әмәк. Менә-менә. Алып төш әле шул Зөһрәне.

Шәмәк. Төшәрмен шул. Менә бу озын чыбыркы очына *(чыбыркы ала)* җәен кармагын бәйлим дә айны тартам да төшерәм. Әнә ич ай өй түбәсенә төшеп җитә язган. *(Йөгереп чыгып китә.)*

Әмәк, Таңсылу *(җитәкләшкән килеш җырлыйлар)*.

Бер-беребезне табыштык,
Табыштык та кавыштык.
Юлларыбыз аерылмас,
Канатыбыз каерылмас.

Шәмәк керә. Ул иңнәренә көянтә-чиләк аскан Зөһрәне җитәкләгән.

Шәмәк. Менә күрдегезме? Зөһрә бу!

Зөһрә *(баш иеп)*. Исәнмесез!

Әмәк, Таңсылу. Исәнме, Зөһрә!

Шәмәк *(Зөһрәнең иңеннән көянтә-чиләкне алып)*. Боларны җилкәңнән алыр вакыт җитте, Зөһрә. *(Көянтә-чиләкне читәнгә элеп куя.)* Бик озак еллар ташыдың инде син суны үги әниеңә. Хәзер син үги булмассың.

Зөһрә. Рәхмәт, Шәмәк.

Шәмәк. Без Зөһрәне үги итмибез бит, шулаймы, дуслар?

Әмәк. Итмәбез.

Таңсылу *(Зөһрәне кочаклап)*. Син минем иң якын сердәшем булырсың.

Зөһрә. Рәхмәт, Таңсылу. Бүген минем иң бәхетле көнем: мин яңадан кешеләр янына кайттым, Җиргә кайттым.

Таңсылу. Бүген безнең барыбызның да иң бәхетле көнебез, шулаймы, дуслар?!

Шәмәк. Әйе, кулыбызда һөнәребез — эшебез бар.

Әмәк. Яныбызда яраткан кешеләребез бар.

Таңсылу. Яраткан кешеләребез белән яраткан эш эшләп яшәргә туган җиребез бар.

Зөһрә. Әйе, туган җиребез бар.

Сәхнәгә кызлар керә. Болар беренче пәрдәдәге кәнизәкләр. Ләкин алар башкача киенгәннәр, чибәрләнгәннәр. Алар Әмәк белән Таңсылуны, Шәмәк белән Зөһрәне уртага алалар һәм түгәрәктә әйләнеп җыр җырлыйлар.

Диңгезләрне кичтегез сез —
Батмадыгыз.
Дәрьяларны кичтегез сез —
Акмадыгыз.
Туктамыйча һаман алга
Атладыгыз.
Кеше дигән зур исемне
Сакладыгыз.

Түгәрәктә җыр дәвам итә. Соңгы куплетны икенче тапкыр җырлыйлар. «Сакладыгыз» дигән сүзләрне җырлаганда пәрдә төшә.

Тәмам.

# Повестьлар

## ЯЗМЫШЛАР ЯЗЫЛГАНДА

Тыңлагыз, тыңлагыз! Мин сезгә үзебез турында сөйлим. Үзебез турында, тормышыбыз турында. Таныштыруны кемнән башлыйк икән? Әнидәнме, әтидәнме, әллә инде Рәйханә апа белән үземнәнме? Ирләрдән тотынырга кирәктер. Шагыйрь әйтмешли: «Без ирләрдән ике кеше». Шуларның мин иң яхшы белгәне — үзем. Миннән башларга кала.

Ләкин үземнең һәрвакыт ерык авызымны, кояшта эрегән сумала тамчысыдай елтырап торган кара күзләремне, иркендә үскән әрекмән яфрагы сыман тырпаешкан колакларымны сурәтли башлаганчы, сезне кисәтеп куясым килә: мин сөйләячәк вакыйгаларның очланып бетмәгәннәре дә бар. Язмышлар языла гына.

Мин үземнең хәзерге акылым белән бәләкәй чагымның тап-тар сукмакларына да барып чыгармын, хәзерге көннәремнең тапталмаган өр-яңа эзләренә дә кайтып төшәрмен. Хикәямдә таркаурак урыннар очратсагыз, гафу итәрсез, тормышта бит вакыйгалар бер җепкә генә тезелмәгән. Аннары сөйләүчесе дә минем кебек, чалбарыннан алда ботинкасын киюче булганда, аннан нәрсә көтәсең. Шулай да сез, мин сөйли башлаганчы ук кул селтәп, китеп барырга ашыкмагыз. Әтичә әйтсәк: без дә төшеп калганнардан түгел. Безнең әти ул сүзен җилгә очырмый. Хикәябезне дә нәкъ менә әтидән башлап китәргә кирәктер, мөгаен. Ул бит безнең өйдә генә түгел, авылда да башлык кеше.

### 1

Вакыйгаларны бераз артка чигереп, әтинең тракторчы булып эшләгәненнән башлыйк. Әйе, озак еллар тимер айгырны йөгәнләгән кеше ул безнең әти. Аның тракторына утырып йөрүләремне мин әле дә хәтерлим. Бервакыт ул мине ерак басуга алып китте. Җәйнең эссе көне иде. Трактор кабинасында һич чыдар хәл юк. Тимергә тотынсаң, кулларны өтеп ала, утыргычка утырсаң, сикертеп торгыза. Мин, койрыгы кысылган тычкан баласыдай, әле бер якка, әле икенче якка тартылам. Әти генә һични булмагандай тик утыра. Ул текәлеп алга караган. Ә алда кап-кара буразналар. Миңа алар очсыз-кырыйсыз булып күренәләр. Мин хәтта әтинең борылышлар ясаганын да хәтерләмим. Ул гел шулай алга бара да бара сыман.

— Әти, — дим, — менә шушылай бертуктамый алга барсаң, кая барып чыгар идең?

— Тагын шушы басуга килеп чыгар идек, ләкин бу башыннан түгел, ә-әнә теге башыннан.

Мин әтинең мондый җавабыннан соң кәефсезләнеп сүзсез калам. Мине бу басу туйдырып бетерде инде. Тизрәк су керердәй җиргә барып чыгасы иде.

— Әти, әти, дим. Озак-озак барсаң, елгалар бармы?

— Бар, улым, елгалар да, диңгезләр дә, океаннар да бар.

— Ә диңгезләр, океаннар нинди нәрсә?

— Алар, улым, иксез-чиксез, чамасыз-төпсез әйбер.

Әтинең бу сүзләреннән берни аңламасам да, «ыгы» дип куйдым. Яры да, төбе дә, өсте дә, асты да булмаган нәрсәне күз алдына китерергә тырышып карадым. Акылым җитмәде.

— Диңгезләрдә су кереп буламы соң, әти?

Әти елмаеп баш какты.

— Диңгезләрнең яры булмагач, су кергәндә киемнәрне кайда калдырасың, әти?

— Яры бар аның, улым, ләкин бер ягыннан икенче ягы гына күренми. Шуңа күрә иксез-чиксез диләр.

— Төбе дә бармы?

— Төбе дә бар. Төшеп җитеп кенә булмый.

— Әйдә, әти, диңгезгә хәтле барабыз. Рәхәтләнеп су керербез. Мин инде йөзә беләм.

— Диңгезгә дә барырбыз әле, улым, ләкин хәзер түгел. Бүгенгә без суны үзебезнең Ыкта гына керербез.

Әтинең авызыннан «Ыкта су керербез» дигән сүз чыккач, сөенечемнән кабинада сикеренергә тотындым. Хәзер инде миңа буразналар елга дулкыннарына охшап күренә башлады. Сирәк-мирәк очраган ак ташлар дулкында сикерешеп уйнаган ак чабаклар шикелле тоелды. Озакламый без ялга туктадык та, әтинең мотоциклына атланып, елгага чаптык.

Их, безнең Ык! Әллә нинди ярсыз, төпсез диңгезләргә алыштырырлыкмыни ул! Ярлары бит аның сикереп чумарга, төбе йөзеп арыгач басып ял итәргә кирәк. Һи, шушындый елганы диңгезгә тиңлә, имеш.

Ә шулай да этинең тракторы белән берәр вакыт диңгезгә барып чыксак, сыңар күз белән генә карап алу ярый үзе.

Ләкин эти тракторы белән алай ук ерак китә алмады. Уйламаган җирдән аны колхоз председателе иттеләр. Бу безнең бөтенебез өчен дә шаккаткыч хәл булды. Бездән бигрәк әни аптырады.

— Ничек син шуңа ризалаштың? — диде ул этигә. — Шундый зур хуҗалык белән җитәкчелек итә алырмын дип уйлыйсыңмы?

— Нигә әле син миңа шикләнеп карыйсың, әнкәсе?

— Нигә дип... Колхоз бит ул трактор гына түгел. Аның механизмы катлаулырак. Мең төрле кеше, мең төрле характер.

— Мин бит коммунист кеше...

— Алайга китсә — мин дә коммунист. Ләкин мин мондый эшкә алынырга батырчылык итмәс идем.

— Шуның өчен анда сине сайламаганнар бит, әнкәсе.

— Бусы инде җитди сүз түгел, Сәләхи, — диде әни. — Мондый чакта «мине сайлыйлар, мин булдыра алам икән» дип кенә карарга ярамый, үзеңнең көчең нәрсәгә җитәрлек икәнен дә уйларга кирәк.

— Көчкә килгәндә, анысы, бәлки, җитәр дә. Әмма белем ягы чынлап та сайрак, әнкәсе. Хәзер бит укымышлылар заманасы.

— Менә шул шул! Югары белемле инженерлар, экономистлар барында сине сайламасалар...

Әни чын-чынлап этинең колхоз председателе булып сайлануына гаҗәпләнде. Безнең әни ул үзе зур кеше. Врач. Врачның да әле ниндие! Ирләр генә эшли ала торганы — хирург. Район больницасында ул хирурглар арасында бердәнбер хатын-кыз. Аны бөтенесе ярата. Больницага килеп керсә, Саҗидә Хәеровна, дип, янында бөтерелеп йөриләр. Больницада гына түгел, авылда да яраталар аны. Безнең авылда кешеләрне фәлән апа, фәлән абый дип кенә атыйлар. Алай зурлап Саҗидә Хәеровна дип әйтү безнең әнигә генә эләккән бәхет. Картрак карчыкларның исеменә «тәй» кушымчасы гына кушабыз: Сәрбиттәй, Минсафаттәй...

Район бездән ерак түгел. Сигез-ун чакрым гына. Авыл белән район арасында борчак тәгәрәтерлек тип-тигез асфальт юл. Автобуслар йөреп тора. Әни иртәнге автобус белән китә дә өйгә кич кенә кайта. Кайвакыт төннәрен кунып калган чаклары да була. Без инде моңа күнегеп беттек. Кайтмаса, аптырамыйбыз. Ашарга-эчәргә Рәйханә апа әзерли. Аннары безнең эти дә аптырап кала торганнардан түгел. Теләсә нәрсә пешерә белә. Кайчакта ул: «Мин бит солдатта хезмәт иткән кеше, ә солдат ул балтадан да ботка пешерә белә», — дип көлә. Минем балтадан пешкән ботканы бик ашыйсым килсә дә, аны пешереп күрсәткәне юк әле үзенең. Ә председатель итеп куйганнан соң, бөтенләй вакыты калмады. Күп көнне аның чыгып киткәнен дә күрми калабыз. Җитмәсә әле укый да.

Уку дигәннән, әкәмәт кеше инде ул безнең эти. Ун классны ул моннан бишбылтыр элек бетергән инде. Авылда зурлар өчен кичке унъеллык мәктәп ачып җибәргәннәр иде, кабат унынчы класска йөри башлады. Әй Рәйханә апа көлде инде үзеннән. «Сине күптән председатель итеп куясылары калган, беренче класстан өр-яңадан минем белән укый башлаган булыр идең, — ди. — Хәзер инде бергәләп алтынчы классны бетерер идек», — ди. Рәйханә апа гына түгел, минем дә исем китте. Мин дә бит укучы. Әлегә ике генә класс укысам да, укуның балтадан ботка пешерүдән кыенрак икәнен беләм. Ә шулай да эти мәктәпкә йөри башлагач, кызыграк булып китте. Безнең дә кадерне белер. Уку ул председатель булып йөрү генә түгел. Анда машинага утырып приказ биреп йөргәч тә. Монда приказны үзеңә үтәргә туры килә. Укытучылар алар син председатель дип тормаслар, белмәсәң, акыртып икеле куярлар. Әнә этинең дәфтәрләрендә дуңгыз баласыдай симез икелеләр күренгәли башлады. Үзе тагын, без күрмәсен диптер инде, дәфтәрләрен әллә кая шкаф артына ук яшереп китә. Юләр инде ул. Безнең өй эчендә мин тапмаган нәрсә буламы соң! Мин аның дәфтәрләрен яшереп куйган көнне үк табып актардым. Шуннан бирле бер көн дә карамый калмыйм. Икелеләре ишәйгән саен, апага да, әнигә дә күрсәтәм. Бервакыт әни, аны җәлләп:

— Син, Сәләхи, дәфтәреңә билге куйдырмый гына йөр, — диде. —Син бит инде кайчандыр унны бетергән кеше. Бераз искә төшерер өчен барып кайтсаң ярар.

— Икелеләрең дәфтәреңдә чекрәешеп ятса, искә тагы да ныграк төшә бит, — диде эти. Аннары ул бераз уйланып утырды да болай диде: — Хәзер мин бөтенесен онытып бетергәнмен, әйтерсең беркайчан да укымаганмын. Хәер, мин укыганда да алай ялтырамадым. Аннары ничектер уку бик кирәк дип тә саналмагандыр инде. Их, ул чакларны кире кайтарып алып булса...

— Институтка ук керергә уйламыйсыңдыр бит? — дип сорады әни.

— Менә тагын, әйттең сүз! Нигә уйламаска? Миңа бит әле 38 генә яшь. Менә быел әйбәт кенә хәзерләнеп кереп кайтсам, 48 яшьтә институтны тәмамлап чыгам. Югары белем белән пенсиягә чыкканчы унҗиде ел эшли алам.

Әни аңа ышанырга да, ышанмаска да белмичә озак кына карап утырды да:

— Ә бит син элек бер дә болай сөйләми идең. Председатель булгач, үзгәрдең. Хәтта мин сине яшәреп киттең дип әйтер идем, — диде.

Әйе, әтинең үзгәргәнен мин дә күреп торам. Көн саен ап-ак күлмәк кия. Сакал-мыекларын кыра. Ботинкаларына кадәр ялтыратып җибәрә. Әзрәк нечкәреп тә китте тәсле. Юкса ул элек аю кебек юан йөнтәс иде. Тузанга батып, мотоциклына да атланып чапмый. Элекке председательне йөрткән брезент башлы «бобик»ны үзе авызлыклый да теләсә кая китә. Ә инде көннәр пычратып, басу юлларыннан машинасы үтә алмаса, Майорны иярли.

Майор — колхозның кара айгыры. Маңгаенда бер ак йолдызы булганга, малайлар шулай диләр. Аны рәтләп җигүче дә юк. Сабан туйлары алдыннан бераз йөртергә алып чыккалыйлар. Үзе ул чабышкы нәселеннән. Ләкин ничә ел район сабан туйларында катнашып та беренчелекне алганы юк. Артык симергән шул. Сырты чокырланып эчкә батып тора. Тәпиләре минем юанлыгы. Ә йөзүен шәп йөзә инде. Әгәр дә ярыштырсак, моторлы көймәне уйламый да узып китә. Әтине председатель иткәч, мин Майорга рәхәтләндем. Кояшлы көннәрдә су буеннан кайткан да юк. Апа әйтмешли, бездә хәзер полный демократия. Теләсәң ни эшлә, сүз әйтмиләр. Әтине аны эт белән эзләсәң дә таба алмыйсың. Идарәсендәдер дип барсаң, басуда, диләр. Басудан эзләсәң, фермада була. Үзе күңелен төшерми тагын. Миңа калса, үзенең шулай вакыты юкка сөенә дә бугай ул. Унынчы классын да тәки икенче катка бетереп чыкты. Хәтта башкалар белән имтиханнарын да биргән. Хәзер инде Казанга китәргә җыенып йөри. Документларын җибәрде, үзен чакырып язу килгәнне генә көтә.

Рәйханә апа — җидене, мин өчне бетердем. Әти әйтә: «Сезнең икегезгә ун класс була, димәк, икегезгә бер аттестат тиешле инде», — ди. Аттестатын бирсәләр, анысыннан апа да, мин дә баш тартмас идек, әлбәттә. Өлгерүен инде без күптән өлгергән. Хәзер бит акселерация заманы. Апаның егетләре инде әллә ничәү. Берсенә ошарга тырышып, маңгай чәчләрен кызган энә белән бөдрәләтеп җибәргән иде, анысы белән ташлашкач, төлке койрыгы ясап куйды. Үзе тагын: «Миңа кайсы килешә?» — дип сораган була. Әни югында аның биек үкчәле туфлиләрен киеп көзге каршына килеп баса да уңлы-суллы бөтерелергә тотына. Кодрәтеннән килсә, бүгеннән утыз яшьлек кызга әверелер иде. Апаның кыланганын карыйм һәм малай булып туганыма сөенәм. Әйдә, алар безгә ошарга тырышсыннар. Ни әйтсәң дә, без ир кешеләр! Без телибез икән ошатабыз, теләмибез икән урамның икенче ягына карыйбыз да китеп барабыз. Аннары кызлар елый-елый чәчләрен үзгәртә башлыйлар. Апа төлке койрыгыннан соң нәрсә ясар икән? Карап карыйк.

Бу егете белән борчаклары пеште, ахры. Төлке койрыгы һаман сүтелмәде. Ул арада әтине Казанга укырга чакырып язу килде. Рәйханә апа белән аны аэропортка хәтле озата бардык. Әни операциядә иде, әтинең киткәнен күрми дә калды. Аэропорттан кайтышлый әнинең больницасына кердек.

Больницада тып-тын. Йөри ала торган авырулар бар да коридорга чыгып нидер көтеп торалар. Шәфкать туташлары, ак күләгәләр шикелле, тавышсыз гына үтеп китәләр. Безгә дә шаулашмаска кушып, «тс-с» дип ымладылар. «Операция бара» дигән язу яна иде. Шуңа һәммәсе аяк очларына гына басып йөри икән. Минем операция ясаганнарын бик күрәсем килсә дә, анда кертмәделәр. Сөт исе сизгән мәчедәй, ишек тирәсендә чуалуымны күргәч, бер юан апа, йомшак кына итеп: «Барыгыз, үскәннәрем, ишегалдына чыгып торыгыз, әниегез күрсә, тиргәр үзегезне», — дип, безнең икебезне дә җитәкләп чыгарды һәм ишекне ябып куйды.

Без, тышка чыгып, юкә күләгәсенә утырдык. Өйгә кайтасы килми иде. Әтине озаткач, өй бигрәк күңелсезләнеп калды. Казанга китмәгәндә дә әти өйдә сирәк була иде булуын. Ләкин үзе өйдә юкта да һәрнәрсәдә аның барлыгы сизелә иде. Аннары аны менә кайтыр, менә кайтыр дип көтеп торуы да рәхәт.

Әнинең эше беткәнен көтеп утырганда, безнең янга ак сакаллы бер бабай килде. «Сез духтыр Саҗидәнең балалары буласызмы әллә?» — дип сорады ул. Аның сүзен раслап баш кактык. Аны белгәч, сөенеп: «Ай рәхмәт, ай рәхмәт», — дип, безнең җилкәләребездән кага башлады. Әйтерсең без аңа берәр яхшылык эшләгән. Җилкәләребезне кагып туйганнан соң, исемнәребезне сорады.

— Фәйрүз, — дидем мин, исемем белән горурлангандай итеп.

— Бәрәкалла, бәрәкалла! Бигрәк күркәм исем икән. Ә син ни атлы, кызым?

— Рәйханә!

— Менәтерә! Шундый да матур исемнәр! Үзегез дә пешеп җиткән алмалар кебек.

Бабай Рәйханә апага сокланып карап торды һәм:

— Тфү, тфү, күзем тимәсен тагын, — диде.

Аның шулай кыланганыннан көләсе килеп китте. Ләкин олылар алдында көләргә ярамаганны мин белә идем, пырхылдап җибәрмәс өчен, авызны уч белән капладым. Юкса минем авыздан барысын да көтәргә була. Йә ул иң ярамаган сүзне әйтеп ташлый, йә иң кирәкмәгән җирдә ерыла башлый. Авызым мине ничәмә-ничә тапкырлар оятка калдырды инде.

Ә бабай сөйләнә дә сөйләнә. Куанычы эченә сыймый. Менә, ди, әниегез миңа шундый итеп операция ясады, егерме яшькә яшәреп киттем. Теләсә нәрсәне умырып ашыйм. Дөньяда миннән дә бәхетле кеше юктыр, ди. Кызык инде бу карт кешеләр, әйтерсең бөтен нәрсәне умырып ашау бик зур бәхет. Ул бит бик пүчтәк нәрсә. Миңа операция ясамасалар да, ашауда күпләрне узып китәм. Тиз ашау буенча ярыш ачсалар, беренчелекне мин беркемгә дә бирмәс идем. Бик ачыккан чакта ут кебек ашны да йотам гына.

Бабай шулай әнигә дә, безгә дә бик зур рәхмәтләр укыганнан соң, безгә озын гомер теләп дога кылып куйды.

Аннары җитез генә сикереп торды да:

— Беләсезме хәзер нишлибез, балалар? — диде. Нишләргә җыенуын төшенмичә, сораулы күзләребезне аңа төбәдек. — Без хәзер сезнең белән кибеткә барабыз. — Бабай шап итеп пижама кесәсенә сукты. — Акча бар! Йә, әйтегез, ни теләр идегез?

Мин иреннәремне ялмап алдым. Күз алдымда кәгазь стаканлы туңдырмалар килә башлады. Дөньяда аннан да шәбрәк теләк булырга мөмкин түгел иде.

Һич икеләнмичә:

— Туңдырма, — дидем.

— Ә син ни телисең, Рәйханә кызым?

— Миңа берни дә кирәкми, бабай.

Мин апаның босоножкидан чыгып торган бармакларына бастым:

— Юләр, морожныйдан баш тарталармыни? Җае чыкканда ашап кал!

Ләкин апа үзенең олылыгын күрсәтергә теләдеме, ык-мык килде.

Бабайның колагына гына мин болай дидем:

— Туңдырманы ат кебек ашый ул, ал гына.

Бабай тырпаеп торган сыңар кашын сикертеп куйды да икебезне ике кулына җитәкләп урамга чыгып китте. Больница капкасы төбендә генә диярлек туңдырма саталар иде. Бабайга мин биш бармагымны күрсәттем: «Биштән дә кимне алма!» Бабай, минем һәрбер әмеремне үтәргә әзер торучы әкияттәге җен шикелле, баш кына какты да икебезгә дә бишәр туңдырма алып бирде. Баштагы икесен апа да, мин дә тиз генә ялт иттереп куйдык. Соңгылары әкренрәк бара башлады. Аларын мин бабай күрмәгәндәрәк яртылаш кына ялаштырып куак төбенәрәк җибәргәләдем. Апаның кулындагылары эри иде, аңа да ярдәм итештем. Шул арада безнең бишәр туңдырма юк итүебезне күргәч, бабайның күзләре шар булды.

— Әллә тагын бишәрне алып биримме? Акчам бар. Пенсиям больниска да килеп тора, Аллага шөкер, — диде ул.

Туйдык, гарык булдык дип аны көчкә ышандырдык.

— Алайса, әйдәгез, менә бу кибеткә дә кереп чыгыйк әле, балалар.

Ул безне үз артыннан ияртте. Апа ничектер, мин кибеттә әйберләр карап йөрергә яратам. Керү белән минем күзем чалбар каешларына төште. Кешеләрне кызыктырыр өчен аларны юри буй-буй итеп сузып куйганнар. Бигрәк тә төрле төстәге нечкә каештан үреп ясалганы шәп. Мондый каешым булса, мин чалбарны гына түгел, трусикны да бәйләп йөрер идем. Их!

Карагыз әле, бу бабай әллә чынлап та әкияттәге җен карты инде, теләкләрне әйтмичә дә белеп ала. Мин икенче яктагы әйберләрне караштырган арада, теге елан кабыгыдай каешны җилкәмә китереп тә салды.

— Матурмы?

— У, бабай, матур гынамы соң? Мин моны мунчада да салмаячакмын.

Ул минем шатланганымны күреп бәхетле елмайды. Рәхмәт әйтмәс борын ук, зур үс, бәхетле бул, дип, аркамнан сөйде һәм Рәйханә апа янына китте. Кызлар кызлар шул инде, рәтле әйбер карый белмиләр. Песи күзедәй яшькелт брошкалар тезелгән җиргә килеп туктаган да катып калган. Ә бабай хәйләкәр. Әле берсен, әле икенчесен алып, Рәйханә апаның түшенә куеп карый. Апа оялган булып маташа. Күреп торам инде, әнә теге зәңгәр брошканы һич кулыннан ычкындырасы килми. «Юләр булма, ал!» — дип, кабыргасына төртәм. Ә ул һаман боргалана. Имеш, таныш түгел кешедән әйбер алу уңайсыз. Мондый бабайлар күбрәк очрап торсын иде әле. Белер идем мин аларның кадерен. Көн саен бер каеш алдырыр идем.

Апа алмыйча күпме маташса да, бабай үзенекен итте. Молодец кеше икән.

— Бүләкне, — ди, — алмыйча ярамый. Алмасаң, мин рәнҗермен. Ә олы кешене рәнҗетүнең гөнаһысы бик зур.

Бу сүзләрне бабай шулхәтле ихлас итеп әйтте, минем Рәйханә апаны гөнаһка батырасым килмәде, тизрәк ал инде, кыланчык, дип, бабайга кушылап кысташа башладым. Тәки алды. Алды да түшенә кадап та куйды.

Мин, аңа якынрак килеп:

— Хәзер теге сине күргәч тәгәрәп китәр инде, — дидем.

— Ни сөйлисең син, башмак авыз, нинди «теге»?

— Белми дип уйлыйсыңдыр әле, Гөлнисаттәйнең Дамиры әллә юкка гына безнең бозауны алып кайтамы?

— Кайтса соң, бозау карашкан бөтен малай минеке була башласа.

— Бөтенесе дә түгел, әлегә Дамир гына, элек Илшат иде.

— И юләр, Илшат белән минем сөйләшкәнем дә юк.

— Сөйләшмәсәң дә, чәчләреңне энә белән бөдрәләтеп йөрдең инде.

Апа минем авызга менеп төшә язды, читкә тайпылып кына калдым. Ярый әле үзем җитез. Без шулай бәхәсләшеп маташкан арада, бабай да кибеттән чыгып киткән. Әнинең эше беткәндер инде дип без яңадан больницага киттек. Әни чынлап та операциясен ясап бетергән, күрәсең, шактый җәфаланырга туры килгәндер — бик арыган төсле күренә. Башка вакытта без килсәк, елмаеп берәр матур сүз әйтеп куя иде, бүген күтәрелеп тә карамады. Шәфкать туташлары да, ярамаган эш эшләп тотылган кешеләр сыман, бер-берләренә карамыйча гына сөйләшәләр.

— Нәрсә булды, әни, нигә болай тын?

Апайның бу соравына әни түгел, теге безне җитәкләп чыгарган юан няня җавап бирде:

— Операциядән соң авыруыбыз үлде. Әниегезне борчып йөрмәгез.

Шыпырт кына чыгып китәргә уйлаган идек, әни туктатты:

— Мин дә кайтам, бераз гына көтегез. — Ул, халатын салып, чәчләрен төзәткәләде. — Әтиегез киттеме?

— Әйе, аны озатып куйдык та кайтышлый монда кердек.

Сүзсез генә капкадан чыгып киттек. Мин инде күптән каешым белән мактанырга уйлап тора идем, шул вакыт әни Рәйханә апаның брошкасын күреп алды:

— Каян килгән брошка бу?

— Күктән төште, әни, күктән. Менә миңа бу каеш белән бергә, — дидем мин, җай чыгуга шатланып.

— Әйбәтләп кенә аңлатып бирегез әле! Йә, кайсыгыз башлый?

Әнинең кырыс тавышын ишеткәч, мин койрыкны кыстым. Әйдә, апа аңлатсын. Тегенди-мондый очракта таякның юан башы сөйләгән кешегә эләгә бит. Минем бер дә юан таяк астына сыртны куясы килми.

— Йә! — дип кабатлады әни.

Шуннан соң Рәйханә апа хәлне сөйләп бирде. Моны ишеткәч, әни барган җиреннән шып туктады.

— Бу ниткән эш? Кем сезгә белмәгән кешедән әйбер алырга кушты?

— Безне белмәсә, ул сине яхшы белә. «Сез духтыр Саҗидә балаларымы?» — дип сорады да, шулай икәнебезне әйткәч, кибеткә алып китте.

— Нindirәк кеше иде?

— Ак сакаллы матур гына бабай.

— Ә-ә! Мөгаен, Кадыйровтыр. Хәзер үк илтеп бирегез әйберләрен! Йә, нәрсә карап торасыз?

Без урыныбыздан кузгалдык.

— Әгәр дә без аның әйберләрен кире кайтарып бирсәк, бабай безгә рәнҗи. Ул бик әйбәт бабай.

Минем болай диюем әнине һич тә йомшартмады, киресенчә, ул безне ныклап ачуланырга тотынды:

— Һы, бүләк, имеш. Миңа әллә нәрсәләр дә бүләк итәләр, һәрберсен ала башласаң. Кара син аларны, нинди кешелекле кешеләр. Рәнҗетүдән куркалар. Ә менә шул әйберләре белән мине рәнҗеткәннәрен аңламыйлар.

— Ул бит, әни, сиңа рәхмәт йөзеннән шулай эшләде, — диде апа. — Син аңа операция ясагансың, терелткәнсең.

— Без бүләк өчен эшләмибез. Хөкүмәт безгә эш хакы түли. Терелткән һәр кешедән бүләк ала башласак, беләсезме без кемнәргә әйләнер идек? Әгәр әниегезнең кеше алдында йөзе кызармасын дисәгез, хәзер үк бүләкләрегезне кире илтеп бирегез.

Әни кызу-кызу атлап китеп барды. Без баскан урыннарыбыздан кузгала алмыйча озак таптандык. Әнине ни өчендер аңлап җиткерә алмадык. Күз алдына теге бабай килеп басты. Ул безгә шундый кирәкле әйбер алып биреп шатландыра алуына һаман куанып елмая сыман.

— Әйдә әйберләрне илтмибез, — дидем мин.

— Әнинең нәрсә әйткәнен ишеттең бит, — диде апа.

— Ишеттем дә, бабай бигрәк жәл.

— Әни жәл түгелме?

— Әни дә жәл.

— Жәл булгач, кире илтергә кирәк.

Без теләр-теләмәс кенә больницага юнәлдек. Мин каешны билдән чишеп кулга тоттым. Апа да брошкасын кулына алды. Бабайны без капка янында ук очраттык. Ул безне күрүгә каршыбызга чыкты:

— Нәрсә, балалар? Әллә әниегезне эзлисезме?

— Ю-ук! Әнине түгел ие...

— Керегез, кер. Сөйләшеп утырыйк.

— Бабай, ни... — дидем мин, аска карап.

Бабай күзләрен мина текәде. Алар «берүк мине рәнҗетә күрмәгез инде» дигән кебек карыйлар иде. Мин каешымны бабайга сузарга теләсәм дә, кулларым күтәрелмәде. Шул вакыт апа көтелмәгән кыенлыктан коткарды:

— Бабай, без бүләк өчен рәхмәт әйтмәгәнбез икән. Зур рәхмәт!

— Ай, рәхмәт төшкерләре! — диде бабай. Үзенең күңеле нечкәрүдән күзләре яшьләнде. — Барыгыз, балалар, барыгыз. Рәхәтен күрегез. Шулай тәүфыйклы булып үсегез.

Ул безнең аркадан сөеп озатып җибәрде.

Мин, каешны болгап:

— Боларны нишләтәбез инде? — дидем.

— Боларнымы? — диде апа һәм урамнан үтеп баручы бер кечкенә кызны туктатты да брошкасын түшенә кадап куйды. Мәсьәләнең болай чишелүенә шатланып, мин дә каешымны бер малайның биленә буарга уйладым. Ләкин тиккә генә бирү жәлрәк иде. Берничә малайны йөгерештердем. Әйберләрдән җайлы котылуыбызга сөенешеп, өйгә кайтып киттек.

— Кара аны, әнигә ычкындыра күрмә! — диде апа.

— Әллә син мине, авызы зур дигәч тә...

Шушы вакыйгадан соң мин апаны якынрак күрә башладым. Кыз кеше булса да, бөтенләй башсыз түгел. Әнә бит ничек җайлы уйлап тапты.

Апа турында сөйли башлагач, бераз җентекләбрәк сөйлим инде, чөнки ул хикәябездә төп урынны алып торачак. Рәйханә апа тулы гәүдәле, юан сыйраклы кыз. Үз классташлары арасында ул, чыпчыклар янындагы күгәрчендәй, әллә каян аерылып тора. Нәрсә күреп шулхәтле тиз үсәдер? Их, андагы гәүдә миндә булса! Ә ул, юләр, шуның кадерен белми. Әни әйтә, акселерация галәмәте, ди. Нигә соң ул акселерация апага гына эләккән дә, миңа юк? Кызларга пычагыма кирәкме тиз үсү? Әнә ич, үз гәүдәсеннән үзе оялып, иптәшләре белән дә рәтләп аралашмый. Көзгегә дә мин югындарак карарга тырыша. Йодрык кыстырып куйгандагыдай тырпаешкан түшләрен көзгедән карап торганда, мин кайтып керсәм, кызарып сүз әйтә алмас хәлгә килә. Кайчагында тиктомалга мине ачуланып ташлый. Яисә бер дә юктан шаркылдап көлә-көлә дә балавыз сыгарга керешә. Мин аны һич аңлый алмыйм. Кыланышларына җавап таба алмаган чакларда, кызлар шулай буладыр инде дип көрсенәм дә үземнең малай булып туыума шатланып куям. Апаның тагын бер гадәте бар: өйдә ялгыз калган чакларда җырларга ярата. Җырны ул чынлап та матур җырлый. Сәхнәдәге артистлар кебек кычкырып, кешеләр ишетсен дип түгел, үзе өчен генә, бөтен йөрәге белән җырлый. Күңелеңне салып тыңламасаң, аның җырлаганын ишетмисең дә. Әнә шулай эчтән генә җырлап утырганда ул бик матурая, күзләрендә әллә нинди матур очкыннар барлыкка килә. Бөтен бите янып торган учак шикелле була. Учак бит ул минут эчендә әллә нинди кыяфәтләргә керә, үзгәрә: бер карыйсың — кояш чыккандагы офыктай гөлтләп кабына, икенче карыйсың — җәйге аяз төндә йолдызлар атылганны хәтерләтеп төрле балкышларга күмелә. Кич белән бөтен утларны сүндереп учак янганын карап утыру нинди рәхәтлек бирсә, апаның авыз эченнән җырлавын тыңлау да күңелгә шундый җиңеллек, күтәренкелек бирә.

Әтиләр, Рәйханә апаның җырга әвәслеген белеп, аңа пианино алып бирделәр: «Бәлки, анда талант яшеренеп ятадыр. Өйрәнсен, ачсын талантын!» Районнан әнинең бер таныш укытучысы килеп, пианинода уйнарга өйрәтеп тә маташты. Ләкин апа пианиноны алып кайткан көннән үк аны үзенең кан дошманы санады. Ә бервакыт өйләрне юганда әллә юри, әллә чын — ачык пианино өстенә бер чиләк пычрак су түкте. Әниләр аның бу кыланышларын күрсәләр дә, күз йомарга тырыштылар. Берсе врач, берсе председатель башы белән кыз кешене тотып каезламаслар бит. Шуннан соң аны пианино уйнарга көчләмәделәр. Хәер, безнең әти инде әллә кайчан апаның кем булырга тиешлеген уйлап куйган. Кем дисезме? Игенче! Агрономмы, гап-гади колхозчымы — аның өчен барыбер. Син бары тик иген генә үстер. Башканы белми дә, белергә дә теләми. Кешеләр иген үстерә белә башлаганнан соң гына маймылдан кешегә әверелгәннәр, ди. Дөньяда шуңынчы кыргыйлык яшәгән. Без үстергән ипи галимгә — акыл, язучыга — илһам, эшчегә көч бирә, ди.

Әни әтинең сүзләрен җөпләгәндәй баш кагып тора да үз һөнәренең яхшылыкларын санарга тотына: «Дөньяда иң борынгы профессия — врачлык. Кешеләр икмәк үстерергә өйрәнгәнче үк бер-берләрен дәваларга өйрәнгәннәр. Врачлык ул нинди дә булса бер авыруны дәвалау гына түгел, ә кешеләр күңеленә

табигать тарафыннан салынган кешелеклелекнең чагылуы да», — ди. Әти аңа: «Кешенең кешелеклелеге профессиягә бәйләнмәгән», — дип каршы төшә.

Безнең өйдә бу бәхәс күптәннән бара. Кулларыннан килсә, әти белән әни Рәйханә апаны урталай бүлеп, бер ягыннан — врач, икенче яртысыннан игенче ясарлар иде. Председатель булып алгач, әти игенче һөнәрен бигрәк тә мактый башлады. Беркөн үзен мәктәпкә чакырдылар. Унынчы классны тәмамлап чыгучыларның бөтенесен дә авылда калырга өндәгән. Безнең авылда болай да инде яшьләр җитәрлек. Казанга укырга яки кияүгә читкә чыгып киткәннәр генә авылда калмый. Рәйханә апага әле укырга китәргә дә, кияүгә чыгарга да иртәрәк, тик әтиләр, әниләр талны нечкә чакта бөгеп калырга тырышалар бугай. Ләкин элек әйткәнемчә, Рәйханә апа инде бик нечкә тал түгел. Ул урамнан үткән чакта, олы гына егетләр дә, барган җирләреннән туктап, борылып-борылып карыйлар. Ә Тургай абый мине үзенең иң якын дусты саный. Белеп торам, шул Рәйханә апа аркасында.

Тургай абый безнең мәдәният йорты директоры. Әкәмәт тә шәп кеше. Дөньяда аның берәр белмәгән нәрсәсе бар микән? Ике институтта укыган, аннан алда ниндидер училище тәмамлаган бугай. Дөрес, институтларының берсен дә бетермәгән. Авылда аны аяклы энциклопедия дип йөртәләр. Нәрсә генә дисәләр дә, үпкәләүне белми үзе. Безнең авылда читтән торып институтларда, техникумнарда укучылар күп кенә. Шул читтән торып укучы абыйлар-апалар үзләренә җибәрелгән контроль эшләрен күтәреп Тургай абый янына киләләр. Тургай абый ул үзе белмәгән нәрсәне дә ялт кына китаптан табып ала: «Туктале, бу хакта фәлән китапның фәлән җирендә язылган булырга тиеш. Фәлән китапта моңа каршы әйтелгән фикер дә бар. Менә шуларның икесен дә укы да уртаклыкны үзең тап». Тургай абый әнә шул һәр ике китапны табып ярдәм сорап килүченең кулына тоттыра яисә ул кеше белән бергәләп үзе укырга керешә. Очына чыга алмастай күренгән эшне төгәлли алса, чын-чынлап куана: «Минем үземә дә файдалы булды әле бу!» — ди.

Тургай абыйның бер кызык ягы бар, ул һәрбер кешедә талант күрә. Берәрсенең җырлаганын ишетсә дә, биегәнен күрсә дә: «О, сездә табигый талант бар. Талантны әрәм итү — кешелек дөньясына хыянәт итү. Бүген үк культура йортына килеп чыгыгыз. Түгәрәккә язам үзегезне», — дип чат ябыша. Мәдәният йортында нинди генә түгәрәкләр ачып бетермәде инде. Шуларның иң кызыгы — пенсионерлар түгәрәге. Авылга килгән көннән үк (ә ул безнең авылда өч ел эшли) тотынды ул пенсионерларга. Башта берәм-берәм һәрберсенә йөреп чыкты. Кемнең нәрсәгә сәләте барлыгын тикшерде. Билгеле инде, әби-бабайлар җырларга атлыгып тормыйлар. Биергә билләре җибәрми. Тик Тургай абый аптырап калмый. Бәйләм бәйләүчеләр түгәрәге ачып җибәрә. «Кем тизрәк? Кем остарак?» Дөньяда кемнең генә үзен иң оста, иң җитез итеп күрсәтәсе килми икән? Шулай итеп, әбиләр осталыкта, җитезлектә ярыша башлыйлар. Тургай абый җиңеп чыгучыларга бүләкләр әзерли. «Авылның иң оста бәйләүчесе» дигән грамоталар яздыра. Бер уйласаң, андый кәгазьгә дөнья күргән, картаеп беткән карчыкларның тамчы да исе китмәс кебек. Әмма алай түгел икән шул. Әбекәйләр бүләккә бирелгән әйберләргә караганда әнә шул грамоталарга ныграк кызыгалар. Грамота эләккәннәре аны зурлап, кадерләп өйләренең иң күренә торган җирләренә кадаклатып куялар. Әмма эш бер ярышу белән генә тукталмый. Хәзер инде Тургай абый бәйләүчеләр түгәрәгенә яшьләрне дә чакыра башлый. Үзләре дә сизмәстән, әбекәйләр бәйләм осталыгына яшьләрне өйрәтергә тотыналар. Баксаң-күрсәң, бәйләм бәйләү, чигү чигү ул гади эш кенә түгел, ә бөек сәнгать икән. Әбекәйләр йөрәгендә бөек художниклар яшеренеп яткан икән. Менә бит Тургай абый ничек китереп чыгара.

Безнең авылның хәзер атаклы рәссамнары өстенә атаклы Шаляпины да бар. Анысы кем дисезме? Элекке мулла — Мөхәммәтҗан бабай. Мөхәммәтҗан бабай хәзер картлар хорының солисты. Ул үзенең калын, көчле тавышы белән җырлап җибәрсә, түшәмдәге люстралар зыңлый башлый. Дөрес булса, Тургай абый аның белән җомга намазында танышкан. Җомганы бездә бер ялгыз бабайлар өендә укыйлар иде. Тургай абый нишләп анда барып чыккандыр, анысын беркем дә әйтә алмый, әмма шунысы хак: Мөхәммәтҗан бабайның кычкырып дога укуын ишеткән дә шаккаткан.

— Бабай, — дигән ул үзен күргәч укуыннан туктап калган Мөхәммәтҗан картка, — тагын бер дога укы әле.

— Укырга була, ник укымаска. Әмма ләкин син миннән көләргә генә уйламыйсыңмы?

— Юк, юк, нинди көлү ди ул, бабай. Күпме яшәп минем мондый тавыш ишеткәнем юк иде.

— Минем тавышны ишетәсең килсә, җомгага йөр син, улым.

— Ә нигә, җомгага да йөрергә була, тик эш анда түгел. Монда сине күпме генә кеше ишетә? — Тургай абый җомгага җыелган кешеләрне саный. — Монда нибарысы алты кеше! Алты кеше өчен шушындый тавышны әрәм итү зур гөнаһ бит, бабай.

— Миңа нишләргә кушасың соң, улым?

— Клубка барырга, бабай, клубка!

— Җомга намазларын клубта укыргамы?

— Ә нигә намаз укырга? Җырларга!

— Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла! Көфер сүз сөйлисең бит. Карт башым белән авыз күтәреп җырлап йөрергә мин юләрмени? Аның гөнаһын кая куясың?

— Гөнаһ нәрсә соң ул, бабай?

— Нәрсә дип, ярамаган эш.

— Ә савап нәрсә?

Мөхәммәтҗан бабай сакалын учлап уйга калган һәм куелган сорауга:

— Савап ул, улым, Алла кушканны эшләү. Ягъни мәсәлән, бәндәләргә яхшылык эшләү, бәндәләрне шатландыру, — дип җавап биргән.

— Бәндәләр бит, Мөхәммәтҗан бабай, күбрәк клубка йөриләр, җомгага түгел. Син клубта савапны күбрәк җыя алыр идең.

Әнә шулай бәхәсләшә, үгетли торгач, Тургай абый тәки мулла бабайны клубка килергә күндергән. Башта аның үзен генә җырлатып магнитофонга язган. Ә магнитофон язмасын Казан радиосына җибәргән. Бервакыт Казан радиосы Мөхәммәтҗан бабайның тавышын бөтен Татарстанга ирештерде. Моны тыңлаганнан соң бар халыкның исе китте. Яшьләр аның тавышының моңлылыгына сокланды, картлар денсезлектә гаепләде. Шуннан соң җомгага да бармас булдылар. Анда йөрүче картларның кайберләре клубка килеп хорга язылды, кайберләре (кыюлыклары җитмәүчеләр) элекке догадашларының клубта сыздырып җырлап йөрүләренә көнләшеп, эчтән генә уфтандылар. Ә Мөхәммәтҗан бабайның даны көнләп түгел, сәгатьләп үсте. Картлар хорын төрле авылларга чакырдылар, хәтта телевизорга да төшереп киттеләр. Хәзер инде Мөхәммәтҗан бабай Тургай абыйны үзе эзли. Тургай абый нинди дә булса йомыш белән берәр җиргә китсә, боегып, ямансулап кала. Андый чакларда ул сакалын сыйпап, элекке гомеренең әрәмгә үтүеннән зарлана: «Вәт бит, агай-эне, без дә яшәгәнбез инде. Яшь чакларда минем тавыш мондый гына идеме соң? Их, үткән заяга гомеркәйләр!»

— Әле син яшьләрдән дә болайрак, — диләр аңа.

— Хәзер инде әртис булгач, искереп беткән Сәрбиҗиһаның белән яшәмәссеңдер, шәт, — дип тә шаяртталар.

— Сәрбиҗиһанны да клубка яздырам, — ди Мөхәммәтҗан бабай аларга, — клубка йөри башласа, нибуч, яшәрер. Ә инде алай да яшәрмәсә, күз күрер тагын.

Тургай абый безнең Рәйханә апаның да җырлаганын ишетеп алган. Күп көттерми безгә килеп тә җитте.

— Әй, Рәйханә туташ! — Мин пырхылдап җибәрдем. — Безгә нәкъ менә сезнеке кебек сопрано тавышлы җырчы кирәк иде. Күпме вакытлар эзләдем. Ә беркөн мәктәптә сезнең җырлаганыгызны тыңлагач, концертыгызның беткәнен көтеп бетерә алмадым. Концерт беткәч сезнең белән сөйләшермен дип торсам, сез каядыр юкка чыктыгыз.

Апа сүзсез генә Тургай абыйга карады. Мин уйлап куйдым: «Мөгаен, берәр тузга язмаган сәбәп табып котылырга тели».

— Тургай абый, нигә сез үз исемегезне Тургай дип йөртәсез? Сез бит Таһир исемле.

— Әйе, Таһир Гайсин мин. Ләкин Таһир Гайсин яңгырамый. Шагыйрь кеше өчен бигрәк тә. Элек-электән һәр язучының диярлек псевдонимы булган. Горькийны гына алыйк. Аның бит фамилиясе Пешков. Әгәр дә без аны Алексей Пешков дисәк, ул бөек Горькийдан гап-гади кешегә әйләнер иде.

— Ә сез ни өчен Тургай, борыч яки горчица түгел?

Апаның бу соравыннан соң Тургай абый бераз кызарып китте. Болай ул үзе матур егет. Тик менә артык озын чәчләренә бераз кайчы белән кереп чыгасы бар, ә бөдрә бакенбардлары өстеннән этинең кырыну машинасын йөртеп чыксаң зыян итмәс иде.

— Ни өчен Тургаймы, Рәйханә туташ? Шуның өчен, чөнки мин кырлар җырчысы. Псевдонимны һәркем үзенең иҗат принципларыннан чыгып сайлый.

Әйе, Тургай абый һәр шигырендә кырларны, басуларны мактый. Аныңча, пары чыгып яткан җирләр яңа пешкән ипи төсле, соргылт болытлар өлгергән бодай басуын хәтерләтә, күлләр — болыннарның күзе, таулар — җирнең колагы. Тургай абый шул килүдән соң безгә шактый килми торды, Рәйханә апа аңа төпле генә җавап бирмәгән иде. Шуңамы эче пошып йөри башлады. Минем уйлавымча, Тургай абыйны ошатты ул. Мин аның турында сүз башласам, ятьрәк икенче якка борырга тырыша. Аның гадәте шулай, үзе теләгән нәрсәдән качарга карый. Хәтта ул үзенең иң яраткан күлмәген дә оялып кына кия.

Шулай да Тургай абый апаны онытмаган икән. Яңадан безгә килеп, апаны өстерәп диярлек репетициягә алып китте. Шуннан бирле Рәйханә апа мәктәптән кайтып әз-мәз дәресләрен әзерләдеме, клубка чаба. Ялгыз боегып утырырга вакыт калмады. Аның клубта җырлавы минем өчен дә ярап куйды. Хәзер мин рәхәтләнеп театрларга, концертларга йөрим.

Безнең авыл — ул яктан бик бәхетле авыл. Районнан әйбәт асфальт юл килә. Башкортстанга якын гына. Шуңа күрә безгә әле Уфадан, әле Әлмәттән, әле Минзәләдән театрлар килеп кенә тора. Билгеле, безгә — балаларга — аерым спектакль куеп маташмыйлар, керә алган кеше кич белән зурларга ияреп керә, керә алмаганы ишек төбе саклап кала. Ә менә мин хәзер Тургай абыйның кабинетында спектакльләр башланганчы ук оялап алам да, спектакль башланып, залдагы утларны сүндергәч, кешеләр арасына чыгып кысылам. Спектакльләрне бик яратам мин. Бигрәк тә мәхәббәт турындагыларын. Беренчедән, андыйларга безнең ише ыбыр-чыбырны кертмиләр — ә тыелган нәрсә, үзегез беләсез, иң яхшы була, икенчедән, мәхәббәт турындагы пьесалар кызыклырак. Бастырыктай егетләрнең кызлар алдында сүз әйтә алмыйча, кара такта янына чыгып баскан начар укучыдай ык-мык килеп торулары шундый көлке. Мин соң дөньяда шундый мәмкә булып йөримме? Яратам икән, шартлатып әйтеп салам. Берне генә түгел, ун кызны яратсам да. Ату көтәсең, көтәсең, кайчан әйтер икән инде бу дип. Ә ул баш әйләндереп йөри дә йөри. Шулай да карап утыруы кызык. Олыларның юләрлеге безнең өчен иң кызык нәрсә бит. Алар үзләре шуны беләләр микән? Юктыр, мөгаен. Өлкәннәр һәрвакыт үзләрен акыллыга саныйлар. Безгә акыл өйрәтәләр. Безнең нинди эш сайларга тиешлегебезне дә билгеләп куялар.

Ярый әле безнең өйдә өлкән бала булып апа туган. Таякның юан башы аңа төшә. Миңа хәзергә кагылмыйлар. Ә Рәйханә апа чынлап та этиләрнең башын аз әйләндермәде. Сигезенче классны бетергәч, ул көннәрнең берендә юкка чыкты. Әй эзләделәр дә соң инде этиләр. Милициягә кадәр барып җиттеләр. Ә ул юк та юк. Мин дә үземчә эзләргә керештем. Апаның ялгыз йөрергә яратуын яхшы белгәнгә, эзләүне мин су буйларыннан, тал араларыннан башладым. Шуннан тотынуга бер сәбәп бар: чөнки мин үзем дә, бервакыт әни мине хаксызга әрләгәч, аръяктагы куе таллык эчендә землянка казып, бөтенләй качып яшәргә уйлаган идем. Хәтта, тормыш башлап җибәрергә дип, тавык оясындагы бер көнлек күкәйне кепкама тутырып алып төшеп комга да күмеп куярга өлгердем. Землянка казыр өчен көрәкнең дә иң үткенен сайладым. Чыгып китәргә бөтен нәрсә әзер булгач кына, әни миңа шундый матур итеп, улым, диде дә, ачуларым таралды да бетте.

Рәйханә апаны мин әнә шул землянка казырга уйлап куйган тирәләрдән эзләдем. Әллә суга батканмы дип әчкә шом да йөгергәләде. Беркөнне мин өйдән түгәрәк зур ипи алып төшеп суга салып карадым. Суга баткан кеше булса, ипи шул урынга килеп җиткәч бөтерелеп торырга тиеш. Безнең авылда мин бәләкәйрәк чакта, бер кыз суга баткач, шулай эзләгәннәр иде бабайлар. Ләкин минем ипи тиз арада көчле агымга эләгеп күзгә күренмәс булды. Дөресен әйткәндә, мин аны, читтәге кире агымга эләгеп бөтерелеп йөрмәсен дип, ераккарак ташлаган идем.

Апаны табуга өметне өзгәч, аннан хат килеп төште. Ул Казанга киткән икән. Ул югаласы көнне Казаннан безнең авылга төрле кием модалары күрсәтергә алып килгәннәр иде. Хатында ул манекенщица булып эшләвен язган. Сездән рөхсәт сорасам, барыбер җибәрмәс идегез, дигән.

Әй эти тузынды да инде шул көнне. Башта ул апаның хәбәре юк чакта пошынып йөргән иде, ә инде аның үз теләге белән «дуңгызлык» эшләгәнен белгәч, ничек кенә сүкмәде. Әгәр апага буе җитсә, педагогика дигән «әбидән» куркып тормыйча, бик әйбәтләп сыртын каешлый иде. Апага тиясе чыбыкның бер башы ул көнне әнигә төште.

— Син либеральлек күрсәтеп шулай боздың аны, — дип башлады эти. — Әллә кайчан тотып эшкә җигәргә кирәк иде. Сөрхәнтәй! Кайтып күземә генә күренсен, мин аны арбага бәйләп фермага илтәм. Саусын әнә сыер.

— Кайтуын кайтса, мин аны үз яныма больницага эшкә кертәм.

Эти белән әни тагын үз һөнәрләренең яхшылыклары турында бәхәсләшергә тотындылар. Рәйханә апа онытылды. Соңыннан алар шактый ачуланышып туктадылар. Минем әле бервакытта да аларның болай ук кызышканнарын күргәнем юк иде. Икесе дә жәл булып китте. Икесенә дә иң матур сүзләр әйтеп юатасы килде. Ләкин нәрсә әйтергә? Әһә, таптым: «Сез бер дә кайгырмагыз! Менә күрегез дә торыгыз, озакламас, Рәйханә апа кайтып төшәр».

— Билгеле, кайтыр, — диде эти, — чөнки ул әле үзенә ни кирәген белми.

Этигә тынычландыргыч тәэсир ясый алуыма шатланып, мин болай дип өстәдем:

— Безнең апа ул эшләр өчен яралмаган. Җырлар өчен...

— Нәрсә?

— Рәйханә апа җырлар өчен генә яралган, дим.

— Кем әйтте сиңа алай дип?

— Ни... Тургай абый безнең апаның тавышын сопрано ди.

— Тургай абыеңа бар кеше дә җырлар өчен яралган аңа. — Эти нәрсәнедер исенә төшереп елмаеп куйды. Аннары, нәрсә булса, шул булыр дигәндәй, кул селтәп чыгып китте.

Әнинең кәефе күтәрелмәде. Безнең әни күп сөйләшми, кайгыны авыр кичерә. Борчуы булганда аның маңгаендагы сыры тирәнәя. Әле бит аңа кырык та юк, чәчләренең инде яртысы ак. Әни белән чагыштырганда безнең әти егетләр кебек. Чәчләре сумаладай кара, тарак тешен сындырырлык куе. Югыйсә икесе бер яшьтәге кешеләр. Бервакыт мин этидән: «Нишләп әнинең чәчләре ак, ә синеке кара?» — дип сорадым. «Әниең күп укыган, шуңар», — диде эти. Укуын эти үзе дә әз укымаган. Тракторчы булып эшләгәндә бигрәк күп укый иде. Хәзер инде аның кызыклы китапларга тотынырга вакыты юк. Әз генә бушаса, контроль эшләренә ябыша. Бер контроль эшен өч тапкыр кире кайтардылар. Ә аларны эшләми торып имтиханнар тапшырырга чакырмыйлар икән.

Беренче курсны әйбәт кенә бетереп кайткач эти шундый сөенде. Аңа кадәр әни дә аның укуына болай гына йөри торган нәрсә итеп карый иде. Шуннан соң этигә ышанычы артты. Ә беркөнне ул этигә:

— Кара әле, Сәләхи, — диде, — син бу тырышлыкларың белән элегрәк укыган булсаң, әллә кем булыр идең инде.

— Тырышлык, — диде эти, җанланып, — тырышлык ул кешегә каян килә икән? Мин, тракторчы булып эшләгәндә, институтка кереп укып йөрермен дип башыма да китерми идем. Тракторчы өчен ун класс белем дә җиткәндер, күрәсең. Ә председатель эше бөтенләй башка икән. Монда инде тырышып та таманга килә.

— Бәлки, син укымасаң эшемнән бик тиз чыгарып атарлар дип куркасыңдыр.

— Мөмкин. Соңгы вакытларда мин үзем дә бу хакта уйлангалыйм. Син менә курку дисең, Саҗидә. Ә бу бит әйбәт курку. Эшемнән алуларыннан куркам икән, димәк, мин бу эшне яратам! Тырыша башлавымның сәбәбе дә, бәлки, әнә шуннан киләдер. Кеше кайчакта үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен белми яши. Әгәр сәләтен ачарга мөмкинчелек туса, таулар актарып ташлый.

— Син председатель булгач та колхозда әллә ни үзгәреш сизелми әле.

— Тукта, син миңа вакыт бир, Саҗидә. Ике ел эчендә үзгәрергә колхоз ул тәкә башы түгел. Тәкәгә генә ике елда мөгез чыга.

— Эшләгән эшеңнең нәтиҗәсе күренми. Үзеңне кызганып әйтүем. Комга су сибеп кенә йөрмисезме дим.

— Су! — Эти уйланып ишекле-түрле йөри башлады. Ул әнигә җавап бирүдән бигрәк үз-үзенә сөйләнә иде: — Су — безнең җиребез кебек үк төп байлыгыбыз. Моңа кадәр әле без аңа игътибар бирмичәрәк яшәдек. Басуларыбыз, болыннарыбыз янәшәдә генә аккан Ык елгасының шаулавын гына ишетеп утырдылар. Сулар никадәр генә шаулап акмасын, үзеннән-үзе сусауны басмый. Иң беренче безгә басуларның сусавын басарга кирәк. Ә нәтиҗәгә килгәндә, анысы күренер. Җир ул бервакытта да кешегә әҗәтле булып калмый.

Мавыгып китеп эти шактый яңалыклар сөйләп ташлады. Безнең күзгә күренмәсә дә, колхозда байтак эшләр башкарылган икән. Элек бездә көтүлекләрне генә сугаралар иде, анда да биш-алты гектар җирне бүлеп алып кына. Ә хәзер басу-кырлардагы игеннәрне сугару өчен әзерлек башланган. Ләкин моның өчен әле күп нәрсә эшлисе бар икән. Эти әйтә: «Иң җанга тигән нәрсә — торба юклык», — ди.

Минем уйлавымча, эти юкка кайгыра. Безнең якларда торба адым саен. Чын менә, арттырып әйтүем түгел. Буровойлар, скважиналар тирәсендә безнең гомергә җитәрлек тимер-томыр бар. Ә бездәге буровойлар исәпсез-хисапсыз. Кешеләр абзарларына өрлек кирәксә дә, телевизорларына антенна кирәксә дә торба куялар. Кем каян һәм ничек табадыр, анысын белмим. Безнең үзебезнең антеннабыз да унбиш метрлы торба. Этигә мин шул турыда әйттем. Башта ул минем сүзләргә әһәмият бирмәгән иде, соңыннан күзләре ялтырап китте.

— Тукта, тукта! Син антенна дисеңме? Ә бит безнең авылда гына дүрт йөз хуҗалык. Шуларның кимендә өч йөзендә телевизор бар. Һәр антеннаны ун метр дип исәпләсәк, өч мең метр торба була дигән сүз.

— Кешеләр телевизорларын ничек карарлар? — дидем мин.

— Анысы зур проблема түгел. Антеннага агач киртә дә ярый. Казан ягындагы авылларда агач антенна белән карыйлар әле. Заманында Петр патша чиркәү кыңгырауларыннан пушка да койдырган... Халык каршы төшмәс дип уйлыйм. Халыкка башны иеп барырга туры килә. Кирәкнең ояты юк. Тик бу бер төкрек кенә шул...

— Ил төкерсә, күл була, — дидем мин. Эти елмаеп куйды.

— Син күпне белә башладың әле, Фәйрүз. Үстегез, үстегез... — Эти нидер уйлап көрсенеп куйды. Шундый яхшы тәкъдимем өчен миңа премия тиешледер дип әйтергә җыенган идем, бер юлга калдырып тордым. Эшләре барып чыкса, кәефе шәп чагын туры китереп бик җилле велосипед сорармын әле. Юкса иске велосипедым адәм көлкесенә калып бетте. Тәгәрмәчләре уйнаклый, руле кәкрәйгән, камерасы кырык ямаулы.

Әтиләр эшләренә мавыгып Рәйханә апаны онытып җибәрделәр, аның исемен телгә алмый башладылар. Тургай абый гына, мине күргән саен: «Апаң кайтмадымы?» — дип сораша. Мин: «Юк», — дисәм, шундый авыр итеп көрсенеп куя, аны кызганудан минем күзләремнән яшь чыга. Ә беркөнне ул мине үз янына чакырып алды да болай диде:

— Мин Казанга барам. Апаңны күрсәм нәрсә әйтим.

— Сүз әйтеп торма, чәченнән өстерә дә алып кайт.

Тургай абый Казанга еш бара. Ул мәдәният институтында режиссерлыкка укып йөри. Ничәнче курстадыр, анысын ул кешеләргә әйтми. Казанда Академия театрында яңа спектакль куеласын ишетсә дә, кая басканын белми йөри башлый. Барырга җай чыгып, яңа спектакльнең премьерасын карап кайтса, куанычы эченә сыймый. Һәр очраган кешегә диярлек режиссерның оста алымнары турында сөйли.

Кайвакыт мин аңардан:

— Ул театр нәрсә турында иде? — дип сорыйм.

— Театр түгел, спектакль, — дип төзәтә ул. Ләкин шуннан артык сүз әйтә алмый. Гомумән, ул эчтәлек белән кызыксынмый кебек. Аны гашыйк иткән нәрсә — артистларның осталыгы, режиссерның табышы. (Режиссер нәрсә табадыр, анысын мин белмим инде.)

Бу юлы да Тургай абый Казанга театрга бара иде. Кем белә, бәлки, Рәйханә апа өчен дә пошынадыр. Ул бит клубка йөри торган бер генә кешесе кимесә дә чын-чынлап кайгыга төшә. Рәйханә апаны җырлау осталыгына, тавыш мөмкинлекләреннән файдаланырга өйрәтер өчен күпме тырышты ул. Хәзер менә агитбригадалар төзеп, концертлар куеп йөриләр. Тургай абый концертларга мине дә катнаштыра башлады. Искитәрлек эш башкармасам да, ул мине үтереп мактый. «Гармунда син шәп уйныйсың, — ди. — Синнән иң кимендә Марс Макаров чыгар», — ди. Аның арттырып әйткәнен беләм, ләкин мактагач барыбер рәхәт. Шундый кеше инде мин: сүксәләр, белгән эшемне дә эшлисем килми, мактасалар, белмәгәнен дә эшләрдәй тоелам. Гармунны мин кайчан уйный башлаганымны хәтерләмим. Безнең өйдә гармун элек-электән бар иде. Әни гармунда матур гына уйный, ләкин кулына сирәк тота. Әти рәтләп уйный белми, тик еш кына шыңгырдаткалап утыра. Бәләкәй чакта мин бик елак булганмын. Бер акырырга тотынсам, һич туктата алмаганнар. Әни гармун уйнаса гына акыруымнан туктый торган булганмын.

Чынлап та, гармунны яратам мин. Бигрәк тә тальян тавышын. Минем гармуным җырларда җырлана торган кыңгыраулы саратский түгел түгелен, шулай да шәп — ярым аккордеон. Шуның белән олы гына кызларны җырлатып-биетеп йөргән булам. Бездә агитбригадалар концертны бик шәп куялар. Беркөнне Тургай абый җәйләүгә алып барса, икенче көнне печәнчеләр янына алып китә. Бигрәк тә сыер савучы кызлар мондый концертны көтеп алалар. Алар җырны-биюне карап кына утырмыйлар, үзләре дә катнашалар. Гармунны күтәреп машинадан килеп төшүгә: «Давай, берәр танцы көе уйна әле!» — дип тәкатькә төшәләр. Радиодан яңа җыр ишетсәләр, Тургай абыйны аптыратып бетерәләр: «Сүзләре ничегрәк? Көенең менә бу җирен ота алмадым, шыңшып күрсәт әле». Тургай абый Казанга киткәч, кайчан кайта, дип аптыратып бетерделәр.

Апа качып киткәннән соң, мин өйдә тулы хуҗага әверелеп барам. Мал-туар карау, кош-кортларны ашату, ишегалларын себерү — һәммәсе минем өстә. Шуңа күрә бөтен кешегә караганда аның кайтуын күбрәк телим. Әти, Казанга барсам, җилтерәтеп алып кайтам дип йөри йөрүен, тик мин эш аңа барып җитмәс дип уйлыйм. Тургай абыйның сагышлы күзләрен күрсә түзмәс, ияреп кайтыр. Апа үзе дә ямансулап йөри башлагандыр инде. Ул бит авылны, су буйларын ярата. Ялгыз калып моңаерга ярата. Ә шәһәрдә анда ничек ялгыз каласың? Әнә бит, телевизордан күрсәтәләр: урам тулы мыжлап торган халык.

Сизенүем дөрескә чыкты: апа Тургай абый белән кайтты. Дөрес, аның белән бер үк көнне түгел. Икенче көнне. Аның белән үк кайтсам кеше сүзен тыңлау була дигәндер инде. Ул шулай, кеше белән килешкәндә дә бераз соңлабрак, ялындырыбрак эшләргә ярата. Ләкин мин белеп торам, Тургай абыйсыз гына эшләнмәгән бу.

Ярый, ничек булса да бер ноль безнең файдага.

Бусаганы атлап керү белән әти үзен тотып ярыр инде дип бераз шөлләп торган идем, ни гаҗәптер, әти рәтләп ачуланмады да.

— Юка җилкә, — дип мыгырданды да шуның белән бетте.

Ә әни ярыйсы кыздырды. Карап-карап торам да мин әниләргә, шаккатып куям: мин көткәннең гел киресен эшлиләр. Кем уйлаган инде әни шулай кызып китә алыр дип.

— Җитте! — диде әни соңыннан. — Әгәр эшлисең килә икән, бүгеннән минем янга эшкә кер. Эшләп укырсың. Безгә санитаркалар кирәк.

— Больницага аяк та басмыйм, — диде апа. — Әле сиңа ияреп кайткан дару исләренә дә күңелем болгана.

— Ә-ә, шулаймы? Больница ошамаса, әнә дуңгыз фермасына барырсың. Әтиең куш куллап алырга тора. Аннан хуш ис кенә ияреп кайтыр үзеңә.

Апаның беркайда да эшләргә нияте юк иде, ахры. Озак карышты. Тугызынчыга укырга да бармыйм дип кырт кисте. Әти: «Хәзерге заманда унны бетермәгән кешене мин фермага да алмыйм», — дигән иде: «Алмасаң, фермаңа атлыгып тормыйм әле», — дип кенә куйды.

Беразга апаны үз иркенә куйдылар. «Кем белә, бәлки, юри генә карышып маташадыр. Укулар башлангач әзерләнер дә китәр».

Мәктәптә яңадан тормыш башлануын белдереп кыңгырау чылтырады. Мин укырга йөри башладым. Җәй көне озак ял иткәннән соң мәктәпкә бару һәрвакыт күңелле. Ел саен күпмегәдер үсеп киләсең. Җәй буе күрми торган дусларыңа үз эшләреңне сөйләп мактанышасың. Безнең авылда урта мәктәп булганлыктан, башка авылдан килеп укучылар да күп. Менә аларга инде теләсә ничаклы шыттыр. «Марс Макаров белән концерт куеп йөрдек», — дисәң дә ышанырлар.

Укуның иң күңелле атнасы үтеп китте, апа мәктәпкә бармады. Директор Гыйлемханов абый безнең өйгә үзе килде. Әти белән алар бик озак сөйләштеләр. Әти Рәйханә апаны ничек тә мәктәпкә җибәрергә сүз биреп калды.

Директор киткәннән соң, әти Рәйханә апаны чакырып кертте дә, каршысына утыртып, сүз башлады:

— Әйдә, кызым, әйбәтләп кенә сөйләшик, аңлашыйк әле. Нигә син укырга бармыйсың?

— Укыйсым килми.

— Ни өчен?

— Ә мин каян белим? Просто укыйсым килми.

— Просто гына берни дә эшләнми. Һәрнәрсәнең сәбәбе булырга тиеш. Яшермә, әйт, без дә консерваторлар түгел.

Апа җавап урынына җилкәсен генә сикертеп куйды.

— Син беләсеңме соң, хәзер ун классны бетерү мәҗбүри икәнлеген? — дип дәвам итте әти.

— Унны бетермәгәнгә судка бирмәсләр әле. Элек җиде класс мәҗбүри булган, аңа карап бар кеше дә җидене бетермәгән.

— Ул вакыттагы шартлар белән хәзергене чагыштырма син. Сугыштан соңгы чорда халык җилкәсенә авырлык аз төшмәде. Шулай да ул чор кешеләре укымаган дип әйтә алмассың. Илнең төп йөген хәзер нәкъ менә шул буын кешеләре күтәреп баралар. Заманнан артта калмас өчен, олыгайгач укып йөриләр.

— Кирәк булгач, мин дә укырмын.

— Бу килеш калсаң, син үзеңә ни кирәген дә аңламассың.

— Әллә мин аңгырамы? Һаман миңа акыл өйрәтәсез. Нишләтсәгез дә мәктәбегезгә аяк басмаячакмын. Күсәк хәтле буем белән... — Апа башлаган сүзен кинәт өздә дә еларга тотынды. Әти аны әллә кызганды, әллә кызуы сүрелә төшсен диде, тиргәмәде һәм сораулар да бирмәде. Апаның үксүе басылгач, үз-үзенә сөйләнгәндәй болай диде:

— Әйе, әйе, син мәктәпкә яшьтәшләреңнән бер елга соңарып кердең шул. Аягың сынып ярты ел гипста яттың. (Кызык, мин боларын белми идем әле. Апаның аяклары бүкән күк, шундый юан аяк та сынар икән.) Үсүен дә тизрәк үсеп киттең. Ләкин, кызым, бу бит җитди сәбәп түгел. Хәзер бөтен бала да таза. Һәммәсе укуын ташлый башласа...

— Бүтәннәрдә минем эшем юк.

— Ну ярар, укыйсың килми икән, көчләмибез. Давай, тот та бүгеннән эшкә чык.

— Кая?

— Менә тагын! Колхозга!

— Колхозда мин эшләрлек эш юк анда. Сыерларыңны күрәсем дә килми. Тракторга кеше йөрткәндә дә утырырга куркам. Амбар каравылчысы итеп үзең куймассың. Тагын нинди эшең бар колхозыңда!

— Бусы инде капризлану. — Әти кыза башлады. — Укыйсы килми, эшләргә теләми. Бәлки, сиңа кияү кирәктер?!

Апа үпкәләп өйдән чыгып китте. Әти үз-үзенә урын таба алмыйча озак йөренде:

— Һә, менә табышмак! Колхозда аңа ярарлык эш юк, имеш. Колхозда эшләгән кешеләрне әллә ул бүтән эш тапмаганга гына йөриләр дип беләме? Каян килгән аңа мондый караш? Юк, юк! Моны болай калдырырга ярамый. Кемнәр үстергән икмәкне ашап шулай ташыганын белсен!

Әти апага карата нинди чара күрергә уйлагандыр, билгесез. Ләкин аны үз эшләре басып китте. Авылда бит анда беркайчан да эш бетеп тормый. Урып-җыюны, язгы чәчүне әйтмим дә. Аннан башка эшләр дә йөзләгән. Әле менә урамның һәр ике ягыннан траншеялар казып яталар. Су кертәчәкләр. Борынгы заманнан калган сиртмәле коелар, су ала башласаң, шыгыр-шыгыр килеп елап утыралар. Искергән кое бураларында гөмбәләр үсә. Һәр кешенең капка төбендә су колонкалары кайнаган самавырдай ташып торса,

яшелчәләргә сибәргә дә шәп булачак. Безнең авылда яшелчә белән бик мавыкмыйлар, ләкин бу су юклыктан гына. Кешеләрнең өй каршысында кыяры-помидоры, шалканы-кишере үсеп утырса, эчне тишмәс иде. Әти әйтә, без әле яшелчәчелеккә дә тотыначакбыз, ди. Кайчандыр безнең колхоз яшелчә бакчалары белән дан тоткан. Кыяр-помидор гына үстереп калмаганнар, кавыннар, карбызлар да чәчкәннәр икән. Кавын-карбызның безнең якларда үсә торган әйбәт сортлары уйлап табылган булган. Хәзер шуларның һәммәсе онытылган. Андый кавын орлыклары сакланса да, аерым кешеләрдә генә сакланган, ди.

Әтинең эшләре әйбәт бара, тик әнә шул торба кытлыгы күп вакыт кулларын тота. Ул торбалар өчен әти кая гына бармады инде. Күпме тапса да җитми. Безнең әтине әгәр берәр торба заводының директоры итеп куйсаң, бөтенесен үзебезнең авылга җибәреп ятар иде. Тимер-томырга бигрәк тыныч карый алмый. «Тимер ул — техника, — ди. — Техникасыз ипи дә, бәрәңге дә, ит тә юк», — ди. Әле дә әти шул тимер-томырлары артыннан Әлмәт якларына чыгып китте.

Әйткәнемчә, әни өйдә сирәк була. Шуңа күрә Рәйханә апа бераз вакытка тынычлыкта калды. Ләкин ул барыбер шат түгел иде. Көннәр буе беркая чыкмыйча өйдә утыра. Клубына да йөрми. Беркөн Тургай абый килеп чакырган иде, дорфа гына:

— Бармыйм, — диде.

— Ни өчен? — диде Тургай абый.

— Попугай сыман көн саен бер үк нәрсәне тот та җырла, тот та җырла. Су язганнан май чыкмый.

— Рәйханә туташ! — диде Тургай абый. — Бу сезме соң? Сәнгать турында шулай дип әйтергә ничек телегез бара?

— Мин сәнгать турында әйтмим, үзем турында әйтәм.

— Сезнең җырыгыз менә шул сәнгать инде ул. Әгәр сез үзегездә булган байлыкны кешедән яшерәсез икән — бу җинаять. Ә җинаятьчеләрне судка бирәләр.

— Алайса, судка бирегез.

— Бирербез дә. — Тургай абый кызарып чыкты. Мин әле аның андый чагын күргәнем юк иде. Хәтта битләрендә тимгел-тимгел таплар барлыкка килде. — Сез, Рәйханә туташ, икмәген җиргә күмеп, кешеләргә дә бирмичә, үзе дә ашамыйча ачтан интегүче саран бай төсле. Хәтта аңардан да яманрак. Чөнки рухи байлык дөньяда берни белән дә чагыштыргысыз нәрсә. Әгәр мин сездә талант чаткысы күрмәсәм, сөйләшеп тә тормас идем.

— Миндә бернинди дә талант юк.

— Анысын инде без күбрәк беләбез. — Тургай абый бераз йомшады. — Менә шул, Рәйханә туташ, бүгеннән репетицияләргә йөри башлыйсыз. Бер үк җырны көн саен җырларга сездән беркем дә таләп итми. Яңаларны өйрәнербез. Безнең гомергә генә яңа җырлар җитәрлек.

— Җырның яңасы да, искесе дә шул инде аның.

— Оһо, Рәйханә туташ, болай булгач сезнең белән сөйләшеп маташуы файдасыз икән. Җырга карата шундый әшәке фикер әйтә алырсыз дип уйламаган идем. Хушыгыз!

Тургай абый үпкәләп китеп барды. Үзенә ул ни әйтсәң дә күтәрә, ләкин үзе башкарган эшкә һичвакыт кер төшертми. Теше-тырнагы белән яклый.

— Нигә инде Тургай абыйга шулай әйттең? — дидем мин апага. — Җырны бит син үзең дә яратасың.

— Мин үземне-үзем дә яратмыйм.

— Тургай абыйның гаебе юк, ул әйбәт кеше.

— Әйбәт булгач, начар кешеләргә ялынып йөрмәсен.

— Ә син клубка барыбер барачаксың. Син бит кешеләрнең ачуын китерер өчен генә шулай киреләнәсең.

— Син дә саруымны кайнатма әле. Каян килгән психолог. Әллә миңа бик рәхәт дип беләсеңме?

— Соң, апа, укуы беркемгә дә рәхәт түгел инде. Тот та мәктәпкә йөри башла. Йөрүен йөрсәң, кучерми калдырмыйлар. Тугызынчыда имтиханнар юк.

Билгеле, апа минем сүзләргә карап мәктәпкә йөгермәде. Шаккатам мин аңа: нинди кеше ул, үзенә нәрсә кирәген белми. Мин үземә нәрсә кирәген һәрвакыт белеп торам. Әгәр китапны укып-укып та башка кермәсә, уйнарга чыгасы килә дигән сүз. Китапны шартлатып ябам да урамга чыгып чабам. Уенга озаграк мавыгып, ашауның вакытын уздырып җибәрәм икән, эчем чурылдарга тотына. Тагын нишләргә кирәге ап-ачык: тиз генә кайтасың да баздан каймаклы катык алып менеп бер-ике телем ипи белән сугасың. Ә инде түбәңне кояш кыздыра башласа, уйлап та тормыйсың, суга чумасың. Шундый гап-гади бит. Аптырап йөрерлек түгел.

Апаның аптырап йөрүе генә җитмәгән иде, соңгы вакытларда ул өйдән чыгып китеп югалгалый башлады. Бу хәл әни белән әтине бөтенләй хафага салды. «Әллә берәр начар юлда йөри микән ул» дип аптыраштылар. Әти әнигә:

— Син хатын-кыз, ана кеше, ныклап сөйләш әле үзе белән, — диде. — Бәлки, сиңа ачылыр. Ни әйтсәң дә, җитеп килгән кыз ич инде ул.

— Мин сөйләшмәдем түгел инде аның белән, — диде әни. — Нәрсә уйларга да белгән юк. Мин аны үз яныма эшкә кертермен дигән идем. Берәр ел санитарка булып эшләсә, бәлки, больницаны ярата башлар иде. Аннары шәфкать туташы булырга укырга җибәрер идек. Шундый мөмкинлекләр бар бит. Бүгеннән медучилищега китәм дисә, баш врач направление бирергә тора. Их, белмиләр шул кадерне.

Әниләрне шулай кайгыга салганы өчен апага берәр җәза бирергә кирәк иде. «Нишләтергә? Йоклап ятканда бөтен киемнәрен яшереп куеп, шәрә калдырыргамы? Менә кызык булыр иде, эчке күлмәктән чыгып китеп карасын!» Апаның шундый кыяфәттә урамда йөрүен күз алдыма китереп, үземнән-үзем пырхылдап көлеп җибәрдем. «Юк, бу җәза барып чыкмый. Бер киреләнсә, юрган ябынып та сызар. Ә бәлки, иптәш малайларга әйтеп тукматыргадыр? Тик караңгыда, сизмәгәндәрәк эләктермәсәң, үзеңнең кабыргаңны санарга да күп сорамас. Аңарда Жботинский көче бар».

Җәзаның әллә ниндиләрен башымнан кичердем. Ләкин апаны акылга утыртырлык нәрсә уйлап таба алмадым. Мин генә түгел, әни дә нинди чара күрүен уйлап йөргән икән. Беркөн кич апага:

— Иртәгә үзем белән алып китәм! — дип кистереп әйтте. — Больницада эшләргә теләмәсәң, мин сиңа башка эш таптым.

— Нинди эш? — диде апа.

— Тегү мастерскоена өйрәнчек булып керерсең. Директорлары белән сөйләштем.

— Миңа эш эзләмәгез, дип ничә тапкыр әйттем мин сезгә. Көн саен тукыйсыз: фәлән җиргә кер дә төгән җиргә кер. Ә мин, бәлки, инде кергәнмендер.

— Ничек? Кайчан? Кая?

Әни берьюлы әллә ничә сорау биреп ташлады. Ул апага ышанмый иде бугай.

— Умартачылар курсына кердем, — диде апа. Ул моны шундый тыныч кыяфәттә әйтте, әйтерсең сүз суга барып кайту хакында бара иде.

— Кайда ул андый курс?

— Районда. Мин өч көн укыдым инде.

Әни бик авыр эш эшләп арыган төсле хәлсезләнеп диванга утырды.

— И бала, бала! Аны соң кешегә әйтеп эшләсәң ярамыймыни? Без әтиең белән, кайда йөри икән бу бала, дип ут йотабыз, кайгырабыз. Ә син, качып-посып, әнә кая барып кергәнсең.

— Сезгә әйтсәң, акыл өйрәтергә тотынасыз, анда кермә, монда кер, имеш.

— Син үзеңне бөтен кешедән дә акыллырак итеп саный башладыңмыни инде?

— Санамасам да, үзем теләгән җиргә керергә хакым бардыр дип уйлыйм.

— Теләгең барын әйтсәң, без дә аңлаган булыр идек.

— Минем моңарчы теләгем юк иде.

Аның әниләр белән киңәшләшмичә укырга керүе, ошамаса ташларга туры килер дип куркудан булган икән. Кешеләрдән яшереп ничек укырга уйлагандыр, анысын ул үзе дә башына китермәгән.

Моны белгәннән соң әниләрнең өстеннән зур тау төште, җиңел сулап җибәрделәр. Апага күбрәк ирек бирергә тырыштылар. Ләкин әле юк-юк та: «Бу тагын нәрсә күрсәтер икән?» — дип, сынаулы караш белән апаны күзәткәлиләр иде. Дөресен әйткәндә, апага мин дә ышанмадым. Ничек инде Рәйханә апа умартачы була алсын? Хатын-кыз умартачы турында минем ишеткәнем дә юк. Безнең авылда мин белә-белгәннән бирле Мәгъфурҗан абзый эшли.

Мәгъфурҗан абзый йомык ялгыз карт. Карчыгы үлгән. Ике малае шәһәрдә яши. Кайвакыт җәй көннәрендә үзләренең «Жигули»ларына төялешеп кайтып киткәлиләр. Шунысы кызык: һәрвакыт ике малае берьюлы кайта. Мәгъфурҗан абзыйларның яшел үлән баскан ишегалларында берсе ак, берсе кызыл «Жигули» бер-берләренә борыннарын төртеп төн куналар. Андый чакларда Мәгъфурҗан абзый капкаларын киереп ачып, җил япмасын өчен зур ташлар белән терәтеп куя. Без малайлар машина тирәсендә кайнашабыз. Мәгъфурҗан абзыйның кырыс йөзендә ниндидер горурлык, канәгатьләнү билгеләре күренә. Бүтән вакытларда кыяр бакчалары тирәсендә чуалгалый башласаң, иң нык чага торган карт кычытканнарны себерке итеп җыеп, безнең шәрә балтырларга чәпелдәтергә әзер торган Мәгъфурҗан абзый мондый көннәрдә бакчасыннан эре-эре кыярларны үз куллары белән өзеп кенә ыргыта: «Ашагыз! Җитмәсә тагын бирермен». Безнең кыяр корсагыбыз тиз генә тулмый, Мәгъфурҗан абзыйның юмартлыгыннан күбрәк файдаланып калырга тырышабыз. Малайлары артык ашыкмаганда, Мәгъфурҗан абзыйны машинага утыртып урманнарга алып чыгалар, умарталыгына алып барып кайталар. Мәгъфурҗан абзый барганда ак «Жигули»га утырса, кайтканда, һичшиксез, кызылына күчә. Ул утырган машина алдан йөрергә тиеш. Уллары кайткач яңа костюм киеп, түшенә ике медален да тагып җибәрә. Менә мондый чакларда ул тагын да юмартлана: коштабагы белән безгә кәрәзле бал да чыгарып утырткалый.

Малайлары этиләре янында озак тормыйлар, төялешеп китеп баралар. Мәгъфурҗан абзый тагын кырыслана. Җәй көннәрендә ул рәтләп өенә кайтмый, умарталыкта ята. Кыш көне кешеләргә итек баса. Итек басучылар безнең авылда аннан башка да бар, ләкин берсе дә аның кебек итеп баса алмый. Мәгъфурҗан абзый баскан итекләрнең кунычы да сынмый, тузып тишелгәнче матурлыгы да югалмый. Бүтән кешеләргә караганда хакны икеләтә артык алса да, аңа һәрвакыт чират була. Балта эшләренә дә оста кеше ул, ләкин аның белән бик шөгыльләнми. Умартачылыкта кайчан эшли башлагандыр, миңа калса, ул гомере буе шунда маташа. Ләкин эшенең рәте-чираты гына күренми. Әтиебез председатель булып та, безнең туйганчы бал ашаганыбыз юк. Балламый безнең колхоз умарталары. Әллә инде соры кортлар гына җыелган. Әти әйтә, безнең яклар умартачылык өчен кулай түгел, ди. Басуларыбыз тулы нефть скважиналары. Ә нефтьтән, билгеле инде, ислемай исе килми. Кайбер скважиналар янында әле дә булса факеллар янып тора. Ул факелларның сүнеп, тирә-юньгә яман ис таратып утырган чаклары еш була. Умарта кортлары нефтьтән бал җыярга өйрәнсәләр генә инде. Шунсыз авылга бал эләкмәс.

Апаның умартачылыкка укый башлавын эти хуп күрмәде.

— Тапкан кызыгыр нәрсә. Юкны бушка алыштырыр өчен нигә укып йөрергә, — дип каршылады ул бу хәбәрне.

— Укуын ярты юлда ташламаса, рәхмәт әйт инде, — диде әни. — Әллә кайда буталып йөргәнче, укый торсын әле. Бәлки, акыл кереп куяр.

— Белмим шул. Моңарчы кермәгән акыл...

Үзе сайлаган һөнәргә болай шикләнеп карауларын апа белмәде, әлбәттә. Башта ул этиләрнең шелтәле сүзләреннән котылыр өчен генә укып маташкан кебек күренә иде, ләкин тора-бара мавыгып китте. Вакыт-вакыт үзләренең нинди тема үтүләрен, умартачылыкның нинди булырга тиешлеген тәэсирләнеп сөйләп тә куйгалады. Бигрәк тә мине якын күрә башлады. Ни әйтсәң дә, аның сүзләрен иң күп тыңлаучы мин бит. Тыңлыйсы килмәгән чакларда да, мин тыңлаганга салышып утырам. Синең ни уйлаганыңны кеше каян белә? Әйдә, аларга да яхшы, миңа да. Ә шулай да апа теләсә мавыктырырлык итеп сөйли ала. Мин генә түгел, эти дә хәзер аңа шикләнмичәрәк карый башлады төсле.

Вакыт әкренләп уза торды, беркөн апа этигә:

— Әти, безнең колхоз умарталары кайда кышлый? — диде.

— Подвалда! Нигә кирәк булды әле ул, әллә бал ашыйсың килдеме?!

— Мин бал ашамасам да ач түгел, ә менә кортлар ач ятмыймы икән? Без нәкъ хәзер кортларны кышлату турында үтәбез. Теория — бер нәрсә, практика — икенче. Үзем барып карыйм әле. Подвалның ачкычы кемдә?

— Мәгъфурҗанда инде. Ләкин ул сиңа ачкыч тоттырыр микән? Подвал суына, дип, ул кышларын үзе дә ачмый, кешеләрне дә кертми.

— Җайлы хәйлә тапкан икән. Хәер, без аңардан ачкычны алу юлын табарбыз. Безгә генә ышанмаса, үзен дә ияртербез.

Рәйханә апа миңа да үзе белән барырга кушты. Дәресләремне әзерләп куйган идем инде, бик теләп иярдем.

Без килеп кергәндә, Мәгъфурҗан абзый итек басып ята иде. Өйләрендә кеше күрмәле түгел, пар баскан. Казанда гөбер-гөбер нидер кайный, бар җиргә керле йон исе таралган. Безне күргәч, Мәгъфурҗан абзый түшәп ята торган итеген сырма белән каплап куйды.

— Персидәтел балалары икән, әйдүк, түрдән. Менә хәзер бәрәңге пешәр.

Казанда бәрәңге түгеллеген беләбез инде, шулай да, рәхмәт, ашыйсыбыз килми, дибез, бу өйдән тизрәк чыгып китү өчен йомышыбызны әйтергә ашыгабыз.

— Һы, алай икән, — ди Мәгъфурҗан абзый, — персидәтел кызы умартачылыкка укый дигәннәрие шул. Әтиең сине ребиҗия ясарга җибәрдемени? Кызны умартачы итсәм, бал ашармын, диюедер. Кортлар алар синең әмереңә буйсынмый шул. Диплумың нипачум.

— Ярар, Мәгъфурҗан абзый, этигә ачуың булса, үзенә барып әйтерсең, хәзергә ачкычларыңны бир. Умарталарның ничек кышлауларын күреп кайтасым килә. Яренгә анда мин эшлисе бит, — диде апа.

— Атаң мине алып ук ташлыймыни инде? Кызына баллы урын кирәк булдымыни? Һы, персидәтел кушкач, ничек бирмисең инде. Мәгез, мә! — Ул стенадагы карточкалар янына эленгән ачкычны алып, апага сузды. Без тизрәк чыгып китү ягын карадык.

Умарталар саклана торган подвал әллә кайда еракта икән. Күрәсең, көзен умарталарны ташып йөрү кыендыр, шуңарга подвалны да шунда казыганнардыр. Подвалның ишеген шактый гына кар басарга өлгергән, ә без көрәкләр дә алып килмәгән идек. Көрәк урынына бармакларны җигәргә туры килде. Итек башларыбыз белән типкәләп һәм учларыбыз белән көри торгач, ишек без сыярлык ачылды. Подвал эче дөм

караңгы иде, башта һични күрмәдек. Бераз ияләшә төшкәч кенә, икешәр-өчәр кат итеп куелган умарта оялары күзгә чалынды.

— Сиңа, Фәйрүз, кайтып килергә туры килмәгәе әле. Болай бит без берни күрмибез. Термометр дигән нәрсә дә юк, ахры, монда. Ансыз температураны ничек белмәк кирәк?!

Мин авылга чабарга җыенган идем, апа кире туктатты.

— Ашыкма әле, Фәйрүз, син кайтып та эш чыгара алмассың. Башта бераз умарталарны тыңлап карыйк. Ничек гөжлиләр икән. Ашыйсылары, эчәселәре килмиме?

— Ашыйсы килсә дә әйтә алмый ич алар.

— Әйтә ала икән шул, энем. — Апа үзенең белеме белән мактанырга теләгәндәй сөйләп китте: — Синең кышкы урман җырын ишеткәнең бармы? Әкрен генә, тонык кына шаулый ул. Талгын җилдән дә куркып утырган усаклар инде яфракларын койган, өздереп-өздереп сандугач сайрамый, көртлекләр дә пырхылдашмый. Табигать чын мәгънәсендә йокыга талган. Тик табигать ул ана кебек сизгер йоклый. Урманның сизгер йокысын кышкы җилләр бер көйгә салып, шаулау барлыкка китерәләр. Тыныч кышлаучы кортлар да әнә шундый кышкы урман шаулавын хәтерләтеп гөжләргә тиеш. Әйдә, хәзер тыңлап карыйк инде. Әгәр тавыш-тын ишетелмәсә, бик саклык белән генә бер-ике тапкыр чирт.

Мин колагымны куеп тыңлап карадым. Башта һичбер тавыш юк иде кебек. Ләкин дикъкать беләнрәк тыңлагач, ниндидер гүләү, ниндидер хәрәкәт барлыгын ишеттем. Әмма бу тавыш апа әйткән кышкы урман шаулавына бер дә охшамаган иде. Башкалары, бәлки, икенче төслерәк шаулыйлардыр дип, тагын берничә умартага колагымны куйдым. Апа да әле бер умартага, әле икенчесенә күчте. Шулай итеп, бөтенесен диярлек тыңлап чыктык. Мин үземнең шигемне әйттем:

— Апа, урман болай итеп шауламый бит. Урман тыныч, сабыр була.

— Миңа да кортлар ни өчендер тынычсызлана кебек тоелды. Бәлки, бу безнең тәҗрибәсезлектәндер. Безнең күч тавышын тыңлаганыбыз бармыни? Шулай да моны ачыкларга кирәк.

— Ничек итеп?

— Ничек итепме? Менә, мәсәлән, безгә болай аңлаттылар: әгәр кортлар ачыкса, коры яфрак кыштырдаган тавыш чыгара. Авырсалар, умарта авызына һава суларга яки эчләрен бушатырга тышкы якка җыелалар. Кышлау өйләре артык җылынып җитсә дә гадәттәгедән ныграк гөжлиләр, чөнки алар умартаны җилләтергә мәҗбүр булалар. Артык хәрәкәт барлыкка килә.

— Ә ничә градус җылы кирәк аларга?

— Нульдән алып дүрт градуска кадәр. Шуннан суынып китсә дә, җылынып китсә дә ярамый. Өйләре суык булса, җылылык чыгару өчен алар балны күп ашыйлар. Аннары умарта өендә дымлылык та 80–85 процентттан артмаска тиеш. Дым күп икән, кортлар үлә башлый, кәрәзләрне күгәрек каплый.

Апам миңа тагын бик күп серләр өйрәтте. Шул арада никадәр нәрсә белеп алган. Кортлар турында сөйләгәндә, үзенең күзләре очкынланып китә, йөзендә ялкын кабына. Аның дулкынлануы миңа да күчә, үзебез генә белгән яшерен сер безне тагын да якынайтып җибәрә.

Без ул көнне умарта өендә озак юанмадык, чөнки кайбер нәрсәләр кирәк икән. Шуларны кайтып алырга булдык. Кайтышлый тагын Мәгъфурҗан абзыйларга кердек. Ул безне мыскыллап каршы алды.

— Җә, ребиҗияләр ничек үтте? Минем өскә нәрсәләр чәпәдегез?

Апа аның соравына җавап бирмичә:

— Умарталарның кышлау өендә термометр, психрометр кебек приборлар булырга тиеш. Нишләп юк? — диде. Мәгъфурҗан абзый аны әллә аңламады (хәер, мин дә психрометрның ни икәнен белми идем), әллә юри аңламаганга сабышты, юләр кеше сыман апага карап тик торды. Апа тагын сорау бирде: — Кышлау өендәге дымлылыкны, җылылыкны ничек үлчисез сез?

— Ә нигә үлчәргә аны? Минем үз умарталарым өй базында кыш чыга. Култык асларына градусник кыстырганым юк. Аңа карап җалу бирмиләр. — Мәгъфурҗан абзый үз сүзеннән үзе көлеп куйды, ләкин апаның аңа кушылырга исәбе юк иде. Ишек төбендә кукраеп торуыбыз Мәгъфурҗан абзыйга ошамый башлады, ахры, кырт кисеп: — Җитмәгән нәрсәләрне атаңнан кайтып сора инде син, кызый, ул баш кеше. Җавабын бирер, — диде.

Безгә чыгып китүдән башка чара калмады.

Без кайтканда, эти өйдә иде. Ул китапханәдән бер кочак китап күтәреп кайткан. Шуларның әле берсен, әле икенчесен актарып нидер эзли. Институтка кереп кайтканнан бирле өйдә аның тик утырганы юк. Әз генә вакыты булдымы, китапларына ябыша.

— Умарталарны карап кайттык. Тәртипсезлек! — диде апам.

— Ни булган?

— Ни дип сорап торасы юк, барып карарга кирәк, — диде апа. — Шунда өч тиенлек термометр да алып куя алмыйсыз.

— Мин моңарчы аны сораучыны ишетмәгән идем әле, — диде эти.

— Ишетмәсәң ишет. Бүгеннән биш термометр кирәк.

— Нигә ул кадәр запас? Әллә берәү генә җитмәс кебек тоеламы?

— Бер белән генә дөрес үлчәп булмый. Умарталар анда өсте-өстенә өелгән. Аста салкын, өстә җылы. Берне өскә, берне уртага кадакларга кирәк, ә калган икесе психрометрлар өчен. Монысы бигрәк тә мөһим.

Апа белән шушы сөйләшүдән соң, эти термометрлар алып кайтты. Апам иң төгәл күрсәтә торган икесен сайлап теге психрометр дигән нәрсәне ясады. Исеме бик куркыныч яңгырагач, мин аны әллә нинди катлаулы нәрсә дип күз алдына китергән идем. Тактага янәшә беркетелгән ике градусник икән. Ләкин ул ничек дымлылыкны күрсәтә ала соң, шунысы хикмәт. Мин ападан бу хакта сорадым.

— Беләсең килсә, әйдә киттек, подвалда карарбыз, — диде. Кабат әйткәнне көттермәдем, апага иярдем. Бу юлы инде без, ишекне көрт баскан булса, көрәргә дип, көрәкләр дә алдык. Әти ул умарталардан әллә ни көтми иде, ахры, без барырга рөхсәт сорагач, кулын гына селтәде. Янәсе, сезнең маташулардан кортларга ни зыян, ни файда, бүтән уен тапмыйсыз икән, йөри бирегез.

Бүген безгә караңгыда күз ияләшкәнне көтеп торырга туры килмәде, мин кесәмә фонарь тыккан идем, ишектән керү белән кабызып җибәрдем.

Апа:

— Яктылыкны умарта авызларына бик юнәлтмә, кортлар уянмасын, —диде.

Без термометрларның төрлесен төрле биеклеккә кадакладык. Җылылык чынлап та өчесендә өч төрле иде, бөтенесен кушып өчкә бүлдек тә уртачасын таптык. Подвалда җылылык тугыз градус иде. Апа куркып китте.

— Менә кортлар нигә тынычсызланалар икән! Бар әле, Фәйрүз акыллым, тышка чык та подвал өстеннән күренеп торган морҗа сыман нәрсәне кара. Күрәсең, тактасын ныклап ябып куйганнардыр. Бөтенләй ачып җибәр.

Мин шунда ук чыгып киттем. Җилләткеч торбаның өстендә такта-мазар юк иде, торба эченә иске бүрек тыгып куйганнар. Бүрекне тартып алдым да апага күрсәттем. Ул өскәрәк куелган умарталарның корт юлларын да ныграк ачты. Хәзер инде дымлылыкны тикшерәсе генә калды. Мин теге прибор белән ничек дымлылыкны белеп була икән дип тын да алмый карап тордым. Апа янәшә беркетелгән ике термометрның берсен чәчүргеч белән бәйләде дә тасманың очын сулы шешәгә батырды. Тасма буйлап күтәрелгән су термометрның шаригын чылата да терекөмешне суыта икән. Менә шуннан инде ике градусник ике төрле күрсәтә башлый. Безнең термометрларның суга батырылганы алты, ә тегесе сигезне күрсәтте.

Минем һаман да берни аңламый торуымны күргәч, апа кесәсеннән дәфтәр битенә сызылган бер сызым чыгарды, аркылы-торкылы сызылган сызымнарның берсе — коры термометрдагы җылылыкны, икенчесе юешлекне күрсәтә. Ә алар кисешкән нокта ничә санына туры килсә, шулчаклы процент дымлылык була икән. Алты белән сигезнең кисешү ноктасы җитмеш-сиксән процент арасында иде.

— Димәк, һава корырак икән, — диде апа, — өсте ачык савыт белән су куярга яки юеш чүпрәкләр эләргә кирәк. Бүген кайтып килергә өлгермәбез инде. Алдагы ялда тагын әйләнербез әле. Хәзергә бер-ике кисәк кар кертеп куйыйк.

Шул эшләрне башкарганнан соң, тагын умарталарны тыңлап карадык. Гөжләү әкренәймәгән иде. Апа борчыла төште. Мин аны үземчә юатырга тырыштым:

— Ул арада гына тынычланмаслар инде, умарта эченә әле саф һава кереп тә җитмәгәндер. Менә морҗасы берничә көн ачык торсын, шуннан соң килеп карарбыз.

— Суынып китмәс микән?

— Китмәс, үзең бит, нуль градус тирәсе җитә, дисең. Бәп-бәләкәй морҗа тишегеннән күпме генә суык керә алсын?!

Кайтышлый без эти янына идарәгә кердек. Апа этигә подвал ачкычын бирде.

— Син, эти, ул Мәгъфурҗан абзыйны идарәгә чакыртып әйт әле. Умарталарны карасын. Китапта бит кортларны кыш көне бикле подвалда тотарга димәгән. Бәлки, ашатырга-эчертергә кирәктер.

— Кортлар сыер түгел инде, ашарга-эчәргә сорамый, — диде эти.

Апа аңа кызып-кызып мондый сүзләр әйтеп ташлады:

— Сез шул ашарга сорап кычкырганның гына авызын томалыйсыз. Кортлар ишек төбенә килеп кычкырмагач, уйлаучы юк.

— Миннән ит-сөт таләп итәләр, бал түгел, — диде эти. — Бал ашамыйча да яшәп була, ә менә син итсез, сөтсез тора аласыңмы?

— Итле, сөтле табынга бал да куелса, начармыни?

— Начар түгел дә, бөтенесенә кул җитми. Менә син умартачы булып эшли башлагач, ашарбыз инде балны. Юкса моңарчы умарталык безне куандырмады.

— Әһәмият бирмәгәч, — диде апа. — Бездә хәзер ни өчен игеннәр уңа башлады? Чөнки игътибар күбәйде. Колхозда югары белемле агроном бар. Терлекчелектә дә шундый хәл. Зоотехник фәнгә таянып эш итә...

— Бөтенесен фәнгә генә кайтарып калдырма син. Игенченең тырышлыгын, үз өстенә төшкән җаваплылыкны ныграк тоюын һәм, иң мөһиме, партиябезнең олы кайгыртуын онытма.

— Онытмыйм, — диде апа, — бары тик умартачылыкка игътибар җитмәүне генә күрсәтергә телим. Йә, үзең әйтеп кара, кем кулына тапшырылган бездә бал кортлары? Мәгъфурҗан абзый ул итек басуыннан, балта чабуыннан башканы беләмени? Әллә кайчан колхоздан берәрсен укытып кайтарырга кирәк иде. Беткәнмени бездә яшьләр? Мин шуны да әйтермен дигән идем, әти, безнең курста укучыларның күбесе — колхоз стипендиатлары. Нигә миңа да колхоз стипендия түләми?

— Син — председатель кызы. Үз кызымны колхоз исәбенә укыта алмыйм бит инде. Кешеләр ни әйтер?

— Ни әйтсен? Мин дә башкалар шикелле колхозчы ла!

Әти, ят кешегә караган кебек, апага карап торды. Күзләрендә гаҗәпләнү, аптырау күрергә мөмкин иде. Мин дә апаның әти белән болай кыю сөйләшүенә шаккатып карап тордым. Курста кыюландырып җибәргәннәр, ахры.

— Хәзер синең ярты ел укуың калды, — диде әти, — стипендиясез дә ач йөрмәссең.

— Эш ач йөрүдә түгел, әти. Менә әлеге дә баягы, агрономны алыйк. Ул ни өчен җиргә ябышып ята? Чөнки ул үзендә җаваплылык тоя, чөнки аны колхоз укытты. Кеше бит һәрвакытта яхшылыкка яхшылык белән җавап бирергә тырыша.

— Синең сүзең белән килешеп бетмим мин, кызым. Агроном абыең колхоз стипендия түләп укытканга гына тырышып йөрсә, поты бер тиен булыр иде. Аңарда игенче каны ага. Җир язмышы — аның язмышы. Ә инде сиңа килгәндә, син болай да аңлы кеше, укып чыккач, ташлап качмассың дип уйлыйм.

Әти бу сүзләрне бераз көлебрәк әйтте. Күрәсең, ул әле апага һаман да шикләнебрәк карый. Ә менә минем ни өчендер аңа ышанычым арта башлады. Апаның әле бервакытта да мондый дәрт белән эшкә тотынганы юк иде. Китапларда язалар бит, кеше тормышта үз урынын тапкач кына бәхетле була ала, диләр. Бәлки, апаның бу үз урынын табуыдыр. Кем белә, бәлки, әле безнең яклардагы умарта кортлары да әзерне генә ашап ятучы буржуйга әйләнмәгәннәрдер. Әнә Шәйхелислам бабайларның умарталары ел саен бал бирә. Бал кирәк кеше шуңа йөгерә. Ай-һай аның кортлары усал. Әллә балны күп җыя торган кортлар усалрак була микән? Җәй көне алар турысыннан үтәрлек түгел, дошман дзотында яшеренеп яткан пулемет кебек, үткән-сүткән кешеләрне чәкеп кенә торалар.

— Апа, — дим мин, — ни өчен кортлар чагалар?

— Ачуыңны китерсәләр, син дә чагарсың, — ди апа.

— Нигә соң аларның ачулары килә?

— Авызыңа төтен җибәреп, кулыңнан ипиеңне тартып алсалар, синең ачуың килмәс идемени?

Мин әнә шундый тузга язмаган сораулар биреп апаны тинтерәтеп бетерәм. Үземчә апаның түземлелеген сыныйм. Ә ул мине чынлап сораша дип белә, җавап бирә алмаган очракларда: «Туктале, китапны карыйм, анда язылмый калмагандыр», — дип, китабын актарырга тотына. Китапта чынлап та барысы да язылган. Апа соңгы вакытта умарталар ясау белән җенләнеп йөри башлады. Әти белән дә бу хакта әллә ничә мәртәбә бәхәскә керде.

— Умарталар стандарт булырга тиеш, — диде ул. — Шуның өстенә җайлы гына сүтелсен дә, җыелсын да. Күтәреп йөрергә, күчерергә уңайлы җиңел материалдан эшләнсен. Суыкларда җылыны тотсын, яңгырларда эченә дым кермәсен. Тычкан-күсе керерлек тишек-тошык калмасын. Рамнары бер зурлыкта булсын. Ә безнең умарталар нәрсә ул! Корт өе түгел, карикатура бит. Берсен югары оч фәлән бабай ясаган, икенчесен түбән оч фәлән абзый әмәлләп биргән. Бүгеннән яңа умарталар ясата башларга кирәк.

— Син нәрсә, әллә этиеңне синең капризларыңны үтәү өчен председатель итеп куйганнар дип беләсеңме? Бүген бу теманы үттек, давай шуны ясыйбыз, дип кайтасың да аяк терәп таләп итәсең. Мин председатель булмасам нишләр идең син?

— Председательгә барып шул ук таләпләрне куяр идем. Син уйлаганча, бу минем капризым гына түгел, әти. Умартачылыкны да фәнгә нигезләп корырга вакыт. Бал кортлары да синең сыерларың кебек үк үзләрен сыйлаганны ярата. Сыерларың ни өчен көненә берәр пот сөт бирә? Чөнки торырга җылы, уңайлы абзарлары, ашарларына теләгән кадәр азыклары бар. Шулар өстенә ветврач аларның сәламәтлеген тикшереп тора. Ни генә эшләтмисез ул сыерларыгызны. Әгәр муеннарыннан кашыганга сөтне арттырсалар, сыер саен бер муен кашучы да куяр идегез әле.

Әтинең ачуы килер дип уйлаган идем, елмайды гына. Үзенең сыерлары белән бераз мактанырга ярата инде ул. Мактанырлыгы да бар: иң сөтле сыерлар безнең колхозда. Сыер савучыларны әле газетага язалар, әле радиодан сөйлиләр. Хәтта башкалага күргәзмәгә кадәр барып җиттеләр.

— Әгәр синең умарталарың сыер биргән чаклы доход бирсә, кортларыңа алтын сарай салыр идек, — диде эти. — Ләкин алар бит үзләрен дә туйдыра алмый, язга чыгу белән кибет шикәре ашата башлыйбыз. Мондый әрәмтамаклар колхозга нигә кирәк? Яңа умарталар ясау түгел, бүгеннән боларын сатар идем әле. Уптым алучы гына юк.

— Әлбәттә, боларын бетерергә кирәк. Өр-яңа баштан, китап кушканча эшләт. Алдан үзең кесә төбен какмыйча, бал кортлары синең табыныңа тәпән-тәпән бал куймас. Аннары бал кортлары китергән файданы бал белән генә исәпләргә ярамый. Алар бит әле ашлыкны серкәләндереп, иген уңышын да арттыралар. Бер умарта корты минутка унлап чәчәккә куна, һәр очышы ун минутка якын дәвам итә. Көн әйбәт торганда, һәр эшче корт кырыктан да ким очыш ясамый. Ә бер умартада унбиш меңләп эшче корт була. Шуларны исәпләп карасаң, бер семья корт кына да никадәр эш башкара. Ә акыллы кешеләр моны исәпләп чыгарганнар да инде. Беләсеңме, эти, умарта корты серкәләндергән җирдә кыяр уңышы, кортлар кермәслек итеп каплап куелган төштәгегә караганда, биш тапкыр артык булган. Карабодай, клевер кырларында да шундый ук тәҗрибә ясалган. Кортлар серкәләндергән үсемлекләрдән уңыш һәрвакыт күбрәк чыккан.

— Сиңа хәзергә һәммәсе дә ал да гөл булып күренә, — диде эти, — ләкин эшкә тотынгач, китапча гына барып чыкмый ул. Үзең үк китап таләпләрен боза башларсың әле. Тормышта әзер рецептлар юк.

— Алайса, нигә укыталар? Нигә китаплар язалар? Аларда бит меңләгән кешенең тәҗрибәсе тупланган. Гомер-гомергә кортлар кыргый яшәгән, кеше аларны кулга ияләштергән. Багана умарталардан такта умарталарга күчкән. Кортларны хәтта аерым үсемлекләргә очарга өйрәтергә мөмкин.

Апа кызып китте. Шул кызып китү аркасында кортлар турында әллә никадәр нәрсә сөйләп ташлады. Кызык кына икән: әгәр бал кортларына бер төрле чәчәк исе сеңдерелгән ширбәт эчереп күндерсәң, алар кырга шул чәчәкне эзләп оча, ди. Телләре дә юк, ә үзара аңлаша беләләр. Әгәр берсе басуда баллы чәчәк тапса, тизрәк кайтып башкаларына «сөйли», комсыз түгелләр. Табышы белән һәркем уртаклашырга тырыша. Ә сөйләшүләре төрлечә биюләрдән гыйбарәт икән: баллы чәчәк табып кайткан корт умартага кереп төрле зурлыктагы түгәрәкләр ясап әйләнергә, ягъни биергә тотына. Эшче кортлар аның тирәсенәрәк җыела, кортның үзенә сеңдереп кайткан исен исниләр, әйләнешләренә карап чәчәкле басуның ераклыгын беләләр икән.

Әти апаның сүзен бүлдерми тыңлады. Соңыннан:

— Ярар, умарта кортларының файдалы икәненә мине ышандырдың, — диде, — ләкин мин ышану гына җитми әле. Бөтен нәрсәне дә председатель генә хәл итми. Партком, идарә членнары белән киңәшеп карармын. Бәлки, идарә утырышына синең үзеңне чакырырга туры килер. Миңа сөйләгән кебек ялкынланып сөйләсәң, аларны да үз ягыңа аударырсың, шәт. Ләкин эшнең икенче ягы бар.

— Анысы нәрсә тагын?

Әти җавапны көттеребрәк бирде.

— Беләсеңме нәрсә? Умартачылыкка син укый башлагач кына әһәмият бирү яхшы түгел. Үз кызының авторитеты өчен тырыша, диюләре бар.

— Алай дип курыккач, элегрәк тотынырга иде. Аннары, эти, синең кызың бит ул умарталарны үз бакчасына кайтарып куярга җыенмый, — диде апа. — Моңа каршы нинди сүз булырга мөмкин.

— Ну ярар, — диде эти, ахырдан апа белән килешеп, — мин бу эшкә ныклап тотынырмын. Син әйткәнчә, икмәкле-майлы табында бал артык түгел. Әмма сине алдан ук кисәтеп куям: әгәр дә мәгәр бу эш минем кулдан килми дип койрык селтәргә уйласаң — үзеңә үпкәлә. Атаң буларак тотып ярырмын, председатель буларак колхозчылар алдында кирәгеңне бирермен.

Шушы сөйләшүдән соң апа тагын да тырышыбрак укый башлады. Умарталар кышлый торган подвалның ачкычын да гел үзе белән йөртә. Ә беркөнне Мәгъфурҗан абзый аңа: «Менә бу битлек белән төтәсләгечне дә апкит, минем өстә ятмасыннар», — дип, умарталыкның барлы-юклы коралларын да китереп тоттырган. Шулай итеп, хәзер бөтен эш апага калды.

Әллә үз өстенә төшкән җаваплылыкны тойганга, апа соңгы вакытларда җитдиләнде. Инде хәзер кортларның тавышларын да аңлый башладым, ди. Тыңлап-тыңлап торганнан соң, менә бу семья ачыккан, ахры, дип, ачып караган икән, чынлап та кәрәзләрендә берни калмаган булган. Колхоз бухгалтериясе биргән акчага шикәр алып, ул берничә мәртәбә кортларына ширбәт ашатты. Язга таба кортларга азык күбрәк кирәк икән, чөнки алар үзләренә яшь алмаш әзерли, ди. Ә беркөнне апа подвалдан елап кайтты.

— Нәрсә бар? Әллә корт чактымы? — диде әни.

— Юк!

— Алайса, нигә елыйсың?

— Ике умартага тычкан кереп, тәмам эштән чыгарган. Кортлары үлеп беткән. Инде хәзер мин аларны нишләтим?

Бу хәлне, эти кайткач, аңа да сөйләп бирде. Әтинең аңа әллә ни исе китмәде:

— Барысы кырылып бетмәсә, шөкер инде, боларына акт төзербез, — диде ул.

— Акт кына умарта кортларын үлүдән коткара аламыни? — диде апа, үртәлеп. — Подвалда тиешле температура саклап булмый. Төнлекне ачсаң, суынып китә, ачмасаң — җылы.

— Нәрсә? Әллә миннән подвал да салдырырга уйлыйсыңмы?

— Яңа подвал кирәк шул. Бусы кечкенә. Умарталар өсте өстенә өелгән. Бу бит бәрәңге тутырырга гына ярый. Умарталар ишәйгәч, монда сыймый да башлаячак.

— Башымны катырмасана, — диде әти, ачуланып. — Умарталарыңның ишәергә исәбе юк. Әнә кырылып баралар.

— Кырылсыннар дип торсаң, кырылмый нишләсен?

— Минем аннан башка да эшләрем муеннан. — Әти, шуның белән бу хакта сүзне бетерик дигән сыман, кул гына селтәде. Аның нәрсәгәдер кәефе кырылганлыгы күренеп тора иде. Умарта турындагы уйларын онытып, кемнәрнедер тиргәргә тотынды: — Һы, тапканнар җайлы метод. Иң яхшы кадрларны тот та алып кит, имеш. Үзләре безгә ярдәм итәр чакта.

— Тагын кемне районга алдылар? — дип сорады әни. Моннан ярты ел чамасы элек әтинең агрономын районга алганнар иде.

— Кемне булсын? Иң яхшы кешене. Мәдәният йорты директорын.

— Тургай абыйнымы? — дидем мин, кабаланып.

— Шуны шул.

— И мескен, — дидем мин, Тургай абыйны чын күңелдән кызганып. — Районда нишләр инде?

— Ул эшләр. Министерствога куйсаң да югалып кала торган кеше түгел. Менә без нишләрбез? Ул бит авылның җаны иде.

— Үзе барында бер дә алай мактамый идең, — диде әни.

— Эш мактаудамыни?

— Алайса, кадрларыңны тота белмисең, тәрбияли белмисең. Авылыңны, колхозыңны яраттыра алсаң, китмәсләр иде.

— Миннән беркем дә китми, алып китәләр. Минем колхозымда район масштабындагы кешеләр үсә. Ә син яраттыра белмисең, дисең. Кешеләрне яраттырырга түгел, эшләргә шартлар тудырырга кирәк. Мин кешегә әнә үсәргә булышам.

— Мин дә мин. «Мин»нең күбәя башлаган әле синең. Колхоз да синеке генә, кешеләр дә. Болай булса, үзеңне дә «алып» китмәгәйләре, ләкин районга түгел, председательлектән.

Әни әйбәт кенә итеп әтине тәнкыйтьләп ташлады. Безнең әни шулай мыштым йөри-йөри дә шартлатып кирәген әйтә. Аның иң яратмаганы — мактану. Үзенең эше турында ул һичбер вакыт мактанып сөйләми. Хәле авыр, инде терелергә өмет юк дигән кешегә операция ясап терелткәндә генә, йөзенә канәгатьләнү билгеләре чыга аның. Анда да әгәр берәрсе: «Саҗидә Хәеровна, сезнең аркада исән калдым», — дип сүз башласа, кырт кисә: «Минем аркада түгел, медицинабызның казанышы аркасында». Әти аңа, син ирләр эше эшләп шулай тупасланасың, ди. Әти арттыра, билгеле. Шулай да әни артык эреп китәргә тормый шул. Безгә ул «улым», «кызым» дип бик сирәк эндәшә. Исемебез белән генә әйтә. Сизеп торам, ярата ул безне, ләкин әти кебек күтәреп түшәмгә чөя алмый. Акча алгач та, әти төсле, кочагы белән әйбер төяп кайтмый. Акчасын өстәл тартмасына сала да үзе үк оныта. Күрәсең, кешеләр шулай төрле-төрле буладыр инде. Аңа карап без әнине әтидән ким яратмыйбыз.

Әле менә апа да кеше рәтенә кереп бара. Һәркайсыбыз белән ачылып сөйләшә. Тик Тургай абыйның районга китүе генә аның кәефен җибәрде. Дөрес, ул аны сиздермәскә тырыша. Әйдә, бик ялындырып маташкан иде, җәфалансын бераз. Тургай абый бигрәк тә миңа кирәк иде. Хәзер теләсә кайчан театрга директор кабинеты аша кереп булмас инде. Ачуым килсә, гармун уйнауны да ташлармын әле. Их, әллә нишлисе килә! Тургай абый миннән Марс Макаров та ясый алмый инде болай булгач. Ә мин, юләр, шигырьләр яза башлаган идем. Аларны кемгә күрсәтим инде? Районга барып була булуын. Шигырь язучылар районда күбрәктер дә әле. Их!..

Эч пошуым басылмасмы дип, апаның умарталарына ияләнгән тычканнарны эләктерергә тәбеләр ясадым. Подвалга барып почмак саен тәбе корып куйдык.

Берничә көннән соң тәбеләрне карарга киттем. Апаны да алып барып мактанасым килгән иде дә, ул, укыйсым күп дип, өйдә калды. Фонарьны яктыртып карыйм, бу ни хикмәт: берсендә дә тычкан юк. Алдар өчен куйган итне ашап киткәннәр. Ә бит шундый шәп конструкцияле капкыннар уйлап тапкан идем. Инде нишләргә? Апага тычканнарны тышка чыгарып аттым диярмен инде. Ә подвалга песине китереп куймый булмас. Дөньяда иң шәп тычкан тәбесе шул бит. Кайткач, апа миннән:

— Тычкан эләккәнме? — дип сорады.

— Һы, — дидем мин, — тычкан гына түгел, икесенә чучка баласы хәтле күсе эләккән иде. Подвалдан еракка илтеп, карга күмеп куйдым.

Үзем шулай дидем, үзем апа күрмәгәндә песине куеныма кыстырдым да кире подвалга чаптым: «Әйдә, рәхәтләнеп сыйлансын. Юкса өйдә тычкан чырае күрмичә интегә. Ялкауланып бетте инде».

Мыраубикә минем тәбеләргә караганда әйбәтрәк булып чыкты. Мәче: «Менә минем эшемне күр», — дигән күк, дистәгә якын тычканны бер өемгә өеп куйган иде. Мәченең башыннан сыйпап куйдым: «Молодец! Тәртибеңә бишле!» Тычканның эзе дә калмады.

Колхозның идарә утырышында язга кадәр умарталар ясый башларга дигән карар кабул иткәннәр. Апа ул көнне идарәдән канатланып кайтты. Ләкин көн артыннан көн үтә торды, ә умарталар ясарга ашыкмадылар. Апа еш кына әтине кысрыклый башлады:

— Кайчан тотынасыз инде?

— Синең бар кайгың умарта гына булгач та, әллә колхозның бүтән эше юк дип белдеңме? Кортларның язгы чәчүгә әзерләнәсе юк әле.

— Алайса, нигә дип карар чыгардыгыз?

— И кызым, карарларның һәммәсен дә шундук үтәп барып булса иде...

Апаның күзләре зур булып ачылды:

— Нәрсә? Сез җыелышып алдашып та утырасызмыни? Димәк, мине юатыр өчен генә карар чыгардыгыз?

— Юк ла. Эшләр кимесен, шуннан соң карарбыз. Материал да бар, кеше җитешми.

— Сиңа бервакытта да кеше җитешкәне юк. Күр дә тор: әгәр умарталарны язга чаклы ясатмасаң, укуымны ташлыйм. Ул череп беткән тартмаларда корт яшәрлек түгел. Шулар белән оятка каласым килми.

— Ә, шулаймы? — диде әти, кызып. — Укуыңны ташларга син сәбәп кенә эзләп йөрисең. Тегеләй итмә, болай ит. Чәйнәп каптыргач, кем дә йота. Син менә үзең чәйнәп кара. Минем өчен укымыйсың.

Апа киреләнеп китеп укуын ташламагае дип, мин курка калдым. Аның тәртәсе усактан, шартлатыр да сындырыр. Их, менә хәзер шәп кенә тылсым белеп, кулларына үткен балталар тоткан унлап останы каршыларына китереп куясы иде. Әти белән апаның авызлары ерылыр иде. Әллә соң үзем ясап караргамы? Ә нигә, бөтен класс малайларын җыям да... Тукта, тукта. Шәп идея бу.

— Әти!

— Әү?

— Таптым.

— Нәрсә таптың?

— Умарталар.

Әти мине шаяра дип белеп бармак янады.

— Тапсаң әйт, башымны катырма.

— Уйлап табучыларга премия бирәләр. Миңа нәрсә эләгер соң?

— Уйнап маташсаң, сыртыңа каеш эләгер.

— Премиясе алай шәп булгач әйтәм инде. Умартаны без ясыйбыз.

— Рәтле сүз әйтәсеңме әллә дисәм, юк белән баш әйләндерәсең икән.

— Бер дә юк түгел. Безнең мәктәптә, беләсеңме, мастерской нинди шәп. Тактаңны гына китер. Кортларның төшенә дә кермәгән умарталар ясап ташларбыз.

Әтинең күзләрендә кызыксыну чаткылары кабынды.

— Ярарлык идея бу, — диде һәм апага карады, ләкин апа нигәдер шатланырга ашыкмады. — Такта бар, өлкән класс укучылары тотынса, барып чыгар, шәт.

— Ә премиягә нәрсә? — дидем мин.

— Анысын әнә апаңнан сорарсың инде. Умарталары баллангач, туйганчы бал ашатыр үзеңә.

Күз алдыма бер тәпән бал килде. Балны теләсәң никадәр ашап буладыр кебек тоелды һәм мин әтинең сүзләре белән рәхәтләнеп ризалаштым.

— Син, кызым, директор абыең янына барып бу хакта сөйләш. Вакыт тапсам, үзем дә сугылырмын.

— Бармыйм мин мәктәпкә, — диде апа, үҗәтләнеп.

— Бусы нинди сүз тагын?

— Анда барсаң, нигә укырга йөрмисең, ди башларлар.

— Дисәләр, нигә йөрмәгәнеңне әйтерсең.

— Мин аны беркемгә дә әйтә алмыйм... — Апа нәрсәдәндер оялгандай кызарып китте.

— Ә мәктәпкә сиңа барыбер барырга туры киләчәк, — диде әти. — Син бит сызымнарыңны әзерләп бирергә тиеш. Үзең дигәнчә эшләтергә. Эшләгән эшне кабул итеп алырга. Син инде кечкенә бала түгел. Капризларыңны ташларга кирәк.

— Каприз түгел бу.

— Алайса аңлат, нәрсә соң?

Апа шактый вакыт турсаеп сүзсез торды. Аннары ул, туктап калсам сүземне дәвам итәргә батырчылыгым җитмәс дигән кебек, тиз-тиз сөйли башлады:

— Яратмыйм мин үзебезнең мәктәпне. Укытучылар көлә миннән. Кияүгә чыгарга вакыт сиңа, диләр. Әйтерсең мин гәүдәмне су сибеп үстергән.

— Укытучылар андый сүз әйтмәс, кызым. — Әти чын-чынлап аптырап калды. — Һәрхәлдә, барысы да алай димәс.

— Барысы да шулай әйтмәсә, берсе гел шулай бәйләнә.

— Кем?

— Аның кем икәне нигә кирәк? Дәресеңне начаррак белсәң дә, син кияүгә чыгарлык кыз, соңгарак калсаң да, син кияүгә чыгарлык кыз. Әйтерсең кияүгә чыгарлык кыз бер дә ялгышмаска тиеш.

— Алай, алай. Эш менә нәрсәдә икән. Бу гына зур бәла түгел, кызым. Алай дип әйткән кеше хәзер үзе дә үкенәдер, бәлки.

— Үкендерерсең аны.

Апа әнә шулай уйламаган җирдән ачылып ташлады. Әллә күңелендәге төенен чишкәнгә, үзе дә җиңеләеп калгандай булды. Әниләрнең күзләренә дә турырак карый башлады. Әти белән алар тормышның мәгънәсе, яшәүнең асылы турында ул көнне озак сөйләштеләр.

Әти шул ук көнне телефоннан мәктәп директорына шалтыратты. Мәктәп мастерскоенда умарталар ясарга мөмкин булмасмы, диде. Такта китерербез, диде.

Гыйлемхан абый да хәйләкәр, файдаланып калырга тырышкан:

— Менә безнең мәктәп машинасы ватылып ята. Шуңа запчастьлар табарга ярдәм итә алмассызмы? — ди икән.

Әти аңа:

— Умарталар ясалып беткән көнне машинагыз йөри башлар, — диде.

Әнә шулай апаның эше көйләнде. Башта ул мәктәпкә бармаска аяк терәп маташкан иде, эти җиңде үзен. Бер юмалап, бер тиргәп, барырга күндерде. Атна уртасында алар бер көн ял итәләр. Менә шул көнне ул йөгереп мәктәпкә килеп җитә. Һәр умартаның иңен-буен үлчи. Ярыклары калмаганмы дип тикшерә. Чистартыр өчен төбе җайлы алынамы дип карый.

Мәктәптә эш гөрләп бара. Атнасына әллә ничә хезмәт дәресе ясасалар да, һәркем риза. Шунысы гына бераз күңелне төшерде: бу эшкә сигезенче-унынчы класс укучыларын гына катнаштырдылар, безгә ышанып җитмәделәр, ахры. Ярар, без дә үсәрбез әле.

Шаулап-гөрләп яз җитте. Кояш нурлары, үткен хирург пычагыдай, бөреләрнең күкрәкләрен ярып җибәрде. Кошлар җыры дәртлерәк яңгырады. Кышкы алама-салама болытлар калмагач, күк йөзе биегәйде. Офыклар киңәйде.

Урамнарда кар суларының гөрелтесе басылгач, үсемлек бөреләре кышкы тунын салгач, басу өстендә беренче тургайлар талпынгач, апа укуын бетереп кайтты. Шунда ук аны тулы хокуклы умартачы иттеләр. Хәзер инде умарталарны подвалдан чыгарырга вакыт иде.

Безнең умарталык гомер-гомергә авыл башындагы таллыкта инде. Таллыкның бер ягында елга, икенче ягында авыл. Арырак киттеңме, талгын гына тирбәлеп утыручы скважина насосларын күрәсең. Якын-тирәне кайчандыр бораулаучылар ергалап бетергән: кайда траншея эзләре, кайда нефтьле су җыелып торган чокыр-чакыр.

Апа башта ук әтигә:

— Быел умарталарны ул таллыкка куймыйбыз, — диде.

— Бик уңайлы урын бит, — диде әти.

— Кемгә уңайлы? Бал ашарга килүчеләргәме? — диде апа. — Әйе. Авыл якын, ләкин кортлар балны авылдан ташымый. Дүрт-биш чакрым болынга очсалар, урман аннан да ерак. Өстәвенә әле су аркылы чыгарга кирәк. Җил-яңгырлы көннәрдә, елга аша чыкканда, кортлар кырылачак. Умарталыкка җайлы урын булмаганда, кайбер колхозларда күчереп йөртү ысулын да кулланалар икән. Моның, әлбәттә, уңай ягы да, тискәре ягы да бар. Уңай ягы шунда — теге яки бу үсемлек чәчәк атканда, умарталыкны якынайтасың, кортлар балны күбрәк җыя. Дүрт чакрымдагы басуга ике тапкыр барганчы, ике чакрымдагын алар дүрт мәртәбә әйләнә. Ләкин бу эшнең мәшәкате күп, ә безнең умарталар әле тотуга таралып китәргә тора.

— Кортларыңны яңа умарталарга күчер, — диде әти. — Көлеп торган егерме баш умарта ясап бирдек үзеңә. Җил-яңгыр үтәрлек түгел. Әтиеңә рәхмәт әйт.

— Эшлим дисәң, син булдырасың инде, — дип, салпы ягына салам кыстырды апа. — Әле син егерме баш умарта белән генә туктамассың. Күбрәк ясат әйдә, мин каршы түгел. Җәйгә чыгуга, кортлар аера башлар. Яңа умартага менә шул күчләрне ябарбыз. Балавыз запасыбыз да беткән, ул турыда да уйлап йөрисеңдер, мөгаен. Шунда беррәттән умарталык инвентаре турында кайгыртырга онытма. Юкса бездә бер ертык битлек белән бер төтәсләгечтән башка нәрсә юк. Аннары умарталыкны яңа урынга күчерсәк, иске келәт таралып бетәр дип тә куркасыңдыр. Куркуың юкка, эти, яңа җиргә ул черек нәрсәне сөйрәп йөрмәбез, әйбәтне салдырырсың. Балавызларны куярлык, умарталык инвентарен сакларлык, каравылчыга җәен кунарлык, умартачыга иркенләп эшләрлек булсын.

— Кортларың урынына үзем бал да җыеп биримме соң? — диде эти.

Мин көлеп җибәрдем. Чынлап та, апа этинең җилкәсенә менеп атланды, борылырга да ирек бирми. Әле бер нәрсә сорый, әле икенче нәрсә. Соңгы вакытларда эти өйгә соң кайта башлады. Ләкин апа хәйләкәр шул, аның кайтканын көтеп ятмый, идарәгә үзе бара.

Колхозның җимеш бакчасын Хаҗиәхмәт бакчасы дип йөртәләр. Анда карлыган, кура җиләге, алмагач һәм башка җимеш агачлары үсә. Сугыш елларында ул бакчаны Хаҗиәхмәт исемле кеше утырткан. «Кешеләрнең табынына ипекәй генә түгел, алмалар куяр вакыт та җитәр, хәстәрен хәзер күрә башлыйк», — дигән. Аңарга каршы төшүчеләр дә әз булмаган. Янәсе, тамак бәрәңге белән ипекәйгә туйса, башкасын сорамас идек әле. Әмма Хаҗиәхмәт абзый чигенмәгән, комсомолларны күтәргән, өмәләр оештырган. Бакча тәки шулай тернәкләнеп киткән. Хәзер инде Хаҗиәхмәт абзый үзе юк, ләкин бакчасын аның исеме белән атап йөртәләр.

— Әти, умарталыкны теге Хаҗиәхмәт бакчасы янына ясасак, ничек булыр икән? — диде апа.

— Хаҗиәхмәт бакчасы бик ерак, умарталарың быелга иске урында калып торсын, — диде эти. — Гел мөгез чыгарырга гына йөрисең. Болай да мәшәкатем муеннан.

— Мөгез чыгару түгел бу, эти, кортлар өчен әйбәт урын кирәк. Беренчедән, иске урында бик дымлы. Ә дымлы җирдә кортлар начар оча, табыш эзләргә көн җылынгач кына китәләр. Икенчедән, ул тирәдә баллы үсемлекләр юк. Ә Хаҗиәхмәт абзый бакчасы бөтен яктан уңайлы. Анда төрле-төрле җимеш агачлары үсә. Төрле агач төрле вакытта чәчәк ата, шуңа күрә кортларга өзлексез азык булып тора. Аннары анда урман якын. Ә беләсеңме, эти, ике-өч зур юкә агачы бер гектар карабодай чәчкәсе хәтле бал бирә ала. Безнең як урманнарында юкә тулып ята ич. Хаҗиәхмәт абзый бакчасына кыяр-кавын да утыртырга була. Бер гектар кыяр чәчкәсеннән утыз кило бал җыярга мөмкин.

— Синеңчә, бөтен җирдә бал тулып ята икән, кер дә ал. Ай-һай, кызым, бик зурдан кубарга маташасың. Биек сикерсәң, тәгәрәгәндә башыңны яруың бар.

— Ә син тәгәрәттермә. Тәгәрәсәм, тотып кал.

Әти белән апа ул көнне озак сөйләштеләр. Әле берсе, әле икенчесе кызып китте. Ахырдан эти умарталыкны Хаҗиәхмәт бакчасы янына күчерергә ризалашты. Апа озакка сузмый гына урын карап кайтты. Күченергә тотынганчы, шактый эш эшлисе барлыгы беленде, һәр умарта астына дүртәр казык кагарга, урынын чүп-чардан, аунап яткан агач-богачлардан чистартырга кирәк икән. Бигрәк тә апаның эчен пошырганы кырмыска оялары булды.

— Кырмыскалар бал кортларының әшәке дошманнары, — диде апа. — Алар умартаның бәләкәй генә ярыгыннан да керә һәм, ирек куйсаң, бөтен балны ашап бетерә. Умарталыкта кырмыска оясы булмаска тиеш.

— Ә нишләтергә соң аларны? — дип сорадым мин.

— Аларны бетерү юлы төрлечә инде, — диде апа. — Ояларына керосин сибәргә дә мөмкин...

— И, апа, кырмыскалар жәл бит. Әнә гел телевизордан кырмыскаларны файдалы дип әйтеп торалар.

— Урман өчен файдалы, ә менә бал кортлары өчен зарарлы.

— Алайса, урманга күчерергә кирәк аларны.

— Ничек итеп? Кырмыска бит ул сарык көтүе түгел, чыбыркылап куа алмыйсың.

— Биология укытучысы Җәүһәрия апа белән сөйләшеп карарга кирәк. Ул нишләтергә икәнен әйтер.

— Сөйләш әле, Фәйрүз акыллым.

Үзенә кирәк чакта апа да хәйләкәр, «акыллым» дип җибәрә. Кирәкмәгәндә бер сүз сорасаң, башың яшь, син тыгылмый тор, дия иде. Ярый инде, мин йомшак күңелле. Бик алай «акыллым»лап үтенгәч, Җәүһәрия апа белән сөйләшермен.

Хәер, бу юлы апа миннән алдарак үзе өлгергән булып чыкты. Бер ял көнне алтынчы класстан алып унынчыга кадәр барчабыз җыелып апаның умарталыгына киттек. Кулларда көрәк, носилкалар. Кырмыска ояларын иплэп кенә ян якларыннан казыйбыз да, нечкә билле хуҗаларны таратмаска тырышып, җире-ние белән носилкага салабыз. Кайберләребез ояларны урманга күчерә, кайберләребез агач күләгәсендә эреми калган карны тарата, кайсыларыбыз умарталар утыртыр өчен казыклар кага. Беркемгә дә тик торырга

вакыт юк. Ә иң ачылып йөргәне апа. Ни булган аңа? Аның бит бервакытта да болай җилкенгәне юк иде. Әллә әнә шулай итеп акылга утыралар микән?

Апаның кәефе шәплекне күреп, шаяртып куям:

— Каен тузыннан тубаллар да ясыйкмы, апа?

— Анысы нәрсәгә?

— Бәй, чәчәкләрдән балны кортларың ни белән ташыр? Олы тубалларны бүгеннән үк әзерләргә кирәк.

Апа көлә. Аңа күңелле, безгә дә күңелле. Аннан соң апа җитди итеп болай ди:

— Әле безгә, Фәйрүз, синең белән бал балансы төзәргә туры килер.

— Анысы нәрсә тагын? — дим.

— Анысы безнең җирләрдән күпме бал алырга мөмкинлеген исәпләп чыгару. Әйтик, менә бу урман кырык-илле гектар ди. Шундагы баллы үсемлекләрне исәплисең, ә һәр үсемлекнең күпме бал бирүе билгеле. Шуннан чыгып бал балансы төзелә. Умарталарны күпме үрчетү дә бал балансыннан чыгып эшләнергә тиеш.

Апаның сөйләгәннәре белән башка балалар да кызыксынды. Төрлесе төрле сораулар бирде. Ә апаны профессор диярсең, барысына җавап таба. Берсе: «Балны туксан төрле чиргә дәва дип әйтәләр, шулай булгач ни өчен больницаларда дару урынына бал гына бирмиләр?» — дигәч тә, апа аптырап калмады:

— Менә үзебезнең умарталар баллый башлагач, шулай итәрләр әле, — диде.

Көнебез күңелле үтте. Шундый кирәкле эш эшли алуыбызга шатланышып өйгә кайттык.

Таралышкан чакта апа:

— Җәй көне җыелышып бал ашарга килегез, — дип калды.

— Ай-һай, бу кадәр авызга җитәрлек балың булыр микән? — дидем.

— Булыр! — диде апа, нык ышанып.

Озакламый умарталарны подвалдан чыгарып, яңа урынга ташый башладылар. Чыгарган вакытта тагын ике баш умартаның корты үлгәне беленде. Апа Мәгъфурҗан абзыйга:

— Үз базыңдагылар үлмәгәндер әле, — диде. — Син бит аларны ашатасың.

— Минем базымда өч умарта, ә монда утыз, — диде Мәгъфурҗан абзый. — Ә син, кызый, артык сикеренмә әле. Кортлар алар һавага чыгаргач та бик һәйбәт үлә беләләр. Калганнары исән-сау тернәкләнеп китсә, шөкрана итеп кенә йөр.

Мәгъфурҗан абзый, әллә үз урынына кергәнгә, апага ачулы карый. Ике сүзнең берендә төрттерергә генә тора. Апа үзе генә эшли башласа, Мәгъфурҗан абзыйдан котылыр идек дип торганда, әти аны тагын умарталыкка китереп куйды.

Апа Мәгъфурҗан абзыйга каршы килде, бүтән кеше бир, диде.

Әти аңа:

— Синең утызга да тулмаган умартаңа ике кеше тиеш түгел, — дип каршы төште. — Мәгъфурҗан абзыйны мин сиңа ярдәмче итеп тә, начальник итеп тә җибәрмим. Каравылчы булыр. Аның бу эштә әз-мәз тәҗрибәсе бар. Кирәк чакта үзеңә киңәшен бирер. Балта эшләренә дә оста ул. Ә менә ярдәмче булып Фәйрүз барыр.

— Миңа зарплата язарсыңмы соң, әти?

Әти җавап урынына бармак кына янады. Акча турында күп сөйләшә башладың, янәсе. Мин бит аны юри генә үртим. Миңа хәзергә әти тапкан да җитә.

Умарталыкта балта тота белгән кеше бик кирәк икән шул. Көн саен кырык төрле эш чыгып тора. Җитмәсә, умартачы өен дә рәтләп сала алмадылар. Колхозның бер будкасын трактор белән сөйрәтеп китереп, аннан-моннан кадакладылар да, вәссәлам.

Апа:

— Ул тишек өйдә катып үләргәме әллә? — дип ризасызлыгын белдерде. — Бүгеннән рәтләсеннәр. Каравылчыга аерым бүлмә бүленсен. Вак-төякне куярга шкаф кирәк. Гомумән, умартачы өенә чебен-корт кермәскә тиеш. Анда бит балы да, балавызы да саклана. Бәлки, көн саен мин өйгә кайтып йөри алмам, кунарга туры килгәндә, туңарлык булмасын.

— Әнә мин сиңа Мәгъфурҗан абзыйны бирдем, теләсәң ничек уртак тел тап, — диде әти.

— Һәр эшләгән эшенә аерым түләмәсәң, табарсың аның белән уртак тел.

— Түләү мәсьәләсен соңыннан хәл итәрбез. Хәзергә кымшана торсын. Сиңа шуны әйтеп куям: гел миңа аркаланма. Үз башың бар, уйла. Син хәзер тулы хокуклы умартачы.

— Сиңа әйтми кемгә әйтим? Син бит председатель.

— Мине һәр колхозчы шулай аптырата башласа...

— Үзем булышырмын, — дип апаның кабыргасына төрттем. Мин алай төшеп калганнардан түгел. Әнә капка төбенә нинди җилле итеп эскәмия ясап куйдым, армиягә китәрлек егетләр менеп биесә дә сынмас. Ишекнең нәрсәсе бар аның? Төзәтербез. Будкаңны өр-яңа итәрбез.

Умарталыкта куна-төнә ятулар, төннәрен агачларның шомлы шаулавы, ябалакларның кинәт-кинәт кычкырулары күз алдыма килеп, күңелне җилкендереп җибәрде. Яратам мин серлелекне. Төннең кара авызына учак ягасың. Учакта йодрык-йодрык бәрәңгеләр пешә. Кайнар бәрәңгене сыек балга манчып ашыйсың. Балга? Кызык! Бәрәңгене бал белән ашыйлар микән? Шәп эшкә керде бит әле бу апа.

Хыяллану җиңел, эшкә тотынырга гына кул җитми. Башта укулар бетсен дип йөрдем, укулар беткәч тә, апа янына барырга һич вакыт табып булмый. Уеннарны калдырсаң, җәл. Өйдәге эштән качып китәр идең, әлегә эш кушмыйлар. Шулай да апага ярдәм итәргә кирәк. Ул мескен анда елап беткәндер инде. «Майор»га атландым да умарталыкка элдерттем. «Майор» юырта башлауга, кесәмдәге өтергеләр, чүкечләр бәрелешеп җырлашырга тотындылар. Аларның бер көйгә шакылдауларына йокымсырагандай иттем. Күз алдыма умарталык өе килде. Имеш, аның бер як стенасы череп ишелгән, ишеген җил каерып аткан. Эчкә ат башы хәтле чебеннәр тулган. Менә мин черек стенаны сыңар кулым белән күтәреп, астына имән терәүләр куям, ике сугуда ишеген кадаклыйм һәм юан күсәк белән чебеннәрне үтерергә керешәм...

Чебеннәргә сугам дип «Майор»га селтәнгәнмен икән, ул кинәт сыргып чаба башлады, шунда уянып киттем. Барып җитәргә бераз ара бар иде әле, аңынчы йокым бөтенләй ачылды.

— Апа, апа, ярдәмчең килә, каршы ал, — дип кычкырдым мин, умарталыкка якынлашуга. Апа урынына Мәгъфурҗан абзый килеп чыкты.

— Бал ашарга килдеңме? — диде ул.

— Бик исем китте балга. Беләсең килсә, мин эшләргә килдем. Менә өтергем, менә чүкечем.

— Алай, алай... Эшләргә, диген.

— Эшләргә шул. Кая, нәрсәдән тотыныйм?

Мин бу сорауны Мәгъфурҗан абзыйга түгел, апага бирдем. Ә ул, авызын ерып, Мәгъфурҗан абзыйга таба күрсәтте:

— Балта эшләре белән Мәгъфурҗан абзый командалык итә. Куллары алтын аның. Бар, кара әле, бер атна эчендә ниләр эшләде.

Мин будка эченә кердем. (Моннан соң мин аны келәт диярмен, чөнки умартачылыкта будкалар түгел, келәтләр генә була.)

Келәтнең эчке ягы ап-ак итеп шомартылган. Түшәмнәр тузан-туфрак коелмаслык итеп кысылган. Ишек тә ипле ябыла.

— Стеналарга кәгазь ябыштырырбыз, Фәйрүз. Килеп яхшы иттең әле.

— Кем эшләде боларны? — дип сорадым ападан.

— Мәгъфурҗан абзый.

— Шуңа ялындыңмы?

— Бер дә ялынмадым. Җаен гына таба белергә кирәк. — Апа хәйләкәр елмаеп куйды.

— Җае кайда иде соң аның, апа?

— Әллә ничек уйламаганда килеп чыкты бу, — дип сөйләп китте ул. — Беркөн аның юкә кабыгыннан кәрзин үреп утырганын күрдем дә исем китте. Шундый матур, базардагы кәрзиннәрең бер якта торсын. Мәгъфурҗан абзый минем сокланып карап торуымны күрде дә: «Ошыймы?» — дип сорады. «Ошамыймы соң» дим мин чын күңелдән. «Гап-гади юкә кабыгыннан шундый матур нәрсә эшләп буладыр дип башыма китермәгән идем». «Һы, — ди Мәгъфурҗан абзый, канәгатьләнеп, — матур дисең инде алайса? Ә менә матурлыкны күрә белмәүчеләр дә бар бит дөньяда. Элекке персидәтел чорында (авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең) умарталыкта өй салып куйган идем. Үземчә сырладым, матурладым. Өч ел тырыштым. Ә ул беркөнне шуны күреп алды да: «Син нәрсә, әллә әкияттән килдеңме? Моның белән гомереңне уздырганчы, умарталарыңны яхшылап кара. Умарталык өенә иске келәт ярамаган тагы!» — диде һәм өемне сүттереп, медпункт салдырды. Мин анысына каршы түгел, әйдә салсыннар. Әмма нигә инде челтәрләп эшләгән гәрничләрне, тәрәзә капкачларын алып атарга иде? Әйбернең бит аның матурлыгы бик бәләкәйдән тора. Өскә кигән күлмәкне генә алыйк: якасын ертып атсаң, нинди яме кала? Бөтен нәрсә дә шулай ул».

Мәгъфурҗан абзыйның шуннан соң күңеле катып киткән икән. Ә инде апаның ул ясаган әйбергә сокланып каравы күңел бозын эретә башлаган. Алар шулай бер-берләре белән уртак тел тапканнар. Хәзер әнә икәүләп җан-фәрман эшләп яткан көннәре. Апа колхоз пилорамыннан бер йөк такта китерткән. Мәгъфурҗан абзый шул такталарны пыран-заран китереп юна. Кайсыннан умарталар өчен рам, кайсыннан башка кирәк-яракны ясый. Ә умарталыкка күп нәрсә кирәк икән. Аерган күчне ябып куярга корт тубаллары дисеңме, тагын әллә нәрсәләр шунда.

Апа үзе дә тик ятмый, умарталарын чистарта, ашарларына куя. Язын әйбәт караганда гына кортлардан бал өмет итәргә мөмкин, ди. Умарталыкка яңалык та керткән әле ул. Колхоз амбары янында аунап ята торган бер иске үлчәүне төзәттереп алып, шуны монда китереп, бер умартасын әнә шул үлчәү өстенә утырткан. «Бу безнең контроль умарта булачак. Кортларның һәр көн күпме бал җыюларын шуңарга карап белербез», — ди. Мәгъфурҗан абзый башын чайкый: «Укыган кеше укыган кеше шул, мин юләр башым белән уйлап, көн саен диярлек умарталарны ачып тикшерә идем. Җайлы гына белеп була икән ләбаса», — ди. Апа аңа: «Мин чыгарган яңалык түгел, китапта шулай язылган», — дип аңлата.

Апа белән Мәгъфурҗан абзый янына мин дә килеп кушылгач, эшләр гөрләп китте. Гөрләми карасын, без бит ул. Балта-пычкының кайсы башыннан тотарга беләбез. Тик шунысы яманрак: кайтып-китеп йөрергә ерак. Үзем өчен кайгырмыйм, минем «Майор» бар. Атлан да чап. Апага җайсыз. Сигез-ун чакрымны көн саен терек-терек. Мәгъфурҗан абзый каравылчы кеше, ул көн саен кайтып йөрми. Умарталык келәтен рәтләп бетерү белән түшәк-ястыгын китереп куйды. Их, лотереяга берәр машина отып җибәрсәм, апаны һәр көн выжлатып алып кайтыр идем.

Ә хәзергә минем велосипед белән йөри торырга була. Өйрәнсен әнә. Җәйге юлдан велосипед белән элдертүгә ни җитә? Рәхәт җылы җил куеныңа керә, битләреңне рәшә юа, колагыңда тургай тавышлары яңгырый. Кызу барганда миңа бөтен нәрсә җырлыйдыр кебек тоела, үзем дә әнә шул гомуми җырга кушылып шыңшырга яратам. Андый вакытта синең үз тавышың ерактан ишетеләдер кебек, кайвакыт көй сузудан туктагач та, колак төбендә җыр дәвам итә. Ахры, җилләр син туктаганны сизми калалар да син булып көй көйлиләрдер.

Апаның велосипедта йөргәне юк иде. Мин аны беркөнне алдыма утыртып алып бардым да, яңадан килгәнче өйрәнә тор дип, велосипедымны калдырып киттем.

Ул көнне апа өйгә кайтмады, умарталыгында кунды. Икенче көнне барсам, ни күзләрем белән күрим, апаның маңгае күпкән, күз кабаклары салынган, беләкләре тырналган. Ни булганын сорап маташмадым, болай да бөтенесе аңлашылды: минем корыч айгырдан егылган. Ләкин мин апага караганда велосипедымны ныграк җәлләдем, чөнки аның алгы тәгәрмәче сигезлегә охшатып пешергән крендельгә әйләнгән, руле сөзешә-сөзешә сыңар мөгезен сындырган кәҗә тәкәсен хәтерләтә, педале кәкрәйгән.

— Әллә Көймә тавыннан төштеңме? — дидем. Умарталыктан төньяктарак Көймә тавы дип йөртелә торган тау бар. Аның түбәсендә каплап куелган көймәгә охшашлы таш ятканлыктан, тауны шулай атыйлар.

— Өйрәнеп җиткәч кенә велосипед ватылды, — диде апа, минем сорауга җавап бирмичә. — Төзәтә алырсың микән, Фәйрүз энем?

Энем сүзе чыккач, аңлап алдым, димәк, велосипед аңа бик кирәк.

— Маташып карармын, әмма бушка түгел, туйганчы бал ашатырсың.

— Һи, сиңа туярга күпме генә бал кирәк соң? — диде апа.

Тиз генә велосипедымны сүтеп ташладым. Тәгәрмәчне тарттырган һәр тимерчыбыкны сүтеп, кыршавын тезем белән төзәттем. Рулен агач бүкәнгә салып төйдем, педален келәт почмагына кыстырып турайттым. Көне буе маташсам маташтым, велосипедны бер дигән иттем.

— Апа, давай бер тәпән балыңны!

— Без бит бер тәпән дип сөйләшмәдек. Туйганчы ашарга менә шушы җитмәсме әле. — Апа минем алга кәрәзле бал куйды. Тәлинкәдә өелеп торган аксыл-сары кәрәзләрне күрү белән комсызланып ашарга керештем. Шундый тәмле, телеңне йотарсың. Кәрәзне чәйнәгән саен, сыгылып-сыгылып бал чыга. Мәңге туймам кебек.

— Кортлар бал җыя башладымыни инде, апа?

— Әйе, әле менә умарталарны чистарттым, ашарларына куйган улак тирәләрен кәрәз белән сарып бетергәннәр, шуларны кырып алдым. Хәзер табигатьтә балавыз вакыты, бушрак урынны кортлар балавыз белән тутырырга гына торалар.

— Мине дә умарта карарга өйрәтерсең әле, апа.

— Үзем дә шулай дип торам. Озакламый күч аера башларлар, бер кешегә бик кыен. Мәгъфурҗан абзыйга гел-гел әйтү уңайсыз. Ул каравылчы бит. Болай да инде балта эшләрен гел ул эшли.

— Нигә соң этидән кеше сорамыйсың?

— Умарталар әз, шуңа штатта кеше каралмаган. Дөресен әйткәндә, минем кешесез генә эшләп карыйсым килә. Үзең — баш, үзең — койрык.

Балдан мәңге туймам төсле иде, тәлинкәнең яртысына җитмәдем, тамак төбен әчеттерә башлады. Шулай да, мондый хөрмәт көн дә тимәс дип, баллы кәрәзләрне авызга тутырыпмы-тутырам. Ә бераздан авыраеп киттем, күзләремнән яшь атылып чыкты, баш әйләнү сиздем. Үлгәнче туктарга кирәк дип, тәлинкәне читкәрәк этеп куйдым.

Апа кыстый:

— Бетәр дип курыкма, хәзер сиңа җитәрлек кенә бал булыр инде, — ди.

— Быел көннәр матур, чәчәкләрдә бал күп. Кортлар бик теләп очалар, буш кайтмыйлар төсле.

— Кортлар балны кая салып алып кайта, апа? Аларның кесәләре юк бит.

— Түшләрендә бал казаннары бар аларның, аны бал бүксәсе дә, диләр. Чәчәкләрдәге нектарны борыннары белән суырып шул бүксәгә тутыралар. Ә чәчәк серкәләрен җыярга арткы тәпиләрендә кесә сыман нәрсәләре бар. Кырдан очып кайткан кортларны карасаң, арткы тәпиләре сап-сары булыр. Гөлдән гөлгә очып йөри-йөри бал кортлары серкәгә, нектарга буялып бетәләр. Үзләренә буялган серкәләрдән арыну өчен алар тәннәрен щеткалыйлар. Әйе, әйе, бал кортының бөтен гардеробы үзе белән йөри. Бер корт үзе бер фабрика ул, энем. Ул фабрика гел эшләп тора. Корт очып кайтканда ук нектарны балга әйләндерә башлый. Нектарны бал итә торган сыекча бар аларда. Шулай да әле чәчәк ширбәте тиз генә балга әверелми. Анда су күп була. Судан арындырыр өчен алар балны кәрәз төбенә әзләп-әзләп кенә салалар. Өйдәге яшь кортлар, канатлары ныгып җиткәнче җилпенеп умарта эчен җилләтәләр, балның суын парга әйләндерәләр. Кортлар алар кеше шикелле акыллы, һәр эшне үзара бүлешеп эшли. Аналарын да бик нык тәрбиялиләр. Анасыз умарта — ятим умарта. Анасын югалтса, картлар табыш җыюдан туктый, гаиләдә таркаулык башлана.

Апа күп кенә кызыклы нәрсәләр сөйләде. Бал кортлары турында ул көне буе сөйләргә әзер. Миңа иң мәзәк тоелганы шул булды: умарта кортының биш күзе бар, ди. Әйтәм, ул дошманын бик тиз күреп ала. Менә эш нәрсәдә икән!

Бал кортлары турында күбрәк мәгълүмат белгән саен, минем кызыксынуым арта бара. Инде без апа белән икәүләп умарталар да караштыргалыйбыз. Дөрес, мин төтен җибәреп кенә торам. Апа куркудан чырылдый-чырылдый рамнарны карый. Күгәргән кәрәзләрне яңага алыштыра. «Кортлар пычраклыкны бер дә яратмый», — ди.

Соңгы вакытта көннәр бик матураеп китте. Без умарталыкта кунып кала башладык. Кояшбикә, без йокыдан торганчы ук, алсу күлмәген киеп тау башына менеп баса да җем-җем тешләрен күрсәтеп урманга карый. Кояшбикәгә матуррак күренер өчен купшы юкәләр яфрак колакларына чәчәк алкалар тага. Ул алкаларны җил малайлары агач саен менеп селкетеп йөри. Җилләр кагылып киткән юкәләрдән тирә-юньгә бал исе тарала. Иртәрәк йокысын ачкан кортлар урманга разведкага китә һәм юкә чәчәкләренә сокланып җырларга тотыналар. Разведчиклар җырына башка кортлар да уяна. Менә бермәлне урман эче тоташ концертка әйләнә. Җилләр әкрен генә думбра чиртә, кортлар чәчәктән чәчәккә кунып бии, яфраклар кул чаба. Бу күңелле концертны күреп, Кояшбикәнең күңеле тагын да күтәрелә. Ул офык баскычларыннан һаман саен өскәрәк менә, тамашаның иң кызык җирен күрми калудан курка, ахры.

Менә шундый кызу көннәрнең берсендә умарталыкта да тамаша башланды. Кортлар үз өйләренә генә сыеша алмыйча, аерырга тотындылар. Апа иртән кайбер оядагы кортларның аеруча нык гөжләүләренә игътибар иткән иде. Шуңа күрә күч яба торган тубалны, төтәсләгечне һәм башка коралларны әзерләп куйды. Мин инде хәзер үз вазифамны яхшы беләм: төтен җибәргечкә ягарга коры черек, агач гөмбәсе ише нәрсәләрне ел буена җитәрлек итеп ташыдым. Ләкин әле кортлар аерганын гына күргәнем юк. Сары умарта алдында кортлар бөтерелә башлау белән бер куак артына постым. Күч аерганда кортлар кызык кына кылана икән — башта бер төркеме чыгып очып йөри, тирә-якны күзәтә, һава торышы белән таныша да кире кереп китә. Алар кереп озак та үтми, башкалары өерелеп чыга (бәлки, шулары уктыр, колакларына тамга салынмаган). Менә бервакыт бөтен умарта алды чуп-чуар корт була. Ниндидер сихергә буйсынган шикелле, кортлар үзләре генә белгән түгәрәкләр ясап биешәләр. Аерыласы күч бөтенләе белән чыгып беткәч кенә, үзләренә сарыр агач эзлиләр.

Апа миңа күчнең кая сарганын карап торырга кушкан иде, күч очып киткән якка йөгердем. Һавага карап бара торгач, бер умартага чак бәрелмәдем, ярый әле бер корт маңгайга угын батырып кисәтеп куйды. Юкса умартага бәрелсәң, кычытмаган җирләреңне кашып җибәрерләр иде. Маңгайны уып маташкан чагымда, теге күчем юкка чыкты. Эзли-эзли ах иттем. Бер усак ботагына сарган икән. Яңадан югалтмас өчен усак ботагына печән бәйләдем дә апа янына чаптым. Аның анда тагын бер умартасы аерып маташа икән. Ашыкмаска кушты.

— Куркытмасаң, бер сарган күч ике-өч сәгать тыныч кына тора әле ул, — диде. — Менә бусы аерылып чыксын да, аннан җыя башларбыз.

Ашыкмаска икән ашыкмаска! Пулемет авызыннан сибелгәндәй умарта авызыннан атылып чыккан кортларны куак артына качып күзәтеп ятуы кыенмыни? Ә менә күчләрне ничек җыярбыз икән? Апа үзе агач башына менә алмый инде, уйлыйсы да юк. Димәк, бу эш миңа кала. Минем корттан котым оча. Апага ярдәм итәргә чыксам да бөтен җиремне кат-кат төтенлим. Чалбар балакларын, җиң очларын ныклап бәйлим. Мин генә түгел, апа да шулай итә. Ә беркөн битлек астыннан аның чәч толымы чыгып калган да,

кортлар тузгый башлау белән апаның толым астыннан тегеләр берәм-берәм үрмәләп керергә тотынганнар. Берсе муенын, берсе җилкә чокырын, берсе ияген үбә башлагач, кулындагы рамын миңа бирде дә, «үләм-үләм» дип кычкыра-кычкыра, келәткә йөгерде. Ярый ла ул качып котылды, ә мин нишләргә тиеш? Минем тәнем тимердән түгел, бармак очларым утлы күмер чүпләгәндәй пешә. Кулда рам, төтен җибәрергә җай юк. Үлле-мәлле умартаны ябып келәткә чаптым, кортлар минем арттан куа килделәр. Атылып килгән уңайга ишеккә барып бәрелсәм, ишек бикле. Эчтән апаның елак тавышы ишетелде:

— Керми тор әле, Фәйрүз, мин бөтенләй чишенеп ташладым. Тагаракта суык су эчендә утырам.

Үземнең хәл мөшкел булмаса, ападан рәхәтләнеп көлә идем инде. Ләкин үземнең дә чалбар бәйләгән урыннарга кадәр әрнергә тотынды. Баштарак кызулыгым белән чагуларын сизмәгәнмен, ахры. Бөтен тәнемә кызамык чыккан кебек.

Ишекне ачтыра алмагач, битлекне салып ыргыттым да чишмә буена киттем. Салкын чишмә суы белән тәнемне озак итеп юганнан соң гына әрнү бераз басылды. Чишмә буеннан кайтып керсәм, ни күрим, апа толымнарын кисеп аткан. Идәндә елан сыман сузылып ята торган ике толымны күргәч, тәннәрем чымырдап китте.

— Нишләдең син, апа? — дидем ачуланып та, гаҗәпләнеп тә.

— Умартачыга толымнар кирәкми икән, — диде апа, ә үзе гаепле кеше сыман читкә борылды. Күреп торам: күзләреннән мөлдерәп-мөлдерәп яшь тама. Чәче аның горурлыгы иде бит. Кисүен дә рәтләп кисмәгән әле, бер толымы озын, берсе кыска.

Кесәмдә ватык көзге кисәге бар иде, корсакка ышкып апаның йөзенә китердем.

— Кыяфәтеңне кара әле. Мунча пәрие төсле булгансың.

Апа башта куркынып артка чигенде, аннары тәгәрәп-тәгәрәп көләргә тотынды. Һич тыела алмый, әйтерсең көлке бүлмәсенә кергән. Әнә шулай тыела алмый көлеп ятканда, йомшак кына итеп ишек477 кактылар. Кем булыр бу? Мәгъфурҗан абзый, сез монда кунган чакта, бәрәңге бакчаларын уаштырыйм, дип кайтып киткән иде.

— Ачма, Фәйрүз, — диде апа.

— Ачмыйча ярамый инде, апа. Бәлки, әни килгәндер.

— Бу кыяфәт белән әнигә дә күренергә ярамый.

Ишекне яңадан кактылар. Бу юлы инде шакылдау таләпчәнрәк ишетелде.

— Рәйханә туташ, Рәйханә туташ!

— Тургай абый килгән, — дидем мин, шатланып, һәм җәһәт атлап ишеккә юнәлдем.

— Ачма! — Апа минем юлыма аркылы төште, шешенгән битләре каушаудан тимгел-тимгел булып чыкты. — Кертмә.

— Кеше районнан тикле килсен дә, ничек кертмисең инде.

— Әнә бик сагынсаң үзең чык.

Мин, тупсага җиткәч, артка борылып карадым һәм апаның сагышлы, үкенүле күзләрен күрдем. Гүя алар: «Их, берәр көн алдарак килгән булсаңчы!» — дип әйтәләр иде.

— Рәйханә туташ юкмы әллә? — диде Тургай абый, чыга-чыгышка.

— Ба... Ә, ни... югые шул.

Минем бу хәбәрдән соң Тургай абый суга төшкән чебештәй мескенләнеп калды.

— Ах, кызганыч, кызганыч!

Нәрсәнең кызганыч икәнен төшенеп җитмәсәм дә, аның сүзен җөпләп баш кактым. Бу минутта бар нәрсәдән кызганычрак Тургай абый үзе иде.

— Тургай абый, — дидем мин, — әйтәсе сүзе булса, Рәйханә апа миңа әйтсен, диде. Мин аңа тапшырырмын.

— Сиңа? Минем килеремне белгәнме Рәйханә туташ?

— Белгән, белгән. Ул гел сине көтеп торды.

Тургай абый, ышаныргамы-юкмы дигән күк, миңа текәлде. Ялганым тотылмасын өчен, мин мөмкин кадәр аңа турырак карарга тырыштым. Сүзебезне Рәйханә апаның да ишетеп торуы бар иде, Тургай абыйны келәттән читкәрәк алып киттем. Рәйханә апа белән Тургай абыйның бер-берләренә ниндидер сәер мөнәсәбәттә йөрүләрен күңелем белән сизенә идем. Икесенә дә ярдәм итәсем килде.

— Рәйханә апаның телендә гел син генә, — дип дәвам иттем мин, үз ялганыма үзем ышанып. — Нишләп һаман килми икән дип, мине аптыратып бетерә.

Тургай абый тәмам җилкенеп китте. Пинжәк изүләрен ачып җибәрде. Шунда аның эчке кесәсендәге блокноты күренеп китте.

— Фәйрүз акыллым, менә бу дәфтәрне Рәйханә туташка бирерсез әле, — дип, ул блокнотны алып миңа бирде.

— Бирермен, Тургай абый. Рәйханә апа үзе дә дәфтәрен алып...

— Нәрсә?

— Ә, юк, Тургай абый, бу дәфтәрне алып калган өчен апа минем ике битемнән пәп итеп үбәр инде, дим.

Тургай абый китеп барды, мин дәфтәрне апага алып керим дип торганда, ул кире борылды да:

— Фәйрүз, — диде, — мин бит Рәйханә туташка менә нәрсә әйтмәкче идем...

— Нәрсә?

— Без, ягъни мәсәлән район үзешчәннәре, сабан туенда концерт куярга әзерләнә идек. Рәйханә туташ җыр белән катнашмас микән?

— Катнашыр, катнашыр, Тургай абый. Ул аңа атлыгып тора.

Рәйханә апа янына атылып килеп кердем дә, борын төбенә китереп, Тургай абыйның блокнотын болгадым.

— Бие, биесәң бирәм.

— Кыланма инде, бала-чага. — «Бала-чага» дигәнгә минем ачуым килгәнне белә ул, юри ачуымны чыгарырга маташа.

— Биемәсәң, җырла!

Апа ялт кына кулдагы блокнотны эләктермәкче булды. Болай да эш чыкмагач:

— Бик кирәге бар иде, — дип турсаеп читкә борылды.

— Беләсеңме монда нәрсә? — дидем мин, аның күңелен ярсытыр өчен.

— Белмим дә, белергә дә теләмим.

— Теләрсең. Тургай абый әйтә, мин, ди, Рәйханә туташны сагынып үләм инде, ди.

— И җил тегермәне! Корыга тел әйләндерәсең.

— Син Тургай абыйны үзең күрсәң иде. Чыраенда адәм кыяфәте калмаган: йөзләре сары балавыз, иреннәре кипкән яфрак. Ул мескен, яшәсә, яңадан бер-ике атна яшәр. Әгәр дә, ди, Рәйханә туташ район сабан туенда җырларга килмәсә, бәхил булыгыз, ди.

— Җитте! Юньләп сөйлә, клоунланма! — Апа чын-чынлап мине ачуланып ташлады. Мин, аның күңелен йомшартыйм дип, Тургай абыйның шигырьләрен бирдем.

Ләкин апа миңа ныклап үпкәләгән булып чыкты. Умарталар бер-бер артлы аерып, күчләр җыясы булмаса, тагын бераз турсаеп йөри иде әле ул. Ләкин бал кортларын горурланып, тәкәбберләнеп куркыта алмыйсың. Агач башына сарган күчне күргәч, апа эреп китте:

— Фәйрүз үскәнем, син генә җыеп төш инде, мин менсәм йә агач сынып китәр, бигрәк нечкә ботакка сарган, — дип, тубалын кулыма китереп тоттырды. Хәйләсен таба үзе, агач сынар, имеш. Ә минем мыжлап торган күчне күрүгә бөтен тәнем кычыта башлаганны белми ул. Берәр төрле хәйлә табып котыласы иде күч җыюдан.

— Әйдә, апа, агачны гына кисәбез. Җирдә рәхәтләнеп утырып җыярсың, — дидем мин.

— Алай кортны туздырырга ярыймыни? Аерган корт сирәк чага ул, курыкма. Анасын тубалга төшерсәң, калганнары аның артыннан үзләре үк керер.

— Корт анасын гомеремдә күргәнем юк бит минем.

— Ул бүтәннәрдән зуррак, нәзегрәк билле һәм бик хәрәкәтчән булыр.

Бу кадәр аңлатудан соң ничек карышасың инде? Төтәсләгечне бер кулга, корт тубалын аркага асып, агач кашыкны кесәгә тыктым да менеп киттем. Кашыкны бал ашарга дип уйламагыз, кортларны шуның белән тутыралар. Мин менә башлауга ук, кортлар тынычсызланырга тотынды, чөнки агач нәзек: ботагына баскан саен, бизгәк тоткан кешедәй дер-дер калтырый иде. Бил каешы белән үземне агачка бәйләп эшкә керештем. Исәбем, апа әйткәнчә, күчнең анасын табып тубалга җитәкләп кертү дә җайлы гына котылу. Ләкин астан өйрәтүе генә җиңел, мыжлап торган корт арасыннан табарсың корт аналарын. Бусы зуррак бугай дип, әле берсен, әле икенчесен кабыкка салам. Күч эченә кашыкны ешрак кертеп болгаткан саен кортларым ныграк тынычсызлана. Кайберәүләрем минем бармак башын кабып карарга да өлгерделәр инде. Мин үземне булачак егет кеше дип кенә түзәм. Югыйсә акыр да ела.

Күпме генә эзләсәм дә, анасын тапмадым. «Аларның аналарында минем ни эшем бар» дип җәһәт-җәһәт күчне тубалга тутырырга тотындым. Инде эш төгәлләнеп килә дигәндә генә, тубалны элеп куйган ботагым сынды да бөтенесе җәһәннәмгә очты. Җәһәннәмгә генә очса тагын бер хәл иде, апаны да, мине дә корт сырып алды. Корт түгел, һава керерлек тә тишек калмагандыр дигән идем, әллә кайлардан таптылар керер җирне. Өстәвенә билдән алдырып бәйләгән каешым чияләнгән. Апага: «Пычак алып чык», — дип кычкырдым. Ә ул йөзтүбән капланган да селкенми дә ята. Ахырда битлегемне салып, каешны тешләрем белән чишәргә туры килде. Мин каешны чишкән арада, бер-икесе иреннең йомшаклыгын татып карарга өлгерде. Никадәр тырышсак та, таралган күчне яңадан җыя алмадык.

— Бер күч югалганга исең китмәсен, — дип юатырга тырыштым мин апаны. — Ул сарык кебек санаулы түгел. Беркем белмәс.

— Хикмәт кешеләр белүдәмени, — дип көрсенде апа.

Кич белән без җыйган күчләрне яңа умарталарга япкач, урман буенда учак тергезеп җибәрдек. Көлгә күп итеп бәрәңге күмдек. Ә үзебезнең бәрәңге әрчерлек тә рәтебез калмаган. Бармак башлары чәнчеп-чәнчеп авырта. Апа минем кыйшайган авызга карый да көлә:

— Шушы килеш кайтып керсәң, әниләр таныр иде микән?

— Ә син үзеңне күр, үзеңне. Битең күмәч хәтле булган.

Күч җыйганда апаның битен корт чакмаган иде. Мин аны кызык иттем, битлеген салып, юынып-киенеп кергәч кенә якасына баллы балавыз ябыштырдым. Бал исен кортлар әллә каян сизә, шул арада тәрәзәдәге бер корт апаны «күчтәнәч» белән сыйлап китте. Бите шешмәсә, авылга кайтам, дияр иде әле. Минем хәзер авылга кайтасым килми, чөнки бәрәңге бакчасындагы алабуталар мине көтеп елап утыра.

Шундый мәшәкатьләр белән көннәр уза торды. Кортлар балны чиләкләп үк ташымасалар да, ярыйсы ук тырышалар.

Апа контроль умартага карый да сөенеп куя:

— Күрәсеңме, Фәйрүз, авырая бит! Әгәр башкалары да шушылай табыш җыйса, без быел балны шәп алабыз, энем!

Минем дә күңел күтәренке. Бу уңышка бит минем хезмәт тә кергән. Әзме кортлардан чактырдым. Әле менә никадәр умартага магазиннар куеп чыктык. Чәчәктә бал барында магазин куярга өлгермәсәң, кортлар эшсез кала. Ә бер тәүлектә бер гаилә корт сигез-унике кило бал җыя ала. Утыз умартадан һәрберсе берәр көн генә эшсез торса да, өч йөз кило бал югалтасың.

Апаның иң нык эчен пошырган нәрсә шул: умарталар һаман аера, ә аерылган умартадан бал көтмә инде. Ул үзен туйдырырлык та азык әзерли алмый. Ел буена бер гаилә корт никадәр бал ашый бит.

Күчкә аерылып хәлсезләнмәсеннәр өчен, апа аерылып чыккан кортларны кире үз умарталарына яба башлады. Болай эшләү аңа ике яклап файда китерде: беренчедән, умарта эчендә эшче корт күбәйде, икенчедән, картайган корт аналарын яшьрәкләргә алмаштырырга мөмкинлек туды. Корт анасы картайдымы, умартаның рәте китә икән. Бары тик соры кортлар гына туа башлый. Бал кортларында әле һаман капиталистик система яши, ахры. Шулай булмаганда соры кортларны ашатып яткырмаслар иде. Хәер, көчле умарталар көз көне революция ясыйлар ди. Соры кортларны өйләреннән куып чыгарып, эшче кортлар үз диктатураларын урнаштыралар. Хәлсез гаиләләрнең генә моңарга көче җитми икән. Ә кышлыкка кергәндә, умартада соры корт калдымы — исән чыгуларын өмет итмә инде. Бал запасын шунда ук ашап бетерәләр дә умартаны һәлак итәләр.

Сабан туйлары да килеп җитте. Умарталыкта Мәгъфурҗан абзыйны калдырып, авылга кайтып киттек.

— Умартаның бөтен балын ашап бетермәсә инде ул, — дидем апага. Нигәдер Мәгъфурҗан абзыйны якын итә алмый идем мин.

— Юләр! — диде апа. — Ул умарталар өчен синнән-миннән ныграк кайгыра әле.

— Кайгырса, бик әйбәт, тиз генә бармабыз.

Авылга кайткач, умарталык истән чыкты. Бөтен авыл гөр килеп тора. Кемгә генә кермә — кунак-төшем. Мичләрдә чаж-чож кабартма, коймак пешә. Гөлбәчтә ачы бал мичкәләре чыжлый. Матур киенгән абзыйлар кеше саен кереп сөлге, кулъяулык җыеп йөри. Бер кызыл башлы сөлгене озын колгага бәйләгәннәр дә байрак сыман итеп күтәргәннәр. Аларга бала-чага ияргән. Урамның әле бер башында, әле икенче башында гармун сыздырганнары ишетелә.

Һәр елдагы кебек быел да сабан туе алдынгыларны бүләкләүдән башланды. Безнең өй эченнән генә беркемне дә андый бәхет көтми иде. Әти председатель булгач, үзен үзе бүләкли алмый. Әни — врач, район кешесе санала. Врачларга премия дә, бүләк тә юк. Менә Рәйханә апага хет берәр яулык бирсәләр ярап куяр иде. Җәй башыннан бирле умарталыкта куна-төнә ята бит. Әле бу юлы кайткач та әни үзенә:

— Синең бернәрсәгә дә болай ябышып ятканың юк иде, кортларны ошаттың, хәерлегә булсын, — диде. — Ләкин син анда үзеңнең өс-башыңның чисталыгы турында онытма. Кыз баланың матурлыгы — чисталыкта.

— Әй, әни, без анда Фәйрүз белән менә дигән душ ясап җибәрдек, көненә икешәр тапкыр юынабыз. Керләнеп йөргәнне кортлар кешеләргә караганда да яратмый.

Әйе, душ шәп шул безнең. Бер зур мичкәне келәтнең түбәсенә менгереп куйдык та шуны көн саен чишмә суы белән тутырабыз. Кояшта су шундый шәп җылына, мунчаң бер якта торсын.

Апа район сабан туендагы концертта да катнашты. Әй, Тургай абыйның сөенгәнен күрсәгез иде. Хорга дирижерлык иткәндә, кулларын селтәп-селтәп җибәрә, әйтерсең очарга талпынган кош. Йөзләгән кеше

аның хәрәкәтен күзәтә. Миңа калса, ул көнне иң бирелеп җырлаган кеше апа булды. Ә сабантуйлар үткәч, ул шактый вакыт боегып та йөрде. Авылдан бик китәсе килми иде, ахры.

Мин дә әллә ни ашкынып тормый идем. Ләкин эти машина белән илтеп куям дигәч, карышмадым, җыена башладым. Әни безнең сумкага тәмле-тәмле ризыклар тутырды. Мин баздан берничә чиләк бәрәңге алып мендем: кырда аннан да тәмле нәрсә юк. Апа авторучкасына кара суыртты. Аның умарталык дәфтәре бар. Кайсы умартаны кайчан караганын, кортларның ни хәлдә икәнлеген җентекләп язып бара. Хәтта кайсы үсемлекнең нинди көнне чәчәк атканын да теркәп куя.

Без югында умарталыкта үзгәреш булмаган. Мәгъфурҗан абзый: «Менә барысы да исән», — дип апага умарталарны күрсәтеп йөрде. Эти дә аларга иярде. Көн әкәмәт кыздыра иде, минем кояшка чыгып йөрисем килмәде. Келәт күләгәсенә сузылып ятып, «Нәни принц» китабын укый башладым. Ләкин миңа нәни принц белән озак сәяхәт итәргә туры килмәде, апаның:

— Фәйрүз үскәнем, чишмәдән салкын су алып кайт әле, — дигән тавышы укуымны бүлдерде.

— Әллә баллап чәй эчәбезме? — дидем мин, шаяртып.

— Эчәрбез. Менә эти бал ашап карасын әле.

— Алайса очтым. Мин чишмәдән кайтканчы, балыңны ала тор.

Умарта караганда төтен өрдергеч гел миңа йөкләнгәнлектән, бу эштән котылу өчен чишмә янында озаграк тоткарланырга тырыштым. Башта күлмәгемне салып рәхәтләнеп юындым, аннары чишмә буендагы тал ботагында атындым, шуннан соң гына кайтырга чыктым. Мин кайтканда, апа капрон табакны тутырып кәрәзле бал алып куйган иде. Авызымнан сулар килеп китте.

— Оһо, — дидем мин, кулларымны угалап, — этине сыйлыйбыз икән.

— Әтидән бигрәк үзеңнең сыйланасың килә бугай әле, — диде апа.

— Монда барыбызга да җитәрлек күренә, — диде эти.

Әтигә бал белән мактанасым килә иде, апаның юмартланып табак тутырып алуына бик шатландым.

Озакламый чәй кайнап чыкты. Җыйнаулашып табынга утырыштык. Мәгъфурҗан абзый түгәрәк ипине түшенә терәп, зур-зур телемнәргә кискәләде һәм, бисмилласын әйтеп, коелган валчыкларны җыеп капты. Мин турыдан балга үрелдем.

Әти пычак очына эләктереп кәрәзле бал алып капты һәм безгә карап хәйләкәр елмайды:

— Әйтәм аны, өйгә кайтмый башладыгыз, монда эшләр көйләнгән икән сезнең. Без әнкәгез белән кайгырабыз тагын, ач ятмыйлармы болар, дибез.

— И, безнең бал ашый башлаганга биш былтыр инде. Әйеме, апа, — дидем мин, этинең сүзләренә бик канәгатьләнеп. Апа астыртын көлемсерәп куйды, ләкин минем ялганымны тоттырмады. Балны күптән ашый башлаганга этине ныклап ышандыру өчен, балга дип үрелгән кашыгымны ярты юлда туктатып калдым.

— Аша, аша! — диде эти. — Үзегезнең хәзинә бит.

— Туеп беткән инде аннан. Балсыз чәйгә ни җитә.

Балны күзем күрмәсен дип, чынаягыма капланып, коры чәйне чөмерергә тотындым. «Табакта бал җитәрлек, эти киткәчтен дә ашап була ич аны».

Әти безне мактый-мактый бал ашады. Минем этигә мөмкин кадәр балны күбрәк ашатасым килә, шул ук вакытта табактагысын киметәсе дә килми иде. Һәр кеше күрсен өчен, мин аны табагы белән тәрәзә төбендә генә тотар идем.

Чәй эчеп туйгач, эти китәргә җыена башлады. Шул вакыт апа аны туктатты.

— Бусын әнигә күчтәнәчкә алып кит, эти, — дип, табакта калган балны банкага тутырып этигә сузды. Мин ашап туймаган булсам да, әнигә җибәрергә каршы түгел идем. «Әйдә, әни күрсен безнең нишләп йөргәнне. Юкка гына кортлардан чактыра-чактыра ятабызмыни без?!»

— Нык кунак иттегез әле сез, — диде эти. — Рәхмәт, рәхмәт!

— Хәзер анлык кына бал бар инде, эти, — диде апа.

— Умарталарны суыртсаң, һәрберсендә яртышар тәпән бал бардыр, — дип өстәдем мин.

Эти китте. Ул киткәч, бер мәлгә күңелсез булып калды. Умарталыкта тагын шул ук эшләр башланды. Өйгә дә кайтасы килми, анда һаман бәрәңге бакчасы уталып бетмәгән. Шулай да авылда шәптер. Малайлар көне буе Ыкта су керәләрдер, ә син ярты кашык балга алданып шушында ят инде. Хәер, эш балда гына түгел. Монда кызык үзе, тик менә иптәш малайларның мине күрмәве кызганыч. Мәктәпкә баргач, мине быел мең корт чакты дип сөйләсәм, ышанмаслар әле. Их, битләр табактай шешенгән көнне рәсемгә төшәсем калган. Кирәк чакта гына төшерүчесе дә юк шул аның. Корт чаккан саен фотога төшеп булмый. Әтидән бер фотоаппарат алдырырга кирәк. Умарталар баллап китсә, бәлки, минем үземә дә фотоаппаратлык кына тияр әле.

— Апа, — дидем мин, уйларымны дәвам итеп, — сиңа аена ничә сум түлиләр?

— Сиңа күпме түләсәләр, миңа да шулай.

— Юк, апа. Син бит йөз процентлы умартачы. Умарталарны подвалдан чыгарган көннән исәпли башласак, ике айдан артып киткән. Һо, апа, синең идарәдә акчаларың җыелып, кассаларына сыймый башлагандыр инде.

— Телеңә салынма, Фәйрүз.

— Чынлап, апа, нигә барып алмыйсың син акчаңны?

— Кит әле, оялмыйча.

— И, исәр. Акча алырга оялалар димени?

— Тиеш түгелне алырга оялалар да.

— Нишләп тиеш булмасын? — Минем ачуым килде. — Без монда күпме чиләнәбез. Куна-төнә ятабыз. Корт чакмаган җиребез калмады.

— Кортлар чагу үзебезнең наданлыктан. Беркөн районда күрше авылның умартачысы белән сөйләшеп торган идем. Ул әйтә, умарталарны төтенсез, битлексез карыйм, ди.

— Аларның кортлары уксыздыр. Безнекеләр янына барырсың битлексез.

— Кайгырма, Фәйрүз, без дә өйрәнербез әле.

— Әнә Мәгъфурҗан абзый ничә ел эшләгән, аңа карап корттан чактырмаска өйрәнмәгән, — дип, үземнекен тәкрарладым мин.

Әйе шул, Мәгъфурҗан абзый корттан безгә караганда да ныграк курка.

— Минем бер җиремне корт чакса, көне буе тәнем кычытып йөри, — ди.

Беркөн ул, тәненең кычытуына түзә алмагач, чалбарын салып, салкын суга кереп утырган. Шуннан бирле салкын тидереп йөри.

— Алай корттан курыккач, нишләп үзең умарта тотасың? — дип сорады апа.

— Карчыгымның төсе алар. — Мәгъфурҗан абзый күзләрен билгесез ераклыкка текәп көрсенеп куйды. — Мәрхүмә кортларны бик ярата торган иде. Әз генә вакыты булды исә умарталары янында кайнашыр иде. Аның белән унике ел умарталыкта эшләп, умарталарны ачып караганым юк иде дисәм дә ялган булмас. Әнә Фәйрүз сыман төтен генә җибәреп торгалый идем. Өйдәгесенә дә, колхозныкына да җитешә иде мәрхүмә. Менә синдә аның чалымнарын күрәм мин.

— Мәгъфурҗан абзый, умарталарны суырта башларга вакыт җитми микән инде? — дип сорады апа.

— Әлегәчә көннәр әйбәт торды, бал төшкәндер, шәт. Бу умартаң шактый авырайды бит. — Мәгъфурҗан абзый контроль умартага ишарәләде. — Магазиннарын тутырган умарталарны аертырга кирәктер. Үсемлекләрдә бал барында тагын җыеп калсыннар.

— Нигәдер кайбер умарталар табыш җыя алмый, Мәгъфурҗан абзый. Әнә теге сары умартаның кортлары рәтләп очмый да.

— Чирле микән әллә? Кыш көне хәлсезләнгән оялар да тиз генә мантый алмыйлар. Андыйларга минем кортка җәй буе ашарларына куя торганые.

— Үзләре җыеп ашасыннар, — дидем мин, ачуым килеп. — Хәзердән үк бал бирә башласаң, кышка ни кала?

— Үзең бирми генә алып булмый ул, — диде Мәгъфурҗан абзый.

Алай икәнен мин беләм, ләкин тизрәк бал суыртып карыйсы килә шул. Миңа инде бөтен умартада тәпән-тәпән бал тулып ятадыр кебек.

Ниһаять, беркөнне апа:

— Бүген бал суырткычны алып киләбез, — диде. Шатлыгымнан ура кычкырдым.

Өй бик сагындырган иде. Тизрәк җыена башладым. Кием-салымнарымны аннан-моннан эләктереп, велосипед багажнигына бәйләдем дә апага кычкырдым:

— Әйдә инде, озайма!

— Кая шулхәтле ашыгасың? Бал суырткычны бездән алда берәрсе алып китәр дип куркасыңмы әллә?

Кайтып бик дөрес эшләгәнбез икән: әни бәлеш пешереп йөри иде. Безнең әни мич ашлары белән безне артык иркәләми. Аш ягына килгәндә, ул кәбестә шулпаларын ялратарак төшә. Бу бәлеш тә, бәлки, пешмәгән булыр иде, көтүдә бер сарыгыбызның сыйрагы сынган икән. Бозыла башлаганчы дип әчәк-бавырларыннан бәлеш пешерергә уйлаган.

Бәлеш телне йотарлык тәмле иде. Өстәвенә бөтенебез бергә җыелышып ашадык. Безнең өйдә мондый хәл сирәк була. Әллә шуңа бәйрәмдәге төсле булып китте. Әнинең дә йөзе ачылган.

— Әнинең берәр катлаулы операциясе уңышлы чыккан, — дидем мин.

— Нәкъ өстенә бастың, әүлия икәнсең. — Әни минем баштан сыйпап куйды. Аның йомшак кулларын битләремдә озаграк тотасым килеп, башымны әни ягындагы җилкәгә ия төштем. — Иркәләнергә песи кебек инде үзең, — диде әни.

— Егет булды инде Фәйрүз, — дип, әти минем сөенечемә тагын бер сөенеч өстәде. Үземнең егет үк түгеллегемне белсәм дә, шулай әйтүләре күңелне үстереп җибәрә шул. — Хәзер алар Рәйханә апасы белән колхозны баетырга уйлыйлар, әнкәсе.

— Баетырбыз шул, — дидем мин, горурланып. — Иртәгәдән умарталарны суырта башлыйбыз.

— Шулаймыни? Бик әйбәт, суыртыгыз әйдә. Бал бик кирәк булыр әле.

Апа һәрвакыттагыча бик әз сөйләште: «ә»гә — «ә», «җә»гә — «җә». Шуннан артыгы сирәк чыга.

Ашап-эчеп туйганнан соң, апа, әтинең машинасына утырып, колхоз кладовоена бал суырткыч алырга китте. Ә мин Ык буена чаптым. Ык мине йомшак кочагын җәеп каршы алды, уйнак дулкыннары битемне иркәләде, кайнар комы тәнемә сарылды. Ашаган бәлешем корсактан төшеп беткәнче ярдан сикердем, беләкләр камырга әйләнгәнче агымга каршы йөзеп, тын куырылганчы тирәнгә чумып су коендым. Малайлар да мине сагынып көтеп торганнар. Кайсы үзенең беләк буе чуртан эләктерүе белән, кайсы көненә егерме тапкыр су керүе белән мактанды. Нәрсә генә дисәләр дә ышандым. Үз чиратымда мин дә кимен куймадым: «Беркөнне тәнемнән йөз ук алдым», — дим. «Ну корт анасы әшәке чага икән, малайлар. Угы телле кармак кебек кәкре. Китереп кадаса, тартып алырмын димә». Малайларга агачка эләгеп сыдырылган беләгемне күрсәттем. Тотып-тотып карадылар, әмма шик белдерүче булмады.

Сөйләшеп, сайрашып арыгач, өйгә кайттым. Апа инде әзерләнеп беткән иде. Колхозның йөк машинасына бал суырткыч, берничә фляга һәм тагын умарталык өчен кирәк-яракны төягәннәр. Калган бәлеш белән тамак туйдырып, машина әрҗәсенә менеп утырдым. Малайлар мине озатып калдылар.

— Умарталыкка бал ашарга килегез, — дип кычкырдым мин аларга, сүзне аңламаслык ара киткәч.

Икенче көнне умарталарны суырта башладык. Рәйханә апа белән Мәгъфурҗан абзый умарталардан рамнарны ташып тордылар, мин бал суырткычны әйләндердем. Башта бу эш күңелле генә кебек иде, бераздан мышнап төштем. Көне дә бик бөркү. Ишек-тәрәзәләрне ачып ташлар идем, бал исенә келәткә кортлар тула. Күрәләтә кортлардан чактырганчы, манма тиргә батуың яхшырак.

Ун умарта әйбәт кенә баллаган иде. Һәрберсенең магазиннарын алып суырттык. Рамнарның күбесен кортлар калайлап куйганнар. Мәгъфурҗан абзый үткен пычагын кайнар суга тыгып-тыгып рамнарның балавыз калайларын кисте.

— Күпмеләп бал чыкты икән? — дидем мин, эш беткәч.

— Ике центнер чамасы булыр, — диде Мәгъфурҗан абзый.

— Хәзер үлчибез аны, — диде апа. Ул бүген шундый шат, очып кына йөри. Йөзе алсуланган, әллә апаның кәефен төшермик дип, кортлар да чакмый үзен.

Флягаларны үлчәүгә куйдык. Барлыгы йөз җитмеш җиде кило тартты.

— Суыртылган һәр умартадан унҗидешәр кило, — диде апа.

— Унҗиде кило да җиде йөз грамм, — дип төзәттем мин. — Ә иртәгә тегеләрен суыртабызмы, апа?

— Юк әле. Шулай да өч-дүрт көннән алты-җиде умарта рамнарын тутырыр дип уйлыйм.

— Ә без аларның тулганын көтмик, апа. Яртылаш килеш тә ярый бит ул.

— Ярамый. Кем белә, бәлки, көннәр бозылып китеп, кортлар оча алмый башлар. Очмаганда аларның үзләренә ашарга да кирәк.

— Астагы рамнарыннан ашасыннар.

— Астагы рамнар кышлыкка. Әле әнә хәлсезләнгән ояларга да баллы рамнар куярга туры киләчәк.

Умарталарның барчасын суыртып, күп итеп бал аласым килә иде минем. Менә әти шаккатыр иде, ичмасам. Әле безнең эшләр бик шаккатырлык түгел шул. Быел япкан кучлардән башка утыз оя кортка йөз җитмеш җиде кило бал балмыни ул? Әнә апа әйтә, алдынгы колхозларда һәр умартадан кырык-илле кило бал алалар, ди. Ә безнең бал һәр умартага бүлсәң, биш кило тугыз йөз грамм гына тия. Их, берәр төрле итеп балны авырайтып булсын иде.

Минем күңелнең төшенке икәнен күреп, Мәгъфурҗан абзый юата:

— Ничава, энекәш, мин эшләгәндә моның чаклы да чыкмый иде. Көннәр болай торса, мужыт тагын суыртырбыз. Апаң эшнең җаена төшенеп килә. Алла боерса, өч-дүрт елдан менә дигән умартачы булыр, — ди.

Мәгъфурҗан абзый сүзләренә кәефем тагын да ныграк кырылды. «Өч-дүрт елдан! Өч-дүрт елдан, бәлки, йолдызларга менә башларлар. Безгә бал бүген кирәк».

Башка вакытларда көннәрнең яңгырлы булуын тели идем, чөнки яңгырлы көнне умарталар аермый, төтәсләгечкә ягасы юк. Китап укып тик ятасың. Ә менә хәзер җаным-тәнем белән яңгыр яумавын телим. Күктә әз генә болыт күренде исә, куркып болытны күзәтәм: яварга килмиме? Җилләр ялкау болытларны ераккарак алып китә башласа, сөенечемнән кычкырып җибәрәм.

— Ур-ра, яумады!

— Нәрсәгә яңгырдан бик курка башладың әле?

— Соң бит, апа, көннәр матур торса, ул умарталарны тагын суыртабыз, дидең. Боларын этигә дә, бүтән кешегә дә әйтми торыйк, апа. Яңадан суырткач бөтенесен берьюлы күрерләр, әйеме?

Апа минем белән килешә.

Ләкин минем теләк кабул булмады: көннәр бозылды. Башта ишеп яңгыр яуды, аннары суытып җибәрде. Кортлар очмый башладылар. Ә бер чирләшкә умартабызның кортлары үлде. Апа, аларның нинди чирдән үлүләрен белергә теләп, әллә никадәр китаплар укып чыкты. Алай да белә алмагач: «Районга лабораториягә алып барырмын», — дип, үлгән умартаның бераз кортын һәм балавызын аерым савытка салып куйды.

Апаның сабантуйдан бирле Тургай абый белән очрашканы юк иде. Шуны исенә төшереп, төрттереп алырга булдым.

— Анда Тургай абый сары сандугачка әйләнмәде микән инде?

— Умартаның корты үлгән, ә син Тургай дип теш ыржайтасың, — диде апа.

— Үлгән шул, — дидем мин, чын-чынлап кайгыга баткан кеше төсле итеп. — Хәзер син шуны районга алып китәсең. Ә анда, юл башында синең килгәнеңне beләсеңме кем көтеп тора?

— Кем?

— Һы, белмәгән булып кылана. Тургай абый, кәнишне. Ул анда клуб түбәсенә менеп, Рәйханә туташ күренми микән дип, көн саен карыйдыр әле. Сине күреп алыр да каршыңа атылып чыгар. Районга нәрсәгә баруыңны да онытырсың.

Минем бу сүзләремә апаның ачуы кабарды. Ул мине ялт кына эләктереп алмакчы булган иде, мин келәттән чыгып сыпырдым. Артымнан уктай атылып ул килеп чыкты. Без бөтен умарталыкны бетереп чабышып йөрдек. Эләктерүен эләктерсә, минем кәҗә маемны чыгара иде инде, кыз кешеләргә тоттыра торган тәпиләр юк шул миндә.

— Бер өйрәтәм әле мин сине, — диде ул, йөгереп тота алмагач, — шундый өйрәтәм, Тургай дип яңадан авызыңны да ачмаслык итәм.

— Тургай, Тургай, Тургай, — дидем мин, аны тагын да ныграк үртәп. — Әгәр Тургай сүзе ошамаса, җизни, алайса.

Бу сүзләрдән соң, апа гел шартлар дәрәҗәгә җитте. Хәтта үзен жәлләп тә куйдым. Ә шулай да телемне тыя алмыйча һаман үртәштем. Нигәдер үртәлгән кешеләрне үртәргә, үчекләргә яратам. Моның өчен үземә еш кына тукмак та төшеп тора инде. Әни әйтмешли, кешене тукмак белән генә өйрәтеп булмый, күрәсең. Аннары соңгы вакытта бернәрсәгә төшендем — кешеләр дөреслекне әйткәндә ныграк үртәләләр икән. Мин бит белеп торам, апаның уенда гел шул Тургай абый. Миннән яшерә-яшерә шуның шигырьләрен ятлап йөри. Нигә инде аны яшереп маташырга? Китсен апа бүген үк районына, илтсен кортларын лабораториягә. Ә мин монда Мәгъфурҗан абзый белән калып торырмын.

Шул уемны әйтергә дип келәткә кереп барам, инде апа белән үртәшү дә хәтеремнән чыккан иде. Ишекне ачып җибәрүгә, апа, җен-пәри тизлегендә, минем яка астына бер корт тыгып җибәрмәсенме. Выжлапмы-выжлый теге корт. Мин үрле-кырлы сикерергә керештем, күлмәкне салып атар идем, төймәләре ычкынмый.

Апа эче катып көлә:

— Менә җизнәңне әйттерәме? — ди.

Азаплана торгач, изү төймәләренең кайсын өзеп, кайсын ычкындырып күлмәкне салып аттым да кортны күлмәк белән бәреп үтермәкче булып селтәнергә тотындым. Ә ул, имансыз нәрсә, минем колак тишегенә керде дә угын батырып та куйды. Берничә минут эчендә, колак кайнар бәрәңге тыгып куйгандай шешеп, томаланып калды.

— Умарталыгыңнан кайтам да китәм, — дидем мин, апага җен ачуларым килеп.

— Ә, шулаймы? Син шаярганда ярый, мин шаярганда ярамыймы?

— Корттан чактыру шаяру буламыни?

— Синең телең корттан да ныграк чага, мин түзәм бит. Менә син дә түз. Син бит әле чүтеки егет кисәге.

Без тагын әрепләшеп китәргә әзер идек, шул вакыт үзенең «бобигы» белән эти килеп төште. Аның янында ике кеше дә бар иде. Аларның берсе — колхозның склад мөдире, икенчесе — бөтенләй ят кеше.

Әле генә әрләшүебезне онытып, этиләр каршына йөгереп чыктык. Эти дә безне сагынган икән, шап-шап итеп җилкәләребездән кагып куйды.

— Ну, — диде ул, икебезгә берьюлы карап, — нәрсәләр белән шатландыра аласыз? Бал елгалары агамы?

— Ага, эти, ага, — дидем мин, ападан уздырып. — Озакламый тәпәннәр җитми башлар.

— Акса, әйбәт. Әйбәт кенә дә түгел, бик шәп.

— И ул җил тегермәненә ышансаң, — диде апа, — бик агарга тормый әле. Бер умартабызның нишләптер кортлары үлде.

— Анысы начар икән, — диде әти. — Ну кайгырмагыз, эшләгәндә андый гына хәлләр була инде ул. Бераз бал суыртkансыздыр бит?

— Суырттык, әти, суырттык, — дидем мин, тагын кысылып, — бераз гынамы соң — ике центнерга якын.

Әти алдында балны нигәдер килограммлап түгел, центнерлап күрсәтәсе килә иде. Тизрәк мактанасы килеп, әтиләрне келәткә таба алып киттем. Керешли әти, ят абыйга ишарәләп:

— Безнең колхозның шефы. Безгә торбалар табып бирде, — диде.

— Ур-ра! — дип кычкырып җибәрдем мин. — Авылга су керәчәк. Кыярларга, помидорларга суны Ыктан ташып сибүләр бетә!

Шеф абый минем котырып шатлануымнан елмаеп куйды. Аның тырпаеп торган мыегы, җыерчыклы йөзе миңа гаҗәп сөйкемле, матур булып күренде. Бөтен урманны яңгыратып, кычкырып йөрисем килде. Су кертер өчен торбалар табылган бит. Әти, мескен, шул торба өчен чабып, «бобигы»ның тәгәрмәчләрен туздырып бетергән иде инде. Без җыйнаулашып келәткә кердек. Рәйханә апа җәһәт кенә самавыр куеп җибәрде. Бераздан урмандагы унлаган сандугач сайравыннан да болайрак итеп самавыр чыжлый башлады. Өстәл уртасына табак белән бал менеп кунаклады. Әти өйдән тәмле-тәмле күчтәнәчләр алып килгән икән, табынга алар да тезелде.

Чәй эчәргә утырдык, шеф абый да кызык кеше булып чыкты, әллә нинди әкәмәтләр сөйләп эчләрне катырып бетерде. Бал капканда, авызы да шапылдап кына тора, бер чәен чөмерсә, ике тапкыр балга үрелә. Әйдә ашасын, кешесенә күрә җәл түгел. Ике центнер балны ашап бетерә алмас әле. Шулай да бал табагына таба абзыйның калагы артык еш йөри башлагач, әйтми булдыра алмадым:

— Абзый, сыек бал эчне бик авырттыра. Беркөн мин ялгыш күп ашап ташлаганыем, урман юлыннан кайтып керә алмый җәфаландым, — дидем.

— Шулаймыни? — диде абзый, чын-чынлап ышанган кыяфәт белән, һәм кашыгын куйды.

Апа миңа үтергеч караш ташлады. Ул гына да әз тоелдымы — астан корт чаккандай итеп ботны чеметеп алды. Мин сикереп тордым. Әти сүзне икенчегә борырга ашыкты.

— Су кергәч, — дип сөйләп китте ул, — безнең авыл иң матур авыл булачак. Урамның ике ягына агачлар утыртып чыгарбыз. Кешеләр җимеш бакчалары үстерә башлар. Капка төбе саен колонка — чык та чыжлатып агызып алып кер.

Әти хыялга бирелеп шактый сөйләде. Авыл турында хыялланырга ярата да инде. Әгәр аңа машинасын, ташын, цементын теләгән кадәр бирсәләр, нишләр иде икән? Бер тылсымлы дога укып, әти теләгән нәрсәләрне кинәт кенә алдына тезеп куясым килде. Үз уйларым үземә кызык тоелып, чак көлеп җибәрмәдем.

Чәйләр эчеп туйгач, әти склад мөдиренә безнең балны өр-яңадан үлчәп, квитанция язарга кушты.

— Ә хәзер, — диде ул, апага карап, — без сезнең балыгызны алып китәбез. Зур рәхмәт сезгә, тырышкансыз. Авылга керәчәк суда үзегезнең дә өлеш бар дип уйлагыз. Балыгыз... Хәер, анысы сезгә кирәкми.

Әти шулай дип сүзен бетерер-бетермәстән тукталып калды. Аннары ул, нидер исенә төшереп, тиз-тиз машинасына таба китте.

— Иң мөһимен онытканмын икән, — диде ул, кире әйләнеп килгәндә. — Менә бит идарә сезгә нәрсә бүләк итте.

Әтинең кулында саргылт катыргыдан ясалган бер тартма иде. Аннан нәрсә чыгар икән дип дүрт күз белән карап тора башладык. Әти юри әкрен кыймылдады: үзе әле миңа, әле апага карап күз кыскалап алды.

— Нәрсә дип уйлыйсыз инде моны? — диде ул.

— Бал савыты, — дидем мин, исем китмичә.

— Син үзең бал савыты. — Шулай диде дә әти тартманы ачып җибәрде, ә анда нәни телевизор иде.

— Батарея белән дә эшли, — диде әти. — Рәхәтләнеп карагыз. Батареясы әле юк югын.

Мин инде авызны турсайта башлаган идем, әти сүз әйтергә ирек бирмәде:

— Батарея урынына мин сезгә машина аккумуляторы алып килдем.

Бу шатлыктан урман яңгыратып ура кычкырдым. Апаның да күзләрендә шатлык очкыннары җемелдәде. Әтиләр китеп баргач, мин апага:

— Берничә елдан безнең бал да идарәгә таба торба белән генә ага башлар әле, — дидем. — Теге абзый балны бик ярата икән, тагын торбалар бирми калмас.

— Ә сиңа кеше алдында телеңне тыярга өйрәнергә вакыт, — диде апа.

Мин аны тагын үчекләргә тотындым.

— Җизни, җизни, күңелем синнән бизми.

Апа мине куа китте. Мин, шаркылдап көлә-көлә, урман сукмагыннан чаптым. Апа да көлә иде. Ә аннары, безгә кушылып, урман көләргә тотынды.

## ЯШЕЛ УТРАУ ХУҖАЛАРЫ

### 1. «Таҗетдин бабай эшләпәсе»

Үзле Яр авылын бер күргән кешеләр аның күзләрне камаштырган зәп-зәңгәр күгенә, савытка салып сөт итеп эчәрлек аксыл рәшәләренә, күңелләргә иркенлек, үпкәләргә рәхәтлек бирүче җәелеп яткан болыннарына, офыкларны үз җилкәләренә күтәреп торучы тауларына сокланып туймый. Ә иң гаҗәпләндергәне, йөрәкләргә иң хуш килгәне — бормаланып-бормаланып аккан Ык елгасы. Ул биредә чынлап та бик матур. Бер урында акыл утырткан карт шикелле салмак хәрәкәтле, тирән төпле. Талгын искән җилнең шаяруыннан барлыкка килгән вак-вак дулкыннар акыл иясенең маңгаендагы сырларына охшый. Ярларның биеклеге, мәһабәтлеге үз дәрәҗәсен белгән кешенең горурлыгын хәтерләтә. Суларның тоныклыгы мәкерсезлек билгесе булып күренә. Ә икенче урында елга танымаслык хәлгә килгән. Дулкыннар, кыр кәҗәсенең шук бәтиләре сыман, ташлардан ташларга сикерәләр. Мәһабәт ярлар урынына тәгәри-тәгәри кызынырлык комлык җәелеп ята. Комлык өстендә озын тәпиле тәкәрлекләр йөгерешә. Тагын да еракларга күз ташласаң, бәрәңге бакчаларының яшел келәмен җиргә кадаклаган колач җитмәслек өянкеләр, ә алар өстендә карга ояларын күрәсең.

Шулай да мин сезгә иң кызыгын әйтмәдем әле. Анысы нәрсә дисезме? Анысы — утрау, дуслар. Әйе, биредә гаҗәеп матур бер утрау бар. Үзле Яр авылы малайлары аны «Таҗетдин бабай эшләпәсе» дип атаганнар иде. Ләкин тора-бара утрауның исеме үзгәрде. Ни өчен үзгәрүен соңрак белерсез. Хәзер аның ачылу тарихын сөйләп китик инде.

Бервакыт шулай, май айларының урталарында, әрәмәдәге шомыртлар мәктәптән кайтучы ак бантиклы кызлар төсле бизәлеп утырганда, елгалар язгы ярсуларыннан туктап ярларына кайтканда, болыннарда чикерткәләр уянганда, зәңгәр күктә куыша-куыша күбәләкләр уйнаганда, Зәйтүн исемле йомылып җитми торган авызлы, озын сыйраклы кара малай белән май чүлмәгедәй түгәрәк эчле, ике көн рәттән яраткан ризыгы — каймакны туйганчы ашаса, икеләтә юанаеп китүче Хәйдәр Өемташ тавына менәргә булдылар. Өемташ тавы Үзле Яр авылыннан күренеп кенә тора. Әмма ул башка республиканыкы. Шулай да теге якта да, бу якта да пограничниклар юк. Постта торучы солдатларны хәтерләтүче төз таллар белән зифа зирекләр генә. Ике як ярны корыч арканнарга асылган басма тоташтырган. Ул басма, сабыйлар бишегедәй, җил искәнгә дә тирбәлеп тора. Хәер, малайлар ул көнне җәһәннәм астындагы басмага барып кадерле вакытларын әрәм итеп маташмадылар. Тоттылар да, күлмәк-ыштаннарын баш түбәсенә бәйләп, елганы йөзеп чыктылар. Салкын су тәннәрен куырса да, башка малайлардан алдарак чиркәнчек алу куанычы эчләрен җылытып, калтырауларын тыярга булышты.

— Тәки Һәнүзләргә сиздерми чыгып тайдык бит, ә? — диде Хәйдәр, түгәрәк корсагын каеш белән тарттыра-тарттыра. — Белеп алсалар, безне дә ияртегез дип, тотам да калмаслар иде.

— Әйе, — диде Зәйтүн, — алар барып җитмиләр, кайтырга ашыгалар. Ә минем тауның ә-әнә теге (ул бармагы белән тау сыртына төртеп күрсәтте) иң биек җиренә менеп, аякларны түбән асылындырып курай уйныйсым килә. Минем курай тавышымны урманнар ишетсен, җилләр болын-кырларга таратсын, болытлар зәңгәр күккә күтәрсен, елгалар диңгезләргә җиткерсен... — Зәйтүн шундый хыялый малай инде ул. Кырга чыкса, курай ясарга әйбәт кура эзли, урманга керсә, колач җитмәслек имәннәргә колагын куеп, аларның шаулаганын тыңлый, елга буена төшсә, дулкыннарга кушылып нидер көйли. Кайвакытта ул үз күңелендә сандугачлар сайравына охшашлы авазлар туганлыгын тоя. Шул авазларны, курае аша өреп, дөньяга чыгармакчы була. Ләкин алар нишләптер күңелдә яңгыраган кебек матур яңгырамыйлар. Зәйтүн көйнең бозылуын курай начарлыктан күрә. Аңа калса, әйбәт курай гына табарга кирәк. Шул вакыт бөтенесе дә җайланачак. Өемташка менүләре дә шуның өчен. Кеше күп йөрмәгән җирдән җилләр өреп шомарткан кура табу. Менә шулчак уйнаячак инде Зәйтүн! Хәйдәр тыңлап кына торсын. Ә Хәйдәр тыңларга булдыра. Зәйтүннең курай өрергә җайланып ясалгандай, йомылып җитмәгән авызына карап көннәр буе утырырга әзер ул. Менә шушы түземлеге өчен ярата да аны Зәйтүн. Бер генә серен дә яшерми. Биек тау башына менеп курай уйнарга теләвен дә Хәйдәргә генә әйтте ул. Бүтән малайларга сер чишсәң, көлә башларлар.

Ләкин ике дусның мышный-мышный тау башына менүләре юкка гына булды. Никадәрле генә эзләсәләр дә, алар рәтле кура тапмадылар. Тау башында кура үсәмени инде? Әй тиле башлар! Бер тилесенең уйлап чыгаруын әйтер идем дә инде, икенчесенең шуңар ышануын әйтер идем. Хәер, безнең хыялый йөрәкле дусларыбыз тауга менүләренә тамчы да үкенмәделәр. Зәйтүн әйткән иң биек кыяга аякларын асылындырып утырдылар да тирә-яктагы сихри матурлыкны күреп таң калдылар. Ул — катыкка манып алгандай ап-ак чәчәкле шомырт куаклары дисеңме, ул — очып баручы каз көтүе төсле ак болытлар дисеңме — барысы да шулкадәр матур, шулкадәр соклангыч, күреп туймалы түгел.

Малайлар бер мәлгә тын тордылар. Җәйрәп яткан киңлекләрне сүзсез генә күзәтүе үзенә бер рәхәтлек бирә иде. Нечкә күңелле Зәйтүн шушы күренешләрнең бөтенесен кысып кочаклардай булып алга омтылды. Һәрбер кошның башыннан сыйпыйсы килде аның. Әгәр булдыра алса, зәңгәр күккә кояш белән шушы кошлар җырының нотасын язар иде. Ләкин әле ул андый гыйлемне белми. Аның бар белгәне — хыяллану.

Ләззәтле уйлар томанында алар шактый йөзделәр. Бераздан Зәйтүн сикереп торды. Ул нидер күргән иде, ахры, кулын алга сузып:

— Кара әле, Хәйдәр, судан бер яшел эшләпә агып килә, — диде.

Хәйдәр ул күрсәткән якка күпме генә караса да, берни күрмәде.

— Кеше ышандырырсың тагын, — диде ул, хәтере калып. — Моннан торып әллә кайдагы елгадан агып баручы эшләпә күреп буламыни?

— Ныклабрак кара, ныклабрак, — диде Зәйтүн. — Эшләпә дигәчтен дә ул чын эшләпә түгел инде. Әнә күрәсеңме, су уртасындагы бер бәләкәй утрауны? Моннан караганда гел Таҗетдин бабай эшләпәсе төсле бит.

Эзли торгач, Хәйдәр дә утрауны тапты. Ләкин ул аны берничек тә Таҗетдин бабай эшләпәсенә охшата алмады. Таҗетдин бабай эшләпәсенең колак турындагы бөкләмнәрен түбән төшереп кия. Шуңа күрә ул бераз сигезле санына охшый. Ә Зәйтүн күрсәткән утрау бер дә алай түгел. Эшләпәгә караганда ул күбрәк кабарып пешкән кабартмагарак охшаган. Әнә бит су өстеннән никадәрле калкып тора. Хәер, эш нәрсәгә охшаудамыни? Иң мөһиме — утрау үзе!

— Җитмәсә, авыл кырыенда гына икән үзе, нишләп моңарчы күрмәгәнбез аны? — диде Хәйдәр, күзе талганчы утрауга караганнан соң.

— Моңарчы булмагандыр ул, — диде Зәйтүн. — Хәтереңдәме, быел боз киткәндә елга Гыйльметдин бабайлар турысыннан икегә аерылган иде. Мөгаен, су үзенә агар җай эзләп теге як әрәмәгә кергәндер дә, ипи кискәндәй, башкорт ягыннан утрау кисеп алгандыр. Шәп бит, ә?

— Әйе, — диде Хәйдәр. — Һәнүзләргә, Нәсихларга чаклы күрүебез әйбәт булды әле. Ату алар утрау таптык дип мактана башларлар иде. Ә хәзер без аны беркемгә дә бирмибез инде.

Дуслар тизрәк үз утрауларын якыннан күрү теләге белән түбәнгә ашыктылар. Кыска сыйраклы Хәйдәрнең табаны тигән җиргә тиде, тимәгән җиргә — юк. Читтән караганда, тау өстеннән тәгәрәп төшүче бер түмгәккә охшаш иде ул. Тигез юлга чыкканчы аларның тырналмаган җирләре, бәрелеп канамаган бармаклары калмагандыр. Утрауга керергә каян көймә табыйк икән дип тә баш ватмадылар, теге вакытта елганы ничек йөзеп чыксалар, бу юлы да шулай эшләделәр.

## 2. Хозурлык

Утрауга аяк басу белән малайлар үзләрен җир әйләнә сәяхәттә йөреп, моңарчы әле һичкемгә билгеле булмаган яңа материк ачучылар кебек хис иттеләр. Күңелләрендә аңлатып бирмәслек соклану һәм горурлану туды. Биредә шомырт чәчәкләре дә аграк, үләннәр дә йомшаграк, һавалар да сафрак, кошлар тавышы да моңлырак, җилләр дә ягымлырак тоелды аларга.

Алар сәяхәтчеләргә генә хас кызыксыну белән утрауда нинди үсемлекләр үскәнен, нинди кошлар оя корганын, нинди чокырлар һәм нинди калкулыклар барлыгын күздән кичерергә, һәр күргәннәрен хәтер дәфтәренә теркәргә тотындылар. Утрауның кай төшенә аяк басма, шунда тереклек, шунда хәрәкәт. Менә каплап куйган каз оясына охшашлы кырмыска түмгәкләре. Нечкә билле кырмыскалар үз ояларына әллә кайлардан чыбык-чабык башлары, үлән сабаклары һәм башка бик күптөрле чүп-чар күтәреп кайтып керәләр. Ныклабрак күзәтеп торсаң, алар кибән куючы колхозчыларны хәтерләтәләр.

Безнең яшь сәяхәтчеләребез бу сөйкемле җан ияләренә озаграк та карап торырлар иде, тик әле бөтен утрауны айкап чыгасылары бар шул. Бәлки, алда аннан да шәбрәк ачышлар, тагын да күңеллерәк яңалыклар көтәдер.

— Утравыбызда нинди агачлар үсә икән, карап чыгабызмы? — диде Хәйдәр. Зәйтүн бу фикерне бик тиз хуплап алды һәм алар: балан — бер, эт шомырты — ике, гөлҗимеш — өч, карлыган — дүрт, дип санап киттеләр. Барлый торгач, ике дистәгә якын төрдәге агач үскәнлеге беленде. Иң күбесе тал икән. Ул утрауны өч яклап уратып алган, әйтерсең аны кешеләр күзеннән яшерергә теләгән. Ә иң сирәк очраганы — кара каен куаклыгы.

Кара каен бу як әрәмәләрдә ят кунак түгел. Ул эт шомыртының бер төре, ахры. Куак-куак булып үсә, ләкин эт шомырты кебек шома түгел, озын-озын энәләре бар. Кабыгы башка агачларныкы төсле буйга каезланмый, ә ак каен кайрысыдай аркылыга каезлана. Тузы елтырап тора, кап-кара. Җитлеккән

җимешләреннән бик әйбәт язу карасы ясап була. Хәйдәрнең апалары аның белән хәтта чәчләрен дә буяп караганнар иде, ләкин пычранулары гына калды, чәчкә керми икән.

Куаклыкларны карап йөри торгач, малайлар кызынып өчен җайлап тараткан кебек сап-сары комлыкка килеп чыктылар. Комлык утрауның дүрттән бер өлешен биләп тора. Кояш иртәннән алып төш урталарына кадәр монда карый икән. Ә таллар өч ягыннан уратып алганнар да һичбер җилне үткәрмиләр. Малайларга иң охшаганы комлык булды.

— Монда көне буе су кереп, көне буе кызынып ятсаң да, эзләп табачак түгелләр, — диде Хәйдәр. — Бер йөк ипи белән бер тәпән каймакны куак төбенә китереп яшереп куй да җәй буе качып яшә. Комының җылылыгы соң, җылылыгы. Табада кыздырылган орлык диярсең.

— Әйдә балык тотып уха пешерәбез, — диде Зәйтүн.

Икесе дә кепкаларына кадап куйган кармакларын актара башладылар. Җепләре дә шунда гына икән. Ә кармак сабына аптырыйсы юк — тирә-юньдә зифа таллар, рәхәтләнеп сайла гына. Талларны хәтта сындырып маташырга да туры килмәде, аяк астында аунап яткан чыбыклар арасыннан менә дигән кармак саплары табылды. Селәүчән юклыгы күңелләрен бераз борчыды борчуын, әмма монда да җаен тиз таптылар. Хәйдәрнең капчыктай тирән кесәсеннән хәйран ипи валчыклары чыкты. Бер юлга кармакларын шуның белән сала тордылар. Соңыннан Зәйтүн чикерткәләр тотарга китте.

Хәйдәрнең балык тотудан бәхете бар иде. Ул кармакны үзенчә әфсенләп сала: «Әпсен-төпсен, балык чиртсен, җимне тапсын, килеп капсын», — ди дә кармагына берничә мәртәбә төкереп куя. Балыклар, аның әфсененнән гипнозлангандай, бүтән кешеләрнең кармагын аралап, Хәйдәрнекенә килеп кабалар. Хәйдәр бөтен кешене кызыктырып: «Берәү-берәү, берәгәйле», — дип, балыкларны тартып чыгара башлый. Әфсенне ул гел бертөсле итеп укымый. Һәр балыкка аерым догасы бар. «Чабак-чабак, алтын канат, җимем тәмле, калма карап», — дип сала икән, чабак каба. Ә инде: «Алабуга — кылыч сырт, бусы сиңа, килеп тот», — дисә, кармагына алабуга ияреп чыга. Дөрес, кайвакытларда чуртанга дип салган кармакка агач тамырлары да эләккәли, чабакка дип әфсенләгән җимне башка хәйләкәррәк балыклар ашап киткәли, ләкин аңа карап кына балыкчының күңеле төшәмени? Ә Хәйдәр ул — пошмас җан — балыклар кармагын сабы-ние белән сөйрәп китсә дә «әһ» тә димәс. Төп шикелле утыра бирер.

Менә бүген дә ул, Зәйтүн чикерткәләр эзләп киткәч, җайлап кына яр башына урнашты. Гадәттәгечә догаларын укып, җименә төкереп, кармак сабын һавада болгап, балык чирттерергә утырды. Ипи валчыкларына әллә ни эреләре алданмадылар, билгеле, хәер, көне белән вагы да ярап куя. Эресе аның бөтен малайларның күзен яндырып, балык тезгән талыңны урам буйлап сөйрәп кайтканда гына күңелле. Ә монда пешереп ашарга шул маймычлардан да шәбе юк инде. Эресе капса, малайларга күрсәтмичә ашавы кызганыч булыр иде әле.

Озакламый, бер уч яшел чикерткә тотып, Зәйтүн килеп җитте. Тик ул килгәнгә карап кына яр башында ялтырап ятучы чуртаннар ишәймәде. Зәйтүнгә аңа курай өрергә генә булсын, балык каптырырга бигрәк кулы бармый инде. Тәлтәвече су өстендә селкенә башладымы, кармак сабына куш куллап ябыша яки дөнья бетереп чирткән балыкны да күрми утыра.

— Иң яхшысы, син хәзер балыкларны чистарта башла, учак тергез, — диде аңа Хәйдәр.

Балыкларны чистарт, дип әйтүе генә ансат, күз белән койрыктан гына торган нәрсәләрнең кай җиреннән тотып чистартасың! Тик Зәйтүн андыйларны да эләктерә алмый, шулай да бу эштән котылу өчен бер җай эзләде.

— Карале, малай, — диде ул, кесәсенә суккалап, — учак ягарга безнең шырпы юк икән. Без бит монда кораблльләре һәлакәткә очрап, ялгышлык белән генә исән калган матрослар кебек. Кесәдә шырпы булса да юешләнер, күкерте эреп бетәр иде. Учакны шырпысыз кабызу әмәлен табарга кирәк.

— Учакны ничек кабызсаң да кабыз, миңа уха гына пешер, — диде Хәйдәр.

Ә Зәйтүн, дустының сүзен бөтенләй ишетмәгәндәй, йомшак чирәм өстенә сузылып ятты да болай диде:

— Шушы утрауда утсыз-сусыз ничә көн яшәп булыр иде икән, ә?

— Уты булмаса да, суы җитәрлек, — диде Хәйдәр, көрсенеп.

— Утны табуы кыен түгел, яр буенда чакматашлар тулып ята.

— Тулып ятса да, учак ягарга ашыкмыйсың әле, — диде Хәйдәр. — Кара инде моны, сузылып яткан. Җылы сөт белән корсагын тутырган мәче диярсең.

— Ашау да булдымы эш! Мин моннан бер дә кайтмас идем. Яр кырыена землянка казып җибәрсәң, карама агачыннан җәя бөгәсең, камышлардан ук ясыйсың...

Хәйдәрнең түземе бетә башлады. Ул кармагындагы маймычын да алып тормастан бер читкә атты да Зәйтүн янына килде.

— Учагыңны кабызасыңмы син, юкмы? Ату мин балыкларымны чи килеш ашап бетерәм.

Зәйтүн аның сүзләрен эләктереп алды:

— Ә беләсеңме? Океан-диңгезләрдә балыкчыларның эчәр сулары бетсә, чи балык ашыйлар икән. Шул сусауны баса, ди.

— Уф, — дип сикереп торды Хәйдәр, — син һаман мине сүз белән сыйлыйсың. Әйдә, өйгә кайтабыз. Түзәр хәлем калмады. Эчемдә ач бакалар чурылдый.

Кайтасы килмәсә дә, Зәйтүн Хәйдәргә ияргә мәҗбүр булды.

**3. Яланаяклы команда**

Зәйтүн белән Хәйдәр утрау табулары турында башта беркемгә дә әйтмәскә уйлаганнар иде, ләкин ачышыңны бөтен дөнья белмәгәч, ни кызыгы бар, дип, серләрен чиштеләр. Билгеле, моңарга һәркем үзенчә шатланды. Ә барыннан да бигрәк утрау белән Һәнүз кызыксынды:

— Ничек соң анда, үлән шәп үсәме? — диде ул.

— Шәп! Билгә җитә! — диде Хәйдәр. — Ну комлыгы җилле инде: мамык мендәрдәй йомшак, мич башыдай кызу, йөгереп туймаслык иркен. Үзе ышыкта, үзенә туп-туры кояш карый. Кояш чыбыркы сабы буе күтәрелүгә, комың төкерек чыжлатырлык кызып та җитә...

— Комлык та комлык дисең син, — диде Һәнүз, Хәйдәрне үчекләгәндәй, — комга кәҗә тәкәсе бәйләп булмый бит...

Һәнүзләрнең мамыклы кәҗә тәкәләре бар. Аны саклау Һәнүзгә йөкләтелгән иде. Артык сөзгәк, артык кире булганлыктан, көтүчеләр аны авылдан чыгуга ук аерып калдыралар. Һәнүз йокыдан торгалаганчы, ул мәхлук ишегалдына кайтып та керә. Малай аны абзарга бикләп кенә куяр иде, ярамый, апалары ачулана. Аларга мамык кирәк. Ач тотсаң, тәкәнең мамыгы начар була икән. Маэмай хәтле генә шушы кәҗә тәкәсе ашъяулык кадәр шәл бирә икән, моны, әлбәттә, Һәнүзнең тырышлыгы аркасында дияргә кирәк. Тәкәне алганга дүрт ел — дүрт апасы шәлле булды инде. Тагын ике апасының һәм өч сеңлесе белән әнисенең генә мамык шәлләре юк. Һәнүз үзе йомшак шарфсыз да түзәр иде.

Их, менә шул Хәйдәрләр табып кайткан утрауга илтеп куясы иде үзен. Көзен генә алып кайтыр идең. Үлән шәпме дип соравы да шуның өчен бит инде. Әмма кеше кайгысы кештәктә дигәндәй, Хәйдәрләрнең кәҗә тәкәләре юк шул. Аңа корсагын кыздырырга ком булсын.

Бу дөньяда иң бәхетсез кеше итеп тойды Һәнүз үзен. Шушы мөгезле карачкыны бүреләр да ашап китми, ичмасам. Ярый әле Һәнүз аны бер һөнәргә өйрәтте. Һөнәр дигәннән, күпме генә тырышсаң да, кәҗә тәкәсеннән итекче дә, пешекче дә чыкмый, әлбәттә. Әмма кәҗә тәкәсе дә талanттан бөтенләй мәхрүм түгел икән. Беренчедән, ул клоуннардан да остарак итеп көлә белә. Өске иренен өскә бөкләп ыржая гына. Болай тавыш чыгармыйча ыржаерга аны кем өйрәткәндер, ул хакта белми Һәнүз, ә менә футбол уйнарга, әйе, әйе, футбол уйнарга Һәнүз үзе өйрәтте. Дөрес, кәҗә тәкәсеннән футболчы ясыйм дип тотынмаган иде ул. Сакаллы мәхлукны чирәмгә бәйләп, үзе шул тирәдә туп тибеп йөри иде. Шулай көтмәгәндә-уйламаганда туп тегенең маңгаена барып төшмәсенме! Тәкә мескен йолкып алган чирәмен дә онытып тупка ташланды да малай аны-моны абайлаганчы тупны һавага чөеп тә җибәрде. Бер чөеп кенә калса тагын бер хәл иде, бәйләгән бавын өзеп, җирне ал тәпиләре белән тырный-тырный үз тирәсендә сикергәләп торучы тупка тагын ыргылды. Ялкау тәкәнең бу кадәр дә ачуланганын күрмәгән Һәнүзгә мондый хәл бик кызык тоелды. Һаман-һаман тупны тәкәнең маңгаена төбәп типте. Тәкә дә аның саен кызды, аның саен ярсыды. Түгәрәк шайтан — туп һавадан төшеп җиткәнче, ул арткы тәпиләренә басып үч алырга әзерләнеп торды. Әмма туп та хәйләкәр шул. Мөгез очы белән эчен актарырга ирек бирми. Әз генә кагылдыңмы — тәгәри дә китә. Мескен тәкәнең авызыннан күбекләр килә башлады. Тәгәри-тәгәри көлүдән Һәнүзнең эчен кату алмаса, белмим, бу уен кайчан туктаган булыр иде икән. Туп тибәргә иптәш таба алмаган чакларда, Һәнүзгә кәҗә тәкәсе ярап куйды. Ә болай да уенның кызыгы бетсә, чирәмгә ике казык кагып капка ясый да бавын шул казыкларга җитәрлек итеп тәкәне бәйләп куя. Аннары үзе ерактан торып тибеп җибәрә. Сакаллы капкачы үз капкасына дошманны якын да җибәрми. Шулай да кәҗә тәкәсе белән уйнау туйдыра. Чөнки аның белән бәхәсләшә дә, кычкырыша да алмыйсың, иң мөһиме — синең оста уйнаганыңны күреп сокланучы юк. Ә бит Һәнүз авылда бер футболчы. Аны хәтта үзеннән өлкәнрәкләр дә командаларына куш куллап алырга тора. Бөтен футболчыларның исемнәрен, биографияләрен белә. Газета-журналларда бирелгән спорт турындагы сорауларга җаваплар язып, бервакыт атаклы футболчыларның автографлары язылган туп та алды. Ул тупны чормада, кеше кулы җитмәслек җирдә генә саклый. Шундый атаклы башың белән кәҗә тәкәсе саклап йөрү җиңел эшмени!

Менә тагын ул мөгезле футболчысын җитәкләп чыгып килә. Исәбе: бу каһәр суккырын утрауга илтеп дөмектерү.

Әмма бүтән җирдә күндәм генә йөргән сакалбай елга буена төшү белән колакларын тырпайтып, күзләрен акайтып шып туктады. Һәнүз аны бавыннан өстерәп тә, сыек чыбык белән сыртын каезлап та тыңлата алмады. Ул арада су буена малайлар да җыелышып җитте.

— Айгырыңны йөздерергә алып төштеңме әллә?

— Сабан туенда чабышырга өйрәтәдер.

— Ярарыгыз инде, — дигән булды Хәйдәр, — нигә аны хурлыйсыз? Айгыр гына түгел, мотоцикл ул. Руле бармы? Бар. Тизлеге — тал чыбыгы, никадәр ныграк суксаң, шулкадәр шәбрәк чаба. Тормозын әйткән дә юк, галәмәт шәп эшли: су күрдеме, дүрт аягын тиң терәп шып туктый.

Малайларның үртәвенә Һәнүзнең әллә ни исе китмәде. Ул, күп уйлап тормастан, тәкәне бу яктагы бер таллык арасына кертеп бәйләде дә үзе малайларга ияреп утрауга китте. Аның куенында тыны чыгарылган теге исемле туп бар иде. Аргы як ярга аяк басу белән, маңгаенда кызыл таплар барлыкка килгәнче өреп, тупны кабартып җибәрде.

— Ботинкаларыгызны салып, ялан аяк кына тибәргә түлке, — дип кисәтте ул. Малайлар һичсүзсез аның белән килештеләр. Утрауга барып җитүгә үк, ботинкаларын салып, карлыган куагы төбенә ташладылар. Әмма аларга тиз генә уенга тотынырга туры килмәде, чөнки футбол өчен дип сайланган мәйдан чүпле иде.

— Карагыз әле, егетләр, — диде Зәкәрия, — галәмәт җилле урын тапканнар бит болар. Туп тибәргә менә дигән аланы бар, юри әзерләп куйганнар диярсең. Күләгәдә кабак төше ярып ятасың килсә, куаклык җитәрлек. Ә комына хет баш-аягың белән чум. Эт белән дә эзләп тапмаслар.

— Үләне дә, үләне! Кәҗә тәкәсе мөгезеннән күмелерлек, — диде Һәнүз. — Карагыз әле, кәҗә тәкәсе йөзә беләме икән?

— Баш катырма әле шуның белән, — диделәр аңа.

— Минем башым гына катканда түгел, — диде Һәнүз. — Менә монда кәҗә тәкәсен чыгарып куйсаң, беркая китаалмый инде ул, ә? Мамыгын тарарга ике айга бер тапкыр гына апкайтасың аннары.

— Ә кем болыны икән бу? — диде Нәзир. — Башкорт әрәмәсе булса, үлән таптаган өчен сыйракларны сындырмаслармы?

— Нишләп башкорт әрәмәсе булсын ул? — диде Хәйдәр, түгәрәк эчен куллары белән угалап. — Әнә, күрәсеңме, башкорт болыны суның теге ягында. Суның бу ягы — безнеке.

— Утрау суның теге ягында да, бу ягында да түгел, уртада.

— Уртада икән, бигрәк шәп, — дип бәхәскә кушылды Һәнүз, — язгы ташу безнең файдага эшләгән. Хәзер без утрауны беркемгә дә бирмибез инде. Әллә безгә уйнар җир кирәкмиме? Урамда шар суксаң тәрәзә вата, туп типсәң бакчага төшә, тәгәрмәч тәгәрәтсәң тавыш чыга.

Ул зурларга үпкәләгән сыман сөйли иде. Һәнүзнең сүзләре башка малайларның да күңелләрендә теләктәшлек тапты. Бермәлгә дәррәү кубып шаулашып алдылар. Гомуми тавышта кемнең нәрсә әйткәнен аңларлык түгел иде. Соңыннан, ярсулары басыла төшкәч, Зәйтүн:

— Ә беләсезме? — дип, малайларны үзенә каратты. — Мин былтыр Казанга абыйларга барганыем. Шунда җиңгәчәй бер парк күрсәтте. Вәт, ичмасам, шәп дисәң дә шәп! Ни генә юк анда. Атынганда болытларга менеп җитәрлек таганнар дисеңме, «үлем элмәге» ясаучы самолет дисеңме, ракета тизлегендә әйләнүче карусель дисеңме — берсе дә калмаган инде. Бот буе малайлар киләләр дә, безнең төшебезгә дә кермәгән самолетларга утырып, һавага ыргылалар. Вәт безнең дә шундый бакчабыз булса, ә?

Малайларның кызыгудан күзләре ялтырый башлады. Һәркемнең хыялы еракка, Зәйтүн күреп кайткан бакча якларына юнәлде. Шәһәр балаларына кызыгудан, хәтта ярыйсы ук көнләшүдән әйтер сүз тапмадылар. Шактый вакыт узгач кына, берсенең көрсенгәне ишетелде:

— Кая инде безгә Казан малайлары белән тиңләшергә? Алар җәй җитсә лагерьларга китәләр. Хайваннар карарга телиләр икән — зоопаркка йөгерәләр. Без бит монда тере маймыл да күрмичә гомер үткәрәбез. Үзебезгә генә маймылланырга кала. Алар мәзәккә тансыкласалар, цирк тулы клоуннары. Шәһәрдә анда һәр өй каршында спорт мәйданчыгы бар. Ә безнең нәрсә? Җәйгә чыксак, бәбкә саклаудан, бозау караудан, бәрәңге утаудан арынмыйбыз.

— Их, бөтен малларны абзары-ние белән колхозга тапшырасы иде, —диде Һәнүз, теге иптәшенең сүзләрен җөпләгәндәй.

Шулай үзара зар түгешсәләр дә, малайлар үз авылларын, үз төбәкләрен яраталар иде. Мондый рәхәт сулар, иркен болыннар, чәчәкле әрәмәләр, саф һавалы кичләр шәһәр балаларының төшләренә генә кергәнлеге дә аларга мәгълүм иде югыйсә. Әмма үзләрен кемнәрдер тарафыннан кыерсытылган итеп тою хисе бу мизгелдә ул хакыйкатьне томалап куйды. Шул вакыт Зәкәрия, барысының да авыр уйларын таратырга теләгәндәй:

— Нәрсәгә әле шәһәр бакчасына исебез китте? — дип сүз башлады. — Безнең бу утрау шәһәр бакчасыннан кай җире белән ким? Зәйтүн, әйт әле, син күргән бакчада мондый ком барыемы?

— Югые.

— Бөтен яктан да менә мондый су белән уратып алынганыемы?

— Син нигә миңа бәйләндең әле? — диде Зәйтүн. — Шәһәр уртасындагы бакчада елгалар агып ята ди, көтеп тор.

— Шулай булгач, — дип дәвам итте Зәкәрия, — безнең бу утрау синең паркыңнан артыграк әле. Атынгычлар ясап җибәрербез. Волейбол уйнарга ятьмә корырбыз...

— Боларны син тылсым ярдәмендә эшләргә уйлыйсыңмы әллә? — дип каршы төштеләр Зәкәриягә.

— Нигә аптырарга? — дип, үз сүзендә нык торды Зәкәрия. — Баганалар тапсак, атынгычына арканын юнәтсәк, ятьмә үрергә җебе булса, үзебез дә әмәллибез аны.

— Әллә ни күп тә кирәкми югыйсә, — диде Нәсих, дустын үчекләп. — Карусель өчен берәр электромотор, ул моторны эшләтергә механик, әйләнә торган утыргычларын ясарга берничә балта остасы булса, шул җитә.

— Ярар, юк белән баш ватмыйк әле, без бит монда футбол уйнарга дип чыктык, — диде Һәнүз. — Әйдәгез, чалбарларыгызны салыгыз, табаннарыгызны майлагыз, эшләрегезне җайлагыз.

Ул, сүзләренә куәт бирергә теләгәндәй, каты итеп тупка тибеп җибәрде. Малайлар җәһәт кенә таралыштылар. Капка юк дип тә тормадылар: янәшә генә үскән ике шомырт куагын бөгеп чалбар каешлары белән бәйләделәр дә менә дигән капка ясадылар. Икенче капка өчен мондый уңайлы куак юк иде, кырмыска түмгәкләреннән файдаландылар. Тик уйнарга керешкәнче, футбол кырын чүп-чарлардан әйбәтләп тазартасы бар иде. Һәнүз, ике команданың да капитаны буларак, үз футболчыларына әмер бирде:

— Футбол кырын бик һәйбәтләп чистартырга!

Малайлар дәррәү эшкә керештеләр. Берәүләр учак кабызды, икенчеләре аунап яткан чыбыкларны җыеп китерә торды. Аякка кадалырдай күренгән кураларны да йолкып читкә аттылар. Футбол мәйданы тиз арада чистарып, матурланып калды. Соңыннан Нәзир сүнеп җитмәгән учакка ымлап:

— Күмеп куйыйк без моны, йә кабынып китәр, — диде. Ике әйткәнне көтмичә, берничә малай учак күмәргә китте. Тик көрәкләре юк икән. Әмма аптырап калмадылар, монда да аларның йөгерек акыллары җаен тапты. Чалбар балакларын бәйләп, шуңарга ком тутырып алып килделәр дә эһ дигәнче учакның эзен дә калдырмадылар.

Ул көнне алар табаннары шырпы сызарлык булып кызганчы, карыннары бәрәңгене бакчасы-ние белән йотар дәрәҗәгә килеп ачканчы туп типтеләр.

**4. Башы баудан башланды**

Буш вакытлары күбәйгән саен, Үзле Яр малайлары үзләренең утрауларына ешрак бардылар. Мәктәпләрдә соңгы звонок шалтыравына әле кайчан гына, ә алар инде мәктәп формаларының кайда икәнлекләрен дә оныттылар. Ялга сусаган акыллары мавыктыргыч һәм кызыклы уеннар таләп итте.

Утрауда һәркем үзенең күңелен канәгатьләндерерлек нәрсә табарга тырышты. Зәйтүнгә, һич уйламаган җирдән, бик шәп кура очрады. Эчен яхшылап чистартып, тиешле урыннарына тишек тишеп җибәргәч, курае кибетләрдә сатыла торган көмеш флейталардан бер дә ким чыкмады. Тик курай никадәр яхшы булмасын, әйтергә теләгәнне әйтә алмады әле. Моңардан Зәйтүн шуны аңлады: эш курайда гына түгел икән. Күңелдәге моңнарны курай аша дөньяга таратыр өчен, әйбәт курай өстенә яхшы уйнаучы да кирәк икән.

Биредә уеннар никадәр күңелле булмасын, вакыт-вакыт малайлар моңаешып калгалыйлар иде. Бигрәк тә Зәйтүн сөйләгән атынгычлар, выжлап әйләнүче карусельләр күз алдына килгән чакта, йөрәкләре җилкенеп-җилкенеп китә. Җитмәсә, беркөн аларның яраларына Равия белән Наҗия тоз салды. Утрауны кемнән ишетеп, каян табып килеп чыкканнар диген. Равиясе ачу китереп фотоаппаратын аскан. Күргән бер куакны черт иттереп рәсемгә төшерә. Әйтерсең шомырт куаклары, гөлҗимешләр бүтән җирдә юк. Наҗиясе тагын ни кыланып йөри: чикерткә җыя, имеш. Үзен тотып чикерткәләре янына салсаң, аерып алгысыз инде. Телен тыеп, шыпырт кына йөрисе урында авызын ерып тора.

— Сезнең бу утравыгызны урлап китәргә килдек әле, — ди. — Әнә Равия бөтен куакларны урлый, мин бөҗәкләрегезне банкага тутырам.

— Бездән кача-поса йөгерә торган җирегез шушы икән инде, — дигән була Равиясе дә. — Без әллә искитәрлек урынмы дигән идек, сезнең монда рәхәтләнеп атынырлык таганыгыз да юк икән.

Серкәсе су күтәрми торган Зәкәрия бу сүзләрдән соң күтәрелеп, кабынып китте.

— Әллә Мәскәүне берьюлы салганнар дип беләсеңме? Теләсәк, таганын да ясарбыз, каруселен дә. Сезнең башыгызга да килмәгән әллә ниләр төзеп куярбыз әле.

Кызларның башларына да килмәгән нәрсәнең ни булырын Зәкәрия үзе дә белми әле. Сүзе аска калмасын өчен генә әйтә ул.

— Әгәр теләсәгез, без ярдәм итәрбез, — диде Равия, җитди тонга күчеп. Малайлар, сүз куешкандай, кычкырып көләргә тотындылар. Янәсе, кызлар ярдәменә калган көннәре юк. Ә Равия бер дә алар белән шаярырга җыенмый иде. Аның нияте чын күңелдән.

— Бик беләсегез килсә, без аркан таба алабыз, — диде ул.

Малайларның ерылган авызлары йомылмаган килеш катып калды. Бусы инде уен түгел: таган өчен бит беләк юанлыгы әллә ничә метрлы аркан кирәк. Ул кадәре эшне өсләренә алалар икән, димәк, бу нечкәбилләр белән сөйләшеп карау ярый. Башын башларга бавы булса, бүтәненә җае тагын чыгар иде.

Әмма Равия тегеләр алдында үзләренең дәрәҗәләрен төшермәс өчен генә шундый вәгъдә биреп ташлады. Дөрес, ул күз алдында йөгерек Һәдиятулла бабайны тотып әйтте. Һәдиятулла карт — гомер-гомергә колхозга бау ишүче. Баса күленә батырган киндер көлтәләре генә дә әллә ничә арканга җитәрлек.

Вәгъдә биргәч, үтәргә кирәк иде. Шуңа күрә Равия белән Нәҗия шул ук көнне Һәдиятулла картларга киттеләр.

— Нигә син Һәдиятулла бабай белән сөйләшмичә, аркан табам дип шапырындың? — диде Нәҗия, иптәшенә хәтере калып.

— Соң ул ташбаш малайларны башкача ничек ышандырасың? Арканны Һәдиятулла бабай ничек тә ишеп бирер әле.

Кызлар урамда кыю күренсәләр дә, Һәдиятулла картларның капка төпләренә килеп җиткәч, шактый вакыт эчкә үтә алмый тордылар. Соңыннан үзләренә күрә бер матур хәйлә тапкач кына кыюландылар.

— Бабай, бездән ярдәм кирәкмиме? — диде алар, исәнлек-саулык сорашканнан соң.

Һәдиятулла карт күзен кыса төшеп аларга карады.

— Сез кемнең тәүфыйклы балалары соң әле?

Тегеләр ата-аналарының кем икәнлекләрен әйттеләр.

— Үзем дә шулайдыр дип уйлаган ием аны. Бу чаклы да эшләргә җиң сызганып торучылар башка беркемнең дә кызлары булмас дигән ием. Килеп иллә дә шәп иткәнсез. Мәфтуха әбиегез бүльнистә ята. Ансыз өйнең җәме юк. Алай үзегез эш сорап килгәч, отказ итеп булмый инде. Идәннәрне бераз чылаткалап алырсыз. Юкса Мәфтуха әбиегез бүлнистән кайтса, идәнне дә юмагансың, дип кире китәр.

Кызлар коедан су китерделәр. Бөтен ләгәннәр тулгач, җиңнәрен сызганып идән юарга керештеләр. Идәнгә атна-ун көн кеше кулы тимәгәнлеге сизелеп тора. Тәрәзә төбендәге кына гөлләре дә шактый тузан йотарга өлгергән. Беррәттән кызлар гөл чүлмәкләрен дә идән уртасына утыртып, һәрбер яфрагын аерым-аерым сөрттеләр. Тәрәзә рамнары да онытылмады. Ә стенадагы көзгене чистартып алганнан соң, Һәдиятулла карт болай шаяртты:

— Кара син, агай, бу хикмәтне, соңгы вакытларда нишләп картайдым икән дип аптыраганыем, көзге гаепле икән: ул картайтып күрсәткән. Менә, рәхмәттән туган балалар, мине дә яшәртеп җибәрдегез бит, ә?

Кызлар, аның сүзләрен дә ишетмичә, эшләрен дәвам иттерделәр. Ап-ак булып калган һәрбер сайгак, тузаны сөртелгән һәрбер яфрак аларга рәхмәт әйтәдер кебек тоелды. Идәннәр юылып беткәч:

— Бабай, кер уасы юкмы? — диделәр алар.

— Арыгансыздыр инде, балалар, бераз капкалап алыйк, — диде карт һәм үзе җәһәт кенә чыгып китте. Озак та үтмәде, кулына бер тәпән күтәреп килеп тә керде. Тәпәннең капкачын ачып җибәрү белән өйгә тәмле бал исе таралды. Равия белән Нәҗия телләрен ялмап алдылар. Һәдиятулла карт түгәрәк ипине түшенә терәп олы-олы телемнәргә кисте һәм кызларга тоттырды:

— Эшләгәндәге төсле кыю кыланыгыз әле. Бер дә тартынып тормагыз. Менә кашык, менә бал. Оялмагыз.

Кызлар башта балны калак очларына гына эләктереп маташканнар иде, татлы юкә балы авызга кереп эри башлагач, калакларын төпкәрәк чумдырырга тотындылар. Һәдиятулла карт, сиздермичә генә, ипи кисеп тегеләргә якынрак шуыштыра торды. Ул арада бабайның электр чәйнеге дә кайнап чыкты. Чәчәкле чынаякларга чәй агызып кызларның алдына куйды ул:

— Мәфтуха әбиегезнең кунаклар сыйлый торган чынаяклары, — диде ул, кызларның чынаяк бизәкләренә карап утыруын күреп.

Бик һәйбәтләп тамак туйдырганнан соң:

— Уасы керләрегез юкмы? — дип кабатлап сорады кызлар.

Һәдиятулла карт юк-юк дип тартышып маташкан иде дә, тегеләр аның ялганын бик тиз тоттылар. Юган чынаякларын сөртергә йомшак сөлге алырга дип кием шкафын ачып җибәрү белән бүселеп бер төргәк килеп төште. Кызлар аның юылмаган керләр икәнен шунда ук күреп алдылар.

Һәдиятулла карт:

— Әбиегез кайткач юар әле, — дип караган иде дә, кызлар үз сүзләрендә нык тордылар. Өйдә яңадан эш кайнады. Берсе казан астына ягып суын җылытты, икенчесе керләр уды. Берсе чайкады, икенчесе чыгарып элде. Бабай гына, нәрсәгә кагылырга белмичә:

— Һай, рәхмәттән туган балалар, — дип сөйләнде. — Мәфтуха әбиегез кайтып керсә, әллә өебезгә килен төшкәнме, дип торыр инде. Гомерегез озын булгырлары. Иртәгә больниская баргач, сезнең турыда әйтеп, әбиегезне шатландырыйм әле.

Кызлар эшләренең нәтиҗәләрен күреп үзләре дә бабайдан ким куанмадылар. Башкаларны шатландыруның никадәр ләззәтле икәнлеген менә шунда тойдылар алар. Шуны белү горурлыгы йомышларын да онытырды. Бары тик өйләренә кайтып җитәрәк кенә Һәдиятулла картларга ни өчен барулары исләренә төште. Әмма кызлар кире борылмадылар. Яңадан барып бау турында сүз кузгатсалар, эшләгән эшләренең куанычы кимер төсле тоелды.

Икенче көнне Равияләр Һәдиятулла картны урамда очраттылар. Бабай йөгерә-атлый каядыр ашыга иде.

— Исәнме, бабай? Мәфтуха әби янына бардыңмы? Тереләме?

— Һай, рәхмәттән туган балалар, бу сезмени әле? Мәфтуха әбиегез терелеп килә, сәлам әйтте. Балны күбрәк ашатырга кушты. Мин кайтканчы тәпәнне бушатсыннар, яңадан бал суыртырга савыты кирәк, ди.

— Әле кая барасың, бабай?

— Менә Баса күленә батырган киндерләрем барые, шуларны судан чыгарып таратырга исәбем.

Нәҗияләр кичә юган керләрен үтүкләп кайтырга дип чыкканнар иде, картның күлгә барасын белгәч, аңа иярделәр.

— Без дә синең белән барабыз, бабай.

Картның кәефе әйбәт иде, каршы төшмәде. Киресенчә, шатланып кына куйды:

— Сез булгач, барып чыга инде ул. Нинди памушник икәнлегегезне белдем хәзер. Кичә әнкәләрегез ачуланмадымы соң?

— Юк, бабай, ачуланмады, — диде Равия.

— Ә минеке ачуланды, — диде Нәҗия.

— Нигә?

— Үзегез, без тимурчылар, дип йөргән буласыз, үзегез ни гомер Һәдиятулла бабагызның хәлен дә белмәгәнсез, диде. Һәдиятулла карт кебекләр күптер әле авылда, диде.

— Әйе шул, — дип элеп алды Равия, — укудан туктагач, малайлар да шул утраулары белән генә булышалар.

— Нинди утрау ул? — дип сорады Һәдиятулла карт.

Кызлар бер-берләрен бүлдерә-бүлдерә сөйләргә тотындылар.

— Без бит утрау таптык, — диде Нәҗия.

— Без түгел, малайлар, — дип төзәтте аны Равия.

— Ну ярар, малайлар булсын. Менә шул утрауга аркан кирәгие... — Нәҗия сүзнең ничектер ятышсызрак чыкканын сизеп туктап калды.

— Аркан белән әллә утравыгызны күккә асасызмы? — диде Һәдиятулла карт, шаярып.

— Ю-ук! — диделәр кызлар. — Таган ясарга кирәгие. Һәдиятулла бабай, син безгә бау ишеп бирмәссеңме дигәниек .

Йомышларын әйткәч, кызлар өсләреннән тау төшкәндәй җиңеләеп калдылар.

Һәдиятулла карт күзен хәйләкәр генә кыса төшеп:

— Сезнең кебек кызларга да ишеп бирмәгәч, — диде. — Тик бер шартым бар.

— Нинди шарт ул, бабай?

— Нindиме? Теге тәпәндәге балны ашап бетерәсез.

— И, бабай, чынлап әйтәсең дип торабыз...

— Ә мин чынлап әйтәм. Шунсыз бер карыш та аркан ишмәячәкмен.

— Әллә бер көндә? — дип сорадылар кызлар, чын-чынлап хафага төшеп.

— Ничә көндә бетерү сезнең эш инде, — диде карт. — Аркан тизрәк кирәк булса, тизрәк ашарсыз. Миңа тәпәне хаҗәт.

Равия Нәҗиянең җиңеннән тартып бераз арткарак калырга чакырды да дустының колагына болай диде:

— Бу бал турында малайларга әйтсәк, тиз ялтыратырлар иде инде, әйеме?

— И, син малайлар дисең, Хәйдәр аны берүзе дә ашап бетерә. — Кызлар үзләренең сүзләреннән үзләре көлеп җибәрделәр. Аларның көлү авазы бөтен кырга яңгырады.

— Их сез, шаян колыннар! — диде Һәдиятулла карт, ярату белән. — Нәрсәдән көләсез? Әллә муеннарыгызны җил кытыклыймы?

— Юк, бабай, кызык бит.

— Әйдә, әйдә көлегез. Сезнең көләр чагыгыз.

Шулай күңелле итеп сөйләшә-сөйләшә, алар Баса күленә килеп җиттеләр. Күл ягыннан ниндидер әчкелтем ис килә иде. Кызларның еш-еш сулап иснең нидән икәнлеген белергә теләүләрен төшенеп алган Һәдиятулла карт болай дип аңлатты:

— Киндер исе бу, балалар. Без хәзер сезнең белән бауның нәрсәдән ясалганын карарбыз. Әнә теге казык башларын күрәсезме? — Ул күлгә төртеп күрсәтте. — Шунда минем киндер көлтәләрем батырылган. Хәзер без аларны ярга чыгарып таратырбыз. Суда ятып йомшарганнардыр, инде җилдә җилләп кипсеннәр.

Һәдиятулла карт сөйләнә-сөйләнә суга кереп китте. Өскә калыкмасын өчен көлтәләрне ташлар белән бастырып куйган икән, берәм-берәм аларны ярга чыгара башлады. Ә Равияләр аңа булыштылар.

Кызлар аркан ишүне бик җиңел генә итеп күз алдына китергәннәр иде, судагы мәлҗерәгән, бүртенгән авыр көлтәләрне өстерәп чыга башлагач, гайрәтләре сүрелеп китте.

— Уф, — диде Равия, авыр көлтәне көч-хәл белән яр башына менгереп тараткач. — Әллә соң бу көлтәләр чыгарган саен арта барамы икән?

Наҗия шунда дустын битәрләп алды:

— Аркан табам дип шапырынмыйлар аны.

— Кем белгән арканны судан чыгаралар дип.

— Менә яңадан үзеңдә юк нәрсәне кешегә вәгъдә итмәссең.

— Соң, малайлар алдында аптырап каласы килмәде инде.

Кызларның нәрсәдәндер канәгать түгеллекләрен Һәдиятулла карт та сизде:

— Нәрсә, әллә билләргә суктымы? Арысагыз, ял итегез. Ашыгыч түгел. Бүген бетмәсә, иртәгә бетәр.

Әмма кызларга аркан ашыгыч кирәк иде шул. Әле бу көлтәләр кайчан таратылып бетә дә кайчан кибә?! Арудан да бигрәк шул кәефләрен төшерде.

Аларның уен белгәндәй, Һәдиятулла карт әйтә куйды:

— Көннәр матур гына торса, атна-ун көннән көлтәләрне дә талкый башларбыз. Сүсе әзер булса, арканны ишәсе генә кала.

Әйтүе тиз, эшләве генә озак. Малайлар күзенә ничек күренерсең. «Мактанчыклар, арканыгыз кая?» — дип, урамга чыгу белән сырып алырлар. Равияләрнең күлдән көлтә чыгарып йөрүләрен күрмәсәләр ярый да. Белсәләр: «Күлдән аркан ишәсезме?» — дип көләчәкләр.

Арып-талып күл буеннан кайткан чакта, кызлар шулай уйладылар. Ләкин кеше белмәгән, бигрәк тә малайлар белмәгән эш буламыни? Кәҗә тәкәсен чирәм белән сыйларга чыккан Һәнүз кызларны ярты юлда ук очратты. Ул аларның юеш киемнәренә ымлап:

— Әллә итәкләрегез белән балык сөздегезме? — диде.

Ни әйтергә белмәгән кызлар:

— Безне караганчы, әнә кәҗә тәкәңне кара, сакалына тигәнәк кунган, — дип җавап бирделәр һәм авылга йөгерделәр.

— Кызларга тел тидермә, — диде Һәдиятулла карт, — алар бүген бик нык эшләделәр. — Һәм карт Баса күленә батырылган көлтәләр турында Һәнүзгә сөйләп бирде. Һәнүзнең бу хәбәрне ишеткәч, йөрәге ярсып китте. Карале, дип уйлады ул. — Бауны нигә кызлардан көтеп ятарга? Әллә без сүс талкымаслыкмы? Бөтен малайларны җыярга да Һәдиятулла бабай белән күл буена төшәргә!

Икенче көнне малайлар иртүк Һәдиятулла картларга киттеләр. Аларның исәпләре кызлардан алданрак үзләре аркан ишеп кую иде. Ләкин алар килеп кергәндә, Равия белән Наҗия кер үтүкләп маташалар иде инде. Малайлар, үзләренең нинди йомыш белән йөрүләрен сиздермәскә теләп, бабайның утынын ярырга тотындылар. Боларның эше бетүгә, юмарт бабайның чәе дә кайнап чыкты. Чәй янына теге тәпәндәге балны кертеп куйгач, малайларның телләре чишелде. Тиз арада аркан кирәклеген сөйләп бирделәр.

— Тиз кирәк, дисез инде алайса? — диде Һәдиятулла бабай. — Элекке сүсем бераз барын бар инде минем. Вакытягы гына таррак. Менә тагын Баса күленә көлтәләр батырасы бар.

— Үзебез батырабыз, — дип дәррәү купты малайлар. — Син безгә күрсәт кенә, Һәдиятулла бабай.

— Алай дисәгез, була. Юкса минем ырматиз кузгалып тора иде.

Чәй эчеп тамак ялгаганнан соң, күмәкләп Баса күле буена киттеләр. Юлда аларга кәҗә тәкәсенә атланып йөрүче Һәнүз очрады. Дусларын күргәч, ул да тәкәсен бәйләп аларга иярде.

Күл буенда эш кайнады. Кайсылары көлтәләрне ташлар белән бастыра торды, кайсылары эшләүчеләрнең аяк астында буталды. Ничек кенә булса да, беркем дә тик тормады. Эш тәмамланганда, үзләре дә болганчык күлгә батырылган киндер көлтәсеннән ким пычранмаганнар иде. Ләкин монда да чарасын таптылар: пычранган киемнәрен чайкап чирәмгә җәйделәр дә үзләре туп тибәргә керештеләр. Бавын өзеп, Һәнүзнең кәҗә тәкәсе дә болар янына килеп җиткән иде: аны капкачы итеп куйдылар. Ике капка ясарга казык-фәлән булмаганлыктан, командаларга бүленеп тормыйча, һәммәсе кәҗә тәкәсенең маңгаена төбәп кенә типтеләр.

Бергәләп тотынгач, эш озакка бармады. Һәдиятулла карт бауны ишкән арада, малайлар кипкән көлтәләрне җыеп сүс талкыдылар һәм бабайга кирәк-ярагын әзерләштеләр. Урамда чыбыркы шартлатып үскән малайлар үзләре дә бау ишүдән бөтенләй мәхрүм түгелләр иде. Шунлыктан арканны таганлык кына түгел, ә бабайга җитәрлек итеп тә иштеләр. Башын башларга бау булгач, барысының да күңелләре күтәрелеп китте.

## 5. Бусы барып чыкмады

Бер генә түгел, ике таган асарлык аркан кулда була торып ничек инде түзеп йөрисең! Тизрәк баганаларын табарга да атына башларга кирәк. Әле бит таганнан башка да әллә ниләр корасы бар. Эш җитәрлек, әмма малайларның вакыты кысанланып китте. Сезнең утравыгыз бар дип кенә әти-әниләре аларны өй эшләреннән бушатырга ашыкмадылар. Әнә Зәкәриягә әнисе ничек кисәтеп әйтте:

— Бәрәңге бакчасын алабута баскан. Тизрәк ута, — диде. Ута, дип әйтүе ансат ул, үзләре утап карасыннар иде менә. Олыларның эш шәп: приказ бирәләр дә эшкә китәләр. Колхоз эшенең нәрсәсе бар аның? Әтисе әнә тракторда, көне буе утырып кына йөри. Әнисенең эшен әйткән дә юк: көнгә күпме сөт савылганны хисаплап бара. Их, Хәйдәрнеке кебек апаларың булсын иде, ичмасам. Бер елак сеңлесе генә булса да ярап торыр иде. Акыртып алабута утарга кушар идең дә үзең чыгып чабар идең.

Зәкәрия шулай үзен-үзе кызганып бакча утарга кереште. Кайчагында үзен артык кызганса, күзеннән яшь чыга иде, бүген анысы да күренмәде. Хәер, яшь чыгудан ни файда! Аны барыбер әнисе күрми. Күрмәгәч, бу яман эштән дә коткармый.

Бер чүп өзгән саен, ике тапкыр тыкрыкны күзәтеп торды ул. Берәр иптәш малае килеп чыкса, су керергә төшәргә сәбәп булыр иде. Тик үч иткәндәй бар да юкка чыгып беткәннәр. Әллә аларны да шушы каһәр суккан бәрәңге бакчаларына бәйләп куйганнар инде. Көтә торгач, ниһаять, тыкрыкта Һәнүз күренде.

— Әйдә су керергә, — дип кычкырды ул. — Прәме көйдерә бүген. Кәҗә тәкәсен абзарга яптым да сыпырттым әле.

— Синең эшләр җайлы, — диде Зәкәрия, көрсенеп. — Кәҗә тәкәсен аны кем дә саклый. Менә син бакча утап кара.

— Бакча бер бетә ул. Ә кәҗә тәкәсе мәңге бетми. Ач та тотып карадым инде, үлә торган хайван түгел.

— Ә син аңа кызу көндә су эчермә.

— Ну, малай, алай булмый инде. Ул да җан иясе бит.

— Анысы шулай, — дип килеште Зәкәрия.

Малайлар бер-берләренә зарланышып су буена төшеп киттеләр. Салкын суда иреннәре күгәргәнче коенганнан соң, комга сузылып яттылар. Рәхәт җылы ком татлы хыялларын уятып җибәрде.

— Карале, Һәнүз, син тәкәңне сакларга бер эт ал. Нәрсәгә аның белән җәфаланасың? — диде Зәкәрия.

— Чынлап та, бер эт алып өйрәтеп җибәрсәң, ә? Шундый бер кино да бар бит: урман каравылчысының кәҗәсен этләре алып кайтып йөри. Тик мондый этне каян табасың?

— Өйрәтсәң, этнең ниндие дә кәҗә генә саклый ала инде, — диде Зәкәрия. — Менә бакча утарга гына ярамый ул эт.

— Нигә ярамасын?! — дип каршы төште Һәнүз. — Һәрбер алабута яфрагына бал сөртеп чыксаң, шуңа алданып утар.

— Юк, алай да утамас. Балын гына ялар да китәр. Ә син чынлап та эт ал, Һәнүз. Этең кәҗәңне саклый башлагач, миңа булышырсың.

— Һи, малай, ул мөгезле шайтаннан котылсам, әллә нәрсәләр эшләшер идем әле. Аңардан котылып булмас шул.

Ике дус шулай кайнар ком өстендә гәп сатып яткан арада, бүтән малайлар да су буена җыелып өлгерделәр.

— Карагыз инде боларны, — диде Хәйдәр, ыштанын сала-сала, — безгә әйтми генә комда рәхәтләнәләр. Ә без аларны урам бетереп эзләп йөрибез.

— Безнең кайда икәнне Һәнүзнең кәҗә тәкәсеннән сорарлар. Ул әйтер иде, — диде Зәкәрия, мутланып.

— Шуңардан сорадык та инде, югыйсә бу ком арасыннан ничек эзләп табар идек, — диде Хәйдәр дә.

— Синең эшләр хутта, корсагыңны катык белән тутырасың да көне буе трай тибәсең, — диделәр малайлар Хәйдәргә.

— Трай тибеп йөрмим әле, — диде Хәйдәр, бик эшлекле кыяфәт белән. — Мин сездән күбрәк эшләдем.

Хәйдәр үзенең нәрсә эшләгәнлеген сөйләргә авызын ачкан иде, малайлар кычкырып көләргә тотындылар да сүзен бүлдерделәр. Бер читтә әкрен генә курай сызгыртып утыручы Зәйтүн дә авызыннан кураен алды. Аның болай да ябылып җитмәгән иреннәре Хәйдәрнең сүзләреннән соң бөтенләй ерылып китте. Чөнки эшләдем дип башкаларны ышандыра алса да, Зәйтүнне ышандыра алмый Хәйдәр. Алар янәшә күрше генә. Араларында хәтта койма да юк. Хәйдәрнең иртән торып юынырга чыкканына хәтле күреп тора Зәйтүн.

Зәйтүн үзе бик иртә торырга ярата. Бакчада кошлар уяна башлау белән кураен ала да ишегалдына чыга. Соңгы вакытта ул каз бәбкәләрен курай уйнап чакырырга өйрәтте. Курай тавышын казлар да ярата икән. Бигрәк тә яшь бәбкәләр. Зәйтүннең уйнавын ишетүгә, йөгереп улак янына киләләр. Кайберләре хәтта, ашауларын онытып, муеннарын бора-бора тавыш килгән якка карыйлар. Мондый бәбкәләрне Зәйтүн «музыкаль бәбкәләр» дип йөртә һәм аларны башкаларыннан аеру өчен тәпиләренә кызыл чүпрәк тә бәйләп куйды. Аның бу кыланышыннан Хәйдәр җай чыккан саен көләргә ярата иде. Әле дә менә башкаларга кушылып Зәйтүннең дә авыз ерганын күргәч:

— Их, музыкаль бәбкә! — дип куйды.

Малайлар шулай бер-берләреннән көлеп арыгач, үзләренең утрауларын исләренә төшерделәр. Болай дип әйтү дөрес тә булмас, чөнки малайларның үз утрауларын бер генә минутка да онытып торганнары юк. Сүзне шаяруга борулары да авырткан урынга кагылырга куркудан иде. Нигә дисәң, һаман да таган ясарлык багана таба алмыйлар. Һәркем үз ишегалларының иң яшерен почмакларына чаклы разведка ясап чыкты, әмма болар эзләгән алтын җирдә аунап ятмый иде шул.

Бәхет кайвакыт көтмәгән җирдән килә, диләр. Дөрес икән. Урам уеннарында сирәк катнашучы бераз чирләшкәрәк Илһам, ябык тәнен малайларга күрсәтергә оялып, бер читтә су кереп ята иде. Үз янына малайлар килүен күргәч, тиз генә судан чыгып киенергә тотынды һәм гомердә булмаган нәрсә — үзе башлап малайларга сүз катты:

— Малайлар! — диде ул, кыю гына. — Мин сезгә таган ясарлык баганалар табып бирәм.

— И, чүрәкәй үрдәк, син дә безне үртәргә булдыңмы? — диде Зәкәрия.

— Үртәмим, валлаһи. Ипидер менә!

— Йә, йә, әйтеп кара.

— Багана дигәнең казык кына булмаса.

— Аңарга казык та багана булып күренәдер, бәлки.

Малайларның сүзләре күбәеп киткәч, Зәкәрия тавышларын басарга теләп кычкырып җибәрде:

— Чыркылдашмагыз әле, кешегә сөйләргә ирек бирегез.

Тавышлар басылгач, Илһам:

— Безнең әтинең өрлеккә дигән бик җилле баганалары бар, — шуларны алабыз.

— Әтиеңнеке булыр ул, безгә тәтемәс шул алар, — диде малайлар.

— Мин әтидән сорадым инде, алыгыз, диде.

Моңа барысы да бик куанышты. Эшне озакка сузмыйча, баганаларны су буена төшерә башларга карар иттеләр. Шул ук көнне егерме-утыз малай Илһамнарның бакча артларына җыелды. Кайда малайлар — шунда тавыш куба. Кычкырышмый, бәхәсләшми генә эшли алалармыни алар? Менә бүген дә гауга чыкты. Башлап җибәрүчесе шул футбол җене кагылган Һәнүз булды. Имеш, боларны таган ясап әрәм итәргә ярамый, футбол капкаларына бер дигән. Яңадан мондыйны үлсәң дә тапмыйсың. Фәлән дә фәсмәтән.

Әмма Зәкәрия элеккечә Һәнүзне яклап чыкмады, таганга булгач, таганга, дип кырт кисте. Бу ике аерылмас дусның беренче тапкыр гына якага-яка килүләре түгел иде, ләкин башка вакытта бәхәс ничек тиз башланса, шулай тына да иде. Бүген сүз озаккарак китте, чөнки малайлар да ике төркемгә аерылды. Бер төркеме Зәкәрияне, икенче төркеме Һәнүзне яклады. Футбол сөючеләр күбрәк булып чыкты, ахры, Зәкәрияләр төркеме җиңелә башлады. «Таганда кызлар гына атына, сезгә яулык бәйләргә кирәк алайса», — дигән сүзләр дә ява башлагач, йодрыклар эшкә җигелде. Чабагач белән ашлык суккандагы шикелле дөпе-дөпе дөмбәсләшү китте. Кемнең кемгә сукканын аермалы түгел иде. Шул вакыт каяндыр Илһамның әтисе килеп чыкты һәм берничә малайны якасыннан эләктереп:

— Нишлисез сез, эттән туган нәрсәләр? — дип үкереп җибәрде.

— Үзегез биргән өрлекләрне алабыз, — диделәр капкынга эләккән малайлар, мыш-мыш итеп.

— Бирермен мин сезгә өрлек!

Илһам иптәшләрен мондый хәлгә куюына кыенсынып, этисе каршына чыгып басты:

— Җибәр ул малайларны, бүрәнәләрне алырга мин куштым, — диде. — Барыбер былтырдан бирле череп яталар бит.

Әтисе Илһамга акаеп карады. Ә теге малайлар, Салих абзыйның бармаклары язылуын сизеп, бу тирәдән ычкыну ягын карадылар. Өрлекләрне Илһамның этисе рөхсәт итмәгәнлеге һәркемгә ачык иде.

Малайлар киткәч, Илһам белән этисе арасында каты гына сөйләшү булып алды. Иптәшләренә эндәшергә кыюлыгы җитмәсә дә, этисеннән куркып тормады Илһам.

— Нәрсәгә саклыйсың ул өрлекләреңне? Мин аларны барыбер балта белән турап ташлыйм, — диде ул. — Хәзер малайлар мине урамга да чыгармаячаклар.

— Урамга чыкмаганнан үлмәссең, шыңшыма, — диде Салих абзый. —Әнә гармуныңны өйрән, ничу трай тибәргә.

— Гармунны мин бүтән кулыма да тотмыйм.

— Кулыңа тотмасаң, муеныңа муенчак итеп асам мин аны. Тик шыңгырдап йөрсен.

Салих абзый үзе кечкенәдән гармунга кызыгып үсте. Төннәрен берәр кеше урамнан гармун уйнап үтсә, сикереп торып гармун тавышын тыңлый иде. Тавыш бөтенләй ишетелмәс булгач та, урынына ятарга ашыкмый, тәрәзә яңагына сөялеп, озак кына тыңлап тора иде. Ләкин бик кызыкса да, аңарга гармун уйнарга туры килмәде. Әле тегесен, әле бусын җиткерим дип йөри торгач, яшьлеге үтеп китте. Эшли башлагач, беренче эш хакына өч бакалы бер тальян гармун алып кайткан иде дә өйрәнә алмады. Аның бөтенләй өмете киселде. Улы Илһам тугач, Салих абзыйның хыяллары яңадан уянды. Малае тәпи басканчы ук, бик зур хромка алып кайтып куйды. Тик Илһам аны күтәрер хәлгә килгәнче үк ватып бетерде. Башта пычак белән күреген тишкәләде, көче җитә башлагач, каерылырдай җирләрен каерды. Салих абзый моның өчен Илһамның йомшак җирен гармун каешы белән бик каты пешерде дә улына тагын да зуррак гармун алып кайтып бирде.

Илһамның әле теге гармун өчен кыйнаган җире төзәлеп тә җитмәгән иде, шуңа күрә бу гармунны үзенең беренче дошманы итеп санады. Дошманнан, билгеле, үч алалар. Илһам да җае чыккан саен шуны гына карады. Элек ул кечкенәлеге аркасында пычак белән эш итсә, хәзер, үсә төшкәч, хәйләнең дә шәбрәген уйлап тапты: тышкы ягына зарар китерми генә телләрен бозды. Улыннан гармунчы ясап булмасын аңлаган Салих абзый Илһамга эченнән ачу саклап йөри башлады.

Ата белән ул арасында менә шундый дошманлык яши иде. Бәлки, Салих абзый шуңарга да Илһамга катырак кагылгандыр. Малайлар каршында авторитет казанырга теләгән Илһам болай гына этисен күндерә алмагач, хәйләгә кереште:

— Әгәр өрлекләреңне малайларга бирсәң, гармуныңны өйрәнәм, — диде ул.

Салих абзый, исе китеп, Илһамга карады. Зур дошманы — гармунны өйрәнергә вәгъдә иткәч, бу өрлекләр бик кирәктер инде дип уйлады. Шулай да: — Нәрсәгә соң ул өрлекләр? — дип сорамый кала алмады.

Илһам утрау турында сөйләп бирде. Дөрес, әле утрауга аның үзенең дә барганы юк, ләкин бармаган-күрмәгән кеше кайчагында күбрәк белүчән була. Илһам да шулай итте: белгәнен белгәнчә, белмәгәнен үзеннән чыгарып сөйләде. Әтисе аны тыңлаганнан соң:

— Күптән шулай диләр аны, — диде. — Тик сез ул өрлекләрне анда ничек алып барырсыз соң?

Анисы инде Илһамга кагылмый иде. Ул тизрәк малайлар янына сөенче әйтергә ашыкты. Әмма бер мәртәбә авызлары пешкән малайлар Илһамга ышанмадылар.

## 6. Офыклар киңәя башлады

Малайларның дәртен бу уңышсызлык сүрелдермәде. Алар башка юллар эзли башладылар. Һәркем үз тәкъдимен кертте. Шундый кызу бәхәс барганда, Хәйдәрнең башында бер план туды. Ул җан дусты Зәйтүнне читкәрәк дәшеп:

— Беләсеңме, малай? Булат абыйга әйтеп карарга кирәк безгә. Ул бит колхозда төзү бригадасы бригадиры. Аның кул астынданиләр генә юк. Мин әйтсәм, ул сарай да салып бирәчәк... — Хәйдәр үзенең бераз арттырып җибәрүен абайлап туктап калды. Мактанса, мактанырлыгы бар Хәйдәрнең. Авылда иң таза, иң әйбәт саналган Булат абый Хәйдәрнең бөтен теләген үтәргә әзер тора. Ник алай дисезме? Моның үзенә күрә сере бар. Ә сер дигәнебез Хәйдәрнең апаларында. Берсеннән-берсе матур өч апасы бар аның. Ә инде уртанчы апасы Галимә — күз өстендә кара каш. Ул тез асларына җиткән озын толымнарын салындырып урамнан үтсә, бөтен егетләрнең күзе юлда була. Клуб сәхнәсенә менеп җырлап җибәрсә, һәр

егет учларыннан ут чыкканчы кул чаба. Менә шушы Галимә апасы өчен Булат абыйсының җан атканын белмиме әллә Хәйдәр? Белә, бик белә. Бераз мактанып җибәрүе дә шуңа күрә иде.

Зәйтүн аның һавалануына игътибар итеп тормады. Вакыты андый түгел. Ул тизрәк дустының фикерен куәтләргә ашыкты:

— Әйе, Булат абый тотынса була инде, — диде. — Булат абый теләсә баганаларын да табар, таганын да ясап бирер. Куллары алтын бит аның. Юкка гына ул салган өйләрне Казан тикле җирдән килеп киноларга төшереп йөрмиләр. Ничек элегрәк башка килмәгән бу?

Хәйдәр белән Зәйтүн шатлыкларын бүтән малайлар белән дә уртаклаштылар. Малайлар сөенешеп Хәйдәрне күккә чөйделәр.

— Корсак кына түгел, баш та бар икән үзеңдә.

Булат абыйларының эштән кайтканын көтеп тору артык озакка китәчәк иде, тоттылар да җыйнаулашып аның эшләгән җиренә юнәлделәр. Колхозның балта осталары дуңгыз фермасы салып яталар икән. Эшчеләрнең үзләрен күргәнче үк, пычкылар чыжылдаган, балталар тукылдаган, чүкечләр шакылдаган тавышлар ишетелә башлады. Малайлар дәртләнеп киттеләр. Менә osталар үзләре дә күренде. Алар арасында Булат абыйларының мәһабәт гәүдәсе әллә каян аерылып тора. Ул ышкы белән нәрсәдер ышкылый иде. Хәрәкәтләре шундый җитез, шундый җыйнак, әйтерсең үзенең яраткан музыка коралында уйный. Башкалар да үз эшләре белән бик мавыкканнар: берәүләр кулында пычкы сандугач булып сайрый, икенчеләрендә чүкеч тукран булып тукылдый, әйтерсең син төзелеш барган җирдә түгел, ә сихри авазлар таратучы серле урманда. Бөтенесе күңелгә якын, бөтенесе күңелгә рәхәт!

Малайлар, аларны эшләреннән туктатырга кыймыйча, озак карап тордылар. Менә, ниһаять, осталар тын алырга туктады. Булат абыйлары ерактан ук Хәйдәрләрне күреп алды һәм үз эшчеләренә ымлап:

— Монда безгә алмашка бригада килгән, егетләр, ә без эш белән мавыгып күрми дә торабыз. Ягез әле, дөресен генә әйтегез, безгә ярдәмгә килдегезме? — диде.

Булат абый әллә чынлап әйтте, әллә шаяра, малайлар аның тел төбенә төшенеп җитмәделәр. Шулай да сынатырга исәпләре юк иде, һәммәсе бер авыздан булмаса да, эшләргә килдек, диделәр.

— Эшләргә килгән кешенең кулында коралы була торган иде, — диде берсе.

— Бәлки, алар тылсым беләләрдер, — диде икенчесе, хәйләкәр елмаеп.

— Ярар, егетләр, — диде Булат, — малайлардан көлмәгез, эш белән сынап карыйк үзләрен. — Һәм Булат бура эченнән ике пычкы алды да малайларга бирде.

— Мәгез, үскәннәрем, менә бу агачларны кисә торыгыз. — Ул кисәргә дигән агачларга балта белән тамга салып чыкты. Малайлар эшнең катлаулырагын теләгәннәр иде. Шуңа күрә пычкыга ялкаурак үрелделәр. Аларның пычкылары, кибеп сөяккә әйләнгән агачлар өстеннән озак кына сикергәләп йөрде, ә инде агачның яртысыннан күбрәгенә җиткәч, еш кына кысылып кала башлады. Әмма малайларның сынатырга исәпләре юк иде, маңгай астыннан өлкәннәргә таба карап-карап алдылар да тагын пычкы тартырга керештеләр. Берсе мышнап туктаса, икенчесе алыштырды. Ә кулларына бөтенләй эш тапмаганнарны Булат абыйлары йомычка җыярга кушты. Анысын малайлар коры тоттылар. Хәер, берәмтекләп җыйсалар, шактый озакка китәсе иде. Монда Зәкәриянең йомры башы ярдәм итте:

— Нишләп боларны берәмтекләп җыеп йөрибез, — диде ул. — Әнә теге киртәнең ике башына бау бәйлибез дә шуның белән бер өемгә тарттырабыз.

Болай иткәч эш чынлап та җайлы китте. Киртәләре йомычка өстеннән шуып кына китмәсен өчен, олы корсаклы Хәйдәрне бастырык өстенә басып йөрергә куйдылар. Ике як баудан да дүртәр-дүртәр малай өстерәде.

Боларның ут өертеп эшләүләрен күргән осталар:

— Элегрәк киләсегез калган, ферманы күптән салып бетергән булыр идек, — диештеләр. Мактау сүзләреннән күңелләре күтәрелеп киткән малайлар тагын да тырышыбрак эшләргә тотындылар. Осталарның кулындагы үткен кораллар аларның күзләрен яндырды. Малайларның кызыгып карап торуын күргәч, арадан берсе әйтә куйды:

— Әллә соң, егетләр, яшь алмашка корал биреп карыйбызмы?

— Бирергә була. Яшьләр төшеп калганга охшамыйлар.

Осталар үз коралларын малайларга бирделәр. Ләкин тегенди-мондый ботакка эләктереп үтмәсләмәсеннәр дипме, кабаланудан кул-аякларын җәрәхәтләмәсеннәр дипме — үзләре дә шушы тирәдәрәк торырга тырыштылар. Малайлар эшкә бик дәртләнеп керешсәләр дә, йомычка җыйгандагы шикелле тиз алдырып китә алмадылар. Булат абыйсының кулындагы ышкы Хәйдәр кулына күчкәч, комга эләккән чана табанындай бөтенләй йөрмәс булды. Йә ул агачка тирән кадала да шомартасы урында киртләп куя, йә бөтенләй йомычка да эләктермәгән килеш өстән китә. Зәкәриягә борау тигән иде, аның эше

Хәйдәрнекенә караганда шомарак барды. Шулай да баштарак, туры гына тишәсе җирдә әллә кая каергалап маташты.

Балта белән эш итүчеләрнең хәле җиңелрәк иде. Үткен балта белән агачка китереп чапкан саен, симез-симез йомычкалар як-якка оча торды. Малайлар тигез итеп юну турында кайгыртмадылар. Алар өчен иң мөһиме — күбрәк йомычка чыгару иде. Канатланып очкан йомычкалар арткан саен, аларның шатлыклары да арта барды. Алар ышкы, борау белән мәш килүче дусларыннан көлеп тә алдылар:

— Хәчтерүшләр, йөрисез шунда чалбар туздырып. Бер самавыр кайнатырлык йомычкагыз да юк. Әнә бездән үрнәк алыгыз.

— Балта белән кем дә эшли, — диде Хәйдәр.

— Агач урынында бодай күмәче, ышкы урынында синең тешләр булса, умырыр гына идең син, ә? — диделәр Хәйдәргә.

Шаяруга Зәйтүн генә катнашмады. Аңарга кечкенә кул пычкысы эләккән иде. Кисә башлау белән ул кипкән ботакка эләкте дә зыңлап китте. Шуның зыңлаган тавышы Зәйтүнгә җитә калды: бер тарта да колагын куеп тавышын тыңлый. Ул инде пычкыны ни өчен кулына алганын да оныткан. Әйтерсең аңа кипкән каен музыкага сәләтлеме-юкмы икәнен белергә кушканнар. Неп-нечкә агачны кисеп чыгара алмыйча күпме маташыр иде, анысы билгесез, шул вакыт аны Зәкәрия күреп алды. Билен турайтып, хәл җыярга җай эзләп торган кешегә җитә калды:

— Карагыз әле, — диде ул, Зәйтүнгә төртеп күрсәтеп, — Зәйтүн агачны сихерләп маташа.

— Скрипка ясарга уйлыйдыр ул, — дип эләктереп алды башкалар да. Малайларның арыганлыкларын күреп, осталар коралларын үзләренә алдылар.

— Булдырасыз икән, ышандык.

— Яңадан да килегез шулай, — диделәр алар.

Малайлар чынлап та арыганнар иде, эш коралларын һич тә ялындырмыйча хуҗаларына кайтардылар. Аннары үзләре ясаган йомычкаларны эчке бер горурлык белән берәмләп кенә теге өемгә өйделәр. Шомарасы урынга киртләнеп-киртләнеп калган агачлар да, өемнең өстенә үк менеп утырган йомычкалар да үтә сөйкемле күренде аларга. Кулларына сеңгән нарат исенә кадәр кадерле иде. Хәзер инде үзләренең йомышлары турында әйтәселәре генә калды. Тик Хәйдәр генә, монда ни өчен килгәнлеген оныткан сыман, һаман такталар өеме яныннан китә алмый. Иптәшләренең кисәтүле караш белән карап алуларын да сизми ул.

Осталар һәркайсы үз урынына таралышып беткәч кенә, Хәйдәр Булат абыйсы янына килде:

— Булат абый, без... мин... Без синең янга килгәниек. Баганалар кирәгие.

Булат малайга сәерсенеп карап куйды.

— Нәрсәгә ул? Әллә штабыгызга телефон үткәрәсезме?

— Ю-ук, безнең нинди штаб булсын. Беләсеңме, Булат абый, без әкәмәт шәп бер утрау таптык бит әле.

— Берәрсе төшереп калдырганмыни?

— Төшермәгән. Башкорт әрәмәсеннән Ык кисеп алган. Су теге Каран буеннан икегә аерылып ага башлаган да ике Ык арасында утрау барлыкка килгән. Без тоттык та шул утрауны үзебезгә алдык. Анда футбол уйнарга да әйбәт: тәрәзәләр ватылмый, бакчалар тапталмый. Менә шул утрауга баганалар кирәгие.

— Нәрсә корасыз соң анда?

— Таган ясарбыз дигәниек. — Ул, ашыга-ашыга: — Арканын таптык инде, — дип өстәде.

— Алай булгач, эшегез бәләкәйдән генә калган икән. Тәк, тәк. Ничек кенә ярдәм итәргә соң сезгә? Бер дә баш эшләми тора бит әле.

Ачык кына җавап ишетелмәгәнлектән, малайларның борыннары салынды. Булат аларның кәефләрен күтәрергә теләп:

— Ярар, дуслар, уйлашырбыз, хәзергә эш бар, — диде.

**7. Рәис белән сөйләшү**

Эш беткәч, Булат Хәйдәрне ияртеп утрауны карарга китте. Яшел утрау аларны саф һавасын аңкытып каршы алды. Камыштай нәзек таллар йомшак җилдә билләрен бөгеп сәлам бирде. Чәчәкләр хәйләкәр генә күз кысышты, куакларда сандугачлар җыры яңгырады.

Бөтен дөнья сихри моңга чумган иде. Әйтерсең син гади бер әрәмәдә түгел, ә нindидер әкият бакчасында. Мондагы саф һавадан күкрәкләрең киңәя, арыган тәннәрең языла. Үзеннән-үзе күңел күтәрелә. Менә әле Булатның да Хәйдәр белән әбәкле уйныйсы, ул да түгел, карамадан сигез буынлы камчы үреп, дөньяга яңгыратып шартлатасы килде. Булачак каенише алдында сабыйлыгын күрсәтмәс өчен

генә йомшак чирәмгә тәгәрәп мәтәлчек атудан, дулкыннар чыгарырлык итеп сызгырудан тыелып калды. Ә Хәйдәр тизрәк Булат абыйсының фикерен ишетергә тели иде.

— Ничек соң, Булат абый, безнең утрау шәпме?

— Искиткеч!

— Менә монда футбол уйнарга бик җилле аланы да бар. Без аны чүпләрдән шундый итеп чистарттык: күлмәгеңне салып түшең белән шуышсаң да корсакка шырпы кадалмый. Корыган агачларны ут төртеп яндырдык, тамыр-томырларны казып ыргыттык.

— Молодцы!

— Булат абый, менә монда таган ясап җибәрербез. Кәнишне без анда үзебез атынмабыз инде, кызлар теңкәгә тияләр, шулар өчен генә корырга булдык. Таганда атыну ир малайлар уены түгел инде, әйеме, Булат абый.

Ләкин Булат Хәйдәрдән арттарак калган иде, бу сүзләрне ишетмәде. Аны утрау чынлап та әсир итте. Күңелендә әллә нинди уйлар кузгалды. Биредә бер таган асып кына эш чыгарлык күренми. Бөтен авыл, хәтта күрше-тирә авылларның да бала-чагалары рәхәтләнеп ял итәрлек урын бит бу! Ләкин моны ничек эшләргә, кем белән киңәшергә?

Булатны шул сораулар борчыды. Соңыннан ул Галимә белән киңәшеп карарга булды.

Хәйдәрнең апасы Галимә мәктәптә укытучы булып эшли. Ләкин ул Казанга ике атналык семинарга киткәнлектән, үз укучыларының нинди эшләр белән мәш килеп йөрүләрен белми иде. Булат аның Казаннан кайтканын түземсезлек белән көтеп алды. Ә беркөнне Галимәнең ферма ягына баруын күргәч, куанып бетә алмады. Юлда ук туктатып, хәл-әхвәлләрен сорашты, аннары Хәйдәрләрнең, Зәйтүннәрнең ни кубарырга теләп йөрүләрен сөйләп бирде.

— Кара син аларны! — диде Галимә, укучылары өчен куанып. — Мин әле аларның ялы хакында үзем дә уйланып йөри идем, ләкин башка рәтле фикер килгәне булмады.

— Син иртәрәк сөенәсең әле, Галимә, — диде Булат. — Малайлар бездән конкрет ярдәм көтәләр. Эш аларга атынчык ясап бирүдә генә түгел. Әгәр мәсьәлә таганда гына булса, мин анда үземнең капка баганаларымны да илтеп утыртыр идем.

Галимә уйга калды. Чынлап та, энеләребезнең, сеңелләребезнең җәйге яллары хакында кайгырта башларга вакыт түгелме икән? Урамда трай тибеп, чыпчык оялары туздырып, башкалар утырткан кыяр-помидорларга кызыгып йөрүче, җае чыкканда бакчага төшү ягын чамалаучы үсмерләр әзмени?

Булат белән Галимә утрауны ни рәвешле бөтен авыл баласы рәхәтләнеп уйнарлык, көч тупларлык урын итү турында озак киңәштеләр. Төрле тәкъдимнәр әйтелде, ләкин алар яраксыз дип табылып, кире кагыла тордылар.

Соңыннан Галимә:

— Кара әле, Булат, — диде, — анда спорт лагере сыман нәрсә ачсак ничек булыр иде икән?

— Минем дә башка шундый ук фикер килгән иде килүен. Әмма андый нәрсә оештыру синең белән миннән генә тормый.

— Анысы шулай, Булат. Тик кем дә булса башлап йөрергә тиеш бит инде. Колхоз рәисе белән дә сөйләшергә, мәктәпкә дә барырга, ронога да хәбәр итәргә кирәк. Кем әйтмешли, бөтен чаңнарны кага башласак, шәт, бернәрсә чыгар.

Яшьләр, шулай киңәшкәннән соң, идарәгә киттеләр. Анда колхоз рәисе Ихсан абый белән бер милиционер кызып-кызып нәрсәдер хакында сөйләшә иде. Алар үзләре янына килеп кергән яшьләргә игътибар итмичә, бәхәсләрен дәвам иттеләр.

— Әллә каян читтән килгән кешеләр эше түгел бу, — диде милиционер. — Шушы авыл малайлары эше.

— Юк, юк! — диде Ихсан абый. — Безнең авылда андый кәкре куллы малайлар барына ышанмыйм.

— Ышану-ышанмау анысы сезнең эш. Әмма дәлилләр шуны раслап тора.

— Нинди дәлилләр?

— Беренчедән, мотоциклны күтәреп чыгып киткәннәр. Габбасларның ишегалларында да, авылдан чыгып киткән юлда да бернинди эз юк. Ә бит үзегез беләсез: кичә генә яңгыр яуды. Бер җирдә булмаса, икенче җирдә эзе калыр иде. Мотоцикл тикле мотоциклны озак күтәреп алып барып булмый. Димәк, кемнәрдер аны якын-тирәгә яшергән.

— Кемнәрдер, каядыр... — диде рәис, кабинетында йөренеп. — Кемнәр икәнен тап син. Болай без өй борынча йөреп тентү ясап йөри алмыйбыз бит.

— Нәрсә, әллә Габбасның мотоциклын урлаганнармы? — диде Булат, сүзнең ни хакында барганлыгын төшенә башлап.

— Әйе, — диде рәис, кәефе китеп. — Кем кызыккандыр шул иске мотоциклга.

— Малай-шалай искесен-яңасын тикшереп тормый, — дип сүзгә кушылды милиционер, — аларга урлашу үзе бер маҗара, ә урланган мотоциклда тотылганчы булса да йөреп калу — икенче маҗара.

— Менә-менә, — дип эләктереп алды сүзне Галимә. — Без дә нәкъ шул хакта сөйләшергә килгән идек.

Милиционер белән Ихсан абый икесе берьюлы Галимәгә борылып карады.

— Әллә кем урлаганын беләсеңме? — диде рәис, ниндидер өмет белән.

— Юк, — диде Галимә. — Мин мотоцикл турында әйтмим.

— Әй, — дип кул селтәде Ихсан абый. — Мин әллә берәр нәрсә беләсеңме дип торам.

— Ә мин беләм, — диде Галимә.

— Нәрсә беләсең?

— Балаларга рәхәтләнеп ял итәрлек, көчләрен, җитезлекләрен сынарлык спорт мәйданчыклары кирәк. Милиционер абый дөрес әйтә: алар һәр җирдән маҗара эзли. Бәрәңгедән җәй буе корт чүпләп, бакчадан алабута утап кына яшәп булмый. Яшь җан романтикага сусаган. Бәлки, әлеге мотоциклны да менә шул җан ярсуларын, маҗараларга сусауларын басар өчен урлаганнардыр.

— Һы, — диде Ихсан абый, — синеңчә бик кызык килеп чыга: әгәр мин берәр нәрсәгә бик сусыйм икән — кешенекен урларга тиеш буламмы?

— Мин алай димәдем. Врачлар, авыруны дәвалауга караганда аны булдырмый калу җиңелрәк, диләр. Менә безгә дә балаларны чын-чынлап мавыктырырлык уеннар уйлап табу зыян итмәс иде. Ә моның өчен стадион кебегрәк нәрсә кирәк.

— Миңа әллә нәрсәләр кирәк, ә иң кирәге — акча, — диде рәис. — Хәтта акча булганда да стадион алай тиз генә ясала торган әйбер түгел. Аны ясар өчен безнең авыл янында җайлы гына урыны да юк.

Галимә белән Булат рәиснең шушы сүзен генә көткәндәй, малайларның ике Ык арасында утрау табуларын, шунда кызлар өчен атынчыклар, ә малайларга футбол, волейбол мәйданчыклары ясау нияте белән йөрүләрен сөйләп бирделәр. Ләкин Ихсан абый яшьләрнең сүзен күтәреп алырга ашыкмады.

— Миннән ипи, сөт, ит сорыйлар. Һәркемгә иртән торуга шулар кирәк. Ә стадион ул булса ярый, булмаса ярый. Без урамда сыер ябагасыннан ясаган туп белән лапта уйнап үстек әле. Аңа карап бандитка әйләнмәдек. Менә сез — укытучылар — балаларны мәктәптә әйбәтрәк тәрбияләсәгез, безгә җиңелрәк булыр иде.

Тәрбия мәсьәләсенә кагылгач, Галимә кабынып китте. Дөрес, мәктәптә әле ул ике генә ел эшли, үзен бик тәҗрибәле кеше дип санамый, шулай да авылның иң абруйлы җитәкчесе тарафыннан укытучыларга карата әйтелгән сүзләр белән килешәсе килмәде.

— Бала мәктәптә көненә дүрт-биш сәгать кенә була, — диде ул. — Калган вакыты аның өйдә, урамда үтә. Сез, Ихсан абый, авылны үзегез үскән чор белән чагыштырмагыз. Ул вакытта авыл урамнарында яшел чирәм гөрләп утырган. Телисең икән, туп тип, телисең икән, ятып ауна. Ә хәзер, үзегез күреп торасыз, урам уртасында асфальт. Аннан бертуктаусыз машинасы, мотоциклы чабып тора. Һәр ата-ана, балам урамга чыкмаса ярар иде, дип куркып яши. Ә сез стадион кирәкми дисез.

— Мин кирәкми дип әйтмәдем. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар. Ә хәзер безнең бер кешене бишкә ярыр чагыбыз.

— Авылда эшнең бетәсе юк инде аның, — диде Булат, Галимәне яклап. — Печәне бетсә — урагы, урагын төгәлләсәң — көзге чәчүе. Бөтенесе бер-берсен көтеп кенә тора. Ә балалар эш беткәнне көтми, үсә, яхшымы-яманмы үз гамәлен кыла бирә.

— Миннән нәрсә көтәсез соң сез? — диде рәис. — Әйтәсен әйттем шикелле. Ярый, сез теләгәнчә утрауга кайбер нәрсәләр ясап куйдык ди. Ул вакытта бөтен бала-чага шунда агылыр. Ә арада йөзә белгәне бар, белмәгәне бар. Димәк ки, безгә елга аша күперме-басмамы салырга туры киләчәк. Алай зурдан кубарлык рәт юк бит безнең.

— Бер башласаң, балалар үзләре дә булышыр иде, — диде укытучы кыз. — Араларында егет булып килүчеләре бар бит инде.

— Шулай да ныклабрак уйлашыйк әле, — диде Ихсан абый. — Башлап ташларлык булмасын.

— Әлбәттә уйлашырбыз, бу әле эшнең башы гына, — дип килештеләр яшьләр.

Булат кына канәгатьләнеп җитмәде.

— Безгә моңа хәзердән үк тотынырга кирәк, Ихсан абый, — дип дәвам итте ул. — Берничә елдан сезнең эшләр ал да гөлгә әйләнә дип кенә малайларны тотып кара син. Без стадионнар төзегәнче, алар җиткән егеткә әйләнерләр.

— Бер буын үсеп җитсә, башкалары булыр, — диде рәис. Тарткалашу шактый озакка сузылды. Ниһаять, рәис чигенде. Булатның, эштән соң бөтенесен үзебез башкарырбыз, бернинди түләү кирәкми, дип әйтүе йомшарттымы яки малай чактагы хыяллары күңелендә яңардымы — малайлар сораган кайбер нәрсәләрне кора башларга ризалыгын бирде. Яшьләрне кисәтергә дә онытмады: — Карагыз аны,

җаваплылык сезнең өскә төшә, бәлки, елга аша чыгарга бер-ике көймә ясарга туры килер. Анысын үзегез карарсыз. Ә син, Галимә сеңелкәш, мәктәп белән киңәш-табыш кыл. Тәрбия эше четерекле нәрсә. Ялгышлык китмәсен. Моңа безнең хакыбыз юк, — диде.

## 8. Көймә килә, эзе юк

Рәиснең рөхсәтен алганнан соң, Булат эшне озакка сузмады, үз бригадасы белән сөйләште. Төзүчеләрнең күбесе бригадирның сүзен хуплап каршы алдылар. Чөнки бөтенесенең дә диярлек урам уеннарыннан ямь тапмыйча, һәр җирдән кызык эзләүче эне-сеңелләре бар. Үз энеләренә яхшылык эшләүдән кем баш тартсын инде? Дөрес, моның колхоз эшеннән бушаган вакытларда гына эшләнергә тиешлеген белгәч, кайберәүләр кире чигенергә маташып карады. Өлкәнрәк бер абзый:

— Минем урамда шар сугардай малаем юк, — дигән иде, Булат аңа:

— Аның каравы бөтен кешенең күз явын алырлык чия бакчаң бар, — дип җавап бирде.

— Һы, — диде абзый кеше, аптырап, — чия бакчасына атынгыч кирәкми аңа.

— Чия агачына кирәкмәгәнен без дә беләбез, — диде Булат. — Тик менә кая барып бәрелергә белмәгән малайлар чия агачына менеп атланмаслар дип кем әйтә ала? Ә бит алар анда бер менгәч, атынып кына калмаслар. Малайлар буш кесә белән йөрергә яратмыйлар.

— Ай-яй, ерактан чирттердең син, — диде абзый кеше, колак артын кашып. — Билгеле, малайларның көне буе утрауда мәш килүләре хәерле.

— Алайса килештек!

— Килешмичә нишлисең инде. Син ышандыра беләсең. Әгәр теләсәң, шайтанның үзен оҗмахка кертерлек агитлый аласың.

Башка каршы төшүче булмады.

Утрауда эшне башлап җибәргәнче, көймәләр ясарга булдылар. Иң кимендә ике-өч көймә кирәк иде. Булат, эшчеләре белән сөйләшкәннән соң, малайларны үз янына җыйды:

— Сезгә таган менә нәкъ бүген-иртәгә кирәкме, әллә бераз түзәрлегегез бармы? — дип сорады ул алардан. Тегеләр мондый сорауның ни өчен бирелгәнен аңламадылар, шуңа күрә өзеп кенә җавап бирә алмадылар.

— Бүген үк дип... Әзрәк түзеп буладыр инде, — диде берсе.

— Тизрәк ясалса, шәп инде ул, — диде икенчесе.

Булат аларга эшнең нәрсәдә икәнен төшендереп бирде:

— Билгеле, бик теләсәгез, эшне таганнан башларга мөмкин. Безнең иртәгә ял көнебез. Без инде үзара килештек: ял көннәрендә сезнең утравыгызга кирәк-яраклар төзиячәкбез...

Булат абыйларының сүзе беткәнен дә көтмичә, малайлар шатланышып «ур-ра» кычкырдылар. Шау-шуны басарга теләп, Булат кулын күтәрде:

— Туктагыз әле, мин әйтеп бетермәдем. Сез хәзергесе вакытта утрауга ничек чыгып йөрисез? Йөзепме?

— Әйе, — диделәр малайлар.

— Ә йөзә белмәгәннәр нишли? — дип дәвам итте Булат. — Алар утрауга чыкмаска тиешләрмени?

— Ык буенда үсеп, йөзә белмәгән малай буламыни? — дип каршы төште чуртандай оста йөзүче Нәсих.

— Бәлки, кызлар арасында йөзә белмәүчеләр бардыр? Әллә сез, үзегез атынганда, кызларны бу як ярда гына каратып тормакчымы? — Булат абыйларының бу соравына малайлар җавап бирергә ашыкмадылар. Чынлап та, алар кызлар турында бөтенләй онытканнар иде. Ә Булат абыйлары сүзен болай дип очлап куйды: — Менә шулай, дуслар, таганнарга тотынганчы, башта көймәләр ясыйбыз. Йөзә белгәннәр дә, белмәгәннәр дә утрауга теләсә кайчан чыгарлык булсын. Аннары көймәсез килеш без утрауга ничек итеп баганалар, такталар ташыйбыз? Йә, сез шуңа ризамы?

— Риза, Булат абый, риза!

— Тик алдан кисәтеп куям: үзегез куш куллап эшләрлек булсагыз гына без моңа алынабыз.

— Без төнлә дә эшләргә әзер, — диделәр малайлар.

— Көндез эшләсәгез дә җитәр, — диде Булат абыйлары.

Икенче көнне Булат абыйларының чакырганын да көтмичә, бөтен малай авылның такта яргычы янына җыйналды. Тиздән эшчеләр дә килеп җитте. Көймә өчен әзерләп куйган такта юк иде, эшчеләрнең үзләренә ярырга туры килде. Ярый әле бик әйбәт коры агачлар таптылар. Быел урамдагы электр баганаларын алыштырганнар иде. Аларның җиргә кереп торган өлеше генә черек, ә өске ягы малайларны картайтырлык нык иде. Бу баганалар белән алар икеләтә оттылар: беренчедән, тактаны яргач киптереп торасы юк, икенчедән, колхозның төзелеш материалына кагылмадылар. Эшчеләр такта ярганда,

малайларга да эш табылды. Алар такта яргыч янына таралган пычкы кибәкләрен зур фанер көрәкләр белән көрәп бер өемгә өйделәр. Бу тирә күптән чистартылмаган булган, күрәсең. Кай урыннарда пычкы кибәге тапталып, такталанып беткән. Башта җиңел генә күренгән эш тора-бара боларны шактый мышнатты. Җитмәсә, көне көн генәме? Баш түбәсенә ут яккандай иртәдән бирле кояш кыздыра. Әниләре кушкан эшне эшләгән чаклары булса, малайлар түбәләре җылына башлау белән Ык буена йөгерерләр иде инде, монда сынатырга ярамый шул. Итәгеңә ут капса да, учыңа йомарлап сүндерергә кирәк. Шунсыз ярамый. Булат абыйларының сезнең белән эш чыкмый икән дип кул селтәве бар.

— Сез артык кабаланмагыз, — диде аларга өлкәннәр. — Барыбер әле көймәләрне бер көндә генә ясап бетереп булмас. Сезгә бит бер көймә генә җитми.

— Берсе ясалса, булды, дияр идек инде, — диделәр малайлар.

Аларның сүзе Булатка да ошады.

— Хәзер безнең тактабыз бер көймәгә җитәрлек бит. Әйдәгез булмаса эшкә тотыныйк, — диде ул. — Мастерскойга кереп эшлибезме, әллә су буендамы?

Малайлар, бертавыштан:

— Су буенда! — дип кычкырдылар.

Булат өч эшчене такта янында калдырды да малайларга приказ бирде:

— Бөтенегез дә берәр такта сөйрәп су буена төшегез.

— Без икешәрне дә сөйри алабыз, Булат абый.

— Бер булгач, бер! Җитмәсә, яңадан кайтып алырсыз.

Малайлар такта өстерәп су буена төшеп киткәч, Булат эшчеләренә болай диде:

— Беребез складтан сумала барып алырбыз. Хәер, бер генә кешегә авыр булыр. Әле бит безнең сумала кайнатырга савытыбыз да юк. Мин үзем алачыкка сугылырмын. Анда эшкә ярамаган берәр мичкә табылмый калмас. Бәлки әле, ат-мазар очрап куяр. Бөтенесен шуңар төяп илтербез. Ә син, Әхмәт абый, кораллар ал да су буена төш. Малайлар таралышып бетмәсен. Коралларны кешегә бирергә жәлли торган гадәтең бар: аны оныт. Малайлар үзләре дә эшләсен. Кораллар үтмәсләнсә, чарларбыз.

Һәркемгә шулай эш бүлеп биргәннән соң, Булат алачыкка китте. Тимерче алачыгы яныннан ул зур гына тимер мичкә табып алды. Ләкин бу керосин, бензин ише нәрсә салыр өчен ясалган мичкә булганлыктан, авызы бик кечкенә иде. Булат аны сварщик янына тәгәрәтеп алып килде дә яртыдан кечерәк өлешен кистереп атты. Ул арада сумалага җибәрелгән егет тә колхозның бишекле мотоциклына атланып килеп җитте.

— Менә, транспортның шәбен таптым, иптәш бригадир, — диде ул. — Инженер үзе районга киткән, ә мотоциклы буш тора икән.

— Әйбәт, әйбәт, — диде Булат. — Алайса, син башта сумалаңны Ык буена илтеп кайт. Аннары менә бу мичкәне алып барырсың.

— Була ул, — диде кулына мотоцикл эләккән егет, — мин бу бахбай белән көне буе әйбер ташырга әзер. Кайчан үземә дә шушындыйны алып җибәрермен инде. Минекенең бигрәк рәте бетте. Артыннан өч чакрым этеп бармыйча кабынмый.

Егет вырлап китеп барды. Булат тагын берничә җиргә керде. Кечкенә әрҗә белән кадак һәм башка кирәк-яраклар алды. Бөтен нәрсә әзерләнеп беткәч кенә су буена китте.

Эшләр гөрләп барадыр дип уйлаган иде ул. Ләкин су буендагы хәлне күреп, бөтенләй аптырап калды. Такталар яр астына таратып ташланган. Бер якта сумала өеме. Шуның өстенә бер кечкенә кыз утырган да мышык-мышык елый.

— Нигә елыйсың? — дип сорады аңардан Булат.

— Ме-менә итәгем сумалага ябышты, — диде кыз, үксүеннән туктый алмыйча.

— Нигә аның өстенә утырдың соң?

— Беркая да кузгалма, шушыларны саклап тор, дип, малайлар утыртып киттеләр.

— Ә алар үзләре кая?

— Ашап киләбез, дип киткәннәрие.

Малайларның бу башбаштаклыгына Булатның ачуы чыкты. Эчтән генә Әхмәт абыйны да: «Малайларны тыеп торыр чагында, үзе шуларга ияреп киткән», — дип сүгеп ташлады. Аннары ул кызга дәште:

— Син, кызый, тор инде. Хәзер мин сакlармын.

— Торып булмый шул, абый. — Кыз торып булмаганын күрсәтер өчен урыныннан кузгалып куйды. Ләкин күлмәк итәгенә чатнап ябышкан сумала аны тиз генә ычкындырырга теләмәде. Бер калкынып, бер утырып маташкан кыз Булатның ачуын оныттырып җибәрде. Ул кыз янына килеп, аны сумала

әсирлегеннән коткарышты. Кызның чәчәкле ак күлмәгендә бүгенге көннең билгесе булып мәңге бетмәс сумала ябышып калды.

Менә берәм-берәм малайлар да су буена җыелыша башладылар.

— Шушымыни сезнең утрауны яратуыгыз? — дип каршы алды аларны Булат. — Теләмәсәгез, турысын әйтегез, мин көчләмим. Такталарны кайтарабыз да куябыз.

— Без бит...

— Ашарга гына киткән идек.

— Әхмәт абыйдан да сорадык, — дип акландылар малайлар.

Ул арада Әхмәт абый да килеп җитте. Булат аны да шелтәләргә уйлаган иде, ләкин үзенең дә бик каты карыны ачуын тойды. «Кара син аны, төш тә җиткән икән, әле эшнең башланганы юк» дип уйлады ул. Һәм бик ачыкса да төшкелеккә кайтып тормаска булды. Белмәссең, тагын эшләр туктап куяр.

Эшне башлап җибәрер өчен, Әхмәт абый белән Булат башта ике җиргә ыстан сыман нәрсә әмәлләделәр. Шунда такталарны салып ничек шомартырга икәнен күрсәттеләр. Тамакларын туйдырып, хәл җыеп килгән малайлар эшкә бик дәррәү тотындылар. Берсе шуып йөрмәсен өчен тактаны тотып торды, берсе юнды. Корал һәркемгә дә җитәрлек иде. Ык буенда урын да бик иркен. Шуңа күрә Булат су буен сайлады да инде. Коенырга теләсәләр — елгасы да янда гына. Малайлар бит үрдәктән ким түгел, сусыз тора алмыйлар. Ыстанда урын җитмәгән малайлар:

— Ә без нишлибез, Булат абый? — дип сорадылар.

— Сез ташлар алып килегез. Сумала кайната башласак, мичкәне утыртырга мич сыман нәрсә ясамый булмас.

— Сумала кайнатырга утын да кирәк икән әле, Булат абый.

— Анысы өчен кайгырмагыз, көймәсен ясаганчы сумала кайнатырлык кына йомычка чыгар.

— Сумаланы бүген үк кайнатабызмы, Булат абый?

— Юк, бүгенгә әнә шул әйткәннәрне эшли торыгыз.

Малайлар һәммәсе дә күрсәтелгән эшкә тотынгач, кызлар да Булат абыйлары каршысына килеп бастылар.

— Малайлар хәтле генә без дә эшли алабыз, Булат абый!

— Шулаймыни, үскәннәрем? Тик нинди эш бирергә икән сезгә? Кораллар да калмады бит әле.

Кызларның кәефләре кырылды.

— Таганга дигән бауны да без таптык әле, — диде Равия, үпкәләгән тавыш белән.

— Бауны алгач, хәзер малайлар борыннарын күтәрде, — дип өстәде Наҗия.

Булат бу кызларга нинди эш бирергә белми аптырап торганда, Әхмәт абый:

— Их, хәзер тешләрне сындырырлык салкын әйрән эчеп җибәрсәңме әгәр, — дип куйды.

— Вәт-вәт, — диде Булат. — Сез салкын кое суы белән берәр бидон әйрән алып килегез. Катыкны бездән кереп алыгыз.

— Катык үзебездә дә бар, — диде кызлар, шатланып, һәм боерыкны тизрәк үтәргә ашкынып өйләренә чаптылар. Әхмәт абыйның әйрән турында искә төшерүе чыннан да вакытлы булды. Бик әйбәтләп корсак тутырып килгән малайларның да иреннәре кибә башлаган иде. Кайберләре инде кызлар киләсе тыкрыкка карап-карап алгалый иде. Иң беренче ак бидонын күтәреп Равия килеп җитте. Ашыгудан ул салып эчәргә кружка-мазар да алып тормаган. Хәер, монда аның кирәге дә булмады. Әйрәнне бидоны-ние белән йотарга җитешкән малайлар, түшләренә салкын әйрәнне агыза-агыза, чын эшчеләрчә кабаланып эчтеләр. Иң нык сусаган Әхмәт абыйга әйрән дә калмады. Ул бушап калган бидон төбенә аптырап карап торганда, Наҗия килеп үз әйрәнен сузды. Шундый зур, шундый кирәкле эш эшли алуларына кызлар чиксез куандылар. Бу минутта алар үзләрен сугыш кырында яралы солдатларга ярдәм күрсәтүче санитарлар итеп тойдылар.

Эшләр шулай бик күмәк башланып китсә дә, бер көндә генә бетмәде. Ә икенче көнне эшчеләрнең ял көне түгел иде. Шунлыктан башланган эш бөтенләй туктап калды. Малайлар кая барып бәрелергә белми йөргәндә, Галимә апалары килеп чыкты.

— Сезгә бүтән помощник таптым әле мин, — диде ул.

— Кемне? — дип сорады малайлар.

— Хәзер күрерсез.

Укытучының сүзен расларга теләгәндәй, кечкенә әрҗә белән коралларын күтәреп балыкчы Гыйльметдин төшеп килә иде. Гыйльметдин абзыйны малайлар яхшы белә: аның көймәсе су өстендә майлагандай шуып йөри. Хәтта йоклаган балыкларны да уятмый, диләр аны.

Һәркем балыкчы абзыйны сөенеп каршы алды. Ә Гыйльметдин абзый күп сөйләшеп тормастан эшкә кереште. Бик тиз арада кемнең ни эшләргә тиешлеген күрсәтте.

— Бүген безгә мүк кирәк булыр, — диде ул ахырдан.

— Анысы нәрсәгә? — дип аптырадылар малайлар.

— Көймәне мүкләргә!

Малайлар мүкне каян табарга икән дип аптырап торганда, Равия белән Нәҗия Һәдиятулла картларга йөгерделәр. Һәдиятулла бабайның өйалдында әллә ничә төргәк чүбек күргәннәр иде. Алар тынныры-сулышлары бетеп килеп кергәндә, Һәдиятулла карт каядыр барырга җыенып тора иде. Кызлар исәнлек-саулык сорашырга да онытып:

— Мүк!

— Чүбек! — диделәр.

Һәдиятулла карт кызларны аңламыйча карчыгы Мәфтухага карады. Аннары:

— Менә шушылар инде, әнкәсе, син бүлнистә чакта өйне ал да гөл итеп торучылар, — диде. Мәфтуха түти рәхмәт әйтеп кызларның аркаларыннан какты. Чәй эчәргә дә кыстап караган иде дә, тегеләр аяк терәп каршы тордылар.

— Без чүбеккә дип килдек, — диделәр алар һәм ашыга-ашыга хәлне аңлатып бирделәр.

— Алай! — диде Һәдиятулла бабай. — Эш мүктә генә калса, табарбыз. — Аннары ул карчыгына карап: — Әллә соң, әнкәсе, үзем дә болар янына төшим микән? Мин бит әле заманында оста булып йөргән кеше.

— Төш шул, — диде Мәфтуха түти. — Аларга кеше артык булмас.

Һәдиятулла карт өйалдындагы бер төргәк чүбекне кызларга бирде дә үзе оста булып йөргәндәге коралларын эзли башлады. Кызлар аны көтеп тормадылар, чүбек бәйләмен икесе ике яктан тоттылар да Ык буена ашыктылар. Алар килеп җиткәндә, эш гөрли иде. Аерылмас ике дус сумала кайнатырга дип ут ягып җибәргәннәр. Әле сумалалары кайнап чыгарга өлгермәгән, Хәйдәрнең юан корсагына инде әллә ничаклы сумала таплары ябышып каткан. Зәйтүннең дә маңгаенда олы миңдәй булып сумалалы бармак белән тигән эз тора. Иң кызыгы шул: Һәнүзнең кәҗә тәкәсе дә монда. Һәнүз аны су буендагы бер талга бәйләп киткән иде, тәкә ялгызы гына ямь тапмыйча, талын тамыры белән йолкып, хуҗасы артыннан килде. Малайлар аны куып та карадылар, ләкин тегенең китәргә исәбе дә юк. Шундый бирелеп эшләп яткан малайларга хәйран калып карап тора. Бу ташбашларның кулларыннан эш тә килә икән дип гаҗәпләнә, ахры.

Ә эшләр бүген чынлап та әйбәт бара. Малайларның да куллары корал тотарга күнегеп килә. Тагын шунысы да бар: су буенда таралып яткан такталар күзгә күренеп көймә рәвешенә керә. Эшеңнең нәтиҗәсен күргәч, күңел дә күтәрелеп китүчән бит. Шуңадыр, ахры, көн уттай кызу булса да, суга чумарга ашыгучы юк. Бик тирләгәннәре дә кепкаларын гына юешләп кия дә тагын үз урынына барып баса.

Коралларын күтәреп, болар янына Һәдиятулла бабай да килеп җитте.

— О, Гыйльметдин дә монда икән! — диде ул. — Миңа эш калдымы соң әле?

— Эш барыбызга да җитә, — диде Гыйльметдин.

Төш вакытларына бер көймә ясалып бетте. Такта ярыкларын чүбек белән мүкләп тоташ сумалалыйсы гына калды. Балыкчы абзый малайларга:

— Барыгыз, ашап килегез, ачыккансыздыр, калганын төштән соң ясап бетерербез, — дигән иде, Хәйдәр учына кайнар бәрәңге тотып:

— Ашарга менә бу бар! — диде.

Алар Зәйтүн белән икесе башкаларга сиздермичә өйләреннән бәрәңге алып килгәннәр иде. Сумала кайнатырга дип яккан учакка бик әйбәтләп шуны күмеп куйдылар. Хәзер менә иң кирәк чакта бәрәңгеләре пешеп өлгерде.

Беркемнең дә өйгә кайтып, кадерле вакытларын әрәм итәсе килми иде. Кабат чакырганны көтеп тормастан, учак янына җыелдылар. Кайнар бәрәңгене, бер учтан икенчесенә күчерә-күчерә, кабаланып ашадылар. Кайнар бәрәңге артыннан салкын әйрән дә эчеп җибәргәч, бөтенләй күңелләре күтәрелеп китте.

Көймәне сумалалау бик җиңел күренсә дә, алай булып чыкмады. Малайлар бер-берләренә комачаулап, эткәләшә-төрткәләшә башладылар. Ахырдан Гыйльметдин бабай белән Һәдиятулла карт малайларның беразын көймә тирәсеннән куып җибәрергә мәҗбүр булдылар. Малайлар сөенешеп суга чумдылар. Тешләре тешкә бәрелерлек туңганчы су кергәннән соң, учак тирәсенә җыелышып җылындылар. Шунда берсе таяк башына сумала элеп кәҗә тәкәсенең мөгезен буяп куйды.

— Маңгаена кара ай да ясыйбызмы? — диде шаян Зәкәрия.

— Үзеңнең маңгаеңа яса, — диде Һәнүз, тәкәсен җәлләп.

— Һа, кызгана икән, әле үзе кайчан үләр икән дип йөри иде.

— Йөрсә соң!

Зәкәрия белән Һәнүз шулай әрепләшеп торган арада, кайнар сумалалы таякны Хәйдәр кәҗә тәкәсенең маңгаена басып та өлгерде. Малайларның башка шуклыкларына түзсә дә, кәҗә тәкәсе монысына түзә алмады. Кайнар сумаладан пешкән маңгае белән Хәйдәрне сөзеп суга очырды. Хәйдәр, сыны катып, сай суга барып төште. Ләкин тәкәгә бу әз тоелды, ул кайнар сумалалы мичкәне төртеп аударды һәм шуннан

соң гына эшем бетте, ахры, дип авылга таба чапты. Ярый әле сумала кешеләргә чәчрәмәде, юкса уеннан уймак та чыккан булыр иде. Өлкәннәр малайларны шелтәләп ташладылар. Сумаланы да яңабаштан кайнатырга туры килде. Шунлыктан эшләре озаккарак сузылды. Көймә ясалып беткәндә, караңгы төшкән иде инде. Ул көнне, үзләре ясаган көймәгә утырып, бер мәртәбә Ыкны аркылы да чыга алмадылар. Артык арыганлыктан, тизрәк кайтып йоклауны хуп күрделәр. Аның каравы икенче көнне, кулларына бер эш тә тотмыйча, алмаш-тилмәш көймәдә йөзделәр. Һәркем, океанга корабле белән беренче тапкыр чыккан капитандай, тирән дулкынлану һәм горурлану тойды.

Хәзер инде әкренләп яшел утрауларына кирәк-яракны ташый башларга да мөмкин иде.

## 9. Башланган эш беткән эш түгел

Булат абыйларының икенче яллары килеп җиткәнче, малайлар үз утрауларына яңа көймә белән такталар китерделәр. Таган өчен баганалар да әзер иде, ләкин, анысы сезгә авыр булыр дип, балаларга бирмәделәр. Хәер, багана мәсьәләсе уйламаган җирдән үзеннән-үзе чишелде.

Соңгы вакытларда көннәр кинәт явымга китте дә яшел утраудагы мәшәкатьләрне онытырып җибәрде. Күңелләре бик ярсыган малайлар да анда барудан тыелып торырга мәҗбүр булды. Чөнки авыр көймәне суга төшерер өчен генә дә берничә малай кирәк иде. Ә яңгырлы көндә елганы йөзеп чыгу турында уйларга да мөмкин түгел, салкын. Теләсәң-теләмәсәң дә, өйдә ял итеп утырырга туры килә. Ярый әле яңгырлар озакка сузылмады. Малайларны куркытыр өчен генә берничә көн яуды да туктады һәм, югалган вакытны кайтарырга теләгәндәй, кояш кыздырырга тотынды.

Яшел утрау хуҗалары, матур елмайган кояшка, җәйге җылы көннәргә сөенеп, тагын үзләренең көймәләре янына җыелдылар. Ә утрауга чыксалар, исләре китте: анда шундый шәп, шундый төз өч багана ята иде.

— Булат абыйлар китергән! — диде Хәйдәр, белдекле күренергә тырышып. — Кичә урамда миңа күз кысып киткән иде, шуңарга икән.

— Әлбәттә, Булат абыйлар! — дип килештеләр аның белән һәм, үзләренең соклануларын яшермичә, баганаларны капшап карый-карый, аркылысын-буен үлчәп чыктылар. Шул вакыт Зәкәрия болай дип кычкырып җибәрде:

— Җегетләр, — ул шулай зурдан кубып «җегетләр» дип сөйләшергә ярата иде, — болар бит Илһамның безгә бирергә уйлаган баганалары.

— Юкны сөйләмә, — дип каршы төште Һәнүз. Теге вакытта Салих абзый аның колагын шактый борган иде, шуңа, ахры, моңа һич тә ышанасы килмәде. — Бирерлек булса, теге көнне бирә иде инде ул аны.

— Әйе шул, — диде Хәйдәр дә.

Тик Зәкәрия дә үз сүзендә нык торды:

— Шул баганалар инде. Мин аны менә бу кабыгыннан таныдым. — Зәкәрия агачның сыдырылган каты кайрысын күрсәтте.

— Бөтен наратның да кайрысы бертөсле була инде, — диделәр аңа.

— Әллә мин тамгасы бармы дигән идем, — дип көлде Һәнүз.

— Кайры тамга инде ул. Кәҗә тәкәсе шикелле аның колагын киртләмәсләр бит, — диде Зәкәрия.

Шулай үзара бәхәс кузгалды. Ләкин Зәкәрия дә, башкалар да сүзен исбатлый алмадылар. Ә баганалар чынлап та шулар иде. Салих абзый, улы гармунда уйнарга өйрәнергә сүз биргәч, яңгырга-нигә карамыйча, аларны утрауга үзе илтеп куйган иде.

Баштарак малайларның, кызларның бу эшләрен вакытлыча мавыгу гына дип караучылар да әкренләп утрау белән кызыксына башладылар. Колхоз эшендә катнашмаган өлкән класс укучылары авылда шактый иде. Алар Һәнүзләр, Хәйдәрләр кебек ыбыр-чыбыр алдында үзләрен бик эре тотмакчылар иде, ләкин беркемнең дә артларыннан ялынып йөрмәвен күргәч, борын күтәрүнең файдасыз икәнен аңладылар.

Утрауда эшче куллар күбәеп киткәч, укытучы Галимә мондый тәкъдим кертте:

— Бөтенебез дә бер урында эшләгәнче, ике бригадага бүленик. Бер бригада көймә ясар, икенчесе утрауда корылмалар төзер.

Эшнең тизрәк баруы һәркем өчен дә әһәмиятле иде, шуңа күрә бу тәкъдим барысы тарафыннан да хупланды. Көймә ясаучыларга башлык итеп Гыйльметдин абзыйны, утрауда эшләүчеләргә Һадиятулла бабайны куйдылар. Бригадаларга бүленү башланды. Нигәдер малайларның күбесе утрауда эшләргә теләк белдерделәр. Күрәсең, төп штаб саналган утрауда һәркем үз куллары белән нәрсә дә булса төзергә теләгәндер. Көймә ясаучылар бригадасына курайчы Зәйтүн белән берничә малай һәм кызлар язылды, Зәйтүннең аерылмас дусты Хәйдәр дә Һадиятулла бабай бригадасына китмәкче иде, ләкин дустына хыянәт итәргә кыймады. Аннары, ни әйтсәң дә, сумала кайнаткан җирдә бәрәңге күмәргә җай бар. Ә Хәйдәр ансыз

йөрми. Моңа кадәр ул утрауга чыкканда капчыктай кесәләренә йодрык-йодрык эре шакмаклы шикәр тутырып чыга иде. Беркөн аны дуслары уйламас җирдән шикәрсез калдырдылар: Хәйдәр чишенеп суга кереп китү белән, киемнәрен бик һәйбәтләп чылатып, юеш чалбар балакларын төйнәп куйдылар. Берберләренә мондый «каз боты ашатулар» — су буенда үскән малайларның күптәнге гадәте. Моңар беркемнең дә исе китми.

Суга батырганда, Хәйдәрнең чалбар кесәләрендә шикәр барын күрмәделәр дә, бары тик балакларын төйни башлагач кына, юешләнгән бер шакмак шикәр чалбар кесәсеннән җиргә килеп төште. Малайлар аны кире кесәгә тыгып куйдылар.

— Хәйдәр бүген баллы «каз боты» кимерә икән, — дип көлделәр алар.

Хәйдәр су коенып чыкканчы юешләнгән шикәр тәмам эреп беткән һәм кесәгә бер оя кырмыска кереп тулган иде. Еларга җитешеп, тешләре белән төеннәрен чишеп маташканда, төрле яктан малайлар кычкырыша башладылар:

— «Каз боты» баллымы?

— Хәзер ул өч көн ашамый тора ала инде.

— Бер оя кырмыска ашагач, кем дә торыр...

Шушы көннән соң Хәйдәр кесәсендә шикәр йөртми башлады. Чи бәрәңге, ичмасам, суда да эреми, аңа кырмыскалар да тими. Ә пешерү өчен хәзер аптырыйсы юк, су буенда һәр көн учак ягыла. Хәйдәр инде бу эшне шактый әйбәт үзләштереп килә. Сумала исенә дә күнекте, һич югында, авыз тик тормасын дисәң, сумала чәйни торырга була.

Менә бүген дә Гыйльметдин абзый кемнең нинди эш ятратуын сорагач, ул учак ягарга теләвен белдерде.

— Анысы да кирәк нәрсә! — диде Гыйльметдин абзый. — Бүген икенче көймәне бетереп куярбыз. Эш күп түгел.

Гыйльметдин абзый үз бригадасында кызлар булгач куркып калган иде. Баксаң-күрсәң, болар малайлардан бер дә ким түгел икән. Нәфис эшләрне хәтта малайларга караганда остарак та башкаралар. Иң мөһиме, ыгы-зыгы кубармыйлар, такта араларындагы ярыкларны томалый алмыйча малайлар җәфаланып беткәннәр иде, ә кызлар дегетләнгән чүбекне нәп-нәзек ярыкларга да шундый оста тутыралар. Өстеннән сумалалап җибәргәч, тактаның бер-берсенә ялганган урыннары да беленмәячәк. Сүзгә саран Гыйльметдин абзый аларны мактамый булдыра алмады:

— Әйбәт, балалар, әйбәт!

Гыйльметдин абзый әйбәт сүзен бик күңеле булганда гына әйтә. Балалар аның бу гадәтен белеп өлгергәннәр иде. Үз эшләрен Гыйльметдин абзый әйбәт дип бәяләгәч, кәефләре тагын да күтәрелеп, көчләре артып китте.

Кызлардан бераз читтәрәк эшләүче Зәйтүннең генә бүген никтер күңеле боеграк күренә. Гыйльметдин абзый аны көймәнең эскәмияләрен шомартырга куйган иде. Әллә ялгызы гына булганга, эше бик үрчеми.

Инде төшке ялга туктарга да күп калмаган иде, шул вакыт Зәйтүн такта шомарткычның үткен пычагы белән кулын кисеп җибәрде. Ул «ах» диюгә, янына дуслары килеп җитте. Зәйтүннең уч төбе тулы кыпкызыл кан иде.

— Тизрәк бәйләргә кирәк! — диде Гыйльметдин абзый. — Кемдә чиста кулъяулык бар?

Беркемдә дә кулъяулык юк икән, бер мәлгә аптырап калдылар. Ләкин бу аптырау озакка бармады, Равия, үзенең башындагы яулыгын салып, Зәйтүннең кулын бәйләргә кереште.

— Канын туктатырга туфрак сибик, — диде Хәйдәр.

— Үзеңнеке канагач сибәрсең, — дип ачуланып ташлады аны Равия.

Мәктәптә укучыларны беренче ярдәм күрсәтергә өйрәткәннәр иде, шунлыктан Равия бу эшнең бөтен шартын җиткереп эшләде.

— Авылга кайтып фельдшерга күрен, — дип киңәш итте Гыйльметдин абзый.

— Төзәлә ул, — диде Зәйтүн, сер бирмәскә тырышып. — Бәйләгәч, каны да туктады.

Гыйльметдин абзый бер сүзне кат-кат әйтә торган кеше түгел иде, Зәйтүнне дә фельдшерга барырга артык кыстамады.

— Алайса ял ит, — диде дә үз эшенә кереште.

Зәйтүн тал төбенә барып утырды.

Зәйтүннең кулы киселгәч, Равия үзе дә аңламастай хисләр кичерде. Аңарга ничек тә ярдәм итәргә, дустының авыртуын уртаклашырга теләде. Тал төбендә утыручы Зәйтүннең агарыбрак киткән йөзен күргәч түзмәде, үзе дә шуның янына китте.

— Бик сызлыймы? — дип сорады ул.

— Юк, — диде Зәйтүн, кыенсынып.

— Авырткан кулыңа тынымны өримме? Шулай итсәң, авыртуы кими аның. Мин бармагым киселсә гел шулай эшлим.

Равиянең бу сүзләреннән соң, Зәйтүн бөтенләй югалып калды. Ә кыз, аның кулын сак кына тотып, бәйләү астыннан тырпаеп торган бармакларына җылы сулышын өрде. Әнкәсез үсеп, наз күрмәгән Зәйтүннең күңеле тулды, тамагына кайнар төер утырды. Равиянең маңгай чәчләре аның беләгенә тиеп, моңарчы һич тә татымаган рәхәтлек тудырды. Кызның шушы йомшак чәчләрен сыйпап аласы килде, ләкин үрелергә кулы күтәрелмәде. Шушы рәхәтлекне югалтудан куркып, ул кымшанмыйча утырды да утырды. Соңыннан, бераз сөйләшер хәлгә килгәч:

— Мин сиңа курай бүләк итәрмен әле, Равия, — диде.

— Мин уйный белмим шул, Зәйтүн.

— Белмәсәң, өйрәтермен. Аны өйрәнү бик җиңел.

— Ярар алайса.

Гап-гади шушы сүзләр ике араны тагын да якынайтыбрак җибәрде. Зәйтүн әле соңыннан да бу рәхәт минутларны еш искә ала торган булды. Ул вәгъдәсендә торды: үзенең иң яхшы кураен Равиягә бүләк итте. Аның уенча, Равиядән менә дигән курайчы чыгачак. Чөнки кызның күңеле йомшак, ә йомшак күңелләр моң белән тулы була.

...Ике бригадага бүленгәч, эшләр күзгә күренеп алга китте. Өлкән класс укучыларының да килеп кушылуы көчне нык кына арттырды. Баганалар утыртырга, таганга бау асу өчен ныклы боҗралар беркетергә көчле кешеләр кирәк иде. Иң беренче итеп таган ясап куйдылар. Монда инде малайлар киң күңеллелек, үзләренчә әйтсәк, егетлек күрсәтергә тырыштылар. Бавы асылып, утырырга бишекләре әзер булу белән менеп атланырга бик теләсәләр дә, кызларга эндәшкән булдылар:

— Әйдәгез, атыныгыз! Без моны сезнең өчен ясадык.

Ике әйткәнне көтә торган вакыт түгел иде, кызлар сөенешеп таганга менеп утырдылар. Малайлар аларны тирбәтеп җибәрделәр. Салмак кына тирбәлгән таганда күзләрне йомып хыялланырга рәхәт. Күзләрне йомгач, дөнья серләнә. Атынгыч, әкиятләрдәге тылсымлы келәм кебек, сине ерак-еракларга алып китә. Йә син, ак болытлардан да югары күтәрелеп, зәңгәр офыкларны кочасың, йә, кояшка кулларыңны сузып, бөеклегеңне исбатларга телисең. Ә кеше үз максатына ирешкән көнне чынлап та бөек була. Кызларның бүген дөньялары түгәрәк, бәхетләре бөтен иде. Алар туйганчы атындылар, иң усал малайлар да аларны куарга ашыкмады. Эшләгән эшләренең нәтиҗәсен һәм кызлар йөзендә балкыган шатлыкны күрү усал малайларны да йомшарткан иде. Хәер, кызлар үзләре дә малайларның киң күңеллелегенә шуның белән үк җавап бирергә тырыштылар. Безгә җитте, үзегез дә атыныгыз дип, берничә тапкыр сикереп-сикереп төштеләр.

Кызлар атынып туйгач, Зәкәрия әллә кайда артта басып торган Илһамны төрткәли башлады:

— Бар, хәзер син утыр, — диде ул.

Ә Илһам, мондый бәхеткә ышанырга теләмичә, баскан урынында тик торды.

— Нәрсә ялындырасың, — дип кычкырыштылар малайлар. — Таганда бит сезнең баганалар.

Әтисенең баганаларын утрауга илттереп куйганнан соң да, Илһам шактый вакыт малайлар арасына керә алмыйча йөрде. Аның шулай адашкан үрдәк бәбкәседәй каңгырап йөрүен Зәкәрия күреп алды да:

— Әйдә безнең утрауга, — дип, үзе белән ияртте. Юлда ул: — Таганга баганаларны Салих абзый илтеп куйдымы? — дип сорады.

— Әйе.

— Ничек алай күндерә алдың?

— Баганаларны бирсәң, гармунга өйрәнәм, дидем.

— Өйрәнәсеңме соң?

— Бер көй чыгарам инде.

— Берәү чыккач, бүтәннәре дә чыга инде аның.

— Бик чыкмый шул. Мин ул көйне әтигә сүз биргәнче үк белә идем инде. Шуны уйнап күрсәткәннән соң гына баганаларны илтеп куйды.

Шушы көннән башлап, Зәкәрия Илһамны җае чыккан саен яклый торган булды. Әле дә менә таганга кулыннан өстерәп диярлек китерде. Баштарак кыймый маташкан Илһам таганга менеп баскач, үзен космоска очучы космонавттай хис итте. Артык дулкынлануданмы, талпына-талпына атынуданмы — йөзенә алсулык бәреп чыкты. Ул үзенең көчсезлеген дә, күп вакыт иптәшләре тарафыннан кыерсытылуын да онытты.

Утрауда эшләр әнә шулай эзгә төшә башлады. Таганнан соң, волейбол уйнарга баганалар утыртып, ятьмә тартып куйдылар. Ә футбол мәйданының чикләрен билгеләр өчен, нечкә сызык итеп чирәмен казып

чыктылар. Кемдер: «Капкалар өчен баганалар утыртып маташмыйк, куакларның башына бәйләп куйгач та әйбәт инде», — дигән иде, Һәнүз бөтенләй ярсып китте:

— Сез нәрсә? — диде ул. — Иң кирәклесенә калгач, ярар, имеш. Сез теләмәсәгез, мин аны үзем утыртам...

Агач-богачка хәзер аптырарлык түгел иде. Моннан берничә көн элек Булатлар үзләренең бөтен бригадалары белән чыгып шактый гына кирәк-яраклар калдырып киттеләр.

Һәнүзнең икеләнүгә урын калдырмыйча «үзем утыртам» дип әйтүе дә әнә шул төзүчеләр калдырып киткән агачлар күп булудан иде. Һәнүзнең ул сүзләренә каршы берәү:

— Бәлки, сиңа Мәскәү стадионнарындагы төсле капроннан үрелгән ятьмә дә кирәктер, — диде.

— Ә нигә? — дип элеп алды Һәнүз. — Ясагач-ясагач, Мәскәү стадионнарыннан ким итмибез инде аны. Безгә бит Ихсан абый акча биргән... — Һәнүз, үз сүзенә раслау көткән сыман, Галимә апасына карады. Ләкин укытучы аны куандырырдай сүз әйтмәде.

— Юк, дуслар, — диде. — Без теләгән бөтен нәрсәне дә ала алмыйбыз. Колхоз булдыра алган кадәр ярдәм итә инде. Калганын үзебез табарга тиеш.

Бу сүзләрдән соң футбол яратучыларның күңелләре төште.

— Алай булгач волейбол ятьмәсе алмаска иде, волейболны аны кер бавы тарттырып куйсаң да уйнап була, — диештеләр алар.

— Их, үзем баесаммы, — дип көрсенде Һәнүз.

Галимә аларны тынычландырырга теләп:

— Тора-бара һәммәсе дә булыр, — диде. — Баганаларыгызны утырта торыгыз. Әле бит эшлисе эшләребез күп.

Чынлап та, утрауда эшләгән саен эш арта барган сыман тоела башлады. Менә хәзер печәннәрен чабып куышлар ясыйсы бар. Юкса яңгыр яуса керер урын юк. Колхоз инде болынга печәнгә төште. Утраунықын да чабарга вакыт. Футбол өчен ике якка ике капка кирәк. Һәнүз инде ул капкаларны әллә ничә тапкыр төшендә дә күрде. Бер төше әле дә хәтерендә сакланып калган. Имеш, аларның стадионнарына Бразилиянең иң көчле командасы килгән. Капитаннары атаклы Пеле икән. Менә ярышлар башлануын белгертеп, судья сыбызгысын сызгыртып җибәрде. Бер якта — Пеле, икенче якта — Һәнүз. Башка уенчылар рәтләп күзгә дә чалынмый. Дошман капкасына якынлашкан чагында, Һәнүзгә атаклы Пеленең тирләгән кап-кара йөзе һәм ыржайган ак тешләре генә күренеп кала. Менә Һәнүз бөтен көченә тупка китереп тибә, туп дошман капкасына барып керә дә, балыкчы ятьмәсенә эләккән балык кебек, озак кына тыпырчынып ята. Капкачы аны тотып алмакчы була, ләкин туп, тере әйбер сыман, капкачының кулыннан ычкыну ягын карый. Пеле үзенең бөтен командасы белән килеп эләктергәннән соң гына, тупны яңадан уенга кертеп җибәрә алдылар.

Менә шушы төш, бигрәк тә тупның ятьмә эчендә балыктай тыпырчынуы, аның хәтерендә бик нык уелып калды. Һәм шул көннән башлап, ул, футбол капкаларын нәкъ зур стадионнардагыча ясарга кирәк дип, сүз беркетеп куйды. Билгеле, баганаларын ясау әллә ни күп көч алмады. Хәзер инде малайлар пычкы-балта тотарга бераз өйрәнделәр. Эшләргә атлыгып торучылар да күп. Капканың нинди биеклектә һәм нинди киңлектә булырга тиешлеген белмәгән малай бик сирәк иде, ике капканы бер көндә әмәлләп ташладылар. Командаларның капкачылары, капкаларны бераз таррак итик, тупны керттермәскә шәбрәк булыр, дигәннәр иде дә, аларның сүзен санга сукмадылар.

Каян ятьмә табыйк дип баш ватып йөргәндә, Һәнүз беркөнне Гыйльметдин абзыйларның коймасында киптерергә эленгән зур җылым күреп алды. «Моның яртысы да безнең ике капкага җитәр иде» дип уйлады ул һәм җылымнан күзләрен ала алмыйча, майлы калҗа күргән мәчедәй, озак кына койма тирәсендә чуалды. Шул вакыт Гыйльметдин абзый чыгып:

— Әллә җылым тартышырга исәбең бармы? — дип сорады.

Һәнүз хәлне аңлатып бирде. Гыйльметдин абзый бераз уйланып торгач:

— Миндә иске җылым бар барын, тик ул тишекле-тошыклы инде, — диде.

— Безгә бит балык сөзәргә түгел, — диде Һәнүз. — Тишегеннән туп чыгып китмәс әле. Аннары без аны ямый да алабыз.

Шатлыклы хәбәрне ул тизрәк дуслары белән уртаклашырга ашыкты. Малайлар эшне коры тоттылар. Тишек-тошыкларны аннан-моннан бергәләп ямадылар да җылымны кискәләп капкаларына беркеттеләр. Гыйльметдин абзый ятьмәне ничек ямарга кирәклеген аларга күрсәтергә дә теләгән иде, ләкин ашыккан малайлар алай нечкәләп утыруны кирәк тапмадылар. Чөнки һәркемнең тизрәк уйнап карыйсы килә иде.

**10. Көтмәгәндә килгән бәла**

Эшләр шулай уңай гына барды. Малайлар, кызлар көймәдә Ык аша чыгып, һәр көн диярлек үз утрауларында туйганчы уйнадылар, күңел ачтылар. Уйнап туйгач, су коендылар. Комда кызындылар. Монда аларга һәр яклап рәхәт иде. Беренчедән, әти-әниләре тегене эшлә, моны эшлә, дип чакырып кертә алмый. Икенчедән, әрәмәнең байлыгы бик зур: җиләге-карлыганы, кузгалагы-какысы, бөрлегәне-шомырты, кыскасы, кемнең җаны ни тели — шул бар. Кызлар җиләк, карлыганнарны еш кына өйләренә алып кайтыр өчен җыялар. Дөрес, малайлар да җиләклерәк аланга юлыкканда изге ният белән җиләк-җимешне кепкаларына җыя башлый, әмма карыннары ача төшкәч түзмиләр, әкрен-әкрен кепкаларындагы байлыкны сыпырып куялар. Аннары: «Җиләк белән вакланырга без кызлармыни. Үлән арасында капшанып вакыт үткәргәнче, балык тотуга ни җитә!» — дип үзләрен акларга тырышалар. Әмма балык дигәне дә бу түземсез җаннарга эләгергә ашыгып тормый. Яр буендагы сай җирләрдә вак-төяк маймычлар каба кабуын. Тик малайларны бу гына канәгатьләндерми. Аларның көймә хәтле җәенне тотып бөтен авылны шаккатырасы килә. Шуңа күрә алар көймәләре белән елганың салмаграк ага торган тирән урыннарына барып кармак салалар. Малайларның өлкәннәрдән ишеткәннәре бар: кайдадыр шушы тирәдә каз-үрдәкләрне йотып ятучы җәен бар. Әллә ничә кешенең оясы-оясы белән каз-үрдәкләре юкка чыкты инде. Тагын шунысы гаҗәп, мондагы җәен каз-үрдәкләрне үсә төшкәч кенә йота, вак-төяк бәбкәләр белән авыз пычратып тормый. Күрәсең, артык зурдыр инде. Малайларның бөтен хыялы — менә шушы җәенне эләктерү.

— Әгәр җәенне эләктерсәк, авылны шаккатырып урам буйлап өстерәп алып кайтыр идек, — дип хыяллана Зәкәрия. — Көтү кайтканда, бар кеше урамда чакта, Рәхмәт тыкрыгыннан килеп чыгасың...

— Ул җәеннең эченнән ун бидрә уылдыгы чыгар иде, — ди Хәйдәр. — Аны майда кыздырып ашасаң, дөньяда бүтән нәрсә кирәкми инде. Аның һәр уылдыгы борчак кадәрледер, әйеме?

— Әй, сиңа шул ашарга гына булсын, — дип каршы төшәләр аңа.

— Һы, — ди Хәйдәр, гаҗәпләнеп, — балыкны ашар өчен тотмагач, нәрсәгә дип тоталар соң?

— Музейга куябыз аны, — дип сүзгә кушыла Илһам.

— Дурак! Бер ел буе ашарлык җәенне музейга куярга, башыңа тай типтеме әллә?

Хәйдәрнең бу сүзләреннән соң бәхәс кызып китә. Җәенне ни эшләтү хакында телләре арыганчы бәхәсләшкәч кенә төркем тына төшә. Анда да әле кызлар: «Атмаган куянның итеннән Хәйдәргә — бәлеш, тиресеннән Зәкәриягә — тун», — дигәч кенә авызлары йомыла.

Шулай бәхәсләшә-бәхәсләшә, хыяллана-хыяллана яшәп ятканда, малайларның, кызларның бөтен хыялларын җимереп ташлаган бер вакыйга булды: көтмәгәндә-уйламаганда ике көймә берьюлы юкка чыкты. Ул гынамы әле. Утраудагы барлык корылмаларны җимереп ыргытканнар иде. Бу оятсызлыкка балалар гына түгел, өлкәннәр дә аһ итте. «Кемнәрнең эше икән бу?» — дип баш ваттылар. Тикшерү өчен районнан милиция чакырттылар. Милиционер теге вакыт Габбасның мотоциклы урлангач килгән яшь егет булып чыкты. Ул әле урланган мотоциклның да эзенә төшә алмаган һәм шуңа күрә ачулы иде. «Әгәр мин бу банданы каптырмасам, иңемдәге старшина погоннарын үзем үк йолкып атып, милициядән китәчәкмен», — диде ул.

— Монда бер үк кешеләрнең кулы уйный, ахры, — диде Ихсан абый.

— Әлбәттә, — дип куәтләде аны милиционер. — Тик мин бернәрсәгә тулысынча ышанам: бу эштә авылыгызның кеме дә булса катнаша. Нигә дисәң, көймәләр бу як ярга чыгарып бәйләп куелган булган. Шулар белән утрауга чыкканнар. Минем уйлавымча, бу шайка ким дигәндә ике-өч кешелек булырга тиеш.

— Бәлки, шулайдыр, — диде Ихсан абый, моңа бик ышанып җитәсе килмичә. — Тик авыл кешесенә утраудагы корылмаларны җимерү нигә кирәк булыр икән? Һәркем үз баласының машина юлында буталып йөрмичә, аулак, тыныч җирдә уйнавына сөенеп бетә алмаган иде бит. Аннары шунысы да бар: авыл кешесе ул урланган көймәләр белән файдалана алмаячак. Берәрсенә сатып җибәрсәләр генә инде.

Милиционер эзләнү эшләрен утраудан башлап җибәрергә булды. Малайлар да аңа иярделәр. Һичкемнең бу кызыклы эштән читтә каласы килми иде.

— Абый, — диде берсе, — синең пистолетың ничә патронлы?

— Бандитларны кырып салырга пистолет түгел, автомат кирәк, — диде икенчесе.

— Җәен тоту кыенракмы, әллә бандитларнымы? — диде өченчесе.

Милиционер үз уйларына чумып барганлыктан, аларның сорауларына җавап бирмәде. Хәер, малайлар аңардан җавап көтмәделәр дә. Алар бер-берләре белән бәхәсләшеп бардылар.

Утраудагы хәлләр утырып еларлык иде. Футбол капкасының баганалары ауган, атынчык-таган җимерелгән. Капкага куйган ятьмәләр ерткаланып беткән. Тикшерүче милиционер ниндидер эзләр күрергә теләпме, бер җирдән икенче урынга йөренде.

— Һәр җинаятьтән нинди дә булса эз кала, ягъни мәсәлән, вещественное доказательство. Без шуны табарга тиеш, — диде ул малайларга.

— Берәрсенең каешы өзелеп, чалбары төшеп калса гына инде, — диде берсе.

Малайлар үзләренең сүзләреннән көләргә тотындылар. Чалбарсыз каракны күз алдына китерү кызык иде, әлбәттә. Араларыннан берсе бу фикерне тагын да көчәйтеп җибәрде.

— Бәлки, аларның бөтенләй күлмәк-ыштаннары юктыр әле. Күлмәк-ыштанлы килеш Ыкны йөзеп чыгып көймә урлап булмый.

— Ыржаймагыз! — диде милиционер шаркылдаучы малайларга. «Вещественное доказательство» бик серьезный нәрсә ул. Әгәр шул доказательствоң юк икән, каракның карак икәнен исбатлый алмыйсың. Ә «вещественное доказательство» юлда аунап ятмый. Аны эзләп табарга кирәк.

Малайлар бу сүзләрдән соң милиционерны үзара «вещественное доказательство» дип йөртә башладылар. Аларга югалган көймәләрне эзләү утрауда уйнау кебек үк кызык иде. Милиционердан «вещественное доказательство» дип көлсәләр дә, эзләүнең ниндирәк юнәлештә барырга тиешлеген төшенделәр алар. Һәм бөтен игътибарларын утраудан нинди дә булса ят нәрсә табарга юнәлттеләр. Һәр куак, һәр чокыр ныклап тикшерелде. Иң беренче табышны Зәйтүн табып китерде. Аның кулында «Мальборо» дигән сигарет кабы иде.

— Менә, абый, — диде ул тикшерүчегә. — Бу безнең утраудагы әйберләрне җимергән кешенеке түгелме икән? Ягъни мәсәлән, «вещественное доказательство».

— Молодец! — дип мактады аны тикшерүче. — Сезнең арагызда тәмәке тартучылар бармы?

Кайбер малайлар башларын түбән иделәр. Кайберләре өлкәннәрдән яшереп аның ише нәрсә белән шаяргалыйлар иде. Милиционер малайларның иелгән башларын күргәч, эшнең асылын аңлап, аларга сорауны бүтәнчәрәк итеп бирде:

— Ярар, борыннарыгызны салындырмагыз. Бу сорауны мин сезне шелтәләр өчен бирмәдем. Менә мондый «Мальборо» сигаретын тартучы бармы арагызда? Минем шуны беләсем килә.

— Юк, — диде малайлар.

— Бәлки, утрауда менә бу корылмаларны эшләүче өлкәннәрнең берәрсе тарткандыр? Хәтерләмисезме?

— Булат абый тартмый, Гыйльметдин бабай махорка тарта, — дип, малайлар һәр эшчене күңел күзе аша уздырдылар. Әмма «Мальборо» сигаретын тартучыны хәтерләмәделәр.

Эзләнә торгач тагын бер нәрсәгә юлыктылар. Бусы бер язу иде. Анда: «Утраудан табаннарыгызны ялтыратмасагыз, агып киткән көймәләрегез төсле эзсез югалачаксыз. Сөякләрегезне эт тә таба алмаячак», — дип язылган иде.

Аунап яткан баганага чәпәлгән бу язуны тикшерүче милиционер җентекләп кат-кат укыды. Бу табыштан ул бик канәгать иде.

— Димәк, — дип фикер йөртте ул, — сезнең бу утрауда буталып йөрүегез кемгәдер ошамый. Димәк, көймәләрне дә шулар агызган. Ә бәлки, үз кирәкләре өчен берәр җиргә яшереп куйганнардыр. Болай булгач табабыз.

Милиционер әле яшь һәм тәҗрибәсез, аның, үзенә ияреп йөрүче малайлар кебек, тиз арада зур җинаятьчеләрне эләктереп дан казанасы килә иде.

Малайлар, тагын берәр кызыклы табышка юлыкмабызмы дип, эзләнүне дәвам итте. Әмма капкан саен калҗа эләкми шул. Озак эзләп тә берни тапмагач, кәефсезләнеп өйләренә таралдылар.

Малайларга тагын урамда, машиналар тыз-быз чабышкан юлда туп тибеп, берәрсенең мотоциклына төялешеп, һаваны төтенгә күмеп йөрергә калды. Тик бу аларның үз хәлләре белән килешүләре түгел иде әле. Табигатьнең матурлыгына, кошлар сайравына, күңелне ымсындырып торучы тауларына ашкынган җан ярсуын урам тузаны белән генә күмәселәре килми иде. Бер көнне алар үзләренең яраткан җирләре — Өемташка менәргә булдылар. Таштагы исемнәрен яңартыр өчен кораллар һәм Хәйдәрнең абыйсы солдаттан алып кайткан бинокльне алдылар.

Өемташ менгән саен берәр яңа матурлыгы белән ачыла. Йә анда берәр елан күрәсең, йә кош оясына юлыгасың, йә моңарчы күзгә чалынмаган чәчәккә сокланасың. Бу юлы малайлар бинокль белән мавыктылар. Биек таудан бинокль аша күзәткәч, дөнья бөтенләй башкача икән. Әллә кайдагы үзәнлекләр, әрәмәләр, текә ярлар уч төбендәге кебек күренә. Әнә үзләренең утрауларына үрелсәң, буй җитәрлек кебек. Малайларга бу кызык булып китте. Бинокль бер кулдан икенче кулга күчте. Күктә очучы чыпчыкларның каз кадәр, үзәнлектә утлап йөрүче кәҗә-сарыкларның дөя кебек күренүеннән малайлар тәгәри-тәгәри көлделәр. Бигрәк тә тау итәгендәге суырлар, икенче төрле әйткәндә, байбаклар кызыксындырды аларны. Суырларны авыл халкы изге җәнлеккә саный. Чөнки алар намаз укыйлар. Моны авыл картлары гына әйтми, малайларның үзләренең дә күргәне бар. Чынлап та, суырлар оя кырыйларына чыгып басалар да, алгы тәпиләрен күкрәкләренә куеп, намаз укыган төсле әле алга иеләләр, әле як-якларына карап алалар.

Малайлар бинокль белән суырларның шул хәрәкәтләрен күзәттеләр. Моңа кадәр ничектер вакытлары җитмәүдәнме, бу изге җәнлекләр үзләренә кеше затын бик якын җибәрергә теләмәүдәнме, аны озаклап

күзәтә алганнары юк иде. Биноклең булгач, суырларга якын барасы юк: бөтен хәрәкәтләре ап-ачык күренә. Әнә аларның оялары янында кызыл балчык өеме. Картлар ул балчыкта алтын бар дип сөйлиләр. Әмма беркем дә ул балчыкны актарып әлеге изге җәнлекләрне куркытырга батырчылык итми. Чөнки аларның байлыгына кагылган кешенең рәхәт күрмәячәген белә. Сунарчы Әгъләм бабай шуларның оясын туздырып кына аяксыз калган, диләр. Хәзер ничә еллар инде һичбер хәрәкәтсез урын өстендә ята.

Суырлар намаз укулары белән генә түгел, чиста һәм тәртипле булулары белән дә халыкның мәхәббәтен казанган. Аларның бәдрәфләре бар. Бәдрәфләренә үзләре салган махсус сукмактан гына йөриләр. Тәһарәт алган шикелле итеп юыналар.

Рәхәтләнде малайлар суырларны карап. Хәтта һәр ояны үзләренә беркетеп, Өемташка менгәч һәрвакыт үз суырларын барлап торырга сүз куештылар.

Суырларны күзәтеп туйганнан соң, карашларын ераккарак күчерделәр. Тик кая гына карамасыннар, нәрсә генә күзәтмәсеннәр, җаннарын туктаусыз ашкындырып торучы нәрсә үзләренең утраулары иде. Менә тагын Һәнүз биноклен утрауга юнәлтте һәм үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде:

— Җегетләр!

— Нәрсә, әллә тал арасында үзеңнең кәҗә тәкәңне күрдеңме?

— Әнә, әнә, — диде Һәнүз, күзәтүен дәвам итеп, — безнең утрауның бу як ярында ике кеше йөри. Су астыннан нәрсәдер тартып чыгарырга маташалар бугай.

— Каяле, кая? — дип бинокльне Зәкәрия тартып алды. Ул озак кына берни күрә алмады. Бары тик бинокльгә Хәйдәр үрелә башлагач кына: «Әйе шул, безнең утрауның бу як ярында кешеләр йөри!» — диде.

Бинокль тагын кулдан кулга күчте. Һәммәсе дә үз утрауларында кеше барлыкка ышанды.

Малайларның моңа кадәр утрауның бу ягын ныклап тикшергәннәре юк иде. Ул якта кайчандыр Башкортстанның вак таш чыгара торган карьеры булган. Хәзер инде карьер ташландык хәлдә. Анда бары тик тешсез авызларын ыржайтып торучы тирән-тирән чокырлар гына калган.

— Нәрсә эзли икән алар? — диеште малайлар. — Анда Ыкның тирән җире. Теге бәндәләр шул тирән җиргә нидер ыргыталармы, тартып чыгарырга телиләрме — һич аңлашылмый.

— Болар, мөгаен, безнең утраудагы әйберләрне җимерүчеләрдер, — диде Илһам.

— Юк, балыкчылар, — диде Зәкәрия янә бинокльгә текәлеп. — Октябрьск каласыннан балык тотарга килүчеләр әзмени. Бер көннәрдә әле ике кеше моторлы көймәдә безнең авыл янына ук килгәннәр иде. Карбит тутырылган шешәне суга ыргыталар да балыкларны шартлатып кына тоталар. Балыклар корсакларын ялтыратып «мине тотыгыз» дип үзләре үк өскә калкып чыга.

Әйе, шәһәрнең якын булуы авыл кешеләре өчен һич файдалы түгел. Ял көннәре җитсә, малай-шалай мотоциклга, өлкәнрәкләре, машиналарга төялеп, Ык буена килә. Кемдер балык тота, кемдер кызына, кемдер әрәмәдә куак төбендә кәеф-сафа корып ята. Үләннәр таптала, карлыган, гөлҗимеш, шомырт агачлары сындырыла. Һәр урында буш шешә, консерва банкалары, иске газеталар өелеп кала. Авыл халкы бу хәлгә ничек кенә каршылык күрсәтергә тырышмасын, барыбер каршы тора алмый. Кеше агымы елдан-ел арта гына бара.

Өемташтан бинокль белән күзәтеп ятучы малайларның үз утрауларында нәрсәдер эшләп йөрүче бу бәндәләргә ачулары килде: «Боларның кем икәнлекләрен белергә кирәк!» — дигән ният белән кайтты алар өйләренә.

### 11. Гайбәтче Гайшә яки көтелмәгән чишелеш

Малайлар күңелләреннән утраудагы кешеләрнең кем икәнлеген ачыкларга дип кайтсалар да, тора-бара бу уйларыннан сүрелделәр. Беренчедән, көннәр бозылып китте. Икенчедән, Гайбәтче Гайшә аларның яраларына тоз салды. «Яшь этәчләрнең кикрикләре шиңгән», — диде ул. — Көймә ясыйлар, стадион төзиләр, имеш. Стадион ул телевизорда бик матур, шунда кереп уйнагыз. Ха-ха-ха! Маңка танаулар, адәм көлкешәләре. Йөрисез шунда кеше булып».

Башка вакыт булса, малайларның Гайбәтче Гайшә сүзләренә исләре китмәс иде, әмма әле йөрәк яралары артык яңа иде шул. Бу сүзләрне авыр кичерделәр һәм утрау хакында яңадан җан җәрәхәтләрен кузгатмаска булдылар.

Ә Гайбәтче Гайшә башкалар ярасына тоз салудан тәм таба торган кеше. Аның ни баласы, ни ире юк. Бәлки, шуңа күрәдер әйбәт гаилә корып яшәүчеләрдән үлеп көнләшә, андыйларның араларына гайбәт уты кертергә, һич югы, балаларын бер-берсенә каршы котыртырга тырыша. Гайбәтче Гайшәләрнең капка турысын малай-шалай читләтебрәк уза. Ул тирәдә җыелышып уйный башласаң, ишегалды себерә торган олы себеркесен күтәреп убырлы карчык килеп чыга. Әгәр сизмирәк калсаң, себеркесе белән сыртыңны каезларга да күп сорамый. Бу хатынның кыланышларына авыл халкы бармак аша карый. Күрәсең, аны

юләргә санауларыдыр. Ул эшкә йөрми, мал-туар асрамый. Нәрсә исәбенә яшидер — моны белүче дә, кызыксынучы да юк. Җитмәсә, әле ишегалдында бозау чаклы эте бар. Ул эт вак-төяк малайларны бер кабуда йотарлык.

Авылның бер диванасы дип саналган шушы бәндәнең кайбер кыланышларына соңгы вакытта малайлар игътибар итә башлады. Иң элек моны Зәкәрия абайлады.

Зәкәрия төнгелеккә кармак салып куя иде. Кармакны ул Ыкның тынычрак аккан урынына — елга төбенә кадап сала. Эрерәк балык эләксен өчен, кармагына берәр ит кисәге яки көндез каптырган маймыч саплый. Төнгелеккә салына торган кармакның бер хикмәте бар: аны иртүк балыклар уянганчы карарга кирәк. Юкса кармакка эләккән балыгыңны ерткыч балыклар ашап китүе яисә башка балыкчыларның эләктерүе мөмкин.

Зәкәрия, гадәтенчә, иртүк торып ул көнне дә кармакларын карарга китте. Әле Ык буе тын. Бернинди шау-шу юк. Балыклар сикерешеп уйнамый. Хәтта елга үзе дә, йокысыннан уянып җитмәгән кебек, салмаграк ага сыман. Зәкәрия теләр-теләмәс кенә киемнәрен салып, кармакларын карарга елгага кереп бара иде, шул вакыт кайдадыр еракта эт өргән тавыш ишетте һәм сагаеп як-ягына каранды. «Бу вакытта Ык буенда нинди эт булырга мөмкин?» дип уйлады ул, эт өргән якны күзәтеп. Ләкин өрү тавышы яңадан кабатланмады. Зәкәрия, ялгыш ишеткәнмен, ахры, дип, кармаклары янына кереп китте. Кармакларына чалгы кайрый торган янавыч хәтле алабугадан кала берни капмаган иде. Малай иртәнге салкынлыктан дерелди-дерелди киенергә тотынды. Һәм... Ни күзе белән күрсен, үзләренең утрауларына олы авызлы этен ияртеп Гайбәтче Гайшә кереп бара иде. Ыкны кайдан йөзеп чыккан, таң тишегеннән утрауда нишләп йөри? Бу сорауларга җавап табу кыен иде.

Зәкәрия чабып авылга кайтты. Хәйдәр, Һәнүз, Зәйтүннәрне уятты. Кабалана-кабалана хәлне сөйләп бирде.

— Ялгыш күргәнсеңдер, — диде дуслары. — Ул тинтәк утрауда нишләп йөрсен!

— Валлаһи, билләһи, шул иде, — диде Зәкәрия. — Аның эте төсле эт бүтән беркемдә юк.

— Әйдәгез Гайбәтче Гайшәләргә киттек, — диде Хәйдәр. — Әгәр эте ишегалдында булмаса, Зәкәриянең сүзе дөрескә чыга.

Бу акыллы фикер иде. Малайлар дәррәү кубып Гайшәләргә киттеләр. Гайшәләрнең капкасы бикле иде. Малайлар койма ярыгы аша ишегалдын күзәттеләр. Ишегалдында җан-тын юк. Эт күренми. Бәлки, оясындадыр. Хәер, моны тикшереп карау өчен әллә ни баш кирәкми — таш алып ояга ыргытсаң, шул җитә. Һәм шулай эшләделәр дә. Оясына таш яуганда да чыкмагач, димәк, эт юк иде.

— Тизрәк утрауга барыйк, — диде берсе.

— Ә эте? Арт ягыңнан умырып алса, гомер буе басып тора торган булып калырсың.

— Нишлибез соң инде?

— Теге милиционер абый янына барыйк.

— Ул «вещественное доказательство»ны эзләп табарга кирәк бит әле.

— Алайса, Ихсан абыйга әйтергә кирәк.

Малайлар идарәгә киттеләр. Ләкин Ихсан абыйлары каядыр ашыга иде, аларның сүзен әһәмият белән тыңламады.

— Әрәмәгә чыккан һәр кешене тикшереп йөри алмыйбыз без, — дип китеп барды ул.

Малайларның кәефе кырылды. Уйлаша-фикерләшә торгач, утрауга үзләре генә китәргә булдылар. Зәкәриянең шырпы күкерте белән ата торган пистолеты, Хәйдәрнең сигездән үрелгән камчысы бар иде — аларны алдылар. Юлда барганда сүз гел шул Гайбәтче Гайшә турында булды.

— Йөзә белә микән ул?

— Мөгаен, этенә атланып чыккандыр. Убырлы карчык бит ул.

— Карчык түгел, яп-яшь әле ул.

— Ә бәлки, ул теге якка безнең көймә белән чыккандыр. Көймәсен күрмәдеңме?

Бу сорау Зәкәриягә иде. Ул:

— Юк, күрмәдем, — диде. — Мин аның эте белән кара каен куаклыгы артына кереп барганын гына күреп калдым.

Малайлар эзләнүне яр тирәсеннән башладылар. Әгәр көймә белән чыккан булса, көймә тикле көймәне күтәреп китә алмый бит инде ул. Көймә, һичшиксез, яр читендә булырга тиеш. Йә берәр камышлыкка, йә таллыкка яшереп куймадымы икән дип, бөтен яр буйларын айкап чыктылар. Әмма көймә күзгә чалынмады.

— Ул убырлы, мөгаен, үзенең себеркесенә атланып чыккандыр, — дип көлеште малайлар.

Утрауны аркылы-торкылы гизә торгач, алар теге көнне бинокль белән Өемташтан күзәткән карьер чокырлары янына килеп чыктылар. Беренче карашка монда бернинди шикләнерлек нәрсә күренмәде.

Тирән-тирән чокырлар, чокырларның төпләрендә су яшелләнеп ята. Кырыйда вак ташлык. Ташлыкта, билгеле инде, кеше эзе калмый. Чокырлардан арырак китүгә текә яр башлана. Бу яр — иске Ык яры. Ык үзенең юнәлешен үзгәртеп авыл ягыннан ага башлагач, бу тирәдә биек ярлар гына тырпаеп калган.

Эзләп-эзләп берни тапмагач, малайлар кайтыр юлга чыктылар. Шунда алар араларында Зәйтүннең юклыгын белеп алдылар.

— Кая китте соң бу Зәйтүн?

— Курай ясарга кура эзләп берәр ешкынлыкка кереп киткәндер әле.

— Әллә теге убырлы карчык тотып алдымы икән үзен?!

Малайлар, кайсы сызгырып, кайсы кычкырып Зәйтүнне чакырды. Тик Зәйтүн күренмәде. Инде аннан башка гына кайтып китәргә дип торганда, әллә каян куаклар арасыннан өне-тыны беткән Зәйтүн килеп чыкты.

— Таптым! — диде ул, еш-еш сулап.

— Кая, нәрсә таптың?

— Вещественное доказательство!

— Нинди вещественное доказательство? Милиционер абый килгәнмени?

— Әйдәгез минем белән, — диде Зәйтүн, хәлен аңлатып тормыйча. Бар да аның артыннан китте. Зәйтүн аларны бер чокыр төбендәге сүнеп җитәргә өлгермәгән учак урынына алып килде. Малайлар эшнең нәрсәдә икәнен бик тиз төшенделәр. Учак якканнар икән, димәк, утрауда кемдер булган. Дөрес, биредә кеше булуы артык гаҗәп түгел. Әмма төнлә кем учак ягып ятар икән? Авыл кешеләре монда чыгып йөрми, чөнки Ыкның монда тирән җире.

— Берәр җирдә бандитлар яшеренеп ятмый микән? — диде берсе.

— Әлбәттә, бандитлар! — дип раслады икенчесе. — Әнә анда каз мамыклары таралган. Мөгаен, безнең казларны шушындагы бандитлар суеп ашап ятадыр.

— Әгәр шул жуликларны эләктерсәк, безгә орден бирерләр иде, әйеме?

— Бирерләр ди, көтеп тор!

— Ә нигә бирмәсеннәр? Суга батучыны коткарган өчен дә медаль бирәләр бит.

Малайлар бәхәсләшә-бәхәсләшә чокыр тирәсендә йөренделәр. Бер-берләренә сиздермәскә тырышсалар да, һәркем күңелендә курку ята иде. Менә-менә чокыр төбеннән яки куаклар артыннан баштанаяк коралланган, яңакларын сакал-мыек баскан юлбасарлар килеп чыгар да аларга ташланыр кебек тоелды. Зәкәрия батырлык өчен күкерт пистолетыннан атып җибәрде. Шартлау тавышына каяндыр, тонык кына булып, эт өргәне ишетелде. Малайларның колаклары сагайды, йөрәкләре дөп-дөп тибәргә тотынды.

— Димәк, теге убырлы карчык монда, — диде Хәйдәр, чыбыркы сабын кыса төшеп.

— Әйе, эт өргәне аермачык ишетелде, — диде башкалар да.

Вакытны юкка әрәм итми генә тизрәк теге милиционерны, һич югы, Булат абыйларын эзләп табу нияте белән малайлар авылга сыпырдылар. Аларның бәхетенә милиционер авылда иде. Хәлне сөйләп биргәч, аның да күзләре ялтырап китте.

— Әйдәгез, — диде ул малайларга, — киттек.

Җыйнаулашып тагын утрауга юнәлделәр. Учак урынын милиционер бик җентекләп тикшерде. Аннан «Мальборо» сигареты төпчеген тапканнан соң, йөзендә серле елмаю балкыды. Карьер тирәләрен ныклап тикшерә торгач, аның игътибарын текә яр үзенә җәлеп итте. Ул билендәге пистолетын капшап алды да яр буена китте. Текә ярның кызыл балчыгы ничектер шикле күренә иде. Якынрак килүгә, яр читендәге олы кәскә игътибар итте ул. Әлеге кәсне күтәреп караган иде, җир астына юл киткәнлеге беленде. Малайларның йөрәге атылып чыгардай булып типте. Милиционер, пистолетын кабурасыннан чыгарып, һавага берне атып җибәрде, аннан:

— Кем бар анда, чыгыгыз!— диде. Тик җир астыннан тавыш-тын ишетелмәде.

Милиционер шактый йөрәкле кеше — ике уйлап тормастан чокыр авызына кереп китте. Малайлар да берәм-берәм аның артыннан чумдылар.

Аста караңгы иде. Баштарак берни күрмәделәр. Бераздан соң күзләре караңгыга ияләшә башлады. Җир асты юлы кергән җирдә тар гына, ләкин ул тора-бара киңәйде һәм безнең геройларыбыз зур бер бүлмәгә килеп чыктылар. Монда өстән тонык кына яктылык төшә иде. Биредәге манзараны күреп һәммәсе аһ итте. Бүлмә эче тулы шыплап тутырылган әйбер. Туннар, бүрекләр. Әрҗә-әрҗә аракы, төргәк-төргәк тукымалар, бер өем «Мальборо» сигареты, тагын әллә ниләр.

— Гали баба һәм кырык карак әкиятендәге кебек монда, — диеште малайлар.

— Абый, абый, бу юлбасарлар оясыдыр, әйеме?

— Бәлки, бәлки.

— Теге вакыт күрше авылның кибетен басканнар иде, бу әйберләр шул кибетнекедер.

— Бәлки, бәлки.

— Ә Гайбәтче Гайшә монда нишләп йөргән? Әллә юлбасарларның атаманнары шул микән?

— Бәлки, бәлки.

Милиционер малайларның барлык сорауларына да «бәлки, бәлки» дип кенә җавап бирде. Аның уйлары еракта иде, күрәсең. Бераздан соң ул ике малайга:

— Сез барыгыз, тиз генә авылга кайтыгыз. Ихсан абыегыз берничә кеше белән монда килсен.

Малайларның бер аяклары монда, икенче аяклары тегендә булды. Авылга керүгә үк, аларга Галимә апалары очрады. Малайлар бер-берсен бүлдерә-бүлдерә хәлне сөйләп бирделәр. Галимә апалары малайларны ияртеп идарәгә китте. Аларның бәхетенә, идарәдә Булат үз бригадасының берничә егете белән каядыр барырга җыенып тора иде. Йөк машинасына утырдылар да бергәләп утрауга киттеләр. Ыкның теге ягына чыгар өчен Октябрьск каласы янында күпер бар, машина өчен сигез-ун чакрым ара берни түгел иде. Эһ дигәнче барып җиттеләр.

Җир асты юлы буйлап малайлар артыннан әлеге бүлмәгә кергәч, күпмедер вакыт һәммәсе сүзсез торды. Моның караклар оясы икәнлеге ачык иде инде. Тизрәк әйберләрне төяргә тотындылар. Әйберләр арасыннан теге вакыт югалган мотоцикл да чыкты. Озакламый угрылар үзләре дә капты. Алар төрмәдән качкан ике бәндә булып чыкты. Тирә-юньдәге кибетләрне басып, авыл халкының каз-үрдәкләрен суеп яткан бәндәләрнең берсе Гайбәтче Гайшәнең энесе икәнлеге ачыклангач, авыл халкы тагын бер мәртәбә аһ итте. Менә ни өчен Гайбәтче Гайшә утрауга чыгып йөргән икән! Бәлки әле, ул каракларга кемдә нинди байлык барын, кемнең өйдә юклыгын әйтеп торгандыр. Әнә хәзер телен тешләде. Хәтта судта да, башын юләргә салып, берни дәшми утырды.

Хәер, анысы инде өлкәннәр эше. Ә малайлар утрауны өр-яңадан үзләренеке иттеләр. Хәзер инде алар чынлап та утрауның чын хуҗалары булып яңа дәрт, яңа көч белән эшкә тотындылар.

# Хикәяләр

## АЧСАҢ КҮҢЕЛ ТӘРӘЗӘЛӘРЕН

Эштән кайткач, ишегалды яктагы тәрәзәмне киереп ачып, тышны күзәтергә яратам. Бала-чагаларның мәш килеп уйнаулары, ишегалдының үзенә генә хас бер хәрәкәт белән гөрләп торуы минем уйларымны бөтенләе белән урап ала да барлык арыганнарымны оныттыра.

Менә шулай тышка карап ял иткәндә, мин үзебезнең ишегалдында һәр көнне бер кызны күрәм. Ул гәүдәгә шактый озын һәм ябык. Хәрәкәтчән, өлгер күренә. Подъезддан ук кебек атылып чыга да, ачкан ишеге ябылырга өлгергәнче, ул инде чатка да кереп югала. Аннан соң күп тә үтми, челтәрле сумкасына төрле ашамлыклар тутырып кайтып та җитә. Аның өстендә күп вакыт юка кызыл пальто була. Ул безгә каршы йортта, өченче катта тора. Менә ул кызыл пальтосын кояшта ялтыратып йөгерә-йөгерә баскычтан менә, бүлмәләренә кергәч, кояш караган тәрәзәләрнең пәрдәсен тартып куя.

Аның ниндидер максат белән ашыгып-ашыгып йөрүенә караганда, ул эшчән кызга охшый. Аны күргән саен, миндә аның белән танышу теләге арта бара. Тәрәзә янында торганда, ул озаграк күренмәсә, күңел тынычсызлана башлый. Башка вакытлардагы кебек, мине ишегалды тормышы да кызыксындырмый. Тынычлыгымны җуям.

Ә беркөнне бик озак карап та кыз күренмәгәч, тәрәзәләремне яптым да киенеп тышка чыктым. Беркая барасым килмәсә дә, хәтсез генә урамда йөрдем. Ләкин аңа карап кына күңел басылмады. Ниндидер бер тарту көчен җиңә алмыйча, шул кыз торган йорт янына килдем. Ахырда түзмәдем, аларга керергә булдым. Әмма икенче катка күтәрелүгә, кыз белән йөзгә-йөз очраштык. Аның чәчләре тәртипсез таралып битенә төшкән. Ул аларны башын артка чөеп, үз урыннарына яткырып куйды. Кызның бер кулында юеш чүпрәк, ә икенчесендә сулы чиләк. Ул баскычларны юып төшеп килә иде.

— Исәнмесез! — дидем мин.

— Исәнмесез?!

— Бу арада бер дә күренми башладыгыз, — дидем мин, кызның эштән туктавыннан файдаланып.

Кыз, чиктән тыш гаҗәпләнеп:

— Кайда күренми башладым? — диде.

— Ишегалдында.

— Ә минем сезне гомеремдә дә күргәнем юк бит, мине каян беләсез?

— Сезне һәр көнне күрә идем, менә бу арада нишләптер күрми башладым. Мин сезнең каршыдагы йортта гына торам.

Сөйләшә-сораша торгач, аның исемен дә белдем — Гөлсинә. Ул кечкенә генә бер бүлмәле квартирада әбисе белән генә яши икән. Әбисе бик картайган, кеше ярдәменнән башка урыныннан да тора алмый. Ә Гөлсинә үзе иртән укуга йөгерә, ә укудан кайткач, кибеткә яки базарга китә. Бөтен авырлык Гөлсинәгә төшә.

Уналты яшьлек кызның ата-анасы булмавы гаҗәпләндерде мине. Бу турыда сорарга да уйлаган идем, ләкин аны уңайсыз хәлгә куясым килмәде. Берәр вакыт, бәлки, үзе дә сөйләр.

Беркөнне, җөрьәт итеп, тагын аларга кереп чыгарга булдым. Шулай да әйтергә кирәк, авыру әбисе белән генә торучы ата-анасыз ятим кыз булгангамы, аларның өендә бернинди шатлык юктыр кебек тоелган иде. Күңелсез бер бүлмә күрермен дип эчкә үттем һәм ишек төбендә тукталып калдым. Минем алда яп-якты, бөтен җирләре пөхтәләп җыештырылган, кечкенә булса да, иркен генә бүлмә иде. Монда бөтен нәрсә үз урынында. Стеналар — үзләренең ачык буяулары, мебельләр — гадилеге белән матур. Түрдә — бердәнбер караватта — кызның әбисе ята. Ул, мин кергәч, әкрен генә торып утырды, аннары гафу үтенгәндәй әйтеп куйды:

— Әйдә, улым, түргә уз. Минем болай ятып торуыма карама, мин гел шулай. Озакламый Гөлсинә дә кайтып җитәр. Бүген аларның класс җыелышлары, шуңар озаграк торды. Синең турыда Гөлсинә сөйләгән иде шул. «Бер абыйны баскыч юдырттым әле» дип көлә-көлә кергән иде беркөн. Аның нинди кызыгын тапкандыр. Бала гына шул әле, бала гына.

Гөлсинә турында сөйләгәндә, карчыкның йөзе яктырып китә. Аз гына елмайса да, битләрендәге җыерчыклары, ниндидер бер әмергә буйсынгандай, авыз тирәсенә җыелалар, һәм карчыкның аксыл йөзе тагын да мөлаемлана. Аның эчкерсез рәвештә үз итеп Гөлсинә турында сөйләве минем күңелемне тиз яулап алды. Мин ни өчен кергәнемне дә онытып, карчыкның тормышы турында тыңладым. Дөрес, ул үзе турында бик саран сөйләде, нинди генә сүз башласа да, бөтен мәгънәсе Гөлсинәгә барып тоташты.

— Бигрәк тә кеше җанлы бала булды инде, — дип дәвам итте ул. — Мәктәптән кайту белән мендәрләремне йомшартып сала, эһ дигәнче ашарга пешереп өлгертә, алда бәхете генә булсын балакаемның.

Ул шулай диде дә көрсенеп куйды.

Мин дә түзмәдем, сорап куйдым:

— Ә аның ата-анасы кемнәр соң?

— Ата-анасын кем дип әйтим икән сиңа. Бик әйбәт кешеләр алар. Мин аларда уналты ел бала карап тордым. Үземнең бәләкәйләрем булмады, картым күптән дөнья куйды. Бер кардәшебез менә шушы Гөлсинәләргә бала карарга димләде. Мин каршы килмәдем. Пенсиямне күчерттем дә килдем. Ялгызым ятканчы, кешеләр янында булырмын, дидем. Аларның дүрт балалары булды. Менә шулай тыныч кына картаеп килгәндә, былтыр аякларым сызлый башлады. Урын өстенә яттым. Чирле кеше дип кыерсытмадылар, киткән чакта елашып ук калдылар. Китмә дип бик кыстаганнар иде дә, киттем. Үлсәм дә үз фатирымда үләрмен, дидем. Ә Гөлсинә баштарак килеп-китеп кенә йөргән иде, соңыннан бөтенләй минем янга күчте. «Әбекәй, син аягыңа басмыйча, мин сездән китмим», — диде. Әти-әниләре дә каршы килмәделәр. «Укуыңа зыян килмәсә, тор әйдә», — диделәр.

Карчыкның әңгәмәсен тыңлап утырганда, Гөлсинә дә кайтып керде.

— Кунак бар икән! — диде ул һәм, тиз генә өстен алыштырып, ашарга әзерләргә кереште. Мин бер карчыкка, бер Гөлсинәгә карадым. Мәктәп хәлләрен җентекләп әбисенә сөйләүче Гөлсинәнең дә, аны тыңлаучы карчыкның да йөзләрендә шатлык иде. Бу матур күңелле кешеләр арасында миңа да рәхәт булып китте. Мин аларның күңел тәрәзәләрен ачып карагандай булдым.

## ТЫКРЫК ЯНЫНДАГЫ ӨЙ

Авылыбызга мин ел саен ук булмаса да, ике-өч елга бер кайтып торам. Һәр кайтуымда әллә никадәр яңалыклар каршы ала: йә торба белән су кертәләр, йә шәһәр клубларына биргесез клуб салып куялар. Быел мине шаккатырганы — тыкрык янындагы Әүхәди абзый өе булды. Ай-яй шәп салган Әүхәди абзый йортны! Ике катлы итеп җибәргән: асты таштан, өсте сап-сары нарат бүрәнәдән. Мәңгелек. Аста — гараж. Гаражында күзеңнең явын алырлык машина.

Мин Әүхәди абзыйның йортын төрле яктан карап чыктым. Сокланып карап йөрүемне күреп, ул:

— Йә, ничек, ошыймы? — дип сорады.

— Шә-әп! — дидем мин, баш бармагымны күрсәтеп. — Во булган! Элек түбәсеннән без тау шуган йорт түгел инде бу.

Һәм минем күз алдыма тыкрык янындагы салам түбәле кечкенә өй килеп басты.

...Сугыш вакыты. Авыл өйләре, җылынырга теләгәндәй, бер-берләренә сыенышып утырганнар. Банат әбинең өе генә бераз читтәрәк, шуңа, ахры, күшеккән бәбкә төслерәк булып күренә. Буранлы кыш җитсә, ышык тыкрыкларны көрт сара башлый, һәм Банат әбинең өе түбәсеннән үк карга чума. Балалар анда үзләренә тау ясыйлар. Өй кырыендагы йомшак көрткә кереп чуммас өчен, башта чаңгы белән эз ясыйлар, ә чаңгылары карны бераз такырайта төшкәч, кемнең нәрсәсе бар — шуны күтәреп тау өстенә үрмәли башлый.

Өенең кыегына ук менеп шусалар да, Банат әби бала-чагаларны кумый. Аларның көне буе чыр-чу килеп уйнауларына хәтта шатлана төсле. Көннәр артык суытып, бала-чагалар тау шуарга чыга алмаса, Банат әби үзенә урын таба алмый йөри. Андый көннәрдә өзлексез диярлек мичenә ягып тора. Авылдашлары Банат морҗасыннан көне буе төтен чыгуын күрсәләр: «Банат нәрсәгәдер ямансулый», — diләр.

Мичендә шарт-шорт утын янса, Банат үзенең ялгызлыгын оныткандай була. Бер яктырып, бер караңгыланып янган мич каршында авыз эченнән нидер сөйләнеп утыра, сугыштагы улы Әүхәди турында уйланырга ярата. Бу утыннарны Әүхәдие кайтарып калдырган иде бит. Әллә шуңа, алар, учакта җанланып, улының хәлен сөйлиләр сыман. Сугышка киткән чакта әнисенең җылы яратуын белгән улы: «Әнкәй, утынны жәлләп якма, өеңне җылы тот, утының бетсә, яңа өйгә дип кайтарган бүрәнәләрне ягарсың», — дип киткән иде. Хәзер менә Банатның утыны бетеп килә. Ләкин өйгә дигән бүрәнәләргә кагылырга кулы бармый. Әүхәдие соңгы хатында җиңелчә яраланып госпитальгә кердем, дигән. Терелсә, бәлки, кунакка җибәрерләр. Әнә бит Сылу малае госпитальдән соң ай ярым өйдә торып китте. Әүхәди кайтса, өен буратып җибәрер. Нигә тиктомалдан бүрәнә ягарга?

Беркөнне Банат әбинең морҗасыннан көне буе төтен чыкмады. Иң беренче моны күршесе Сәгыйдә абайлап алды. «Ни булды икән?» — диде ул, пошынып, һәм йөгереп Банатларга керде. Керсә, мич каршысындагы артлы урындыкка сөялеп утырган килеш Банат әби үлгән иде.

Әбине икенче көнне шау-шусыз гына җирләп куйдылар. Улына телеграмма суктырганнар иде, кайта алмады. Бары тик госпиталь врачларыннан гына Әүхәдинең катлаулы операция ясатып ятуын белделәр. Әнисенең күңелен төшермәс, өметен өзмәс өчен генә «Җиңел яраландым» дип язган икән.

Банат әбинең морҗасыннан төтен чыкмый башлагач, бала-чагага кыен булып китте. Алар үзләренең юешләнеп каткан бияләйләрен морҗадан чыккан төтенгә куеп җылытып алалар иде. Чалбары юкарак малайлар морҗага сөялеп торырга да каршы түгелләр иде. Хәзер менә шул рәхәтлек бетте. Хәтта таудагы чыр-чу кимеде кебек. Банат әбинең төтене чыкмавы бала-чаганы гына түгел, олыларга да ничектер авыр тәэсир итте. Күршеләре, ишегалдына чыккан саен, Банат әби өе ягына карап көрсенеп куя торган булдылар. Беркөн Сәгыйдә түзмәде, үзләреннән бер кочак коры утын алып керде дә Банатның мичендә ягып җибәрде. Утны сагынган мич дөрләп янарга тотынды. Банатлар морҗасыннан чыккан төтенне күргәч, авыл халкы башта аптырап калды. «Әллә Әүхәди кайтты микән?» — дип, хәл белергә керә башладылар. Ә Сәгыйдә, акланырга теләгәндәй, болай сөйләнде: «Ягып җибәрдем әле. Әүхәди больницадан терелеп чыкса, җылы өйгә кайтыр».

— Бик әйбәт, — диделәр авылдашлары.

Дөрес, арада: «Утының кычыта икән, як», — диючеләре дә булмады түгел. Ләкин Сәгыйдә андыйларга җавап биреп тормады. Банатлар морҗасыннан хәзер һәрвакыттагыча төтен чыга иде.

Баштарак Сәгыйдәгә сәерсенеп караган кешеләр дә кочаклап утын китерә башладылар. Банат мичендә бер дә ут сүнмәде. Шырпысы бетеп, учак тергезә алмаучылар Банатларга ут алырга килә торган булдылар.

Яралардан бераз савыгып авылына кайтканда, Әүхәдине яккан мич, ап-ак иттереп юылган өй каршылады. Әнкәсенең үлү кайгысыннан катып киткән күңеле авылдашларының җан җылысын тоеп эреде. Ә инде тәмам тазарып, яңадан фронтка китәргә торганда, сугыш бетеп китте.

Әүхәди сугышка кадәр үк китереп ташлаган бүрәнәләрен каезлап, черемәсеннәр өчен астына агач-богач кыстырып әйбәтләп өйде. Аннары, үзен кабат армиягә алмаячакларын белгәч, өй салырга кереште.

Озак салды ул өйне. Башта дүрт почмаклы итеп, тыйнак кына итеп салды. Ләкин аңа бу кысан тоелдымы, сүтеп өр-яңадан алты почмаклы итеп җиткерде. Тора-бара монысын да килештерми башлады. Һәм, озак уйлап тормастан, алты почмаклы өен сүтеп ыргытты. Соңрак аскы катын таштан, өске катын агачтан эшләде. Тик барыбер күңеле канәгатьләнмәде: «Нәрсә җитми безнең йортка? Нигә ул һаман җансыз күренә?» — дип сорый иде ул кайвакыт авылдашларыннан. Авылдашлары: «Бала җитми. Өйнең җаны — бала», — дияргә теләсәләр дә, Әүхәдинең яралы күңеленә кабат җәрәхәт салудан куркып, сүзләрен әйтми калдыралар.

Әйе, Әүхәдиләрнең балалары юк. Фронтта алган яраның нәтиҗәсе иде бу.

Күңел китеклеген онытыр өчен Әүхәди бөтен барлыгы белән эшкә чумарга тырышты: көтү көтте, фермада эшләде — бер эштән дә йөз чөермәде.

Малчылыкта эшләгән чагында, бер елны аны Мәскәүгә авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә җибәрделәр. Күргәзмәдән машина белән бүләкләнеп кайтты.

Кайда машина — шунда бала-чага. «Авылны бер урат әле», — дип сырып алырга гына торалар. Әүхәдигә шул гына кирәк тә, машинасы сыйдыра алган хәтле бала-чага төяп югары очтан түбән очка, түбән очтан югары очка элдертә.

Ишегалларына дөнья яңгыратып шаулаучы ыбыр-чыбыр кереп тулган чакларда, Әүхәди үз өенең нурланып, матурланып киткәнен тоя. Ә инде кыш җитеп, тыкрыкларга җилләр тырышып кар ташый башласа, Әүхәди үз өенә терәп үк тау ясарга тотына: көпшәк карны таптый, тыгызлый, су сибә, шомарта.

Кайчандыр Банат әбинең салам түбәле тәбәнәк өен беренче биеклек иткән малайлар хәзер үзләренең малайларын җитәкләп тыкрык янындагы Әүхәди йорты янына киләләр. Әүхәди тавы биек булып, якты булып һәркемне үзенә тартып тора.

Мин, үз уйларыма бирелеп, Әүхәди абзыйның өенә карап торам. Әүхәди абзый миңа кул изи, балалар белән бергә тау шуарга чакыра. Аның тавышын балаларның шат авазлары күмеп китә. Әүхәди абзыйның бәхете минем җанга дә рәхәт җәйге җил сыман кагылып уза. Бала чагымда шуган тауның тагын да ныграк биегәюенә сөенеп, үз юлымнан китеп барам.

## ЛАЕКЛЫ КИЯҮ

*Хәзерге заман әкияте*

Яп-якты кояшлы көннәрнең берендә, университетлары, институтлары, дистәләрчә кино-театрлары белән дан тоткан зур бер ташкаланың биек түшәмле, иркен балконлы өч бүлмәле фатирында бер кыз бала дөньяга килгән. Акырып ата-аналарын борчымасын өчен, туу белән аның авызына резин имезлек каптырганнар. Ул имезлеген чәйни-чәйни теш чыгарган, стенадагы келәмнәргә тотына-тотына тәпи басарга өйрәнгән. Хәер, аягына басканчы ук аны пианино артына утырткannar. Гүзәл кыз маңгаен клавишларга бәрә-бәрә музыка серләренә төшенгән. Аягына басуга ук, роликлы тимераякларда шуа башлагангамы, ай үсәсен көн үскән, үскән саен чибәрләнә төшкән. Аның серле күзләрендә төннәрен йолдызлар төшеп коенганнар, якты йөзеннән ай үзенә нур алган, ә баскан эзләрендә матур-матур гөлләр шыткан. Кызның сылулыгыннан зифа каеннар көнләшкән, озын толымнарына борма сулар кызыккан. Энҗе тешләрен балкытып көлеп җибәрсә, хәтта кояш тоныкланып кала икән.

Гүзәл кыз бик тиз арада мәктәп баскычларын сикереп узган, күз ачып йомганчы институтны бетергән, көзгегә карап күзләренә сөрмә тартып өлгергәнче егерме бишкә җиткән. Шуннан соң кызның әти-әниләре әйткәннәр: инде, кызым, син әнис алмасыдай пешеп җиттең, шәһәрдә бер матур булдың, кулыңда дипломың бар, ике чит тел беләсең, мәҗлесләрдә теләсә нинди исерекне җырлатырлык пианинода уйныйсың, балет түгәрәкләренә йөреп, фырт егетләр белән ресторанда биерлек модный биюләр өйрәндең, хәзер үзеңә тиң кияү тапсаң иде, дигәннәр. Безнең картаймыш көнебездә томрап торган оныклар сөясебез, аларны, сине иркәләгән кебек, иркәлисебез килә, дигәннәр.

— Ярый, ярый, — дигән кыз, — әмма миңа тиң егетне ничек табарга?

— Әйе, — дип килешкән ата-ана, — андыйлар сирәген сирәк. Ләкин бик тырышсак, тапмый калмабыз. Сине балет түгәрәгенә язмый маташканнар иде, кешесен таптык та яздырдык, музыка мәктәбенә үтмәгән идең, тагын җайладык, институтка кергәндә янә табаннарыбызны төшерсәк төшердек, барыбер үзебезнекен иттек. Дөрес, ул чактагы дус-ишләр безне хәзер читләтеп үтәләр, ни әйтсәң дә, үзебез пенсиягә чыктык, аның каравы безнең тормыш тәҗрибәбез артты. Эшнең җаен беләбез.

Һәм алар, озак уйлап тормастан, болай дип пышылдаганнар:

— Безнең асыл кызыбызга асыл кияү кирәк иде, асыл кияү кирәк иде.

Пышылдап әйтелгән сүзнең кычкырганга караганда ераграк ишетеләчәген алар инде беләләр иде. Ниятләрендә һич ялгышмадылар: боларның пышылдауларын күршедә яшәүче чукрак кортка ишетеп алды, ишетеп алды да түкми-чәчми телсез ахириенә сөйләде, тегесе исә ошбу хәбәрне бөтен дөньяга таратты. Менә килә башладылар, мин сиңа әйтим, кияү егетләре. Ул Алып батырдай гайрәтлеләре дисеңме, ул Шомбайдай хәйләкәрләре дисеңме, ул ак сакаллы карттай акыллылары дисеңме — кемнәр генә юк араларында. Килә тордылар, китә тордылар. Ишекләр ябылырга, самавырлар кайнап чыгарга, камырлар ачырга, табалар чыжларга, мичләр суынырга өлгермәде. Килгән яучыларны сыйлап кызның әти-әниләренең табаннары төште, куллары коймаклы табаны күтәрә алмас булды, йокысызлыктан керфекләре авырайды. Затлы бүләкләрне карап күзләре камашты, вәгъдә ителгән бирнәләрне тыңлап, колаклары томаланды. Әмма асыл кызларына ошарлык асыл егет күренмәде.

Менә, ниһаять, җиде диңгез кичеп, җитмеш тауны үтеп, җитмеш җиде каланы артта калдырып, бер егет килеп керде боларга. Моңа кадәр мәрмәр сындай хәрәкәтсез утырган кызның сыңар керфеге селкенеп куйды.

— Чибәр егет, син кем, кайсы илләрдән, нәрсә белән килдең? — дип сорадылар аңардан.

— Мин — очучы, ерак диңгез артыннан җилдән җитез самолет белән килдем, — диде егет. — Сезнең кызыгызның гүзәллеге бар дөньяга таралган. Ул хакта диңгездә акчарлаклар, һавада — бөркетләр, далада — җилләр, болында — гөлләр, урманда чишмәләр сөйли. Утыз ел буена түкми-чәчми йөрәгемдә саклап йөрткән мәхәббәтемне бүген менә гүзәл кызның кулларына салырга дип килдем. Рәхим ит...

— Тукта, тукта, — диделәр егеткә, — алай ашыкма. Мәхәббәтең йөрәгеңдә утыз ел буе йөреп гайрәтләнгәндер, анысына ышанабыз. Ләкин, безнең уйлавыбызча, дөнья көтәр өчен гайрәтле мәхәббәт кенә җитми. Безнең «Ни белән килдең?» дигән соравыбызны син аңлап җитмәдең шикелле. Аның эчке мәгънәсе бар, егеткәем.

— Ә-ә, — диде лачын егет, бераз төшенә башлап, һәм күкрәк кесәсеннән хезмәт кенәгәсен тартып чыгарды: — Менә карагыз, — диде ул, — унике ел стажым бар, беренче класслы очучы дигән таныклыгым. Паспортым чиста, моңарчы өйләнмәгән.

— Шул гынамы?

— Шул гына.

— Әзрәк икән, егеткәй.

Лачын егет уйга калды һәм кинәт нәрсәнедер исенә төшерде:

— Ә-ә, ул гына түгел икән, тиздән фатирга чиратым җитә. Өйләнеп җибәрсәм, бәлки, тизләтерләр дә... — диде.

— Ә кемнәрең бар? — дигән сорау бирелде аңа.

— Беркемем дә юк. Мин балалар йортында үскән кеше. Ул яктан тыныч була аласыз.

— Ярый, — диделәр лачын егеткә, — бәхетең җиңде, сине кияүләр исемлегенә беренче итеп теркәп куябыз. Өч ел үткәч килерсең, әгәр дә мәгәр ул вакытта кызыбыз үзенә лаеклыны тапмаса, һичшиксез, синеке булачак.

Очучы егет башын түбән иеп чыгып китүгә, түш кесәсенә инженерлык дипломы салып, уң кулының имән бармагында яңа марка «Жигули» ачкычы бөтереп, икенче бер егет килеп керде.

— Сәлам чибәр туташка, көянтә кашка, күктәге айга, җирдәге кояшка, түтәлдәге гөлгә, гөлдәге былбылга, — диде ул җор теллеләнеп һәм кызның алдына килеп кара бөдрә чәчле башын иде. Бу егетне күргәч, сылу кызның ике керфеге селкенеп куйды. Хәтта күз дә сирпеп алды бугай әле.

— Телең шома күренә. Син кем, нәрсә белән килдең? — дип сорадылар егеттән.

— Мин — кичәге студент, иртәгәге инженер, — диде егет. — Әтием алып биргән «Жигули» белән килдем.

— Кемнәрең бар?

— Әти белән әнием һәм студент сеңлем.

— Бүтән беркемең дә юкмы?

— Тагын бер алама маэмаем бар. Машинаны саклап калды.

— Ярый, егет, — диделәр кичәге студент, иртәгәге инженерга, — син безгә ошый яздың. Кияүләр исемлегенә икенче кеше итеп язып куябыз. Дүрт елдан килерсең, шул чакта кызыбыз кияүгә чыкмаган булса, аны үзеңнеке дип сана.

Гарьлегеннән күз яшьләренә буылып чыгып китте кичәге җор телле студент. Аның әле профессорларга имтихан бирә алмаганда да мондый гарьлек кичергәне юк иде.

Кичәге студентның эзләре суынып өлгермәде, бусагада пәһлевандай икенче берәү пәйда булды. Җилкәсенә ул олы сандык күтәргән иде, маңгаеннан терекөмештәй тир тамчылары тәгәри. Егет, авыр сандыгын идәнгә куеп, сәлам бирде.

— Бу йортта кияүгә чыгарга теләгән кыз бар дип ишеткән идек, ошаса, шуны алып китәргә исәп, — диде ул, турыдан ярып. Аның бу тупаслыгыннан кызның юка иреннәре тагын да юкарды.

— Нахал!

— Ә нигә? Без төшеп калганнардан түгел, — дип гөрләде егет, — кызның теләсә ниндиен сайларга хакыбыз бар.

— Син кем? Нәрсә белән килдең? — дип сорадылар аңардан.

— Мин — эшче егет. Трамвай белән килдем.

— Сандыгыңда нәрсә?

— Сандыгымдамы? Менә карагыз.

Егет сандыгын ачып җибәрде һәм көлтә-көлтә кәгазьләр тартып чыгара башлады:

— Болар миңа ун ел буена бирелгән мактау кәгазьләре. Мин бер генә ярышта да беренчелекне бирмәдем. Югары разрядым бар. Бер бүлмәле фатирда берүзем яшим. Риза булсаң, әйдә, чибәр кыз, тотын эшче кулына. Син болай ошардай күренәсең.

— Тукта, тукта, — диделәр эшче егеткә, — мактаулы эшче булуың әйбәт, анысына һич сүзебез юк, әмма безнең әле сиңа тагын бер соравыбыз бар.

— Рәхим итегез.

— Синең кемнәрең бар?

— О-о, — диде егет. — Без алты бала. Өч апам колхозда: кайсы сыер сава, кайсы терлек карый. Калган өчебез шәһәрдә. Барыбыз да алдынгылар. Тагын өйдә карт әти-әнием. Тик сез борчылмагыз, алар безнең янга килмәячәкләр. Шәһәрне яратмыйлар. Кызыгыз бер бүлмәле фатирда үзе баш, үзе койрык булыр.

— Бүтән беркемең дә юкмы?

— Алайса, безнең сиңа дигән кызыбыз да юк. Рәхим итеп, ишекне теге яктан яп...

Көннәр болыттай агыла торды, чибәр кызның күңелен яуларга теләүчеләр һаман күбәя барды. Иңнәренә алтын погоннар таккан хәрби хезмәткәр дисеңме, төрле илләр гизгән атаклы спортчы дисеңме, рәсемнәре газетаның беренче битләрендә басыла торган атаклы уйлап табучы дисеңме — кемнәр генә юк инде. Әмма кыз хәрби хезмәткәрнең алтын погонына да, атаклы спортчының ялтыравыклы медальләренә дә, уйлап табучының шөһрәтенә дә кызыкмады. «Унбиш ел көтсәм көтәрмен, барыбер үземнекен итәрмен», — дип, көзгедәге үз чагылышы белән сөйләште. Дөньяда һәркемгә үз ише табылачагына ышанып, өметләнеп яши бирде. Ишек шакучылар кими төшкәч тә өметен өзмәде. Чибәрлеге өстенә бик сабыр да иде шул.

Көтә-көтә көтек була язгач, көннәрдән бер көнне өстенә җитмеш җиде ямаулы джинсы костюм, башына туксан тугыз маймыл рәсеме төшкән кепка кигән бер бәндә килеп керде боларга. Керде дә ләмгә баткан ботинкалары белән кыйммәтле келәм өстендә мәңге чистармаслык эзләр калдырып түргә узды, аннары авызындагы чүмеч кадәр челемен кулына алып: «О,кей, пардон! — дип йомшак кәнәфигә чумды. — Шушымыни инде сатлык товар?» — диде бераз торгач, җиде бөртек кашын сикертеп.

— Йә-йә, — диделәр аңа, — телең нәрсә сөйләгәнне колагың ишетсен.

— Мин һәрнәрсәне үз исеме белән атарга яратам, о кей, пардон!

Егетнең тупаслыгы чибәр кызның йөрәгендә нindидер өмет чаткысы уятып җибәрде. Тупас, димәк, үзенә ышана.

— Син кем? Нәрсә белән килдең? — диде чибәр кыз, сорауны эти-әниләре биргәнне көтмичә.

— Минме? Мин бер танышымның танышы. Ә бирегә икенче танышымның машинасында килдем һәм коры кул белән түгел. — Ул шап итеп чалбарының җитмеш җиденче кесәсенә сукты. Егетнең бу сүзләреннән соң чибәр кызның йөрәгенә мәхәббәт ялкыннары үрмәләп менә башлады. Бер кызды ул, бер суынды, бер ярсыды, бер тынды.

— Яле, егет, яле, — диде аннары, — минем ошбу соравыма җавап биреп кара. Тик шуны бел: егетләрнең арысланнары нәкъ шул сорауга мин теләгән җавапны таба алмадылар.

— Мин табалмаган нәрсә юк, о,кей!

— Син әле генә чалбарыңның җитмеш җиденче кесәсенә сугып, буш кул белән килмәдем дип мактандың, ләкин юкка: анда шыплап энҗе-мәрҗәннәр тутырган булсаң да, алар мине тамчы да кызыксындырмый. Байлык дөнья чүбе ул: бүген бар, иртәгә юк. Син миңа шуны әйт, кемнәрең бар?

— Йөз җирдә йөз танышым бар, — диде егет, кукраеп. — Ә биредә, — ул яңадан кесәсенә сугып алды, — аларның телефоннары язылган блокнот. Мин бөтен эшне шулар аша гына йөртәм. Ни телисең, чибәр туташ, теләгеңне сыра күбеге шиңгәнче үтим.

Егет майланып беткән блокнотын кызның алдына китереп салды.

— Күзеңне йом да теләсә кайсы санга төрт. Әһ дигәнче ике гыйфрит каршыңа килеп басар.

Кызның мәхәббәте көчәйгәннән-көчәйде, куллары калтыранды, телләре көрмәкләнде. Ниһаять, бераз аңга килгәч, блокноттагы бер санга китереп төртте:

— Шалтырат!

— О,кей, пардон, пыжалысты!

Егет телефон номерын җыйды һәм үзе генә аңлый торган телдә нидер мыгырдады. Телефон трубкасында да шундый ук аңлаешсыз авазлар ишетелде. Бер-берләре белән сөйләшеп алгач, кияү егете кызга карады:

— Нәрсә боерасыз?

— Бер атнада туй күлмәге әзер булсын! — диде кыз.

— Ике сәгатьтән мин әйткән адрес буенча туй күлмәге тегеп китерегез! — диде кияү. — Үлчәме, — ул кызга карады, — кырык сигез. Фасоны — дөньяда юк фасон. Әйе, әйе, үз кәләшемә. О,кей!

Кияү егете трубканы куйды, мәхәббәтеннән тәкатьсез калган кыз егетнең муенына барып сарылды:

— Мин — синеке. Син нәкъ мин эзләгән кеше. Бер айдан язылышабыз.

— Нигә бер айдан? — диде фырт егет һәм телефоннан кемгәдер шалтыратты, аннары кәләшенә борылып:

— Ике сәгать ярымнан безне загста көтәләр, ә аңынчы туй күлмәгең килеп җитеп, син аны биш тапкыр киеп салырга өлгерерсең, — диде.

Ул тагын берничә җиргә шалтыратты, күрсәтмәләр бирде. Туйны алар озакка сузмадылар, шул ук көнне кичен ясадылар. Баллар-майлар елга булып акты. Бүләккә дигән кызыл маллар кибет киштәләрен читләтеп, турыдан-туры базадан китертелде, дөньяда юк шәраблар мичкәсе-мичкәсе белән ташып утырды. Шәраб күлләрендә кызыл балыклар йөзеп йөрде, ул кызыл балыклар кара уылдык чәчеп тордылар. Ашаган саен сый артты, эчкән саен шәраб күбәйде. Бәхетле кәләш көлүеннән дә матуррак булып хрусталь савытлар чыңлады. Туйда бер генә үпкә сүз дә ишетелмәде: һәр ике як канәгать иде. Бу туйда мин дә булдым: төпсез чүмеч белән дөньяда юк шәраб чөмердем, башсыз кашык белән аш состым. Сыйлары өч кабарга җитмәде, биш кабуда бетмәде. Шулай да, җәмәгать, бу мәҗлескә баруыма үкенмим. Нигә дисезме, сер итеп кенә әйтәм, анда мин кияү егетенең бер танышының танышы белән таныштым. Ул танышның танышы миңа бик кирәк кеше булып чыкты.

## ТУГАН КӨН БҮЛӘГЕ

Гөлзадәгә бүген төшендә кояш бүләк иттеләр. Кемдер яп-якты кояшны ике кулына күтәргән дә Гөлзадәгә таба килә: адымнары сак, салмак. Әйтерсең кулындагы кыйммәтле байлыгын җиргә төшереп җибәрүдән курка. Артык якты булгангамы, күз чагыла, күтәреп килүчене танып булмый.

Менә ул Гөлзадә каршына басты да бик таныш, бик ягымлы тавыш белән:

— Гөлзадә, суз кулларыңны, сиңа кояш алып килдем, — диде.

— Юк, юк, — диде Гөлзадә, артка чигенеп, — кирәкми. Ул бик кайнардыр.

— Әйе, кайнар. Аның кайнарлыгы синең гомерең буена җитәрлек.

— Мин ул кайнар кояш белән нишләрмен соң?

— Тормышның җилекләргә үткеч салкыннары, күңел күген каплаучы болытлары була. Җан өшеткеч салкын көннәрдә кулларыңны шушы кояшка сузып җылынып алырсың. Күңел күгеңне болытлар сарганда, үз кояшыңны күккә чөярсең.

— Алайса алам, тик мин бу кояшны кайда сакларммын соң?

— Йөрәгеңдә. Аны бары йөрәктә генә сакларга ярый, юкса суына, сүнә. Чөнки ул яктылыкны, җылылыкны кеше йөрәгеннән алып яши торган кояш.

Шулай дип ул Гөлзадәнең кулларына кояш тоттырып китте. Әлеге кеше күздән югалгач, Гөлзадә үзенең гаҗәеп булган күкрәгенә кысты һәм бөтен тамырлары буйлап кайнарлык узганын сизде. Бу кайнарлык учактан төшкән кызулыкка да, күктән таралган кояш нурларына да охшамаган иде. «Һей-ей, юмарт җанлы кеше, кем син? Исемең ничек синең?» — дип кычкырмакчы булды Гөлзадә, ләкин тавышы чыкмады. Шунда ул уянып китте.

Уянса, кулында бернинди кояш юк. Үзе һаман больница палатасында ята. Нишләп монда соң әле ул? Ә-ә, әйе, авырып китте бит. Чир белән яман сүз бердер, күрәсең, иң көтмәгән җирдә ега да сала. Юкса әле Гөлзадәнең авыруга бирешеп торырлык чагымыни? Төше бигрәк матур иде, кызганыч, озынгарак сузылмады. Ә шулай да нишләп аңа мондый төш керде икән? Тукта, тукта, бүген аның туган көне ләбаса. Мөгаен, берәрсе кояш кебек искиткеч бүләк китерер. Кем бирер икән андый бүләкне? Әниләреме? Һи, көт алардан. Классташ дусларымы? Юк, классташлары Гөлзадәнең туган көнен белмиләр. Яратмый Гөлзадә үзенең туган көнен бәйрәм итәргә, тууын зур шатлыкка санамый ул. Сигезенче класста укыганда, әтиләре:

— Хәзер син зур кыз булдың инде, үткәрик туган көнеңне. Чакыр иптәшләреңне, күңелле итеп утырырсыз, — дигәч, ризалашкан иде. Берничә классташ дустын да чакырган иде. Бик күңелсез тәмамланды ул көн: эти-әниләре әллә ни арада исерешеп өлгерделәр. Бигрәк тә әтисе ни сөйләгәнен белми башлады: — Шәпме минем кыз? — диде ул, Гөлзадәнең классташы Наилне эләктереп алып. — Ошаса, өйләндерәм үзегезне.

Наил кызарынды, ярдәм сорап Гөлзадәгә карады. Гөлзадә, мөмкин кадәр йомшак итеп:

— Син, эти, юк-барны сөйләмә, — диде.

— Кәк-тәк юк-бар булсын?! — дип кыза башлады ата кеше. — Сиңа хәзер ничә яшь? Унбишме? Унбиш яшьтә, понимаешь, этиең инде...

Унбиш яшьтә ничек кызлар кочагына керүе, мәхәббәтнең бу вакытта ничек ялкынлы булуы турында тупас итеп, ямьсез итеп сөйләргә тотынды. Гөлзадә әллә нинди юллар белән аны туктатырга тырышса да, үзенекен тукыды ул. Ахыр чиктә Гөлзадә иптәшләрен өйләреннән алып чыгып китте. Иптәшләре алдында эти-әниләренең шулай йөгәннән ычкынулары өчен оят иде аңа. Ничә тапкыр антлар итә-итә сүз бирделәр, яңадан бу йөз кызарткыч нәрсәне авызга алмыйбыз, диделәр, ә үзләре, юк сәбәпне бар итеп, шуңа тотынырга гына торалар. Әти-әниләренең гадәтләрен яхшы белгәнгә, кыз һәр бәйрәмне сагаеп, шомланып, куркып көтте. Аның өчен иң озын, иң газаплы көннәр — бәйрәм көннәре иде. Шуңа күрә үзенең туган көнен кешеләргә әйтмәде. Бераздан алар икенче фатирга күчтеләр. Гөлзадә унынчы классны башка мәктәптә укый башлады. Иптәшләре чакырса, туган көн кичәләренә барды, бүләген җәлләмәде. Әмма үзе беркемне дә чакырмады. Әгәр берәрсе: «Синең, Гөлзадә, туган көнең кайчан соң?» — дип сораса: «Мин бит әле тумадым. Кайсыдыр халыкта туган көне дип кешенең нинди дә булса эш күрсәткән көнен саныйлар икән, ә минем андый эш күрсәткәнем юк», — дип, сүзне шаяруга бора иде.

Бүген менә һич көтмәгәндә туган көне исенә төште. Теге матур төш, бәлки, аңа туган көн бүләге буларак кергәндер. Язмыш кайчакта кешегә рәхимле булып куя бит. Мәхәббәттән уянган йөрәктәй, язгы бөреләр уянып килгәндә, кояш нурлары боз сөңгеләренә эленгән тамчыларга тулып тәрәзәдән караганда, урам карлары җылы сүздән йомшаган күңелдәй эреп барганда, больницаның соргылт стеналарына карап ятучы унҗиде яшьлек кызның үз язмышыннан бүләк көтүе гаҗәпмени? Ул, больница стеналары хыялын чикләмәсен өчен, нянялардан башын тәрәзәгә таба бордырып куйдырды. Болай, ичмасам, гәүдәң монда ятса да, күзләрең тышта. Агач ботакларына кунган кошларны күзәтәсең, трамвайларның «яшен»нәрен күрәсең, ашыгып-ашыгып аккан ак болытларны әле сарык көтүенә, әле язып ташланган ап-ак йон өеменә

охшатасың. Тыштагы хәрәкәт вакытның агышын сиңа сиздереп тора. Ә больницада вакытның үткәнлеген белү, тою кешегә бик кирәк.

Әмма Гөлзадәгә хыялга бирелеп озак ләззәтләнеп ятарга ирек бирмәделәр. Палатадагы ике хатын үзара ызгыша башлады. Хәер, аларның ызгышмаган көннәре юк. Ә әйткәләшү һәрвакыт форточка хакында чыга. Хатыннарның берсе форточканы ачып җибәрдеме, икенчесе шунда ук килеп яба. Баштарак алар бер ачалар, бер ябалар, ачып-ябып арыгач, һәр икесе үз караватына утырып әйткәләшергә тотына. Гөлзадә белән алар беренче көнне исемнәрен әйтеп танышканнар иде, тик кыз ул чакта кеше исемен истә калдырырлык хәлдә түгел иде. Аннары ул аларны күңеленнән «Ачучы» һәм «Ябучы» дип кенә атый башлады.

Бу апалар больницада шактыйдан бирле яталар инде. Шифаханәнең бертөрле кызыксыз тормышы аларны шулкадәр туйдырган, эчләрендә кайнаган ярсуның, чирләреннән котыла алмаудан туган көчсезлекнең ачуын хәзер бер-береннән алмакчы булалар. Әгәр язмыш бераз рәхимлелек күрсәтсә, авырулары бетү ягына барса, алар, бәлки, һичкемнән ким түгелләрдер. Бәхетле кешеләр киң күңелле була бит. Бәхетсез чакта да җаныңның олылыгын, башкалар гамен үз гамеңнән өстен куя белү сыйфатын саклап калу өчен рух ныклыгы белән якты акыл кирәк.

Гөлзадәнең укыганы бар, нindidер бер шагыйрь нәкъ менә шулай дигән. «Көчле рухлыларны кайгы-хәсрәт берләштерә, көчсезләрне — талаштыра», — дигән. Бу сүзләр гүя бу апаларга карата әйтелгән.

Гөлзадә әле үзенең көчле кешеме, түгелме икәнлеген белми. Моңарчы аңа күтәрә алмаслык кайгы да, җиде кат күкләрнең ишеген ачарлык шатлык та килгәне юк. Ә шатлык шәрабын бер чөмереп карыйсы килә. Бүген күргән төше аны бигрәк әллә нишләтте. Менә-менә палатага кояш күтәргән егет килеп керер сыман. «Сиңа бүген унҗиде яшь тулган икән, Гөлзадә туташ — кара каш, — дияр ул. — Мондый көнне кеше больницада ятарга тиеш түгел. Әйдә тор», — дияр. «Миңа торырга ярамый шул әле», — дияр Гөлзадә. «Унҗиде яшьлекләргә бөтен нәрсә ярый. Мин бер тылсымчы, синең кайнар маңгаеңа үземнең кулымны куйсам, авыртуларың бетәр. Мендәреңә язгы нурлар көлтәсе булып төшкән чәчләреңнән сыйпасам, канатлар үсеп чыгар. Мин кулымдагы кояш белән бергә сине күккә чөярмен. Син яз йөрәге — сандугачка әверелерсең дә бәхет турында, мәхәббәт турында, яшәүнең матурлыгы турында җырларсың. Синең җырыңны тыңлаган кешеләрнең йөзләрендә елмаю кабыныр. Дөньяда исәнләшүне онытучылар ерактан ук бер-берләренә колач җәеп килерләр. Эшкуарлар бер мизгелгә эшләрен ташлап, җыр тәэсиренә бирелер. Кайгылылар — кайгыларын, чирлеләр — авыртуларын, бәхетсезләр — бәхетсезлекләрен онытып торырлар. Әнә көзгедән кара әле: синең күзләреңә яз тулган, бит алмаларыңа шәфәкъ нурлары кунган, ияк чокырыңа мәхәббәт яшеренгән...

Кояш күтәргән егет, татлы сүзләр пышылдый-пышылдый, әкрен-әкрен артка чигенде. Гөлзадә мендәр астындагы түгәрәк көзгесен алып үзен күзәтергә тотынды. Шул вакыт тәрәзәдән бер учма яктылык бөркелеп керде дә Гөлзадәнең керфегенә кунды, күзен чагылдырды. Кыз, үҗәт чебеннән котылырга теләгәндәй, башын кинәт читкә борды. Әмма яктылык та аңардан калышырга теләмәде: башны борган саен эзләп тапты һәм керфекләрне аралап күзгә тулды. Чагылудан Гөлзадәнең күзе яшьләнде. Ул, яшьләнгән күзен уа-уа, бу нинди нәрсә булды соң әле дигән күк, тәрәзәгә карады. Ә анда, күкрәге белән амбразура капларга җыенган солдаттай, тәрәзәгә иелеп үскән чаган башында бер егет утыра иде. Егетнең кулында көзге. Көзге белән ул кояш нурларын Гөлзадәгә таба җибәреп утыра. «Камил бит бу! — дигән уй йөгереп үтте Гөлзадәнең миеннән. — Әйе, Камил. Унынчы «Б»дан. Тәнәфес вакытларында ул Гөлзадәләр классына кереп сүзсез генә утырырга ярата иде.

— Сезнең кабинетыгыз якты, — диде ул шундый көннәрнең берсендә.

— Сездә дә ике тәрәзә, бездә дә ике тәрәзә инде, — диде Гөлзадә, беркатлыланып.

— Анысы шулай, — диде Камил. — Тик сездә кояшсыз көннәрдә дә якты.

Камилне күргәч, кыз бераз калкыныбрак ятты. Кулындагы көзгесе белән ул Камил җибәргән кояш нурларын егетнең үзенә юнәлтте. Ике йөрәк кояш нурлары ярдәмендә сөйләшә башлады.

— Син больницага кергәннән бирле класста гына түгел, мәктәптә яктылык кимеде, — диде егет, кулындагы көзге белән Гөлзадәнең битенә җылы нур рәвешендә кунып.

— Син нинди әйбәт кеше икәнсең, Камил, — диде Гөлзадә, җибәргән нурлары белән егетнең муенын иркәләп. — Мин бүген иртәдән бирле көттем сине. Юк, иртәдән бирле генә түгел, унҗиде ел буе көттем мин сине, Камил.

— Син безнең мәктәпкә укырга килгәч, мин үземне кинәт бик көчле, бик акыллы, бик батыр кеше итеп сизә башладым, Гөлзадә. Хәзер мин эшли алмас эшләр юк сыман. Мин бүгеннән, әкият героена әйләнеп, җиде дәрья гизәргә, җиде кат күкләрнең ишекләрен ачарга әзер.

— Син болай да мине күкнең җиденче катына алып мендең инде, Камил. Әгәр мин кулларымны селкеп җибәрсәм, канатланып очармын да, сайрар кошка әверелеп, иңеңә килеп кунармын кебек.

— Юк, юк, син сайрар кошка әверелмә, Гөлзадә. Бая әйткәнемчә, яз йөрәге сандугач булма. Сайрар кошлар җыры вакытлыча гына. Алар яз килсәләр, көз китәләр. Син һаман шулай сөенә белә торган, көенә белә торган, очына белә торган кеше булып кал. Мин синең шатланган чакларыңны күреп шатланырмын, сагышка чумсаң, хыялдагы Дөлдөлемә атланып сагышыңны таратышырга килермен, кайгың булса, кайгыңны үз иңнәремә аударырга тырышырмын.

— Ә беләсеңме, Камил, бүген бит минем туган көнем.

— Син минем өчен күптән тудың инде, Гөлзадә. Билеңнән түбән төшкән ике толымың беренче күрүдә үк йөрәгемә кереп уралды. Сөт белән юылгандай ап-ак кулларыңа кагылып алырга сәбәп эзләп, мин синнән китаплар сорап тора идем. Ә синең күзләреңнең нурында коену рәхәтлеген мин дөньядагы бернәрсәгә дә тиңли алмыйм. Синең бер карашыңнан мин җанымны факелдай яктыртырлык яктылык алып калам.

— Нигә соң син үз хисләреңне элегрәк әйтмәдең, Камил?

— Мин алар турында сиңа һәр очраган саен әйтә килдем, Гөлзадә. Ләкин безнең ул вакытта бүгенге кебек тылсымлы көзгебез юк иде.

— Әйе шул. Язмыш бүген безнең кулларыбызга мәхәббәт дигән тылсымлы көзге тоттырды. Ул көзгедә син минем йөрәгемне, мин синең йөрәгеңне күрәм. Безгә туктаусыз узып торган машиналар тавышы да, больницаның калын стенасы да комачаулый алмый. Без сүзсез сөйләшәбез, мәхәббәт телендә сөйләшәбез, Камил.

— Үткән-сүткән кешеләр миңа, бу ниткән юләр икән дигәндәй, сәерсенеп карап китәләр. Әгәр алар безнең сүзсез сөйләшүебезне аңласалар, нәрсә диярләр иде икән, Гөлзадә?

— Үзләренең шундый чакларын исләренә төшерерләр иде. Ә андый чаклары булмаган кешеләр нинди зур бәхеттән мәхрүм икәнлекләрен аңлап ачынырлар иде.

Егет белән кыз кулындагы көзгеләр әнә шулай сөйләштеләр. Иң кыю телләр әйтә алмаган сүзләрне көзге әйтте. Иң иркә куллар кагылырга базмаган битләргә көзге кагылды, моңа кадәр уйга гына китерсәң дә тәнне ялкынга уратучы иреннәрне көзгедән төшкән нурлар үпте. Сөйләшеп, җаннарына мәңге бетмәс шатлык төягәннән соң, Камил куеныннан кып-кызыл ике алма чыгарды.

— Форточкадан ыргытам, тот, — диде ул.

— Юк, юк, Камил, ыргыта күрмә, тәрәзәне ватарсың. Үзең кертеп бир.

— Сезнең анда «карантин» дип язып куйганнар, Гөлзадә.

— Ә-ә, әйе шул. Грипп чоры бит.

Камилнең кинәт нәрсәдер исенә төште, чалбар кесәләрен актарырга тотынды. Аннан ул пәке алып бер алмасының эчен чокыды да ашык-пошык нидер язып алма эченә тыкты.

— Тот, Гөлзадә!

Бер-бер артлы ике алма ачык форточкадан Гөлзадә яткан караватка килеп төште. Гөлзадә алма эчендәге язуны алып укыды. Анда: «Бу алмалар безнең яшьлегебез бакчасыннан өзелгән. Алар сихри көчкә ия. Шуларны ашауга, синең бер чирең дә калмас, Гөлзадә», — дип язылган иде.

— Болар миңа туган көн бүләкләре, — дип уйлады Гөлзадә, кып-кызыл алмаларны күкрәгенә кысып. — Бүген минем туган көнем! Кеше үзенең сөюен һәм сөелүен аңлаган көнне туадыр, мөгаен.

## КУНАК

— Әни, этләргә кайчан акыл керә?

— Әллә синең эттән башка сүзең юкмы? Ике сүзнең берендә гел эт дип торасың, — дип, әнисе кызын тиргәп ташлады. — Эткә түгел, кешеләргә дә акыл керми әле. Дөньяда калмады ул акыл дигән нәрсә. Ә син эт, дисең.

Кызы Гөлнарага күрше малае Булат эт баласы бүләк иткәннән бирле ананың тынычлыгы югалды. Дөрес, Гөлнара бик сөенде бу бүләккә. Йодрык кадәрле бу җан иясен ничек кенә иркәләмәде: башларыннан сыйпады, куенына салды, назлы сүзләр пышылдады. Туганнан бирле аягына басып карамаган, дөнья яктысын гомере буена бары тик тәрәзә аша гына күргән Гөлнарага бу көчек моңарчы үзе белмәгән-күрмәгән башка дөньядан килгән бер кунак булып тоелды. Шуңа күрә ул көчегенә исемне дә Кунак дип кушты.

Кунак нәселле эт түгел иде. Йоны сары, күзләре өлгереп җитмәгән шомырт төсендә, борыны кара. Гөлнараларга килгәндә, әле ул бик кечкенә, сөттән башка нәрсә ашамый иде. Кызның әнисе эшкә киткән чакта Кунакка идәндәге тәлинкәгә сөт салып калдыра. Гөлнарага термос белән ашын, чәен һәм башка

ризыкларын куя. Кыз, бик кыенлык белән булса да, термостагы ашны тәлинкәгә бушатып ашый, чәен эчә. Кайвакыт пешеп тә куйгалый. Элегрәк, әле Гөлнара үзе генә ашый алмаган чакта, әниләре аны караштырырга, ашатырга-эчертергә күрше Сания апага әйтеп китә иде. Ләкин Сания апалар озакламый яңа фатир алып, шәһәрнең икенче башына күченеп киттеләр. Яңа күршеләре исә гел урын өстендә яткан Гөлнараны күрүгә, боларның бусагасын атлап кермәс булды. Ә кызның әнисе Гөлнараны карап өйдә генә утыра алмады. Ашарга-эчәргә кайгыртырга, даруын-бинтын алыр өчен гел акча кирәк иде. Һөнәре буенча инженер булса да, кызына дару юнәтү, кирәк чакта больницага салу җиңелрәк булмасмы дип, бер больницага санитарка булып эшкә урнашты ул. Көне буе авырулар карау бик ялыктыра, бик арыта иде. Аларын онытыр идең, тик өеңнең бусагасын атлауга тагын шул: Гөлнара аның эштән кайтуын дүрт күз белән көтә. Көне буена ялгызы ятып, йә ул урын-җиренә чәен түгә, йә башкасы белән пычрана. Кыл кыймылдатырлык хәлең калмаса да, аның өстен-башын алыштырырга, бит-кулларын юдырырга, кичкелеккә аш-суын әзерләргә кирәк була. Өстәвенә бу Кунак бик үк тыйнаклардан булып чыкмады. Үзенең «күчтәнәчләрен» өйнең теләсә кайсы җиренә салып китә. Бер карыйсың, идәндәге паласны юешли, икенче карыйсың, нәкъ синең юл өстеңә «чүмәләсен» өеп куя. Киим генә дисәң, чүәкләрең, башмакларың урынында булмый. Кайсын карават астыннан, кайсын шкаф артыннан эзләп аласың. Беркөнне идәнне пычрату гына җитмәгән, Гөлнараның өстеннән юрганын тартып төшергән. Балакай көне буе өстенә ябынмый ятып тәмам туңган. Әнисе кайтып кергәндә, ул дер-дер калтырый иде. Ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җиткән ана яңа гына аягыннан салган итеге белән этнең башына кундырды. Кунакка болай да ул соңгы вакытларда бик ачулы иде. Сабыр савытына бусы соңгы тамчы булды. Башына итек эләккән эт карават астына кереп өрергә тотынды. «Әле син ашаткан хуҗаңа өреп ятасыңмы?» — дип, ана өр-яңадан ярсып эткә ташланды.

— Әнием, кыйнама. Ул гаепле түгел, юрганымны ялгыш үзем төшереп җибәрдем, — диде Гөлнара, җан дустын якларга теләп.

— Кыйнап кына калмыйм, чыгарып атам мин аны, — диде ана. — Бөтен өйнең астын-өскә әйләндерде бит инде. Идәннең линолиумын тырнап ерткалап бетерде, стеналарда обой калмады. Караватыңа менгереп өйрәттең дә һәр көн өс-башыңны пычратып бетерә. Аның артыннан җыештырып йөрергә вакытым юк минем. Болай да икегә ярылырдай булып йөрим. Кертеп бирәм мин моны Булатның үзенә.

— Әнием, кертмә инде. Ул бит шундый матур, шундый акыллы...

— Акыллы, имеш. Акыллы җан иясе хуҗасына этлек эшләми. Оятсыз Кунак булды бу.

— Әнием, Кунакны бер юлга гафу ит инде. Яңадан ул болай тәртипсезләнмәс. Әйеме, Кунак?

Кунак, аңлаган кебек итеп, башын кыңгыр салды. Ялагайланып ана тирәсендә бөтерелгәли башлады. Аның ашыйсы килә иде.

— Барыгызга да ашарга кирәк, — диде ана. — Ә кибеттә, сезнең Кунагыгыз бар дип, артыгын бирмиләр. Тиешле өч кило итнең дә яртысына сөяк салган. Тәмам оятлары бетте бу сатучыларның. Шушыны ай буена җиткерергә кирәк.

— Әнием, син итле ашны көн саен пешермә, — диде Гөлнара, әнисен юатырга теләп. — Мин итне бик яратмыйм да әле. Телисеңме, ай буена мин гел сөтле аш ашап кына торам?..

— И, ачуымны китереп ятмасана, — диде ана. — Сөтле аш ашап торам, имеш. Әле итле аш ашатып та тәнеңдә чыпчык чукырлык ит юк. Бу дөньясын әйтер идем. Без яши башлагач кына бөтенесе кирегә китте. Ни алам дисәң, шул юк. Нәрсәгә тотынсаң, шул җимерелә. Җәфалар өчен генә яраткандыр инде безне Ходай бу дөньяга.

Гөлнара әнисен яхшы аңлый, әмма ярдәм генә итә алмый. Әлбәттә, Гөлнара башка кызлар кебек сәламәт булса, әнисе дөньяны бу кадәр каһәрләмәс иде. Бөтен хәсрәтнең башы — Гөлнара. Күрәсең, кайберәүләр дөньяга гел газапланыр өчен генә туалардыр. Әнә бит ишегалды тулы бала-чага, һәммәсе шат, чыр-чу килеп уйный. Уйнап туйгач, алар кереп әниләренә ярдәм итәләрдер. Кибетенә йөгерәләрдер. Этләре юешләгән җирне әниләре күргәнче тиз генә сөртеп алалардыр. Гөлнара Кунакны бик тәртипле итәр иде дә бит, юк шул, булмый. Шушы кечкенә көчекне тәртипкә өйрәтер өчен дә сәламәт булу, артыннан чабу, кисәтү кирәк. Әнә бит ул нинди тиктормас җан. Аңа теләсә нәрсәне тарткалап төшерү, аунатып йөрү кызык кына. Ул синең кычкырганыңа карамый: барасы җиренә бара, эшлисе этлеген эшли. Хәер, Гөлнара аңа ныклап ачулана да алмый. Әнисе өйдән чыгып китүгә, Кунакны үз янына чакыра башлый. Баштарак Кунак караватка менә алмый иде. Гөлнара әнисеннән карават кырыена бер эскәмия куйдыртты. Кунак башта шул эскәмиягә менә, эскәмиядән караватка сикерә. Кайвакыт чакырып-чакырып та килмәсә, Гөлнара аңа чын күңеленнән үпкәли. «Ярар, мин дә кирәк булырмын әле», — ди. Шуны аңлаган кебек, Кунак бераздан кыз янына менә, ялагайланып битләрен ялый. Һәм алар икесе бер мендәргә баш салып черем итеп алалар. Уянгач, Гөлнара Кунактан болай дип сорый: «Йә, сөйләп җибәр әле, нинди төш күрдең?» Кунак бер-ике тапкыр өреп куя. «Ә-ә, бүреләр килгән идемени, син шуларны куркытып җибәрдеңмени? Менә

нинди батыр икәнсең син. Ә беләсеңме, Кунак, син үскәч, чын эт булгач, мин сине урамга чыгарырмын. Син анда үзең кебек кара борынлы, кәкре койрыклы этләр белән уйнарсың. Яшел чирәмнәрдә аунарсың, чәчәкләрнең, агач яфракларының исен иснәрсең. Алардан нинди ис килә икән — кереп миңа сөйләрсең. Сиңа минем янда кызык түгелдер, әйеме? Бәлки әле, урамда йөрү тәмен белгәч, яңадан минем яныма кайтасың да килмәс. Син еракка-еракка китәрсең. Мине онытырсың». Кунак ләң-ләң итеп тагын бер-ике өреп куя. «Ә-ә, онытмам, дисеңме? Бик акыллы шул син. Синең йоннарың нинди йомшак, тәнең нинди кайнар. Синең бөтен җирең әйбәт, тик менә тәртибеңне төзәтергә кирәк иде бит. Әнине ачуландырмыйк инде без, яме. Аңа бит болай да бик авыр. Ул эштән арып кайта. Кайткач, безгә ашарга-эчәргә әзерли. Әгәр вакыт-вакыт әнием сиңа суга икән, син аңа рәнҗемә, яме, Кунак. Ул бит усаллыктан түгел. Сине ярата ул. Яратмаса, әллә кайчан куып чыгарган булыр иде инде».

Гөлнара Кунак белән шулай сөйләшә. Кунак күп вакыт тыңлап тора. Сирәк-мирәк кенә ләң-ләң дип сүз кыстыргалап куя.

Кунак Гөлнараның тормышына җанлылык кертеп җибәрде. Аның белән сөйләшеп, аның уйнаганын карап көннәренең узып киткәнен сизми башлады. Хәтта Гөлнараларга бик сирәк керүче күрше малае Булат та боларга еш кереп йөри торган булды. Булат үзе этләрне бик ярата, тик эти-әниләре аңа эт алырга рөхсәт итми. Гөлнараларга кергәч, Кунак белән уйнап рәхәтләнә. Кунак та аны сагынып көтеп тора. Күрәсең, этләргә дә аяклы кеше белән уйнау кызыклырактыр. Әнә бит ул Булатның балагыннан ничек эләктергән: өстерәлеп барса бара, әмма җибәрми. Булат аны идәндә ауната, сыртына салып корсагын кытыклый. Кунак ыһ-ыһ килеп көлә.

— Кара әле, — ди ул Гөлнарага. — Кунак көлә белә икән.

— Әйе шул, — ди Гөлнара. — Әнә авызын ничек матур ера. Көлү генә түгел, сөйләшә дә белә әле минем Кунак.

— Син бигрәк инде, — ди Булат, — шыттырам дигәч тә.

— Шыттырмыйм. Икәү генә калгач, әллә ниләр сөйли ул. Беркөнне үзенең күргән төшен сөйләде.

— Этләр төш күрә микән? — дип, җитди сорау бирә Булат.

— Әлбәттә, — ди Гөлнара. — Минемчә, этләр гел кешеләр төсле: уйлый, төш күрә, сөйләшә. Әнә бит ул шаярганда ничек шатлана. Ә ачулансаң, боегып кала. Шатлана, кайгыра белгәч, сөйләшә белми димени?!

Булат белән Гөлнарага бик рәхәт, бик күңелле. Ул, мәктәптәге кызыклы хәлләрне сөйләп, Гөлнараны көлдереп бетерә. Кызга мәктәп серле дөнья булып тоела. Аның мәктәпне бары тик телевизордан гына күргәне бар. Дөрес, укырга-язарга әнисе өйрәтте аны. Китапларны күп укый ул. Аңа аеруча табигать турында, төрле җәнлек-җанварлар турында язылган китаплар ошый. Телевизордан җәнлекләргә багышланган тапшыру булса, Гөлнара өчен зур сөенеч. Күрәсең, кеше күңеленә табигый матурлыкка сусау, шуңа омтылу ана сөте белән салынадыр. Кеше үзе дә кайчандыр табигатьнең иркәле баласы булган, ләкин ул тора-бара үзен-үзе кысан читлеккә япкан. Читлегенә матур-матур әйберләр тутырып, ирегең тагын да тарайткан. Гөлнараның җаны әнә шул тар читлеккә ябылырга теләмичә, әле тәрәзә аша урамга, әле телевизор экраны аркылы күз күрмәгән ерак сахраларга, урманнарга ашкына иде.

Ә Кунак көннән-көн үсте, матурланды. Күргән кешеләр аңа сокланып: «Кара инде моны, төлкең бер якта торсын, нинди матур!» — диләр. Кунак үзен мактауны аңлаган кебек сөенеп койрык болгый. Аеруча якын итеп үзенә иелгән кешеләрнең битләрен, борыннарын ялап ала. Ләкин, нәселе белән өй эте булмагангамы, тәртипкә өйрәнми, һаман «күчтәнәчләрен» теләсә кайда калдыра. Гөлнарага әнисе алдында бик кыен. Бүген Кунак бигрәк әллә нишләде. Гөлнараның кычкыруына да карамыйча, идән паласын пычратып китте. Гөлнара моңа бик үртәлде. Кунакны үз янына чакырып китереп каты-каты итеп колагын тартты. Кунак үпкәләп кухня ягына качты.

Гөлнара идән паласының пычранган җиреннән күзен ала алмады. Тылсымлы бер әйбер кебек ул аны гел үзенә тартты. «Хәзер әни кайтып керсә, Кунакны куып чыгарачак. Тагын күңелсез, ялыктыргыч ялгызлык башланачак. Их, Кунак, Кунак! Нигә соң син шулай тәртипсез икән. Бүтән вакытта бик акыллы бит син. Мин кычкырып китап укыганда, башыңны кыңгыр салып, аңлаган сыман, тыңлап торасың. Яхшы кешедән яманны аерасың. Гөлчирә түтине күрүгә, йоннарыңны ничек кабарта башлыйсың. Чөнки ул бөтен кешене сүгә. Безне дә: «Боларга шушы эт кенә җитмәгән иде инде. Үз пычракларын җыештырып бетерә алмаганны, эт алган булдылар», — дип һәр кешегә сөйли.

Их, Кунак, Кунак! Хәзер нишлибез инде, ә? Әни бит теге көнне үзеңне кисәтеп куйды: «Паласны тагын пычратсаң, куып чыгарам, үпкәләмә», — диде».

Гөлнара шулай үз-үзенә сөйләнеп ятканда, үпкәсен онытып Кунак килеп җитте, һау-һау дип, ни өчендер өрә башлады ул.

— Нәрсә? — диде Гөлнара, — ни әйтергә телисең?

— Һау-һау, — диде Кунак.
— Төшеп җыештыр, юкса аерылышабыз, дисеңме?
— Һау-һау.
— Эшләмиләр аны шундый этлекне.
— Һау-һау.
— Хәзер үкенәм, дисеңме? Соңыннан үкенүдә файда юк шул. Әллә төшеп карыйм микән? Бәлки, шуышып барып җитәрмен. Әни кайтканчы синең «күчтәнәчеңне» гәзиткә булса да җыеп ала алсам, бәлки, әни үзеңне куып чыгармас, ә?
— Һау-һау.
— Шулай итеп кара, дисең инде алайса. Ярар, карап карыйк.
Гөлнара тәгәрәп төшәргә җай эзли башлады. Иң элек, тәгәрәп төшкәндә йомшаграк булсын өчен, өстендәге юрганын идәнгә ташлады. Аннары аякларын берәм-берәм кулы белән үзенәрәк тартып китереп, аларны тездән бөкләде. Карават кырыенда тумбочка тора иде, аны читкәрәк этеп карады, тик тумбочка авыр иде, кузгата алмады.
«Ярар, әллә нәрсә булмас әле, — диде ул. — Караваты биеген биек инде. Әни аңа йомшак булсын өчен катлы-катлы матраслар түшәгән».
Гөлнара, суга чумарга җыенган кешедәй, күкрәген тутырып бер сулады да, булдыра алган кадәр көчле итеп, гәүдәсен түбәнгә ыргытты. Башта гәүдә, аннары аяклар идәнгә төште. Төшкән вакытта тумбочка торкасына чигәсе бәрелеп бик каты каный башлады. Әллә үз канынннан куркып, әллә каты бәрелүдән Гөлнараның һушы китте. Әнисе кайтып кергәндә, ул һушсыз килеш идәндә кан эчендә ята иде.
— И Ходаем, нәрсә булды? — диде ана һәм кызын күтәреп караватка салды. Бәла килгәнен сизенеп, эт чиный-чиный ананың аягына уралды. Ана ачуланып аны тибеп җибәрде: «Йөрмәле аякка уралып. Барысы да синең аркаңда».
Ана кеше Гөлнараның ни өчен идәнгә төшкәнлеген шунда ук аңлаган иде инде.
Кызын ул больницага салды. Хәзер, Гөлнара анда чакта Кунакны берәр яры олактырырга кирәк иде. Күрше тирәләренә әйтеп карады, ләкин алырга атлыгып торучы күренмәде. Таныш-белешләре аша эзләтә торгач, шәһәр читендә үз йорты белән торучы бер агай Кунакны үзләренә алып китте. «О-о, нинди матур! — диде ул, Кунакның йонынннан сыпырып. — Син миңа бик ярап куярсың әле. Сезгә бәя күтәрелде хәзер».
Ә Гөлнара янына килгән саен Кунакның хәлен сораша. Беркөнне ул:
— Әнием, Кунакны монда алып кил әле, бик күрәсем килә, — диде.
— Син нәрсә, кызым, — диде ана, — кем инде больницага эт алып килә? Монда керттермәячәкләр аны.
— Син бит шушында эшлисең, сиңа рөхсәт итәрләр әле, — диде Гөлнара. — Рөхсәт итмәсәләр, врачлар китеп беткәч, кич белән алып кил.
— Юк, юк, кызым. Булмастайны сорама. Менә терелеп кайткач...
Ана сүзен әйтеп бетермәде, кинәт кенә йөрәге кысып куйды. Гөлнара өйгә кайтып Кунакның юклыгын белгәч нишләр? Юкка биреп җибәрде бугай ул аны. Озак тотмаслар, Гөлнараны больницадан чыгарырлар. Терелми торган авыруларны монда бик озак яткырмыйлар.
Ана шулай хафаланып йөри башлады. Кунакны кире барып алыйммы әллә дип берничә мәртәбә омтылды, ләкин вакыты җитмәде. Ә ул арада Гөлнараның чире көчәйде, һәм ул, дөньяның барлык газапларын монда калдырып, үлеп китте.
Ана берьялгызы калды. Хәзер инде аның өе бер җыештырган килеш атналар буе тора. Һәр көн кызының керләрен юып бозылып беткән куллары да төзәлде. Әмма җанда әллә нинди ару, әллә нинди газап. Дөресен әйткәндә, аның җәфаланып яткан кызына карап: «Үлсә, бәлки, үзенә дә, миңа да җиңелрәк булыр иде», — дип уйланган чаклары булмады түгел. Инде менә кызы дөньяда юк. Аңа анда мондагыдан җиңелрәктерме, анысы караңгы, ләкин кызы үлү белән анага җиңеллек килмәде. Ананы бердәнбер дөньяда тотып торган нәрсә шушы кызы булган икән ләбаса. Кызының берәр йомышын үтәп, аны шатландыру, аның турында кайгырту үзе дөнья рәхәте булган икән. Бәхетне без күп вакыт үзебез шатлану, үзебезгә килгән уңыш дип уйлыйбыз. Кем өчендер яшәү, кемнедер сөендерү — үзеңә килгән сөенечтән һич ким түгел икән. Бәлки, әле артыгырактыр да.
Ана менә шуны аңлады. Шушыны аңлау аның ялгызлыгын тагын да караңгырак, күңелсезрәк итте. Һәм ул беркөнне, Кунакны кире үзләренә алып кайтырга дип, этне алып киткән кешеләргә китте. Кайчандыр кызының кулы кагылган, кызының назын яланына сеңдергән Кунак, һичшиксез, аның газапларын киметер кебек тоелды. Ләкин язмыш бәхетсез анага тагын бер мәртәбә каты итеп сугарга уйлаган булып чыкты. Кунакның тиресен теге бәндә өй стеналарына тарттырып кадаклап куйган иде.

## ЮГАЛГАН БАШМАК
## ҺӘМ ВАТЫЛГАН ВЕЛОСИПЕД

Кибеттә нидер алырга торганда: «О-о, Равил! Син ничек үскәнсең, настоящий егет булгансың», — дигән тавышка борылып карасам, артымда кайчандыр бергә укыган һәм артык шөкәтсезлеге аркасында бер малай белән дә дуслаша алмаган Флера басып тора. Әгәр өске иренендәге ясмык кадәр миңе күземә чалынмаса, Флераны танымас идем хәтта. Чибәрләнгән, тулыланган. Элек аның нечкә озын муенына утыртылган башы казыкка эленгән чүлмәк кебегрәк тора иде. Хәзер менә шушы муенга ит кунган. Әйтерсең ул күргәзмәгә куяр өчен ак мәрмәрдән эшләнгән гүзәл сын! Кайчандыр койма тактасыдай шома түшенә пар күгәрчен килеп кунган. Кыз әз генә хәрәкәтләнсә яки тирәнрәк итеп сулыш алса, бу күгәрченнәр очып китәр кебек тоела. Ә күзләр! Күзләр! Аңардан сибелгән нур көлтәләре сине әллә нинди сихри яктылыкка күмеп, җанга моңарчы татылмаган рәхәтлек бирә.

Минем шулай телсез калып үзенә текәлүемне күргәч, ул: «Әллә танымыйсың инде, Равил?» — дип, көмеш кыңгырау чыңлагандай матур тавыш белән көләргә тотынды.

— Әйе, — дидем мин, ниһаять, телгә килеп. — Сине танырлык кына түгел. Шөкәтсез үрдәк бәбкәсеннән гүзәл аккошка әйләнгәнсең бит син.

— И-и, шаяртма әле, Равил, — диде Флера, бераз чытлыкланып. — Безгә аккош булырга язмаган инде.

Теле белән Флера шулай дисә дә, күзләре, күзләре генә түгел, бөтен барлыгы, һәр хәрәкәте, хәтта ирен өстендәге миңенең вакыт-вакыт дерелдәп куюларына кадәр аның үз матурлыгын бик яхшы белүе һәм шушы матурлыгы белән мине шаккатырудан эчке бер ләззәт кичерүе хакында сөйләп тора иде. Без аның белән урамга чыктык.

— Безнең авылга килеп тә карамыйсың, — диде Флера, юк-барны сөйләнеп барган җирдән кинәт җитдиләнеп.

— Сезнең авылда ни бар соң? — дидем мин һәм шунда ук үземнең юләр сүз ычкындыруымны сизеп, иренемне тешләдем. Ләкин Флера минем бу урынсыз соравыма үпкәләмәде. Киресенчә, бераз шукланып:

— Безнең авылда мин бар, — дип куйды.

Мин шунда, үзем дә сизмәстән:

Сезнең авылда син бар,
Безнең авылда мин бар.
Йөзләреңне матурлаучы
Ирен өстеңдә миң бар, —

дип, ярым җитди, ярым шаярып бер шигырь әйтеп ташладым.

— Әллә шигырьләр язасың инде, Равил? — диде Флера, сөенечле гаҗәпләнеп.

— Юк, — дидем, — сине күргәч үзеннән-үзе телгә килде. — Бәлки, бу минем беренче һәм соңгы шигырем булыр.

Без ул көнне Флера белән районның байтак урамнарын таптадык. Күрешми торган бер елдагы вакыйгаларны сөйләштек.

— Кызлар белән йөри башлагансыңдыр инде, — диде Флера, сүз арасында. Мин, шаярып: «Безгә дигән кызлар мич алдында көл ашый әле», — дигән булдым. Ләкин үземнең күз алдыма күрше кызы — сары сипкелле Сәкинә килеп басты. Әйе, Сәкинә белән дуслык бар анысы. Ә минем аның белән «йөрүемә», мөгаен, Сәкинәнең абыйсы Мәхмүт сәбәпче булгандыр. Мәхмүт абый авыл клубында киномеханик. Мине күрүгә ул: «Әйдә, кияү, кер, бүген бик әйбәт индийский кино алып кайттым», — дип, клубка берсүзсез кертеп җибәрә. Кинода Сәкинә белән бергә утырабыз. Кайтканда бергә кайтабыз. Сәкинә минем өчен чын хәзинә. Атнага ике килгән киноның берсен дә калдырмыйбыз. Аннары шунысы әйбәт: Сәкинә күршедә генә тора. Әллә кая авылның икенче башына барып озатып йөрисе юк. Менә шулай мин расхутсыз, мәшәкатьсез генә кызлар белән йөреп маташам. Яшьтәшләр арасында дәрәҗәм зур. Мин үземне күптән чын егеткә санаймын. Әле менә Флера да: «Үскәнсең, настоящий егет булгансың», — дип мактап җибәргәч, түбә күккә тиде.

Флера белән аерылышканда, мин алар авылына барып чыгарга сүз бирдем. Сүз биргәч, әлбәттә инде, үтәргә кирәк иде. Ләкин ничек? Флералар авылы бездән утыз биш чакрым ераклыкта. Автобус дигән нәрсәләр йөрми. Җәяү барырга бик ерак. Кызлар артыннан алай еракка барып йөрергә өйрәнмәгән.

Әлеге дә баягы мине бу бәладән тагын Сәкинә коткарды.

— Нишләп әле балтасы суга төшкән карттай аптырап йөрисең? — диде ул, минем соңгы вакытта пошаманга төшүемне күреп.

— Ни бит... — дидем мин. — Димскәйгә барып кайтасы барые. Ничек барырга икән дим.

— Нәрсәң калган ул Димскәйдә? Берәр кызга гашыйк булмагансыңдыр бит?

Эзенә генә басты, җен кызы. Сизгерлеге бар. Әгәр ул бу минутта йөзгә караса, үзенең сүзе дөрес икәнне аңлар иде. Әмма мин, хәлемне сиздермәс өчен үпкәләгәндәй итеп:

— Син нәрсә? — дидем. — Безнең бит анда апалар тора. Шуларга барып кайтасы барые. Үләргә ята, ди.

Дөрестән дә, Димскәйдә безнең ерак апалар бар. Мин аларның безгә кайсы яклап кардәш икәнлекләрен генә белмим. Яши торган авыллары ерак булгач, бик аралашкан юк. Сәкинә сорамаса, ул апаларның барлыгы исемә дә төшмәгән булыр иде, мөгаен. Сәкинәгә: «Димскәйгә Флера янына барам», — димәссең бит инде.

Сәкинә, изге җан, ерак юлга чыгасымны белгәч, мине бик тиз юатырга тотынды:

— Кайгырма, Равил, берәр машина очрар әле. Телисеңме, мин Мәхмүт абыйның велосипедын сорап торам?

— Бирмәс шул ул, — дидем. Ә үземнең велосипед сүзен ишетүгә, күзләрем яна башлады. Шәп нәрсә инде ул каһәре. Безнең авылда әле велосипед өчәү генә. Шуның берсе Мәхмүт абыйныкы. Өр-яңа, ялтырап тора. Без Сәкинә белән Мәхмүт абый өйдә югында чирәмлеккә чыгып аның велосипедында йөрергә өйрәнәбез. Мин инде ярыйсы гына элдертәм. Хәтта алдыма Сәкинәне утыртып та йөри алам. Әгәр дә мәгәр Сәкинә абыйсының велосипедын сорап тора алса, бу бит Флера каршында мине янә бер буйга үстереп җибәрәчәк.

Әй, шәп кыз инде бу Сәкинә. Тәки абыйсын күндерде. Мин, үз абыемнан калган өр-яңа кәчтүм-чалбарымны киеп, Мәхмүт абыйның ялтырап торган велосипедына атландым да Флералар авылына — Димскәйгә сыптырдым.

Мәхмүт абыйдан кача-поса авыл урамын бер-ике ураганда бик җиңел тоелган велосипед бара-бара шактый авырайды. Мин мышнап төштем. Берничә урында туктап ял итәргә туры килде. Әмма: «Мин бит кызлар янына барам», — дигән уй озак утырырга ирек бирми иде. Хәер, унҗиде яшьлек чагында яшел чирәмдә бер минут аунасаң, тәнеңә бер көнлек көч керә.

Мин Флералар авылына барып җиткәндә, көтү кайтып килә иде. Шул вакытка туры килдем. Ялтырап торган өр-яңа велосипедка атланган фырт егетне бөтен кеше күрсен әле. Мөгаен, Флера да көтү каршына чыккандыр.

Як-ягыма карана-карана барам. Күңелдә аңлатып бетергесез тантана, күкрәккә сыймаслык горурлык. Димскәйнең бөтен кәҗә-сарыклары гаҗәпләнеп миңа карап кала. Флера өйләрен күпер төбендәрәк дигән иде, килеп җитәм бугай. Әнә анда күпернең теге ягында Флера түгелме соң? Шул бит, шул!

Мин, педальгә катырак басып, йөрешемне тизләтә төштем. Инде Флераның каршына килеп басам дигәндә, тыныч кына үтеп баручы бер бозау миңа таба борылды да велосипедым-нием белән чөйде дә ыргытты. Мин Флераларның тузанлы капка төпләренә барып төштем. Велосипедыма күз салуга, йөрәк урыныннан кузгалды. Чөнки өр-яңа велосипедның алгы тәгәрмәче сигезле санына әйләнгән иде.

Велосипедымның бөгәрләнгән тәгәрмәчен тотып Димскәйнең барлык бозауларын каргап утырганда, яныма Флера килеп җитте.

— Равил? — диде ул, әллә нинди ягымлы һәм гаҗәпләнүле тавыш белән. — Синме соң бу?

— Минием лә! — дидем мин, Флера алдында мескен хәлгә төшүемә гарьләнеп. — Менә бит велосипедны нишләтте дуңгыз бозау. Хәзер моны ничек төзәтергә инде!

Флера минем янга чүгәләде. Велосипедта нәрсәдер аңлаган кеше сыман кәкрәйгән тәгәрмәчне тотып караган булды. Ул арада көтү кайтып бетте, безнең тирәгә малай-шалайлар җыела башлады.

Шунда арада берсе:

— Безнең абыйның да бервакыт билсәпите шулай булган иде, — диде.

— Йә-йә?! — дидем мин. — Төзәтә алдымы соң?

— Төзәтте. Списләрен сүтеп алып кыршавын турайтты да куйды. Бернәрсәсе юк аның.

— Бар әле, үскәнем, абыеңа әйт, — диде Флера. — Монда килсен. Флера чакырды, диген. Тиз бул, яме!

Малай өйләренә элдертте һәм тиздән абыйсы белән килеп җитте. Абый дигәне минем белән бер чорлырак егет аламасы булып чыкты. Ул бер велосипедка, бер миңа каш астыннан караштырып алганнан соң, эшкә тотынды. Исеме Зәйтүн икән. Флераның бу егет аламасы тирәсендә: «Зәйтүн, Зәйтүн!» — дип бөтерелгәләп йөрүенә бик эчем пошты пошуын, әмма велосипед хакына түздем, сер бирмәскә тырыштым. Зәйтүн, минем кебек үк фырт егет булмаса да, кулы эшкә ятышлы икән. Караңгы төшкәнче тәки велосипедның тәгәрмәчен тәгәрәр хәлгә китерде.

Велосипед белән маташкан арада, Димскәйнең барлык егетләре Флералар капка төбенә җыелып беткән иде инде. Флераның әбисе тәрәзәдән башын тыгып: «Кызым, Флера, бәрәңге суына. Кер!» — дип кат-кат чакырса да, аның сүзенә колак салучы булмады.

Мин күптән күрешмәгән апамнарның өен табып, велосипедны аларга кайтарып куйдым. Апамнарда сөтле чәй эчеп, Флералар капка төбенә яңадан килгәндә, ул да әбисенең бәрәңгесе белән тамак туйдырып чыккан иде. Капка төбендәге олы ташка утырдык. Кыюланып кызның кулыннан тоттым. Аның кулы әкрен генә калтырый иде. Бу калтырау миңа да күчте. Шунда мин аны теге күрешкәннән бирле бер минут та истән чыгармавымны, төннәр буе гел аны уйлап ятуымны — барысын-барысын сөйләп бирергә теләп:

— Флера! — дип пышылдадым.

— Әү, Равил, — диде Флера, бары тик агач артына поскан җил генә ишетерлек итеп.

— Флера... — дидем мин янә, һәм әйтергә теләгән сүземне әйтергә базмыйча, — сезнең авылның көтүе зур икән, — дип куйдым.

Бу сүзләремнән соң Флераның минем учта яткан кулы тартылып куйды. Мин ахмаклыгымны аклар өчен акыллырак сүз эзләргә тырыштым.

— Флера!

— Әү, Равил.

— Синең әбиең ничә яшьтә?

Флераның кулы, оясыннан очып чыккан коштай, минем учтан чыкты. Мин бар кыюлыгымны җыеп тагын:

— Флера, — дидем. Ул баягыча «Әү» димәде. «Үпкәләттем» дип уйладым. Безнең сөйләшү ничек дәвам иткән булыр иде, белмим, ләкин шул вакыт безне Димскәй егетләре сырып алды. Күреп торам, болар минем кабырганы санап карамакчылар. Безнең үзебезнең авылда, мәсәлән, читтән килгән егетләрне өлешсез җибәрмиләр. Мондый очракта, әлбәттә, егетлек күрсәтеп маташуга караганда таюың яхшырак. Әмма таюның арты яман — кызыңның күзенә бүтән күренә алмаячаксың. Инде нишләргә? Озак уйлап торырга вакыт юк: егетләр мине Флералар коймасына кысканнан-кыса бара. Шул вакыт Флера: «Егетләр, карагыз әле, йолдыз атыла», — дип җибәрмәсенме! Егетләр һәммәсе берьюлы күккә карадылар. Ул арада Флера минем кулдан эләктереп алды. Без егетләр божрасыннан ычкынып йөгердек. Егетләр безне куа чыктылар. Әллә без артыгын шәп чаптык, әллә егетләр бик усал булмадылар, кемнеңдер ачык капкасы аша ишегалдына кереп кача алдык. Ишегалдында төз лапаска сөялеп куелган баскыч тора икән, шул баскыч буйлап лапас түбәсенә менеп киттек.

Төз лапас өстендә бер-беребезгә кысылышып озак утырдык. Урамда сирәк-мирәк җырлап кайтучы егетләр тавышы да басылды. Мин мәхәббәтемне белдерергә шушыннан да шәбрәк җай чыкмастыр дип, иң кайнар сүзләрне тезәргә дип авызымны гына ачкан идем, Флерам әллә нинди куркынган тавыш белән:

— Равил! — диде. — Минем аяктан сыңар башмак төшеп калган икән бит.

Флераның сүзләре минем аңыма барып җитми торды.

— Башмак? — дип сорадым, юләр кеше сыман.

— Әйе. Әбекәйнең башмагы иде. Әллә төшеп эзлибезме, Равил?

Минем бу әйбәт кунычадан һич төшәсем килми иде, аннары бит әле әйтергә теләгән сүзләр дә әйтелмәде. Утыз биш чакрым араны кеше велосипедларында килеп, кызга мәхәббәтеңне белдерми кит, имеш. Юк, булмас! Һич югы, бер кочаклап үбәргә тиеш мин аны!

Кыюланып китеп Флераны кочып алдым да ни булса булыр дип, үземә табарак тарткан идем, Флера:

— Их, башмак, — дип көрсенеп куйды, — табылса гына ярар иде. Әбекәйнең намаз укыганда гына кия торган башмагы иде бит.

Кызны кочаклаган кулларым аны җәлләүдән үзеннән-үзе язылып китте.

— Синең башмак кына әле, минем велосипед күрше абыйныкы иде, — дидем мин. — Хәзер мин аны ничек Мәхмүт абыйга кайтарып бирим инде? Никадәрле төзәтсәң дә, ул элекке хәленә килмәячәк.

— Бу башмакны әбекәйгә бабам Бөгелмә базарыннан апкайтып биргән, — диде Флера.

— Ә Мәхмүт абый велосипедны Октябрьск кибетеннән алган булган. Безнең бөтен авылга өч кенә велосипед. Шуларның иң яңасы Мәхмүт абыйныкы.

— Әбекәй әйтә, хәзер башмакларны рәтләп ясамыйлар, ди.

— Велосипед бит ул яшь тай кебек, атлануга алып чаба.

Без төз лапас өстендә менә шундый «мәхәббәт» сүзләре сөйләштек. Урамнар тынгач, башмакны эзләргә төштек. Ләкин таң атканчы йөрсәк тә, башмак табылмады. Сыңар башмагын тотып Флера өйләренә кереп киткәндә, аны чын күңелдән кызганып карап калдым.

Икенче көнне мин авылыбызга кайтып киттем. Велосипедымның алгы тәгәрмәче кылдый-былдый тәгәрәп йөрәгемне юл буе телгәләп кайтты. Әмма Мәхмүт абый ачуланмады.

— Булачак кияүне гафу итәргә туры килер инде, — диде ул, гадәттәгечә шаяртып. — Ничек соң анда, апаң терелгәнме?

— Апам?.. Ә-ә, әйе. Терелгән.

Берничә көн үтүгә, югалган башмакны эзләргә Флералар авылына тагын барасы килә башлады. Бу юлы инде велосипедны Мәхмүт абыйдан үзем сорарга булдым. Чөнки Сәкинә алдында бик оят иде миңа.

— Ни, Мәхмүт абый, Димскәйдәге апа тагын чирләп киткән. Велосипедыңны биреп... — Мин, сүземне әйтеп бетерергә дә куркып, Мәхмүт абыйга карадым.

— Алай-алай, — диде Мәхмүт абый. — Кулың шифалы булгач, барып терелтеп кайт инде алайса. Җәфаланып ятмасын.

Шулай итеп, Флералар авылына мин еш-еш «башмак эзләргә» бара башладым. Мәхмүт абый велосипедын биргәндә: «Апаңа миннән сәлам әйт», — дип, мыек астыннан елмаеп кала иде. Бераздан мин эшли башладым һәм үземә велосипед алып җибәрдем. Теге югалган башмакны эзли-эзли тагын бер велосипед туздырырга туры килде. Башмакны тапмадык табуын, әмма уртак мәхәббәтне таптык. Флера белән өйләнешеп ике егет үстердек. Хәзер инде үзебезнең улларыбыз кемнәрнеңдер авылында «башмак эзлиләрдер». Ә безнең башмакның югалмый калган сыңары иң кадерле истәлек булып сандык төбендә саклана.

## ӘЙТТЕМ БИТ

Сәгатен алмагач ботагында күрмәгәч, Гыйльми агарынып китте. Тиз генә як-ягына каранып алды. Бакчада аннан башка беркем дә юк иде. Рекс та, башын алгы тәпиләренә салып, машина күләгәсендә тыныч кына черем итеп ята. Гыйльми алмагачны селкеткәләп карады, төбендә үскән үләннәрне капшап чыкты, әмма сәгать юк иде. Шул вакыт Гыйльминең күзе койма буенда шыпырт кына кура җиләге ашап йөрүче күрше малаена төште һәм аның ачудан яңаклары кыйшаеп куйды.

— Әй, ташбаш, сәгатьне китер! — дип кычкырды ул.

— Ә-ә? — Малай гөнаһсыз күзләрен Гыйльмигә текәде.

— Сәгатьне китер, дим.

— Нинди сәгать ул, абый?

— Мин синең абыең түгел, фәрештә булып кыланма. Китер сәгатьне.

Малай аптырап җилкәләрен сикерткәләп алды, җиңе белән авызын сөртте. Моңа кадәр ирененә генә буялган кура җиләкләре аның битләренә үк буялды. Малай нindидер көлке кыяфәткә керде, әмма Гыйльминең көләргә исәбе юк иде. Ул торган саен ярсыйрак төшеп җикеренә бирде:

— Йә, нәрсә дип карап каттың? Алып чык сәгатьне. Ишетәсеңме?

Гыйльминең тавышына күршесе Зиннәт тә өеннән килеп чыкты.

— Ни бар, күрше? — диде ул, күзлеген сөртә-сөртә.

— Әнә синең ташбашың минем сәгатьне чәлгән.

— Нинди ташбаш? Нинди сәгать? Аңлатыбрак сөйлә әле, зинһар.

— Нәрсәсен аңлатып торасың инде аның. Менә бу алмагач ботагына, эшләгәндә пыяласы сызылмасын дип, килү белән сәгатемне элеп куйган идем, әле алыйм дип карасам, юк. Синең малай алмыйча, кем алсын аны.

Зиннәт кырыс кыяфәт белән улына карады.

— Син алдыңмы, Марат?

— Юк, әти. Мин бернинди сәгать тә алмадым.

— Бәлки, агач төбенә төшкәндер, ныклабрак карыйк әле.

Зиннәт Гыйльмиләргә керде. Алар икәүләшеп өр-яңадан алмагач тирәсендәге бөтен үләнне капшап чыктылар. Тырма тешенә ияреп чыкмасмы дип, тырма белән тырмап карадылар, тик сәгать барыбер табылмады.

— Чит кеше кермәде инде монда, — диде Гыйльми, — әгәр чит кеше керсә, безнең Рекс өрми калмас иде. Ул бары синең малайга гына өрми.

Гыйльминең сүзләрендә хаклык бар иде, әлбәттә. Рекс бик усал эт. Бакчага ят кешене кертү түгел, ул тирәдән берәрсе үтә башласа да, дөнья кубарып өрергә тотына иде.

Зиннәт әйтер сүз таба алмыйча тирләп чыкты. Аның улы Маратның бер дә андый гадәте юк иде бит. Бервакыт әле урамнан кәшилүк табып, айлар буе шуның хуҗасын эзләп тә йөргән иде. Юк, юк, Марат андый эшкә бармас.

— Сәгатең нинди иде соң? — диде Зиннәт, аптыраганнан.

— Нинди дип, гади электрон сәгать иде инде. Тик бит эш сәгатьнең нindилегендә түгел. Нинди булса да, ул минем әйберем, ә мин үз әйберемне синең малаең урласын өчен алмадым.

Гыйльминең бу сүзләреннән соң Зиннәтнең муен тамырлары бүртеп чыкты. Ул бакчада нишләргә белмичә йөргән малаена кычкырды:

— Марат, кер әле монда.

Марат купкан койма арасыннан яны белән генә шуып болар янына керде.

— Йә, — диде аңа әтисе, — күзләремә карап әйт, син алдыңмы Гыйльми абыеңның сәгатен?

— Юк, әти, мин бернинди дә сәгать алмадым.

Марат, еларга җитешеп, әтисенә карады.

— Мин алдым дип әйтерлек булгач урламый да инде ул аны, — диде Гыйльми. — Яле, кесәләреңне күрсәт әле.

Марат кесәләрен әйләндереп салды. Аның бер кесәсеннән сыңар ябе сынган пәке, икенче кесәсеннән папирос кабы килеп чыкты. Моны күргәч, Зиннәтнең чәчләре үрә торгандай булды.

— Ә-ә, син тартасыңмыни әле? — диде ул һәм озак уйлап тормыйча улының яңагына чабып җибәрде. Марат әтисенең бервакытта да мондый ярсулы чагын күргәне юк иде, яңагы авыртканын да тоймыйча мөлдерәп әтисенә карады. Әтисенең күрше Гыйльми абый янында гаепле кешедәй бөтерелеп йөрүе ничектер кызганыч иде. Ул, әтисен юатырга теләп:

— Юк, әти, мин тартмыйм, — диде.

— Тартмагач, синең кесәңә каян килеп кергән ул?

— Коробкасы матур булгач, юлдан алган идем, аның эче буш, әти. Менә...

Марат папирос кабын аерып әтисенә күрсәтте. Зиннәт, артык кызып китүенә кыенсынгандай, бер улына, бер аның кулындагы буш папирос кабына карады. Ә Гыйльми исә Маратның кесәсеннән папирос кабы чыгуга шатланып:

— Менә бит, — диде, — әле син аның тәмәке тартуы турында да белмәгәнсең. Без үзебез дә белмәгән килеш балаларны якларга тотынабыз. Ул алай итмәс, тегеләй итмәс, дибез. Ә алар әллә нишләп йөриләр, безнең башка да килмәгән явызлыклар кылалар. Аннары бандитлар, хулиганнар каян килеп чыга икән дип аптырыйбыз.

— Юк, юк, моның булуы мөмкин түгел, — диде Зиннәт. — Мин үз улыма ышанам.

— Ышану-ышанмау анысы синең эш, әмма иманым камил — сәгать сездә. — Ул шулай диде дә ачу белән җиргә төкерде. Бу төкерек Зиннәтнең йөзенә тимәсә дә, ул кул аркасы белән йөзен сыпырып алды.

— Ярар, — диде ул аннары, — сәгать баш бәясе әйбер түгел, алып бирербез.

— Ә миңа үземнеке кирәк, үземнеке! — диде Гыйльми. — Кулымдагы сәгатькә караган саен минем үземне гаепле сизәсем килми. Кара син боларны — нинди киң күңелле кешеләр! Имеш, яңаны алып бирәләр. Бирми генә торыгыз әле. Минем үз искем бик кадерле.

Ике күрше арасында шушы көннән салкынлык башланды. Зиннәт үзенең дачасына Гыйльми килмәгән көннәрдәрәк килергә тырышты. Гыйльми исә Зиннәтләрнең койма аша бу якка чыгып үскән чия ботакларын кыркып төшерде. Ике арадагы купкан коймаларны ныгытты. Ә бервакыт көз көне алар ничектер бергә туры килделәр. Зиннәт алмагачларының артык ботакларын кисеп йөри иде. Гыйльмине күргәч, исәнләшми кала алмады. Тик Гыйльми аның сәламен җавапсыз калдырды. Зиннәткә кинәт авыр булып китте, ул, Гыйльмиләр ягына карамаска тырышып, шарт-шорт ботаклар кисте. Шунда аның күзе алмагач ботагы арасындагы бер ояга төште.

— Саескан оясы! — диде ул, сукранып. — Ел саен шушында оялый, тапты җайлы урын.

Зиннәт көрәк сабы белән бу ояны бәреп төшермәкче булган иде, оя алай тиз генә кубарга теләмәде. Зиннәткә, баскыч алып килеп, ояны кулы белән куптарып алырга туры килде. Зиннәт ачу белән саескан оясын җиргә тондырды. Шул вакыт оядан ниндидер ялтыравык тимер-томырлар коелды. Зиннәт гаҗәпләнеп җирдә таралып яткан әйберләргә карады.

— Карале, — диде ул аннары, үзе дә сизмәстән, — бу безнең яз көне югалган көмеш чәнечке түгелме соң? Шул бит, шул! Ә бусы нәрсә? Бизәкле чынаяк ватыгы.

Зиннәтнең күңеленә шул вакыт ниндидер уй килде: ә бәлки...

Ул тиз-тиз ояны актарырга тотынды. Оя төбендәге мамыклар җил белән һавага күтәрелделәр. Мамыкның кайберләре Зиннәтнең тузгыган чәченә кунды, ләкин ул аларны сыпырып төшерергә дә онытып, оя төбен актаруында булды. Менә бермәлне аның кулы бер шома нәрсәгә тиде. Зиннәт күпмедер вакыт хәтта кулын оядан тартып алырга куркып торды. Әйе, оя төбендә Гыйльминең сәгате иде. Зиннәт аны уч төбенә салып озак кына карап торды. Чыпчык борыны кадәр шушы нәрсә аларга күпме күңелсезлек китерде. Улы Марат хәзер бакчага аяк та басмый, Зиннәт үзе юктан кызып китә торганга әйләнде. Инде, ниһаять, өстән авыр йөк төшәр. Күршесе белән аралар җылынып. Гыйльми үзенең ялгышын аңлап гафу үтенер.

Зиннәт балаларча җитезлек белән койма аша сикереп Гыйльмиләргә керде.

— Күрше, әй, күрше!

— Нәрсә бар? Әллә лотереяга машина оттыңмы? Бик канатлангансың.

— Машина нәрсә ул, — диде Зиннәт, — машинадан зуррак нәрсә таптым әле мин монда. Менә кара...

Зиннәт учын ачып Гыйльмигә таба сузды.

— Саескан оясыннан килеп чыкты. — Зиннәт сәгатьне Гыйльминең учына салды. — Менә бит, ә, кем уйлаган саескан шундый этлек эшләр дип... Мә, бүтән югалтма. — Зиннәт, сөенечтән балкып, ничә айлардан соң беренче мәртәбә күршесенең күзләренә карады.

— Әйттем бит мин сәгать сездә генә дип, — диде Гыйльми, сәгатьне учында сикертә-сикертә. — И шулай булды да.

Янып торган учакка чиләге белән шакшы су тондыргандай, Зиннәтнең йөзендәге елмаю кинәт сүнде. Ул җиңел генә сикереп кергән койманы чыга алмыйча азапланып бетте. Берничә минут эчендә ике арадагы койма гүяки коточкыч биек булып үскән иде.

**ЭЧТӘЛЕК**

**Әкиятләр**
Йолдыз тапкан кыз
Яралы торна
Урман әкияте
Яз кайда кышлый?
Тылсымлы ачкыч
Кызыл алма
Хәким урманы
Ак каз
Зәңгәр күлдә Ай коена
Кояштагы тап
Канатлы ат
Рәссам кыз
Биюче бака
Акайкүз
Кыядагы ояда
Иң бәхетле көн
Хәтерсез күке
Юылмас хурлык
Алсу чәчәк
Иң ошаган бүләк
Карачкы
Хыялый чебеш
Үлемсез эт
Карлыгач, Акколак һәм Тычкан
Салпыкикрик һәм велосипед
Ике чәчәк
Пеппи
Кара бәхет
Бер ярлы белән бер бай
Имеш-мимеш
Буар елан
Йокыбай
Бер малай һәм ике урындык
Тиен малае Тим-Тим
Сөрмәкүз
Бөкре урман сакчысы
Яңа ел төнендә

**Әкият-пьесалар**
Исемсез кыз
Хәзинә
Каракның бүреге яна
Бәхет ачкычы
Баз бакасы
Бүре белән Төлке
Әмәк белән Шәмәк

**Повестьлар**
Язмышлар язылганда
Яшел утрау хуҗалары

**Хикәяләр**
Ачсаң күңел тәрәзәләрен
Тыкрык янындагы өй
Лаеклы кияү
Туган көн бүләге
Кунак
Югалган башмак һәм ватылган велосипед
Әйттем бит

Литературно-художественное издание

***Яруллин*** *Фанис Гатауллович*

**ПРОИЗВЕДЕНИЯ**

В трех томах
Том 3

Казань. Татарское книжное издательство. 2008
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Яруллин*** *Фәнис Гатаулла улы*

**ӘСӘРЛӘР**

Өч томда
3 том

Мөхәррире *Р.М.Касыймова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Р.Н.Шакирова, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 19.11.2007. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 22,68.
Шартлы буяу-оттиск 23,10. Нәшер-хисап табагы 25,05. Тиражы 2000 д. Заказ К-11.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.